Сафа Сабиров

# АЛТЫН БАЛДАКЛЫ АБЫСТАЙ

ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯЛӘР

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2 Рос = Тат) – 4
С 12

**Сабиров Сафа**

Алтын балдаклы абыстай: Повесть, хикәяләр.– Казан: Татар.кит.нәшр., 2004.– 368 б.

Китапка саф күңелле асыл затларыбыз – татар хатын-кызларына багышланган, аларның шатлык-кайгылары, якты хыяллары, йөрәк серләре тасвирланган повесть, хикәяләр туплап бирелде.

ISBN 5-298-01412-7

© Татарстан китап нәшрияты, 2004

*Документаль повесть*

# Алтын балдаклы абыстай

## АВТОРДАН

Хәрби диңгез флотында хезмәт иткәндә, утыз сигезенче елның көзендә, мин Владивосток порты эшчесе Шакир исемле бер агай һәм аның хатыны Фәгыйлә апай белән танышкан идем. Хезмәттән буш көннәрдә аларга барып-килеп тә йөри башладым. Казанда бергә укыган дус кызым килеп төшкәч, без өйләнештек һәм өч ай аларда фатирда тордык. Үз куышыбыз булганнан соң да җиде ел дәвамында дусларча йөрешеп яшәдек, сугыш вакыты кыенлыкларын үзара ярдәмләшеп бергә үткәрдек.

Фәгыйлә апай иренә караганда зыялы, укымышлы, әдәбият белән кызыксынучан, базарда очраса, гарәп хәрефләре белән язылган иске китаплар алып кайта, гомумән дә укырга ярата, Тукайның күп кенә шигырьләрен яттан белә, шагыйрьне еш телгә ала иде. Сөйләшә торгач, сүз арасында мин аның кайчандыр Тукай белән шәхсән таныш булганлыгын, уникенче елның җәендә Троицк шәһәреннән ерак түгел казакъ даласына кымыз белән дәваланырга килгән авыру шагыйрьгә ике ай ярым дәвамында аш-су пешереп торганын, керләрен юганын, ара-тирә аның белән сөйләшеп утырганын да белдем.

Дөресен әйтим, моны белү миңа бик кызык, бик мөһим тоелды. Ул вакытта әдәбият дөньясыннан ерак торсам да, җай чыккан саен, Фәгыйлә апайдан сораштырып, ул сөйләгәннәрне истәлек дәфтәремә терки бардым.

Бөек Ватан сугышы вакытында Владивосток янындагы хәрби-һава частена очучы һәм шагыйрь Салих Баттал килде. Аның белән мине «Калинин» крейсеры тупчысы Локман Бадыйкшанов таныштырды. Шуннан бирле Салих абый, бер көнлек коры азык паегын кыстырып, безгә куна килгәли башлады... Тиздән мин аны Фәгыйлә апайларга алып бардым.

Революция елларында һәм азактан да күптөрле нахак гаепләүләргә, допросларга дучар булган Фәгыйлә апайга погонлы офицер Салих Баттал шикле тоелды бугай. Беренче очрашуда әңгәмәбез теләгәнчә җанланып китә алмады. Тик бераздан, якынрак танышкач кына, Фәгыйлә абыстайның теле чишелде. Тукай белән очрашкан көннәрне кабат кичергәндәй, гадәтенчә дулкынланып сөйләде. Аның хатирәләренең Тукай белән бәйле өлешен язып, без кырык икенче елның башында Казанга Татарстан Язучылар союзы идарәсенә җибәрдек.

Дүрт ай чамасы вакыт үткәннән соң, Казаннан С.Баттал исеменә җавап килде. Кыскача эчтәлеге түбәндәгечә иде:

*«Шагыйрь Г.Тукайның рәсми расланган, дәреслекләрдә басылган тулы биографиясе бар. Кайчан кая барганы, кайда күпме торганы, кемнәр белән очрашуы, ниләр сөйләшүе – барысы да замандашларының истәлекләреннән билгеле. Троицк шәһәре янында казакъ даласында булуын раслый торган бернинди дә чыганак юк.*

*Аннары заманында Тукай шигырьләренә охшатып язучы дилетантлар, халык арасында хәтта «Мин – Тукай» дип йөрүче самозванецлар да булуы билгеле. Сезгә бу вакыйганы сөйләүче ханым да әнә шундый махинаторга тарыган булса кирәк. Шунлыктан сезнең бу язганнарыгызны чын реаль факт дип кабул итеп булмый».*

Әмма аңа карап Фәгыйлә апайның авыр тормыш юлы, Г.Тукай турындагы хатирәләре минем башымнан чыкмады, һаман хәтердә сакланып, миемне өзлексез «бораулый» килде. Ул хакта мин, илле сигезенче елның башында Мәскәүдә нәшрият хезмәткәрләре курсында укыганда, шагыйрь Әхмәт Фәйзигә дә сөйләдем.

Аның «Тукай» романының икенче томын яза башлаган вакыты иде. Ул мине игътибар белән тыңлады, сораштырды. Тукай Троицк шәһәренә мулла Рахманкулов чакыруы буенча барган, шул хакта ул үзе гәзиттә язып та чыккан, ә Казан кызыл авызлары шул мулланы Тукайга ярдәмче итеп күрергә теләмәгәннәр булса кирәк, диде.

Берничә көннән тагын очрашып сөйләшкәндә, Әхмәт абый миңа: «Ул әби исән вакытта тизрәк, икәү бергә Владивостокка барып, аны ничек тә күрергә, җентекләп сөйләтергә кирәк. Юл расходларын Язучылар союзы түләмәсә, үзем түләрмен. Бу миңа бик мөһим», – диде.

Үкенечкә каршы, бу ният гамәлгә ашмый калды. Әхмәт абый тиздән каты авырып китте һәм җәй уртасында, Казанга кайтып, Аккош күлендәге язучылар дачасында вафат булды.

Хәер, Фәгыйлә апай белән очрашуны Салих абый Баттал да онытмаган, ерак Владивостоктан Язучылар союзы идарәсенә җибәргән хат караламасын машинкада бастырып алган булып чыкты, шуның бер нөсхәсен миңа да бирде. Ул нөсхәне миннән шагыйрь Әхмәт Исхак алып торды. Чөнки аның либретто өстендә эшләгән, композитор Әнвәр Бакиров белән бергә Тукайга багышлы опера язып йөргән чагы иде. Аларның ул эшләре никтер барып чыкмады. Әхмәт абый алган нәрсәне кире кайтарып бирмичә үлеп китте.

Салих абый Батталның исә, тар милләтчелек карашы өчен дип, партиядән чыгарылган бик кәефсез вакыты иде. Шунлыктан булса кирәк, ул бу эштә бөтән катнашырга кыймады шикелле.

Мәгълүм ки, Тукайга азмы-күпме ярдәме тигән замандашларын ихтирам белән искә алабыз. Ә кара реакция вакытында авыру шагыйрьне курыкмыйча казакъ даласына кымыз белән дәваланырга чакырып китер-

гән, аңа уңай шартлар тудырган, аның иминлеге турында кайгырткан Рахманкулов Габдрахманны әдәбиятчылар арасында җылы сүз белән телгә алучы да юк. Хәтта, киресенчә, яманлаучылар да булган. Г.Ибраһимов, мәсәлән, үзенең егерме бишенче елны чыккан «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» дигән китабында башка иттифакчылар белән беррәттән, Рахманкуловка да «буржуаз милләтче» дигән мөһер сугып үтә.

Әнә шундый каршылыклы мөнәсәбәтләргә карамастан, ерак Тын океан буенда Фәгыйлә апай белән очрашу минем күңелемдә һәмишә онытылмас якты хатирә булып саклана. Мин ул хакта Г.Тукай истәлегенә багышланган кичәләрдә, әдәбият сөючеләр белән очрашуларда еш сөйлим, кешеләрнең кызыксынып тыңлаганнарын күрәм. Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның әлегә тикле беркайда яктыртылмаган соңгы сәфәрен, замандашы Фәгыйлә апай сөйләгәннәрне һәм аның үз башыннан узган гыйбрәтле маҗараларны киң катлау укучылар игътибарына тәкъдим итәргә булдым.

* * *

Мин беренче мәртәбә күреп танышканда, Фәгыйлә апай инде кырыклардан узган, әмма үзе әле һаман яшьләрчә төз буй-сынлы, җиңел сөякле, тиз аралашучан, ачык чырайлы бер ханым иде. Тик шунысы сәер, бистә мөселманнары аны үзара никтер Алтын балдаклы абыстай дип йөртә иде.

Абыстай дип гадәттә мулла, мәзин хатыннарына, балалар укытучы мөгаллимәләргә генә ихтирам белән, олылап мөрәҗәгать итә торган булганнар. Ә хәзер, революциядән соң, бу сүзләр ничектер гайре табигый яңгырый, Фәгыйлә апайдан астыртын көлү, кимсетү кебегрәк тоела. Болар гына җитмәгән, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, хәтта бармагына алтын балдак киеп йөрүен гайбәт итүчеләр дә бар. Минемчә, монда нииндидер аңлашылмаучылык, гаделсезлек бардыр сыман.

Бу хакта мин Фәгыйлә апайның кылларын да тартып караган идем. Әмма ул моңа әллә ни игътибар итмәде бугай, берни дә әйтмәде. Үз уйларына чумган хәлдә, сүзсез генә йөри бирде.

Шулай да беркөнне икәү самавыр янында тәмле пәрәмәч белән чәй эчеп утырганда, ул сүз арасында, көтмәгәндә нидер хәтерләгәндәй:

– Бүген иртән синең теге соравың башыма килде дә кинәт аптырап калдым әле,– дип әйтеп куйды.– Минем баштан үткәннәрне көн-төн өзлексез сөйләсәң дә, очына чыгарлык түгел. Аларны искә төшерсәм, бәхетсез яшүсмер елларым, авыру Тукайның бездә булган көннәре; аннары менә бу алтын балдак аркасында күргән бәла-казалар, эзәрлекләү, җәберләүләр – һәммәсе дә кабат баштан кичергән кебек күз алдыма килеп баса. Йөрәгем әрни, сулышым кысыла башлый.– Фәгыйлә апай дулкынланудан тынып калды. Савыт-сабаны җыештыргач, өстәл янына килеп утырып, гадәтенчә ашыкмыйча сөйләвен дәвам итте: – Мин мөгаллимнәр гаиләсендә туып үстем, унике яшькә хәтле шунда үзебездә укыдым. Безнең Пүчинкәдә мәктәп булмаганлыктан, эти фатирыбызның ал ягында төшкә хәтле малайларны, әнием өйләдән соң кызларны укытты. Шуның өстенә бушрак вакытларда дәрес биреп, алар мине дә киләчәктә мөгаллимәлеккә имтихан тотарга әзерләргә тырышалар иде. Тормышыбыз бик мулдан булмаса да, болай әйбәт кенә яши идек. Икесе дә яраткан эшләреннән канәгать. Аларның бердәнбер иркә тае – мин дә бәхетле идем.

Гөнаһ шомлыгына каршы, эпидемия вакытында алар икесе дә бер атна эчендә ваба чиреннән вафат булды. Унөч яшемдә берьялгызым ятим калдым. Кытлык вакыт. Ачтан үлмәс өчен еш кына хәер сорашып җан асраргa, кайда туры килсә, шунда кунарга туры килә иде.

Шундый авыр көннәрнең берсендә күрше авыл базарында мәрхүм этидән калган хәтфә кәләпүшне биш кадак арыш онына алмаштырып, көзге пычрак юлдан кайтып барганда, мине җигүле тимеркүк ат узып китте. Тарантаста байларча киенгән өлкән яшьләрдәге ирле-хатынлы бер пар утыралар иде. Тышкы кыяфәтләре белән безнең мөселман әһеленә охшаганнар, йөзләрендә иман нуры бар шикелле. Миңа таба карый-карый нәрсәдер сөйләшәләр кебек тоелды.

Шагыйрь Габдулла Тукайның күңелемә сеңеп калган:

«Шат яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы» дигән сүзләрен авыз эченнән көйләп бара идем. Ирексездән: «И Раббым, дөньяда нинди рәхәттә һәм шул ук вакытта коточкыч михнәттә яшәүче бәхетсез адәмнәрең бар», – дип нәүмизләнеп артларыннан карап калдым.

Мәгәр алар ерак китмичә никтер туктадылар. Кызгандылар бугай, чакырып алып, мине тарантаска утырттылар. Сораша торгач, абзый кеше минем мәрхүм этиемне якыннан белүче булып чыкты.

– Әйбәт мөгаллим, милләтпәрвәр мөселман иде, авыр туфрагы җиңел, урыны җәннәттә булсын, ә син игелекле, тырыш кыз булып үс, – дип кызганды һәм, садака итеп, бер тәңкәлек көмеш акча бирде. Ә карчыгы, авыз эченнән дога укый-укый, башымнан сыйпады.

Көнозын аягөсте йөреп бик алҗыган, ачыккан идем. Тарантас читендә сөялеп утырган җирдән оеп йокыга киткәнмен һәм үзебезнең Пүчинкә яныннан үткәнебезне сизми калганмын. Мин уянып күземне ачканда, инде кичке эңгер куерып килә, ат тугарылган, тарантас ишегалдындагы ике катлы йорт болдыры каршында тора иде. Онлы капчыгымны култык астына кыстырып, тиз генә ыч-

кынмакчы булсам да, хуҗабикә мине җибәрмәде. Вакыт соң инде, караңгы төште, дип, кунарга калдырды. Тамак туйганчы ашаган-эчкәннән соң, өйнең аскы катында хезмәтче түти белән бер бүлмәдә буш караватка урын җәйдереп, мине шунда төн кунарга калдырды.

Ә иртәгесен мин уянганда, шактый өлкән яшьләрдәге хезмәтче хатын, авыр сулый-сулый, нидер эшләп йөри иде. Тиз генә торып, аңа булыша башладым. Икәү бергә өйалды тәрәзәләрен, идәнне юып чыгардык: өске катка менә торган баскычның паласын чыгарып селкедек. Шулчак үз бүлмәсеннән чыккан хуҗабикә, минем җиң сызганып эшләгәнемне күрү белән: «И, эш сөючән уңган кыз икәнсең», – дип мактап алды. Хезмәтче хатын да мине мактап берничә җылы сүз әйтте.

Шуның уңай тәэсире тиде бугай, иртәнге аштан соң, онлы капчыгымны алып һәм барысы өчен дә рәхмәт әйтеп, Пүчинкәгә кайтырга кузгалгач, хуҗабикә мине туктатты да:

– Фәгыйлә кызым, менә нәрсә: әгәр үзең разый булсаң, без сине асрауга алырга телибез, – диде. – Ялгыз башың мохтаҗлыкта ач-ялангач җәфаланганчы, бездә тамагың тук, өстең бөтен булыр. Хезмәтче апаңа булышырсың. Икәү бергә шул бүлмәдә торырсыз. Берничә елдан, балигъ булгач, күз күрер, нишлисен үзең хәл итәрсең.

Ярдәмчел хуҗабикәнең бу киңәшенә шундук күнеп, мин аларда асрау кыз булып калдым һәм башка хезмәтчеләр белән беррәттән һәртөрле йорт эшләрендә катнашып, моңарчы күрмәгән-белмәгән бөтән мохиттә яши башладым.

Шәһәрдән егерме чакрым читтә, кечерәк кенә чишмәле матур үзәнлектә урнашкан бу утар – безнең хуҗабыз Әхмәтҗан агай биләмәсе. Ул шәһәр мулласы белән кәсептәш. Хәзрәт үзе гел дин, мәчет, мәдрәсә, мөтәвәллият мәшәкатьләренә чумганлыктан, ширкәт эшләре белән күбрәк Әхмәтҗан бай шөгыльләнә икән. Хуҗабикәбез Әсмабану абыстайның сәламәтлеге шәптән түгел, тыны бетүдән зарлана. Ун яшендә йөрәк авыруыннан гүр иясе булган мәрхүм кызын сагынып еш искә ала, юксына. Шуңа күрә булса кирәк, ул мине үз баласы кебек якын итә, Фәгыйлә кызым дип йөртә. Кайдадыр ерак шәһәрдә укучы улыннан хат килсә, күзләрем начар күрә, дип, кабат-кабат миннән укыта.

* * *

Кече яшьтән хезмәт эчендә кайнап, өй мәшәкатьләрендә әнкәсенә булышып үскән Фәгыйлә яңа урында да, кушканны көтмичә, һәр эшне үзе белеп, җиренә җиткереп башкара. Һәрчак таләпчән, әмма киң күңелле, гадел Әсмабану абыстайның ышанычын акларга тырыша. Авыр югалту хәсрәтеннән акрынлап арына төшкәч, чандыр яшүсмер кызчык аш-суга мул тормышта яши башлагач, зифа буйлы, төскә-биткә чибәр мөлаем кыз булып үсеп җитлегә. Эштән буш араларда Әхмәтҗан байның китапханәсендәге әдәбиятны, газета-журналларны караштыргаларга да вакыт таба. Ул бигрәк тә яраткан шагыйре Габдулла Тукай әсәрләрен бирелеп укый, аның күп шигырьләрен, әкиятләрен бер укудан күңеленә сеңдереп, эш арасында авыз эченнән көйләп йөри.

Фәгыйлә монда тора башлауга тугыз ай чамасы үткәннән соң, җәй башында Әхмәтҗан байның ерак шәһәрдә укучы улыннан килеп төшкән хатыннан тиздән аның җәйге каникулга ялга кайтачагы мәгълүм була. Шуның өстенә Әхмәтҗан агай тагын бер көтелмәгән хәбәр алып кайта: шәһәр мулласы Габдрахман хәзрәткә Казаннан бер авыру мөгаллим килгән, тиздән шул монда кымыз эчеп дәваланырга рәхим итәчәк, имеш. Габдрахман хәзрәт аны мөмкин кадәр кадерләп тәрбияләүне, савыктыру өчен кулдан килгәннең барысын да эшләүне бик үтенгән. Тырышыгыз, савыктырсагыз, саваплы булырсыз, дип әйткән.

Шул сөйләшүдән соң утарда кадерле кунакларны каршыларга ашыгыч рәвештә хәзерлек эшләре башланып китә. Хәер, шәкерт егет бүлмәсенә әллә ни кирәк түгел, хуҗасы әлерәк кенә чыгып киткән кебек, анда һәрнәрсә бар, һәрнәрсә үз урынында, тәртиптә. Ә аның күршесен, авыру мөгаллимгә дигән буш бүлмәне рәткә кертү өчен, Әсмабану абыстай белән Фәгыйләгә шактый тырышырга, көнозын маташырга туры килә. Бигрәк тә тәбәнәк мичкәдәге кыяклы фикус һәм түшәмгә сузылган үрмәле гөлне әйбәтрәк итеп урнаштыра алмыйча аптырап бетәләр.

Хәер, бик ашыкмаска да мөмкин булган икән. Кунаклар өч көн үткәч кенә кайтып төштеләр. Алар шәһәрдә Габдрахман хәзрәт өендә очрашып танышканнар, шуның кучеры аларны утарга китереп куйды. Шәкерт егет, әтисе кебек буйга сузан булса да, төскә-биткә күбрәк әнисенә тартым, җыйнак кына почык борынлы, очлы иякле, җитез хәрәкәтле. Әнисе болдырда күренүгә, аны каршы барып кочаклады, маңгаеннан үбеп, хәл-әхвәлен сорашты. Аннары әтисе белән ике куллап күреште.

Аның белән килгән кунак мөгаллим уртачадан тәбәнәгрәк буйлы, чандыр гәүдәле. Сәламәтлеге шәптән түгеллеге күренеп тора, яңаклары суырылып кергән. Ул кара тужурка, тар читле соры эшләпә кигән. Какча йөзле булгангамы, тышкы кыяфәте белән бераз яшүсмер шәкерткә охшаган иде.

Әхмәтҗан абзый аны олылап каршылады һәм, хәл-әхвәл сораштыра-сораштыра, өске катка үз бүлмәсенә озата менде.

Кунаклар юлдан соң юынып, өс-башларын алмаштырып, аш бүлмәсендә табынга җыелгач та, мөгаллим гел ихтирам үзәгендә булды. Әле берсе, әле икенчесе төрле сорау белән аңа мөрәҗәгать итә, Әсмабану абыстай, барысыннан бигрәк тырышып, аны сыйлый. Әхмәтҗан бай да, шәкерт улы да аңа Габдулла әфәнде дип эндәшәләр. Фәгыйләгә бу бик сәер тоела. Әдәбият әһелләре, китаплар, газета, журнал исемнәре еш телгә алынудан гына бу мөгаллим дигән кешенең яраткан шагыйре Габдулла Тукай икәнен аңлап ала һәм, моны башына сыйдыра алмыйча, бик хәйран кала.

Әхмәтҗан бай белән Габдулла әфәнде балконга чыккан арада, кунак шәкерт, әнисенә һәм Фәгыйләгә сер итеп кенә сөйләгәндәй: «Бу кунакның хатын-кыздан читләшүчән бер сәер гадәте бар. Аның тирәсендә күп чуалмаска, юк-бар сораулар белән борчымаска тырышыгыз», – дип искәртү ясый. Шуның өстенә аның «мөгаллим» дип аталуы да очраклы түгел, имеш. Чөнки соңгы вакытта аның баш очында кара болытлар куерган, күзәтүләр башланган. Шуңа күрә кымыз эчеп дәваланудан тыш, ул рәсми һәм яшерен шымчылар күзеннән югалып торырга мәҗбүр булган. Шәһәр мулласы Габдрахман хәзрәт шул максат белән аны бирегә, аулаграк тарафка чакырып китергән. Гомумән, ул турыда күп сөйләшмәү хәерле. Берәрсе кызыксынып сораштырса-нитсә, кымыз эчеп дәваланырга килгән авыру мөгаллим, дип әйтергә кисәтеп куя.

* * *

Әхмәтҗан утарыннан дүрт чакрым чамасы читтә иркен далада берничә казакъ Габдрахман хәзрәтнең бияләрен савып, терлекләрен көтеп яши. Саф һавада күбрәк булсын, кымызның яңа өлгергәнен эчсен, итнең яңа суелганын ашасын дип, шунда, казакъларның киез өйләре янында, хәзрәт кушуы буенча, Тукайга да бер чатыр корып куелган. Монда килеп, көтүче казакъларда кунак булган шагыйрь барысыннан канәгать, күтәренке күңел белән берничә шаян җыру язып ташлый:

Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи,
Бәхте барлар кырда җәйли, валлаһи!

Ак күмәч берлән ашарлык саф һава;
Җир яшел; кошлар да сайрый, валлаһи!

Ак болыт, күчмә казакълардай күчеп,
Бер кунышлык күкне сайлый, валлаһи!

Аз гына бер җил исү берлән, үлән
Җирдә уйный кайный-кайный, валлаһи!

Кичкырын Тукай утарга кайтып кергәндә, хуҗалар өстәл өстендә җырлап торган җиз самавыр янында чәй эчеп утыралар иде. Әсмабану кунакка чәй ясап бирә, чәшкесенә лимон кисеп сала, җиләк-җимешне якынрак этәреп куя. Кунак бераз чәй эчеп сусавын баскач, Әхмәтҗан бай сүзгә керешә:

– Габдулла әфәнде, сезгә бер соравым бар. Әгәр урынсыз санасагыз, җавап бирмәскә мөмкин. Исемдә чакны, онытылганчы сорап калырга теләүдән генә. Кыскасы, менә нәрсә: зур талантлы мәшһүр әдип Галимҗан Ибраһимовның сезгә тискәре карашы, тырнак астыннан кер эзләп урынлы-урынсыз мәкаләләр чыгаруы. Бу миңа һич аңлашылмый. Моның сәбәбе нәрсәдә?

Тукай сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куя, чәшке төбендә калган чәй белән иреннәрен чылатып ала да:

– Мондый сорауны миңа еш бирәләр, моның белән күпләр кызыксына, – дип сөйләп китә. – Бу күңелсез сүзне озынга сузмас өчен, аларга: Галимҗан әфәнденең серкәсе су күтәрми, ул үзен мактаган, тәлинкә тоткан иярченнәрне ярата, әз генә тәнкыйтьчеләрне дә өнәми, читкә кага. Аның минем бакчага таш атуы да башлыча шуннан булса кирәк. Әмма эш анда гына түгел. Моның төбендә бүтән, җитдирәк сәбәп булуы, Галимҗанның әдәби иҗатка берьяклырак, эстетларча карашы төсмерләнә. Әмма болардан да мөһимрәк, беренче чиратта торган мөкатдәс бурыч бар: халыкның милли аңын уятырга, инкыйраз булудан саклап калырга, башлыча шул юнәлештә гамәл кылырга кирәк бит.

Шагыйрьнең күп шигырьләрен яттан белгән Фәгыйлә, үзен-үзе инандырырга теләгәндәй, эчтән кабатлый:

Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,
Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,
Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,

Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен.

Габдулла Тукай килгәннән бирле, кичләрен мондый сөйләшүләр, соңгы вакытта әдәбият, дин әһелләрен эзәрлекләүләр көчәюе турында фикер алышулар еш булгалый. Шул арада Фәгыйлә өлкәннәрнең сөйләгәнен дә колак салып игътибар белән тыңлый, дөнья хәлләрен ишетә һәм Тукай шигырьләренең эчтәлеген, мәгънәсен тагы да тирәнтенрәк ачкандай була.

* * *

Кичә көндез утарга көтмәгәндә ике кунак: шәһәрдән бер татар баеның буй җиткән улы белән кычыткан чыпчыгы кебек тиктормас кызы килеп төште. Икесе дә Әхмәтҗан улының кечкенәдән бергә уйнап үскән дуслары, икесе дә кайдадыр укыйлар; егет юрист булырга укый, сеңлесе маена чыдый алмаудан ниндидер лекцияләр тыңлап йөри икән. Бәхтиярның каникулга кайтканын ишеткәч тә, үзләре әйтмешли, дуслык визиты белән рәхим иткәннәр.

Әтиләре Әхмәтҗанның ширкәтчесе булганлыктан, яшь кунаклар хөрмәтенә җиңел кулдан тиз генә табын әзерләделәр. Өлкән хуҗалар үзләре катнашмаса да, аш-су шактый мулдан булды. Иш янына куш дигәндәй, Әсмабану абыстай компания өчен кирәк санап, Фәгыйләгә дә, рәтлерәк киенеп, табында катнашырга һәм хезмәт күрсәтергә кушты.

Кунак егетнең сул күз өстендә никтер кашы юк. Шуны яшерү өчен булса кирәк, тузгак җирән чәче маңгаена төшеп тора. Егет бераз кызмача. Табындашлар үрнәгендә туган телдә сөйләшергә керешеп караса да, татар һәм урыс сүзләрен бергә бутаудан, кушать итәбез, гулять итәбез кебек тозсыз кабатлаулардан ары китә алмады. Моны шундук абайлап өлгергән Бәхтияр, кинаяле шаярту белән:

Без алай да итәбез,
Без болай да итәбез.
Без итә дип, сез итмәгез,
Без заманча итәбез, –

дип, җиңелчә көлдереп куйды.

Үткен һәм чая кунак кызның киеме дә күзгә бәрелеп тора. Кыска җиңле, ачык изүле ефәк блузка астыннан яртылаш шәрә күкрәк йомрылары, тулы беләкләре юри күрсәтергә куйган төсле. Бармакларына күп итеп алтын, көмеш йөзек-балдак кигән. Сөрмәле күзләрен Бәхтиярдан һич алмый. Аз гына да тартынмыйча, гел шуның янында төчеләнә, әледән-әле беләкләренә кагылып, үзенә каратырга тели. Моны күреп торган Фәгыйлә, Тукайның дүрт кенә юллык көлдергеч шигырен хәтерләп, авыз эченнән кабатлый:

Ундыр җаный бармагы,
Уникедер балдагы,
Тагын берне кияр иде,
Инде урын калмады.

Тукай табыннан ялыкты бугай, беравык утырганнан соң, сый-хөрмәт өчен рәхмәт әйтеп, акрын гына үз бүлмәсенә чыгып китте. Бәхтияр шәкерт ябышкак кунак кыздан арына алмый. Юрист Куртай Фәгыйлә янында төчеләнә, татар, урыс сүзләрен бутый-бутый, тозсыз мәзәкләр сөйләүдән туктамый. Күзләре белән эзләнеп, өстәлдә хәмерле шешә таба алмагач:

– Юк, болай гына булмый, пить хочу,– дип, күрше бүлмәгә чыга да саквояж белән ике шешә шампан шәрабы алып керә.– Сездә сухой закон бит, настроение күтәрә торган напиток булмый. Поэтому специально үзебез алып килдек. Әйдәгез, картлар күрмәгәндә, бераз кайфовать итеп алыйк.

Фәгыйләгә гел чыгып-кереп йөрергә туры килә. Табынга утырса, тагын Куртай килеп бәйләнә, мәгънәсез мәзәкләр белән йөдәтә башлый.

Кичкырын ишегалдында саубуллашканда, коляскасына утыргач та, һаман телен тыя алмыйча:

– Бахти дус, секрет булмаса әйт әле, мондый соблазнительный прислуганы атаң табып бирдеме, әллә үзең таптыңмы?– диде, әшәке көлеп.– Аны кара, берәрсе урлап китмәсен. Синең урыныңда булсам, мин моны кулдан ычкындырмас идем.

Бәхтиярның ачуы йөзенә чыкты, кунакның әдәпсезлеге өчен оялгандай:

– Тс-с, алай ярамый, зинһар, тозсызланма,– дип туктатты һәм капканы ачарга кушты.

Кичке эңгердә адашмагайлары дип, Бәхтияр белән Фәгыйлә җилбәзәк кунакларны ярты чакрымдагы олы юл чатына хәтле озата чыктылар. Бәхтиярга елышып утырган чытык кызый һәмишә төчеләнеп бара.

Юл чатында коляскадан төшеп калгач, Бәхтияр белән Фәгыйлә кирегә чокыр-чакырлы тар сукмак буйлап турыдан гына кайттылар. Әлегә тикле аларның болай аулакта икәү генә калганнары булмагангамы, кинәт уңайсыз тынлык туды. Бераз дәшми барганнан соң гына, сүз юкта сүз булсын дигәндәй, Фәгыйлә кеткелдәп көлеп җибәрде:

– Һи-һи-һи-и, шултикле дә тигәнәк кебек ябышкак булыр икән. Теге кунак кыздан көлүем, гел сезнең янда сайрап кына торды.

Бәхтияр, бу шаяртуны өнәмәгәндәй:

– Ә абыйсы синнән күзен алмады, нинди генә ширбәтле сүзләр әйтмәде,– дип, борын астыннан мыгырдап куйды.

Сай гына коры ерганак аша үткәндә, Бәхтияр, асрау кызның кулыннан тотып, каршы яктагы тәбәнәк кенә текә ярдан күтәрелергә ярдәм итте. Караңгыда чокыр-чакырлы тар сукмакның калган өлешен дә алар кулга-кул тотынып, бер-берсенең уч җылысын тоеп, күңелле сөйләшеп кайттылар.

* * *

Атна-ун көн ял иткәннән соң, Әхмәтҗан бай варис улын, рессорлы тарантаска утыртып, шәһәрдәге, бистәләрдәге кибетләрен, тире эшкәртү, тун тектерү, кымыз әчетү цехларын күрсәтергә, компаньоннары, урыннарда алыш-биреш итүче агентлары белән таныштырырга алып чыгып китте. Иртәдән кичкә хәтле бәйрәм кебек гөрләп торган утарда тормыш тынып калгандай булды, нәрсәдер җитмәгән сыман тоелды.

Тукай көнозын кымызчы казакълар янында яки үз бүлмәсендә язу-сызу, газета-журналлар уку белән мәшгуль. Кайвакытта ул акрын гына ишекле-түрле атлап йөри яисә моңлы көйгә ишетелер-ишетелмәс кенә сузып җырлый. Ара-тирә хастасы кузгалган минутларда, буылып кых-кых йөткерә башлый. Коридордан үткәндә-барганда, моны ишеткән Фәгыйлә аның ишеге янында ирексездән туктап кызгана, балаларча беркатлылык белән шагыйрьгә ничек тә ярдәм итәсе, авыр уйларыннан азат итәсе килә. Вәләкин бу коры хыял гына, һичкайчан гамәлгә аша торган түгел. Аннан Габдулла әфәнде хатын-кыз белән ләчтит сатып утырырга яратмый, урынлы-урынсыз сораштырулар белән комачауламагыз, дип, Әхмәтҗан бай үзе каты кисәтеп куйган иде бит.

Мәгәр аның шагыйрь белән якынрак танышуы һич уйламаганча-көтмәгәнчә килеп чыкты. Беркөн иртән бүлмәсенә җыештырырга кергән Фәгыйлә белән шагыйрь үзе, сүз кузгатып, аны-моны сораштыра башлады. Аның ятим калган асрау кыз икәнен белгәч, ихласлы кызгану белән:

– И-и, шулаймыни?! – дип гаҗәпләнде.– Алайса, без икебез дә рәхимсез язмышның бәхетсез үгиләре икәнбез, – диде.– Хәер, мин моны беренче күрүдән үк төсмерләгән идем. Чөнки йөзеңдә барча ятимнәргә хас нәүмизлек галәмәте бар. Андый тамга үсеп буй җиткәч тә бетми, күңелдә сүнмичә һаман пыскып, сызлаган теш кебек, һаман бәгырьне өзгәләп тора.

– Хак сүз, дөрес әйттегез, мин моны үземнән дә беләм, – диде Фәгыйлә дә җанланып. – Ялгыз калган минутларда мәрхүмә әнкәм күз алдыма килеп басканда, бигрәк тә кыен була, күзләр яшьләнә:

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы,
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы,–

дип моңланып, күңелемне бушатам.

Тукай колакларына ышанмаган сыман гаҗәпкә калды, кинәт зур булып ачылган күзләрен Фәгыйләгә төбәп:

– Чү, син бу шигырьне каян беләсең? – диде.

– Әти исән чагында, без «Вакыт» газетасын алдыра идек, бу шигырьне шуннан укып беләм. Бик авыр минутларда аны күңелдән кабатласам, әнием белән сөйләшкәндәй җиңеләеп калам. – Чак кына дәшми торганнан соң, Фәгыйлә отыры җанланып китте: – Габдулла абый, мин сезне ничектер бүтәнчәрәк күз алдына китерә идем бит. «Су анасы» әкиятен укыганда, кеше әйберен чәлдерүче шук малай кебек булсагыз, «Шүрәле»дә кыргый урман сарыгын төп башына утырткан баһадир егеткә охшата идем. Сез аларны чынлап булган хәл, үз башыгыздан кичергән кебек килештереп язгансыз.

– Күрәм, кызый, син үзең дә кибәк башка охшамаган, төшеп калганнардан түгел бугай. Яшьли әдәбият укырга яраткансың, укыганыңның мәгънәсен аңларга тырышкансың, уйлана, хыяллана беләсең. Бу исә бик мөһим, адәм баласына гаять кирәкле шәйдер.

Җылы сүзләре белән ятим кызның күңелен күтәрсә дә, Тукайның кәефе юк, чырае төссез. Әледән-әле кыһ-кыһ ютәлли. Авыруын сиздермәскә тырышуы күренеп тора. Йөткерүе басылмаса, ак-

ланырга теләгән сыман: «Юлда килгәндә, бераз җил тиде бугай, шул йөткертә»,– дип, камзул кесәсеннән дару алып каба.

Аларның мондый очрашу, әңгәмәләре азактан да еш булгалый. Берәр эш белән бүлмәсенә асрау кыз керсә, шундук Тукайның йөзе яктырып китә, каләмен куеп, хәл-әхвәл сораша, сөйләштерә, тапкыр шаярту ишетсә, рәхәтләнеп көлә.

Кәефе әйбәтрәк бермәлне, кичке аштан соң, чәй янында күңелле генә гәп корып утырганда, ул үзе дә:

– Инде күптән, туган авылым Кушлавычка кайткач булган хәл,– дип, мәзәк сөйләргә тотынды.– Шунда тегермәнче улы, шәһәрдә укучы егет белән таныштым, ара-тирә аларга баргалый башладым. Эш юктан эш булсын дигәндәй, бу егет мине ауга, бытбылдык атарга чыгарга үгетли башлады. Гомеремдә бер тапкыр мылтык тотканым булмаса да, бик кыстагач, ризалык бирдем. Икебез дә мылтык һәм бытбылдык алдый торган сыбызгы белән коралландык. Миңа ата бытбылдык сыбызгысы бирде, үзенә ананыкын алды. Мине алар белән эш итәргә өйрәтте.

Басуда дугалы ат күмелерлек булып үскән куе арышның өлгереп килгән вакыты иде. Авылдан чыгып, беравык баргач, юл икегә аерыла. Тегермәнче улы миңа уңга китәргә әйтте, үзе сулга борылырга булды. Бытбылдык атсак-атмасак та, кичкырын шушында очрашып, бергә кайтырга сүз куештык.

Ярты чакрым чамасы барганнан соң, кулымдагы ата бытбылдык сыбызгысын сузып-сузып сызгырттым да колак салып тыңлауга күчтем.

Озак көтәргә туры килмәде, миңа җавап кайтаргандай, каяндыр ана бытбылдык сайраганы ишетелде. Сыбызгымны сызгырта-сызгырта, арыш арасыннан шул тарафка юнәлдем. Ишетәм, ана бытбылдык та миңа таба якыная. Әһә, бу мескен кош минем сыбызгыга алдана, мәйтәм. Ә үзем, як-якка карана-карана сак кына атлап, һаман барам да барам.

Чү, каршымда якында гына нәрсәдер кыштырдаган кебек булды, каралҗым шәүлә күренде. Әһә, бытбылдык шул икән дип, мылтыгымны төзәп атып җибәрсәм, куе арыш арасыннан... тегермәнче улы атылып килеп чыкты. Мескеннең куркудан коты алынган, мылтыгы миңа төбәлгән иде.

Бермәл күзгә-күз шаккатып карап торганнан соң, исән калу шатлыгыннан кычкырып көлеп җибәрдек һәм юл буе бер-беребезне шаяртышып кайттык. Шулай да адәм көлкесенә калмас өчен, без бу вакыйганы беркемгә сөйләмәскә сүз куешып аерылыштык.

Әмма Тукайның андый көр күңелле, сүзчән көннәре сирәк була. Ул әледән-әле буылып-буылып йөткерә. Күрсәтергә теләмәгән сыман читкә борылып, сәдәп хәтле генә ак таблетка йота. Ютәле басылып торган чакларда да күңеле күтәрелми, ахрысы. Бүлмәсендә үзе генә калды исә, гел бер шигырен көйли:

Яшь вакытта яшьнәдем, көчле вакытта күкрәдем;
Яшьнәмим дә, күкрәмим дә – утсыз инде күкрәгем!

Асрау кыз Фәгыйлә аның өчен үлеп тора: кадерләп кайгырта, мунча кергән саен, керен юып үтүкли, урын-җирен, сөлгеләрен алыштыра. Кымызын вакытында эчертеп, тәмлерәк ашатып, аны үзенчә тизрәк савыктырырга, тазартырга тырыша. Әмма ике айга якын дәвалануга карамастан, шагыйрьнең хәле җиңеләйми, савыгу сизелми...

Нәкъ шул көннәрдә Өсмабану абыстайны дәваларга шәһәрдән чакыртып китерелгән врачка бер уңайдан Тукайны да күрсәткәннәр иде. Мәгәр ул тынычландырырлык берни дә әйтә алмады. Авыруны игътибар белән тыңлап караганнан соң, ютәлдән эчәргә дип, аспирин гына биреп калдырды. Бары тик ишегалдына озата чыккан Әхмәтҗан байның үзенә генә: бик кичегеп кузгалгансыз, элегрәк кайгыртырга кирәк иде, ашыгыч рәвештә диспансерга салырга кирәк, дип әйтеп киткән.

Бу хакта үзенә һични әйтмәсәләр дә, Тукай барысын да сизә һәм әллә ни игътибар итми шикелле. Хастаханәләр, дарулар турында андый-мондый сүз чыкса, гадәтенчә игътибарсызлык белән: «Иң яхшысы – врачларга күренмәвең хәерле, алар еш кына булмаган сырхауны да һичшиксез уйлап чыгаргалыйлар, – дип шаяртырга ярата. – Аларга ышанып, кайчак авыртмаган әгъзаң да сызлый сыман, чынлап сырхауга сабышасың».

Ә үзе, бүлмәсендә ялгызы гына калган чакларда, моңсу көйгә сузып-сузып һаман бер җырны кабатлый:

Быелгы җәй үтәрме,
Киләсе җәй җитәрме?
Киләсе җәй рәхәтен
Ходай насыйп итәрме?..

* * *

Нәкъ Тукай врачлардан шаяртып көлгәнчә, рас килеп чыкты: әлегә тикле азмы-күпме ярыйсы гына кыймылдаган Әсмабану абыстай, табибка күренгәннән соң, тыны бетүдән ешрак зарлана, хәлсезләнә башлады. Шуңа күрә өй эшләренә бик кысылмый, вакытын күбрәк намаз укып, тәсбих тартып үткәрә. Эштән иртәрәк бушаган кичләрне Фәгыйләне дә үзе белән бергә намаз укырга чакыра. Атна көннәрне җомга намазыннан соң аңа кулдан күчереп язылган «Йосыф китабы»н яки берәр мөнәҗәтне көйләп укыта.

Монда килүенә ике ай чамасы үткәч, Тукай аулак тормыштан зарыга башлады шикелле. Сүз арасында Казанны, китап нәшриятларын, газета-журнал редакцияләрен, әдәбият әһелләрен ешрак телгә алгалый, озакламый кайтып китү, юлга әзерләнү турында сөйләнә. Шулай да артык куырмый, тагын атна-ун көн сабыр итәргә, тиздән Бәхтиярның каникулы беткәч, аның белән бергә китәргә исәп тота.

Чынлыкта исә вакыйгалар кинәт һич тә көтелмәгән борылыш ала. Уйламаганда, утарга Троицк шәһәре мулласы, Тукайны монда кымыз белән дәваланырга чакырып китергән Габдрахман хәзрәт килеп төшә. Бик ашыккан, ахрысы, юртак аты шабыр тиргә баткан.

Ишегалдында тарантастан төшеп, хуҗалар белән исәнләшкәндә әйтүенә караганда, далада терлек көтүче казакълар янында булган, шуннан кайтышлый берничә минутка авыру шагыйрьнең хәлен белешергә генә кергән икән. Шунлыктан атын туарырга да рөхсәт итмәде.

– Бәйдә килеш кенә бераз тын алсын, суынсын. Вакытым тар, юл уңаеннан берничә минутка гына сугылдым, – дип сөйләшә-сөйләшә, алар өске катка Тукай янына менеп киттеләр.

Әмма аның берничә минутка гына дигәне сәгатькә якын сузыла. Бераздан Әсмабану абыстай кушуы буенча Фәгыйлә лимонлы чәй әзерләп керткәндә, киңәшмә инде тәмамланган була, хөрмәтле хәзрәтнең ашыга-ашыга:

– Менә шуңа күрә дә бу четерекле йомышны беркемгә дә ышанмыйча, үзем килеп ирештерергә булдым, – дип әйткән азаккы сүзләрен генә ишетеп кала. – Ярый, мин кузгалам. Икенде намазына кайтып җитмәсәм, кайда, нинди йомыш белән йөргән, дип төпченә башлаулары бар. Хәзерге шөбһәле заманда дөнья хөсетле затлар белән тулы. Кешеләр бер-берсен күзәтеп, иснәнеп йөриләр, әләкләшергә генә беләләр. Ялган бәла-гайбәтләрдән, Тәңрем, берүк үзең сакла!.. Габдулла әфәнде, сиңа хәерле юл телим. Гаеп итеп китмә, исән-имин кайтып җит. Һәрхәлдә, бу борчулы ыгы-зыгылардан ераграк булуың хәерле.

Хәзрәт китеп бару белән, Тукай шундук кайтып китәргә җыена башлый. Әсмабану абыстай белән Фәгыйлә, бөтен эшләрен ташлап, ашыгыч рәвештә юл кирәк-яракларын хәстәрли. Кичкырын, барысы бергә җыелып, соңгы кабат ашагач-эчкәч, Тукай, асрау кызны үз бүлмәсенә дәшеп, кәрҗиненнән юкарак кына китапчык ала, беренче битенә тиз генә нәрсәдер язып, Фәгыйләгә бирә:

– Менә сиңа бәләкәй генә бүләгем. Киләчәктә дә үзлегеңнән укып, халкыбызга аң-белем таратучы мөгаллимә булып үс.

Шул ук кичне Бәхтияр аны җиңел тарантаста станциягә илтә һәм бәла-казасыз төнге поездга утыртып җибәрә.

Ә Габдрахман хәзрәтнең нинди шомлы хәбәр алып килгәнен Бәхтияр иртәгесен сер итеп кенә әнисенә әйткән. Фәгыйлә исә моны Әсмабану абыстайның колактан колакка бик яшерен сер итеп сөйләвеннән ишетеп белә. Инде байтактан бирле шомлы хәбәр йөри, Лена дигән елга буендагы алтын приискаларында йөзләрчә баш күтәрүчеләрне атып үтергәннәр бит. Шуларның байтагы, каты эзәрлекләүгә түзә алмыйча, бу тарафка качып килгән, имеш. Хәзер шәһәрдә аларны эзләү, аулау бара. Шикле тоелган һәр кешене кулга алып, бәйнә-бәйнә тикшерәләр, төпченәләр, ди.

Былтыр кыш Казанга барган чакны, Габдрахман хәзрәт тагын бер күңелсез хәбәр ишетеп кайткан булган. Әмма ул хакта беркемгә дә әйтмәгән генә. Анда ул властьларның Тукайга кырын карый башлаганын, аны яшерен күзәтү астында тотуларын ишетеп белгән. Шуңа күрә ул авыру шагыйрьне кымыз эчертеп дәвалау белән беррәттән, шымчылар, җәберләүчеләр күзеннән югалып торсын, җаны тынычлансын дип, монда килергә чакырган булган.

Тукайны озатканнан соң ике атна үткәч, Бәхтиярның да каникулы бетеп, ул да укырга китеп барды. Җәй башыннан бирле бәйрәм кебек күңелле тормыш гөрләп торган утар хуҗасыз йорт кебек тынып калды. Иртәдән кичкә тикле аш-су пешерү, бүлмәләрне җыештыру, кымыз китертү белән мәш килгән, бер минут та буш вакыты булмаган асрау кыз Фәгыйләгә көннәр эчпошыргыч озын тоела башлады, ул хәзер еш кына күңелсез уйларга бирелә, моңая.

Әхмәтҗан бай һәрдаим сәфәрдә, кәсеп эшеннән бушамый. Әсмабану абыстайның хәле хөртиләнә бара, телдән бик зарланмаса да, ничектер авыр сулый. Ә үзе ике сүзнең берендә исән-сау ба-

рып җитте микән, хәбәре озак юк, дип, һаман улы турында борчыла. Бүген иртән аннан хат килеп төшкәч кенә, кәефе күтәрелде, көнозын шул хакта сөйләнеп йөрде. Бәхтияр хатының азагында Фәгыйләгә дә сәлам язган. Әсмабану моны асрау кызга берничә тапкыр әйтә, хатның ул юлларын кызның үзенә дә укыта. Кичен улына хат язганда:

– Фәгыйлә кызым, әйдә синнән дә сәлам җибәрик, – дип эндәшә. – Ул анда берьялгызы бит, ямансудыр, безне сагынадыр. Әйдә языйк, күңеле булсын балакайның.

Егеттән хатлар атна саен килеп, һәркайсында Фәгыйләгә кайнар сәлам, сагыну сүзләре язылган була. Бераздан егет хатларын турыдан-туры кызның үзенә адреслап та җибәрә башлый. Соңгы хатында аны чын күңелдән яратуын, бик сагынуын һәм, нәкъ утраудагы кебек, еракта да аның кул җылысын тоеп яшәвен әйтеп яза.

Эшләр болайга киткәч, Фәгыйлә кинәт шиккә төшә. Миңа тиң түгел бит, яманатым чыгудан Ходай сакласын дип, Бәхтиярның хатларына җавап язуны туктата. Мондый очракта биредә калырга ярамавын ул яхшы аңлый һәм үзенең шик-шөбһәсен егетнең әнисенә дә җиткерә. Төрле имеш-мимеш, гайбәт сатулар тудырмас өчен, хәзер үк моннан китәргә карар кыла.

– Әсмабану абыстай, мин сезне туган әнием кебек якын итәм, игелегегезне беркайчан онытмам, – дип әйтә. – Шуңа күрә китәм дә. Шулай кирәк, башкача мөмкин түгел. Мине дөрес аңлагыз, зинһар, гаеп итмәгез.

Кыенсыну белән һәм бераз читләтеп-читләтебрәк әйтелгән бу хәбәрне Әсмабану абыстай башта аңына сыйдыра алмыйча аптырап торды. Ахыр чиктә төшенеп алгач, колакларына ышанмагандай:

– Авызыңнан җил алсын, тфү-тфү. Берүк, андый сүзне бүтән әйтә күрмә, – ди, җиңелчә ачуланып. – Үзең дә күрәсеңдер, Бәхтияр бозык түгел, тәүфыйклы егет, сине үлеп ярата, сиңа өйләнергә өмет баглый. Әхмәтҗан абыең белән мин дә үз кызыбыз кебек якын итәбез. Безгә килеп үзе тагылып йөрүче яртылай каферләшкән ташкурчактан Раббым үзе сакласын. Син минем үз кызым кебек якын киленем, картлык көнемдә карауччыбыз булырсың.

Һәркемнең киләчәк тормышы, кайда, кемнәр белән ничек яшисе үзе туганчы ук Ходай Тәгалә тарафыннан тәкъдирдә язылган була, дип әйтер иде безнең әти. Фәгыйлә кызым, синең язмышың безнең гаилә, безнең улыбыз Бәхтияр белән бәйле. Мин моны гарәфә кич төшемдә күрдем, тормышта да шулай булсын диеп, садака адарындым. Берүк фәрештәләрнең амин дигән сәгатенә туры килсен.

Фәгыйлә йомшак күңелле карчыкның бу киңәшен шундук кире кагарга җөрьәт итми. Башта уйлаганча, көне-сәгате белән шундук чыгып китми, беразга түзәргә була. Шул арада абыстайның бу саташулы хыялы да, бәлкем, басылыр әле дип тынычланырга тырыша.

Әмма ләкин Әсмабану абыстайның уйлары басылмый. Киресенчә, хәле хәл булуга карамастан, башында туган ниятен гамәлгә ашырырга ашыгуы сизелә. Бу эштә ул ире белән уртак фикердә булса кирәк. Иң әүвәл Фәгыйләне өйнең өске катына, Тукайдан бушаган бүлмәгә күчертә, аңа ярдәмче итеп Пүчинкәдә бергә укыган Җәмилә исемле кызны ала. Кышкы каникул башлангач, Бәхтиярны чакыртып кайтаралар да, озын-озакка сузмыйча, яшьләрне кавыштырырга керешәләр. Шәригать кушканча булсын дип, шәһәрдән Габдрахман хәзрәтне китертеп никах укыталар, никахлашу галәмәте итеп, бер-берсенең бармагына алтын балдак киертәләр. Кайчандыр хәер сорашып нужа күргән, аннары асрау кыз булып хезмәт иткән Фәгыйлә бай егет хатынына әверелә.

Инде моңарчы ук бу гаиләдә үз кеше булган яшь килен яңа әхвәлгә тиз күнегә, әмма борын чөеп йөрми. Әсмабикә абыстайга элеккечә ихтирамлы булып кала, әни, дип үлеп тора. Хезмәтчеләр һәм аш-су пешерүче авылдашы берәр ялгышлык җибәрсә дә, аларга каты бәрелмичә аңлатып бирә йә үзе эшләп күрсәтә.

* * *

Әсмабану абыстай, якыннарын артык интектермәскә теләгәндәй, Ходайдан сабырлык сорап, мыштым гына үлеп китте, үз бүлмәсендә җомга намазы укыганда, намазлык өстендә җан тәслим кылды.

Газиз әнисе кебек якын булган, күп ярдәме тигән йомшак күңелле каенанасын югалту Фәгыйләгә бик авыр иде, ул үзен икенче тапкыр ятим калган кебек хис итте.

Бәла ялгыз йөрми, дип, тикмәгә әйтмәгәннәр, ахрысы. Әсма абыстайны югалту хәсрәте басылырга өлгермәде, язгы кояшлы көннәрнең берсендә яңа бәла – бөтен татар халкын тирән кайгыга салып, бөек шагыйрь Габдулла Тукайның вафат булу хәбәре килеп төште. Бу хакта барча газета-журналлар язып чыкты, илне матәмле сагыш-моң басты.

Бу кайгылы хәбәрне ишеткәч, Фәгыйлә кинәт миңгерәп китте, күз аллары томаланды, Тукайны юк итеп һич аңына сыйдыра алмады ул. Әле кайчан гына ул монда булган, бергә сөйләшеп, бер табында ашап-эчеп утырганнар иде. Менә шушы бүлмәдә Фәгыйлә аны:

Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын,–

дип хәйран калдырган иде бит.

* * *

Тормыш мәңгелек агым кебек, бер генә минут та тукталып тормый. Эреле-ваклы көндәлек мәшәкатьләре, шатлык-кайгылары, туу һәм югалтулары белән үз юлыннан өзлексез дәвам итә.

Казакъ даласындагы ялгыз утарда да тормыш үз җаена акрын гына бара бирә. Әхмәтҗан агай елдан-ел сизелерлек картая бара. Хуҗалык белән идарә итүне аз-азлап улына тапшыра, үзе күбрәк тирә-юньдәге авыл мәчет, мәктәпләренә, мохтаҗ хәлфә, шәкертләргә ярдәм күрсәтү һәм биш вакыт намаз укудан бушамый. Бәхтияр укуын тәмамлап кайтуга, җиң сызганып эш йөртә. Яшь бичәсе белән иркенләп чәйләшергә, күңелен күрергә вакыт калмый.

Ерак Көнбатышта зур сугышлар башлангач, аларның эшләре тагын да уңышлырак бара. Ширкәт җитештергән җылы тун, киез итекләргә, хәтта кымызга да бәяләр көннән-көн күтәрелә бара. Күптән түгел генә пайга кергән алтын приискасы да ярыйсы гына эшли, хәтсез хәзинә бирә.

Хәзер үзе байбикә булып калган Фәгыйлә Әсмабану абыстайны еш искә төшерә, үз урынына асрау кыз булып килгән Җәмилә белән теге яки бу эш турында сөйләшкәндә, мәрхүмә абыстай менә болай итә, тегеләй итә иде, дип, телгә ала. Эштән буш вакытларда алар Габдулла Тукай шигырьләрен, Галимҗан Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» дигән хикәясен, башка әдипләрнең әсәрләрен укыйлар. Ара-тирә Пүчинкә зиратына барып, әти-әниләре рухына садака биреп дога кылдыралар, авылдашлары белән очрашалар, халыкның елдан-ел бөлә барганын, коточкыч мохтаҗлыкта яшәгәнен күрәләр.

Утарга килә торган газета берсеннән-берсе шомлы хәбәрләр белән тулы. Шәһәрләрдә ачлыкка түзә алмаган меңнәрчә эшчеләр эш ташлап протест белдерә. Авыл халкы алпавыт урманын кисә. Фронтта солдатлар командирларына буйсынмый, күбесе коралын ташлап качып китә.

Ул да түгел, тагы да тетрәткечрәк яңалык: Петербургта патшаны тәхеттән бәреп төшергәннәр, илдә власть әкренләп халык кулына күчә икән, дигән хәбәрләр йөри. Бөтен илдә кырмыска оясына таяк тыккан кебек, кая карама – ыгы-зыгы. Шәһәрдә завод, фабрикалар эшчеләр кулына күчә. Күп урыннарда алпавыт утарларын талаулар башлана. Хуҗалары кайсы качып котыла, кайсы, каршылык күрсәтеп, бәрелештә вафат була.

Әнә шундый дәһшәтле көзге көннәрнең берсендә Фәгыйләнең шәһәргә киткән ире белән каенатасы да кире әйләнеп кайтмады, җир йоткан кебек, икесе дә юкка чыктылар. Шәһәргә барып эзләү, сораштырулар бернинди нәтиҗә бирмәде. Күргән-белгән танышларның күбесе төрле якка таралып беткән. Шәһәрдәге йорт та, аскы каттагы кибет тә пыран-заран китерелгән, хезмәтчеләр, приказчиклар – барсы да кайсы кая китеп юк булган.

Менә Әхмәтҗан байның даладагы утарына да чират җиткән. Пүчинкә кешеләре иртәгә иртән килеп, мал-мөлкәтне үзара бүләчәкләр, имеш. Кичен бу хәбәрне озын колактан ишетеп белгән Фәгыйлә шул ук төнне Габдрахман хәзрәтләргә юл тотарга карар кыла. Хезмәтче кыз Җәмилә дә аның белән бергә китәргә була, тәрәзә төбендәге алтын йөзекне алып бармагына кия.

Фәгыйлә исә чак кына уйланып тора да, башта иң кадерле нәрсәсе – шагыйрь үзе вафат булгач беренче тапкыр чыккан «Габдулла Тукаев мәҗмугаи асаре» исемле калын китабын яулыкка төреп кулына ала. Аннары соңгы тапкыр бүлмәләрне йөреп чыкканда, затлы бизәнү әйберләренә, көмештән ясалган, алтын йөгертелгән савыт-сабага карап үтә. Элек боларга аның бер дә исе китми иде. Хәзер үзе дә көтмәгәндә, мондый авыр заманда боларның да кирәк булуы ихтимал дигән фикергә килә. Озын-озак уйлап тормастан, боларын да зур гына бер футлярга тутыралар. Аны кучер малае чанасына салып бәйлиләр дә төнгә каршы хәтәр сәфәргә чыгып китәләр.

Ул вакытта, төрле сәбәпләр аркасында әйберләрен күтәреп, төн карасы астында каядыр шылучы качаклар күп була. Аларны аулау, мөлкәтләрен конфискацияләү максаты белән юлларда өчдүрт кешедән гыйбарәт булган коралллы дозор отрядлары йөри торган була.

Моны белмәгән Фәгыйлә белән Җәмилә таң алдыннан шәһәргә барып җитәрәк, бәхетсезлеккә каршы, әнә шундый отрядка очрый. Башлыклары булса кирәк, кыска тун, колакчын бүрек кигән

базык гәүдәле берсе: «Кто такие, что везете?» – дип, боларны туктата. Фәгыйлә урысча азрак сукаласа да, берни дә аңламаган сыман, ык-мыклап тизрәк үтеп китмәкче була.

Отряд командиры аны туктата, ачулы сүгенә-сүгенә чананы тибеп аудара, асты өскә әйләнгән футляр эчендәге әйберләр чәчелеп китә. Шырпы яндырып карасалар, кар өстендә җем-җем итеп яткан асылташлы бизәнү әйберләрен күреп, дозорчыларның күзләре дүрт була. Ачулы командир зур хәзинә табу шатлыгыннан хәтта юашланып китә, әдәплеләнә төшә.

Артык сүз куертып тормастан, дозорчылар шырпы сыза-сыза кар өстендәге әйберләрне җыеп футлярга тутыра башлыйлар. Ут сүнеп торган арада, әле берсе, әле икенчесе берәр әйберне тиз генә үз кесәсенә салып куя. Эш тәмам булгач, котлары алынган ике бичара юлчыны, куркыныч юлбасар тоткандай, кораллы сак астында шәһәргә, элеккеге полиция участогы бинасында урнашкан милиция бүлегенә китерәләр.

Монда Фәгыйлә белән Җәмиләне ярым чишендереп, култык асларын, күкрәкләрен оятсызларча капшый-капшый, җентекләп тентиләр, футлярдагы хәзинәгә опись ясыйлар. Фәгыйлә Тукай китабын сорап караса да, кире кайтарып бирмиләр. Аннары аларны күрше бүлмәгә аерым-аерым чакырып икесеннән дә допрос алалар. Фәгыйлә үзе турындагы барлык сорауларга да чын булганча дөресен җавап бирә. Төрмәгә утыртуларыннан куркып, үзенең буржуй хатыны икәнен генә әйтми калдыра. Допрос алучы күпме төпченсә дә:

– Алар мин ятимәне асрау кыз итеп алдылар, бераз үткәч, хезмәтче булдым, – дип, Фәгыйлә үз сүзендә тора. – Дөнья бозылгач, ягъни бу чуалышлар башлангач, аталы-уллы хуҗаларыбыз шәһәргә киткән җирдән юкка чыктылар. Ике көн көтеп тә хуҗалар кайтмагач, без дә хуҗасыз утарда калудан курка башладык, шыпырт кына тайдык. Шайтан котыртты бугай, комсызланып, бу шылтыравыкны үзебезгә бәлагә алганбыз. Тфү, тфү, башы-ахыры шул булсын!

Шунда көтмәгәндә тагын бер бәла килеп чыга: допрос кәгазенә кул куйганда, дозорчылар башлыгы Фәгыйлә бармагындагы никах балдагын күреп ала да, каракны җинаять өстендә тоткан кебек, яман җикеренә башлый:

– Әһә-ә, эләктеңме... Әле генә комсызлануың өчен үкенгән булып, тәүбә итеп кыланган идең. Ә үзең әнә ничек. Халык милке булырга тиешле алтын балдакны безгә тапшырмыйча, яшереп калгансың. Таш кебек катып торма, хәзер үк бармагыңнан балдагыңны салып өстәлгә куй.

– Юк, юк, мин берни дә яшереп калмадым, балдакны аны һич тә бармактан салып булмый, бары тик шуннан гына.

– Әһә, шулаймы? Салдыру дигәндә безгә куш. Без аны хәзер күз ачып йомганчы...

Дозорчы әнә шулай шапырына-шапырына эшкә керешә. Әмма таш кебек каты куллары белән Фәгыйләне кычкыртып газапласа да, бармакка тирән батып кергән балдакны барыбер салдыра алмый. Борын астыннан мыгырдый-мыгырдый туктарга мәҗбүр була. Чөнки кияүгә чыкканнан соңгы дүрт ел дәвамында Фәгыйләнең бармаклары шактый тулыша төшкән, тирән батып кергән алтын балдак сары тегәрҗепкә охшашлы сызык кына булып күренеп тора.

Дозорчылар ахыр чиктә җәфалауны хәзергә туктатып торырга булалар һәм Фәгыйлә белән Җәмиләне коридорның аргы башындагы салкын камерага илтеп ябалар.

* * *

Иртән милиция түрәләре эшкә килгәч, камерадагы тоткыннарны берәм-берәм чакырып, тикшерү – фильтр аша үткәрү башлана. Эшне тиз тоталар бугай, бераздан камера шактый бушап кала. Менә утар качакларына да чират җитә. Башта хезмәтче кыз Җәмиләне чакырып алалар. Бераздан милиционер Фәгыйләне чакырып чыгара. «Өлкән тикшерүче» дип язылган ишектән кыюсыз гына атлап кергәч, зур өстәл янында кәгазьләр актарып утырган тикшерүче, күтәрелеп тә карамыйча:

– Кайдан, кем буласың? Садись, рассказывай,– дип, артсыз урындыкка ымлап күрсәтә һәм үзе һаман алдындагы кәгазен укый бирә.

Фәгыйлә төнлә дежурныйга ни сөйләгән булса, бу юлы да сүзгә-сүз шуны кабатлый, бары тик үзенең бай хатыны икәнен генә әйтмичә яшереп калдыра. Тикшерүче рәтләп тыңламаган кебек булса да, аны шып туктата:

– Ник скрывать итәсең? Менә бу допрос протоколында хезмәтче кызыгыз әйтүенә караганда, син есть бай хатыны бит, значит буржуйка, классовый дошман,– дип, алдындагы кәгазьгә төртеп күрсәтә. Шунда ул Фәгыйләгә күтәрелеп карый һәм кинәт гаҗәпкә кала: – Чү, кемне күрәм мин. Хәтерем ялгышмаса, син Бәхтиярларда прислуга идең бит. Хатыны да булгансың икән. Алайса, ник скрывать итәсең?

Беркайчан алдау-йолдауны белмәгән Фәгыйлә комач төсле кызара, абына-сөртенә кыенлык белән:

– Юк, ялганчы түгел,– дип акланырга тырыша.– Ул йортта асрау кыз булуым да, аннары хәдимә булуым да хак сүзләр. Фамилиям дә дөрес, тумыштан килгән чын фамилиям. Ә монысы, допрос протоколында язылганы, куркудан, буталудан килеп чыккан. Алла хакы өчен, зинһар, гафу итегез.

Бу көтелмәгән очрашудан Фәгыйлә бик аптырап кала һәм, әле һаман ышанып бетмәгәндәй, күз кырые белән тикшерүчегә ирексездән карап ала. Әйе, бу, һичшиксез, шул, моннан биш ел элек утарга кунакка килгән ябышкак Куртай бит. Хәзер ул сизелерлек калынайган. Элеккечә туган телендә сөйләшә белми, сул кашы юк. Чагыр күзләре йотардай комсыз карый. Беравык сүзсез утырганнан соң, үзалдына уйлангандай:

– Менә бу, чынлап та, удивительный. И, кызганычка каршы, запоздалый очрашу, помогать итәргә авыр булачак,– дип, борын астыннан сөйләнә.– Чөнки барсы да инде дежурный журналына язылган, әйберләргә официально опись ясалган, значит, яшереп калу мөмкин түгел. Аннары Әхмәтҗан бай бер алтын приискасында пайчы иде бит, димәк, аның кайдадыр яшереп куйган алтын запасы бар. Точно беләбез, сбежать иткәндә, алар ул запасны урлап китә алмадылар. Шул алтынны табарга ярдәм итсәң, без сине шундук чыгарып җибәрербез. Разумеется, табылган запастан үзеңә дә бераз эләгер. Төнге допрос протоколында бармагындагы алтын балдагын бирмәде, салдырып алырга кирәк дип язылган. Алай ярамый, балдакны хәзер үк салып бир.

– Алтын запасы турында бер кәлимә сүз ишеткәнем, күргәнем булмады, шуңа күрә һични әйтә алмыйм. Ә балдакны яшереп калмадым. Менә ул, тирән батып кергән. Допросчылар салдыра алмадылар. Балдакны алтын-көмешче оста кайчысы белән генә кисеп алып була, диделәр.

– Ярар, анысы калып торсын, соңынтын карарбыз. Ә хәзер безнең өчен иң важные – алтын запасы. Син безгә шуның кайда икәнен әйтергә, булышырга тиеш.

– Бик булышыр идем, әмма мин берни дә белмим бит. Шунлыктан һични әйтә алмыйм.

– Ашыкма, бәлкем, хуҗаларыңнан куркасыңдыр.– Тикшерүче яшерен сер әйткәндәй, тавышын акрынайта төште.– Бер дә курыкма, алар юк инде, кире кайтып булмый торган дөньяга бөтенләйгә киттеләр.

Кинәт коты алынган Фәгыйлә, моны аңына сыйдыра алмыйча:

– Ничек киттеләр, кем әйтте аны? – дип кычкырганын сизми дә калды.

– Син нәрсә, әллә ишетмәдеңме? Безнең изолятордан качкан унике подследственный арестант төнге караңгыда елга аша үткәндә, барсы да юка боз астына батып погибать итәләр. Алар арасында Әхмәтҗан бай белән аның улы Бәхтияр да бар иде. Значит, алтынның кайда икәнен курыкмыйча әйтергә мөмкин.

Моңа бик ышанып бетмәсә дә, Фәгыйлә кинәт миңгерәп китә, күз аллары томанлана. Куртайның соңгы сүзләре сабакташы Бәхтиярның һәлакәтенә шатлангандай мәкерле тоела, рәхимсезлеге белән җанны өшетә. Фәгыйлә шундук бисмилла әйтеп мәрхүмнәр рухына дога кылырга керешә.

Күренеп тора, тикшерүче эшне ашыктырмакчы. Түземсезлек белән тамак кыра да:

– Монда мәчет түгел, соңынтын молиться итәрсең,– дип, Фәгыйләнең догасын туктатып, допрос алуын дәвам итә.

Ул, бөтен осталыгын куеп, допрос ала. Турыдан-туры да, төрлечә уратып-уратып та сораштыра, тасма телләнеп үгетләп тә карый. Әмма көткән җавапны һич әйттертә алмыйча ярсып бетә. Ахыр чиктә ризасызлык белән:

– Бар, яхшылап уйла, хәтерләргә тырыш,– дип, тоткынны камерага илтергә куша.

Ул Фәгыйләне иртәгесен дә, берсекөнне дә бүлмәсенә чакыртып, озак-озак допрос ала, аның кичә сөйләгәнен бүгенгесе белән җентекле тикшерә. Дөресен әйтмичә барыбер чыгармыйбыз, дип, тагын кисәтеп карый. Өченче очрашуда да тоткынның телен чишә алмагач, түземен җуеп, ачулана башлый:

– Ярар, черт с тобой. Алайса, синнән бүтән җирдә бүтән кешеләр допрос алыр. Анда болай гына сөйләшмәсләр, телеңнән тартып сөйләтерләр. Безнең кебек җәлләп тормаслар, балдагыңны ничек салдырасын белерләр.

Шул ук көнне озату кәгазенә Фәгыйләне буржуй хатыны дип, алтын хәзинәсе кайда икәнен әйтмәвен һәм хәзер дә бармагындагы алтын балдакны бирмәгәнен язып, аны кораллы сак астында шәһәр төрмәсенә җентекле тикшерү үтәргә җибәрәләр.

* * *

Шәһәр төрмәсендә Фәгыйләне хатын-кызлар камерасына ябалар. Кием-салымнарына, үзләрен тотышларына караганда, тоткыннарның күбесе яңа власть тарафыннан җәберләнгән мул тормышлы зыялыга охшаганнар. Арада байларча купшы киенгән яшь ханымнар да, рәнҗүләре йөзенә чыккан әбиләр дә бар. Кайберләре инде атна-ун көн тикшерелмичә, чират көтеп тора, бу кандала оясында озак тотудан зарланып, шау-шу кузгаталар.

Монда тик тотмыйлар, төрле эшкә җигәләр икән. Бирегә килгәннең икенче көнендә үк, солдат кебек сафка бастырып, Фәгыйләне дә сак астында тимер юл станциясенә вагоннан ташкүмер бушатырга алып киттеләр.

Тынчу, сасы камерада аз сүзле булып тоелган йомык тоткыннар саф һавада җанланып китеп, эш арасында кайгы-хәсрәтләре белән уртаклашалар, башларыннан үткән маҗараны, ишеткән-белгәннәрен сөйлиләр. Фәгыйлә аларны колак салып тыңлый. Бу зинданда тикшерү үткәч, аларны төрле срокларга хөкем итеп, Чиләбе шәһәрендәге хезмәт-тәрбия колониясенә җибәрәчәкләр икән. Ә менә мондый эш арасында кайчак ул бәладән качып котылучылар да булгалый, имеш.

Станциядә поездлар бер-бер артлы үтеп тора. Барсы да халык белән тулы, давыллы туфаннан куркып качкан кебек, барсы да бер тарафка – Көнчыгышка таба агыла. Менә шундый поездларның берсе тоткын хатын-кызлар эшли торган ачык платформа янына килеп туктый. Вагоннардан сикереп төшкән пассажирлар вокзал эчендәге буфетка, азык базарына ташланалар, берсен-берсе этә-төртә чәйнекләренә кайнар су алалар. Бераздан, зың-зың итеп кыңгырау чылтырагач, итәкләренә ут капкандай, һәммәсе дә вагоннарына чаба башлыйлар.

Буфетта артыгын эчкәннәр, күрәсең, бер-берсенә кизәнә-кизәнә вокзалдан ике исерекбаш килеп чыга да перронда чынлап торып бар көчләренә сугыша башлыйлар, җиргә егылып, рәхимсез кыйнашалар, начар сүзләр белән сүгенәләр. Сәгате-минуты белән җыелган халык тын да алмыйча шаккатып тамаша кыла. Тоткын хатын-кызларны саклаучыларның икесенең дә күз карашы шунда төбәлгән.

Күрше рельстагы поезд менә-менә кузгалып китәргә тора, паровоз морҗасыннан очкыннар бөркеп чыгара, соңгы пассажирлар вагоннарга күтәрелә. Фәгыйлә ирексездән: «Их, шуның белән качып китсәң иде», – дип, эчтән ниятләп куя һәм йөрәге ешрак тибә башлавын сизә. Ә аның кулдашы, Наташа исемле яшь кенә чая хатын акрын гына:

– Мин тәвәккәллим, ычкынам. Әгәр теләсәң, әйдә, миннән калма, – дип, күмерле вагоннан җиргә сикереп төшә.

Озын-озак уйлап торырга вакыт юк. Кулындагы тимер көрәген ташлап, Фәгыйлә дә аның артыннан йөгерә һәм инде кузгалып китә башлаган сары вагонның асылмалы баскычына тотына. Наташа һәм шундагы бер егет аны вагон эченә кулыннан тартып күтәрәләр.

Йөк ташый торган вагон халык белән шыгрым тулы. Болай да тыгыз бит, ник утырттыгыз, дип, ризасызлык белдерүчеләр дә була. Әмма Наташа ,аларны ишетмәгәндәй, тимер мич янындагы ташкүмер ящигы өстенә утыра, бераз кысыла төшеп, Фәгыйләгә дә урын бирә. Шуның белән шаушу да басыла.

Тиздән Фәгыйлә үзе дә бераз тынычлана һәм кызу тимер мич янында җылыда башкаларның сөйләшкәнен мыштым гына колак салып тыңлап бара. Сөйләшүләренә караганда, бу халык арасында караклар, документсыз шикле кешеләр дә бар, аларны аулау максаты белән әледән-әле тикшерүләр үткәрелә, документсыз шикле кешеләрне кулга алалар икән. Бу капкынга эләгүдән ничек котылырга белмичә, Фәгыйлә куркуга төшә, поезд туктаган саен, ишеккә борчулы карана башлый. Үзенең хафалануын ул янында йокымсырап утырган юлдашына да әйтә. Икесенең дә һичнинди документы юк бит, монда бер генә минутка да калырга ярамый.

Алар шундый карарга киләләр һәм тиздән, поезд Чиләбе станциясендә туктагач, тавыш-тынсыз гына вагоннан төшеп калалар.

Ярым караңгы перронда халык мәш килә. Төрле багаж, төенчек күтәргән кешеләр, соңга калудан курыккандай, бер-берсен этә-төртә шәһәргә чыга торган капкага тыгыла. Кемнәрдер каршыга, поездга ашыга. Дүрт-биш минут дәвам иткән ыгы-зыгы арасында Фәгыйлә юлдашы Наташаны күздән югалта. Ул кинәт аптырап, як-ягына иләс-миләс каранып, шәһәр урамына китүчеләр артыннан ташлана. Арлы-бирле сугылып йөргәннән соң, кире вокзалга кайтып, поезд көтүчеләр арасында эзләнә. Ниһаять, тәмам алҗып, тез буыннары калтырый башлагач, залда буш урыннарның берсенә хәл алырга утырган көе авыр йокыга тала.

Күпмедер вакыт йоклаганнан соң, ул ниндидер тәмле искә уянып китә һәм түзә алмаслык ачыгуын сизә. Күзләрен ачып караса, үзенең вокзал ашханәсенә якында гына утырганын, кемнәрнеңдер ачык ишектән кергәнен-чыкканын күрә, алар белән бергә ул да эчкә керә. Кешеләр акча түләп кухня тәрәзәсе янына барып баса, ә Фәгыйлә өстәлләрдәге ризык калдыкларын ашарга керешә. Ул

иртәгесен дә, берсекөнне дә шулай тукланып, төннәрен залда поезд көтүче пассажирлар арасында йоклап җан асрый.

Көндезләрен, җай туры килгәндә, ул ашханә идәнен җыештыручыларга, кухняга ташкүмер кертүчеләргә булыша. Кухня эшчеләреннән берәрсенең вак бәлеш яки пилмәнне матур итеп ясый белмәве күзенә чалынса, ничек бөгәргә кирәген шундук аңлатып бирә. Фәгыйләнең бу һәвәслеген тиздән шеф-повар Анастасия түти дә күреп, аны үзенә булышчы итә. Вокзалда кунып йөрүче ялгызак икәнен белгәч, икәү бергә күңеллерәк булыр дип, үз өендә кечерәк кенә буш бүлмәсенә торырга кертә. Өстенә кияргә иске халатын, йон оекбашын бирә.

Күренеп тора, Анастасия эш йөртә белә торган булдыклы хатын. Төннәрен идән астында еш кына самогон кудырып сату итә. Өй артындагы сарайда симертергә куйган зур-зур ике дуңгызы бар. Кухнядагы аш-су калдыкларын алып кайтып дуңгызларны ашату, сарайны чистарту, төрле өй мәшәкатьләре – барсы да Фәгыйлә җилкәсенә күчә. Авыр булса да, Фәгыйләгә түзәргә туры килә. Дөньяның асты өскә килгән бу фетнәле заманда паспортсыз беркая барып булмый. Шулай карлы-буранлы кыш үтеп китә, кояшлы, җылы яз көннәре җитә.

Настя түтинең ялгызлыктан зарлануы күз буяу өчен генә булган икән. Милиция бүлегендә писарь булып хезмәт итүче сөяркәсе бар. Бик эчкече бәндә, гел самогон сорап аптырата. Тегесе бирмәсә, гауга куптара, тавышлануы такта стена аша ишетелеп тора. Пасха бәйрәме көнне дә кич белән ашап-эчеп, күңелле генә җырлап утырганнар иде.

– Беләм мин сине, үтәли күрәм, паспортсыз качакларны, сукбайларны җыеп, ярты бәягә эшләтәсең, – дип җикеренә башлады писарь. – Ачуымны китерсәң, якташым дип кызганып тормам, тотармын да иртәгә үк җиткерермен.

Көн буе эшләп тәмам алҗыган Фәгыйләнең ятып йокларга җыенган вакыты иде. Күрше бүлмәдән милиционерның янавын ишеткәч, нишләргә дә белмичә куркуга төште. Менә хәзер кереп кулга алмагае дип каушап калды.

Үзен кулга алып бераз тынычлангач, күрше бүлмәгә колак салып тыңларга тотынды. Аннан бернинди хәрәкәт, тавыш ишетелмәгәч, барлы-юклы кием-салымын җыеп төйнәде дә шыпырт кына чыгып ычкынды.

* * *

Төнге тынлыкка чумган шәһәр читендәге зур тимер юл станциясе, үзгә бер дөнья кебек, гөр килеп тора. Рәт-рәт тезелгән поездлар арасында әледән-әле паровоз кычкырткан, сузып-сузып сыбызгы сызгырткан тавышлар ишетелә. Әле анда, әле монда утлы фонарь тоткан кеше күренеп үтә. Вокзал каршындагы пассажир поезды янында чемодан, сумка тоткан кешеләр тыз-быз килә. Кемнәрдер — китүче, кемнәрдер — озатып калучы.

Ерак Көнчыгышка — Владивосток шәһәренә юл тотарга тиешле тизйөрешле поезд менә-менә кузгалып китәчәк икән. Фәгыйлә, тиз генә билет алып, төрле ярлы-ябагай йөри торган иң арзанлы гомум вагонга кереп утырды.

Вагон эче икегә бүленгән. Беренче бүлек чуар халык һәм төрле чемодан, кәрзин, капчыклар белән тулы, эчкә үтәрлек тә түгел, басып торырга да урын юк. Боларның күбесе инкыйлаб үгиләре, яңа власть белән килешә алмыйча, бәхет эзләп чит җирләргә күченүчеләр. Туган-үскән җирдән бөтенләйгә аерылу кыен булса кирәк, йөзләрендә әмәлсез гаҗизлек галәмәте күренеп тора.

Вагонның икенче бүлеген бер төркем диңгезчеләр – Петербургтан Владивостокка, хуҗасы ташлап качкан пароходка эшкә баручы команда арендага алган. Монда шактый иркенрәк, бүтән беркемне дә кертмиләр. Башка урын булмаганлыктан, Фәгыйләгә шунда бүлмә ишегенә аркасы белән сөялеп торырга, һәр чыккан-кергән кешегә, читкә тайпылып, юл бирергә туры килә.

Команданың капитаны, җиз якорьлы фуражка, зәңгәрсу китель кигән урта яшьләрдәге диңгезче, юл өстендә басып торган Фәгыйләне жәлләде бугай, аталарча кайгыртучанлык белән:

– И матурым, тынгысыз урында кунаклагансың. Болай ярамый, төенчегеңне ал да, әйдә, безнең якка кер, – дип, ян утыргычтагы берничә чемоданны өске киштәгә күчереп, бушаган урынны аңа бирде.

Инде күптән җылы сүз ишетмәгән Фәгыйлә, мондый ягымлы мөнәсәбәткә сөенеп, киң күңелле капитанга кабат-кабат рәхмәтләр әйтте. Аннары, төенчегенә башын куеп, кырын яткан хәлдә оеп, күзләрен йомды.

Ул иртәгесен якында гына кемнәрдер сөйләшкән тавышка уянып һәм бераз тыңлап яткач, шуны белеп алды: команданың повары тиф белән авырып, юлда хастаханәгә кереп калган. Шунын

аркасында менә өченче көн инде кешеләр җылы ризык күрми, рестораннан тукланырга күбесенең кесәсе сай, имеш.

Капитан белән сөйләшкәннән соң, бу эшкә Фәгыйлә үзе тотынды. Артельче үлчәп биргән азык-төлектән ресторан кухнясында төш вакытына менә дигән тәмле аш, итле карабодай боткасы, йөзем компоты пешереп, бөтен команданы сөендерде. Барыннан да бигрәк капитан мактады:

– Юкса көймә комга утырган иде, ярый әле син коткардың. Алайса, матурым, менә нәрсә: әйдә без сине штатка алабыз, диңгезче повар – кок булырсың, чит илләрне күрерсең.

– Юк, юк, диңгезче булмыйм, йөзә белмим мин, – дип көлеп, Фәгыйлә кул гына селтәде.

Чиксез-кырыйсыз киң дала, куе урманнар аша поезд ыжгырып алга бара. Меңнәрчә чакрымнарга сузылган юл һич бетмәс кебек, ялыктыра башлый. Күңелсезлектән котылу өчен, кешеләр домино, шахмат уйныйлар йә диңгезне сагынгандай, барысы бергә моңлы көйгә сузып җырлыйлар.

* * *

Күп газаплы авыр сәфәр азагына якынлашып килә. Менә Хабаровск шәһәре дә артта калды.

Иртәгә иртән Тын океан буендагы иң ахыргы шәһәр Владивостокка барып җитәчәкләр.

Кая барып бәрелергә белмәгәндәй каңгырап утырган караңгы чырайлы диңгезчеләр, ниһаять, бердәм тату гаилә кебек, күңелләре күтәрелеп уйный-көлә башлый. Тузгый чәчле шадра егет кенә, сүзгә катнашмыйча, башкалардан читтәрәк утыра һәм күз кырые белән генә әледән-әле Фәгыйләгә шикле каранып ала.

Чү, астыртын күзәтүче түгелме бу дип, борчуга төшә Фәгыйлә. Каушавын сиздермәс өчен, ул калтыраган куллары белән төенчеген актарырга керешкән була. Менә утардан киеп чыккан йон кофтасы иң өстә ята, аның ашханәдә эшләгәндә туплаган барлы-юклы акчасы шуның кесәсендә саклана. Мәгәр, гөнаһ шомлыгына каршы, куйган урынында акча юк. Фәгыйлә, үзәк өзгеч ачыну белән:

– Ах, акчамны урлаганнар, – дип кычкырып җибәрә. – Бая кухняга аш пешерергә чыкканда гына булавка белән эләктереп куйган идем бит. Берәрсе күреп торды микәнни?!

Бу күңелсез хәбәрдән бөтен команда авыр хәлгә калып, кинәт киеренке тынлык туа. Кешеләрнең ни әйтергә белмичә, бер-берсенең күзенә карарга уңайсызланганын күреп, моңа сәбәпче булган Фәгыйлә үзе дә: ай, ялгыш артык кычкырдым, ахрысы, дип уңайсызланып, әчтән үкенә башлый.

Шулчак капитан аягүрә торып баса. Бөтен команданы ашыкмыйча күздән кичергәннән соң:

– Моннан күп вакытлар элек, җилкәнле флот заманында, төзәлмәс каракларны, корабта коткы таратучыларны диңгездә кеше яшәми торган кыргый утрауда төшереп калдыра торган булганнар, – ди. – Әгәр ымсынып алган кеше акчаны хәзер үк кайтарып бирмәсә, без аны беренче тукталышта ук поездан куып төшерәчәкбез. Чөнки андый ышанычсыз кеше белән диңгезгә чыгып булмый.

– Шулаен шулай да, әмма урлаучының кем икәнен ничек беләсең? Шунсыз төшереп калдырып булмый бит, – дип, реплика ташлый бер түземсезе.

– Хәзер беләбез аны. Балтикада пароходыбыз минадан шартлап һәлак булганчы, без барыбыз да бергә эшләгән кешеләр, бер-беребезне яхшы беләбез, бер-беребезгә ышанабыз. Аз таныш булган бердәнбер кеше, юлга чыгар алдыннан гына кадрлар бүлеге җибәргән яңа кочегар бар. Әйдәгез сорыйк әле, акчаны кем алганын шул күрмәгәнме яки үзе нәфес коткысына бирелмәгәнме? Ул шунда якында гына утыра бит. Әгәр дөресен әйтсә, без дә аның хәленә керербез.

Яңа кочегар дигәннәре Фәгыйләгә шикле күренгән әлеге тузгый чәчле егет икән. Үзе турында сүз кузгалгач, башы түбәнрәк иелде, таяныч эзләгәндәй, әйләнә-тирәгә аптыраулы каранды.

Теге реплика ташлаган матрос, әле һаман тынычлана алмыйча, каршы чыга:

– Җәмәгать, акчаны кем чәлдергәнен тәгаенләми торып, гаепсез кешегә яла ягабыз, ялгышабыз түгелме?

Вакыйганың болай зурга китүенә уңайсызланып, Фәгыйлә борчуга төште, юкка гына әйттем дип, әчтән үкенә башлады. Тузгый чәчле егет исә, аңа таба борылып:

– Мадам, сезнең акчагызны мин алдым, зинһар, кичерегез, – дип гафу үтенә һәм акчаны, күкрәк кесәсеннән алып, Фәгыйләгә бирә. – Алтын балдаклы булгач, калын кесәле дип уйлаган идем. Төенчек эченнән күренеп торган кәгазьне ничек алганымны сизми дә калдым. Сукбайлыкта өйрәнелгән начар гадәт онытылып бетмәгән, күрәсең. Бүтән беркайчан кеше әйберенә тимәскә, тырышып эшләргә сүз бирәм. Минем бүтән беркемем дә, беркая барыр җирем дә юк. Мине үзегездән аерып, тагын сукбайлыкка дучар итеп ташлап калдырмавыгызны бик үтенәм.

Катгый чырайлы капитан күзләре белән генә сизелер-сизелмәс елмаеп куя. Үз власте белән хәл итәргә хокукы булса да:

– Йә, нишлибез, егетләр! Кем ничек уйлый? – дип, бөтен командага мөрәҗәгать итә.

Вагонда тирән тынлык туды. Бер-берсеннән киңәш көткән сыман кайберләре үзара карашып торгач, арадан берсе үзалдына уйлангандай гына әйтә куйды:

– Да-а, авыр язмышлы сукбай, ташлап калдырырга ничектер кул бармый.

Аңа тагын берничә кеше кушылды, төрле яктан:

– Дөрес әйттең, чынлап та, кызганыч.

– Куып чыгарсак, тагын юлдан язмагае.

– Әйе, әйе, егет кызганыч, – дип әйтүләр ишетелде.

Шуның белән хөкем вәссәлам. Егетнең хәленә кереп һәм каты кисәтеп, бер юлга аны гафу итәргә булдылар.

Бу күңелсез вакыйганың шулай уңай хәл ителүенә Фәгыйлә дә канәгать. Тузгый чәчле егетнең шат йөзенә карап утырган шәпкә: «Минем хәлем дә нәкъ аныкы кебек, таянырлык беркемем дә, барып ышыкланыр җирем дә юк бит. Әгәр алсалар, әллә шул пароходка повар булып керим микән», – дип, икеләнүле уйларга чумды.

Мәңге бетмәс кебек озын тоелган күп газаплы ялыктыргыч юл, ниһаять, бетте. Төрле сәбәпләр аркасында туган-үскән җирен ташлап чит-ят җирләргә бәхет эзләп китүчеләр белән шыгрым тулы поезд Владивостокка барып җитте. Чит илләргә юл тотучылар, вагоннардан төшү белән, соңга калудан курыккандай, абына-сөртенә якындагы диңгез вокзалына таба ташлана, һәркайсы диңгез корабына билет алырга ашыга.

Ә Балтикадан күчеп килүче диңгезчеләр командасы пароходчылык идарәсенә юнәлә, кичә повар булырга ялланган Фәгыйлә дә алар белән бергә. Әлеге дә баягы һаман бер киртә: кадрлар бүлегендә паспортың юк дип, аны эшкә алмадылар. Инде нишләргә, бөтенләй таныш түгел ят шәһәрдә ялгыз башың кая сугылырга?

Шулчак ул үзе дә көтмәгәндә: «Чү, читкә китүчеләрдән берәрсе, гаилә әгъзасы итеп үзенә ияртмәс микән?» – дип уйлап куя. Поездда бер кызның ыгы-зыгы арасында әнә шулай вагонга утыруы турында кемдер сөйләгән иде бит.

Әнә шул үзе уйлап чыгарган хыялый ният белән Фәгыйлә портка тәпили. Анда тимер-бетон причалга яны белән туктаган зур пароход янында халык мәш килә. Барысы да палубага менә торган асылмалы баскычка таба омтыла. Һәркемнең паспортын, билетын җентекле тикшереп үткәрәләр. Чират торучылар арасында кәләпүшле мөселманнар да бар. Фәгыйлә сүз катып караган агайлардан берсе, аны тыңлап та бетермичә, иңбашларын җыерып кына тискәре җавап бирде дә читкә борылды. Икенчесе, акылга зәгыйфь мәзәкче күргәндәй, күзләрен шар итте.

Беркатлы балаларча мәгънәсез эш белән шөгыльләнгәнен Фәгыйлә, ниһаять, үзе дә абайлап алды, үзен-үзе кызганудан күз яшьләренә буылды. Каргышлы илне ташлап китүчеләр барсы да аңа бик канәгать, бәхетле кебек тоелдылар.

Акрын гына кузгалып киткән зур пароходны Фәгыйлә, күзләре белән озатып, еракта томансу пәрдә эчендә эреп югалганчы онытылып карап торды. Бераздан аңына килеп әйләнә-тирәсенә караса, причал инде бушап калган. Әлерәк кенә киткән пароходның швартовларын (чалкаларын) тумбадан ычкындырган ике эшче генә якындагы склад ишегеннән аны гаҗәпсенеп күзәтеп тора иде.

Төенчеген култык астына кыстырган Фәгыйлә порттан чыкты да, кай тарафка юл тотканын уйлап тормастан, тротуар буйлап башын аска иеп акрын гына китеп барды.

Үзәк урамнан бара торгач, аяклары алҗыган Фәгыйлә тимер юл вокзалына килеп керде. Буфеттан кыздырылган балык белән бер кисәк икмәк алып тамак ялгагач, бөтен гәүдәсе авыраеп китте, күзләре йомылды. Бу төнне ул шунда пассажирлар залында урындык артына сөялеп утырган хәлдә йоклап үткәрде.

Фәгыйлә иртәгесен җыештыручылар дөбер-шатыр эшләгән тавышка уянып китте. Күзен ачып караса, кояш инде шактый югары күтәрелгән, әлерәк кенә Мәскәү поезды килеп туктаган. Юлчыларның күбесе мөһаҗирләр икәне күренеп тора, вагоннан төшү белән, ашык-пошык сорашалар да диңгез вокзалына пароходка билет алырга йөгерәләр. Фәгыйлә дә аларга иярә, берәр якташ, ирен, каенатасын белгән, ишеткән кеше очрамасмы дип эзләнә. Пароходка утырырга ниятләнеп тә карый.

Әмма аны бу юлы да утыртмыйлар. Мөһаҗирләр тулы зур пароход кузгалып китә. Нәүмиз Фәгыйлә причалда ялгыз торып кала, күзләре томанлана.

Мәгәр причалда ул үзе генә түгел, аны кичә күреп калган ике кеше бүген дә шунда якында гына ни турындадыр сөйләшеп сәерсенү белән күзәтеп тора икән. Берсе куш иякле, чалыш авызлы, бик тынгысыз булса кирәк, кулдашының терсәгенә кагылып, саф татар телендә:

– Шакир, карале, бу кичәге пароходны өзгәләнеп озатып калган мәткә ич, – ди. – Бүген дә кемнедер озатты. Кием-салымы шәптән булмаса да, үзе җиләк кебек, күз төшмәслек түгел.

Шакир дигәне зур, таза гәүдәле сазау егеткә охшаган. Эчке ризасызлык белән:

– Тс-с, әдәпсезләнмичә, чамалабрак сөйләш, – дип искәртү ясады.

Фәгыйлә аларның сөйләшкәнен ишеткәч, көтмәгәндә иң якын кешеләрен очраткандай шатланды гына:

– Һи-и, колакларыма ышанмый торам, чынлап та, үзебезнең мөселман әһелләре икән. Әссәламегаләйкем, мөхтәрәм милләттәшләр!

Әмма милләттәш агайлар якты чырай күрсәтергә ашыкмыйлар. Яшь чибәр хатынның артык ачылып китүен өнәмәделәр, җилбәзәкләрчә әрсезлеккә санадылар бугай, теләр-теләмәс кенә, ничектер ягымсыз исәнләшәләр. Чалыш авызлысы Фәгыйләне баштанаяк җентекләп күздән кичерде дә, өнәмәвен яшермичә, мыгырдап куйды:

– Мөслимә башың белән шамакайланып йөрмә монда, бар, юлыңда бул, китә бир.

Икенчесе дә, алай каты бәрелмәсә дә, җиңелчә әрнү белән:

– Дөрестән дә, бер дә килешкән эш түгел, – дип шелтәли. – Бармагыңда алтын балдак, ә өстеңдә керләнеп беткән иске халат. Болай бер дә килешми. Бераз чистарак, пөхтәрәк киенеп йөрергә кирәк бит.

Моны ишетү Фәгыйләгә бик авыр иде. Үзенең тышкы кыяфәте өчен йөзенә оялу катнаш ачыну чыгарып, тирән дулкынлану белән җавап кайтарырга теләде ул:

– Әгәр минем хәлемне белсәгез... – Әмма башланган сүзен әйтеп бетерә алмыйча, күз яшьләренә буылып причалдан чыгып йөгерде.

Бу көн аның өчен аеруча авыр булды. Кая сугылырга белмичә, күңелсез уйларга чумган хәлдә урамнарда йөри торгач, ул шәһәр кырыендагы кечерәк кенә базарга барып чыкты һәм юл читендә китап сатып утыручы ак сакаллы карт янында ихтыярсыздан тукталып калды. Ашъяулык хәтле генә кечкенә җәймә өстендә яткан төрле китаплар арасында берсе аның күзенә таныш чалынды. Инде шактый таушалган, тышлыксыз булса да, үзенең шактый зур форматы, калынлыгы һәм кәгазенең саргылтсу төсе белән нәрсәнедер хәтерләтә, кайдадыр күргән кебек тоела. Китапны кулына алуга таный һәм, битен ачып карау белән, шигырьне укып та тормастан күңеленнән кичерде:

Якын дустым! Сиңа миннән киңәш шул:
Кешеләргә сереңне сөйләмәс бул.
Эчеңдә нәрсә янганын үзең бел,
Үзең кайгыр, үзең егъла, үзең көл.

Бу – Тукай әсәрләренең беренче зур җыентыгы икән. Акчасы юклы-барлы гына булса да, Фәгыйлә аны шундук сатып алды. Сөекле шагыйрен күргәндәй, күңеле күтәрелеп китте. Вокзал каршындагы кечкенә бакчада сәгатьләр буе каңгырып утырган авыр вакытларда шуны укып юана, рухи таяныч таба торган булды.

* * *

Причалда зур складтан сулдарак порт эшчеләре ашханәсе бар. Фәгыйлә аны узып барышлый очраклы рәвештә генә күреп алды һәм бераз тамак ялгап алырга булды. Чиратка басып кухня тәрәзәсеннән балыклы аш белән икмәк алгач, кая барып төртелергә белмичә аптырап, бермәл әйләнәтирәгә каранып торганнан соң гына, ул иң аргы өстәлдә буш урын күрде.

Фәгыйлә тиз генә барып, ашын, икмәген өстәлгә куйды. Үзе табуреткага утырып, төенчеген тез өстенә урнаштыргач, башын күтәреп караса, каршында өченчекөн аны кимсетеп әрләгән ике татар ашап утыра иде.

Аны күрү белән, тегеләр дә, үз күзләренә үзләре ышанмагандай, сәерсенеп калдылар. Өлкәнрәге яланбашлы, чал кергән сирәк чәчлесе Фәгыйлә алдындагы төенчеккә бермәл карап торды да:

– Ник аны гел үзең белән йөртәсең, бирнәң түгелдер ич? – дип, чәнечкеле елмаеп куйды.

Фәгыйлә, әрем телле агайга күтәрелеп карамастан:

– Юк, бирнә түгел, төрле чүпрәк-чапрак кына, – дип, кашыгын кулына алды. – Калдырырга урыным булмаганлыктан, үзем белән йөртергә туры килә.

Милләттәш агайлар ничектер уңайсызланып калдылар. Яшьрәге бу күңелсез әңгәмәне икенчегә борып җибәрергә теләде бугай:

– Тукта, чүпрәк-чапрак кына түгел шикелле. Төенчегеңнең ачык кырыеннан китапка охшаган нәстә күренеп тора түгелме?

– Әйе, китап. Тукай шигырьләре. Кичә генә базардан сатып алдым. Мин аны яраткан шагыйрем төсе итеп саклыйм. Халкыбызның тиңдәшсез зур талантлы шагыйре бит ул. Аның:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы,–

дип башланган шигырен һәр мәктәп баласы кечкенәдән яттан белеп үсә, гомере буе хәтерендә саклый!

Яңа танышларның яшьрәге, ризасызлык белән:

– Акыллым, сөйләвеңә караганда син йомры башлы, укымышлы күренәсең, – диде. – Ә тормышта үзеңне-үзең кимсетеп йөрисең. Барып сыенып оям да юк, дидең. Мондый сукбайлыктан нинди рәхәт табасың?

Бу ихласлы кызыксынудан Фәгыйләнең кинәт күңеле тулып, бик нәүмизләнде. Акланырга теләгән сыман:

– Рәхәт эзләүдән түгел, зур бәхетсезлеккә дучар булдым. Хәзер миңа кем икәнемне яшереп йөрергә туры килә, – дип башлаган сүзен әйтеп бетермичә, телен тешләде. Артык сөйләнеп үзен тоттырудан шикләнде.

Шунлыктан ул ашык-пошык ашап, тиз генә амин тотты да моннан чыгып ычкынды. Причалдан чыккач та, әле һаман тынычлана алмыйча, Габдулла Тукайның:

Эчеңдә нәрсә янганын үзең бел,
Үзең кайгыр, үзең егъла, үзең көл,–

дип әйткән гыйбрәтле киңәшен такмаклады.

Мәгәр шул көннән башлап яңа танышларының Фәгыйләгә карашы сизелерлек йомшарды. Ашханәдә кассага чират торганда, үзләре янына чакырып алалар, бергә утырып ашаганда, сүз арасында читләп-читләп аның үткәне, кайда туктавы, бу тирәдә нишләп тулгануы белән кызыксыналар.

Берничә көн аралашкач, Фәгыйлә аларның агалы-энеле брадәрләр икәнен, портта килгән-киткән пароходларның чалкаларын кабул итеп, тумбага элэктерүче-ычкындыручы булып эшләгәннәрен белде.

Икесе бер анадан туган булсалар да, алар бер-берсенә аз гына да охшамаган. Өлкәне Закирҗан исемле. Кыска буйлы, салынкы кашлы ир уртасы кеше. Тормышка кара күзлектән караучы, урынлы-урынсыз төрттерүчән икәнлеге күренеп тора. Менә бүген дә ашханәдә очрашу белән чәнечкеле сүзләр әйтеп көләргә тотынды:

– Ә-ә, алтын балдаклы хәерче, тагын мөһаҗирләр пароходын озатырга килдеңме? Әллә үзең дә китәргә телисеңме инде?

Аның энесе Шакирҗан, киресенчә, ягымлы елмаеп исәнләшә, абыйсының тозсыз төрпәлеген йомшартырга теләгәндәй:

– Кәефләр ничек? Ыгы-зыгылы тынчу вокзалда төн үткәрү кыен булгандыр? – дип кайгыртучан сораштыра.

– Мин ачык һавада, вокзал каршындагы скверда утырган көенчә йокылы-уяулы төн үткәрдем. Чөнки вокзал кешеләре минем поезд көтүче пассажир түгел икәнемне беләләр. Хәзер миңа сукбай итеп карыйлар, залга кертмиләр.

Фәгыйлә моны артык сыкранмыйча әйтсә дә, үзе бик алҗыган, тәмам хәлсезләнгән, нәүмизлеге йөзенә чыккан иде. Брадәр швартовчылар моны күреп кызгандылар, күңелләрендә аңа ничек тә ярдәм кулы сузу теләге туды бугай. Үзара күзгә-күз карашып алалар да, Фәгыйлә белән якын таныш кебек җанланып сөйләшә-сөйләшә, өметсез уйларын таратырга тырышалар. Ә кичкырын, эш вакытлары беткәч, әйдә, бездә кунарсың, дип, аны да ияртеп китәләр. Башта бераз икеләнсә дә, йортсыз-җирсез Фәгыйлә, Аллага тапшырып, барырга мәҗбүр булды.

Шакирҗанның өе бистә читендә диңгез култыгына караган сөзәк тау итәгенә урнашкан икән. Түбәсендә калайдан кисеп ясалган горуранә кыяфәтле этәч кукраеп тора. Капкадан керүгә, чылбырга тагылган көлтә койрыклы зур сары эт хуҗасын сырпаланып каршылый. Абзар ишеге янында күшәп яткан ак кәҗә, кунак белән танышырга теләгәндәй, килеп Фәгыйләгә сыена.

Тәүлек буе вахта торып кайткан хуҗаларның арыганлыгы күренеп тора. Шунлыктан җиңелчә ашап-эчкәч тә Закирҗан одеял, мендәр алып чоланга йокларга чыгып китә. Шакирҗан түр яктагы ян тәрәзә кырыендагы караватта Фәгыйләгә урын җәеп биргәннән соң, үзе мич артындагы тапчанда урын әмәлләп ята.

Күпме вакыт йомшак урын-җир күрмәгән һәм тәмам хәлдән тайган Фәгыйлә башы мендәргә тию белән изрәп китә, күз кабаклары авырая, татлы йокыга тала башлый.

Шунда ул кемдер төрткәндәй сискәнеп уяна. Тукта, бу чит-ят ирләр янына мин ник килдем әле, дип, шомга төшә. Төнге караңгылыкта кыштырдап тавыш ишетелгән саен кемдер йөргән, акрын гына аяк очларына басып якынайган кебек тоела аңа.

Ул таң алдыннан гына, ниһаять, каты йокыга китә.

* * *

Фәгыйлә ниндидер сәер ят тавышка уянып һәм кайда икәнен, кем борчыганын абайлый алмыйча, бермәл йокылы-уяулы ятты. Күзләрен ачып караса, иртәнге эңгер сыегая башлаган, яңа көн туып килгән вакыт. Караватт янындагы яртылай ачык тәрәзә каршында ак кәҗә мәэлдәп тора. Шундук йокысы ачылган Фәгыйлә, көтелмәгән гаҗәпсенү белән:

– И сакалбай, син уяттыңмыни мине? – дип, ихтыярсыз елмаеп куйды.

Ул, Шакирҗанны уятмас өчен, аяк очларына басып, акрын гына ишегалдына чыкты. Ак кәҗә аны күрү белән килеп сыена, ничектер түземсезләнеп мәэлди-мәэлди сырпалана. Шунда Фәгыйлә, аның сөт тулып калынайган җиленен күреп, якындагы казык башында эленеп торган чүлмәкне ала да, чүгәләп, тынгысыз кәҗәне сава башлый.

Бераздан торып чыккан Шакирҗан хәйран кала:

– Һи, миннән алданрак терешкәнсең икән! – Гомер булмаган хәл, кичә кәҗәне саварга онытканмын. Күземне ачуга, шул исемә төште. Ашыгып чыксам, син инде савып утырасың икән.

– Җилене авырткан булса кирәк, тәрәзә каршында мәэлдәп ул мине үзе уятты, – ди Фәгыйлә.

Шакирҗан кәҗә һәм сугымга дигән үгез бозауны өй каршындагы яшел чирәмгә чыгарып арканлый. Фәгыйлә тагарак янында чыр-чу килгән тавык-чебешкә көрпә болгатып бирә. Аннары өйгә кереп, бергәләшеп иртәнге аш әзерлиләр.

Алар күңелле сөйләшә-сөйләшә ашап утырганда, чоланнан Закирҗан да килеп керә һәм үзалдына сөйләнгән сыман:

– Әһә, борчаклары пешкән икән, юкса болай чөкердәшмәсләр ие, – дип астыртын төрттереп ала.

Әмма Шакирҗан, аның тупас кинаясен ишетмәгәндәй, сүзсез ашый бирде.

Болар агалы-энеле икесе дә балта осталары, портта бер тәүлек дежур торганнан соң, буш көннәрендә тагын кайдадыр эшләштергәлиләр икән. Бүген дә, ашап-эчкәннән соң, эш кораллары тулы сумкаларын иңбашларына асып, юлга кузгалдылар.

Капкадан чыккач, Шакирҗан өйгә кире борылып керде:

– Әйтергә оныта язганмын, мунча бездән ерак түгел, күрше урам чатында гына. Теләсәң, чабынып, юынып кайтырга мөмкин. Сабын, мунчала, сөлге алып барырга онытма. Каен себеркесе чоланда эленеп тора.

Инде күптән мунча күрмәгән, керләнеп беткән Фәгыйлә бер дә кыстатып тормастан, бик рәхәтләнеп мунча кереп кайтты. Чәй эчеп, әзрәк ял итеп алгач, беренче мөмкинлектән файдаланып, иң әүвәл өйлә намазы укыды. Аннары бөтен хуҗалыгын ышанып калдырган Шакирҗанга рәхмәт йөзеннән мендәр тышларын, тәрәзә пәрдәләрен, үзенең иске халатын юып киптерергә элде, идәннәрне юып чыгарды. Шакирҗан әйтеп калдырган ит, карабодай ярмасы белән кичкә аш, ботка пешереп куйды.

Кичкырын түр тәрәзәдән диңгез култыгына карап утыра торгач, ул тагын борчулы уйларга чумды. Закирҗанның иртәнге пычрак сүзләре, исенә төшеп, йөрәкне әрнетә. Хәер, чит ир белән аулак өйдә кунган хатын турында башкаларның да шулай уйлавы бик ихтимал бит. Юк, юк, моңа юл куярга ярамый. Шакирҗан кайту белән, рәхмәт әйтеп, моннан тизрәк ычкынырга, фатир һәм эш эзләргә кирәк.

Фәгыйлә әнә шундый уйлар белән йөргәндә, төштән соң Шакирҗанны атлы арбада шифаханә кучеры кайтарып куйды һәм култыклап өйгә керергә ярдәм итте. Көтелмәгән бәла: тар тактага басып биектә эшләгәндә, таеп егылып, сул аягын сындырган. Шифаханәдә гипслап, өйдә дәваланырга кайтарганнар.

Аның чырае көл кебек, иреннәре кара көйгән. Әз генә кыймылдаса да, сызлануы йөзенә чыга, ишетелер-ишетелмәс кенә сыкранып куя. Өйдә аны үзен генә калдыру мөмкин түгел. Шуңа күрә Фәгыйләгә китү турындагы ниятен кичектереп, авыруны караучы булырга, аш-су әзерләргә, йортта барча эшне башкарырга туры килер.

Төнне авыр үткәрсә дә, иртән Шакирҗанның газаплы сызлавы бераз басылды шикелле. Гипслы аягын борчымас өчен саклык белән торып утырып, тамагына капкалап, даруын эчте:

– Бик белеп әйткәннәр: саулык – иң зур байлык. Сәламәт булмасаң, тормышның яме китә, берни эшли алмыйсың, – дип, ачыну катнаш шаярту белән үзеннән-үзе көлгән була. – Фәгыйлә, ярый әле син бар, югыйсә бөтенләй ярдәмчесез калачак икәнмен.

Фәгыйлә көнозын аяк өстендә, эш артыннан эш табылып кына тора. Шулай да, юк вакытны бар итеп дигәндәй, бүген төштән соң бер бушрак арада ул түр тәрәзә янына утырып, беркөн базарда сатып алган китабын актара башлады. Яттан белгән шигырьләрнең исемен күргән саен, якын танышын очраткан кебек, сизелер-сизелмәс кенә көлемсерәп куя.

Аны күзәтеп яткан Шакирҗанга бу сәер тоелса кирәк, дусларча шаярту белән:

– Һәр сәхифәсен ачкан саен елмаясың. Нинди китап ул, бик хикмәтлемени? – дип кызыксынды.

– Менә үзең тыңлап кара, – ди Фәгыйлә һәм җанланып укый башлый:

Җиһанда үлми һәрбер ыңгырашкан,
Вә юлны тапмый калмый һәр адашкан.

Көрәш угърында ар, тал, тирлә, имгән;
Өмид итмә булышмакны ләимнән.

Сәгадәт талына менсәң — үзең мен;
Ни ярдәм килсә дә килсен үзеңдин.

Ә менә монысы тагы да хикмәтлерәк, тагы да тирәнтенрәк уйлар уята:

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле, –
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзелеп-өзелеп кенә әйтеп бирә
Татар күңеле ниләр сизгәнен,
Мескен булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

– Дөрес әйтәсең, чынлап та, тирән эчтәлекле, уйландыра торган шигырьләр.– Шакирҗан яткан җиреннән торып утырып, кызыксыну белән сораштыра бирә: – Фәгыйлә, карале, боларны аңларга, болай баш йөртә белергә сине кем өйрәтте? Әллә тумыштанмы, үз тырышлыгың белән ирештеңме?

– Кем әйтмешли, анысы да, монысы да булгандыр инде. Минем әтием дә, әнием дә мөгаллимнәр иде. Узганда-барганда күрше авылларның мөгаллимнәре дә кергәлиләр, чәй янында халкыбызның фаҗигале язмышы, туган тел, әдәбият, мәгърифәт турында әңгәмә коралар. Мин аларны кызыксынып тыңлый идем, китапларда, газета-журналларда басылган шигырьләрне, хикәяләрне килү белән ябырылып укый идем. Боларның тәэсире, мөгаен, булмый калмагандыр.

Мондый әңгәмәләр аларга бер-берсе белән якыннанрак танышырга мөмкинлек бирә. Фәгыйлә үзе турында барсын әйтеп бетермәсә дә, Шакирҗанның бирегә моннан җиде ел элек, Лена елгасы буендагы алтын приискаларында забастовкалар бастырылгач, эзәрлекләүдән качып килеп, шушында оя корганын белә. Хатыны былтыр көз йөрәк авыруыннан вафат булган. Шуннан бирле ялгыз яши. Үзе эштә вакытта йортны эте Актырнак саклый, күрше балыкчы карт күз-колак була. Аннары Мәкәрҗәдә йөкче булып көн күрүче абыйсы Закирҗан да гаиләсе белән күчеп килеп монда төпләнә. Гомумән, шәһәрдә татарлар байтак, базарда, кибетләрдә еш очрыйлар, үзара йөрешәләр, аралашалар икән.

* * *

Җәй уртасында, болытлы караңгы төннәрнең берсендә, таң алдыннан һич тә уйламаганда-көтмәгәндә портка дистәләрчә япон кораблары кереп кораллы гаскәр төшерә. Шуның катнашы белән шәһәрдә власть акгвардиячеләр кулына күчә, эш башында утыручыларны кулга алулар, атулар башлана. Бик күпләр төн карасы астында шәһәр тирәсендәге урманнарга, моторлы баркасларга төялеп, чит илләргә качып китә. Югыйсә корал тотарга яраклы ир-атны ирексезләп армиягә алалар. Ә аягы төзәлеп бетмәгән Шакирҗан анда-монда чыкмыйча күбрәк өйдә утыра, вак-төяк эшләрдә Фәгыйләгә булышкалый.

Көндезге мәшәкатьләрдән соң кичке аш әзерләгәндә, ишегалдында кинәт Сарбайның ярсып өргәне ишетелде. Тәрәзәдән карасалар, капкадан урта буйлы, сакаллы диңгезче кергән, эт яныннан

үтеп китә алмыйча басып тора. Җиз төймәле күгелҗем китель кигән, кулында шактый зур сумка. Төп кебек базык гәүдәсеннән, бөтен килбәтеннән көч-куәт бөркелеп тора. Шакирҗан аны күрү белән танып алды:

– И-и, кунгас капитаны Борһан ич бу! Күптән күренгәне юк иде, кайдан калкып чыккан тагын? – дип чыгып каршылады ул кунакны. Өйгә кергәч Фәгыйләгә карап сагаеп калганын сизепме, ул аны тынычландырырга ашыкты: – Борчылма, чит кеше түгел, бертуган абыем кызы. Фәгыйлә сеңлем, әйдә, табыныңны җәй.

Кунак буш кул белән килмәгән. Сумкасыннан алып тозлаган балык, бишәр банкы кызыл икра һәм кысла консервасы чыгарды. Шундук өстәл тирәли җыелып утырдылар.

Мәгәр кунак каядыр ашыга бугай. Бераз ашагач-эчкәч, стенадагы сәгатькә карап ала да:

– Шакир абый, мин зур йомыш белән әле. Киңәш сорап килдем,– дип сүз башлады кунак.– Үзең беләсең, бу мәхшәргә, җәберләүләргә түзә алмыйча хәзер күпләр чит илгә күчеп китә. Бу зәхмәтле чир безнең командага да йокты. Иртәдән кичкә хәтле һаман шул хакта бәхәсләшү бара – китәбезме, юкмы? Шакир абый, син күпне күргән башлы кеше. Синең акыллы киңәшеңне тыңлап, без бу кунгасны шалкан бәясенә генә сатып алдык. Тоткан балыгыбызны порт ашханәсенә сатарга ярдәм итәсең. Менә тагын киңәш сорап килдем. Безгә нишләргә: китәргәме, юкмы? Ничек уйлыйсың?

– Юк, туганкаем, тиктомалдан болай җиңел генә хәл итә торган мәсьәлә түгел бу,– ди Шакирҗан.– Мин аны үзем дә байтактан бирле уйлап йөрим, әмма һич тә очына чыга алмый идем. Атаклы шагыйрь Габдулла агай Тукаев ул хакта инде күптән йөрәккә үтәрлек ачык итеп әйткән:

Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;
Бәйләмеш бу җиргә безне Тәңребез (гыйззе вә җәл).

«Китмибез!» дигән бу хикмәтле шигырьне мин Фәгыйлә сеңлем авызыннан ишеттем. Хикмәтле вәгазь кебек әледән-әле искә төшеп тора.

– Әһә, бу җиргә безне Тәңребез бәйләмеш, китмибез, дигәнме?! Бик дөрес әйткән. Алайса, без дә китмибез, вәссәлам! – Капитан Борһан, өстеннән авыр йөк төшкәндәй, җиңел сулап куйды.– Шакир абый, белми идем, укымышлы мөлаем сеңлең бар икән. Хәерле киңәшегез өчен икегезгә дә зур рәхмәт.

Кунакны озатып кергәч, Шакирҗан, уңайсызлану белән:

– Бая сеңлем дип әйткән өчен ачуланма инде, ничектер ялгыш, үзеннән-үзе килеп чыкты,– дип гафу үтенгәндәй итте.

– Зарар юк, ул хакта бер дә борчылма.– Фәгыйләнең авыз кырые белән генә сизелер-сизелмәс елмаюы чалынды.– Алайса, мин дә сине Шакир абый дип йөртермен. Күрше-күлән алдында да уңайлырак булыр.

* * *

Беркөн Шакирҗан балыкчы капитан алдында сеңлем дип атаганнан бирле, Фәгыйлә яңа урында үзен иркенрәк тота башлады. Әйткәнне көтеп тормастан, йорт эшләрен үз белдеге белән башкара. Буш араларда берәр эш табылмасмы дип, сирәк-мирәк шәһәргә дә чыккалый. Ире Бәхтияр турында ишеткән-белгән берәр якташы очрамасмы дип, төньяктан поезд килгән сәгатьләрдә вокзалда булгалый.

Ә базарга барган беркөнне ул теге ак сакаллы картның борынгы китаплары арасында шәмәхә кара белән гарәпчә кулдан язылган калын дәфтәргә тап булды. Алып караса, атаклы «Йосыф китабы», имеш! Шактый таушалган булса да, танып укырлык әле. Фәгыйлә шатлыктан чүт кычкырып җибәрмәде. Ул кульязма китапны шундук сатып алып, урамда укый-укый кайтты.

Ә эш һаман табылмый, ялкау әрәмтамак кебек һаман чит кешедә яшәргә туры килә. Бу хәл шактый озакка сузылды бит инде. Вак-төяк йомыш белән кергәли торган күрше-күлән дә, йөрешә торган таныш-белешләре дә Фәгыйләгә Шакирҗан хатыны итеп карыйлар. Хәтта сирәк-мирәк килгәләүче абыйсы Закирҗан да болар турында: никахлап өйләнешмичә генә ир белән хатын кебек торалар дип уйлый. Фәгыйлә моны авыр кичерә, бу гайре табигый кыенлыктан ничек котылырга белмичә көенә.

Җитмәсә, үч иткән кебек, Шакирҗанның да кәефсез вакыты. Аягы күптән төзәлүгә карамастан, менә елдан артык инде эшсез йөри. Чөнки портта японнар хуҗа, һәркайда шулар башбаштаклык итә.

Мәгәр замана ыгы-зыгылы, авыр булса да, тормыш тукталып тормый. Эреле-ваклы мәшәкатьләре, кайгы-шатлыклары белән үз юлыннан өзлексез бара бирә. Әнә һичнигә карамастан, капитан

Борһан да мәш килеп, хатыны Салисәнең туган көнен бәйрәм итәргә әзерләнеп йөри. Шакирҗан белән бергә кунакка Фәгыйләне дә чакырганнар иде. Ләкин Фәгыйлә каршы төште:

– Һич бара алмыйм, кеше көлкесенә калырга теләмим, – диде.

– Юк, бармый ярамый, сеңлем, – дип, Шакирҗан аны күндерергә тырышты. – Очраган саен Салисә гел сине сораштыра, танышырга тели. Кабат-кабат әйтеп чакырды, алып килмәсәң, бик үпкәлим, диде.

Шуңа күрә Фәгыйлә теләмәсә дә барырга мәҗбүр. Шуның өстенә хәстәрле Шакирҗан юбилярга бүләккә япон халаты – киң итәкле, кыска җиңле, сары чәчәкле матур кимоно алып куйган икән. Ядкарьне киңәшмичә үзе генә әзерләгән өчен уңайсызланган сыман:

– Салисә буйга синең белән бер чамада, шуны күздә тотып алдым. Кая ничек ята икән? – дип, затлы халатны Фәгыйләнең иңбашына салып, җиңелчә шаяртып алды.

Алар барып кергәндә, кунаклар инде җыелган иде. Хуҗа хатын Салисә тәрәзәдән күзәтеп торган, ахры, ишектән керүгә, беренче булып ачык йөз белән:

– Әйдәгез, әйдә, рәхим итегез. Килеп бик яхшы иткәнсез, түргә узыгыз, – дип, аларны ягымлы елмаеп каршылады һәм олылап түр башына утыртты.

Кунаклар барсы да диярлек бер даирә кешеләренә охшаган – гаиләле яшь парлар. Өлкәнрәк яшьтәгеләрдән берүзе килгән Закирҗан гына.

Табын тиз җанланып китә. Шау-гөр килеп юбилярны тәбрикләүләр башлана. Салисә Шакирҗанның халатын шундук кия, җылы сүзләрен, дустанә теләкләрен дулкынланып тыңлый, бүләге өчен рәхмәт әйтә.

Аннары, тост күтәргәннән соң, Фәгыйлә белән Шакирҗан янына барып басып:

– Менә сезгә карап торам да шаккатам, бер-берегез өчен яратылган кебек, бигрәк тә пар килгәнсез. Сер булмаса, без дә белик әле, сез ничек табыштыгыз? – дип әйтеп сала.

Болар ничек җавап бирергә белмичә, икесе дә бик аптырап кала. Телдән язган кебек сүзсез утыру озакка сузылгач, Фәгыйлә чарасыздан:

– Мин берни дә әйтә алмыйм, әнә ул сөйләсен, – дип, Шакирҗанга күрсәтергә мәҗбүр булды.

Дәресен хәзерләмәгән шәкерт кебек, Шакирҗан да, ык-мык итеп, авыз эченнән ишетелер-ишетелмәс нидер мыгырдану белән җавап бирүдән котылырга ниятли.

Салисә исә һаман үзенекен тукый:

– Тартынып торма, ничек булган булса, шулай әйт тә бир, – ди.

– Алай икәнен мин үзем дә беләм. Ә менә юкны, булмаганны ничек сөйләмәк кирәк.

– Чү, туктале, миңа барып җитми бу. Нәрсә югын, нәрсә булмаганын, зинһар, кеше аңларлык ачыграк итеп әйтеп бир әле.

Табында тынлык туа. Барсы да әсәренеп кала. Фәгыйлә, юк йомышны бар итеп дигәндәй, мыштым гына почмак якка чыгып сыза. Шакирҗан, алдындагы тәлинкәсенә карап утырган хәлдә, үзалдына сөйләнгән сыман:

– Бернинди табышу, пар килү юк. Фәгыйлә бездә болай гына, вакытлы фатирчы булып кына тора, – дип, акрын гына әйтеп куйды.

Ишетелер-ишетелмәс кенә әйтелгән бу сүзләр кунакларга аяз көнне яшен суккандай тәэсир итә, колакларына ышанмыйча, һәммәсе дә шым калалар.

Әлеге дә баягы дигәндәй, иң әүвәл хуҗа хатын Салисә күз кырые белән генә Шакирҗанга ризасызлыгын сиздерде:

– Ничек инде болай гына, фатирчы булып кына?! Аннан соң ул Закирҗанга ташлана. Ә син безгә нәрсә сөйләгән идең? Уйдырма, гайбәт тарату гына булдымыни ул?..

– Билләһи менә, һич тә гайбәт таратудан түгел, ялгышканмын мин, – дип, каргана-каргана, Закирҗан акланырга тотынды. – Елдан артык бер өйдә икәү генә торгач, уртак табактан ашагач, алар инде гаилә корган, ирле-хатынлы булган шикелле ич. Ә Фәгыйлә анда тулы хокуклы хуҗа хатын кеби, бөтен йорт эшләре аның кулында.

Шакирҗан да шуны кабатлый:

– Хак сүз, дөрестән дә шулай. Мин, йөри алмыйча, каста ятканда, бердәнбер ярдәмчем Фәгыйлә булды, бөтен өй эшләрен үз өстенә алды. Шуннан бирле ул һәр эшне үзе белеп, җиренә җиткереп башкарды. Күрәсез, килбәте, шулай ук табигате-холкы да тел-теш тидерерлек түгел.

– Соң шулай булгач, син, акыллы баш, ник өйләнмисең соң? – ди Салисә.– Әллә өнәмисеңме, әйбәтрәкне эзлисеңме?

– Юк, өнәүдән дә, әйбәтрәкне эзләүдән дә түгел. Бүтән мөһимрәк сәбәбе бар аның. – Шакирҗан әйтер сүзен таба алмагандай тукталып калды һәм бермәл ык-мык итеп торганнан соң гына, абынасөртенә дәвам итә: – Фәгыйлә мөгаллимнәр гаиләсендә туып-үскән укымышлы, зыялы зат. Ша-

гыйрь Тукай шигырьләрен күңелдән белә. Борынгы мөнәҗәтләрне, тарихи бәетләрне көйләп сөйли. Ә мин үзлегемнән азмы-күпме укырга, язарга өйрәнгән надан мужик. Шуңа күрә өйләнү турында сүз кузгатырга һич телем бармый. Урынлы-урынсыз сүз ычкындырып, хәтерен калдырудан шикләнәм.

– И-и, тәти абыем, бигрәк тә куркак куян икәнсең,– диде Салисә, юри уфылдап.– Турысын әйтим, синең ише баһадирга артык кыюсызлык бер дә килешми. Һаман шулай җебеп йөрсәң, гомергә карт буйдак булып калуың ихтимал.

Әлегә тикле сүзсез генә елмаеп утырган Борһан, үтә җитди кыяфәт белән, сүзне икенчегә борды:

– Салисә җаным, синең бу хикмәтле вәгазьләреңә Шакирҗан абый, мөгаен, колак салмый калмас. Шулай да татлы телеңә аз гына ял биреп тор,– дип, барсын да җиңелчә көлдереп алды.– Ә хәзер, әйдә, җырга күчик әле. Син миңа булышырга тырыш.

Аннары ул, комод өстендәге бәләкәй тальян гармунын алып, сагыну көенә моңлы тавыш белән үзәк өздереп җыру сузды:

Үз илләремдә чагында
Киң урамнар тар иде...

Салисә һәм башкалар да, аңа кушылып, җырны бергәләп дәррәү күтәреп алдылар:

Киң урамнарны тар итеп
Йөргән чаклар бар иде.

Борһан бик тә оста гармунчы икән. Кунакларны күптөрле көйләргә җырлата, хатын-кызны такмак әйтә-әйтә биетеп тә ала. Азакка таба, табын тынып торган бер арада, Шакирҗанга борылып сөйләнеп алырга да өлгерде:

– Синең хәйләкәрлегеңне беләм мин. Әмма мин дә ачык авыз түгел. Теге чакны сездә булганда, Фәгыйлә апайны сеңлең итеп таныштыруга шундук шигем туды. Чөнки күзләрең бүтәнчә сөйли, ягымлы иркәләп карый иде.

Көтмәгәндә уңайсызланып калган Шакирҗан ирексездән: май кап, күп шаулама дигәндәй, бармак янап куйды. Бу шаяртуны почмак якта шыпырт кына тыңлап торган Фәгыйлә, ирексездән елмаеп, берни дә ишетмәгәндәй, сүзсез генә табынга чыгып утырды.

Хуҗалар аларны иң азактан ирле-хатынлы икәүләшеп озата чыктылар. Тынгысыз Салисә Шакирҗанга акыл өйрәтүдән туктый алмады:

– Караңгыда абынып егыла күрмәсен, Фәгыйлә апайны менә болай култыклап алып кайтырга тырыш. Бер-берегезгә ышанып тормыш юлдашы булыгыз, исән-имин кайтып җитегез.

* * *

Япон самурайларының башбаштаклыгы дүрт ел дәвам итте, исәпсез-хисапсыз бәла-каза китерде. Шәһәрнең дошманнан азат ителүен хезмәт халкы шатланып каршылады, бу зарыгып көтеп алган тыныч тормышка ирешү иде.

Аягы төзәлгәннән соң байтак вакыт беркая урнаша алмый йөргән Шакирҗан да портта элекке урынында эшли башлады. Шуның өстенә Борһан командасы тоткан балыкны ашханәләргә, базар харчевняларына сатарга булышып та бераз файда күрә ул.

Салисәләр мәҗлесендә уен-көлке арасында аларның ирле-хатынлы да, агалы-сеңелле туганнар да түгеллеге ачылу бигрәк тә Фәгыйләне уңайсыз хәлгә куйды. Иң яманы – төрле имеш-мимеш гайбәтләргә азык бирәчәк. Оятсыз күз, буйдак ир белән ачыктан-ачык никахсыз тора, дип чәйнәп, бөтен бистәгә таратачаклар.

Такта тротуарлы караңгы урамнан култыклашып кайтканда, Шакирҗан бу зарга әллә ни игътибар итмичә:

– Барсына да төкер, юкка борчылма, – ди. – Әгәр теләсәң, барсының да авызын көне-сәгате белән капларга мөмкин. Бар эш синнән, үзеңнән генә тора.

Аның тел төбендә ни ятканын: үзенә тормыш юлдашы булырга үтенгәнен Фәгыйлә белеп тора һәм шуны тагын кабатламасын өчен:

– Ул хакта хәзергә авыз да ачма, кыстама, – дип, аны туктата. – Йә, үзең уйлап кара, никахлы хәләл җефетле башым белән ничек икенче иргә чыгыйм мин. Әгәр ул исән булып табылса, Ходай каршысында ни дип җавап бирербез.

– Инде күптән бакый йортта бит ул. Аларның аталы-уллы икесе дә боз астына батып һәлак булганын үзең дә беләсең ләбаса.

– Ул хакта мин үз күзләрем белән күрмәгән, чит-ят кешенең башка берәүдән ишеткән хәбәреннән генә беләм. Аның замана үзгәргәнне көтеп кайдадыр аулакта яшеренеп ятуы, көне-сәгате белән калкып чыгуы бик ихтимал. Күп гаиләләр әнә шулай табыша. Сиңа инде ияләшкән булсам да, үз итсәм дә, мин иртәгә үк берәр таныш-белешкә күчәргә, эш эзли башларга мәҗбүрмен. Мин синең яхшылыкларыңны онытмам, гомер буе рәхмәтле булырмын.

* * *

Фәгыйлә бүген гадәттәгедән иртәрәк уянды һәм йокыдан арыну белән кичәге карарын хәтерләде. Шакирҗанның берничә мәртәбә: «Мине ялгыз калдырып китәргә ник ашыгасың? Беркая китмә», – дип ялварып әйткән сүзләрен кабат ишеткәндәй, күңеле нечкәреп китте. Әмма ул йомшаклыкка бирешмәскә, сүзендә нык торырга карар кылды. Кичтән әзерләп куйган кечерәк кенә төенчеген култык астына кыстырды да, Шакирҗанны уятмас өчен аяк очларына басып, акрын гына өйдән чыгып китте. Ишегалдында аны күреп сөенгән сакалбай кәҗә белән бәйдәге эт Сарбай янында да тукталып тормады. Башларыннан сыйпап кына саубуллашты да, күңеле тула башлавын сизеп, тизрәк китү ягын карады.

Эш эзләп кая булса да барырга да фатир турында белешергә, күргән-белгән кешегә керергә әле иртә иде. Шәһәр үзәгенә җитәрәк тукталып калды. Кая юл тотарга белмичә бераз уйланып торганнан соң, таныш урамнан тимер юл вокзалына төште. Стенадагы расписаниедән карап, ике сәгатьтән Мәскәү поезды килеп җитәчәген белде. Безнең яклардан берәр күргән-белгән таныш кеше очрамасмы дип, шуны көтәргә булды.

Поезд нәкъ вакытында килеп җитте. Вагоннардан төшкән халыкның күпчелеге шәһәргә таралды. Пароходларга төялеп чит илләргә китүчеләр, багажларын күтәреп, баераклары йөкчеләр яллап, портка таба борылды. Фәгыйлә дә берәрсен очратырга өметләнеп шунда юнәлде. Юл уңаенда бер аксак картның чемоданын күтәреп илткән өчен азрак акча да төшерде. Һәм элегрәк, бер тиенгә тилмереп йөргән авыр көннәрдә, шушы һөнәрдән файдалана белмәгән өчен хәтта үзен-үзе җиңелчә шелтәләп тә алды.

Причалда якташларыннан беркемне дә очрата алмагач, ул кичә Салисәләрдә танышкан хатын – ресторанда официантка булып эшләүче Җамалияне эзләп китте. Әмма ул, үч иткәндәй, бүген көндез ял итә, кич белән генә эшкә чыгачак икән.

Башка барыр җире булмаган Фәгыйлә күрше урамдагы «талчук» базарына китте. Анда ак сакаллы бабайның җәймә өстендә яткан борынгы китаплары арасыннан гарәп хәрефләре белән басылган берсенә игътибар итте. Кулына алып караса, бөтен дөньяга атаклы «Мең дә бер кичә» әкиятләре, имеш. Бәһасе дә артык кыйбат түгел. Иртән портта теге аксак юлчы биргән әҗернең яртысы да җитәчәк.

Фәгыйлә китап өчен акча түләп маташканда, алар янына кара җилән, киң читле эшләпә кигән өлкән яшьләрдәге ир кеше килеп, китапчы бабай белән ике куллап күрешкәч, хәл-әхвәлен сорашкан арада, Фәгыйләне тиз генә күздән кичереп өлгерде:

– Кыяфәтең белән мөслимәгә охшагансың, әссәламегаләйкем, кызым. Болай сау-сәламәт күренәсең, әнә китап алырга җыенасың бугай. Бу якларга кайдан, ничек килеп чыктың? Әтиең-әниең кемнәр?

Кара-тутлы агай бераз колакка катырак бугай. Фәгыйлә үзенең кайдан, кем икәнен әйткәч:

– Троицки шәһәреннәнмени? – дип кабатлап сорады. – Мин үзем дә шул яктан. Ирең Бәхтиярны да, каенатаң Әхмәтҗан байны да күреп белә идем. Алар аталы-уллы икесе дә, давыллы-фетнәле көннәрдә тоткынлыктан качып киткән төнне Уй елгасын үткәндә, юка боз астына батып харап булды бит. Унике кешедән бары тик берсе көчкә котылып калды. Бөтен шәһәр халкын тетрәткән коточкыч фаҗига булды бу. Бик кызганычлы бәет тә чыкты. Мәрхүмнәрнең авыр туфрагы җиңел булсын, амин!

Ул саубуллашып китә башлагач, кинәт нидер хәтерләгәндәй, Фәгыйләгә борылды:

– Без – туган-үскән җирдән еракта яшәүче татарлар, үзара элемтәдә торабыз, кирәк чакта берберебезгә кулдан килгәнчә ярдәм итешергә тырышабыз. Кирәк булсам-нитсәм, минем адресны менә шушы бабайдан белерсең...

Хәзрәт үзе күздән югалса да, аның, алар икесе дә харап булды, дип әйткән шомлы сүзләре, Фәгыйлә колагында озак чыңлап торды. Алайса, теге чакны таралган ул хәбәр дөреслеккә туры килә. Димәк, алар инде моннан биш ел элек гүр иясе булганнар.

Бермәл миңгерәеп торганнан соң, Фәгыйлә һушына килеп якында басып торган мөслимә хәерче карчыкка мәрхүмнәр рухына атап садака бирде.

Базардан чыккач, ул кая барырга белмичә аптырап торды. Күңелсез уйларга чумган хәлдә урам буйлап йөри торгач, кичкырын бистә читенә, иртән кире кайтмаска дип чыгып киткән таныш йорт каршына килеп басты.

* * *

Алар өйалды бусагасында кара-каршы очраштылар. Шакирҗанның портка төнге сменага чыгып барышы икән. Фәгыйләне күрү белән, җаенке кашлары күтәрелеп, уйчан йөзе яктырып китте.

– И-и, кайтып бик әйбәт иткәнсең. Озын гомерле булырсың, әле генә сине юксынып утыра идем. Синсез өй күңелсез, табынга утырып ашыйсы килми. Кемнәрдер гаеп итмәгәе дип, мине ялгыз калдырдың да киттең. Кая барып эзләргә белми аптырадым, – дип өтәләнде ул.

Моны күреп Фәгыйлә дә, ярый әле кайтырга булдым, дип ягымлы елмаеп куя. Ә Шакирҗан, әле һаман куанычын тыя алмыйча:

– Якын итеп кайтуыңа бик шатмын! Үз өең итеп урнаш, чишен, аша-эч. Кичке аш мич алдында. Мин сиңа да әзерләгән ием, суынмагандыр әле. Бер дә борчылмыйча, күңелсез уйларга бирелмичә, иркенләп ял ит. Ә хәзер миңа сменага төшми ярамый. Хәзергә хуш, сау бул, күңелсезләнмә.

Фәгыйлә аны капкадан чыгып киткәнче тәрәзәдән карап озатып калды.

Шул ук җәйне, бераз вакыт үткәч, алар, загста язылышып һәм Әдһәм хәзрәттән никах укытып, гаилә төзеделәр; берничә пар дус-иш белән күңелле генә туй мәҗлесе үткәреп, ирле-хатынлы булара к әйбәт кенә яши башладылар.

* * *

Ятим балалар йорты, хәрби казарма режимы сыман, махсус эчке тәртип кагыйдәләре буенча яши. Хәзер монда көн уртасы. Дәресләрдән бушаган балалар көндезге аштан соң бүлмәләргә көндезге ялга таралды. Шау-гөр килеп торган спортзал, вестибюль, коридорлар бушап калды.

Иртәдән бирле аяк өстендә йөреп шактый алҗыган Фәгыйлә дә, бераз ял итәргә теләп, балконга чыгып утырды һәм тирән итеп саф һава сулады. Кәрниз өстеннән булса кирәк, якында гына үзара серләшкәндәй күгәрченнәрнең күңелле гөрләгәне ишетелә.

Әле кайчан гына ул күгәрченнәр алтау иде, малайлар ясаган иркен кетәктә әйбәт кенә яшиләр иде. Былтыр бер явызы ут төртеп яндыргач, икесе шунда харап булды. Икесе кыр күгәрченнәре белән каядыр китеп юкка чыкты. Өченче пары туган-үскән урынын ташлап китәргә теләмәде, ахрысы. Шунда калдылар, сарай очырмасында оя әмәлләп гомер итәләр. Аларның ягымлы гөрләгәненә тәэсирләнеп утырган Фәгыйлә үзе дә көтмәгәндә эчке дулкынлану белән, менә без өйләнешкәнгә дә егерме биш ел үтте, дип уйлап куя.

Шөкрана, алар, бер-берсенең кадерен белеп, тату яшиләр. Фәгыйлә эшкә керергә теләвен әйткәч, Шакирҗан аны бер якын танышы ярдәме белән балалар йорты ашханәсенә урнаштырды. Паспорты булмаганлыктан, аны вакытлы рәвештә савыт-саба юучы, җыештыручы итеп алалар. Һәр эшне тырышып, җиренә җиткереп башкара. Үз вазифасыннан тыш, Борһан командасы китергән балыкны һәм бәрәңгене чистартуда җиң сызганып катнаша.

Өч айлык срогы беткәч, аңа бүтән килмә дип әйтүче булмый, ул эшли бирә. Ай артыннан ай үтә, ел тула, эшләү һәмишә дәвам итә. Кешелеклеге, эшкә уңганлыгы өчен хезмәттәшләре аны үз күрә, профсоюз комитетына әгъза итеп тә сайлыйлар.

Көннәрдән бер көнне стена газетасында китапханәнең эшләмәве, нинди дер чиновникның китапханәче штатын кыскарту аркасында йөзләгән баланың әдәбият укудан мәхрүм ителүе турында борчылып язылган имзасыз мәкалә чыга. Күләме кыска гына булса да, бу язма директор бүлмәсендә зур сөйләшү кузгатырга этәреш бирә. Һәрьяклап уйлашкан-киңәшкәннән соң, профком әгъзасы Фәгыйләне, кухня штатында саналган хәлдә, вакытлы рәвештә китапханәче итеп күчерәләр.

Бала чактан әдәбиятны яратып үскән Фәгыйлә бу эшкә бик теләп алына. Сукбайлыкта йөреп тупасланган балаларны әдәби әсәрләр укырга җәлеп итеп, саф күңелле героик образлар үрнәгендә дөрес юлга бастырырга тырыша ул.

Болар арасында татар, башкорт, казак, төркмән балалары да бар. Кайберләре урысча начар белә. Шунлыктан башта авыр укысалар да, тора-бара шомаралар. Акрынлап телләре ачыла, дәресләрне җиңелрәк үзләштерәләр. Фәгыйлә аларга Тукай шигырьләрен укып күзләрен ачарга, киләчәкләре турында уйлый белергә өйрәтә, бигрәк тә аның:

Көрәш угърында ар, тал, тирлә, имгән;

Өмид итмә булышканны ләимнән.

Сәгадәт талына менсәң — үзең мен;
Ни ярдәм килсә дә килсен үзеңдин,–

дигән гыйбрәтле фикерен зиһеннәренә сеңдерергә тырыша. Берәрсе кыенлыкка тарыса, файдалы киңәш, үгет-нәсихәтләре белән, аңа төшенкелеккә бирешмәскә, урта белем алгач, югары уку йортларына керергә рухи ярдәм күрсәтә. Шуңа күрә дә кайберләре, соңынтын да элемтәне өзмичә, ничек укуы, уңышлары турында һәм авыр минутларда эчкерсез булышкан өчен зур рәхмәтләр әйтеп аңа җылы хатлар яза.

Ә былтыр көз бер мөселман мәрхүмне искә алу кичәсендә Әдһәм хәзрәт авырып килмәгәнлектән, аның өчен Коръән аятьләрен Фәгыйлә укый һәм тыңлаучыларда әйбәт тәэсир калдыра, җылы хуплау таба. Шуннан соң берәрсенә ясин чыгарга, дога кылырга, мәрхүмне искә алырга кирәк булса, уразада авыз ачу – ифтар мәҗлесләре үткәрсәләр, күбрәк Фәгыйләне чакыралар. Үзара сөйләшкәндә сүз чыкса, аны: «Алтын балдаклы абыстай», – дип, ихтирам белән телгә алалар.

* * *

Утызынчы еллар азагында япон милитаристларының басып керү куркынычы тугач, Тын океан хәрби флотын ныгыту башлана, ул Идел, Кама, Агыйдел елгачылары белән тулыландырыла. Алар арасында махсус югары һәм урта белемле татар, башкорт яшьләре дә байтак була. Шундый хәрби диңгезчеләрдән Мөхәммәтвафа исемле бер егет портта Шакирҗан белән якыннан таныша, бәйрәм көннәрендә, эштән буш вакытларында аларга килгәли, тиздән бу гаиләдә үз кеше булып китә. Ул Тукай шигырьләрен бик ярата, шагыйрьнең яңалифчә басылган китабы да бар, кая барса да, аны үзе белән йөртә, күңеле төшенке минутларда шуны укып җан азыгы ала икән. Фәгыйләнең кайчандыр Тукай белән таныш булганын, ике айдан артык вакыт дәвамында аңа аш-су әзерләгәнен, бүлмәсен җыештырганын белгәч, ул, колакларына ышанмагандай, тәмам мөкиббән була, килгән саен кызыксынып Тукай турында сораштыра.

Бу хакта Мөхәммәтвафа хәрби авиациядә хезмәт итүче танылган шагыйрь Салих Батталга да сөйли. Менә аны да Фәгыйлә абыстай белән таныштыра. Тукайның казакъ даласына кымызга баруы турында Баттал элек бераз хәбәрдар булса да, Фәгыйләне игътибар белән тыңлый, күп сүзләрен, кабат-кабат әйттереп, барысын да куен дәфтәренә язып бара.

Боларга Баттал икенче тапкыр рәхим иткәндә, аның белән бергә шәһәрнең үзәк почтасында эшләүче урта яшьләрдәге сөйкемле генә бер татар хатыны да килә. Ачык йөзле, тасма телле, җиңел аралашучан икән. Бусаганы атлап үтеп исәнләшү белән, күптәнге якын танышларына кергәндәй:

– Баттал Мәскәүдән, Казаннан килгән хатларны безгә почтага үзе кереп ала, мин аның белән шунда таныштым. Сезнең хакта да аннан ишетеп белдем, – ди. – Менә сезгә барышлый ул безгә кергән иде. Аңа тагылып сезгә килергә батырчылык иттем. Чөнки тере Тукай белән таныш булган, азмы-күпме аралашкан кешене күрү, чынлап та, бик кызык бит. Ә сезнең өчен, Фәгыйлә апай, ул очрашу, мөгаен, онытылмас истәлекле зур вакыйга булып калгандыр.

Йомшак күңелле Фәгыйлә бу җылы сүзләрдән эреп киткәндәй, аны якты чырай белән кабул итә, хәзинәдә булган аш-суы белән кыстый-кыстый сыйлый.

Шакирҗанның эштә вакыты була. Баттал диңгез култыгына су коенырга төшеп китә. Табын янында икәү генә калгач, кинәт теле чишелеп киткән Фәгыйлә игътибар белән тыңлый белүче Әмиргә Тукай турында да, үз башыннан кичкәннәрне дә сөйләп эчен бушата.

Тиздән алар якын сердәш, ахирәт дуслар булып китәләр. Әмирә аларга еш килгәли, өйдә икәү генә булган вакытларда Фәгыйләнең Габдулла Тукай шигырьләрен, «Йосыф китабы»н көйләп укыганын тыңларга ярата. Берничә тапкыр ул каяндыр кайтышлый Фәгыйләнең эшләгән җиренә дә кереп чыга. Аның урысча начар белүче мөселман балаларга дәрес хәзерләргә, үсә төшкәннәренә һөнәр сайларга, намуслы тормыш юлына басарга аналарча эчкерсез булышканын күреп таң кала.

Шуннан соң күп тә үтми, Фәгыйлә белән Шакирҗан эштә вакытта боларның өенә кемнәрдер кергән, бөтен әйбер асты өскә актарылган була. Тентү ясаганнар, нәрсәдер эзләгәннәр бугай. Болай бернәрсә дә урланмаган шикелле. Фәгыйләнең комод өстендәге Кол Гали, Тукай китаплары һәм «Идегәй» дастаны басылган «Совет әдәбияты» журналы гына юкка чыккан.

Алар моны ничек аңларга, нәрсәгә юрарга белмичә аптырашка төшсәләр дә, һәрьяклап уйлаганнан соң, ул хакта хәзергә беркая хәбәр итмәскә, башы-азагы шул булсын дип, эчкә йотып калырга булалар.

* * *

Бу арада Фәгыйләнең колагына һаман бер сүз – юбилей дигән сүз чалына башлады. Шуның белән янәшә еш кына аның исемен дә телгә алалар. Аннары профком рәисе белән бер фотограф керә дә китапханәдә өстәл янында утырган хәлдә аны рәсемгә төшереп алалар.

Рәсемнең Мактау тактасына куярга кирәклеген ул соңынтын, фотограф чыгып киткәч кенә белә һәм катгый рәвештә моңа каршы килә. Профком рәисен күндерә алмагач, әсәренеп, директор янына керә:

– Мин гади бер тәрбияче-китапханәче, Мактау тактасына куярлык берни дә эшләгәнем юк. Рәсememне шунда куеп мине кеше көлкесенә калдырмагыз, – ди ул, зинһарлап үтенгәндәй.

Балалар йорты директоры, керәшен татары, кайчандыр Фәгыйләне ашханәгә җыештыручы итеп алган, тәрбияче-китапханәче итеп күчергән, айлык курска укырга җибәргән карт педагог Александр Николаевич, гадәтенчә игътибар белән тыңласа да, аңа каршы килә:

– Үзегез дә беләсез, бездә балигъ булган балаларыбызның һәм түгәрәк датасы тулган хезмәттәшләребезнең юбилеен бергәләп үткәрү гадәте бар. Бездә эшли башлавыгызга егерме биш ел тулуны бергәләп бәйрәм итәргә булдык, шул хакта радио аша да хәбәр иттек. Сез карышмагыз инде. Югыйсә кыланчыклану, үҗәтләнү сыман килеп чыга.

Фәгыйлә, үз сүзеннән чигенергә теләмичә:

– Сез дөрес әйтәсез, мин моңа риза, әмма мине тагын бер шомлы вакыйга борчый, – диде һәм кичә көндез үзләре эштә вакытта өйләренә кемдер кереп тентү ясавы турында сөйләп бирде. – Шунысы сәер, бөтен әйберне актарып, астын өскә китерсәләр дә, бернәрсәне дә урламаганнар. Гарәпчә язулы борынгы берничә китабым һәм журналым гына юкка чыккан. Шымчылар эшенә охшаган. Кемнәрдер казына, иснәнә бугай. Берәр күңелсезлек килеп чыкмагае, дим.

Директор бераз уйланып торганнан соң, үзалдына сөйләнгәндәй:

– Әйе, шулай булса кирәк, – диде. – Күптән түгел миңа телефоннан бер ир кеше шылтыратып, бездә ялган фамилияле динче, милләтче хатын эшләгәнен хәбәр итте. Мин кайдан, кем шылтыратуын сорагач, җавап бирмичә, телефон трубкасын элеп куйды. Әмма без, күп еллар кулга-кул тотынып эшләүчеләр, бер-беребезне яхшы беләбез. Кемнәрнеңдер итәк астыннан ут йөртүләренә карап, паникага бирелмәскә, ятимнәребезне аякка бастырырга бурычлыбыз. Мәктәпләрдә киеренке вакыт: уку елы тәмамланып килә, имтиханнар бара. Барыннан да бигрәк рус теленнән авыр баручы балаларга аеруча күбрәк ярдәм итәргә кирәк. Берүк, күчә алмыйча, классларында утырып кала күрмәсеннәр.

* * *

Кичкырын эштән соң өенә кайтып җитәрәк Фәгыйлә үзләренең капка төбендәге эскәмиядә ике хәрби диңгезче утырганын күреп шиккә төшә һәм ихтыярсыз туктап кала. Тик бераз якынрак килгәч кенә ул аларның үз кешеләр: шагыйрь Салих Баттал белән Мөхәммәтвафа икәнен танып җиңел сулап куя. Каушавыннан тиз генә арынып, күтәренке көр тавыш белән:

– Күптән күренгәнегез юк, кая югалдыгыз? Әйдә, рәхим итегез, – дип, кунакларны өйгә алып керә, хәл-әхвәлләрен сораштыра-сораштыра самавыр куя башлый:

– Фәгыйлә түти, зинһар, мәшәкатьләнмәгез, без берничә минутка йомыш белән генә килдек, ашыгабыз, – дип, Баттал аны туктатмакчы була.

Әмма Фәгыйлә, авыз ачарга да бирмичә, сәгате-минуты белән табын әзерли. Шакирҗан кичке сменага китәр алдыннан итле пылау пешереп калдырган икән. Шуны тиз генә җылытып китерә, башка тәм-том куя, чынаякларга чәй ясый.

Тамак ялгап, берәр чынаяк чәй эчкәч, Баттал кул сәгатенә карап ала да сый-хөрмәт өчен рәхмәт әйтә:

– Миңа китәргә вакыт, юкса поездга соңга калам. «Совет әдәбияты» журналының «Идегәй» дастаны басылган санын мин Мөхәммәтвафага укырга биргән идем. Үзе укыгач, ул аны сезгә дә биргән икән. Без шуны алырга килдек.

Фәгыйлә телдән язган кебек тынып кала, әйтер сүзен эзләгәндәй, стена буендагы комод өстенә карап:

– Тукай шигырьләре, «Йосыф китабы» белән бергә журнал да менә шушында тора иде. Үзебез юк вакытта кемнәрдер кереп өйдә тентү ясаган, нәрсәдер эзләгән. Болай бер әйбергә дә тимәгәннәр шикелле, комод өстендәге журналны, китапларны гына алып чыкканнар.

Кинәт шаккатудан Мөхәммәтвафаның күзләре шар була:

– Нинди гөнаһ шомлыгы бу! Үзебез юк вакытта нәкъ шундый тентү безнең фатирда да булган. Бигрәк тә китап киштәсендә казынганнар. Бер яраткан китабымны – Садри Җәләлнең «Дим буенда» дигән повестен гына алып чыкканнар.

– Бу әсәрләр хәзер икесе дә тыелган санала, аларны укучы, таратучылар буржуаз милләтчелектә гаепләнә, – ди Салих Баттал. – Димәк, безнең тирәдә чуалучылардан кемдер моны белгән, тиешле власть органнарына җиткергән. Хәзер шул сигнални дәлилләп исбатлар өчен материал җыялар булса кирәк.

Бу әләкче кем булыр икән дип, барысы да аптырап калалар, аралашкан һәр милләттәшне күздән кичереп, фикерләшәләр. Уйлап-уйлап та очына чыга алмагач, Мөхәммәтвафа үзалдына сөйләнгәндәй:

– Беркөн сездә булганда, Фәгыйлә апай, синең ахирәт дустың Әмирә Тукай китабын да, «Идегәй» дастаны басылган журналны да кабат-кабат актарып, укып утырган иде, – ди. – Ул ханым почтада цензор булып эшли, хәрби корабларда хезмәт итүче татар, башкорт егетләренә килгән-киткән хатларны шул тикшереп үткәрә, тыюлы, гаепле саналган хәбәрләр, хезмәттән зарланулар очратса, власть органына сигнал җиткерә. Андый хат авторларын яшертен күзәтү башлана. Бу китапларның югалуларында да шуның кулы уйнамаганмы дип шикләнәм.

– Ихтимал, аның шундый шикле тип булуы бик мөмкин, – ди Салих Баттал да. – Узган сишәмбедә, вокзалга кичке поездга төшеп барганда, Әмирәнең шәһәр эчке эшләр бүлеге болдырыннан төшеп килгәнен күрдем һәм, бу монда нишләп йөри икән дип, гаҗәпкә калдым. Ул да мине ерактан күреп алды һәм, кинәт коты чыккандай, яшен тизлеге белән кире кереп күздән югалды.

Фәгыйләнең чыраена ризасызлык чыкты, беравык уйга чумып утырды да:

– Сез икегез дә артык шикләнәсез, гаепсез кешегә нахак бәла тагасыз шикелле,– диде.– Әмирә белән без турылыклы ахирәтләр, ул миңа каршы андый явызлык кылмас дип ышанам.

* * *

Эчке эшләр бүлекчәсенең хатын-кызлар камерасы коридор кебек озынча тар бүлмәдә. Стена буйлап сузылган такта сәке төнлә кулга алынган исерек марҗалар белән тулы. Һавасы тынчу, күңел болгаткыч сасы. Кандалалары усал, бер минут та тынгылык бирмичә, аяусыз талый.

Кичә кич кулга алынган Фәгыйләне шунда төн кундырганнан соң, иртән допроска чакырып чыгардылар. Ул, тикшерүчене күрү белән: «Чү, кайчандыр безгә хуторга кунакка килгән Куртай ич бу! Кәҗә тәкәсе кебек тагылып теңкәгә тигән иде», – дип гаҗәпләнде, эченә җылы кергәндәй булды. Әмма Троицк милиция бүлегендә рәхимсез каныгуын хәтерләү белән, өмет чаткысы шундук сүнде.

Куртай сизелерлек калынайган, чал чәче элеккечә кашсыз маңгаена салынган. Кайчандыр уйнак йөзе көзге яфрак төсле саргайган. Сүнек күзләре белән үтәли күрергә теләгәндәй, беравык текәп карап торганнан соң, яшь чаклары исенә төште бугай, үчле елмаю белән:

– Әһә, хәтерлим, сез теге чакны Троицк төрмәсеннән качып эзсез югалдыгыз бит, – диде урысчалап. – Монда килеп оялагансыз, «Алтын балдаклы абыстай» булып начар дан казангансыз, монда җинаятьле юлга баскансыз. Сез хәзер, погранзонадагы ябык шәһәрдә ялган фамилия астында күп еллар прапискасыз торуда, дини мәҗлесләрдә молитвалар укуда, детдомда мөселман балаларын аерым җыеп, яшерен рәвештә дини рухта тәрбияләүдә, тыелган китаплар пропагандалауда гаепләнәсез.– Куртай өстәле тартмасыннан «Идегәй» дастаны басылган журналны, Кол Гали, Габдулла Тукай китапларын тартып чыгарды.– Менә болар барсы да сезнең совет строена каршы идеологик диверсияче икәнегезне исбат итә торган кире кагылмаслык нигезле дәлилләр.

Фәгыйлә, аны тыныч кына тыңлый алмыйча:

– Болар барысы да нахак гаепләү,– дип ачыргаланып акланырга тотынды.– Беренчедән, мин хәзер икенче ирем фамилиясендә, егерме ел буена бу шәһәрдә даими пропискада торам. Мөселман балаларны җыеп ярдәм итүдә дә бернинди диверсия юк: русча начар белү аркасында алар укуда артта калалар, дәресләрне авыр үзләштерәләр иде. Шуңа күрә мин аларга дәрес хәзерләргә, уку фәннәрен үзләштерергә ярдәм итәм. Монда бернинди яшеренү юк. Ул хакта мәктәптә класс җитәкчеләре дә, безнең дирекция дә яхшы беләләр һәм хуп күрәләр. Сезнең кулдагы бу китапларда да совет властена каршы пропаганда юк. Алар барысы да татар әдәбиятының алтын хәзинәсе булып саналган мәшһүр китаплар.

– Җитте, туктагыз, барыбер аклана алмассыз. Югарыда әйтелгән җинаятьләр буенча сез җавапка тартыласыз. Тиздән суд булачак, дәлилләрегезне шунда сөйләрсез.

Ә Фәгыйләнең башында үзе көтмәгәндә: «Боларны ничек белгәннәр, кем җиткергән? – дигән сорау туды.– Ахирәтем Әмирәдән гайре бу китапларны бүтән беркемгә дә күрсәткәнем юк иде бит. Баттал белән Мөхәммәтвафаның шикләнүе нигезле, доносчы шул микәнни?!» – дип тирән көрсенеп куя.

Берничә көннән суд булганын көтеп торырга Фәгыйләне тагын кандалалы сасы камерага илтеп ябалар. Ул берсеннән-берсе дулкынландыргыч уйларга чума. Ул чирек гасыр эшләгән ятимнәр йортының бүген илле еллыгы бит. Хезмәттәшләре һәм балалар шуны бәйрәм итәчәкләр. Шуның өстенә бүген аның үзенә дә илле яшь тулган көн ләбаса. Ә ул, явыз җинаятьче кебек, сасы кандала оясында җәфа чигеп утыра. И Раббем, нинди гөнаһ шомлыгы булды бу? Тагын нинди бәла-казаларга дучар буласым бар икән дип шомлана, күзләренә яшь тула.

* * *

Бүген бүтән борчымаслар кебек иде, мәгәр төштән соң Фәгыйләне тагын чакырып чыгардылар. Тикшерүче Куртай бу юлы аны җылы каршылады һәм кул ишарәсе белән каршыдагы буш урындыкка утырырга тәкъдим итте. Аның үзен тотышында ниндидер үзгәреш бар, сизелер-сизелмәс кенә уңайсызлану, тынгысызлык төсмерләнә. Алдында җәелеп яткан «Красное знамя» газетасын тиз генә бөкләп читкәрәк куйды да:

– Карагыз әле, без земляклар, күптәнге знакомыйлар бит,– дип, ярым татарча, урысча сөйләп китте.– Поэтому жәлләдем, ягъни сезне судка бирмәскә, освободить итәргә булдым. Монда булганыгызны беркемгә дә әйтмәскә расписка языгыз да кайтып китәрсез, – диде.

Фәгыйлә моны башына сыйдыра алмыйча: «Нинди тамаша бу?! Урынсыз шаяртумы яки кимсетеп үч алумы?» – дип аптырауга төшә һәм бары тик ишеккә чыккач кына аның чынлыгына инана. Мәгәр шундук башында яңа шик туа: тикшерүче ник болай кисәктән генә үзгәрде? Көтмәгәндә азат итүнең сәбәбе нәрсәдә, дигән шомлы сорау борчый аны.

Башта туп-туры өйгә кайтырга уйласа да, Фәгыйлә бу ниятеннән кинәт ваз кичә. И-и, бөтенләй исеннән чыккан, аны кичә кич кулга алынганын эштә белмиләр бит. Хәзер үк кереп күренергә, әйтергә кирәк.

Директор газета укып утыра иде. Фәгыйлә ишектә күренү белән:

– Әйдүк, керегез... Хуш киләсез, рәхим итеп утырыгыз, – дип, ягымлы елмаеп каршылый.

Ул бу шомлы хәбәрне инде белгән, иртән Шакирҗан килеп әйткән. Хәзер шул хакта сөйләшергә крайбашкарма комитетына барырга җыенган икән.

– Юк, болай булгач бармыйм инде. Аллага шөкер, котылгансыз. Шуңа канәгать булыйк, – ди. – Шулай да ничек болай җиңел котыла алдыгыз, сөйләгез әле.

– Тикшерүче ничек болай тиз чыгарганын һич аңламыйм, – дип, Фәгыйлә үзе дә бик гаҗәпләнә. – Иртә белән беренче тапкыр допрос алганнан соң, суд булганчы сак астында көтәргә дип, кире камерага озаттырган иде. Ни күзем белән күрим, ике-өч сәгать үткәч, тагын чакыртып алды да, мин сезне жәлләдем, судка бирмәскә, освободить итәргә булдым, дип, төче телләнеп ишеккә чыгарды. Мондый кисәк әверелешнең хикмәте нәрсәдә икәнен мин һәмишә аңлый алмыйм.

Александр Николаевич, беравык уйланып торганнан соң, ниһаять, нидер абайлагандай:

– Аның сере биредә түгел микән? – дип, мәгънәле елмаеп, күзлеген киеп, өстәлдә яткан газетага төбәлде. – Менә монда ике материал басылган. Аларның берсе – сезне Мактау грамотасы бүләкләү турында партия крайкомы һәм крайбашкарма комитеты карары. Икенчесе – әдәби язма. Авторы Вафа Зәбиров, бәлки, беләсездер. «Ятимнәрнең игелекле тәрбиячесе» дигән очеркында сезне күккә чөеп мактаган. Молодец! Ә тикшерүче, мөгаен, шушы газетаны укыганнан соң куркуга төшкән, баштагы явыз хөкемен кинәт аклауга үзгәртергә мәҗбүр булган, күрәсең.

– Әйе, әйе, нәкъ шулай, сез әйткәнчә булса кирәк, – дип, Фәгыйлә бик гаҗәпкә кала. – Мин икенче тапкыр кергәндә, бу газета аның өстәлендә ята иде.

– Ярар, монысы ачыкланды. Мин сезне зур бәйрәмегез: бу бәладән хәвеф-хәтәрсез котылу, тууыгызга илле яшь һәм бездә егерме биш ел намуслы хезмәтегез белән котлыйм! – дип, директор Фәгыйләнең кулын кыса. – Ә калганын кич белән клубта тантаналы кичәдә дәвам итәрбез. Ә сез шуңынчы барыгыз, өегезгә кайтып ирегезне шатландырыгыз. Мәгәр онытмагыз, сез килеп җитмичә кичәне башлап булмаячак. Сәгать биштән соңармыйча клубта булырга тырышыгыз.

* * *

Адәм баласы, үзе бәхетле, көр күңелле булганда, әйләнә-тирәдәге мохиткә алсу күзлектән карый, тормышны якты, матур итеп күрә. Фәгыйлә абыстай белән дә бүген нәкъ шундый хәл булды. Кичә кич кулга алынгач, тоткыннарны йөртә торган «кара козгын» машинасында китеп барганда, бу берьяклы таныш урам аны үгисетеп озатып калган шикелле иде. Ә бүген, бәла-казадан котылып кайтып барганда, аның йөзе шат, йөреш-килбәте яшьләрчә җиңел. Кояш нурына балкыган урам ягымлы елмаеп каршылый сыман.

Иш янына куш дигәндәй, өстәвенә бүген аңа илле яшь тулды бит. Шул гомернең яртысы балалар йортында эшләп үткән, ярдәмчесез ач-ялангач ятимнәрне һәлакәттән саклап калуга, җәмгыятькә файдалы кешеләр итеп тәрбияләп үстерүгә багышланган.

Махсус педагогик белеме булмаса да, Фәгыйлә абыстайның бу мәсьәләдә ныклы үз мәсләге бар: укыту, тәрбия эшендә балага белем, мәгълүмат бирү белән бергә, аны уйларга, киләчәге турында кайгырта белергә өйрәтү – аеруча мөһим максат. Даһи Тукай да соңгы шигырьләренең берсендә:

Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул;
Алга барганнарга тик табыла табылса — Алла ул! –

дип, васыять итеп әйтеп калдырган бит.

## *Хикәяләр*

# Хатлар язам сагынып

Беребез исән булганда,
без икебез дә яшәрбез.

*Э.Хемингуэй*

***Нурислам абый!***

Сезгә бу хатны язаргамы, юкмы дип байтак вакыт уйланып, икеләнеп йөрдем, берничә мәртәбә язып та, почтага илтмичә, ертып ташладым. Сәбәбе шунда: сез мине дөрес аңламассыз дип уңайсызландым, әйтер сүземне кирәгенчә әйтә алмам, хәтерегезне калдырырмын, сезне үпкәләтермен кебек тоелды. Шулай да, һич кулым бармаса да, ниһаять, бу юлы язарга, ә хатымны җибәрергә булдым.

Озын сүзнең кыскасы, Нурислам абый, мин сездән моннан соң безгә килмәвегезне үтенәм. Элеккечә бәйрәм-җыеннарда, туган көн мәҗлесләренә чакырмасак, зинһар, үпкәләмәгез. Тормыш шулай куша. Чөнки, сез килеп киткән саен, безнең гаиләдә үпкәләшү килеп чыга. Хөснулла атналар буе беркем белән сөйләшмичә кара көеп йөри, андый көннәрне ул хәтта бәләкәй улы Кәбиргә дә якты чырай күрсәтми.

Сезгә тагын бер үтенечем бар: бу хат турында берүк Хөснуллага сиздерә күрмәгез; тырнак астыннан кер тапкандай, аңа тагын бәйләнергә, авызын-борынын турсайтып, тузынып йөрергә сылтау булмасын иде.

Менә бар сүзем шул. Зинһар, үпкәли күрмәгез. Мине дөрес аңларсыз дип уйлыйм.

*М-м*

***Нурислам абый, тагын мин борчыйм әле сезне.***

Мин югыйсә бүтән язмаска тиеш идем. Соңгы вакытта сез килми башлагач, безнең тормыш бераз рәтләнгән, Хөснулланың сәбәпсезгә вакланулары, юкка-барга бәйләнүләре кимегән сыман иде.

Әмма теге көнне без сезнең пароходка утырып кайтканнан бирле, Хөснулла тагын өйдә һичкем белән сөйләшмичә кашларын җимереп йөри башлады. Аның мондый кыланышларын баштарак мин авыр кичерә идем, сәбәбен аңлый алмыйча йөдәп бетә идем. Һаман саен кабатлана торгач, хәзер инде мондый хәлгә акрынлап күнегеп тә киләм бугай. Мөмкин кадәр тынычрак булырга, үземне кулга алырга, артык борчылмаска тырышам.

Хәтерлисездер, ул көнне пароходта кайтканда, террасада икебез генә калган бер арада, сез Хөснулланың ник бәйләнүен, ник безгә килергә ярамаганны белергә теләгән идегез. Әмма мин ни дә булса әйтергә өлгермәдем, нәкъ шул мәлне Хөснулла килеп комачаулады. Бу хәл сәер тоелмасын, икеле-микеле уйланырга урын калмасын дип, менә сезнең шул соравыгызга җавап язуым.

Ул чакны Хөснулла белән сез, гадәттәгечә, якын дусларча ачылып сөйләшмәдегез, ике арагыздагы киеренкелекне бер-берегезгә сиздертергә теләмәгәндәй, вахтадан буш сәгатьләрдә гел шахмат уйнап кайттыгыз. Улым Кәбир дә (ир бала ирлеген итә бит) һаман сезнең янда чуалды, әтисе берничә тапкыр ачулануга да карамастан, алдыгызга утырып, китель төймәләрегезне санап, фуражкагызны киеп уйнады.

Бу хәлгә Хөснулланың кәефе бик бозылды, чырае торган саен караңгылана барды, рәттән берничә тапкыр уенын оттырды. Соңынтын, үзебезнең каютага чыккач, таякның юан очы тагын миңа төште: баланы теләсә кемгә сыенудан тыя белмисең, әтисеннән биздерәсең, имеш... Сезнең белән очрашканда рәтлерәк киенгән өчен дә, ачык йөз күрсәткән өчен дә мин гаепле.

Ярар, ул хакта калып торсын. Сүз уңаенда бәләкәй генә бер яңалык та хәбәр итим: быел көз мин су транспорты инженерлары институтының читтән торып уку бүлегенә керергә булдым, бу көннәрдә кабул итү имтиханнарына әзерләнәм. Миңа уңышлар теләгез.

Улым Кәбирдән сәлам сезгә. Менә хәзер сезгә хат язуымны белгәч, Нурис абый (сезнең исемне ул үзенчә шулай кыскартып әйтә) ник безгә килми, аның пароходына тагын кайчан барабыз, дип аптыратырга тотынды.

Сезгә сәламәтлек, эшегездә уңышлар теләп калабыз.

*Мәрьям*

***Нурислам абый, исәнмесез!***

Сез белмисездер әле, улым белән мин Чистай кешеләре булдык бит, хәзер без шунда яшибез. Монда эшемнән, тормыш шартларымнан зарланырга сәбәп булмаса да, күңел никтер урынында түгел, башка әллә нинди борчулы уйлар килә, сез безгә килеп йөргән чаклар искә төшә.

Соңгы вакытта еш искә алудан, ахры.

Кичә кич ачык тәрәзә янында йокыга талып барганда, пристань ягыннан сезнең «Владимир Маяковский» пароходы тавышы ишетелгән кебек булды. Башта мин моңа ышанмаган, еш искә алудан гына шулай охшашлы тоелгандыр дип уйлаган идем. Аның Иделдә йөрүен, бу якларга килүе бик икеле икәнлеген яхшы белсәм дә, таныш гудок тавышыннан күңелем җилкенеп китте, байтак вакыт йоклый алмыйча яттым.

Шулай да мин дөрес ишеткәнмен бит, кичә пристаньга, чынлап та, сез туктагансыз икән. Ремонтка туктаган ниндидер бүтән пароход урынына сезне Кама линиясенә күчергәннәр икән. Ул хакта мин иртәгесен безнең затонга эш белән килгән таныш диспетчердан очраклы рәвештә ишетеп белдем.

Ел буе диярлек хәбәрләшми торганнан соң, сезнең якында гына булып та күрешмичә китүегезне белү миңа бик аяныч тоелды, һәм мин, җилкенеп китеп, менә шушы хатны язарга керештем.

Безнең Чистайга килүебез, сезнең өчен көтелмәгән хәл булып, сәер тоелуы ихтимал. Мәгәр бу чыннан да шулай, җәй башыннан бирле биредә яшибез.

Безнең биргә күчеп килүебез әтинең нахак бәлагә таруы аркасында булды. Бәлкем, инде үзегез дә ишеткәнсездер (андый хәбәр озын аяклы була бит), быел техникумда язгы имтиханнар вакытында ни өчендер гаепләп, әтине директорлыктан алдылар, төрле комиссияләр килеп тикшерә, төпченеп казына башладылар. Аның сәбәбен мин соңынтын, байтак вакыт үткәч кенә белдем.

Шул ук вакытта минем үземә карата да кешеләрнең мөнәсәбәте кинәт үзгәрде. Эшкә барып керсәм, сизәм, кайберәүләр, очрашканда, күрмәгәндәй, читкә карап яки ашыккан кыяфәт белән коры гына сәлам биреп үтәләр. Хәтта әти урынына техникум директоры булып калган «безнең Хөснуллабыз» да бүтәнәйде, абруена тап төшүдән куркып булса кирәк, миннән күрәләтә читләшә, әнисе каты авырый дип, кунарга да өйгә кайтмый башлады. Әнә шундый күңел өшеткеч атмосфера эчендә калдым мин.

Хәер, мине һәрвакыттагыча үз итеп, теләктәшлек күрсәтүче, кирәк чакта киңәшләре белән эчкерсез булышучылар да аз булмады. Техникумның суднолар йөртү бүлеге начальнигы, гражданнар сугышы чорында минем әти белән бергә кызыл флотилиядә сугышучы Матвей Михайлович Белоусов, җылы мөнәсәбәтен һич тә яшермичә, теләсә кем алдында ачыктан-ачык дусларча исәнләшә, хәлемне сораша, мине тынычландырырга тырыша иде. Гадәттә, үзен бераз рәсми тотучан, корырак күренсә дә, хәлемнең кыенлыгын башлап сизүче һәм авыр вакытта ярдәм кулы сузучы кеше шул карт коммунист дисәм, һич тә ялгыш булмас.

Беркөнне, техникумда сынаулар тәмам булганнан соң, юлыбыз туры килеп, кичкырын эштән кайтып барганда, әнә шул дәдәй:

– Мәрьям, син ялыңны кайда үткәрергә уйлыйсың? Башка җәйләрдәге кебек быел да пароходта эшләргә җыенасыңмы? – дип кызыксынды.

– И Матвей Михайлович, ял кайгылары түгел әле миндә, – дидем, ачыну белән. – Күрмисезмени, җәтмәгә эләккән балык кебек, кая барып бәрелергә белми йөрим.

– Күрәм, күгәрченкәем, бик яхшы күрәм, хәлеңне дә аңлыйм. Әйтергә теләгән сүзем дә шул хакта... Минемчә, сиңа климатны үзгәртергә, бу имеш-мимеш гайбәт оясыннан бераз вакытка китеп торырга кирәк. Чистайда минем бертуган сеңлем яши. Үз өе, ире үлгәннән бирле ялгызы тора... Улыңны үзең белән ал да туп-туры шунда кит, җәеңне шунда тынычта үткәр. Камада су коенырсыз, кояшта кызынырсыз, карлыган, гөмбә җыярсың, нервыларың ныгыр... Син монда барыбер әтиеңә әллә ни ярдәм итә алмассың, ул хакта без, хәрби флотилия ветераннары, үзебез кайгыртырбыз. Вәсил Билаловичның кем икәнен беләбез без. Якын арада барысы да ачыкланыр дип уйлыйм.

Бу киңәш башта ничектер бераз сәер тоелса да, һәрьяклап уйлаганнан соң, мин аны хуп күрдем һәм берничә көннән улым белән Чистайга килеп төштек.

Кайгыртучан Матвей Михайлович безнең хакта сеңлесенә хәбәр иткән һәм, Казан пристанендә озатып калганнан соң, телефоннан да сөйләшкән икән. Аның сеңлесе – урта яшьләрдәге ачык йөзле, бөтерчек кебек хәрәкәтчән түтәй Марина Михайловна – пристаньда безне бик җылы каршылады, өйгә кайткач та, якын туганыдай, кадерләп кунак итте.

Ул үзе затонда суднолар ремонтлау заводында кадрлар бүлеге мөдире булып эшли икән. Аның затон турында, шунда үткәргән еллары турында сөйләгәннәрен тыңлый-тыңлый ул кичне без чәй янында озак утырдык.

Улым белән мин урнашкан шактый иркен бүлмәнең түр тәрәзәсе Камага караган, ян тәрәзәдән якында гына яр астында озын күл сыман елга култыгы – затон күренеше ачыла. Кичләрен, тын су өстенә төн пәрдәсе иңгәч, яр өстендәге завод тәрәзәләрендә, биек кран башларында утлар җемелди, пристаньнан ара-тирә кычкырткан пароход тавышлары сезне искә төшерә, ямансулата.

Менә без шулай Чистай кешеләре булдык инде. Яңа урында рәтләп ияләшергә өлгермәдем, заводта Марина Михайловнаның ярдәмчесе, йөкле хатын декретка чыккач, аның урынына вакытлыча мине кадрлар бүлегенә инспектор итеп куйдылар.

Башта кызыксыз булыр сыман күренсә дә, бу эшкә мин бик тиз бирелеп киттем. Кешеләрне заводка, пароходларга эшкә кабул иткәндә, төрле язмышлар, гыйбрәтле хәлләр белән очрашулар күп нәрсәгә күземне ачты; тормышны, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тирәнтенрәк аңларга, тагын да мөһимрәге – кайгы-хәсрәтләр астында сыгылмыйча, нык тора белергә, гаделлек өчен, хакыйкать өчен көрәшергә кирәклеген төшендем мин биредә...

Шулай да дөнья мин уйлаганча ук тоташы белән караңгы түгел икән. Беркөн Казаннан Матвей Михайлович шылтыратты һәм әтиемнең нахак бәладән имин котылуын әйтеп, мине бик сөендерде. Озак та үтмәде, алар үзләре дә бирегә килеп, берничә көн бездә ял иттеләр.

Ни өчен эштән алынуы турында әти үзе бернәрсә дә сөйләмәде, тик болай, аңлашылмаучылык аркасында, дип әйтү белән генә чикләнде, ә мин төпченеп сораштырырга кыенсындым. Аларның үзара сөйләшкәндә өзек-өзек колакка кергән сүзләреннән шуны аңладым: пароходчылык идарәсендә һәм безнең техникумда оялаган бер төркем карьерачы интриганнар әтине ниндидер җинаятьчеләр белән якын элемтәдә булуда, кемнәргәдер техникумны тәмамлау турында законсыз диплом бирүдә һәм кода-кодагыйлыкта (монысы, мөгаен, аның кызы – мине күздә тотып әйтелгәндер инде) гаепләп, аның өстеннән ялган әләк язган булганнар икән. Азактан, доносның нигезсезлеге ачыклангач, тикшерүне шундук туктатканнар һәм, хаталык өчен гафу үтенеп, әтине элекке эшенә чакырганнар.

Инде шактый өлкән яшькә җиткән һәм үткән сугыш яраларыннан гел интеккән бичара әти бу юлы сизелерлек бирешкән, күңеле төшенке күренде. Шунлыктан булса кирәк, ул моннан киткән вакытта техникумга элекке урынына кире кайтмаска, җиңелрәк эшкә күчәргә уйлавын әйтте.

Ул чакны мин шунда әти белән бергә Казанга кайтып китә алмадым, Марина Михайловнаны эшендә кинәттән генә ярдәмчесез калдырудан уңайсызландым. Аннары бу адымнан мине анда Хөснулла белән очрашырга теләмәү дә тоткарлый, юлымда киртә булып тора иде.

Әтине озатканнан соң күп тә үтмәде, һич уйламаганда-көтмәгәндә безгә Хөснулла үзе килеп төште. Күчтәнәчләрен, Кәбиргә алып килгән уенчыкларын ачып салды, безне бик сагынып килүен һәм хәзер үк үзе белән өйгә алып китәргә ниятләвен әйтте. Бу юлы аның Казанда миннән читләшеп йөргән чактагы салкын һавалылыгы бөтенләй юкка чыккан: хәзер ул кайгыртучан, мөлаем булып әверелгән, һәм шул ук вакытта аның үзен тотышында, сагаюлы күз карашларында яңа чалым – ниндидер аптыраулы кыюсызлык та сизелә иде.

Хәер, безнең мөнәсәбәтләр инде Казанда ук салкынайган иде. Монда килгәч, мин аннан тагын да ераклашуымны, тәмам бизүемне аңладым һәм, үземне ирексезләп, аңа якты чырай күрсәтмәдем.

Минем халәтемне Хөснулла үзе дә сизде, ахрысы. Һәрхәлдә, сөйләшеп аңлашу турында сүз кузгатмады, ашыгыч эшләрем бар дип, шул ук көнне кичке пароход белән кире кайтып китте.

Менә шул, яза торгач, хатым озынга китте. Хушыгыз, безләрне бөтенләй онытып бетермәгез.

*Мәрьям*

***Сөекле Нурисым!***

Дөньяда шундый да зур якты бәхет, сөю һәм сөелү бәхете булуы мөмкин дигән уй моңарчы беркайчан башыма килгәне юк иде. Синең белән соңгы мәртәбә пристаньда очрашканнан бирле минем әле һаман айный алганым юк, бәхеттән исергәндәй, рәхәтлектә йөзәм, гел елмаеп йөрим. Марина Михайловна да гаҗәпләнә, Мәрьям, бу арада син балкып киттең, канат куйган кебек, очып кына йөрисең, ди.

Тик шунысы үкенечле, ул көнне күзгә-күз карашып бер туйганчы рәхәтләнеп сөйләшә алмадык. Үч иткән күк шуннан элек кенә минем улым Кәбир белән Казанга киткән чагым иде. Өченчекөн кичкырын өйгә кайтып керсәк, өстәлдә хат ята. Синнән икәнлеген күрүгә, йөрәгем ярсып тибә башлады. Юл киемнәремне дә чишенеп тормастан, өлгерми калудан курыккандай, тиз генә конвертны ачып, шундук түземсезлек белән укырга керештем.

Менә хикмәт, мин Казанда булган вакытта сез Чистай затонында тәүлек буе торып, пароходыгызның пар казанын чистарткансыз икән. Шул вакыт эчендә син безгә ике тапкыр килеп тә, мине өйдә очрата алмагач, менә шушы хатны язып калдыруыңны белдем һәм шатлыгымнан чүт кычкырып җибәрмәдем.

Бу вакытны Марина Михайловна өйдә түгел иде. Мин бераз тынычланып, теге-бу иткән арада, ул кайтып җитте һәм, ишектән керү белән:

– Әһә, кайткансың икән, шәп булган... Укыдыңмы, белдеңме кем килгәнен? – диде ул, минем кулдагы хатны күреп.– «Владимир Маяковский» әлерәк кенә затоннан чыгып китте. Хәзер ул пристаньда, расписание буенча сәгать алтыда рейска китәчәк... Димәк, утыз минут вакыт бар, яр буйлап турыдан йөгерсәң, өлгерәсең әле. Бар, элдерт, һич югында, үзен күреп, озатып калырсың.

Мин нәкъ шулай эшләдем дә: озын-озак уйлап тормастан, улымны Марина Михайловнага калдырдым да, яр өсләп кенә пристаньга чаптым. Инде кич кергән вакыт булса да, әле һаман һава бөркү иде. Тирләп беттем, сулышым капты. Чокыр-чакырлы яр читендә абынып, бер-ике мәртәбә чүт егылмадым. Әмма үзем, һичнигә карамастан, һаман йөгердем, кош кебек очтым.

Син дә мине көткәнсең, тау өстеннән йөгереп килгәнемне күргәнсең икән, дебаркадер басмасына чыгып каршыладың. Җан-фәрманга ашыгуым бушка булмады, пароход беренче гудок кычкыртканда, мин причалга килеп җиттем һәм тау өстеннән йөгереп төшкән шәпкә инерция белән синең кочагыңа барып та кердем.

Причал тулы кеше күз алдында болай тору уңайсыз иде, без синең каютаңа кердек. Анда барыннан элек күземә ташланган нәрсә – синең өстәлеңдә пыяла астына куелган үз фоторәсемем булды. Улым Кәбирне алдыма утыртып төшкән бу рәсемне әлегә тикле күргәнем юк иде. Күзләремә ышанмыйча бермәл карап торганнан соң:

– Ни күрәм мин?! Берәр могҗизамы, әллә күземә генә күренәме? – дип бик гаҗәпләндем.

– Һичнинди могҗиза юк, Мәрьям җаным, – дип, иңемнән кочаклап, иркәләргә керештең. – Былтыр безнең пароходта барган чакны үзең дә күрмәгән бер арада төшереп алган рәсем бу. Шуннан бирле ул рәсем, аерылмас юлдашым кебек, гел минем белән. Сине сагынган, бик юксынган вакытларда шуңа карап алсам, үзеңне күргәндәй булам. Мәрьям бәгырем, бел: мин сине бик, бик яратам, син һәрчак күңелемдә минем...

Син сүзеңне әйтеп бетерергә өлгермәдең, китәргә вакыт җитүен хәбәр итеп, югарыда икенче гудок бирделәр. Шунда мин аерылышуның нинди авыр газап икәнлеген бөтен рухым белән тойдым, күзләремә яшь тулды.

– Мәрьям, акыллым, болай кинәт кенә аерылышырга ярамый бит. Әйдә Балык Бистәсенә хәтле безнең белән бар, каршы килүче пароход белән кире кайтырсың, – дип, яшьле битемнән үбә-үбә син мине бераз озата барырга үгетли башладың.

Әмма безгә, тиздән тагын очрашырга сүз куешып, аерылышырга туры килде. Бик кыен булса да, үзем бер дә теләмәсәм дә, пароходтан төшеп калдым. Юкса өйдәгеләрнең борчылуы бар иде.

Сез кузгалып киткәнне мин тау өстеннән карап калдым, пароходыгыз күгелҗем еракта эреп күздән югалганчы озак карап тордым. Бик ямансу булса да, сагышым якты, күңелем синең сөюең белән тулы, чиксез шат идем мин.

Аннары мин шундук вокзалга кереп расписание карадым. Горькийда булганнан соң, «Владимир Маяковский» Пермьгә барышлый бирегә тагын дүрт тәүлек үткәч, шушы вакытта киләчәк

икән. Дүрт көн, дүрт төн көтәсе бар, ничек түзмәк кирәк?.. Сине пароходта озата бармаганыма да үкенеп куйдым.

Пристаньнан өйгә мин әнә шундый уйлар эчендә кайттым. Иртәгесен дә шул: күңелемдә гел син, эчемнән гел синең белән сөйләшеп йөрим. Пушкинның шигъри юлларын кабатлыйм:

Ямансу һәм җиңел миңа монда,
Тик син генә бөтен сагышым.
Тик син генә... Күңел сыза, тынмый,
Сыза борчылмыйча, көймичә,
Йөрәк тагын сөя, чөнки булмый,
Булдыра алмый йөрәк сөймичә.

Ниһаять, мин түзмәдем, эштән кайтып кичен бүлмәдә ялгызым гына калгач, үзең белән серләшкәндәй, сиңа менә шушы хатны яздым. Мин аны Казан пристанена адреслап җибәрәм, пароходлар почтаны шуннан алалар бит.

Тиздән очрашуны түземсезлек белән көтеп калучы

*Мәрьямең.*

***Нурис бәгырем, бердәнберем минем!***

Бүген беренче июль, сугыш башлануга ун көн үтте дигәндә, беренче хәбәрең килде, ниһаять. Кыска гына ачык хат, син аны юлдан салгансың. Хәзергә үз адресың юк, анысын билгеле булгач та хәбәр итәрмен, дип әйткәнсең. Мин барыбер сиңа язарга утырдым әле. Адресың мәгълүм булгач, салып җибәрермен.

Менә бит нинди гөнаһ шомлыгы: шат күңел белән сине каршыларга әзерләнеп йөргән вакытта ил өстенә кинәт коточкыч сугыш афәте килеп төште, күпме халыкның бәхетен, матур тормышын, якты хыялларын җимереп ташлады. Хәзер монда бар ир-егетләр хәрби комиссариатка ашыга, минем кебек хатын-кызлар сөйгән ярларын яуга озата.

Шулай да мин сине алай бик тиз китәрсең дип уйламаган идем. Шул өмет белән пристаньга «Владимир Маяковский»ны каршыларга төштем. Ул нәкъ расписаниедә билгеләнгән вакытта килеп җитте. Әмма анда инде син юк идең; Казанда төшеп калып, үзең учетта торган хәрби комиссариатка китүеңне әйттеләр. Албасты саташтыргандай, нишләргә белмичә, кинәт гаҗиз калдым, күз алларым томанланды. Тәмам миңгерәгән, хәлдән тайган килеш көчкә өйгә кайтып җиттем, йоклый алмыйча төн буе газапланып чыктым. Ә иртәгесен, эштән ике көнгә рөхсәт алып, беренче очраган пароход белән Казанга киттем. Ниятем – ничек тә үзеңне күрү, фронтка киткәндә сине озатып калу иде.

Юл буе ут йотып, соңга калмагаем дип, бик борчылып бардым. Пароходтан төшкәч тә, өйгә дә кереп тормастан, пристаньнан туп-туры военкоматка йөгердем. Әмма безгә очрашу насыйп булмаган икән. Военкоматта дежурный командир кемгәдер телефоннан шылтыратып белешкәннән соң, синең шул көнне иртәнге эшелон белән китеп баруыңны әйтте. Бик аяныч, аз гына соңга калганмын. Биш-алты сәгатькә иртәрәк килеп өлгергән булсам, тәгаен күрешәчәкбез, вокзалга хәтле сине озата барасы икәнмен.

Шул ук көнне бер уңайдан техникумга да сугылдым. Хәзер анда беркем дә юк диярлек: студентлар җәйге практикага пароходларга, пристаньнарга таралган, укытучылардан кулына корал тотарлык бар ир заты военкоматта карала, фронтка китәр алдыннан ашыгыч рәвештә расчет алып йөри. Шулай да Матвей Михайловичны очраттым. Чал мыегын кыскартып кырыккангамы, хәтта бераз яшәреп киткән сыман күренде. Һәрвакыттагыча формада, пөхтә киенгән, хәрәкәтләреннән энергия, ихтыяр көче бөркеп тора. Мине күрү белән үз бүлмәсенә алып керде. Чистай хәлләрен сораштырды, аннары:

– Килеп шәп иткәнсең... Хәзер син монда бик кирәк, тизрәк Казанга кайт, – диде. – Укытучыларның күбесе фронтка китә. Пароходларга чыгып практикантларның хәлен белүче, кирәк очракта ярдәм итүче кеше юк.

Мин аңа тәгаен ышандырып берни дә әйтә алмадым, уйларга, әти белән, Марина Михайловна белән киңәшергә кирәк, дидем. Затонда да кешегә кытлык, эш муеннан. Үземне җылы кабул иткән кешеләрне шундый вакытта капылт кына ничек калдырып китәсең?

Азактан, инде саубуллашып чыгарга кузгалганда, Матвей Михайлович, мине туктатып:

– Чыгып китәргә ашыкма, тагын бер эш бар, – диде һәм, минем Хөснуллага мөнәсәбәтем, ничек торуыбыз турында кыскача гына сораштырганнан соң, эчке борчылу белән дәвам итте: – Мин сиңа бер күңелсез хәбәр әйтергә мәҗбүрмен: әтиең өстеннән ялган әләк язуда Хөснулланың да кулы уй-

наганлыгы мәгълүм булды... Хәзер, хаинлыгы ачылгач, ул ах-вах килә, елан кебек боргалана, үкенә: аңа кемнәрдер югарыдан басым ясаган, мәҗбүр иткән, имеш... Менә шул. Авырткан җиреңә тигән булсам, үпкәләмә, сине үз итеп, белеп тор дип әйтүем.

Хөснулланың комагайлыгын, карьерачы икәнлеген инде яхшы белсәм дә, бу тикле түбәнлеккә, хыянәткә барып җитәр дип һич уйламаган идем. Бигрәк тә эти каршында үземә уңайсыз, тормыш юлдашым булган кешенең аңа карата кылган әшәкелеге өчен минем дә гаебем бар сыман тоелды.

Ул көнне Казанда минем тын алырга да вакытым булмады. Техникумнан чыгу белән, эти янына ашыктым. Гадәттә һичкайчан зарланмаса да, картлык көнендә аңа җиңел түгеллеген сизәм мин. Тиз генә керләрен, идәннәрен юып, бүлмәләрне җыештырып китәргә уйлаган идем. Кая ул җыештыру, кул да тидертмәде. Карт елгачы бит, бөтен квартира, пароходта пөхтә капитан каютасы кебек, ялт иткән, һәркайда тәртип һәм чисталык.

Әтинең сәламәтлеге ныгый төшкән, сөбханалла, кәефе дә әйбәт күренә. Техникумга тагын элекке эшкә чакыралар икән. Мондый вакытта өйдә кул кушырып утырырга исәбе юк, иртәгә үк эшкә керешергә җыена.

Байтак вакыт күрми торгангамы, өй шундый сагынылган, тансык, күңелгә якын, һәрнәрсә элеккечә үз урынында, һичнинди үзгәреш юк шикелле. Бердәнбер яңалык – түр як бүлмә стенасында этинең кызыл флотилиядә хезмәт иткән вакытта синең этиең Алимҗан абый белән төшкән фоторәсеме генә үзгәргән. Белгәнемчә, ул болай зур түгел, почта конверты хәтле генә кечкенә форматлы иде. Минем сәерсенеп карап торганны күреп:

– Төп нөсхәсен Нурислам алып торган иде, шул зурайттырып, рамлап китерде, – диде эти. – Әйбәт, мәнле егет, кичә сугышка китәр алдыннан кереп, саубуллашып чыкты. Хәзинәдә бары белән кунак иттем, этисе белән бергә йөргән чакларны искә алып утырдык. Аннары военкоматка озатып та куйдым үзен.

Ә мин телдән үзенә әйтмәсәм дә, монысы өчен молодец дип, эчтән генә этине мактап та алдым.

Хәзер һәркемнең телендә фронт хәбәрләре: фашист урдаларының котырынып алга баруларын, безнең җирләрне басып алуларын ишетү авыр тәэсир итә, борчулы уйлар уята. Шул хакта сүз кузгалгач, эти минем халәтемне сизгәндәй:

– Юк, алай өметсезлеккә бирелергә ярамый, без алай ансат кына баш ия торганнардан түгел, – диде, өстәл өстендәге китапны алып. – Син кайтып керер алдыннан гына Пушкинны карап утыра идем әле. Менә монда Александр Сергеевич менә болай ди: «Россия үз өстенә төшкән бөек вазифаларын үтәп килә, аның иксез-чиксез киңлекләре монгол көчләрен йотты һәм Европа читендә туктатты...» Мин моңа өстәп Наполеон белән дә нәкъ шулай булды, дип әйтер идем. Ә гражданнар сугышы елларында илнең дүрттән өч өлешен дошманнар басып алган вакытны да без югалып калмадык, ач, ялангач көе, бөтендөнья империалистларының кара көчләрен һәм эчке бандаларны тармар итеп куып чыгардык. Менә бераз баш-күз алгач, болары да тиешлесен алырлар, ник басып керүләренә үкенерләр.

Аны-моны сөйләшеп утырган арада, тышта кичке эңгер-меңгер иңде, миңа юлга кузгалыр вакыт җитте. Затонда эш, өйдә бала көтә. Эти кунарга кыстаса да, калмадым, төнге пароход белән кайтып киттем. Әтинең ныклы тәвәккәллеге бераз миңа да күчте бугай, аның белән сөйләшкәннән соң, албасты кебек басып торган авыр уйлардан арынып, акрынлап күңелем ныгуын сиздем.

***...Нурлы кояшым***, адресың һаман килеп җитмәсә дә, менә мин тагын язарга утырдым әле. Башымда һаман бер уй: без ник болай бик соң табыштык?.. Кайта-кайта үземнән-үзем шуны сорыйм.

Без бер-беребезне инде күптән, яшүсмер чактан бирле беләбез бит. Әле дә исемдә, минем алтынчы класска күчкән җәем иде, көннәрдән бер көнне эти сине безгә алып кайтты да:

– Менә дустым Алимҗан улы табылды бит, ниһаять, – диде, бик шатланып. – Бу тикле дә коеп куйган этисе булыр икән... Мин аны әллә кайлардан эзләтеп йөрим, ә ул үзебезнең шәһәрдә күрше район мәктәбендә генә укып йөргән икән. Безнең техникумга керергә килмәгән булса, тәки табасы түгел икәнмен.

...Ул чакны эти безне, моторлы көймәсенә утыртып, Иделгә алып чыкты бит. «Ваня–коммунист» корабында синең этиең белән бергә ак бандаларга каршы сугышкан урыннарны күрсәтте, каһарман комиссар Маркин турында сөйләде... Шул көзне син техникумда укый башладың. Ял көннәрендә безгә килә идең, агалы-сеңелле бертуганнар кебек, икәү бергә Черек күлгә тимераякта шуарга йөри идек. Җиденче классны тәмамлагач, мин дә техникумга кердем. Әтием анда директор булганга, очраклы рәвештә генә түгел, ә кечкенәдән Иделне яратып, шунда пароходлар йөртәсем килгәнгә, бик теләп кердем. Пароход йөртү хатын-кыз эше түгел, дип, эти башта бу ниятемне хуп-

ламаса да, соңыннан күнде, минем һөнәремне кызым дәвам иттерәчәк, дип, хәтта горурланып та куя иде.

Исеңдәдер, ул вакытта безнең техникум үзешчәннәре бик шәп эшлиләр, Мәскәүдә үткәрелгән иҗат конкурсларыннан призлар алып кайталар иде. Һәр шимбә саен диярлек кичләрен концерт яки спектакль була, аннары хәлдән тайганчы оркестрга бии идек. Бу инде мин үсмер кыз булып җиткән, егет-җилән күз сала башлаган вакыт. Ул җәһәттән син мине бар дип тә белмәдең, бертуган сеңелеңдәй, баласытып кына карадың бугай.

Хәер, син, гомумән, кызлар белән бик аралашучан булмадың бит. Кулыңнан китап төшмәде, җыелышларда да, трамвайда барганда да, хәтта ашаганда да – һаман укуда идең, китаптан гайре берни күрмәдең шикелле.

Ә синең белән бер группада укучы сабакташың купшы Хөснулла Каюмов, ябышкак сагыз кебек, гел минем янда булды, адым саен төче телләнеп, тәмам башымны әйләндерде. Яшь чак – юләр чак, дип тикмәгә әйтмәгәннәр, күрәсең. Мин җилбәзәк тә нәкъ шулай, этиемнең карышуына карамастан, күп уйлап тормыйча, Хөснуллага тормышка чыктым. Шул язны син техникумны тәмамлап эшкә киттең. Ә Хөснулла туй тантаналарыннан соң билгеләнгән пароходына бармыйча, ничектер җаен табып, су транспорты институтына укырга керде.

Бөтен фаҗига әнә шулай килеп чыкты. Төзәтелмәслек хата ясавымны, үз тормышымны үзем харап итүемне мин бик тиз күрдем.

***...Хатымны дәвам итәм.***

Мин хәзер һаман синең хакта уйлыйм, икәү бергә булгандай, эчтән гел синең белән сөйләшеп йөрим, бу авыр көннәрдә башымда туган уй-фикерләремне уртаклашам, киңәшәм. Юлдан салган бәләкәй генә ачык хатыңны (бу икенчесе) алып укыгач, үзеңне күргәндәй сөендем һәм менә тагын язарга утырдым. Адресың мәгълүм булгач, шул чакны барысын бергә салып җибәрермен.

Хәзер монда бөтен тормыш үзгәрде. Кулына корал тотарлык егетләр, ирләр барысы да хәрби хезмәттә; завод цехларында, пристаньда һәм пароход, баржаларда өлкән яшьтәге агайлар, хатын-кыз һәм яшүсмерләр генә калды. «Ургыл» пароходында пенсия яшенә җиткән карт капитаннан кала, бөтен команда сугышка китеп барды. Алар урынына шундук яңа команда тупладык. Күбесе моңарчы пароходка аяк басмаган кыз-кыркын. Идарәдән сәгать саен диярлек шылтыратып ашыктыралар: ничек тә капитанга ярдәмче табарга да тизрәк рейска озатырга... Кадрларга шундый кытлык чакны бу бик кыен эш, өй саен йөреп, инде ялдагы карт лоцманнарны ялынып-ялварып эшкә чакырырга керештек.

***...Сөеклем***, бүген өченче хатың, ниһаять, синең адресыңны алып килде, хәл-әхвәлләреңне белеп бераз тынычландым. Юкса күңел урынында түгел, үземне Чехов хикәясендә билгесез адрес буенча бабасына хат язучы ятим малай хәлендә хис итә башлаган идем.

Син анда барып җитеп, хәрби штурманнар хәзерләү курсларына эләккәнсең икән. Минем уйлавымча да шулай булырга, Идел штурманы хәрби флотта хезмәт итәргә тиеш иде. Ярар, хәерлегә булсын, укуыңда сиңа уңышлар телим.

Анысы да монысы, монда мине дә кузгаттылар бит әле. Теге «Ургыл» пароходына капитан ярдәмчесе таба алмагач, мине җибәрергә булдылар. Балам бар, аны кем белән калдырыйм дип, башта карышып та маташкан идем. Кая ул тыңлау! Авыз ачарга да ирек бирмәделәр. Кыен булса да, күнәргә туры килде. Улымны үзем белән алып китәм, шулай тынычрак булыр дип уйлыйм.

Бүген безнең бик мәшәкатьле көн, коры җир белән араны өзеп, барыбыз да пароходка күчтек. Төштән соң рейска китәбез. Шунлыктан сүземне кыска тотам, гафу ит, юлга чыккач, пароходтан иркенләбрәк язармын. Син хатларыңны һаман шушы адреска, Марина Михайловна исеменә сал. Мин ничек тә аның белән элемтәдә булырга тырышырмын, җай туры килгән саен белешеп торырмын.

Сине сагынып, бик юксынып калучы

*Мәрьямең.*

*P. S.* Чистайда соңгы көнне эшебез бик тыгыз булды, язганнарымны конвертлап почта ящигына илтеп салырга да вакыт таба алмадым. Шунлыктан хатымны бераз соңарып юлдан җибәрәм.

*М–м*

***Нурискәем***, менә без юлда инде, бу хатымны пароходта язам. Чистайда чакны хәл җиңелрәк булган икән. Хәзер без еракта йөрибез, хатларың килгәнме-юкмы икәнлеген дә белеп булмый. Һәрхәлдә, бер җае табылыр, якын арада мин аларны ничек тә кулга төшерермен дип өметләнәм.

Башта үзем турында, эшләребез турында берничә сүз. Мин затонда кадрлар бүлегендә эшләгән чакта, «Ургыл» пароходына яңа команданы бик төпченеп сайламаган идем. Кешеләрнең эшкә яраклымы-түгелме икәнен дә артык тикшереп тормадым. Менә хәзер шул пароходка үзем капитан ярдәмчесе булып килгәч, кем әйтмешли, чәчләрем үрә торды. Моңарчы пароходны яр буеннан гына күреп белгән кызлар, солдаткалар белән ничек эшләрбез дип, хәтта бераз шүрләп тә калдым. Ярый әле капитаныбыз – инде пенсия яшеннән узган агай Трофим Григорьевич – җайлы кеше, кайберәүләр кебек, пароходта хатын-кыз эшләүгә тискәре карамый. Минем ярдәмче булып килүемә бер дә ризасызлык күрсәтмәде. Яңа команда турындагы борчулы сүзләремә дә хафаланмыйча, тәҗрибәле картларга хас сабырлык белән:

– Берни кылыр хәлең юк, – диде. – Шул булган халык белән эшләргә, белмәгәннәрен өйрәтергә туры килер. Башка чара юк, тормыш шулай куша.

Эш арасында берәр җитешсезлек өчен кинәт кызып китеп, кайчак каты орыша, хәтта сүгенә торган гадәте булса да, Трофим Григорьевич күңелендә ачу сакламый, бик тиз суына һәм, урынсызга чәпчегән өчен акланырга теләгәндәй: «Менә шундый кабалан инде безнең эш. Искедән калган начар гадәт, һич ташлап булмый», – дип, үзалдына зарланып куя. Әмма минем үземә карата дорфалык күрсәткәне юк. Яше ягыннан мин аннан өч мәртәбә кечерәк булсам да, капитаннар, штурманнар арасында әүвәл-әүвәлдән яшәп килгән әйбәт йола буенча миңа, Мәрьям Вәсилевна, дип, ихтирам белән эндәшә. Минем елга техникумы директоры, карт капитан кызы икәнемне кемнәндер ишетеп белгәч, молодец, үз эшен дәвам иттерүче кыз үстергән дип, әтине дә мактап куйды.

Мин бигрәк тә үзем өчен борчылам. Улым туганнан бирле пароходта эшләмәү аркасында гел үзгәреп торучан фарватерны, әлбәттә, шактый онытканмын. Шунлыктан һәрвакыт сизгер булырга, елга картасына ешрак карарга, кыен участокларда ярдәмгә капитанны да рубкага чакырырга туры килә.

Ә менә бөтен машина өчен җаваплы кеше – өлкән механигыбыз – үз урынында түгел бугай. Былтыр гына техникум тәмамлаган ул хатын безнең заводта мастер булып эшләгән. Бу җыйнак гәүдәле, тулы алсу иренле яшь чибәрне мин күреп белә идем, ул һәр көн иртән эшкә ире белән култыклашып килә, кичен култыклашып кайтып китә, үзешчән сәнгать концертларында халык җырларын оста башкарып, тыңлаучыларны үзенә карата иде. Ирен сугышка озаткач, ике-өч көн үтмәгәндер, без аны «Ургыл» пароходына өлкән механик итеп күчердек. Менә шул япь-яшь хатын үзе кебек үк тәҗрибәсез машинист, майлаучы, кочегар кызларны җитәкләп эшләтә, бөтен машинаның тоткарсыз эшләвен тәэмин итә алыр микән?

Аның каравы боцманыбыз шактый тәҗрибәле һәм эшкә уңган булып чыкты. Сугышка хәтле ире белән шушы пароходта матрос булып эшләп йөргәндә, ярыйсы гына шомарган Мәрфуга барча эшләр белән үзе белеп командалык итә, матрослардан берәрсе ялкауланса-нитсә, ир-ат боцманнардан кимен куймыйча, суганлап-борычлап кыздыра да белә. Мәгәр аңа беркем дә үпкәләми, читләшми үзеннән, киресенчә, аңа елышалар, ярдәмчеллеген тоеп булса кирәк, матрослар, койрыкчылар гел аның тирәсендә кайнашалар.

Идарә җитәкчеләре безне бик ашыктырып, «Ургыл» зур пароход түгел, якын-тирәдә генә йөрисе, кирәкле ярдәмне һәрвакыт күрсәтербез дип, сыйпап-юмалап озатканнар иде. Чынлыкта исә беренче рейстан ук ерак юлга чыгарга туры килде. Без, Кама буе пристаньнарында яңа гына армиягә алынган һәм әле хәрби форма кияргә дә өлгермәгән ир-егетләрне төяп, Югары Идел якларына китеп бардык.

И, мондагы моң-зарны белсәң икән! Туган улларын, кадерле ирләрен, сөйгән егетләрен озатканда, пристаньнарда елап калган аналарны, яшь киленнәрне, кызларны күреп күзләр яшьләнә, тын кысыла. Аларга карап, Нурис җаным, синең өчен шомланып, үзем дә өзгәләнәм.

Хәзер без юлда. Туган-үскән җирләреннән, якыннарыннан яңа гына аерылып киткән кайбер егетләр, моңланып, үзәк өзгеч сагышлы җырлар көйләп баралар...

Капитан Трофим Григорьевич миңа бик үк ышанып бетми бугай. Кичә Кама Тамагы пристаненнан кузгалып киткәннән соң, кичке караңгыда минем вахта башлануга карамастан, ул байтак вакыт үзе рубкада торды, гәрчә телдән аны-моны сиздермәсә дә, минем ничек эшләвемне игътибар белән күзәтеп барды. Ярдәмчеләренә ышанмыйча, тәүлек буе диярлек рубкадан төшмәүче капитаннар турында моңарчы да ишетеп белә идем. Әгәр Трофим Григорьевич та шулар кебек артык тынгысыз командир булса, бер дә шәп түгел, әлбәттә.

Ярар, анысына ничек тә түзәрмен, юкка-барга бәйләнергә урын калдырмаслык итеп эшләргә тырышырмын.

Хуш, сау бул, сөеклем.

Сиңа кайнар сәлам һәм якты теләкләр юллаучы

*Мәрьямең.*

***Җан сөйгәнем***, затоннан чыкканнан бирле синнән килгән хатларны һаман күргән юк әле. Чистайга кайтып, аларны алу мөмкинлегенең кайчан буласын хәзергә чамалап әйтүе дә кыен.

Шактый озакка сузылган беренче рейсны бары тик бүген тәмамладык, шөкрана, эшелоныбызны әйтелгән шәһәргә бәла-казасыз илтеп җиткердек. Шулай да юлда булган бер сәер вакыйганы сиңа да языйм әле. Беркөн, иртәнге вахтага менәр алдыннан аскы палубаны йөреп чыкканда, боцман Мәрфуга, мине туктатып:

– Әнә теге парга игътибар беләнрәк карагыз әле,– диде, башкалардан читтәрәк торган ике егеткә ишарәләп.– Сезнеңчә ничек, аларның берсе хатын-кызга охшаган түгелме?

Алар алгы якта иңгә-иң сыенып сул як бортта торалар һәм бер-берсенә үпкәләшкәндәй, сүзсез генә суга карап баралар иде. Берсе калку яңаклы, базык гәүдәле җирән егет, икенчесе, чынлап та, хатын-кыз. Чәчен алдырткан, егетләрчә чалбар, кепка кигән булуга карамастан, зифа буе, күлмәк астыннан калкып торган күкрәк йомрылары, кыйгач кара кашлары – барысы да аның буй җитеп килгән матур кыз икәнлеген әйтеп тора иде. Бик гаҗәпләндем:

– Моны кем оештырган, нинди әкәмәт бу?!

Безнең үткен зиһенле боцманыбыз Мәрфуга ул кыз белән инде танышып өлгергән, аны каютасына алып кереп, чәй янында сораштырып, барысын да белешеп өлгергән иде. Боцман кыскача гына сөйләгәннән шуны ачыкладым: алар икесе дә бер авылныкылар, бер-берсен яратышып өйләнешергә булалар, туйга әзерләнү мәшәкатьләре башлана. Әмма көтмәгәндә сугыш чыгып, егет хәрби хезмәткә алына һәм күп мәшәкатьләр белән әзерләнгән туй булмый кала. Гашыйк кәләш, озынозак уйлап тормастан, кияү егете белән бергә үзе дә фронтка китәргә карар кыла. Әбие дә, кияү егете дә аны кулдан килгәнчә тынычландырырга, бу тиктомал ниятеннән дүндерергә тырышалар. Ә кызый һаман үзенекен итә. Военкомат кире какканнан соң да чигенми. Яшертен генә чәчен алдырып, кемнеңдер чалбарын, кепкасын һәм ирләр күлмәге кия дә пристаньга йөгерә, төнге ыгы-зыгы арасында китүче районнашлары белән бергә пароходка кереп утыра. Кияү егетенә ул бары тик пароход пристаньнан кузгалып киткәч кенә күренә.

Бу хакта инде безне озата баручы эшелон начальнигы да белә икән.

– Менә сиңа көтелмәгән сюрприз... Шул гына җитмәгән иде, – диде ул, борчылу белән. – Хәзер безнең алда ул шашкан кызны ничек тә аерып калдыру бурычы тора. Күренә, кызның башы-күзе әйләнгән, бик иләс-миләс чагы. Димәк, моны саклык белән, берәр бәла-каза чыгармаслык итеп, җайлап кына эшләргә кирәк. Сезнең пароход кызлары бу четерекле эштә, зинһар, безгә булышсыннар инде.

Нишлисең бит, кирәк булгач, булышырга туры килде. Башта ничектер уңайсыз булыр кебек тоелса да, бик ансат эшләнде тагын. Моның өчен боцман Мәрфуга, сиңа ир-ат арасында ипсездер дип, кызны төнгә үз каютасына алып кереп яткырды. Ә иртәгесен качак кәләш йокыдан торып каютадан чыкканда, гаскәриләр инде төшеп киткән, пароход яр буеннан шактый еракта якорьда тора иде.

И шулчак бичара кызның ачыргалануын күрсәң икән. Тәмам шашты, үзен-үзе белештермәс хәлгә җитеп ярсыды. Ярга йөзеп чыгам дип суга ташланудан көчкә тыеп калдык без аны.

Бераздан, пароходны чистартып чыгаргач, без дебаркадер янына барып туктадык һәм элегрәк кенә көнбатыш өлкәләрдән килеп төшкән качакларны – юлда дошман бомбалары астында газиз балаларын югалткан аналар, ятим калган сабыйлар, яралы карт-карчыкларны кабул итә башладык. Алар барысы да коточкыч йончыган, кайберләре акылдан язар хәлгә җиткән, кайберләре үз аягы белән пароходка керерлек тә түгел иде. Андый бичараларны пароходка җитәкләп, каты яралыларны носилкага салып кертергә туры килде.

Әлегә хәтле без сугыш фаҗигасен газеталардан укып, радиодан ишетеп кенә белә идек. Аның аяусыз куркынычын, бөтен ил өчен коточкыч һәлакәтен бүген беренче мәртәбә үз күзебез белән күреп тетрәндек. Бу куркыныч хәлгә әлеге кияү егетеннән аерылып калган кыз Зәкия дә бик әсәрләнде, үз кайгысын читкә куеп, шундук ярдәмчесез сабыйларны, яралыларны кертеп урнаштыруда булыша башлады һәм шуның белән ул үзе дә безнең команда члены, үз кешебез кебек якын булып китте.

Пароходта берьялгызы калган ул кызны без, башта ничек тә юллык акча юнәтеп, туган авылына озатырга уйлаган идек. Пароходтан төшеп киткән вакытта кызның кияү егете дә боцманга шундый киңәш әйтеп калдырган булып чыкты. Әмма Зәкия үзе мондый сәер сәяхәттән соң авылдашларына кайтып күренергә уңайсызланды бугай.

– Юк, мин анда кайтмыйм... – диде ул, безнең киңәшне катгый рәвештә кире кагып. – Зәкинең (кияү егетенең исеме шулай икән) адресы табылу белән, мин барыбер аның артыннан китәчәкмен, аның белән бергә иңгә-иң торып фашистка каршы сугышачакмын. Миңа бүтәнчә тормыш юк... Аның адресы табылганчы, бу тирәдә вакытлы рәвештә берәр заводка яки пристаньга эшкә кереп ничек тә торырмын әле.

Янында бернинди документы һәм рәтле өс-баш киеме дә булмаган бу яшь кызны без таныш түгел шәһәрдә төшереп ялгызын калдырмаска, үзебезнең штатта буш урынга вакытлы рәвештә матрос итеп алырга булдык. Аны матрослыкка өйрәтергә боцман Мәрфуга үзе теләк белдерде.

***...Күз нурым!***

Кичә яза башлаган хатымны менә бүген көндезге вахтадан бушагач дәвам итәм.

Теге көнне пароходка кабул иткән халыкны Казанга алып кайтырга приказ булды. Мең газаплы хәтәр юлдан соң бичара качаклар пароходта бераз хәл алдылар, тынычланган кебек булдылар. Елый-елый шешенеп беткән ятим нарасыйлар гына, кайгыларын аңнарына сыйдыра алмыйча, әле һаман өзгәләнеп әниләрен эзлиләр.

Яңа матросыбыз Зәкия эштән буш сәгатьләрне гел шулар арасында: берсенең кайгысын уртаклаша, икенчесен тәмле теле белән юата, үзләре йөри алмаган яралыларга чәй китереп бирә. Әнисез калган өч яшьлек бер ятим малайны душта коендырып, үз каютасына алып кергән, ашатып-эчертеп йокларга яткырган. Хәзер шуның белән мәшгуль, аны үзенә уллыкка алырга ниятләнә, дип сөйлиләр.

...Бүген рубкада көндезге вахтада торганда, кайдандыр түбәннән бик таныш һәм җанга якын көйгә хатын-кыз җырлаганы ишетелә башлады:

Әй, бөдрә чәч, зәңгәр күз,
Әйтмәм лә, бәгырькәем, авыр сүз...

«Зәңгәр күз» – безнең техникум студенты чыгарган һәм авыр истәлекләр белән бәйле бик моңлы һәм популяр җыр, мәхәббәт сагышыннан үзенең яшь гомерен харап иткән егет җыры бит. Хәтерлисеңдер, атна саен клубта үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәләрдә бергәләп тә, күңел яманса вакытларны аерым-аерым да без ул җырны башкара идек. Мин аны хәзер дә дулкынланмыйча тыңлый алмыйм.

Башта бу җыр миңа радиодан ишетелгән Казан концерты кебек тоелган иде. Әмма ялгышканмын. Штурвал көпчәге янында торучы рулевой кыз Җәмилә, минем уйларымны бүлде:

– Ишетәсезме, безнең Зәкия нишләтә... Бу тикле дә моң булыр икән, күздән яшьләр чыгара...

– Радиодан түгелмени бу?! Шул җырлыймыни?! – дип, бик гаҗәпләндем.

Бераздан вахтадан бушап аскы палубага төшкәч, мин юри алгы яктан әйләнеп үттем һәм анда Зәкияне күрдем. Түгәрәкләп өелгән сүс чалка өстендә алга карап утырган хәлдә, кемгәдер моң-зарын сөйләгәндәй, әле һаман җырлый, аның янында җыелган качаклар да, безнең пароход кызлары да, сихерләнгәндәй тынып, аны тыңлыйлар иде. Шунда бер читтә шыпырт кына туктап, мин дә китә алмыйча байтак вакыт дулкынланып тыңлап тордым... Хәер, бу көннәрдә мин, гомумән, җырларны, бигрәк тә ямансу көйләрне бирелеп тыңлаучан, үзем дә авыз эченнән көйләп йөри торган булып киттем әле; һәр моңсу, сагышлы җыр сине хәтерләтә.

Гаҗәп хәл, шушы яшемә җитеп әлегә тикле мин, гомумән, чын мәхәббәтнең, җан-тән белән сөю-сөелүнең нәрсә икәнлеген белмәгәнмен. Шуңа булса кирәк, китапларда тасвирланган шашкын гашыйкларны, янып-көеп гыйшык тотуларны мин шагыйрьләр уйлап чыгарган ялтыравык сүз, төче телләнү дип кенә кабул иттем. Әгәр инде иптәш кызларымнан берәрсе үзенең сөю-сөелү шатлыгы белән уртаклашса, яраткан егетен күкләргә чөеп мактаса, мин аны баш әйләнүдән килеп чыккан чамасыз күпертү, төчеләнү дип уйлый идем. Менә хәзер үзем нәкъ шундыйга әвереледем, гел синең хакта уйлап йөрим, син һаман минем белән.

Күптән түгел генә пароход Рязаньда торган вакытта яр буена чыккан идем. Шунда пристань каршында ыгы-зыгы килгән халык арасында бер елгачыны күреп шаккаттым. Буе-сыны, кителе, фуражкасы, йөреше – барысы да нәкъ синеке, шатлыктан чүт кычкырып эндәшмәдем үзенә. Бераздан, артыннан куып җитеп, яннан карап узгач кына үземнең ялгышуымны аңладым.

Бүгенгә хуш, сау бул, дускаем.

Сине һәрчак күңелендә йөртүче

*Мәрьямең.*

***Нурисым!***

Соңгы вакытта безне өйдән еракта, гел Иделнең югарыгы агымында яисә Ока елгасында эшләттеләр. Ике ай буе синнән бернинди хат-хәбәр алмаудан, билгесезлектән борчыла-борчыла тәмам гаҗиз булган, интегеп беткән идем. Ниһаять, менә тагын Казанга кайттык. Пристаньга килеп туктау белән диспетчер бүлмәсеннән Чистайга шылтыраттым. Минем бәхеткә, квартира хуҗасы Марина Михайловна эш урынында туры килде. Исәнләшеп хәл-әхвәл белешкәч тә, синнән биш хат бар дип, мине бик сөендерде. Хатларыңның берсе – бүген эшкә барганда таныш почтальон урамда биреп калдырганы – шунда, үз янында икән. Түзмәдем, хатыңны шундук ачтырттырып, телефоннан укып бирүен сорадым. Марина Михайловна хатны зур кыенлык белән, абына-сөртенә укыса да, һәр сүзеңне үз авызыңнан ишеткәндәй булдым, әйтеп бетергесез куандым. Иң мөһиме – син исән-сау, шуңа сөендем. Бик сагындым, мәхәббәтең сугыш кыенлыкларын җиңәргә ярдәм итә дип, минем күңелне күтәргәнсең. Җылы сүзең өчен мең рәхмәт сиңа, кадерлем.

Казанда әтине дә күрдем. Без киләсене белешеп торган икән, мин өйгә шылтыратканчы ук пристаньга ул үзе төшеп җитте. Кәбирне бик сагынган, аңа уенчык, күчтәнәчләр алып килгән.

Әтине тагын техникум директоры иткәннәр. Күз тимәсен картка, хәзергә бирешми, әйбәт кенә йөреп тора. Без рейстан кайтканчыга тикле дип, Кәбирне үз янында кунакка алып калды.

Әти сөйләгәннәрдән тагын бер яңалык – Хөснулланың пристаньга тәэминат начальнигы булып күчүе мәгълүм булды. Техникумнан расчет алган көнне салмыш хәлдә әти янына кереп тагын бер кат гафу үтенгән, минем белән килешергә, бергә тора башларга ярдәм итүен сораган.

Безнең монда хәзергә әллә ни зур яңалыклар юк. Һаман шул линиядә – Иделнең югарыгы агымына йөрибез: моннан азык-төлек, кием-салым, сугыш кирәк-яраклары һәм гаскәриләрне төяп барабыз, аннан тылга күченүче завод-фабрика җиһазлары, каюталарда эшчеләр һәм яралылар алып кайтабыз. Хәзер бөтен флот диярлек шунда эшли, Мәскәү янындагы хәлнең кискенлеге шуны таләп итә.

Эш муеннан, буш вакыт юк диярлек. Кеше җитмәү аркасында тәүлегенә уникешәр сәгать (алтышар сәгатьтән ике тапкыр) вахта торабыз. Ә миңа әлегә таныш түгел Ока елгасында ярым сукыр лоцман белән эшләве баштарак бигрәк тә читен булды. Тик бераздан, фарватерны азмы-күпме үзләштергәч кенә, җиңелрәк сулыш алдым. Шөкрана, капитаныбыз Трофим Григорьевич та, беренче көннәрдәге кебек, эч пошырып янымда тормый, хәзер ул миңа тулысынча ышана. Үз сәгатьләре тәмам булганнан соң, миңа хәерле вахта теләп, тыныч күңел белән рубкадан төшеп китә.

Менә рәхимсез сугышның авырлыгы безнең команда өстенә дә төшә башлады. Кичә, Чистай белән сөйләшкәннән соң, шатланып пароходка кайтып керсәм, мине Трофим Григорьевич чакыртып алды да, авыр сулап:

– Военкоматтан күңелсез хәбәр бар, фронтта безнең боцман Марфаның (Мәрфуганы үзенчә шулай йөртә) ире һәлак булган, – диде. – Менә шуны үзенә ничек әйтергә белмичә аптырап торам. Хатын-кыз кеше, сез шуны җайлабрак, ничек тә йомшаграк итеп әйтә алмассызмы?..

Бу минутта Мәрфуга үзе, зәңгәр майкасының җиңнәрен сызганып, шлангтан су сиптерә-сиптерә палуба юдырта, артыннан швабра белән сөртә баручы кызларны ашыктыра, көр тавышыннан, җиңел хәрәкәтләреннән аның ныклыгы, кыенлыкларга бирешмәслеге күренеп тора иде. Шулай да бу кайгылы хәбәрне аңа үзем генә әйтергә телем бармады. Кызыл почмакка чакыртып, капитан белән бергәләп белдерергә туры килде.

Кулдан килгәнчә җайлап, мөмкин кадәр йомшаграк итеп әйтсәк тә, бу хәбәрдән Мәрфуга кинәт миңгерәүләнде, өянәк тоткан кебек, иреннәре калтырый башлады, төсе китте. Тиз генә салып биргән суны бер-ике йотым эчкәч кенә телгә килеп, ишетелер-ишетелмәс өнсез тавыш белән:

– Бар таянычым син идең, башыңа җиткәннәр икән, ләгънәтләр, – диде һәм, үзе генә калырга теләп булса кирәк, алпан-тилпән атлап, кызыл почмактан чыгып китте.

Мәрфуганың кайгысы бөтен командага авыр тәэсир итте, һәркайсыбызның күңелендә сугыштагы якыннары турында борчулы уйлар уятты. Яшерен-батырын түгел, үземнең дә йөрәгем жу-у итеп китте: син дә шунда ут эчендә йөрисең бит. Син анда, зинһар, алдыңны-артыңны карап йөр, якты киләчәгебез хакына сак була күр.

Сине һәрвакыт юксынучы

*Мәрьямең.*

***Нурисым, җан кисәгем минем!***

Әлегә тикле һич булмаган хәл, бу арада сиңа атна буе хат яза алмадым. Син анда көтә-көтә миңа үпкәләп беткәнсеңдер инде. Зинһар, үпкәли күрмә. Мин гаепле түгел, бу көннәрдә иркенләп ашарга, мендәргә баш төртеп алырга да вакыт булмады. Соңгы рейс азагында затоннан еракта – ачык елга уртасында бозга катып калудан көчкә котылдык.

Ярар, ул хакта азактарак язармын. Башта сине бөек Октябрь бәйрәме һәм бүләкләнүең – орден алуың белән котлыйм! Синең өчен мин бик шатмын, батыр бөркетем, молодец! Сугышчан дустың Суранов белән бергә төшкән фоторәсемеңне рамка эченә куеп стенага элдем. Нинди хәтәр «эш» өчен бүләкләнүең турында фронт газетасында басылган мәкаләне кисеп алып җибәрүең бик яхшы булган. Без аны кызыл почмакта бөтен команда белән укыдык, шуннан соң бу арада шактый өшәнгән кызларымның зарлану-сыкранулары шактый кимеде, ул көнне без аеруча тырышып эшләдек.

Без затонга бәйрәм алды кичендә генә кайтып кердек. Синнән әлегә тикле килгән хатларны мин Чистайга кайткач барысын берьюлы алдым. Кайсы карандаш, кайсы кара белән аяк өсте генә язылган бу конвертлар, өчпочмаклап бөкләнгән дәфтәр битләре, берничә җөмләдән генә гыйбарәт кыска-кыска ачык хат-хәбәрләрне Марина Михайловна өеме белән алдыма китереп салгач, башым күккә тигәндәй булды. Минем өчен болар гади хат-кәгазь генә түгел, дәһшәтле сугыш эченнән синең күңел җылыңны чәчми-түкми саклап китерүче, безнең ерак араларны якынайтучы тылсымлы җепләр бит алар.

Әнә шулай рәхәткә чумып шул хатларны укып утырганда, бүлмәгә көтүе белән безнең пароход кызлары килеп керде. Авыр сугыш вакыты булса да, барысы да бәйрәмчә киенгән, йөзләре шат. Арада боцман Мәрфуга гына моңлы-зарлы, ире һәлак булганнан соң, ул бичара һаман искә килә алмый әле.

Җырчы Зәкия өстәл өстендәге хатларны күрүгә сагаеп калды: «Үзе бер почта ич бу... Бөтенесе дә шушы командирларданмы, боларның кайсы сезнеке?» – дип, стенадагы фоторәсемгә текәлде. Башкалар да, моны ничек аңларга дигән сыман, бер миңа, бер рәсемгә сораулы карап алдылар.

Сизәм, күңелләрендә шик тугандай, сагаеп калды болар. Мин аларга синең турыда берни дә әйткәнем юк бит әле. Җәен Казан пристанендә туктап торган чакларны Хөснулланың берничә мәртәбә пароходка кергәнен, Кәбирнең этисе шул икәнлеген алар беләләр бит. Һәм менә хәзер мине ир өстеннән башка берәүгә гыйшык тота дип гаеплиләр иде бугай. Бөтен кыяфәтләреннән шул күренә, сәгате-минуты белән күз алдында үзгәреп, читсенеп карыйлар... Андый аңлашылмаучылыкка, имеш-мимеш гайбәтләргә урын калдырмас өчен, инде елдан артык Хөснулла белән тормавымны, якын арада рәсми рәвештә аерылышачагымны шундук аларга кыскача гына әйтеп бирергә туры килде.

Әйтергә мөмкин, Октябрь бәйрәмен без барыбыз бергә ярыйсы гына күңелле үткәрдек. Мәскәү янында фронт хәлләре гаять кыен булуына карамастан, Кызыл мәйдандагы хәрби парад, куәтле танк колонналарының шуннан туп-туры яуга китүен радиодан ишетү барыбызны да канатландырды, күңелләрдә җиңүгә ышанычны ныгытты.

Марина Михайловна безне бәйрәмгә пешергән тәмле балык пирогы белән сыйлады, кара карлыган вареньесы белән чәй эчерде. Аннары Зәкиянең моңлы җырларын тыңладык, аңа кушылып үзебез дә җырладык.

Марина Михайловнаның шәһәр укытучылар йортына бәйрәм кичәсенә чакыру билеты бар икән. Үзенә ияртеп ул безне дә алып барды һәм, таныш администраторы белән сөйләшеп, барыбызга да залга керергә ярдәм итте. Без пароходта йөргән вакытта бирегә Мәскәүдән күп кенә атаклы язучылар, артистлар күчеп килгәнен мин ишетеп белә идем. Бүгенге кичәдә шулардан К.Федин, Н.Асеев, М.Исаковский катнашты, яңа әсәрләрен укыдылар, кызыклы истәлекләр сөйләделәр, күпсанлы сорауларга җавап бирделәр. Атаклы әдипләрнең, сәнгать осталарының шигырьләрен, җырларын тыңлаганда, үземнең бөек совет иле гражданины икәнемне, халкыбызның какшамас бердәмлеген бөтен җаным-тәнем белән тоеп, дулкынланып утырдым.

Менә хәзер шул кичәдән соң тын бүлмәдә сиңа хат язып утырам. Айлар буе юлда йөрүдән, ыгы-зыгылы пароход тормышыннан соң күптөрле эш-мәшәкатьләрдән азат хәлдә тын, җылы бүлмәдә утыруы үзе бер рәхәт. Ә бит без бер атна элек Чистайдан еракта бөтен кыш буена боз эчендә катып калу куркынычы астында идек.

Ул чакны Идел суы әле суынып бетмәгән, һәркайда пароходлар йөри, пристаньнарда калган соңгы йөкләрне ташыйлар иде. Ә безне исә, Кама елгасының дүрт-биш көнгә элегрәк бозлануын исәпкә алып, ашыгыч рәвештә Чистайга кайтырга, затонда кышка туктарга приказ бирделәр.

Әйе, ашыгырга кирәк иде. Чөнки төньяк җиле көннән-көн кырыслана бара, кышның салкын сулышы үзен нык сиздерә иде.

Казанда үз затоныбызга кайтырга приказ алгач та, без бернинди йөксез, пассажирларсыз шундук юлга кузгалдык һәм, һичкайда туктамыйча, шул ук кичне Кама Тамагына төшеп җиттек. Анда да пристаньга туктап тормастан, барган шәпкә Лобач тавы турында гудок кычкырта-кычкырта Идел белән саубуллаштык та, агымга каршы борылып, Камага керүгә көзге зим агымына тарыдык.

Инде эңгер-меңгер куерган, күз бәйләнгән вакыт иде. Рәтләп күренмәгәнгә булса кирәк, башта ничектер ышанасым килмәде. Әле иртә, мөмкин түгел, миңа гына шулай тоеладыр дип тынычландырырга тырыштым үземне. Әмма үзем сизәм, пароход рульне начар тыңлый, әле уңга, әле сулга чалулый башлады. Йөреше дә сизелерлек авырая төште, әйтерсең йөкле баржа тартып барабыз инде.

Әйләнә-тирәдә төн карасы тагын да куера төште. Су өстендә бер генә йөзмә маяк та юк; елга борылышларын күрсәтүче яр өстендәге парлы-парлы перевал утлары гына анда-санда күзгә чалынып киткәли.

Шул арада сөйләшү трубасы буенча алгы пролеттан матрос Зәкия, борчулы тавыш белән:

– Мәрьям Вәсилевна, сез ничек анда, күрәсезме?! Боз килә башлады бит, – дип хәбәр итте.

Тиз генә рубка өстендәге прожекторны кабызып карасам, ике күзем дүрт булды: су өстендә, ярдан ярга тоташ җәелеп, итле аш өресе төсле зим ага. Әмма бу Зәкия хәбәр иткәнчә, боз түгел әле, кайдадыр елганың югарыгы агымында яуган карның, салкын суда эремичә, ботка кебек куерып килә башлавы гына. Шулай да һава суыкка китсә, берничә сәгать эчендә аның боз булып ката башлау куркынычы бик ихтимал.

Шундук капитанны уяттырып рубкага чакырырга туры килде. Һәрьяклап уйлашканнан, киңәшкәннән соң, мондый караңгы төндә маяксыз юлда шуннан ары бармаска булдык. Лаешка җитәрәк сул як яр чыгынтысы ышыгында якорьга туктап, төнне шунда үткәрдек.

Иртән яктырганда үч иткән кебек, һава отыры суыта төшкән, кичәге юеш кар боткасы боз кисәкләренә әверелгән, көпчәк канатлары арасына тулып каткан иде. Лом һәм кәйлә белән ике як көпчәкне боздан әрчү шактый озакка сузылды, сәгать унбердә генә кузгалып китә алдык.

Авырткан башка тимер тарак дигәндәй, бер кирегә китсә китә бит. Вак бозлардан ачык җылуларны сайлый-сайлый өч сәгать бармаганбыздыр, төньяктан чыккан ачы җил иләмсез тавышлар белән мачтага, ванталарга бәрелеп сызгыра, эре-эре ак «чебеннәр» очыра башлады. Берничә минут эчендә күз ачкысыз кар бураны күтәрелде. Фарватердан читкәрәк тайпылып, без тагын якорь салдык һәм көннең калган өлешен шунда үткәрергә мәҗбүр булдык.

Буран кичке караңгы төшкәндә генә туктады, соры болытлар таралып, чалт аяз салкын төн башланды. Болай суыкка киткәч, яктырганны көтеп, иртәгә хәтле монда тору хәтәр, хәлнең кыенлашканнан-кыенлаша баруы көн кебек ачык. Руль һәм көпчәкләрне мең бәла белән боздан арындырып, без тагын юлга кузгалдык.

Башта баруы бик кыен булды. Вак боз тулы елга һәм тугайлар кар белән капланып, ак ятьмә ябынгандай, барысы да тоташ бер төстә, кайда су, кайда яр кырые икәнен дә аерырлык түгел иде. Шулай да бераздан, күз ияләнә төшкәч, тонык ай яктысында боздан ачык урыннарда су өсте каракучкылланып ачыграк күренә башлады, тирәнлекне үлчи-үлчи төн буе акрынлап бардык.

Иртәгесен таң беленгәндә, без инде Балык Бистәсе турысына менеп җиттек. Җил басылса да, көн тагын да катырак суыта төште, күз алдында калыная, зурая барган бозлар корпуска дөбердәп килеп бәрелгән саен, бөтен пароход шомлы калтыранып куя: боз кантарлары бәрелүдән көпчәк канатлары чатный башлады.

Шундый суыкта көпчәкнең ватык канатларын алып, яңаларын гайкалар белән беркетеп кую – безнең эше хатын-кызга гына түгел, тәҗрибәле ир-егетләр өчен дә шактый кыен эш. Ул көнне безгә бу авыр эшне ике тапкыр башкарырга туры килде. Тайгак бозлы көпчәк тырнаклары арасында өзлексез чайкалып торган суык судан өс-башыбыз, гипслаган кебек, бөгелмәс булып катты, кул-аяк күшегеп бетте.

Шөкрана, тырышуыбыз бушка китмәде. Мең газап белән булса да, көн яктысында Чистайга кайтып җиттек, бик зур бәладән – кышкы юлда катып калудан котылдык.

Тагын шунысы гаҗәп, затонда безнең урын син эшләгән «Владимир Маяковский» пароходы белән янәшә туры килде. Аны күргәч, кайчандыр бергәләп Ульяновскига барган, пристаньда синең белән соңгы тапкыр саубуллашкан минутлар күз алдыма килеп басты, бик ямансу булып китте.

Менә шулай, кадерлем, атна буе хат яза алмасам да, син һаман минем күңелемдә булдың, гел синең хакта уйлап, сагынып эшләдем.

Сиңа саулык-сәламәтлек теләп

*Мәрьямең.*

***Кадерлем!*** Берничә көн элек кенә сине Яңа ел белән котлап инде бер хат җибәргән идем. Яңа елны без бик шатланып каршыладык. Гаскәрләребезнең Мәскәү янындагы зур җиңүе безнең янган йөрәкләргә шифалы май булып ятты, барыбызны да канатландырды, рухи көч бирде. Кешеләрнең борчулы йөзләрендә өмет яктысы балкыды. Бу зур шатлык белән сине дә тәбрик итәм һәм сезнең тарафларда да яңа җиңүләр теләп калам.

Бераз гына үзем дә мактанып алыйм әле: үткән навигациядә хәрби йөкләрне ташу заданиеләрен уңышлы үтәгән һәм гаять авыр метеорологик шартларда юлда катып калмыйча, пароходны төзек-имин хәлендә затонга алып кайткан өчен (каты суыклар кинәт башлану нәтиҗәсендә затоннардан еракта елга уртасында катып калучы пароходлар байтак быел), безгә пароходчылыкның күчмә вымпелын тапшырдылар, барыбызны да кышка берәр пар киез итек һәм акча белән бүләкләделәр.

Бу көннәрдә без барыбыз да ремонт белән мәшгуль, җәен бер семьядай тату эшләгән команда членнары кышын да гел бергә эшлибез, шатлык-кайгыларны бергә уртаклашып яшибез.

Хәер, бер кешегә кимегәнбез икән. Яңа ел алдыннан гына яраткан җырчыбыз матрос Зәкия көтмәгәндә авылына кайтып китәргә булды. Шәһәрдә кемнәндер кияү егетенең фронттан яраланып кайтуын ишетү белән, кызый тәмам иләсләнде: «Ул минем монда икәнемне белми торгандыр, юкса килеп җитәр иде. Бәлкем, минем ярдәмемә мохтаҗдыр»,– дип, күз яшьләре белән зинһарлап китәргә рөхсәт сорый башлады.

Дөрестән дә, үлеп яраткан кияү егетеңнең сугыштан кайтып төшүе – бу сиңа уен эш түгел бит. Мин шулай уйладым һәм бичара кызның хәленә кердем, капитанны да шуңа күндердем. Затонда эшче кулларга зур кытлык булса да, Зәкия белән саубуллашырга туры килде.

Быел затонда шундый хәл – һәр команда үз судносын үз көче белән ремонтларга тиеш. Завод цехларына ышаныч аз: анда квалификацияле эшчеләр җитми, кирәкле материал һәм инструмент яклары да бик кысан. Ә пароход ремонтлау – безнең кызларның күпчелеге өчен бөтенләй таныш булмаган яңа шөгыль бит. Турыдан-туры ремонтка керешкәнче, башта кызларны тиешенчә инструмент тотарга өйрәтергә, һәрнәрсәне бәйнә-бәйнә аңлатырга, эшләп күрсәтергә туры килде. Хәзер инде бераз рәтләндек шикелле, эш темпы көннән-көн сизелерлек тизләнә бара. Безнең өчен хәзер иң мөһиме – машина; якын арада цехта поршень боҗраларын кырдырып бирсәләр, калган эшләрне ничек тә үзебез ерып чыгар идек.

Син, зинһар, минем хакта кыенлыклардан зарланып яза дип уйлый күрмә. Юк, һич тә алай түгел, сине үзебезнең хәлләр белән таныштыруым гына. Ничек кенә авыр булса да, без монда чыдарбыз, фронт өчен кирәкнең һәммәсен дә эшләрбез. Бар ышаныч сездә, безнең уй-өметләр сезнең белән, анда сез нык тора күрегез... Тагын менә нәрсә, андагы хәлләр, сугышташ иптәшләрең турында син бушрак вакытларда мөмкин кадәр тулырак язарга тырыш. Без монда барыбыз да һәрчак фронт турындагы уйлар белән яшибез.

Әмма радио һәм газеталар бу көннәрне сезнең якларда фашист юлбасарларының бик тә яман котырынуын, Севастополь өчен сугышларның көннән-көн кыза баруын хәбәр итә. Бәгырькәем, син дә шул дәһшәтле ут астында йөрисең бит. Гәрчә хатларыңның берсендә: баштарак куркыныч иде, хәзер инде алай ук түгел, күнектем, дип язсаң да, мин бик борчылам. Син берүк анда гамьсезләнмә, алдыңны-артыңны карап йөр, яме.

Соңгы хатыңда син Кәбирнең хәлен сораштырып, киләсе җәйдә аны үзем белән пароходка алып чыкмаска, синең әниеңдә калдырырга әйтеп язгансың. Ярар, анысын яз җитәрәк хәл итәрбез. Ә малайга күз тимәсен, әйбәт кенә үсеп килә. Бар белгәне сугыш уены, фашистны тукмау. Мин кулга кәгазь, каләм алып утырсам, шундук: «Нурис абыйга хат язабыз», – дип, ул да килеп сызгаларга тотына. Сиңа хат язып утыруымны күреп, әнә улым тагын үзалдына: «Нурис абый, тизрәк фашистны җиң дә миңа тасмалы бескозырка алып кайт», – дип сөйләнә-сөйләнә нидер сызгалап утыра. Үз хатым белән бергә менә аның кәгазен дә конвертка салып җибәрәм.

Хуш, сау бул, бәгырькәем. Гомерлеккә синең

*Мәрьямең*

***Күз нурым,*** ай буе хатың килми торуы бик авыр булды, тәмам зарыктырды. Аптырагач, берәр хәбәрең юкмы дип, Казанга әниеңә дә шылтыраткан идем. Әмма аңа да берни килмәгән, ул бичараны да, нәкъ минем кебек, билгесезлек борчый булып чыкты.

Менә бүген хатыңны алып укыгач, эчкә җылы керде, исән-сау икәнлегеңне белеп бик сөендем, дөнья яктырып китте. Шундый ук хатны, шәт, әниеңә дә салгансыңдыр, аны да тынычландыргансыңдыр бит? Әгәр язмаган булсаң, тизрәк язып сал. Үз тарафымнан мин дә бүген үк хәбәр итәрмен.

Хатыңда ачык итеп язмасаң да, сизәм, син анда каты яралангансың бугай. Югыйсә ай буе хәбәр бирми тормас идең... Ярар, анысы инде үткән хәл, азагы хәерле булсын. Госпитальдән соң атна-ун көнлек ял бирерләр кук язгансың. Менә монысы бигрәк тә шәп булыр иде.

Шатлыгым йөземә чыккандыр, күрәсең, эштә кызлар бик тиз сизеп алдылар, минем өчен алар да куандылар. Ә нечкә күңелле җырчы матросыбыз Зәкия, көндез ашханәдән чыкканда, сер әйтергә теләгәндәй, миңа якынрак елышты: «Мәрьям апай, әгәр ачуланмасагыз, сезгә бер соравым бар, – диде. – Зинһар, әйтегез әле, ул дустыгыз турылыклы кешеме, сез аңа чын күңелдән ышанасызмы?.. Урынсыз сорау биргән булсам, гафу итегез, берни дә әйтмәгез...»

Хәтерлисеңдер, элекке хатларымның берсендә ул кызның кияү егете янына авылга кайтып китүе турында язган идем бит. Менә шул кыз бездән киткәннең иртәгесен, буранлы караңгы кичтә, бик туңган хәлдә туп-туры минем бүлмәгә кайтып керде. Бөтен өс-башына, каш-керфекләренә апак булып кар сырышкан иде, көчкә таныдым үзен. Марина Михайловна белән мескен кызның күшеккән кулларын спирт белән удык, кайнар аш ашаттык, тир чыкканчы мәтрүшкәле чәй эчертеп, җылы урынга яткырдык, һәм суык тиеп авырудан әнә шулай көчкә саклап калдык үзен. Ниләр булганын мескен кыз иртәгесен чәйдән соң гына сөйләп бирә алды.

– Мәрьям апай, җаным, бу авыр хәлне мин бары тик сезгә генә, бертуган апам кебек якын күргәнгә генә сөйлим,– дип башлап китте ул, өстәл янында икебез генә калгач.– Юлда кайтып барганда ук әле, ниндидер күңелсезлек буласын алдан сизенгәндәй, кинәт эчем поша башлады. Теге чакны пароходтан минем белән саубуллашмыйча китеп баруы да, шуннан бирле бер тапкыр хат җибәрмәве дә, сугыштан авылга кайтуын хәбәр итмәве, мине эзләмәве дә кинәт ничектер шикле тоелды, күңелемдә берсеннән-берсе караңгы, авыр уйлар уятты.

Шулай ут йотардай булып кайтып барганда, юлда атлы юлчы куып җитте үземне. Безнең авыл хатыны, ире фронтка киткәч, аның урынына почта ташучы булып калган Хәдичә түти икән. Үткән җәйдән бирле авылыбыз кешесен күргәнем юк бит, чанасына бик рәхәтләнеп менеп утырдым. Күп сүзлелеге белән дан тоткан Хәдичә түти шундук авыл хәлләрен сөйләп китте. Фронттан яраланып кайтучылар арасында ул минем кияү егетем Зәкине дә телгә алды һәм аның кибетче Хәлимә белән буталуын әйтүе – әрнүле йөрәгемә очлы ук булып кадалды.

Без авылга кичкырын, ут алган вакытта кайтып кердек. Яшерен-батырын түгел, дөресен әйтим, ул чакны мин аны-моны уйлап эш итәрлек хәлдә түгел идем, тилебәрән орлыгы ашаган кебек, тәмам ярсыган идем. Кибетче Хәлимә өе турына җиткәч, түзмәдем, почтальонга рәхмәт әйттем дә, чанадан төшеп калдым. Атылып-бәрелеп өенә барып керсәм, болар икесе тәмләп кенә түр сәке өстендә сыйланып утыралар. Хәдичәсе, мине күрүгә, буш шешә янындагы аракылы ике стаканның берсен тиз генә самовар артына алып куйды, яртылай ачык изүе аша күренеп торган күкрәген каплый-каплый, почмак якка кереп китте. Тегесе – мин сагынып, ярдәмгә мохтаҗдыр дип кайгыртып кайткан кияү егетем – бурлат кебек кызарган, маңгаена, битләренә бөрчек-бөрчек тир бәреп чыккан.

Хәрби флотта хезмәт иткән булса кирәк, өстендә буй-буй сызыклы матрос күлмәге, җирән мыек җибәргән. Мине күргәч, күзенә ышанмагандай, текәлеп катты бу. Аннары күзләрен челт-челт итеп, почмак якка каушаулы карангалап: «И синмени әле бу... Әйдә, табынга рәхим ит, – диде. – Хәдичә киң күңелле ул, әйдә утыр, утыр... Әни шәһәргә, түтиләр янына күчеп киткән булгач, мин менә шушында тукталдым әле...»

Әйткәнемчә, минем хәтәр ярсып, бу вәгъдәсезне әллә нишләтердәй булып керүем иде. Ә аның почмак якка шикле карана-карана боргалануын күргәч, үземдә җирәнү хисе туды, үпкә сүзләр әйтеп, үземне кимсетүдән көчкә тыелып калдым һәм ләм-мим сүз катмыйча чыгып киттем.

Шуннан соң инде, төрле гайбәтләргә азык биреп, авылда кеше-кара күзенә күренмәдем. Мин ятимне кече яшьтән карап үстергән әбиемдә төн кундым да иртән таң белән кире юлга чыктым... Әле кичтән үк, кая китәргә дип борчылып, пароходтан китүемә үкенеп, йоклый алмыйча озак яттым. Әмма йокыга киткәч, төн буе төшемдә сезне, пароходны күрдем, мине кире кайтырга чакыргандай, хәтта сузып-сузып аның гудок кычкыртканын ишеттем... Шул гудок мине кире монда кайтарды... Мин җилбәзәкне тагын үз гаиләгезгә алуыгызны сорыйм. Минем бүтән барыр җирем юк, сезнең белән бергә яшәргә, бергә эшләргә телим.

...Зәкия ачынып сөйләгән бу аяныч вакыйганы мин дулкынланып тыңладым һәм, кулымнан килгәнчә, ул кызны ничек тә юатырга, хәленә керергә тырыштым. Марина Михайловна белән киңәшкәннән соң, әлеге күңелсез хәлне бүтән кеше-карага сиздермәскә сүз куешып, Зәкияне без элекке эшенә алдык һәм, тулай торакта урын бушаганчы, вакытлы рәвештә боцман Мәрфуга квартирасына урнаштырдык. Ә мин әле һаман тынычлана алмыйм, Зәкияне күргән саен аның еш кабатлый торган бер сагышлы җыры исемә төшә:

Яр сөюне чыгарганнар
Йөзне саргайтыр өчен...

Тормышта әнә шундый газаплы, бәхетсез мәхәббәт тә була икән.

Үзем турында сүз чыккач, тагын шуны да хәбәр итим: мин, ниһаять, Хөснулладан рәсми рәвештә аерылдым, хәзер аның белән һичнинди багланышым юк. Ул, Кәбирне үзенә калдыруны дәгъвалап, минем сиңа булган якынлыкны гаепләп, бала тәрбияләргә мораль хокукы юк дип, судлашып та караган иде. Әмма барыбер пычагым да чыгара алмады, тагын бер тапкыр үзенең кара эчле икәнлеген, күңел биздергеч хөсетлеген генә күрсәтте.

Ярар, хәзергә хуш, сөеклем. Тизрәк кайтып җитүеңне көтеп

*Мәрьямең.*

*P.S.* Син, мөгаен, юлдан туры Казанга, башта әниең янына кайтырсыңдыр инде. Шулай да, җанкисәгем, анда артык озак юанмаска, бераз безгә дә вакыт калдырырга тырыш. Мин моны көнләшү-күпсенүдән әйтүем түгел, үзеңне бик юксынып, бик күрәсем килүдән искәртүем генә.

*Мәрьям*

***Нурис җаным,*** язгы Кама буйларыннан кайнар сәламнәремне юллыйм сиңа.

Соңгы хатыңда Казанны сагынам, Идел, Кама язын, шаулап боз киткәнен, пароходларның гудок кычкырта-кычкырта затон белән саубуллашып беренче рейска чыгуларын, елгачыларның тантаналы-эшчән йөзләрен күрәсем килә, дип язгансың.

Әйе, яз җитте, назлы җылы җилләре, көмеш тамчылары белән бар дөньяны җанландырып, күңелләрдә якты өмет-хыяллар уятып, елның иң матур фасылы – кояшлы яз керде. Безнең ише елга халкы, билгеле инде, аны аеруча шатланып каршылый, навигация ачылу үзе зур бәйрәмгә әверелә бит. Мондый чакны хәтта, гадәттә, караңгы чырайлы, сүлпән кешеләр дә җанланып, ачылып китә, карт агайларның йөзенә яшәү шатлыгы чыга.

Әйе, кышның гомере бетте. Яз кояшы, аның кар-бозларын эретеп, тау битләрен ача, гөрләвекләр чаптыра, инеш-ерганакларда йөгерек ташкыннар уята, җылы яклардан чакырып кайтарган купшы сыерчыкларын сайрата.

Безнең Урта Идел, Кама буйларында язгы уяну әсәрләндергеч мәһабәт була, үзенең шифалы сулышы, дәртле гөрелтесе белән күңелләрне җилкетә бит. Әле кайчан гына елга үзенең авыр тәкъдиренә буйсынгандай, калын боз астыннан тын гына ага сыман иде. Дөнья мәшәкатьләре белән мин елганың кышкы йокыдан уянуын рәтләп күрми дә калганмын. Бүген ул, кинәт ярсыгандай, калын боз тауларын бер-берсенә бәрә-суга көньякка сөрә башлады, биек ярларыннан ташып чыгып, киң тугайларга җәелде. Безнең затон да су белән тулды; түбәндә тау астында кышлаган йөзләрчә пароход, дебаркадер, баржалар, елга төбеннән үсеп чыккандай, яр өстендәге завод корпуслары, безнең урам йортлары белән бертигез биеклеккә күтәрелеп, үзләре бер йөзмә шәһәрчеккә охшап калды. Аларның мачталары очында елгачыны ерак юлларга чакырып кызыл флаглар җилферди, әле анда, әле монда күңелле гудок тавышлары яңгырый.

Хәзер бөтен затон, кырмыска оясы кебек, мәш килә. Завод цехларында, пароход, баржаларда соңгы эшләр төгәлләнә, һәркайда флотны эксплуатациягә тапшыру бара. Безнең «Ургыл»ны да бүген кабул иттеләр. Тәҗрибәле карт капитаннардан, инженер механиклардан, санитар врач һәм пожарниклардан торган бу авторитетлы комиссия бөтен пароходны җентекле тикшереп, машинаны эшләтеп караганнан соң, ремонт сыйфатын бертавыштан «яхшы»га бәяләде һәм тырыш хезмәтебез өчен командага рәхмәт белдерде. Иртәгә барыбыз да кышкы квартиралардан пароходка күчеп, каюталарда тора башлыйбыз һәм менә-менә боз китеп бетү белән беренче рейска чыгабыз.

Навигациягә әзерләнгәндә башта бөтен командабыз үзгәрешсез калыр, быел да былтыргы составта эшләрбез кебек иде. Әмма иң соңгы чиктә һич уйламаган-көтмәгән яктан күңелсез хәл килеп чыкты – врачлар, командага смотр үткәргәндә, капитаныбыз Трофим Григорьевичның «тавык күзе» чире белән авыруын, караңгыда начар күрүен белделәр, шул сәбәпле аңа пароходта эшләргә рөхсәт бирмәделәр. Вакытлы рәвештә капитан вазифасын миңа йөкләделәр. Командада тагын бер үзгәреш – матрос Зәкияне үзе соравы буенча машина бүлегенә кочегар итеп күчердек. Механик ярдәмчесе, бөтен пароходта бердәнбер егет Исәнбаев, аны үз вахтасына алып, эшкә өйрәтергә теләк белдерде.

Менә шулай мең мәшәкать, тынгысыз ыгы-зыгы арасында көн артыннан көн үтә, баш кашырга да вакыт калмый.

Нурискәем, син бездә торып киткәннән соң, мин, гомумән, ничектер үзгәреп, яңа энергия өстәлгәндәй, ару-талуны, төшенкелеккә бирелүне белми торган булып әвереләдем әле. Син һәрчак кү-

ңелемдә минем. Вакыт-вакыт хәтта китмәгәнсең дә, янымдадырсың кебек хис итәм, синең белән бергә үткәргән ләззәтле дөньяда яшим. Чын мәхәббәтнең ләззәтен, сөю-сөелүнең әйтеп бетергесез зур бәхет икәнлеген бөтен җаным-тәнем белән хәзер генә белдем. Без бер-беребез өчен яратылган бәхетле җаннар бит...

Шатлыкны кеше күзеннән яшереп булмый, дип әйтәләр. Миндә дә шундый хәл, эчемә сыймаган куанычым йөземә чыккан, күрәсең. Хезмәттәшләрем, якын танышларым, бу шатлыкның чыганагын сизгәндәй, очрашканда дусларча кызыксыну белән синең хакта сораштыралар, сиңа сәлам әйтәләр.

Син әниеңә мине күккә чөеп, бик мактап сөйләгәнсең, ахры, миңа язган хатыннан шуны сиздем. Ничектер шулай килеп чыкты, без аның белән бер-беребезне күреп белешкәнче үк хат аша танышып, үз кеше булып, дуслашып өлгердек инде. Синнән хат озаграк килми торса, берәр хәбәрхәтер юкмы дип, миңа борчылып яза. Син аңа карата игътибарлырак булырга, озак-озак көттереп зарыктырмыйча, берничә сүз генә булса да, мөмкин кадәр ешрак язарга тырыш. Ана күңеле шуңа да бик шатлана ул.

Монда булган чакны Кәбир турында сөйләшкәндә, син миңа быел аны үзем белән пароходта йөртмәскә, җәйгә әниең янында калдырырга киңәш биргән идең бит. Уйлана торгач, күрәм, син әйткәнчә эшләргә туры киләчәк, иң яхшысы шул булыр.

Күптән түгел улым Кәбир белән берничә көнгә Казанга әти янына кайткан чакны, без сезгә дә кердек. Разия апайга рәхмәт, безне бик җылы каршылады. Очлы күзле Кәбир, стенада синең фоторәсемеңне күрүгә, үзеңне очраткандай, шатланып кычкырып җибәрде:

– Әнием, карале, бу безнең Нурис абый ич... Чыннан да шул үзе, ул монда ничек эләкте икән?.. Ә менә монысы... – дип, аннары әтиең портреты каршында бер мәлгә аптырап калды. – Монысы мыеклы моряк, ул да Нурис абыйга охшаган.

Разия апайның күңеле нечкәреп китте бугай, күзләре яшьләнде. Кара син аны, күрү белән таныды, балакаем. Нурислам абыйсын ярата икән, дип сөйләнә-сөйләнә Кәбирне башыннан сыйпап сөйде. Ул кичне без синең хакта сөйләшеп, әтиеңне искә алып төн уртасына кадәр утырдык.

Тиздән минем җәй буена пароходта китеп баруым турында сүз чыккач, ул инде күптән уйлап куйгандай: «Теләсәң-теләмәсәң дә, Мәрьям җаным, Кәбирне бездә калдырырга туры килер, – диде. – Мондый хәтәр вакытта баланы үзең белән пароходта йөртү ярамас. Бу – бер минем сүз генә түгел, киткән чакта Нурислам да шуны әйтеп калдырган иде».

Аннары Разия апай, безне синең бүлмәңә алып кереп, «Ваня – коммунист» корабының син ясаган моделен күрсәтте. Идел-Кама картасында калын кызыл сызык белән шул кораб үткән сугыш юлын күрсәткәнсең, Пьяный Бор янында комиссар Николай Маркин белән бергә яуда әтиең һәлак булган елга култыгында һәйкәл-обелиск галәмәте ясап, траурлы кара рам эченә «1918 елның 1 октябре» дип язып куйгансың. Шул ук стенада кара тасмасына көмеш буяу белән «Юнгштурм» дип язылган бескозырка эленеп тора иде. Разия апай, ул бескозырканы кечкенә малай вакытта син яратып кия идең, дип әйтте һәм аны Кәбиргә бүләк итеп бик сөендерде.

Китап тулы шкафыңны караганда, Разия апай, бер тартмадан алып: «Менә монда Нурисламның миңа язган хатлары саклана, эчем пошкан чакларда мин аларны еш кына алып укыйм, – диде. – Ә менә болары – тасма белән аркылы-торкылы бәйләнгән бу төргәктә аңа фронтка килгән хатлар саклана. Нурислам аларны үзе белән алып кайтты һәм югалтмыйча сакларга кушты».

Шулчак мин өске конвертның адресы минем кулым белән язылган булуын күрдем һәм ул төргәктә барысы да минем хатлар икәнлеген шәйләп алдым. Шатлыклы дулкынланудан йөземә кызыллык йөгергәнен тойдым.

Көнозын аяк өсте йөреп, Кәбир тәмам изрәгән икән. Разия апай белән мин синең бүлмәдә чөкердәшеп утырган арада, ул бичаракай түр якта кырын яткан җиреннән эреп йокыга киткән. Аны уятмас өчен ул төнне без сездә куна калдык. Иртәгесен дә көн буе бергә булдык. Разия апай кайчандыр син тыңлаган маҗаралы әкиятләрне, «Сак-Сок» бәетен, Тукай шигырьләрен сөйләде. Кәбир аларны бик яратып тыңлады, кайберләрен кабат-кабат сөйләтте һәм шул кыска гына вакыт эчендә, Разия апайга ияләшеп, күптән белгән әбиседәй, аны үз итеп өлгерде. Шуңа күрә ул мин саубуллашып китеп барганда да бер дә көйсезләнмәде, Разия апай белән бергә миңа тәрәзәдән кул болгап озатып калды.

И, сүземнең иң кирәген онытa язганмын, әниең дә шуны әйтергә кушкан иде ләбаса: син анда, зинһар, сакланыбрак йөр, ялгыш авыр күтәреп-нитеп әле ныгып җитмәгән иңбашыңны кузгата күрмә.

Сиңа өчебез исеменнән дә хәерле теләкләр юллап һәм үбеп

*Мәрьямең.*

***Күз алмам, син нихәл анда, исәнлек-саулыкмы?***

Мин монда капитан булырга ризалык биреп ашыктым бугай, аның моңарчы ничектер күреп җиткермәгән кыенлыклары, тынгысыз мәшәкатьләре бик күп, җаваплылыгы зур икән. Элек, ярдәмче чакны, минем бөтен вазифам тиешле сәгатьләрдә вахта торудан, план үтәлеше, тоткан ягулыкка исәп-хисап ясау, командага эш хакы өләшүдән гыйбарәт иде, калган вакытны үз иркемдә, тыныч күңел белән рәхәтләнеп ял итә идем. Хәзер капитан булгач, тәүлек буе вахта торам кебек: хәтта каютада ял иткән сәгатьләрдә дә пароходның һәр гудогына колак салып, кыен перекатларны үткәндә корпус астында су сайлыгын тоеп борчылып барам. Трюмнарда товар ящигы ватылса да, пароход расписаниедән соңга калса да, берәр холыксыз пассажир ризасызлык белдерсә дә – барысы өчен дә капитан җаваплы бит. Шуның өстенә ярдәмчем Мидхәт агай – укый-яза белми торган бер карт лоцман, аның өчен бөтен контора, исәп-хисап эшен үземә башкарырга туры килә. Күрер күзгә баһадир кебек зур таза гәүдәле агай булса да, үзе бик тә кабаланучан, юлда аз гына катлаулы хәл килеп чыкса, шундук аны-моны уйлау-шәйләү сәләтен югалта, караул... харап булабыз, дип акырып, бөтен пароходта паника куптара. Аның каравы хатыны Гарифә түти молодец, гомер буе ире белән пароходта йөри-йөри остарып беткән, чын ирләрчә батыр йөрәкле хатын, эшне дә яхшы белә. Ире вахта торганда, рубкада ыгы-зыгы чыкса, ул инде миннән алда менеп җиткән, тиешле чараны күрә башлаган була. Гаҗәп хәл, аның алдында карт лоцман үзе дә бик тиз тынычлана һәм, урынсызга каударлануы өчен уңайсызлангандай, мыек астыннан үзалдына нидер мыгырдана башлый. Шуңа күрә безнең телгә чая штурвалчы кыз Җәмилә үзе юкта Мидхәт агайны Мыеклы түти дип йөртә... Берни кылып булмый, нужа кушкач, әнә шундый ярдәмче белән дә эшләргә туры килә.

Быел без затоннан чыкканнан бирле хәзергә һаман бер линиядә – Казан белән Уфа арасында йөри бирәбез. Минем өчен моның уңай ягы шунда, атна саен Казанда булганда синең хатларыңны алырга, улым Кәбир белән күрешергә мөмкинлек бар. «Ургыл» пристаньга якынайганда, Разия апай белән Кәбир инде причалда булалар һәм безне кул болгап каршы алалар. Кәбир мине капитан күперчегендә күрүгә, пароход туктаганны да көтмәстән, балаларча түземсезлек белән кулындагы конвертын селки-селки: «Әнием!.. Менә сиңа хат. Нурис абыйдан килгән...» – дип, бар көченә кычкырып причалдагы халыкны көлдерә.

Монда безнең хәлләргә килгәндә, болай ярыйсы гына эшлибез, зарланырга урын юк шикелле. Июнь планын арттырып үтәдек, расписаниедән чыккан юк. Быел кызларны да, былтыргы кебек, адым саен өйрәтеп торасы юк, барысы да үз эшен белеп башкара. Хәзер алар Иделне яр читеннән беренче мәртәбә күргән кешедәй хәйран калучы кыюсыз яшүсмерләр түгел, ә эштә чыныккан, Иделгә ихлас күңелдән гашыйк, хезмәтчел елгачы булар ак үсеп киләләр. Пароходны туган-үскән өйләредәй якын итәләр, шәһәргә чыккан вакытларда аның җилкендергеч-яңгырашлы сузып кычкыртуын ишетү белән:

– Әнә безне «Ургыл» чакыра, тизрәк кайтырга кирәк,–дип, мең тавыш арасыннан танып, шундук пароходка ашыгалар.

Хәер, бар эш тә шома гына бара дип әйтү дә дөрес булмас, ара-тирә команда тормышында киртәгә сыймаган күңелсез хәлләр дә булгалый. Минем белән бергә вахта торучы штурвалчы кызыбыз Җәмилә Казаннан алып килгән төрле чүпрәк-чапракларны он, ярма кебек азык-төлеккә алыштырып маташканда, беркөн Бирски пристаненда милициягә эләкте. Үз җаваплылыгыма алып, кызны судка эләгүдән көчкә коткарып калдым. Соңынтын пароходта ныклап сөйләшкәндә, бичара кызый үзенең гаебен аңлады шикелле. Бу алама эшен ул, өйдә ачлы-туклы яшәүче ятим энекәшләремә бераз ярдәм итәргә теләгән идем, дип аңлатты һәм бүтән һичкайчан алай эшләмәскә сүз бирде.

Соңгы вакытта мине тагын теге җырчы кочегар кыз Зәкия борчый башлады. Күрәм, кияү егетенең хыянәтен авыр кичерә бичаракай. Ишкәксез көймәгә эләккән кеше кебек, нишләргә белми, күз алдында ябыга.

Ниһаять, түзмәдем, Зәкияне үзен генә очраткан бер арада:

– Син, сеңелкәем, ул өстерәлчеккә бик мөкиббән булма, артык газапланма... Алай җебеп төшәргә ярамый, кулга алырга тырыш үзеңне,– дип, үгет биреп карадым.

– И Мәрьям апай җаным, ярамаганын үзем дә беләм,– диде бичара, күз яшьләренә буылып. – Нишлим соң, онытып булмый бит... Күңел ярамыйга карамый, һаман үзенекен итә, йөрәк яна.

Моңа каршы мин ни әйтергә белмичә аптырап калдым һәм мондый хәлдә акыл өйрәтеп, үгетнәсихәт белән генә ярдәм итеп булмавын аңладым. Мәхәббәт тоташ шатлык кына түгел шул. Бәхетсез мәхәббәт әнә нишләтә, дәвалап булмый торган авыру кебек, кешене саргайтып киптерә, бөтен тормышын агулый. Җан яраткан, күңел тарткан яр бер генә була ул дип, тикмәгә җырламыйлар, күрәсең.

Менә яза торгач, кызып китеп, үзебезнең хәлләр турында тулы бер отчет килеп чыкты бугай. Син үзең хатларыңда эшең, тормышың, иптәш кызларың хакында күбрәк яз, барысын да беләсем килә, дип әйткәнсең бит. Әгәр бу вак-төякләрне тутырып бик арытсам, син, зинһар, гафу ит.

Чү, сиңа әйтергә тагын бер хәбәрем бар ич. Үткән рейстан соң Казанда торган чакны, елгачылар клубында пристаньга Дәүләт оборона комитеты байрагын тапшыруга багышланган тантаналы җыелыш булды. Анда без дә катнаштык. Җәй буе эштән башы чыкмаган безнең кызлар өчен үзенә күрә бер бәйрәм сыман күңелле вакыйга булды ул. Кичәнең рәсми өлешеннән һәм концерттан соң, танцылар башланып китте. Госпитальдән савыгып чыккан яшь командирлар, сугышчылар безнең кызларны күп тапкырлар биергә чакырдылар. Шул арада кайбер җитезрәкләре хәтта хат язышырга вәгъдәләшеп, адреслар алмашырга да өлгерде шикелле.

Клубның буфет бүлмәсендә хезмәт алдынгылары хөрмәтенә кечерәк кенә чәй мәҗлесе әзерләгәннәр иде. Безнең пароходтан профорг Мәрфуга белән мине дә дәштеләр. Хөснулла да шунда, тәэминат начальнигы буларак, чәй мәҗлесен оештыручы шул икән. Өстендә өр-яңа зәңгәрсу бостон китель, җиңнәрендә сары укалы нашивка җемелди. Идарәдән килгән начальникларны зур тырышлык белән сыйлаганын күрсәң, исләрең китәр инде. Тәэминат эше килешкән бугай, күзгә күренеп симергән,ияк аслары сөтләч сыер җилене кебек салына башлаган. Берничә тост күтәргәннән соң, битләре кызарды, чигә тамырлары бүртеп чыкты. Башта игътибар итмәгән кебек булса да, азактан таралышырга кузгалганда, бу мине бер читкәрәк алып китте дә:

– Карале, без бала-чага түгел, – диде. – Болай киреле-мырлы йөрүдә ни мәгънә, безнең уртак улыбыз бар бит. Давай, тагын бергә тора башлыйк... – Мин тыңларга теләмичә китә башлагач, беләгемнән тотып өстәде: – Туктале, серьезно сөйләшкәндә алай чәпчемә әле... Нәрсәсенә исең китте шул Исламның?.. Син аны сөттән ак, судан пакь дип беләсеңме?! Аның мәхәббәт маҗараларын сөйләсәм, чынлап әгәр, чәчләрең үрә торыр...

– Тузга язмаганны сөйләмәгез! – дип, мин аны шундук кырт кистем. – Исергәнсез, юк белән саташасыз. Ул хакта миңа бүтән әйтәсе булмагыз.

Хөснулланың кызарып бүрткән битләре агарып китте, кашлары җимерелде. Әмма гадәти сабырлыгын җуймады, ярсып китмәде. Кеше-кара ишетүдән шикләнгәндәй, як-ягына тиз генә сагаюлы караш ташлап алды да әйтте:

– Ләкин белеп тор: үзем исән-сау вакытта мин барыбер законлы улымны әллә кемнәр кулына бирмәм... Мин моны болай гына калдырачак түгелмен.

Хәзер, авызым бер пешкәч, мин аның икейөзлелеген, явыз ниятле гайбәтче икәнлеген яхшы беләм, шунлыктан синең хактагы гайбәтенә аз гына да ышанмыйм.

Бу урында аның белән бәхәсләшү, ни дә булса исбат итү, аңлашу – мәгънәсезлек булыр иде. Мин бүтән берни әйтмичә, Мәрфуганы култыклап алдым да пароходка кайтып киттем.

Менә шундый хәлләр, дускаем. Беләм, ул сүзендә торачак, аңа хас зәһәр үҗәтлек белән этлек итәчәк. Ләкин мин аз гына да курыкмыйм, хаклыгыма иманым камил.

Ярар, ул хакта калып торсын әле, сиңа әйтергә мөһимрәк сүзем бар.

Колагыңа пышылдап кына: «Мин сине көннән-көн якынрак үз итәм, тирәнтенрәк сөям», – дип әйтәм һәм, ниһаять, сине табуыма, сине яратуыма шатланам.

Безнең кечерәк кенә китапханәбездә Александр Блокның бер томы бар. Сине бик юксынган минутларда шуны укырга яратам, ямансу уйларыма шуннан үземә аваздашлык табам. Бүген шунда: «...Только влюбленный имеет право на звание человека», – дигән сүзләрне укып уйга калдым. Беренче карашка сәеррәк тоелса да, асылда, бик дөрес әйтелгән бит. Мин моны үземнән беләм. Моңарчы мин кызыксыз, сырхау кеше кебек, сүлпән тормышта яшәгәнмен. Тик синең белән табышкач кына, Блок әйткәнчә, яшәү шатлыгын тоеп яши башладым, үземнең чын мәгънәсендә бәхетле кеше икәнемне сиздем. Еллар авыр, кайгы-хәсрәтле булуга карамастан, тормышның матурлыгын хәзер мин ачыграк күрәм, тиздән тагын кавышу хыяллары белән өметләнеп яшим.

Сине һәрчак юксынучы *Мәрьямең* дип белерсең.

***Сөеклем, бердәнберем***, менә икенче ай инде хат-хәбәрең юк. Сиңа ни булды? Бу билгесезлек безне авыр кайгыга салды, күңелдә борчылу көннән-көн арта бара.

Бу билгесезлеккә бүтән түзәр хәлебез калмады. Шушы хат белән бергә, хәлеңне хәбәр итүләрен сорап, командирыңа һәм икегез бергә фоторәсемгә төшкән хезмәттәш иптәшең Сурановка да язам. Чөнки әниең бик өзгәләнә, күз алдында бетешә, йөзенә карарга кызганыч.

Әлегә хәтле Уфа – Казан линиясендә эшләгәндә, атнага бер тапкыр булса да, мин аларны күрә, кулдан килгәнчә булышкалый идем. Соңгы вакытта, Иделнең түбәнге агымына йөри башлаганнан бирле, ул мөмкинлек тә кимеде, хәзер без Казанда элеккеге кебек еш булмыйбыз.

Бу көннәрдә Сталинградтагы хәлләрне, мөгаен, ишетеп беләсеңдер. Хәзер анда кыямәт көне: бөтен шәһәр, яр буендагы пристаньнар – барысы да ут, кара төтен эчендә, бомба, снарядлар өзлексез шартлаудан су өсте кайнап тора. Дөресен әйтим, беренче мәртәбә барып төшкәч, башта бик курыктык, янар тау авызына эләккән кебек булган идек.

Шул утлы гарасат эчендә безнең гаскәрләр батырларча сугыша, һәр сталинградчы: «Безгә Идел аръягында чигенергә җир юк!» – дип, дошманның коточкыч басымына бирелмичә каршы тора. Безнең елгачылар да шунда: ут яңгыры астында баржаларга, пароходларга, баркасларга төяп, Идел аша гаскәр һәм корал ташыйлар, причалларда янгын сүндерәләр, дошман уты астыннан яралы сугышчыларны алып чыгалар. Әмма шунысы гаҗәп, берсенең дә йөзендә курку-шүрләү галәмәте юк. Аларга карап, тиздән без дә кыюландык.

Хәер, беренче тапкыр барып төшкән көнне анда безгә озак булырга туры килмәде. Төнге караңгыда алып килгән солдатларны һәм йөкләрне бушатып бетерүгә, пароходны җыештырырга да бирмичә, шундук причал тулы каты яралыларны төяргә керештеләр... Инде яктырып, өскә бомбалар ява башланганда, без хәтәр зонадан чыгып өлгергән идек.

Шулчак безнең «Ургыл»ны күрсәң, чын мәгънәсендә йөзмә госпиталь дип әйтер идең. Бөтен каюталар, коридорлар, хәтта палуба һәм трюмнар да яралылар белән тулды. Озата баручы врач һәм медсестралар каты авыруларга ашыгыч ярдәм күрсәтергә кереште. Безнең сандружиначы кызлар да шунда: яралыларны карашалар, аш-су пешерүдә булышалар, каты яралылардан салдырылган канлы күлмәк-ыштаннарны юып киптерәләр; җиңе өзек эчке күлмәк, сыңар балаклы кальсоннарны күреп, күзләре мөлдерәмә яшь белән каплана. Эштән буш сәгатьләрдә үзем дә күбрәк яралылар арасында булам, каты авыруларның хәл-әхвәлләрен сорашам, юатырга, күңелләрен күтәрергә тырышам. Күпме харап булган яшь гомер, җимерелгән якты хыяллар... Үлем хәлендә ыңгырашып ятучы каты яралыларны, гомергә гарип калган яшь егетләрне күреп күңел тула, йөрәк сызлый.

Шундый күңелсез уйлар белән баш түнгән килеш коридор буйлап барганда күрәм: беренче класс салоны ишеге төбендә әлеге җырчы кызый Зәкия басып тора. Күзе тулы яшь, елый-елый шешенеп беткән, бөтен гәүдәсе дер-дер калтырый.

– Ни булды, – мин әйтәм, – ник елыйсың?

Рәтләп сүзен дә әйтә алмый бичара.

– Үлем хәлендә... Ә-әнә шунда алып кереп киттеләр... Мине кертмиләр... – дип үкси бу.

Кемне алып кергәннәр, кемгә ни булган? Белеп сөйлиме, саташамы? Һич аңлап булмый. Тик бераздан, кызны тынычландырып кабат сөйләткәннән соң гына, ниһаять, хәл ачыкланды. Зәкия бер командирга су эчергәндә, яралылар арасыннан кемдер аңа исеме белән «Зәкия» дип endәшкән кебек була. Иелеп караса, ни күрсен: идәндәге матрас өстендә газапланып яткан кызылармеец аның кияү егете Зәки икән, шул төшендә моның исемен әйтеп саташа икән. Күп кан югалтуданмы, бүтән сәбәптәнме, егет тәмам хәлсезләнгән, йөзенә үлем аклыгы кунган була.

Зәкия шундук врач янына йөгерә, медсестраны аякка бастыра. Яралыны тиз генә операция өстәленә салып, ашыгыч ярдәм күрсәтергә керешәләр. Вакытында күрсәтелгән ярдәм, шулай итеп, егетне үлемнән йолып кала.

Иртәгесен, ул йокыдан уянганда, кризис инде үткән була. Егет акрынлап тернәкләнә башлый, кем аркасында исән калуын белеп бик гаҗәпләнә, дулкынлана. Хәзер ул кәләшенә мең рәхмәтләр укый, бик үкенә, гафу итүен үтенә, диләр.

Мин еш кына шулай итәм: кайгылы уйлар белән ялгызым калмас өчен, юк эшне бар итеп дигәндәй, профорг Мәрфуганы дәштереп алып, икебез бергә вахталар арасында ярыш нәтиҗәсен тикшерәбез яки затонга кергәч башкарасы ремонт эшләрен ачыклый башлыйбыз. Мәрфуганың тырышлыгын, һәр эшне дәрт белән башкаруын, оптимистлыгын күреп, мин үзем дә ничектер җиңеләеп киткәндәй булам, күңелемдә ныклык тууын сизәм.

Шулай көннәрдән бер көнне команда арасында аның хакында, механик ярдәмчесе Исәнбаев белән чуала, егет аңа гашыйк булган, өйләнергә җыена икән, дип сөйләнә башладылар. Мин башта ышанмасам да, бер җае туры килгәндә, сүз ара сүз чыгып, аның үзеннән:

– Исәнбаев белән бик дус икәнсез, дөрес сүзме шул, әллә гайбәт кенәме? – дип сорадым.

– Аңа ник гаҗәпкә калдыгыз әле, дөрес булса, гөнаһ эшмени... – диде Мәрфуга, сүзне уенга борган сыман. – Сезнеңчә соң ничек, мин инде бер дә ир-ат күз салмаслык әбимени?!

– Юк, гайбәт итүдән түгел, дусларча якын күреп кызыксынуым гына... Исәнбаев бик төпле, акыллы егет.

– Якын күреп булса, мин дә дөресен әйтим... Исәнбаев әйбәт егет, мине үзенә кияүгә чыгарга соравы да хак. Турылыклы тормыш иптәше һәм балаларыма кайгыртучан әти булачагына да ыша-

нам. Шулай да мин отказ бирдем әле, яшьрәк кызлар табарсың дип әйттем. Сигез ел буе бергә торган иремне, ике улымның әтисен алай тиз генә оныта алмыйм, зинһар, үпкәләмә, дидем. Аннары үзегез дә күрәсез, хәзер андый эшләр белән маташа торган вакыт түгел. Киләчәктә, сугышлар бетеп, еллар тынычлангач, анда күз күрер әле.

Бу аңлашудан соң Мәрфугага ихтирамым тагын да артты, күнозын шуның тәэсирендә дулкынланып йөрдем... Тыштан кешегә сиздермәскә тырышсам да, мин үзем дә газаплы билгесезлек эчендә бит. Тизрәк Казанга кайтып җитеп, анда синнән килгән хатны алып укырга ашкынам.

Их, Нурискәем, үлеп сагынам үзеңне, тел белән әйтеп аңлата алмаслык өзгәләнгән вакытларым була. Әмма ничек тә түзәргә, сагышымны кешегә сиздермәскә тырышам. Бик үзәк өзелгән минутларда эчтән генә көйләп йөрим:

Бик сагындым, бәгырем,
Бик сагындым сине,
Әле дә ничек түзәм мин!

Хуш, сау бул, җанкисәгем,

*Мәрьямең.*

***Нурисым, йөрәк парәм, ни булды сиңа, кайда син?..***

Өченчекөн хатыңны күрергә өметләнеп Казанга кайтсам, миңа аяусыз авыр яңалык – сине хәбәрсез югалган дип әйтеп тирән кайгыга салдылар. Хәер, мин моны причалга килеп җиткәнче үк, Кәбир белән Разия апайның яр буенда канаты каерылган кош кебек нәүмиз кыяфәттә торуларын күрү белән үк ниндидер бәла барын сиздем һәм пароходны көч-хәл белән китереп туктаттым.

Разия апай күп елаудан тагын да бетешкән, аягында көчкә басып тора иде. Минем каютага керү белән, төптән киселгән тал чыбыгы кебек, диванга сыгылып төште һәм бераз хәл алгач кына, күз яшьләренә буыла-буыла әйтте:

– Нурислам харап булган, югалган... Ятим калдык ич...

Мин бу куркыныч хәбәрне башта бермәл аңыма сыйдыра алмый тордым, кинәт миңгерәүләнеп киттем. Ниһаять, аңыма барып җиткәч, йөрәгем алынды.

– Юк, юк, мөмкин түгел, ышанмыйм... – дип ачынып, бу хәбәрне кире кактым. – Беренчедән, хәбәрсез югалу – ул әле харап булу түгел. Аннары ничек, нинди шартларда югалуын тиешенчә белешергә, ачыкларга кирәк. Кайдан белдегез аны, кем әйтте?

Сораштыра торгач, бу кайгылы хәбәрне Хөснулла килеп әйткәнен белдем. Ә аңа сезнең уртак танышыгыз – фронтта синең белән бергә фоторәсемгә төшкән иптәшең Суранов язып җибәргән, имеш. Разия апай сүзләренә караганда, болай да авыр кайгылы бу хәбәрне Хөснулла тагын да шомландырып әйткән, дошман тылына разведкага барган җиреннән Нурислам үзе кайтырга теләмәгән дип, шик-шөбһә тарата башлаган. Хөсетле җаһил Хөснулланың тел төбе кая тартканын да, сәбәбен дә яхшы аңлыйм. Бер сүзенә дә ышанмыйм мин аның.

Хәер, Сурановтан хат алуы дөрес булуы да ихтимал. Тиздән аның безгә җибәргән хаты да килеп җитте. Әмма анда, Хөснулла әйткәнчә, сине гаепләү, шикләнү турында берни дә юк. Киресенчә, синең өчен якын дусларча бик борчылып, дошман тылына разведкага барганда эзәрлекләп килүче фрицларны тоткарлау өчен калган җиреннән кайтмады, дип көенеп язган. Хатның азагында, имза куйганнан соң, өстәп язылган тагын шундый юллар бар: «Безнең частьта Нурислам Алимҗанович үзенең каһарманлыгы һәм зирәклеге белән танылган офицер, бик авыр хәлләрдә дә югалып кала торганнардан түгел. Бу юлы да бер җаен табар, иртәме-соңмы табылыр, исән-сау кайтыр дип ышаныйк».

Мин үзем дә шулай уйлыйм, Разия апайны да ул өмет белән юатырга тырышам. Шулай да бик читен миңа, хәлемне үзем генә беләм. Кеше алдында әллә ни сиздермәсәм дә, эштән буш сәгатьләрдә каютада ялгыз башым тәкатьсез булам, албасты каплагандай, тын кысыла, күз яшьләрем төер булып тамагыма тыгыла. Өстәвенә Казанда кайгы-хәсрәткә баткан хәлдә калган Разия апайның газаплануын уйлап борчылам. Ул анда япа-ялгызы бит.

...Хәзер без, корал һәм гаскәриләр төяп, тагын Сталинградка барырга чыктык. Бер без генә түгел, анда каты сугышлар башланганнан бирле хәзер бөтен Идел, Кама флоты шул якка йөри.

Пароход пристаньда чакны, гадәттә, эш күп була, мәшәкать өстенә мәшәкать өстәлеп тора һәм шул ыгы-зыгы арасында кайгы-хәсрәт ничектер бераз басылган, арткы планга чигенгән сыман тоела. Ә менә хәзер, юлда барганда, эштән буш сәгатьләрдә каютада берьялгызым калу белән күңел тула, берсеннән-берсе сагышлы, авыр уйлар борчый башлый. Мондый авыр сәгатьләрдә мин дәфтәр, каләм алам да, көндәлек язгандай, уйларымны, башымнан кичкәннәрне синең белән уртаклашам, шуның белән юанам.

Без монда барыбыз да фронт турындагы уйлар, фронт хәбәрләре белән яшибез. Кызыл почмакка кергән һәркем иң әүвәл стенадагы картаны карарга керешә. Ул картада хәзер фронт сызыгы, Кара диңгез, Азов буйларыннан сузылып, Дон далалары аша үтә һәм, йөрәккә кадалган канлы хәнҗәр кебек, очлы башы белән Сталинград янында Идел ярына килеп терәлә. Сугыш язмышы шунда хәл ителгәнен без һәммәбез дә яхшы беләбез һәм җиңү хакына бөтен тырышлыгыбызны куеп эшлибез.

Шул ук вакытта пароход тормышы үз юлыннан бара бирә, ара-тирә һич уйламаган-көтмәгән күңелсез хәлләр дә булгалап тора. Беркөн шулай рубкада, вахтадашым Җәмилә (ул безнең артельчебез дә) штурвал көпчәге янында сүзсез генә күз яшьләрен агызып тора, тыны кысылгандай, әледән-әле авыр сулап куя. Мин борчылып сораштыра башлагач, бичаракай кычкырып еларга ук керешге һәм көч-хәл белән:

– Бәла-а... бәла... Азык-төлек карточкаларымны югалттым... – дип әйтә алды. – Теләсә нишләтегез, мин гаепле...

– Ярар, бик өзгәләнмә, – мин әйтәм, аны тынычландырырга теләп. – Илдә чыпчык ачтан үлми, диләр, син дә ризыксыз калмассың. Уртак казаннан бер кешегә генә ничек тә өлеш чыгарырбыз әле.

– Үз карточкам гына түгел шул, бөтен команданыкын югалттым. Барысын бергә җеп белән бәйләп куйган идем... Ух, бар икән күрәселәрем.

Аның ник шулай өзгәләнеп елавын мин шунда гына абайлап алдым һәм, хәзер инде ни әйтергә белмичә, үзем дә исәңгерәп калдым. Бөтен команданы азык-төлексез калдыру уен эшмени?! Ул талон-карточкаларсыз бер грамм азык алып булмаячак ич. Ай буе шултикле халыкка нәрсә ашатмак кирәк... Ул карточкаларны Җәмилә чыннан да югалтканмы, әллә берәр комсызлык-фәлән бармы – анысын кисеп әйтүе кыен әлегә. Акчага хирыслыгына, һәр тиенен саклап торуына карап кына кеше өстенә гаеп ташлап булмый бит.

Һәрхәлдә, башны ташка орып булмый, ай-вай килеп ачыргаланудан мәгънә юк. Бер әмәлен табарга, бу авыр хәлдән ничек тә чыгарга кирәк иде.

Профорг Мәрфуга белән уйлашканнан, киңәшкәннән соң, хәзергә бу хакта командага аны-моны әйтмәскә булдык. Ә үзебез икмәк карточкаларын югалту турында администрация һәм профсоюз оешмасы исеменнән рәсми акт төзеп, икебез дә кул куйдык, ышанычлырак күренсен өчен, аны пароход печате белән расладык. Аннары Саратовта туктап торган арада шул документ белән пристаньның тәэминат бүлегенә ярдәм сорап мөрәҗәгать иттек. Анда кеше җанлы агайлар утыралар икән, безне игътибар белән тыңладылар һәм, пароходчылык идарәсенә телефоннан шылтыратып сөйләштеләр дә, Казан пристане исәбенә безгә шундук икмәк һәм башка ашамлыклар карточкасы бирделәр. Башта бик катлаулы күренгән бу проблема әнә шулай хәл ителде.

...Нурлы йөзем, синең эзсез югалуыңны мин берничек тә аңыма сыйдыра алмыйм, һаман синең хакта уйлап йөрим. Бераз эштән бушап каютада үзем генә калгач, менә тагын хатымны дәвам итәм.

Бу юлы без Сталинград зонасына көндез барып төштек. Алып килгән хәрбиләрне һәм йөкләрне, шәһәрдән шактый читтә, Ахтуба тармагына кереп, сөзәк яр буена бушатырга приказ булды. Чөнки ике яруслы «Ургыл» белән көпә-көндез шәһәр пристанена барып туктау – күрәләтә ут астына керү булыр иде. Фашист козгыннары хәтта монда да ябырылып килеп җиттеләр. Зенитчыларга рәхмәт, дошманны якын да җибәрмәделәр.

Моннан караганда куе төтен белән капланган Сталинград үзе күренми диярлек, андагы көчле сугышлар авазы, өзлексез күк күкрәгәндәй, шомлы гөрелдәп тора, элсерәткеч эссе һавада әледән-әле шартлау дулкыннары яңгырап үтә. Йөкләрне бушатып бетергәннән соң, төнге караңгыда без дә шул ут эченә барып кердек.

Ярым җимерек дебаркадер каршында яр буе тулы яралы халык иде. Озын-озак маташыр чак түгел, вакытның һәр минуты кадерле. Килеп туктау белән тиз генә трапны рәтләдек тә шундук кешеләрне утырта башладык. Минем белән бергә пролетта басып торган эшелон начальнигы үз аяклары белән йөри алырлыкларның кергән берен өченче, дүртенче классларга, трюмнарга төшереп җибәрә торды; носилка белән күтәреп кертелгән һәм ашыгыч ярдәмгә мохтаҗ булган аеруча каты яралыларны медпунктка әверелгән салонга якынрак каюталарга, коридорларга урнаштырдык. Күп дигәндә, кырык-илле минут эчендә бөтен пароход халык белән шыгрым тулды. Хәтта аскы палуба, терраса һәм коридорларда атлап йөрер урын калмады диярлек.

Инде бар эш тәмамланып, чалкаларны ычкындырыр вакыт җиткәч кенә, каршы тау артыннан, ыжгырышып, немец самолетлары килеп чыкты һәм безнең причалга бомба яудырып үттеләр. Бәхеткә каршы, бомба безгә тимәде. Шулай да берсе янәшә генә төшеп без туктаган, инде болай да

ярым җимерек агач дебаркадерны чәлпәрәмә китерде, шартлау дулкыннары колак пәрдәсен чатнатып китереп бәрелдә дә бөтен пароход каты сикереп куйды... Һавага күтәрелгән ләмле су баганасы һәм такта кисәкләре безнең өскә ишелеп төште. Яшерен-батырын түгел, дөресен әйтим, бермәл исәңгерәп тордым, шартлау дулкынының җиленнән күперчек өстеннән чүт егылып төшмәдем. Бу коточкыч шартлау башкаларны да нык куркытты бугай, рубка астындагы террасада тәртипсез ыгы-зыгы, шау-шу кузгалды һәм кемдер җан ачысы белән:

– Караул, харап булдык... Батабыз... – дип, бар көченә кычкыра-кычкыра күперчеккә йөгереп менде. Бу – ярдәмчем Мидхәт агай иде. – Чынлап әйтәм, батабыз, су палубага җитте... Билләһи менә, үзем күрдем...

Курыкканга куш күренә, диләр. Янәшәдә генә бомба шартлаудан күтәрелгән су баганасы караңгыда куркак җанлы агайга батабыз кебек тоелган булса кирәк. Ул, дөрестән дә, бик курыккан, күзе-башы алакайган, бөтен гәүдәсе бизгәк тоткан кебек калтырый иде.

Штурвал көпчәге янында торучы Җәмилә аны әле генә танығандай, бермәл шаккатып карап торды да, ачу белән:

– Абзый кеше, син монда ялгыш менгәнсең... Батып харап буласың килмәсә, әнә шунда йөгер... – дип, ярга таба төртеп күрсәтте.

Куркудан әле һаман айнымаган мескен агай иронияле кинаяне аңламады, як-ягына тиз генә күз атып алды да:

– Әй, ашыгычлык белән ялгыш менгәнмен... – дип, траптан йөгереп төшеп тә китте.

– Күр инде бу җен өшкергән нәрсәне... – Җәмилә аның артыннан суганлы-борычлы сүзләр әйтеп, мыскыллы көлеп калды. – Бөтен пароходта карап торган ике ир зат бар иде, аларның да берсе куяннан туган булып чыкты... Моңа Мыеклы түти кушаматы да әрәм. Харап булдык, батабыз, имеш...

Әмма Сталинград гарасатын кичергән яралылар моңа әллә ни әһәмият бирмәделәр. Хәл ачыклану белән, пароходта тынычлык урнашты. Мин дә тиз генә үземне кулга алдым һәм шундук аска шылтыратып, тизрәк машинаны эшләтергә команда бирдем. Анда сөйләшү трубкасы янында механик Тамара Федоровна үзе тора икән. Гадәттә сабыр холыклы, һәрвакыт ягымлы механик, бу юлы танымаслык булып үзгәргән кырыс тавыш белән:

– Юк, машина менә хәзер генә эшләрлек түгел,– диде.– Безнең монда ут сүнде. Кайдадыр труба чатнады бугай, сызгырып пар чыга әнә. Авариянең кайда икәнлеген ачыклагач, нәтиҗәсен хәбәр итәрбез.

– Хәбәр итәрбез түгел... Мөмкин булмаса да, хәзер үк эшләтегез!.. Ишетәсезме, самолетлар кабат әйләнеп килгәнче, бу хәтәр упкыннан тизрәк ычкынырга кирәк. Юкса эш харап...

Югарыда ниләр барын, хәлнең ни дәрәҗәдә куркынычлыгын түбәндә эшләүче механиклар күрми бит. Тамара Федоровнаның машина эшләтерлек түгел дип сөйләнүе, мөгаен, шуннан булгандыр. Мондый хәтәр хәлдә машинаның чыннан да сафтан чыккан булуы да бик ихтимал. Әмма минем командам катгый яңгырады бугай. Моны сизеп алган механик:

– Аңлашылды! Мөмкин булмаса да, машинаны эшләтеп карармын... – дип, приказны кабатлады һәм пароходыбыз тиздән кузгалып та китте.

Ашыгыч кузгалып бик дөрес иткәнбез. Берничә минуттан фашист козгыннары өерләре белән тагын килеп чыктылар һәм әле генә «Ургыл» торган причалны котырынып бомбага тота башладылар. Тончыктыргыч ачы төтен катнаш шартлау дулкыннары безнең өстән өермәдәй ыжгырып үтте.

Шунда рубкада безнең белән булган эшелон начальнигы, соры мыеклы, җитез хәрәкәтчән яшь лейтенант, кемгәдер мактаган сыман:

– Менә бу безнеңчә, хәрбиләрчә булды. Аз гына соңарсак та, барыбыз да бетәсе икәнбез... – диде.

Шул кузгалудан без туктаусыз бар көчкә йөзеп бара бирдек. Дүрт йөздән артык яралы кеше тулы пароходны һәлакәттән саклап калу өчен, төн карасы астында сугыш зонасыннан мөмкин кадәр ераграк китеп өлгерергә кирәк. Чөнки дошман авиациясе Сталинград белән генә чикләнми, аннан шактый ерак пристаньнарны да еш кына бомбага тота, килү юлларына йөзмә миналар ташлый бит.

Агымга каршы бик акрын барабыз кебек тоелган минутларда, мин механикка шылтыратып, парны җәлләмәскә, машинаны катырак эшләтергә команда бирәм. Ә өлкән механик Тамара Федоровна, киресенчә, тизлекне акрынайта бара, әледән-әле шылтыратып, тизрәк якорьга туктарга, машинаны карарга рөхсәт сорый. Ниһаять, аның түземе бетә, таң алдыннан ул үзе рубкага күтәрелә һәм майлы кулларын сөртә-сөртә ишектән керүгә:

– Менә үзем менеп сөйләшергә мәҗбүр булдым, бүтән барыр хәл юк. Аңлагыз, хәзер үк туктарга кирәк, – ди ул, ялварулы таләп белән. – Причалда бомба шартлаганда какшаган болтларны ны-

гытмыйча бүтән барып булмый, югыйсә елга уртасында бөтенләй туктап калуыбыз ихтимал... Аннары корпуста кайдадыр тишек булса кирәк, машина бүлегенә кергән суны насос бушатып өлгерә алмый...

Шултикле ялварып сорамаса да, хәлнең мөшкеллеген хәзер инде мин үзем дә күрәм, бу эшне бүтән сузарга ярамаганлыгын да аңлыйм. Аннары без инде шактый ерак китеп өлгергән идек. Эшелон начальнигы лейтенант Габбасов белән киңәшкәннән соң, елганың сул ярындагы өянкеле яр эченә уелып кергән аулак култыкта якорь салып, какшаган механизмнарны бераз ныгытырга, корпус тишекләрен ямарга керештек.

Бераздан, инде эш бетте, хәзер кузгалып китәрбез дигәндә, бәланең тагы да хәтәррәге – пар казанынннан мич эченә су саркып керүе мәгълүм булды. Үзең беләсең, аны туктатыр өчен бөтен парны бушатып, казанны, мичне суытырга һәм тик шуннан соң гына ремонтлап, яңадан пар күтәрергә мөмкин. Моның өчен кимендә бер тәүлек вакыт кирәк бит.

Дөресен әйтим, нишләргә, нинди чара күрергә белмичә, барыбыз да хәвефкә төштек. Ә өлкән механигыбыз Тамара Федоровна, бермәл уйланып торганнан соң, үзенә хас тәвәккәллек белән форсунканы сүндерде, кранны ачып казандагы пар басымын бераз киметте. Аннары сырма фуфайка, чалбар, колакчынлы бүрек, бияләй киде дә, топка эченә кереп, торбаларны ремонтларга тотынды. Адәм түзгесез эсседә фуфайкасы көйри башлагач, без аны тартып чыгарып, өстенә су койдык. Соңгы мәртәбә кергәннән соң, инде эшен тәмамлап, мич эченнән чыкканда, аның киемнәре генә түгел, хәтта каш, керфекләре дә яртылаш өтелгән, борын очы, битләре пешкән иде.

Моны күреп таң калган эшелон начальнигы лейтенант Габбасов, тәэсирләнүен тыя алмыйча:

– Молодец, чын фронтовикларча булды бу!.. Мондый батыр йөрәкле механик белән ут та, су да берни түгел... – дип мактады һәм тиз генә Тамара Федоровнаны машина бүлегеннән күтәреп чыгып, врач карамагына тапшырды.

Ә без тиз генә пар басымын күтәрдек тә тагын юлга кузгалдык.

...Көндезге вахтадан соң бераз черем итеп алмакчы идем. Юк, күңел тыныч түгел. Күзгә йокы керми, башта берсеннән-берсе борчулы уйлар кайный. Менә торып утырып, сиңа язуымны дәвам итәм.

Хәзер без юлда, пароход тормышы акрынлап үз эзенә керде. Төшке аш вакытында, күрәм, үткән төнне генә Сталинград гарасатын кичергән кызлар инде тынычланганнар, берни булмагандай, өстәл янында шау-гөр килеп утыралар. Әнә ак халат, цилиндр кебек зур калпак кигән, колакларына асылташлы алка таккан мөлаем йөзле кок Ольга Казакова камбуз тәрәзәсе янына килеп баскан һәркемне, гадәтенчә, кунакчыл елмаеп каршылый һәм, тәлинкәгә аш салып биргәндә, әйбәт аппетит теләп яки дусларча берәр ягымлы шаян сүз әйтеп кала. Менә тәрәзә янына боцман Мәрфуга килеп баса. Ольга ишек ягына эзләнүле карап ала да:

– Чү, ник әле син бүген үзең генә, Исәнбаең кермәдемени?! – дип гаҗәпләнгән була. – Гадәттә, сез гел бергә ашыйсыз бит, шуннан гына әйтүем...

– И Ольга җаным, ул җәһәттән син үзең дә бер дә кимен куймыйсың лабаса, – диде Мәрфуга, шундук повар кызның үзен дә чеметтереп. – Бая монда су эчәргә кергән сары мыеклы яшь офицер белән бик мутланып торучы син түгел идеңме соң? Чынлап әгәр, шаклар каттым, кай арада лейтенантның башын әйләндереп өлгергәнсең. Менә бу чын сихерче икән, мин әйтәм, хәтта көнләшеп куйдым үзеңнән...

Барысы да, чәй эчүләреннән туктап, дәррәү көлеп алдылар. Бу көтелмәгән төрттерүдән каушап калган кокның болай да алсу битләре тагын да кызара төште.

...Тормыш дигәнең гаҗәп нәрсә, мең төрле вак-төяк мәшәкатьләре, кайгы-хәсрәтләре, мәхәббәт-нәфрәтләре белән үз юлыннан бара бирә. Мин моны кичә телгә алып үтелгән повар кыз Ольга Казаковага гаҗәпләнүдән әйтүем. Боцман Мәрфуганың ашханәдә төрттерүе нигезсез булмаган, сары мыеклы лейтенант Габбасов кыска гына вакыт эчендә дөрестән дә Ольга белән дуслашып, берберсенә гашыйк булганнар икән.

Бүген кичке аштан соң ремонт эшләренә затонга заявка язып утыра идем. Ишекне шакылдатып каютага Ольга белән әлеге лейтенант Габбасов килеп керделәр һәм, әйдә, син башла, әйдә, син әйт дигәндәй, бер-берсен әйдәкләп, хәрәкәтсез калдылар. Алар икесе дә шат йөзле һәм никтер каушаганнар иде. Сталинградта хәтәр ут астында яралыларны пароходка төяү вакытында кыю командалык иткән яшь лейтенант, ниһаять, кыяр-кыймас телгә килеп:

– Мәрьям Вәсилевна, зинһар, гафу итегез,– диде.– Б-без зур үтенеч белән... Сездән рөхсәт сорарга кердек...

Әле берни дә аңламыйча, мин үзем аптырап калдым:

– Нинди рөхсәт, ни өчен гафу итәргә?!

– Эш шуннан гыйбарәт, Ольга белән без бер-беребезне яратабыз,– диде Габбасов, кыюлана төшеп.– Ягъни без өйләнешергә булдык. Иртәгә Казанга кайткач, мин Оляны әниемә күрсәтергә, аның фатихасын сорарга алып барам.

– Әгәр бер-берегезне чынлап сөйсәгез, рәхим итеп өйләнешегез... Мин чит кеше, бу эштә сезгә каршы килергә хакым юк...

– Юк, Мәрьям Вәсилевна, сез чит кеше түгел... Ольганың әтисе-әнисе дә, якын туганнары да юк, ул кечкенәдән ятим, балалар йортында үскән бит. Ул әйтә, сез рөхсәт итсәгез генә миңа кияүгә чыгам, ди.

– Мәрьям Вәсилевна, мин сезне бертуган апам кебек якын күрәм, ихтирам итәм, – дип, Ольга үзе миңа килеп сыенды. – Сез дә миңа туган апам булыгыз, Даутка кияүгә чыгарга фатихагызны бирегез.

Ольганың мине туган апасыдай үз итүен сизеп килсәм дә, әти-әнисез үскәнен белми идем. Менә хәзер, шулай олылап, киңәш-фатиха сорап кергәч, ул миңа тагын да якынрак булып китте. Егете дә төпле, тәүфыйклы күренә, төскә-биткә дә чибәр генә. Үзләре инде аңлашкан, килешкән булгач, мин ни әйтим?

– Алайса, ярар, хәерле сәгатьтә булсын... Сезгә бәхетле тормыш телим,– дидем.– Шулай да күңелемдә булганны әйтим: сез бер-берегезне бик аз беләсез әле, ашыкмыйсызмы?.. Әнә шул борчый мине. Аннары күрәсез, елларның да бик авыр чагы.

– Ольга да шуны әйтә: бер-беребезне әле аз беләбез, вакыты да ул түгел, дөньялар иминләнгәнне көтик, ди... Әйдә шулай итик, мин ашыктырмыйм. Киләчәктә гомерлек яр булырга ныклап сүз куешсак, ярәшсәк, миңа шул җиткән.

– Дөресен әйтәсең, шулай эшләгез... Синең әниең дә хәер-фатиха биргәч, шунда кияү-кәләш булырсыз, күгәрченнәрем.

Менә шулай кодагый-капитан булып киттем мин.

Тагын шунысы гаҗәп: соңгы вакытта безгә фронтлардан күп хат килә башлады. Бөтенләй күрмәгән-белмәгән сугышчылар, командирлар эшебезне мактап, уңышлар теләп, кайберләре кызлар белән якыннан танышырга, хат алышырга теләп язалар. Башта бу хәлгә бераз аптырап калган идек. Соңыннан шул мәгълүм булды: безнең команда турында хәрби газетада очерк басылып чыккан, фронтовиклар безнең тормышны, эшебезне шуннан укып белгәннәр икән. Ул хатларга каршы безнең кызлар бик теләп җавап язалар, кайсыберләре арасында хәтта якын дуслык җепләре дә ялганып килә бугай.

***...Күз нурым***, синнән һаман һичнинди хәбәр юк, без һаман кайгы-хәсрәттә, сине көтеп яшибез.

Бу юлы Казанда торган көннәрем бик ачынулы һәм ыгы-ыгылы үтте. Миңа тагын җан тетрәткеч әшәкелек белән күзгә-күз очрашырга туры килде.

Рейстан кайтып кергәндә, синнән бернинди хат-хәбәр килмәве – беренче зур авырлык булды, болай да түнгән кайгылы башымны тәмам миңгерәүләндерде.

Аннан бераз айнырга өлгермәдем, авырткан башка тимер тарак дигәндәй, көтмәгәндә пароходка әлеге җан көеге Хөснулла Каюмов килеп керде. Үзе белән бергә конторадан ревизор һәм бер милиционер да алып килгән. Бик тыгыз чагыбыз иде, пристань белән бәйле эшләрне тиз генә бетереп, Аракчино затонына пар казанын чистартырга, Сталинградта ватылган механизмнарны ремонтларга, корпус тишекләрен яматырга барырга ашыга идек. Хөснулла безне туктатты, профорг Мәрфуга белән артельче Җәмиләне һәм мине ашыгыч рәвештә кызыл почмакка чакыртты да:

– Өчәү бергә бөтен команданың айлык паегын мыштым гына үзләштерүче шайка менә шушы инде, оят түгелме сезгә...– дип, безгә җикеренергә тотынды һәм портфеленнән бер кәгазь тартып чыгарды.– Азык-төлек карточкаларын югалткannar, янәсе. Шул хакта акт төзеп, алдау юлы белән Саратовта яңа карточкалар алгансыз. Менә ул акт, рәсми рәвештә кул куелган. Моны болай гына йомып калып булмый, өчегезне дә катгый җавапка тартырга туры киләчәк.

Без ни әйтергә, ничек акланырга белмичә гаҗиз калдык. Артельче Җәмилә кычкырып еларга тотынды:

– Капитанның да, боцманның да монда катнашы юк. Ант итеп әйтәм, икмәктер менә, мин югалттым, мин генә гаепле...

– Җитте, шаулама, анысын милиция ачыклар. – Каюмов портфеленнән тагын бер кәгазь чыгарып салды. – Менә прокурордан ордер, бу милиционер пүнәтәйләр белән хәзер өчегезнең дә каюталарын тентер. Кладовой ачкычларын миңа бирегез, хәзер үк ревизия ясатабыз.

Каюмов, натурасы белән кулы үзенә кәкре кеше, бик ихтимал, бу очракта безне, чынлап та, хәрәмләшкән дип уйлагандыр. Һәрхәлдә, аның шуңа ныклы ышануы һәм, форсаттан файдаланып, миннән үч алырга ниятләнүе ачык сизелә иде.

Бу нахак гаепләүне ишетү ифрат кыен һәм бөтен команда алдында оят булса да, тешләрне кысып түзәргә, кызарырга туры килде. Чөнки безнең гаепле түгеллегебезне исбат итәрлек, акланырлык бернинди дәлилебез юк иде.

Каюмов әйткән сүзендә тәки торды. Каюталарны тентү һәм ревизия ул көткән нәтиҗәне бирмәсә дә, барыбер безнең эшне тикшерү органнарына тапшырды. Мәгълүм ки, тикшерү астындагы кеше капитан булып эшли алмый бит. Затонга ремонтка кергәннең иртәгесен миңа алмашка бүтән капитан – инде күптән ялга чыккан такыр башлы бер мәзәкчән агай килде.

Безнең эшне ашыктырырга, пароход затонда торган вакытта ачыклап бетерергә кушылган икән. Шул ук көнне тикшерү башланды. Мин яңа капитанга пароходны тапшырган арада, команда әгъзаларыннан байтагы, шул исәптән Җәмилә белән Мәрфуга да инде допроста булып өлгергән, һәркайсы югалган карточкалар турында үзе белгәнен сөйләгән иде. Тик шуннан соң гына миңа чират җитте.

Тикшерүче – ярым хәрби формадан киенгән, саргылт кыска чәчен артка яткырып тараган урта яшьләрдәге хатын – бик вакчыл һәм бәйләнчек булып чыкты, казына-казына нервыларны талкып бетерде. Ул допрос протоколына кул куйдыргач та тәгаен берни әйтмәде. «Тикшерү нәтиҗәсен прокурор раслаганнан соң үзем хәбәр итәрмен», – диде дә, йөрәккә шом салып, килгән юлыннан китеп барды.

Аның артыннан мин дә, барлы-юклы әйберләремне чемоданга тутырып, пароходтан китәргә җыена башладым. Елдан артык бергә эшләгән, шатлыгын-кайгысын уртаклашып яшәгән бертуганнардай якын иптәшләрдән аерылып китүе җиңел булмады. Кызларым да бик көенеп, әгәр суд була калса, бөтен командабыз белән сезне яклап чыгачакбыз, дип озатып калдылар.

...Бәла ялгыз йөрми, диләр.

Минем белән дә шулай булды. Команда белән саубуллашып пароходтан чыгып барганда, таныш түгел бер яшүсмер кыз килеп мине яр өстендәге цехка телефонга чакырды. Барып тыңласам, безнең квартирадан синең әниең шылтырата икән.

– Уф, көчкә эзләп таптым үзеңне... – диде ул, авыр сулап. – Мәрьям җаным, хәзер үк өйгә кайтып җит. Әтиеңә әллә ни булды... Кәбир белән мин барып кергәндә, ул өстәл янында утырган җиреннән кинәт гырылдап...

Инде байтактан бирле әти йөрәк өянәге белән азаплана, берничә мәртәбә больницада дәваланып, үзе әйтмешли, «моторын» төзәттереп чыкканы да бар иде. Разия апай, сүзен әйтеп бетерә алмыйча, үксеп елый башлау белән йөрәгем жу итеп китте, бу юлы хәлнең хәвефле икәнлеген шундук сиздем. Кинәт бөтен барлыгымны курку биләп алды. Ни булганын ачыклап сораштырырга телем әйләнмәде, дөресрәге, батырчылык итмәдем. Хәзер кайтам, дип әйттем дә шундук юлга ашыктым.

Хәлбуки күңелем сизеп хәвефләнгәнмен икән. Кичкырын мин кайтып кергәндә, өй тулы дусиш, якын танышлар, техникум кешеләре җыелган: әти, әлерәк кенә йокыга талган кебек, үз караватында ак мендәр өстендә чалкан ята иде. Матвей Михайлович аның хәрәкәтсез кулларын кушырып куйгач кына, әтинең инде үле икәнлеге аңыма барып җитте.

Шунда минем зиһенем чуалды, күз алларым томанланды. Аннан соң булган хәлләр: иртәгесен әтине җирләү, дус-ишләр һәм күрше-күләннең кайгымны уртаклашулары, юатулары – һәммәсе дә саташулы авыр төш сыман күз алдымнан уздылар.

Мин әнидән бик яшьли калганмын. Әтием сөйләгәннәрдән аның гражданнар сугышы вакытында Идел хәрби флотилиясе йөзмә госпиталендә медсестра булып хезмәт иткәнен беләм, әмма үзен бик тонык төсмерлим. Шулай да ятимлекне белмәдем. Мине үгилектә калдырмас өчен, әтием бүтән өйләнмичә, тол яшәде, мине үзе кадерләп үстерде. Шуңа күрә дә аның үлеме минем өчен гаять зур югалту, бик авыр кайгы, әледән-әле күзләрем яшьләнә. Андый минутларны улым Кәбир, уенынан туктап, битләремне сөртә, әнием, елама, дәү әти урынына мин сине үзем яратырмын, һичкемнән рәнҗеттермәм, дип, үзенчә юаткан була.

Күрәм, Разия апай да минем өчен җан атып йөри. Әтине җирләгәннән бирле бу көннәрдә ул һаман бездә вак-төяк эш, төрле сүз белән мине мавыктырырга, хәсрәтле уйларны оныттырырга тырыша.

...Болай йончыткыч кайгы-хәсрәткә чумган хәлдә, әле кайчандыр буласы судны көтеп, көннәр буе өйдә утыруы бик авыр. Кая да булса эшкә урнашырга, ни беләндер шөгыльләнергә, хәрәкәтләнергә кирәк...

Әнә шундый уйлар белән бүген иртән Аргы Устьега төштем һәм, паромда аргы якка чыгып, кайчандыр эти белән бергә йөргән яр буйларыннан үттем, Ослан тавы өстеннән чал Иделгә, мәһабәт кремль диварларына, шәһәр урамнарына, гомеремдә беренче мәртәбә күргәндәй, озак карап тордым.

Мондый киеренке вакытта артык шикләнүчән буласың икән. Иртән өйдән чыкканда эш эзләргә уйлаган булсам да, пристаньда кадрлар бүлегенә керергә дә, техникумга барырга да оялдым. Күргән-белгән кеше миңа нәфрәт белән, гаепле итеп карар кебек тоелды.

Ахыр чиктә мин бүген беркая да бармаска, прокуратурага кереп, эшебезнең барышын белешергә дә өйгә кайтып китәргә булдым. Теге чакны бездән допрос алган караңгы чырайлы тикшерүче хатынның каядыр ашыккан чагына тарыдым бугай, мин барып кергәндә, ул кабинетыннан чыгып килә иде.

– Мин бит сезне кичкә чакырткан идем, ничек болай ашыгып киләсе иттегез? – диде ул, ризасызлык белән. Аннары, мин бернинди чакырусыз үзем эшебезнең барышын белешергә килүемне әйткәч, ул кире борылып бүлмәсенә керде. – Мин дә сезне шуны әйтергә чакырткан идем. Сез килгәнсез икән, рәхим итеп утырыгыз, әйдә сөйләшик. – Ул өстәл өстендәге сары тышлы делоларның берсен ачып, иң азактан теркәлгән кәгазьне тиз генә күздән кичерде дә әйтте: – Озын сүзнең кыскасы шул: гаебегез расланмау сәбәпле прокурор сезнең эшне туктатырга, тәэминат бүлегеннән кергән материалны нәтиҗәсез калдырырга карар чыгарды. Чөнки карточкаларның югалу фактын җинаятьчел максат белән артельче урлаган, профорг белән сез шуны яшереп калган дип инкриминировать итәргә, ягъни кемне дә булса җинаятьтә гаепләргә нигез тапмадык. Тикшерү нәтиҗәсе пароходчылык идарәсенә хәбәр ителде... Ә артельче кызыгызга гамьсезлеге өчен үз властегыз белән шелтә бирергә мөмкин. Киләчәккә сабак булыр. Менә бар әйтер сүз шул. Борчыган өчен гафу итегез. Бу күңелсез хәлне уңышлы ерып чыгу белән котлыйм сезне.

Беркөн, затонда сорау алганда, артык рәсми, бәйләнчек күренгән тикшерүче хатын күз алдында иң ягымлы кешегә әверелде! Өстемнән авыр йөк төшкәндәй, җиңел сулап куйдым. Шатлыклы дулкынлану белән:

– Гадел булуыгыз өчен сезгә бик зур рәхмәт... – дип, тикшерүченең кулын кыстым.

Тикшерүче яныннан мин, анадан яңа туган кебек, бүтән кеше булып, адәм күзенә туры карарлык хәлдә кыюланып чыктым.

Өйгә кайтып керсәм, анда пароходтан артельче Җәмилә килгән, бик җанланып Кәбир белән уйнап утыра. Мине күрүгә, тантаналы тавыш белән хәбәр итте:

– Мәрьям Вәсилевна, шатлык... Югалган карточкалар табылды...

Колакларыма ышанмагандай:

– Чынлапмы, безнең карточкалармы? – дип сорадым. – Ничек табылды, кайдан килеп чыктылар?..

– Мин аларны Куйбышевта йөзмә магазиннан азык-төлек алганда төшереп калдырганмын. Шуннан почта белән җибәргәннәр… Менә алар, үзем теркәп куйганча, берсе дә югалмаган…

Дөресен әйтим, үзем дә бик сөендем. Күзем белән күреп торсам да, әле һаман ышанмаган кебек, карточкаларны кулым белән капшап, актарып карадым.

Үз чиратымда мин дә Җәмиләгә әле генә тикшерүче янында булуымны һәм безнең эшнең туктатылуын әйттем. Аннары без, күңелендә шик калмасын дип, ул карточкаларны конверты, хаты белән шундук тикшерүчегә илтеп тапшырдык. Болай эшләү башта миңа ничектер балаларча кылану, инде эш тукталганнан соң артык ваклану булыр сыман иде. Тикшерүче исә, киресенчә, хуп күрде.

– Азык-төлек карточкаларын безгә китереп бик дөрес эшләгәнсез, – дип, хәтта мактап куйды. – Югыйсә тәэминат начальнигы, безнең нәтиҗә белән килешмичә, җинаятьчеләрне яклыйсыз, дип, ризасызлык белдергән иде. Менә хәзер, бу карточкаларны күрсәткәч, бернинди җинаять юклыгын, без хаклы икәнлекне ул да танырга мәҗбүр булачак.

…Менә мин тагын үз «Ургыл»ымда, пароходчылык идарәсеннән алынган телеграмма-приказ белән үз урыныма кайтып, яраткан эшемә керештем. Хәзер «Ургыл»ның тышкы күренеше элеккечә тоташтан зәңгәрсу-ак түгел, ә яшькелт-сары төскә ала-кола чуарлап буялган һәм сирәк урманлы тау битенә охшап калган. Моны хәрби командование кушуы буенча маскировка максаты белән шулай эшләгәннәр. Хәзер Иделдә бөтен флот шундый төскә буялды.

Команда кызлары мине шатланып каршыладылар. Аларның җылы исәнләшүләрен күреп, күңелем нечкәреп китте. Бу эчкерсез якынлыкны минем урынымда калып торган карт капитан да сизгән булып чыкты.

– Сезне пароход командасы галәмәт якын күрә икән, – диде ул, мине мактап. – Тиз кайтып бик әйбәт иткәнсез, чөнки сизәм, саулыгым чамалы, иске баржа кебек шыгырдап, ыңгырашып кына йөрим… Алмашка кеше юк дип, бик зинһарлап сорагач кына килүем иде.

Кешенең уңганлыгы, эшкә тырышлыгы бер караудан күренә бит. Капитан агай, минсез затонда торган бер атна дәвамында, пар казанын чистартудан тыш, команда көче белән корпус һәм машинаны ремонтлатып өлгергән, пароходны тышкы яктан буятып, яп-яңа төскә керткән. Моның өчен чын күңелдән рәхмәт әйттем үзенә.

Команда тормышында тагын бер яңалык мин пароходка кайткан көнне булды. Шуның алдыннан гына без – боцман Мәрфуга белән мин – койрык якта яңа ремонтланган шпильне эштә сынап маташа идек. Шул мәлне алгы пролеттагы кызлардан берсе:

– Әй, боцман!.. – дип кычкырды. – Монда чык әле, әнә анда сине сорап ниндидер солдат килгән…

Каерылып карасак, пароходтан ярга сузылган такта трапта, чынлап та, баһадирларча киң җилкәле бер солдат елмаеп тора; ул кызыл йолдызлы пилоткасын көяз егетләрчә чак кына кыңгыр салган, гимнастеркасының буш җиңен бил каешына кыстырган иде.

Мәрфуга исә аны күрү белән тораташ кебек катты, кинәт хәрәкәтсез калды, төсе китте, бизгәк тоткандай, иреннәре калтырый башлады. Ниһаять, ул телгә килде:

– Юк, күз алдану түгел, шул үзе… Сәлим бәгырем, чынлап син ич… – дип кычкырып җибәрде һәм абына-сөртенә солдат янына йөгерде.

Мәрфуганың сугышта үлде дип саналган иренең көтмәгәндә кайтып төшүе бөтен команда өчен күңелле бәйрәмгә әверелде, яраткан боцманыбыз өчен барыбыз да ихлас күңелдән сөендек. Кичен кызыл почмакта җыелып, фронтовикның үзен дә сөйләттек, күптөрле сораулар белән йөдәтеп бетердек. Сәлим көр күңелле, бик җор солдат икән, сугышта күргәннәрен, төнлә дошман тылында каты яраланганнан соң, партизаннар землянкасында кулын ампутацияләүләрен бернинди сыкранузарсыз сөйләп барыбызны да дулкынландырды. Арадан кемдер, бер кулсыз кыен түгелме, дип кызыксынгач, Сәлим, җор кешеләргә хас шаярту белән:

– Юк, бер дә кыен түгел… Хәтта уңайрак та әле, – дип, җиңелчә көлдереп тә алды. – Сөйләгәндә кулыңны болгама, дип, элек Мәрфуга гел теңкәгә тия, ачуны китереп бетерә торган иде. Хәзер күрәсездер, ләм-мим, бал капкан кебек, елмаеп кына утыра әнә.

Аңа сыенып утырган Мәрфуганың йөзендә шатлык балкый, ул көне-сәгате белән күз алдында яшәреп, куанычы эченә сыймагандай, гел елмаеп йөри торган булып китте. Шунда мин ирексездән: «Ярый әле теге чакны ашыгычлык белән иргә чыгудан тыелып кала белдең, молодец!» – дип, аның өчен ихлас күңелдән куанып утырдым.

Тиздән җиңү белән сугышлар бетеп, безгә дә менә шундый бәхетле кавышулар насыйп булсын иде.

…Затонда ремонтланып чыккач, безгә пристаньда күп торырга туры килмәде. Сталинград ашыктыра. Причалга килеп туктауга, пароходка үзләренең сугыш припаслары белән хәрбиләр төялде. Шул арада бөтен яр буе озата килүчеләр белән тулды. Соңгы үгет-нәсихәтләрне әйтеп, һәрвакыттагыча күз яшьләре түгеп, саубуллашулар башланды.

Безнең кайчан китәсене алдан белешеп торганнар булса кирәк, мине озатырга Разия апай белән Кәбир дә төшеп җитте. Моңарчы бер дә болай булганым юк иде, бу юлы әллә нишләдем, алардан аерылып киткәндә, күңелем тулды, күзләрем яшьләнде… Юлга кузгалып, пароход елга уртасында агым уңаена борылгач, мин бинокльдән причалга караганда, анда халык инде таралган, яр өстендә минем бәгырькәйләрем – Кәбир белән Разия апай – бөтенләйгә саубуллашкандай, әле һаман кул болгап торалар иде.

Бераздан, көндезге вахтадан бушаганнан соң, ашханәгә төшсәм, анда бөтен команда тын да алмыйча профорг Мәрфуганың кычкырып нәрсәдер укыганын тыңлап утыра иде. Мин ачык ишектән керү белән, Мәрфуга укудан туктады.

– Казанда культбазадан алган газета-журналлар арасыннан менә бу пакет килеп чыкты, – диде ул, кулындагы кәгазьне күрсәтеп. – Сталинградтан, флотилия хәрби советыннан хат. Үткән рейста хәрби эшелонны фронтка хәвеф-хәтәрсез вакытында китереп җиткергән һәм ут эченнән йөзләрчә яралыларны эвакуацияләгән өчен безгә рәхмәт әйтеп язганнар.

Тын гына тыңлап утырган кызлар, кинәт җанланып, теге чакны Сталинградта күргән хәвефле эпизодларны кабат башларыннан кичергәндәй, бер-берсенә сөйләргә тотындылар. Ә мин хатны үзем укып чыккач, көтмәгәндә башыма килгән бер сәерсенү белән:

– Ул вакытта бездә хәрби флотилиядән беркем дә булмады кебек. Моны кем шулай белеп, үзе күргәндәй, тәфсилләп язды икән? – дип кызыксындым.

Бу сорауга шундук җавап бирүче булмады. Чак кына соңрак, мин өстәл янында ялгызым калгач кына, үзенә дә чәй салып, каршыма повар Ольга килеп утырды һәм сер итеп сөйләгәндәй:

– Бая сез әйткән хәбәрне газетага минем Даутым җибәргән булса кирәк, – диде. – Мөгаен, шулдыр, безнең кешеләрнең исемен, фамилияләрен, кем булып эшләүләрен шул язып алган иде.

Күр инде бу кызыйны, минем Даутым, имеш. Кай арада Даут инде аныкы булып та өлгергән.

– Теге безне озата барган яшь лейтенантмы, сиңа өйләнергә теләгән мыеклы егетне әйтәсеңме? – дип гаҗәпләндем. – Йә ничек, ул чакны әнисенә барып күрендегезме соң?

– Бардык, Мәрьям Вәсилевна, күрендек... Мондый хәвефле вакытта сугыштан улы исән-сау кайтып төшү шатлыгыннан әни карчык чүт сыгылып төшмәде, күз яшьләре белән елый башлады...

Мин үзем бер дә кыймыйча, уңайсызланып кына барган идем. Иске карашлы карчык, мине – бүтән милләт кешесен өнәмәс, кире кагар дип шикләнгән идем. Әмма ялгыш уйлаганмын. Даут минем хакта: «Әнием, менә сиңа килен, үземә тормыш иптәше алып кайттым... Исеме Ольга, туган кызың итеп кабул ит», – дип әйткәч, әни карчык икебезне дә кочаклап, безгә тигез гомерләр теләде.

Тормыш, мин әйтәм, тоташ кайгы-хәсрәттән, кыенлыклардан гына тормый икән. Менә тагын бер кызыбыз, үз парын табып, оя типте. Хәерле сәгатьтә булсын, аларга без дә бәхетле тормыш телик.

Анысы да монысы, менә тагын кара көз керде бит. Идел отыры суына, көннәр кыскара бара, күп вакыт дөм караңгыда йөзәргә туры килә, берни күренми. Быел бу безнең соңгы рейсыбыз булыр инде. Былтыргы кебек юлда боз әсирлегенә эләкмәс өчен, тизрәк Казанга кайтып житү белән затонга китәрбез дә кышка туктарбыз.

Бу көннәрдә безнең монда өметле хәбәрләр йөри башлады. Сталинградта оборона сугышлары алып бару белән бергә, шул ук вакытта кайдадыр далада безнекеләр зур көч туплый, тиздән хәлиткеч һөҗүмгә күчәчәкләр икән дип сөйлиләр. Берүк шулай була күрсен, тизрәк башларына житсеннәр иде шул явыз фашистларның.

Ә син, Нурис бәгырем, һаман юк, бернинди хат-хәбәрең дә юк... Шул хакта уйлый башласам, күңелем тула, тамак төбенә сагышым төер булып тыгыла.

...Казаннан алынган приказда әйтелгәнчә, без беркайда туктамыйча, туп-туры Сталинградка төшәргә тиеш идек. Әмма юлда бер кечерәк кенә үзгәреш килеп чыкты: без алып бара торган хәрби часть командиры соравы буенча беразга гына Саратовта туктарга, һәм, селектордан сөйләшеп, Сталинград зонасына кай вакыттарак барып керергә, анда туктыйсы урынны ачыкларга туры килде. Шул кыска гына вакыт эчендә безнең кызлардан кайберләре фронттагы якыннарына язган хатларын почта ящигына салырга, ә профорг Мәрфуга хәтта культбазадан яңа газета, журналлар да алырга өлгерде.

Пароход пристаньнан кузгалып киткәннән соң чирек сәгать үтмәгәндер, рубкага боцман Мәрфуга атылып килеп керде. Траптан ашыгып менгәнгә булса кирәк, ул еш-еш сулый, кулында газета, бөтен кыяфәтеннән никтер бик исәренгәнлеге күренеп тора.

– Мәрьям Вәсилевна, әйтегез әле, сезнең Нурисламыгызның фамилиясе, әтисенең исеме ничек әле аның? – диде ул, ишектән керүгә.

Хәрби часть командиры белән мин яңа алынган приказны ничек үтәү турында киңәшеп, Сталинград районында туктыйсы урынны карта буенча ачыклап тора идек. Һәр эшнең вакытын һәм җаен белә торган зиһенле Мәрфуганың чит кеше алдында тиктомалдан шундый сүз кузгатуын ошатмадым.

– Ул хакта соңынтын сөйләшербез... Комачаулап йөрмә, бар, эшеңдә бул, – дип, аның сүзен бүлдем.

– Ачуланмагыз, әйтегез инде... – диде Мәрфуга, үҗәтләнүен дәвам иттереп. – Алимҗанов Алимҗанович түгелме?

– Эш вакытында урынсыз сораулар белән комачаулап йөрисез. Йә, шулай булса нишләгән?..

– Алайса, мин тәбрик итәм сезне... Шатланыгыз, Нурисламыгыз табылды, менә ул! – дип, Мәрфуга кулындагы газетага бармагы белән төртеп күрсәтте. – Саратовта алган менә бу газетада шул

исемне күрү белән, чү, мин әйтәм, безнең Мәрьям Вәсилевна Нурисламы түгелме бу... Табылган, димәк, исәнсау, орден белән бүләкләнгән... Менә монда шул хакта язганнар.

Искәрмәстән капылт килеп төшкән куанычлы хәбәр дә кешене миңгерәтә икән. Мәрфуганың бу сүзләреннән башым әйләнеп китте, күрмәс күзләремне газетага төбәгән хәлдә бермәл аңыма килә алмый тордым.

Хәрби часть командиры татарча аңламаса да, минем хәлемне сизде булса кирәк, карыйсы эшләрем бар, дип, рубкадан төшеп китте. Ә мин, тиздән вахтадан бушап, каютада бераз тынычлангач кына, газетадагы ул хәбәрне иркенләп укый алдым һәм разведкадан кайтканда эзәрлекләп килүче дошман отрядын тоткарлап, иптәшләреңне коткаруыңны, зур кыенлыклар белән үзебезнең якка исән-сау чыгуыңны белеп, әйтеп бетергесез сөендем. Вакыт-вакыт хәтта күңел ышанмый, саташмыйммы мин, төштә генә түгелме бу дип, үземнән-үзем сорап куям.

Юк, төш түгел, реаль чынбарлык бу! Күңел күгемне каплап торган авыр хәсрәт болытлары, ниһаять, таралды, сулышым җиңеләюен бөтен барлыгым белән сизеп шатланам... Бүген соң инде, иртәгә Сталинградтан әйләнеп чыгу белән бу хакта ничек тә тизрәк Разия апайга ашыгыч телеграмма бирергә, тизрәк аны да сөендерергә кирәк булыр...

***Хөрмәтле Нурислам абый, исәнмесез!***

«Ургыл» командасы исеменнән сезгә бу хатны пароходның штурвальные, һәрвакыт Мәрьям Вәсилевна белән бергә рубкада вахта торган, соңгы ел ярым дәвамында, гомумән тормышның ачысын-төчесен бергәләп татыган Җәмилә Бәхтиярова яза.

Иң әүвәл Мәрьям Вәсилевнаның безнең өчен таләпчән һәм гадел капитан гына түгел, һәркайсыбыз турында аналарча кайгыртучан, хәзерге кыен көннәрдә ярдәмчел юатучыбыз да булуын әйтеп үтәсем килә. Шул ук вакытта ул үзе дә кыенлыкларны аз күрмәде. Сезнең югалу хәбәренә күңеле белән ышанмаса да, ул аны бик авыр кичерде, нәкъ шул айларда аның әтисе үлеп китте. Өстәвенә, җәрәхәткә тоз салгандай, нахак гаеп тагып, аны хөкемгә тартырга маташучылар да табылды.

Мәрьям Вәсилевна исә, кыенлыкларга бирешмичә, һаман эштә янды, кайгы-сагышларын эштә басарга тырышты. Ә сез табылгач шатлыгын күрсәгез икән!.. Ул көн безнең пароходта, зур бәйрәм кебек, күңелле булды, сөекле капитаныбызның сугышта югалган кадерле кешесе – сез табылуга барыбыз да чиксез сөендек. Ул хәбәр басылган газета кулдан-кулга күчеп йөрде.

Шул кичне, караңгылык куергач, без Сталинград турына төшеп җитеп, төн пәрдәсе астында үзебез алып килгән хәрби эшелонны тиз генә бушаттык та шундук яралыларны кабул итәргә керештек. Әйләнә-тирә дөм караңгы булса да, гадәттәгечә, бар эш һичнинди матавыксыз, оешкан төстә барды. Ниһаять, чалкаларны ычкындырып, причалдан кузгалган вакытта дошман безне һавадан ракета белән яктыртты һәм шундук биек тау башына урнашкан туп, минометлардан өстебезгә ут ачты; караңгы күктә утлы эз калдырып яуган яктырткыч пулялар рубка стенасын тишкәләп үттеләр.

Шулчак рубканың ачык тәрәзәсе каршында басып барган Мәрьям Вәсилевна кинәт нидер кычкырып, күкрәгенә тотынды. Мин борчылу белән: ни булды, яраландыгызмы әллә, дип сорарга өлгермәдем, ул шундук тураеп машинаны катырак эшләтергә, рульне уңга борырга команда бирде. Тиз генә кузгалып утыз-кырык метр китәргә өлгермәгәнбездер, әле генә без торган урынга кинәт төшкән снаряд шартлавыннан пароход бөтен корпусы белән сикереп куйды... Һавада ракета сүнү белән әйләнә-тирәне тагын коточкыч караңгылык каплады. Шул форсаттан файдаланып, без алдау маневрлары ясый-ясый бар көчкә хәтәр зонадан читкә, елганың сул ягына ташландык.

Берничә минуттан «Ургыл» дошман урнашкан куркыныч таулар турыннан хәвеф-хәтәрсез үткәч, мин җиңел сулап куйдым. Ә Мәрьям Вәсилевна пароход белән командалык итеп барган җиреннән:

– Уф-ф... Бүтән түзәр хәлем юк... – дип, ишетелер-ишетелмәс ыңгырашып, штурвал өстенә яны белән ава башлады.

Мин аны көч-хәл белән тотып калдым һәм арткы стена буендагы такта тапчанга яткырдым. Караңгыда кулым җылы юешкә тиде, һәм мин аның бөтен юбкасы, китель итәге манма кан булуын шәйләп алдым... Минем тавышка шундук менеп җиткән кешеләр аны медпунктка алып төшеп киттеләр...

Бераздан яралыларны озата баручы хәрби врач тикшереп караганнан соң, аның күкрәген ике урында пуля тишкәнлеген һәм бик күп кан акканлыгын әйтте... Димәк, Мәрьям Вәсилевна әле пристаньда ук каты яраланган булуына карамастан, коточкыч авыртуга бирешмичә, хәвефле моментта үз постында торуын дәвам иттергән һәм, пароходны һәлакәттән алып чыгып, тәмам хәлдән тайгач кына аяктан егылган икән. Ә мин, аның белән янәшә торып та, шуны күрмәгәнмен.

Вахтада һаман бергә торгангамы, Мәрьям Вәсилевна мине аеруча үз итә сыман иде. Шуңа булса кирәк, бераздан медпунктта аңына килгәч, ул иң әүвәл мине чакыртып алды.

– Җ-Җәмилә, синме бу... Якынрак кил... – диде ул, мине кыенлык белән танып. – Менә үләм инде, хушыгыз... Сүземне бүлмә, хәлем барда әйтеп калыйм... Минем өстәлдә Нурислам абыеңа язган берничә хатым бар, син аларны ничек тә тапшыр инде... үзеңнән өстәп шуны яз, әгәр очрашырга туры килсә, телдән дә әйт: Кәбиргә әти булсын, аны Туган илгә тугрылыклы, намуслы кеше итеп тәрбияләп үстерсен...

Соңгы сүзләрен ул бик кыенлык белән пышылдап кына әйтә алды һәм, хәле бетеп, бөтенләй тынды, йокыга талды. Күзләрен йомган хәлдә беравык ятканнан соң, ул тагын кузгалырга теләгәндәй, бөтен гәүдәсе белән талпынып, кипшенгән иреннәрен көч-хәл белән кыймылдатып, авыз эченнән нидер сөйләнә башлады. Мин аның авызыннан буылып-буылып чыккан саташулы сүзләрен аңламадым, бары тик берничә мәртәбә улы Кәбир һәм сезнең исемне әйткәнен генә ишетеп калдым.

Шул һушсызланудан Мәрьям Вәсилевна бүтән аңына килмәде, хәле авырайганнан-авырайды, ул безнең күз алдында сүнә барды. Доктор аның яраларын яңадан бәйләп, хәзинәдә булган даруларны биреп тә хәлен җиңеләйтә алмагач:

– Гангрена башлану куркынычы бар, ашыгыч операция кирәк, – диде. – Пароход шартларында аны эшләү мөмкин түгел, беренче пристаньда туктап, тизрәк больницага салырга кирәк.

Башта без Мәрьям Вәсилевнаны ничек тә Казанга, дәвалау мөмкинлекләре күбрәк булган шәһәргә алып кайтырга уйлаган идек. Эш болайга киткәч, планны үзгәртергә, врач таләбе буенча Камышинда туктарга туры килде. Батыр капитаныбыз Мәрьям Вәсилевнаны без шунда «ашыгыч ярдәм» машинасы чакыртып, һушсыз хәлендә больницага озаттык.

Шушы конвертка салып, Мәрьям Вәсилевнаның соңгы көннәрдә язып та озатылмый калган берничә хатын сезгә җибәрәбез һәм барыбыз өчен дә авыр булган кайгыгызны уртаклашабыз.

***Соңгы сүз***

Бөек Ватан сугышы вакытында Сталинградта һәлак булган Идел капитаннарының фотопортретлары, пароходчылык музееның үзәк залында путаллы рамнар эченә алып, иң күренекле урынга куелган. Музейга килүче экскурсантлар – күпсанлы мәктәп балалары, яшьләр, өлкән буын кешеләре – Туган ил азатлыгы өчен гомерен фида кылган батыр командирларның рәсемнәрен караганда, шундагы хатын-кыз капитан портреты янында озаграк тукталып, соклану һәм ихтирам белән тын гына торалар.

Бирегә беренче мәртәбә килгән көнне бу портретны күрүгә, мин дә ихтыярсыз тукталып калдым һәм шунда язып куйган кыскача биографик белешмәне дулкынлану белән укып чыктым. Сәбәбе шул: аның исеме, фамилиясе, төсе-бите миңа таныш кебек тоелды. Хәтерем ялгышмаса, кайчандыр, мин елга техникумында укыган вакытта, ул безгә кышларын сигнализациядән дәрес бирә, ә җәйге айларда пароходта капитан ярдәмчесе булып эшли иде.

Әле дә исемдә: мин күргән-белгән елларда ул зифа буйлы, бик чибәр яшь ханым иде, елмаючан ачык йөзле булгангамы, хәтта бераз җилбәзәк сыман күренә иде. Хәзер исә аның елгачы капитан киеменнән пароход күперчегендә аяк өсте басып төшкән бу рәсемдә яшьлеккә хас гамьсезлекнең инде эзе дә юк. Шулай да ул элеккечә мөлаем, өстендәге ак кителе, җыйнак гәүдәсенә килешле сыланып тора; зур түгәрәк күзләренең төбәп каравы, матур иреннәренең сизелер-сизелмәс кенә елмаюы белән ул кемгәдер сөенечле хәбәр әйтергә тели сыман иде.

Тик шунысы кызганыч, рәсем астындагы биографик белешмә бик кыскача язылган, аннан капитан Билалованың эшчәнлеге һәм һәлакәте турында тулырак мәгълүмат алу мөмкин түгел иде. Шунлыктан мин аның хакында, бүтән документлар юкмы, дип кызыксынып, музейның фондлар бүлегенә кердем.

Бүлек мөдире, инде өлкән яшьләрдәге бик ихтирамлы бер агай, зур шкаф эчендә байтак вакыт актарынганнан соң, бер төргәк табып чыгарды.

– Күптән түгел моны безгә яшь эзтабарлар тапшырган иде,– диде ул, төргәкне аркылы-торкылы бәйләгән ал тасманы чишеп.– Тышына язылган исем-фамилиясенә караганда, шул капитан хатлары булса кирәк. Алар татар телендә язылган. Әле һаман һич кул җитми, берәрсенә укытып ачыклаган да юк... Менә карагыз әле, укып чыккач, эчтәлеге белән, бәлкем, безне дә таныштырырсыз.

Төргәкне ачып карау белән, аның эчендә шул безнең техникум укытучысы штурман Мәрьям Билалованың Бөек Ватан сугышы вакытында фронттагы якын дусты Нурисламга язган хатлары икәнлеге беленде. Ул хатларда тасвирланган вакыйгалар, телгә алынган кешеләрнең гыйбрәтле язмышлары, җанлы картинадай, күз алдыма килеп басты.

Дөрес, сугыш елларында мин үзем Иделдән еракта, илебезнең диңгез чикләре сагында булдым. Сталинградта каты сугышлар барган көннәрдә, бер төркем коралдашларым белән бергә фронтка китәргә сорап гариза да биргән идем. Ләкин җибәрмәделәр, бөтен кешене фронтка озатып булмый, Ватан кушкан җирдә хезмәт итәргә кирәк, дип әйттеләр.

Хәер, ул вакытта анда да җиңел булмады. Япон самурайлары рәсми нейтралитет саклаган булсалар да, ил чигендә әледән-әле кораллы провокация ясап тордылар, океан юлларында каракларча яшеренеп күпме пароходларыбызны батырдылар, кешеләрне һәлак иттеләр. Кыскасы, гел уяу булырга, дарыны коры тотарга туры килде, кораллы провокация – һөҗүм була-нитә калса, шундук җимергеч җавап бирергә әзер тордык. Без һәрвакыт тылдагы якын туганнарыбыз, сөйгәннәребезнең күңел җылысын тоеп яшәдек, алар җитештергән хезмәт җимеше белән тукландык, киендек, коралландык. Шул какшамас бердәмлек безне көчле итте.

Ул көннәрдә без барыбыз да күңелләребез белән Иделдә, Туган ил язмышы хәл ителгән Сталинград фронтында булдык. Шул тарафтан килгән һәр хатны, һәр газета, радио хәбәрен түземсезлек белән көтеп ала идек. Ул кайнар көннәр күңелләргә беркайчан да онытылмас булып сеңгән.

Шуңа булса кирәк, Идел капитаны Мәрьям Билалованың яңалифчә язылган, еллар үтү белән саргаеп, күп урыннарда хәрефләре танымаслык уңып беткән хатларын мин тирән дулкынлану белән укыдым, һәр героик көрәш елларының кайнар сулышын безнең көннәргә алып килгән ул җанлы сәхифәләрне әдәбият сөючеләр игътибарына тәкъдим итәргә булдым.

## Яшен суккан имән

Волгоград белән Әстерхан шәһәрләре арасында, чал Иделнең уң ягында, татар хатын-кызларыннан иң өлкән һәм бик тә үзенчәлекле шагыйрә Газизә Сәмитова туып үскән Ташлыяр исемле авыл бар. Теплоходта үткән саен, күңелемдә шул авылны күрү теләге туа, әмма һаман ничектер форсат чыкмый иде.

Былтыр җәй, ниһаять, җаен туры китердем: туристик походка барганда, теплоходтан төшеп калып, шагыйрә авылында иреклеккә сусап моң-зар тулы шигырьләрен иҗат иткән йортта булдым, аны күреп белгән карчык-корчык белән очрашып сөйләштем, зиратка барып каберенә баш идем.

Кичкырын, шуннан пристаньга кайтырга чыкканда, зират капкасы янында мин кәкре башлы тимер таякка таянган өлкән яшьләрдәге бер агайны куып җиттем. Болай күзгә бәрелеп тормаса да, аның бер аягы протез бугай, атлаган саен ишетелер-ишетелмәс шыгырдап куя. Елгачы киеменнән булганга, ул миңа пристань кешеседер кебек тоелды. Сәлам биреп исәнләшкәннән соң, мин аннан:

– Әйтмәссезме, Әстерханга бара торган теплоход кайчанрак булыр икән? – дип сорадым.

Елгачы карасу-зәңгәр кителенең күкрәк кесәсеннән чылбырлы сәгатен алып, кысык күзләре белән карады да:

– Юк, пассажирлар теплоходы тиз түгел, – диде. – Ә менә Әстерханга баручы юл участогы судносы озакламыйча килеп җитәргә тиеш. Мин үзем Владимировкага шуның белән кайтам. Бик ашыксагыз, капитаны белән сөйләшеп карагыз, бәлкем, сезне дә утыртыр.

Сизелерлек акцент белән сөйләшүеннән мин аның рус түгел, бүтән милләт кешесе икәнлеген искәреп алдым һәм ихтыярсыздан йөзенә кызыксынып карадым. Янәшә барган шәпкә ул да сораулы күзләре белән миңа текәлде. Аннары, үзалдына уйлангандай:

– Әгәр ялгышсам, гафу итегез... Мин сезне кайдадыр күргән-белгән кешегә охшатам, тавышыгыз да бераз таныш шикелле, – диде. – Әмма хәтерем начар, кайда күргәнемне, кем икәнегезне һич искә төшерә алмыйм.

Шул арада мин аны үзем дә танып алдым һәм, шундук татарчага күчеп, бу көтелмәгән очрашуга бик гаҗәпләнгән хәлдә:

– Чү, Мирза дус, сине күрәмме мин?! Исән-сау гына йөрисеңме?.. – дип кочаклап алдым. – Хәтернең гаебе юк, без үзебез танымаслык булып үзгәргәнбез. Менә мин дә сине танымадым ич...

– Анысын дөрес әйтәсең, сине дә тиз генә танырлык түгел, – диде ул, ябык куллары белән мине кочаклап. – Яшь вакытта синең дә чәчең чем-кара, куе иде, кышкы суыкта да егетләнеп, яланбаш йөри идең бит. Ә хәзер әнә чаларгансың. Их-х, аннан бирле күпме гомер үтте бит.

Әйе, исәпләсәң, искитмәле, безнең соңгы очрашуга ярты гасыр үткән, үзе бер гомер. Шулай да мин яхшы хәтерлим, ул вакытта Мирзаны безнең белән бергә хәрби хезмәткә алмадылар, бизгәк белән авыру сәбәпле бугай, комиссиядән үтмәде, үз пароходында капитан ярдәмчесе булып эшли калды. Флотта хезмәттә вакытта баштарак хат язышып торсак та, сугыш башлангач, без бер-беребезне күздән югалттык, һәм, илле елдан соң, көтмәгән җирдә очраштык.

Мирза – минем бертуганым кебек якын яшьлек дустым. Авыр кытлык елларны техникумда укыганда, пароходта практика үткәндә, кем әйтмешли, барын бергә, югын уртак бүлеп яшәдек. Каникул вакытларында барыр җире булмаган мин фәкыйрьне үзләренә алып кайта, алар мине бөтен семьялары белән якын итәләр; энесе Хәбиб әдәбиятны бик ярата, Тукайның, Такташның күп шигырьләрен күңелдән белә, үзе дә язгалый, кайбер шигырьләрен миңа да укып күрсәтә иде. Минемчә, анда чынлап та уй-хисләрен үзенчә әйтү сәләте, талант чаткысы бар иде.

Шуңа күрә дә Мирзаны очрату белән, минем күз алдыма шул киң маңгайлы мөлаем яшүсмер килеп басты. Очрашу дулкыны бераз басылып, аны-моны сорашканнан соң, мин аның белән кызыксындым:

– Карале, синең бик тә уңган энекәшең бар иде бит. Хәтерлим, һәр эштә синең күк булырга ярата иде. Хәзер ул нихәл, тормышта нинди юлдан китте, бик картаймадымы әле?

– Ә-ә... аны-ы әйтәсеңме... Син аны хәтерлисеңмени әле? – дип, Мирза ык-мык килде, кинәт теле көрмәкләнгәндәй, бөтенләй тынып, мескен кыяфәткә керде.

Беравык сүзсез баргач, тиздән без Идел буена килеп чыктык һәм, биек яр өстендә чирәмдә утырып, бераз ял итәргә булдык. Мирза китель каптырмаларын ычкындырды, тирләгән ияк астын, муенын кулъяулыгы белән ашыкмый гына сөртә-сөртә ләм-мим дәшми утыра бирде.

– Дускаем, теге чакны син Югары Идел пароходчылыгында эшли идең бит, бу якларга ничек күчәсе иттең? – дидем, озакка сузылган тынлыкны бозып.

– Әйе, шулай килеп чыкты, – диде Мирза. – Кырыгынчы елны мин эшли торган «Донбасс» пароходы Түбән Иделгә күчерелгәч, Владимировка затонында кышларга калдым, аннары бөтенләйгә шунда төпләнеп, әни белән энекәшне дә үз яныма чакыртып алдым. Чөнки ул вакытта миңа Казаннан ерактарак булу, таныш-белешләр күзенә чалынмый яшәргә кирәк иде.

Шушы урында мин Мирзадан чүт кенә, хатыныңны чакыртмадыңмыни, дип сорамадым. Чөнки мин – Мирзаның туенда кияү егете булып йөргән кеше – аның хатыны Зөлфияне яхшы хәтерлим. Безнең техникумда иң матур, гел «бик яхшы»га гына укучы бик тә сөйкемле ул кызга без – егетләр – барыбыз да сокланып карый идек. Аның этисе – мәшһүр драматург һәм артист – безнең драмтүгәрәккә шефлык итә, репетицияләргә килә иде. Әмма безне барыбызны да көнләштереп, Зөлфиягә минем якын дустым Мирза өйләнде.

Ә менә хәзер аның турында ләм-мим. Елга аръягындагы томансу тугайларга төссез күзләре белән бермәл карап торганнан соң:

– Әни бирегә бер дә теләмичә килде, – диде, сүзне никтер икенчегә борып. – Хәер, аның сәламәтлеге инде бик какшаган иде, монда гел авылны сагынып моңайды. Ул вафат булганда, мин үзем фронтта идем. Исән вакытта васыять итеп, үлгәч мөселман зиратына күмегез, дип әйтеп калдырган булгач, аны бирегә китереп җирләгәннәр. Менә бүген шулар янына килеп, каберләрен каравым иде... Ярар, ул хакта калып торсын әле, ә син үзең монда ничек киләсе иттең, бу зиратта кемең бар?

Мин үземнең бирегә ник килүемне әйттем һәм аның үзеннән:

– Туктале, туганкай, сине ничек аңларга?! – дип гаҗәпләндем. – Башта әниеңне генә әйткән идең, сүзеңнең азагында шулар янына дип әйткәч, ничектер берничә кабер сыман килеп чыкты. Дөрестән дә шулаймы, әллә мин ялгыш ишеттәмме?

– Юк, ялгыш ишетмәгәнсең, дөресе шулай – анда безнең ике кабер. Ул каберләрнең икенчесендә минем энекәш, әле генә син телгә алган Хәбибрахман ята...

Шулай да барысы да аңлашылсын өчен, сүзне бераз ерактанрак башларга туры килә. Мин боларны якын дустым булганга сиңа гына сөйлим, мине аңларсың дип ышанам...

Хәрби хезмәткә мине сугышның беренче көнендә Владимировка рейдында тоз төягән ике баржаны буксирга тагып маташканда, катерда килеп алдылар.

Армиядә миначылар отрядына эләктем. Фронтта хәлләрнең авыр чагы иде, яхшылап әзерләнергә вакыт булмады. Саратов янындагы хәрби лагерьда өч атна чамасы алай-болай өйрәттеләр дә фронтка җибәрделәр. Хәлбуки миңа анда озак булырга туры килмәде. Тиздән Мәскәү янында башланган һөҗүм сугышлары барышында аягым яраланып, кар өстендә егылып калдым: тез капкачым чәрдәкләнгән, кан тамырларым зарарланган булып чыкты.

Иртәгесен, эвакогоспитальгә эләккәч, операция булды. Аннары Чабаксарда госпитальдә берничә ай дәваланганнан соң, кырык икенче елның язында агач аяк белән титаклап, Владимировкага кайтып кердем...

Шушы урында Мирза, зиһене чуалгандай, тынып калды, авыр сулап куйды. Ә миңа аның баядан бирле хатыны турында ләм-мим әйтмәве ничектер сәер тоела башлады. Авыз йомып утыру озакка сузылгач, мин аннан үзем:

– Тормыш юлдашың нихәл, исәнлеге-саулыгы ничек? – дип сорадым.

Мирза миңа туры карамыйча, ишетелер-ишетелмәс хәлсез тавыш белән:

– Төгәл генә әйтә алмыйм, исән булса кирәк, – диде. – Мин аны сугышка хәтле, өйләнгәннең икенче елында ук аерган идем.

– Ничек инде аердың, характерларыгыз килешмәдемени, әллә җилбәзәк-фәлән булып чыктымы?

– Юк, аннан түгел, бик тату яши идек. Әти-энисе дә минем өчен үлеп торалар, гомумән, дөнья матур, тормыш ал да гөл иде...

Әнә шундый рәхәт көннәрнең берендә һич тә уйламаганда-көтмәгәндә, безнең атаклы драматургыбыз һәм артистыбыз, минем каенатам халык дошманы – буржуаз милләтче булган өчен кулга алынды. Зөлфиянең әнисе, театрдан чыгып, каядыр Урта Азиягә китәргә мәҗбүр булды.

Ул вакытта андый кешеләргә һәм аның якыннарына нинди караш булганын үзең дә беләсеңдер. Кара хәбәр пароходчылыкка барып җиткәнче дип, миңа да Зөлфия белән араны өзәргә, йөкле вакыты булуга карамастан, тиз генә рәсми рәвештә аерылырга туры килде. Берни эшләр хәл юк, заманы шундый иде.

Шуннан бирле мин аны күргәнем булмады. Ул чакны әни дә, энекәшем Хәбибрахман да исән иде әле. Дөресен әйтергә кирәк, алар икесе дә минем бу адымымны һич тә өнәмәделәр. Хәбиб исә хәтта миннән сизелерлек читләште, рәтләп сөйләшмәс булып үзгәрде.

Аннары, аерылуга өч-дүрт ай үткәч бугай, шундый бер очрак булды: өстәл өстендә Хәбиб калдырган китапны караштыргалап утырганда, конвертлы хатка юлыктым. Адресын күрү белән таныдым, Зөлфия кулы белән язылган. Түзмәдем, шундук кабаланып укырга тотындым. Хәбиб аңа әни һәм үз исеменнән минем өчен оялуларын, борчылуларын әйтеп язган булса кирәк. Зөлфиянең җавап хатыннан шул сизелә. Туганнарча якын итүләре өчен аларга рәхмәт әйтелгән. Аннары төсе-бите белән бик тә миңа охшашлы малае туу турында хәбәр ителгән иде... Менә шундый хәл, дускаем, теләсәң нәрсә уйла, теләсәң ничек аңла...

Ярар, анысы күптән булган хәл, хәзергә калып торсын, алгарак күчик. Ул вакытта без затонга якында гына өч тәрәзәсе күп сулы Идел тармагы Ахтубага караган үз өебездә тора идек. Ишегалдында Алабай дигән бик акыллы чуар этем бар иде. Бичаракай онытмаган, капкадан үтүгә танып алды, чиный-чиный сырпалана башлады.

Ишекне ачып өйгә керсәм, кухняда күрмәгән-белмәгән яшь кенә бер хатын пешеренеп йөри. Ачык изүле зәңгәр халат өстеннән ак алъяпкыч бәйләгән, куе чәчләрен артка яткырып тараган. Ул мине ярдәм сорап килүче авыру кеше дип уйлады бугай, күрү белән:

– Медпунктта дежур сестра юкмыни, кай төшегез авырта? – диде рус телендә.

– Минем бер җирем дә авыртмый, аягым төзәлеп килә, – дидем һәм үземнең кем икәнлегемне әйттем.

Ул да үзенең кем икәнлеген әйтте, шинелемне салырга ярдәм итте. Шулай танышып алгач, аяк өсли генә сөйләшкән арада, мин аның Елизавета Николаевна исемле икәнен, затон медпунктында дежур сестра булып эшләвен белдем. Ире Севастополь портында кранчы, сугышның беренче төнендә бомба шартлаудан һәлак булган. Ә Елизавета үзе бер төркем ятим балалар һәм ундүрт яшьлек энесе белән бергә эвакуацияләнеп бирегә килгәч, апалы-энеле боларны фатирга безгә керткәннәр. Энесе Федор безнең Хәбиб белән яшьтәш, мәктәптә бер класста укыйлар икән.

Озакламыйча, шау-гөр килеп, алар үзләре дә кайтып керде. Икесе дә яланбаш, тузгый чәч җибәргәннәр. Хәбиб сизелерлек үсә төшкән, өстендә минем иске бушлатым. Ачык йөз белән кулымны кысып исәнләште һәм шунда кинәт нидер хәтерләгәндәй, кашларын җыерып куйды. Аннары сабакташына борылып:

– Федор, таныш бул, бу минем абыем Мирза, фронтовик, – диде, чырае тагын да караңгылана төште.

Күренеп тора, һаман Зөлфия өчен гафу итми.

Ә Лизаның энесе – гел елмаеп торган кебек ачык йөзле, бик тә хәрәкәтчән үсмер – яшькелт тышлы сырмасын тиз генә ишек янындагы ыргакка элеп куйды да:

– Шулаймы, чын фронтовикмы?.. – дип, минем белән ике куллап күреште. – Менә гаҗәп, Хәбиб, син шундый фронтовик туганың булуын бер дә әйткәнең юк иде бит.

Кара син аны, бөтенләй онытկан шикелле бит, әйтерсең мин аның абыйсы түгел. Эт булып эт онытмаган, ә бертуган энем искә төшереп телгә дә алмаган… Бик авыр булса да, үпкәләп булмый, әлеге дә баягы һаман Зөлфия аркасында.

Без, кулларны юып, өстәл янына утырган арада, Лиза, өйгә тәмле ис таратып, тәлинкәләргә уха салырга кереште. Мин госпитальдән паекка алган икмәк белән шикәрне дә өстәдем, шәпләп сыйландык.

Федор бик төпченүчән икән, чәй янында сугыш хәлләрен сораштыра-сораштыра аптыратып бетерде. Тик бераздан, түр якта йокларга яту алдыннан өсне чишенгәндә, минем агач аякны күргәч кенә аптыраулы кыяфәттә тынды.

Хәбиб табын яныннан элегрәк торып киткән һәм без түр якка чыкканда, ул инде йоклап ята иде. Шунда ачык ишектән төшкән ут яктысында аның караваты янында стенага эленгән рамкалы фоторәсемгә күзем төште. Кем рәсеме икәнен белергә теләсәм дә, ярым караңгыда барып карарга уңайсызландым, иртәгә яктырткач карармын дип уйладым.

Юл кайтып арылган, күрәсең, иртәгесен мин соң уяндым. Яшьләр ашап-эчеп инде мәктәпкә киткән, Елизавета алгы якта өстәлне җыештырып йөри иде. Хәбибнең пөхтә итеп җыелган караватына карау белән, кичә кич күргән теге фотоны хәтерләдем. Әмма бүген рәсем юкка чыккан, аның урынында стенада түгәрәк эшләпәле тимер кадак кына тырпаеп тора иде.

Мин Лизага:

– Кичә кич монда рамкалы фоторәсем бар иде, бүген юк булган, – дип әйттем.

– Әйе, ике хатын-кыз янәшә утырып төшкән фото бар иде, – диде Елизавета, карават янына килеп карап. – Аларның берсе инде карчык кеше, Хәбиб аны әнием дигән иде. Икенчесе – тез башына бала утыртып төшкән сөйкемле яшь хатын. Хәбиб монысы туганнан туганыбыз дип әйтте бугай.

Елизавета эшкә киткәч, тамакка капкалап алдым да ишегалдына чыктым; Алабай белән бергә каралты-кураны, бакчаны күздән кичердек.

Шундый கояшлы матур көнне өйдә утырып буламыни, яр буйлап затонга таба киттем. Аягым юклыгы бик сизелмәсен дип, мөмкин кадәр аксамыйчарак атларга тырышам. Ахтубада ишелеп-актарылып боз китүгә, затонда эш кайный.

Борыннары белән ярга терәлеп тезелгән буксир пароходлар арасыннан үземнең «Донбасс»ны ерактан күреп алдым. Эчке дулкынлану белән палубага менгәч, ничектер уңайсыз булып китте, ичмаса, бер генә танучы булсын үземне! Бөтен команда алмашынып беткән: карт-коры да хатын-кыз. Шулай да үзләре тырышканнар, пароходны ремонтлап, әзерлек хәленә керткәннәр, Иделгә чыгарга капитаннары гына юк. Минем былтыр монда эшләгәнемне белгәч, әйдәгез, безгә капитан булып килегез дип, үгетләргә тотындылар. Караванкада затон капитаны да хәл-әхвәлне белешкәннән соң шуны әйтте. Кызыктыргыч тәкъдим бит, шундук риза булдым. Әмма больницада врач протезны күрү белән кычкырып көлде генә. Капитанлыкка рөхсәт бирү урынына, коры җирдә җиңелрәк эш сайларга киңәш итте. Кая барып сугылырга белмичә аптырап калдым, йокым качты.

Нәкъ шул чакны безнең күршебез, яше җитмештән узган маякчы бабай авырып китте, эшкә чыга алмаслык бетәште. Беркөн шулай хәлен белергә кереп, төрле сүз арасында үземнең зарымны әйткәч, бу, минем хәлемә кереп:

– Безнең идарәдә миңа алмаш таба алмыйлар, – диде. – Тот та шунда кер. Барып-кайтып йөрергә дә ерак түгел, рәхәтләнеп эшлә.

Башка чара юк, күрше бабай киңәше белән маякчы булып кердем. Мине пристаньга якында гына, Ахтуба тармагы белән Идел арасындагы утрауда урнашкан постка маякчы итеп билгеләделәр. Мәктәптә укулары тәмамлангач, Хәбиб белән Федор килеп кул астына керә башлады.

Безнең будка утрауның түбәнге очында яр кырыена урнашкан. Түр тәрәзәдән караганда төп елга үзе дә, Ахтуба тармагына керү фарватеры да ачык күренә. Эше дә әллә ни авыр түгел: кич эңгер төшкәндә фонарьларны көймәгә төяп, тиешле урынга куясы да ут кабызасы; иртән, яктыргач, барысын да җыеп кайтасы да куыкларны чистартасы, керосин саласы. Миңа көч килмәсен дип, боларны гадәттә яшьләр башкара. Ә мин яр өстендәге мачтага перекатның тирәнлеген күрсәткеч сигналларны эләм, запас ишкәкләр ясыйм, талчыбыктан сөкә үрәм. Балык ярыйсы эләгә, күбрәк шуның белән тукланабыз.

Дежурлыктан буш көннәрне Елизавета килгәли, су буенда савыт-сабаны ком белән ышкып чистарта, өйне рәткә кертә. Ул, гомумән, эшкә уңган, тырыш булып чыкты: балыкны әле кыздырып, әле каклап яки уха пешереп төрләндерә, икраны тәмле итеп тозлый белә; үзебездән арткан балыкны ара-тирә пристаньга илтеп саткалый.

Баштарак Елизавета мине читсенә, өйдә икебез генә булганда сүзсез кала иде. Шулай да торабара акрынлап ияләште, бер хәтәр вакыйгадан соң, аның тартынуы бөтенләй юкка чыкты.

Ул чакны көн буе бездә булганнан соң, Елизаветага өйгә кайтырга кирәк иде. Аны Ахтуба аша көймәдә аргы якка чыгарырга мин үзем алындым. Җилле-яңгырлы кич булса да, яр буенда ышык-

та алай хәтәр түгел күк иде. Кузгалып киткәч, ачык су өстендә давыл көчле булып чыкты, ярсу дулкыннар көймәне чөеп уйный, баштанаяк коендыра; койрык якта ике куллап көймә читләренә ябышып утырган Лиза да, Алабай да шомланып шыңшый башладылар. Ә үзем Лизаны тынычландырырга тырышам:

– Курыкма, берни булмас… Әнә яр буена чыгып җитәбез, – дип, бар көчемә ишкәк ишәм.

Шул мәлне каяндыр бик якыннан гына нәрсәнеңдер ажгырып якынаюын ишеттем. Мин аның нәрсә икәнен абайларга да өлгермәдем, караңгыда ниндидер сигналсыз катер зур тизлектә барган шәпкә яны белән бәреп, көймәбезнең астын өскә әйләндереп үтте.

Су өстенә калкып чыгу белән көймәгә тотындым. Алабай да шунда дулкыннар арасында кайнаша. Ә Лиза юк. Әйләнә-тирәдән эзлим, кычкырып та карыйм, ул һаман юк. Су төбенә китүеннән куркып котым алынды… Алабай да ачыргалана, никтер көймә астына кермәкче итенә. Аннан күреп шундук үзем дә шәйләп алдым: Лиза көймә астында капланып калган булып чыкты. Аннан коткарганда, ул ярым һушсыз хәлендә иде, мин аны яр буена көчкә алып чыктым… Дулкыннар арасында бата-чума йөзгәндә, аягымның протезга кырылып яман чиләнгәнен шунда гына сиздем.

Әлеге давыллы кичтән соң, Лиза сизелерлек үзгәрде. Миңа сез дип түгел, син дип эндәшә, көлемсә карап сөйләшә торган булып китте. Аңа карап мин дә елмаям, күңелем күтәрелүен сизәм.

Озын сүзнең кыскасы, без бер-беребезгә гашыйк булдык. Яңа гына дәрт кергән яшүсмер кебек, аның килгәнен түземсезлек белән көтәм, аргы якта яр өстеннән кул изәгәнен күрү белән, аны үзем көймәдә чыгып каршылыйм.

Безнең якынлыкны яшьләр, әлбәттә, сизәләр. Федор – киң күңелле егет – каршы түгел, мөнәсәбәте җылы, апасы белән миңа бәхетле гаилә тормышы теләве күренеп тора. Ә Хәбиб, киресенчә, отыры салкыная төште, хәзер инде бер миңа гына түгел, хәтта Лизага карата да ничектер кырысланды сыман.

Җитмәсә, үч иткәндәй, караваты янына стенага тагын теге фоторәсемне элеп куйды бу… Күрү белән күзләрем шар булды. Рәсемдәге ике хатын-кызның берсе – безнең әни, икенчесе – минем аерган хатыным… Зөлфия тез башына куе чәчле малай утыртып төшкән. Үзем дә көтмәгәндә: чү, бу бөтеркәч минем туган балам була ич дип, кинәт исәнгерәп калдым һәм, Лиза күрмәсен дип, карточканы алып тиз генә яшереп куйдым. Бу рәсемгә алар, мөгаен, мин фронтта чакны очрашып төшкәннәр булса кирәк.

Хәбиб, стенада карточканың юклыгын күрүгә:

– Мондагы әни карточкасын син алдыңмы?.. Хәзер үк урынына куй… – диде, кашларын җыерып.

Бүтән чакны мин ул малай актыгына абыйсы белән алай дорфа сөйләшергә ирек бирмәс идем. Бу юлы хаклык аның ягында булгангамы, ничектер уңайсызланып калдым, авызын капларлык сүз таба алмадым.

– Анда әни үзе генә түгел, син шуны аңларга тиеш, – дип акланырга тырыштым. – Инде аерылган чит кеше рәсеме, күз көеге кебек, монда эленеп торуы ни пычагыма кирәк!

– Нигә чит булсын… Әнидән тыш анда тагын синең улың да бар бит, әллә ул да чит кешеме?.. Әни соңгы сулышына кадәр алар турында борчылды, аларны ташлама, дип, миңа васыять әйтеп калдырды.

Менә шундый хәл, дускаем, теләсәң нәрсә уйла, теләсәң ничек аңла…

Мирза, сүзеннән туктап, елганың үр ягына борылып карады: «Әнә үзе килә, безнең теплоход… Әйдә, пристаньга төшик», – диде.

Кичке караңгы төшкән вакыт. Көндезге бөркүдән соң, су буенда салкынча-дымсу һаваның сафлыгы рәхәт җиңеллек бирә.

Дебаркадер палубасын юеш швабра белән сөртеп маташучы хатын-кыз матрос, эшеннән туктап, Мирзага ихтирамлы сәлам бирде. Шунда каяндыр килеп чыккан кәттә кыяфәтле пристань начальнигы да кул биреп, исәнлек-саулык телим сезгә дип сәламләде.

Менә яңгыравык тавыш белән гудок кычкыртып, су өстендә күбекле дулкыннар кузгатып, дебаркадер янына кечерәк кенә ак теплоход килеп туктады. Пассажирлар йөртүче түгел, фарватерны караучылар судносы икәне күренеп тора: алгы һәм арткы палубасына конус сыман очлы йөзмә маяклар, ацетилен баллоннары төягән.

Бу теплоход капитаны да Мирзаны кадерле кунак кебек олылап каршылады һәм палубага аяк басу белән безне кызыл почмакка алып керде.

Кызыл почмак дигәннәре кирәк вакытта ашханә урынына да хезмәт итә икән. Стеналары матур плакатлар, пейзажлар белән бизәлгән. Ак халатлы кунакчыл кок хатын безнең алга өстәлгә графин, ике кружка китереп куеп:

– Эсседә тамагыгыз кипкәндер… Кичке аш өлгергәнче менә салкын квас, сусавыгызны басыгыз, – диде.

Пристань һәм теплоход кешеләренең Мирзаны бу тикле хөрмәтләүләре миңа ничектер сәер тоела башлады. Кызыл почмакта икебез генә калгач, мин аңа:

– Сине монда яхшы беләләр, бик хөрмәт итәләр икән, уч төбендә генә йөртмиләр, – дип әйттем.

– Әйе шул, шуның белән теңкәгә тияләр. – Мирза үзеннән-үзе көлгәндәй, көенечле елмаеп куйды. – Син нәрсә, бу теплоходның исемен күрмәдеңмени?.. Алайса ярар, ашыкма, бераздан мин сөйләгәннәрдән анысы да ачыкланыр.

…Сугышның инде икенче елы булса да, навигациянең беренче яртысы әйбәт кенә барды, пароходлар тәүлек буе туктаусыз йөри бирде, без дә зарланырлык бәла-каза күрмәдек. Әмма җәйнең икенче яртысында фронт безнең якка да якынайды. Сталинградка килеп җиткәнче үк әле дошман авиациясе Иделнең түбәнге агымында безнең кәрваннарны аяусыз тупка тота, ул ташлаган миналарга эләгеп, нефть кәрваннары шартлый, зур-зур пароходлар тулы пассажирлар һәлак була башлады, бөтен флот төнге караңгыда эшләүгә күчте.

Мондый шартларда, табигый, безнең эш тә катлауланды, күп кыенлашты. Көндезләрен туктаусыз күзәтеп торырга һәм, мина төшкән урыннарны үзебез ясаган пеленгатор белән билгеләп, шундук тральщиклар базасына хәбәр итәргә кирәк. Ә төннәрендә кәрваннарны көймәдә чыгып каршылыйбыз, хәвефсез юл күрсәтеп, участок аша озатабыз.

Күпертмичә әйтәм, начальство да эшебездән канәгать була, еш кына күрше участокларга үрнәк итеп мактыйлар иде.

Хәлләр авыр, эш күп булса да, Лиза белән мин – чиксез бәхетле, сугыш бетүгә өйләнешергә сүз куештык. Минем исәп алай сузмаска иде. Әмма ул килешмәде: «Вакыты кулай түгел, дошманны җиңгәч тә өлгерербез», – дип, кичектерергә киңәш итте.

Август ахырларында дошман безнең участокка бигрәк тә каныкты, көн саен икешәр, өчәр мәртәбә килеп мина ташлый башлады. Августның утыз бере көнне дә шулай булды. Төштән соң өйдә чирек сәгать черем итмәгәндер, якында гына баш очында самолет үкергән тавышка уяндым. Тиз генә торып өйдән чыгарга өлгермәдем, Федор йөгереп кереп, фашист козгыны фарватерга мина ташлады, дип әйтте.

Шундук Хәбибне көймә белән пристаньга телефоннан тральщиклар базасына хәбәр итәргә җибәрдем. Үч иткәндәй, нәкъ шул мәлне түбән якта борылыш артыннан зур-зур ике ак пароход килеп чыкты. Бинокльдән күрәм: икесе дә талчыбыкка төрүле, гаскәриләр белән тулы. Әһә, мин әйтәм, хәйләкәр фашист миналары боларга адарынып ташланган икән. Мачта очына тиз генә ике кызыл конус элеп, пароходларга туктарга сигнал бирдек.

Озакламыйча базадан кечерәк кенә тимер баржа таккан «Маякчы» теплоходында тральщиклар килеп җитте. Безнекеләр яр өстендә торып калды, үзем өлкән маякчы буларак, тральчыларга мина төшкән урынны күрсәтергә киттем. Теплоход алдан бара, корпусы магнитсыз булганга, аңа мина куркыныч түгел. Су төбендәге магнитлы мина безнең арттан килүче траллау баржасын шартлатырга тиеш.

Елга үзәге буйлап түбән таба да, агымга каршы да узабыз, тагын һәм тагын үтәбез, барыбыз да тын да алмыйча тральчы баржага карап барабыз. Мәгәр мина һаман табылмый, без түземсезлек белән көткән дәһшәтле шартлау яңгырамый.

Тральчылар командиры, запастан чакыртылган урта яшьләрдәге лейтенант, каш астыннан миңа ризасыз карап, нервылана башлады:

– Монда юк минаны эзләп су сукалауда ни мәгънә… Әйт әле, ул минаның кай турга төшкәнен үз күзең белән ачык күрдеңме, кирәкмәскә башны әйләндермисеңме?

Уңайсыз булса да, дөресен әйтергә:

– Юк, үзем түгел, энекәшем күрде, шуның вахтасы иде, – дип акланырга мәҗбүр булдым.

Эшне туктатып, кире кайтырга туры килде. Ә түбән очта без туктаткан пароходлар кузгалырга рөхсәт сорап, әледән-әле гудок кычкырта башладылар.

Болай булгач, аларны тоткарлауда мәгънә юк, тегендә Сталинград гаскәр көтә, корал көтә иде. Әнә шулай уйлап мачта очына рөхсәт сигналы – кызыл конус белән кара цилиндр күтәрергә керештем.

Шунда Хәбиб каршы төште:

– Тукта, күтәрми тор… Сез анда мина төшкән турдан читтәрәк йөрдегез шикелле. Аз гына сабыр ит, мин үзем барып күрсәтим әле.

Мин үзем риза булмасам да, тральщик командиры каршы килмәде:

– Дөрес әйтәсең, энекәш, мондый эштә эштер-өштер генә ярамый… Әйдә, кузгалыйк.

Без өчебез дә будка каршында торып калдык, «Маякчы» тагын тимер баржасын тартып кире китте. Бу юлы ул без йөргән турдан шактый сулданрак китеп барды һәм, ак бакен янынннан үтүгә, аның корпусы астыннан болганчык су өермәсе бәреп чыкты, гөрселдәп шартлау дулкыны һаваны тетрәтте.

Берничә минуттан без көймәдә барып җиткәндә, «Маякчы»ның арткы ягы суга иңә төшкән, матрослар, берсен-берсе ашыктыра-ашыктыра, аның корпусындагы зур гына тишекне киндер пластырь белән каплап маташа, капитан күперчегендә тральщик командиры биноклен як-яка юнәлтә-юнәлтә су өстендә нидер эзли иде. Мин, өскә менү белән:

– Менә бәла, арткы палубада тральга карап барган җирдән сезнең егет юкка чыкты бит, – диде ул дулкынланып. – Мин үзем менә шунда идем, мина шартлаудан күтәрелгән өермә баганасы өстемә ишелеп аяктан екты, суга төшүдән көчкә тотынып калдым. Тиз генә аякка басып караганда, егет инде юкка чыккан, нәкъ ул торган турда теплоход борты умырылып тишелгән иде.

Ул көнне без Хәбибне караңгы төшкәнче эзләдек, әмма таба алмадык. Иртәгесен күрше участоктан килеп әйттеләр: агым су аның үле гәүдәсен бездән түбәнге участокта комаяклы яр буена илтеп салган иде.

Бу авыр фаҗигане башына сыйдыра алмыйча, Мирзаның сүзен бүлеп сорадым:

– Аңлашылмый… «Маякчы»ның корпусы магнитсыз булгач, мина ник аның астында шартлаган икән?

– Әйе, барыбыз да шулай уйлаган иек, – диде Мирза. – Моңарчы фашист һаман магнитлы мина ташлады, без шуны зарарсызлап килдек. Ә бу юлы, бәхетсезлеккә каршы, бүтән төр мина, мотор гөрелдәүдән шартлый торган акустик мина булып чыкты…

Безнең батыр йөрәкле Хәбибебез әнә шулай, үзен корбан итеп, гаскәри эшелон төялгән зур пароходны юлда һәлак булудан коткарып калды. Аның бу батырлыгы телдән телгә күчеп, бөтен Идел буена таралды, ул хакта газеталарда яздылар… Минада шартлаган теплоход ремонттан чыккач, Хәбиб истәлеген мәңгеләштерү максаты белән аңа «Маякчы Шәмсиев» исеме бирелде. Күрәсең, ул әле дә булса әйбәт кенә йөри бирә.

Мин Хәбибне Ташлыяр зиратына илтеп, әни кабере белән янәшә җирләдем… Шул көзне үк икесенең дә баш очына яшь каен утырткан идем. Кырык биш ел эчендә зур булып үстеләр, бөтен әйләнә-тирәгә ямь биреп, үзара гәпләшкәндәй, акрын гына лебердәп торалар. Быел җәй башында алар янында үземә дә урын билгеләп, барысын бергә чардуган белән ураткан идем. Менә бүген шуны буяп кайтып килүем.

Гаҗәп хәл, еш искә алганга булса кирәк, кайчак Хәбиб үлмәгәндер, вакытлы рәвештә каядыр киткән кебек тоела, аның теплоходын күргән саен, үзен очраткандай булам. Менә хәзер бирегә кереп утыргач та, йөрәк телгәләнә, әллә кайчангы хәсрәтле уйлар кузгала.

Мин кинәт гаҗәпләнү белән:

– Пристаньда караңгыда исеменә игътибар итмәгән идем, бу – шул теплоходмыни?! – дидем, Мирзаның сүзен бүлеп.

– Әйе, «Маякчы Шәмсиев» шушы. Аңа бу исем Флотилия Хәрби Советы приказы белән бирелде. Менә хәзер мине ник хөрмәтләүләрен аңладыңмы инде?.. Бүген пристаньнарда да, затонда да шулай, Хәбибкә тиешле хөрмәтне миңа кабул итәргә туры килә. Ничектер алдашу сыман килеп чыга. Шуның өстенә туган-тумачасыз, ялгыз яшәү үзәккә үтә.

– Нишләп ялгыз?.. Син Лиза белән өйләнешергә җыенганыгыз турында әйткән идең ич.

– Ул ният барып чыкмады, Лизага әллә ни булды, – дип, Мирза кул гына селтәде. – Хәбиб һәлак булганнан соң, ул безнең постка сирәгрәк йөри башлады, миңа карата ни сәбәптер суына башлады. Ахыр чиктә мине кызганып булса кирәк, үзенә хас ягымлылык белән:

– Мирза, син мине дөрес аңларга тырыш, – диде. – Сугыш хәлләрен үзең дә беләсең. Беркөн военкоматка чакыртып учетка алдылар, кичләрен медсестралар курсына укырга йөрергә куштылар. Озакламыйча алып куюлары да ихтимал.

Тиздән аны, дөрестән дә, армиягә алып, фронтка җибәрделәр. Соңыннан медпункт кешеләреннән ишетеп белдем, Лизаны военкомат чакыртып алмаган, ул үз теләге белән киткән булып чыкты.

Менә шундый хәл, дускаем, теләсәң нәрсә уйла, теләсәң ничек аңла.

Кичке аштан соң без, өске палубага чыгып, эскәмиягә утырдык. Теплоход төнге тынлыкта алга бара. Вахта кешеләре үз эшләре белән мәшгуль: начар күренә торган маяклар очраса, туктап, баллонны алмаштыралар, давыл кузгатканнарын тиешле урынга күчереп куялар да, юл уңаена борылып, тагын китеп баралар. Мирзаның сүзсез утыруы озакка сузылгач, мин аңа:

– Сугыштан соң гомерең шул постта үттеме? – дип сорау бирдем.

– Юк, сугыш беткәнче үк әле аннан алып, мине пристаньда причал начальнигы, аннары диспетчер итеп куйдылар. Байтак еллар Баскунчак тозын баржаларга төяп озатуда эшләдем. Үземчә болай тырыштым шикелле. Орден белән бүләкләндем, сугышта катнашкан өчен медаль дә бирделәр. Ул җәһәттән бер дә кешедән ким-хур түгел, зарланырга урын юк.

Әмма мин, ялга чыкканнан бирле, дәваланып булмый торган авыр чир – йокысызлык чире белән җәфа чигәм… Искитмәле хәл: башны мендәргә төртүгә йокыга китәм дә шундук саташулы төш дөньясына чумам… Бик озак йоклаган кебек иләс-миләс уянып китсәм, күп дигәндә, ярты сәгать үткән була. Аннары инде күзгә һич йокы керми, төштә күргәннәрне төрлечә юрап, төрлечә уйлап ята-ята, баш түнеп бетә.

Үзең беләсең, хәзер уйланырлык, баш ватарлык нәрсәләр аз түгел. Тормыш күз алдында үзгәреп тора. Кайчандыр без изге санаган кайбер шәхесләр яман залим булып чыкты, каторгага сөрелгән «халык дошманнары»ның гөнаһсыз корбаннар икәнлеге ачылды.

Бу искитмәле үзгәрешне мин үз күзем белән күрдем, башымнан кичердем. Шуннан элек кенә «Зур Идел» газетасында безнең техникумга сиксән ел тулу уңае белән очрашу үткәреләчәк, анда укып чыгучыларны очрашуга чакырабыз дип язылган белдерү укыган идем. Ничектер күңелем җилкенеп китте. Тукта, мин әйтәм, яшьлек елларым үткән шәһәрне, бергә укыган дусларны күреп кайтыйм дип, Казанга бардым, үзәк мәйданда күтәрелгән мәһабәт «Татарстан» кунакханәсендә туктадым. Заманында мин театрал идем бит, бу юлы да беренче кичне үк театрга барырга булдым. Шул ният белән вестибюльгә төшкәч, афишада Зөлфия әтисенең исемен күреп шаккаттым. Бүген кич аның пьесасы куелачак икән.

– Бу тыелган пьесаны куярга ничек батырчылык иткәннәр икән?.. – дип, үзалдыма әйтеп куюымны сизми дә калдым.

Шунда минем белән янәшәдә афишага карап торган урта яшьләрдәге ир кеше, гаҗәпләнеп:

– Белмисезмени, ул хаксызга гаепләнгән булып чыкты бит. Инде акланды, пьесалары һәркайда куела, – диде.

Бу сүзләрдән, кинәт миңгерәгәндәй, зиһенем чуалды. Бераз аңыма килгәч, әле һаман башыма сыйдыра алмыйча: дөресен әйтәсезме, чынлапмы? дип сораудан чак тыелып калдым. Моннан соң инде театрга барырга аягым тартмады. Киосктан газета алдым да, үзем генә калырга, тынычланырга теләп, номерыма кереп бикләндем... Әмма барыбер тынычлык тапмадым. Бераздан, буфетта тамак ялгап кергәч, йокы алдыннан газетаны карый башлауга, тагын шул спектакльгә, төгәлрәге, аны бик мактап язылган зур рецензиягә тарыдым. Ул төнне йокым йокы булмады, әллә нинди буталчык төшләр күреп саташып чыктым.

Иртәгесен телефоннан шылтыратып белдем, очрашу кич белән Зур драма театры бинасында булачак, моның өчен техникумга барып регистрация үтәргә кирәк икән.

Хәзер техникум, без укыган вакыттагы кебек, склад сыман шыксыз бинада түгел, яңа урында бишәр катлы мәһабәт корпуслары белән үзе бер шәһәрчек булып чыкты. Уку корпусының парадный ишегеннән иркен вестибюльгә барып керүгә, каршы яктагы стеналарда техникумны тәмамлаучы атаклы кешеләрнең, хезмәт алдынгыларының портретлары. Очрашуга килүче һәркем иң әүвәл үз сабакташлары янында туктала. Безнең курсташлардан Советлар Союзы Герое Михаил Девятаев белән новатор капитан Кәбир Ибраһимов рәсемнәре куелган.

Бераз читтәрәк, махсус стендта, атказанган педагогларның рәсемнәре. Шулар арасында көтмәгәндә үземнең яшь чагында төшкән сурәтемне күреп, бик аптырап калдым. Рәсем астындагы язуны укыгач кына, ул кешенең мин түгел, хәзерге вакытта корабльләр төзү теориясеннән укытучы икәнен белдем. Аннары үзе безнең милләт кешесе булса да, аның фамилиясе, инициаллары да бөтенләй бүтән иде.

Шулай да бу охшашлык миңа бик сәер тоелды һәм дулкынландырды. Канцеляриядә килгән кунакларны теркәүче шактый өлкән яшьләрдәге ханым ул педагогның үзен дә, әнисен дә якыннан белә, алар белән күршеләр икән. Минем читләтебрәк кызыксынып сораштыруыма, сүзчән ханым ачык йөз белән:

– Хәбиб Салихович безнең студентларның иң яраткан педагогы, – диде. – Аның әтисе Салих абый фронтта һәлак булды. Әнисе Зөлфия апай да безнең техникумны тәмамлаган кеше. Берьялгызына кыен булса да, улын укытты, кеше итеп үстерде. Хәбиб үзе дә молодец, әнисенең өметен аклады. Башта безнең техникумны, аннары су транспорты институтын «бик яхшы»га тәмамлап, хәзер үзе бездә укыта.

Стендтагы сурәтне күргәч тә, башымда шундыйрак фараз туган иде, фамилиясе бүтәнчә булганга гына бераз шигем бар иде. Әнисенең исемен дә атап әйткәч, икеләнергә урын калмады: үземә охшаган бу чибәр ир-егет минем улым булып чыга бит...

Минем эчке халәтем йөземә чыктымы, әллә Хәбибкә охшашлыгымны төсмерләп алдымы – регистратор ханым миңа ничектер сәерсенү белән текәлебрәк карый, кайда, ничек гомер итүемне җентеклерәк сораштыра башлады... Ярый әле шул мәлне канцеляриягә гөрләп бер төркем кунаклар килеп керде. Регистратор ханым алар белән маташкан арада, мин шыпырт кына чыгып тайдым. Бик каушаган булуыма карамастан, вестибюльне үткәндә туктап, теге сурәткә кабат карадым һәм аның бөтен төс-кыяфәте коеп куйган мин икәнен тагын бер күрдем. Хәтта бит чокырлары, иягендәге ясмык хәтле генә түгәрәк миңе дә – барысы да минеке.

Анысы да монысы, сәгате-минуты белән монда Зөлфия үзе килеп чыгуы, бергә укыган сабакташлар очравы да ихтимал бит. Теге дөньядан әйләнеп кайткан тере мәет кебек, мондый хәлдә алар күзенә ничек күренәсең, ни дип әйтәсең?.. Үземне һәм улымны, аерган хатынымны уңайсыз хәлгә куюның, инде әллә кайчан онытылган имеш-мимеш гайбәтләрне кабат кузгатырга этәргеч бирүнең нигә кирәге бар?! Һәм мин Зур театрга кичке очрашуга бармаска булдым, шул ук көнне беренче очраган поезд белән кире кайтырга чыктым.

Шәһәрдә әллә ни сизелмәгән иде, поезд кузгалганда вагон тәрәзәсеннән карауга кинәт бик ямансу, үземә-үзем кызганыч булып китте. Кайчандыр Зөлфия белән кулга-кул тотынып йөргән Кремль тауларын, Казанка буйларын күреп күңелем тулды. Хәзер дә уйласам, ис-акылларым китә, үз бәхетемне үзем җимердем бит, ялгыз бүре кебек, бер башым торып калдым, һичкемгә кирәгем юк.

Шулай да моңарчы мин бик бирешмәдем. Бер мин генә түгел, тормыш шулай кушты дип, үз-үземне юата идем. Бактың исә, һәркем минем кебек коелып төшмәгән. Әнә этисе репрессияләнгән Зөлфиягә курыкмыйча өйләнүче, баласын уллыкка алучы киң күңелле кыю кеше дә булган бит. Әнием белән энекәшем Хәбиб тә авыр көннәрдә Зөлфиягә терәк булырга тырышканнар. Зөлфия дә җавапсыз калмаган, рәхмәт йөзеннән улына Хәбиб исемен кушкан... Хәзер, ул көннәрнең аянычлы истәлеге булып, алар әни белән өчесе бергә төшкән фоторәсем генә калды.

Гомер онытасым юк, мин малай чакны безнең авыл читендә, яшел чирәмле калкулыкта зур ябалдашлы мәһабәт имән бар иде. Җәй көннәрендә ул төрле кошлар сайравына күңелле шаулап тора. Көндезләрен без бала-чага шунда мәш киләбез, кичләрен яшьләр җыелып күңел ачалар. Озын сәфәргә чыгучыларга, хәерле юл теләгәндәй, яшел яулыгын болгап озатып кала; еракларлардан туган авылны сагынып кайтучыларны, ерактан күреп, якты чырай белән шул каршылый иде. Шуңа да авыл халкы аны ярата, җырларына кушып җырлый. Безнең Хәбиб аның матурлыгын данлап бик дулкынландыргыч шигырь дә язган иде.

Көннәрнең берендә, төгәлрәге, хәтәр җил-давыллы караңгы төнне яшен сугудан шул имән янды, өтек ботаклары як-якка тырпайган кара күмерле кәүсә генә торып калды, аннан кош-корт кына түгел, бөтен авыл бизде.

Бу вакыйга халыкта авыр тәэсир калдырды. Хорафатларга ышанучан әби-сәби аны төрлечә юрады, бәла-казасы тимәсен дип, садакалар адарынды. Без, бала-чага, аңа карамыйча үтәргә тырыша идек... Менә хәзер, картлык көнендә мин дә шул котсыз кара агач кебек калдым, дөньяда һичкемем юк.

Мирза соңгы сүзләрен эчке ачыну белән ишетелер-ишетелмәс пышылдап әйтте, хәле беткәндәй, башын түбән иде.

Шулчак безнең баш очында гына кинәт гудок кычкыртып җибәрде. Күтәрелеп карасак, Владимировка пристанена якынаеп киләбез, имеш. Сүз белән мавыгып, таң атканын да сизми калганбыз.

«Маякчы Шәмсиев» теплоходы бирегә берничә минутка, Мирзаны төшереп калдырырга гына туктады. Төнге вахтада торучы капитан аны: «Онытып бетермәгез, тагын килегез», – дип, җылы озатты, полиэтилен пакет белән күчтәнәчкә берничә сазан балыгы да бирде. Мин Мирза белән киләчәктә элемтәне өзмәскә, хат язып торырга сүз куешып аерылдым.

Теплоход елга уртасында агым уңаена борылгач, мин рубкага менеп бинокльдән караганда, Мирза инде яр өстендә тора, иртәнге алсу таң фонында аның ялгыз силуэты бая үзе сөйләгән яшен суккан каен төсле караеп шәйләнә иде.

...Иртәгесен Әстерханнан кире кайтышлый Ташлыяр буеннан узганда, мин тагын шагыйрә Газизә Сәмитованы хәтерләдем: менә, ичмасам, каһарман зат, гадәт-йола, шәригать законнары изге саналган иске заманда хатын-кыз башы белән, яратмаган деспот иреннән аерылып, үзенең шәхси һәм иҗатка хокукын саклый алган бит. Ә менә минем сабакташым Мирза, авыр сынау көннәрендә үзен-үзе ихтыяри сөргенгә дучар итеп, тормышын харап иткән, сөйгән хатыныннан, бердәнбер баласыннан мәхрүм калган. Күркәм медсестра Елизавета белән дә гаилә кора алмаган. Ник алай килеп чыккан? Моның тамыры кайда, сәбәбе нәрсәдә?.. Әнә шундый авыр уйлар, күңелсез сораулар мине еш борчый.

Ә вакыт дигәнең тукталып тормый, үз җае белән тәгәри бирә. Мирза белән очрашканга да инде шактый гомер үтте. Ә мин аңа әле һаман язганым юк, ихтыярсыз суза киләм. Кәгазь, каләм алып өстәл янына утырсам, ни язарга белмичә аптырап калам. Җылы сүзләр белән юатсам, авырткан җиренә кагылып, хәтерен калдырырмын шикелле. Берни әйтмәсәм дә уңайсыз, ничектер игътибар итмәү, битарафлык килеп чыгар сыман.

Ул хакта уйлый башласам, иң әүвәл минем күз алдыма Мирза үзе сөйләгән аянычлы манзара – теге яшен суккан имән килеп баса. Шул ук вакытта батыр йөрәкле Хәбиб тә истә, иртән алсу таң атканда, аның исемендәге ак теплоходта Идел буйлап баргандай, сулыш киңәя, күңелсез уйлар тарала.

Әмма ләкин боларны һичничек әйтеп булмый, хат тагын язылмый кала бирә.

# Сыерчыклар ни дип сайрый?

## I

Кояш көннән-көн ягымлырак елмая, үр-калкулык битләреннән йөгерек гөрләвекләр шаулап ага, елгада су арта. Яр өстендәге өянкеләрдә күптән түгел генә җылы яклардан кайткан кара каргалар шау-гөр килеп оя тибә.

Затонда елгачыларның кышкы квартирлардан теплоходларга, баржаларга күченгән мәшәкатьле вакыты. Кечерәк кенә сары чемодан тоткан повар кыз Нәзифә, соңга калмагаем дигән сыман, җиңел адымнар белән затонга ашыга һәм барган шәпкә әледән-әле үзалдына елмаеп куя. Әйләнә-тирәдәге ыгы-зыгылы җанлылыктан, кояшлы язгы һавадан аның йөрәге җилкенә, үзен җиңелчә исергәндәй хис итә, тизрәк Иделгә чыгарга, хыял кебек иксез-чиксез зәңгәр киңлеккә ашкына ул.

Әнә былтыр җәй ул эшләгән биек корпуслы мәһабәт «Владивосток» теплоходы причалда кояш нурына балкып тора. Нәзифә аны туган-үскән йорты кебек үз итеп яратып өлгергән иде. Причалга якыная барган саен, аның йөрәге ешрак тибә, күңелендә шатлык дулкыны күтәрелә.

Әнә алгы палубада зәңгәр куртка кигән базык гәүдәле бер егет, рулевой Госман Хәйруллин, судан коткару боятләренә кызыл буяу белән теплоход исемен язып маташа. Такта траптан менеп килгән Нәзифәне күрү белән, аның шатлыгы йөзенә чыкты.

– Әһә, менә туйдыручыбыз да килеп җитте. Әйдә, рәхим ит, – диде ул елмаеп. Һәм шундук эшеннән туктап, Нәзифәнең кулыннан чемоданын алды.

Алар исәнләшеп хәл-әхвәл белешкән арада, кайдадыр якында гына кош-корт чыр-чу килгәне ишетелде. Башларын күтәреп карасалар, югарыда рубка өстендә бер пар сыерчык кайнаша, кемдер куйган ояга яр буеннан коры салам, иске яфраклар ташып, ашыга-ашыга торак әмәлли, имеш.

– Карале, рубка өстендә сыерчык оялаган ич, – диде Нәзифә. – Сыерчык ияләшкән йортка шатлык килә, диләр. Шулай булсын, безгә шатлык китерсеннәр.

– Күрми дә торам, чынлап та сыерчыклар ияләшкән,– диде Хәйруллин да гаҗәпләнеп.– Чү, бу ояны капитан оныгына мин ясап биргән идем бит. Өенә алып китәсе урында, ул малай актыгы аны рубка өстенә менгереп куйган булып чыкты. Кай арада сыерчыклар ояны үз итеп тә өлгергән.

Күренеп тора, хәзер сыерчыкларның туйлашу вакыты. Түш һәм муен каурыйлары кояшта утлы-яшелле җемелди, хәрәкәтләре ашкынулы; эштән туктап ял иткән арада, бер-берсенә мәдхия җырлагандай, әледән-әле чут-чут итеп сайрарга керешәләр.

– Госман абый, син ничек уйлыйсың, – диде Нәзифә, – бу сыерчыклар ни дип сайрый икән? Гомумән, берәр нәрсә тоеп, белеп сайрый микән алар?

– Әлбәттә, белеп сайрыйлардыр... Минемчә, алар нәкъ син уйлаган нәрсә турында сайрый бугай.

– Бигрәк инде син... – Нәзифә, урынсыз сүз ычкындыргандай, уңайсызланып калды, битенә җиңелчә кызыллык йөгерде. – Мин берни дә уйламыйча, болай гына әйтүем иде. Ә син шуннан да мөгез чыгарып торасың шунда.

– Мин дә уйнап кына әйтүем, бер дә мөгез-фәлән чыгарып түгел. Әйдә, каютаңның ачкычын бирим. Әйберләреңне урнаштыр да, азык-төлек алырга барырбыз. Склад ябылганчы өлгерергә кирәк, иртәгә иртүк рейска чыгабыз бит.

Теплоходта көндезге ял вакыты, әлерәк кенә завод ашханәсеннән кайткан бер төркем команда вәкилләре, урта люк капкачы өстендә, кояшта тәмәке көйрәтә-көйрәтә, гәп сатып утыра иде. Барысы да былтыр бергә эшләгән таныш-белеш диярлек. Арада купшы гына киенгән җирән мыеклы таныш түгел берәү бар. Быел яңа штурман килә дип әйткәннәр иде, бу мыек шул булса кирәк. Нәзифә, сәлам биреп, уйнак адымнар белән яннарыннан үткәндә, егетләр дусларча елмаеп исәнләште-

ләр һәм повар кызның зифа буена сокланып карап калдылар. Арадан бер озын теллесе, үзенчә мәзәк итеп булса кирәк:

– Менә бу фигура, бөдрә чәч... Моңа якорь салып карасаң да ярый, ягъни исәп өчен генә булса да, – дип, реплика ташлады һәм мәгънәле генә тамак кырып куйды.

Моны ул акрын гына, янында утырган егетләр ишетерлек итеп кенә әйтте шикелле иде. Әмма аны Нәзифә дә ишетте һәм, шундук туктап, ялт борылды:

– Якорь салып караргамы, исәп өченме?! Йә, күрик әле, кем ул шундый кайнар йөрәкле вәсвәсәче?

Кинәт уңайсыз тынлык урнашты. Теге пычрак телле бәндә үзен белгертергә батырчылык итмәде, ахрысы, бүтән сүз уйнатмады, куркакларча посып калды. Башкалары аны уңайсыз хәлгә куярга теләмәделәр, күрәсең, берни дә ишетмәгәндәй-күрмәгәндәй, ләм-мим сүзсез утыра бирделәр.

Нәзифә берничә адым китеп барганнан соң да, әле һаман тынычлана алмыйча, эчке чиркану белән:

– Былтыр бездә мондый затсызлану юк иде, кайсы булды икән бу? – дип, үзалдына әйтеп куйды.

II

Поселок клубы гөр килә, яше-карты шунда җыелган.

Бүген анда зур тантана – навигация ачылу алдыннан затон белән саубуллашу кичәсе. Кышкы ремонт алдынгыларына Мактау грамоталары, кыйммәтле бүләкләр бирделәр. Завод җитәкчеләре, хезмәт ветераннары – карт капитаннар, механиклар иртәгә Иделгә чыгасы командаларга хәерле теләк, үгет-нәсихәтләрен әйттеләр.

Аннары тәнәфестән соң кичәнең икенче бүлеге башланды. Бәйрәмчә киенгән яшь штурманнар, рулевой, матрослар, чәчәкле чуар киемле җиңел хәрәкәтчән кыз-киленнәр вальска бөтерелделәр. Кышлау вакытында табышкан гашыйк парлар ташлашмаска вәгъдәләштеләр, хат язарга сүз куештылар. Буфетта бераз тамак чылатып алган рулевой Хәйруллин гына, бәйсез буйдаклыгы белән горурланган сыман, авыз эченнән һаман бер җырны кабатлап йөри:

Үз башыма хәсрәт итеп,
Яр сөясем калмаган...

«Владивосток» егетләре – үзләре бер артель – Нәзифәгә туктап тын алырга да ирек бирмиләр, әле берсе, әле икенчесе танцыга чакырып кына тора. Яңа штурман Борһанов иң оста биюче булып чыкты. Аның әрсез шаянлыгы, берсеннән-берсе көлдергеч мәзәкләре бушка китми бугай, Нәзифә аңа ягымлырак елмая, аның белән теләбрәк бии. Дөрес, моны ул үзенчә башкаларга бик сиздермәскә тырыша, егетләрнең берсенә дә өстенлек күрсәтмәгән сыман, һәркайсы белән эчкерсез ачык йөзле, дусларча уйный-көлә.

Кичә таралганнан соң, теплоходка кайтканда да шаян штурман һаман Нәзифә тирәсендә булды, бетмәс-төкәнмәс мәзәкләрен, күңелле шаяртуларын туктаусыз сиптерә торды. Аннары яр буена җитәрәк, караңгыда тайгак чокыр-чакыр аша үткәндә, ярдәм иткәндәй, култыклап алды да, төркемнән арттарак калырга теләп, адымын акрынайта төшкән иде. Әмма Нәзифә аның бу ниятен әдәп белән йомшак кына кире какты:

– Иртәгә камбуз эшли башлый бит, иртүк торасым бар, – дип, теплоходка башкалар белән бергә кайтуны мәгъкуль күрде.

Бу кичне ул җыйнак итеп җыештырылган кечерәк кенә каютасында, канатлы уйларга чумган хәлдә, йоклап китә алмыйча озак ятты. Клубтагы күңелле кичә, җилкенеп биюләр, егетләрнең берсеннән-берсе уздырып үзе тирәсендә бөтерелүләре күз алдыннан кабат үтте. Өйдән киткәндә артык бала җанлы әнисе аның өчен борчылу белән, елгачылар шома телле, ышанычсыз тупас халык, берүк алдыңны-артыңны карап йөр, сак бул, дип кисәтеп калган иде.

Бер дә белеп әйтми, әлбәттә, ялгыш уйлый. Нәзифә моны үзе күреп белә. Һәркайда җиңел аралашучан булганга һәм үзләрен артык иркен тотканга гына бераз җилбәзәк күренәләр алар... Шунда ул үзе дә көтмәгәндә кайсыныңдыр көндез палубада әйткән затсыз сүзләрен хәтерләп уйга талды. Кайсы мәнсезе булды икән, бүген клубка барды микән ул?

Шулай да көнозын аяк өсте мәш килү үзенекен итте. Нәзифәне акрынлап татлы талыгу басты, керфекләре авыраеп, күзләре үзеннән-үзе йомыла башлады. Кайдадыр баш очында сыерчык сайрый, колакка ятышлы вальс моңнары яңгырый һәм өн белән төш катнаш дулкыннар кочагында тибрәлеп, ул татлы йокыга китте.

## III

Кар кебек ак калпак, кыска ак халат кигән Нәзифә, иртән каютасыннан чыкканда, кояш инде шактый югары күтәрелгән, теплоход затонның боздан ачык өлешендә салмак кына борылып, хушлашу гудоклары кычкырта-кычкырта, юлга чыгып бара иде. Өске палубада җыелган команда членнары яр буенда озатып калучы туган-тумача белән кул, яулык болгап саубуллаша; бүген алар, кичәге кебек, уен-көлкечел, шаян түгел, барысы да уйчан, басынкы, йөзләре боек иде.

Сыерчыклар исә, киресенчә, ифрат тынгысыз, рубка өстендә ут чыккан кебек тыз-быз киләләр, оя эченә әле кереп, әле чыгып ачыргаланалар. Ул да түгел, берсе, затоннан аерылырга теләмәгәндәй, теплоход кышлаган причалга таба очып китте, икенчесе, оя түбәсендә канатларын җилпи-җилпи, аның артыннан карап калды.

– Ай, иркәге бугай, оясын ташлап китте, – диде Нәзифә, камбуз ишегеннән карап торган җиреннән. – Кара син, ә... Ул кайтмаса, аның артыннан монысы да китүе ихтимал бит.

Бу хәл палубадагы егетләргә дә сәер тоелды, әле берсе, әле икенчесе эткә сыерчык очып киткән тарафка борчулы карана башлады. Рулевой Хәйруллин гына исе китмичә:

– Сыерчык үз оясын, тормыш юлдашын ташлап китә торган җилбәзәк кош түгел,– диде.– Ул болай гына, ияләшкән яр буйлары, төркемдәш сыерчыклар белән хушлашырга киткән булса кирәк. Менә күрерсез, күп тә үтмәс, һичшиксез, очып кайтып җитәр.

– Һи, әйттең сүз, җилбәзәк кош түгел, имеш,– диде штурман Борһанов, үртәүле көлеп.– Кайтты ди, тот капчыгыңны. Беркатлы сабый кебек син, тузга язмаганны сөйләп торасың шунда.

Ул тагын нидер әйтмәкче булып авызын ачкан иде. Шунда эткә сыерчыкның очып кайтып төшкәнен күреп, ярты сүздә шым булды. Әле һаман борчулы карап торган Нәзифә шат тавыш белән:

– Кайтты ич, акыллым, әнә кайтты, – дип кычкырып җибәрде.

– Әйе, әйе, кайтты, молодец! – дип, егетләр дә моны хуп күрделәр.

– Сыерчык ул күке ише зимагур түгел, оя җанлы кош.

– Болай булгач, боларны команда составында алырга туры килә инде. Әй, Нәзифә, ишет, бүгеннән ашны ике җанга күбрәк пешерә башларсың.

Тиздән, затон тамагыннан Идел киңлегенә чыккач, теплоход бар куәтенә эшләп китте. Сыерчыклар бу халәткә, гел алмашынып торган әйләнә-тирәгә аптыраулы каранып бардылар да бераздан янә сузып-сузып сайрый башладылар.

Һәм шуннан бирле алар, тулы хокуклы команда членнары кебек, гел теплоходта йөри, йөзмә ояда көн итә торган булып киттеләр. Дөрес, баштарак алар бераз сагаючан, кинәт гудок кычкыртулардан сискәнеп куючан иде. Тора-бара тынычландылар, тынгысыз ыгы-зыгылы тормышка тәмам ияләштеләр. Тагын шунысы кызык, кешеләрне бер-берсеннән аера-таный беләләр, палубада еш ишетелә торган аврал, чалка, трап кебек кайбер сүзләрне кешегә охшатып кабатлыйлар.

Юлда барганда, алар күбрәк ояда үз эшләре белән мәшгуль яки, йорт кошлары кебек, аяк астында, камбуз тирәсендә чүпләнәләр. Пристаньнарда туктап торган вакытларны әле берсе, әле икенчесе бөҗәк эзләп яр буена чыга һәм кузгалып китү алдыннан гудок кычкыртуга, шундук очып кайтып керә.

Канатлы җырчыларны команда членнары да үз күрәләр, кул астында булган ризык валчыклары белән кунак итәләр. Кичке ямансу сәгатьләрдә аларның мачта очында әле чут-чут итеп өздереп, әле сузып-сузып сайраулары һәркемнең күңеленә хуш килә.

Озакламыйча сыерчыкларның туй каурыйлары утлы-яшелле җемелдеген югалтты, икесе дә басынкыланып калдылар. Әнкә сыерчык инде беркая чыкмый, хәзер ул гел оя эчендә йомыркада утыра. Кайгыртучан иркәге аңа җимне үзе ташып ашата. Ә эштән буш араларда, оя каршындагы мачта очына куна да, назлы сайрап, бикәченең күңелен күтәрә.

## IV

«Владивосток» һәрвакыт диярлек хәрәкәттә, үткен борыны белән елганы урталай ярып, һаман алга бара. Вахта артыннан вахта алышына, һәркем үз эше белән мәшгуль.

Башкалар кебек вахта тормаса да, Нәзифә дә иртәдән кичкә тикле үз постында: камбузда аш-су пешереп көненә өч мәртәбә команданы ашата-эчертә, савыт-сабасын да, пристаньнарда туктап торганда, артельче Хәйруллин белән магазиннан азык-төлек ала, кичләрен кызыл почмакта мөдирлек итә, егетләр белән стена газетасы чыгарыша.

Нәзифәдән тыш теплоходта тагын берничә хатын-кыз бар. Алар – ирләре янында булу өчен кайсы матрос, кайсы моторчы булып эшләүчеләр яки җәйге ялларын якыннары янында үткәрергә килүчеләр – үзара гына әйткәндә, Нәзифәдән бераз көнләшәләр дә. Чөнки буйдак егет-җилән генә

түгел, гаиләле ирләр дә киң күңелле, ачык йөзле, эшкә уңган повар кызны эчкерсез үз күрәләр, кирәк чакта эшендә теләп булышалар.

Нәзифә инсафлы кызларга хас сизгерлек белән үзен һәрвакыт әдәпле тота, чытлыкланып, кемгә дә булса өстенлек күрсәтеп, имеш-мимеш сүз йөртүчеләргә азык бирми, һәркайсына эчкерсез ягымлы. Теплоход кешеләре аны шулай дип белә, шуның өчен үз итә.

Ләкин бу тыштан гына шулай, дөресрәге, баштарак шулай иде. Чынлыкта исә аның йөрәгенә берәү ут салды инде. Хәзергә әле телдән сөйләшкәннәре, ачыктан-ачык аңлашканнары булмаса да, Нәзифә гел аның турында уйлап йөри, ул ашханәгә килеп кергәндә, кинәт кояш чыккандай, аның өчен дөнья яктырып китә, йөрәге ешрак тибә башлый, йөзенә кызыллык йөгерә. Йөрәгендә беренче мәхәббәт ялкыны кабынганнан бирле, ул, төскә-биткә тагын да чибәрләнеп, тагын да мөлаемланып китте. Хәзер ул һәр иртәне елмаеп, якты өмет белән уяна, һәр яңа туган көн менә-менә зур сөенеч алып килер кебек.

## V

Нәзифәнең бүгенге көне дә матур башланып китте. Иртәнге аштан соң кызыл почмакта айлык эш йомгакларын тикшерүгә багышланган җыелышта алдынгылар арасында профорг аның исемен дә телгә алды һәм Мактау тактасына куярга тәкъдим кертте.

Гадәттәгечә тыныч кына башланган бу җыелыш бик тиз кызып китте. Һәркемне энә күзеннән үткәргән кебек, җентекле тикшергәннән соң гына тавышка куеп расладылар.

Нәзифәгә чират җиткәч, шау-шулы җыелыш кинәт тын калды. Повар профессиональ елгачы булмагангамы, кешеләр үзара сораулы карашып алдылар. Бераздан, түр тәрәзә янында моңарчы тын гына утырган капитан Федор Петрович сүз сорагач, Нәзифә эсселе-суыклы булып китте, эштә эленке-салынкылыкны, һәртөрле җыйнаксызлыкны җене сөймәгән таләпчән карт елгачы менә хәзер бөтен команда алдында тиргәп оятлы итәр кебек тоелды.

Капитан исә, утырган җиреннән кузгалмыйча, гадәтенчә сабыр гына:

– Ник әле сез, Надяны күрмәгән-белмәгән кебек, ләм-мим сүзсез калдыгыз? – диде ул, аптыраулы тавыш белән. – Диңгезчеләрдә бер әйтем бар: корабта яхшы кок врачка тиң санала, диләр. Әйтегез әле, безнең кок та шундый түгелмени?! Һәркөн ул пешергән тәмле ашны рәхәтләнеп ашыйсыз. Туган көн бәйрәмнәрегездә һәркайсыгызны бизәкле торт, баллы чәкчәк белән кадерләп сыйлый... Берүк күз тимәсен, бик тырыш, бик уңган кыз, кирәк булганда юк кына азык-төлекне дә оста төрләндереп, менә дигән аш әзерләп бирә белә. Шуның өстенә китапханәче, кызыл почмакны плакатлар, рәсемнәр белән бизәде. Минемчә, Почет тактасына, һичшиксез, лаеклы кок.

Капитан сүзенә кушылып, барысы да дәррәү кул күтәрделәр, Нәзифәгә эшендә яңа уңышлар теләделәр. Аның белән янәшә утырган штурман Борһанов, сүзсез генә тәбрик иткәндәй, терсәгенә җиңелчә кагылып алды. Башкалар да, җыелыштан соң төш вакытында ашханәгә кергән берсе, дусларча җылы сүз әйтеп, шатлыгын уртаклашты.

Ә кичен, кызыл почмакта бар кеше таралып беткәч, Нәзифә стена газетасына рәсемнәр ясап утырганда, ачык ишектә штурман Борһанов күренде һәм керә-керүгә стеналардагы Идел күренешләрен, теплоход ветераннарының фоторәсемнәрен, киштәләрдәге экспонатларны өстән-өстән генә күздән кичергәннән соң:

– Белми идем, болар барысы да синең эшмени? – диде. – Үзең дә яшь пионер кебек, иренмәгәнсең... Инде төн уртасы бит. Бүгенгә җитәр, газетаңны иртәгә калдырып торсаң да гөнаһ булмас.

Бу юлы Борһанов көндәгечә формадан түгел, кыска җиңле ак майка кигән, бүрек кебек калын җирән чәчен артка яткырып тараган, таза муенына нәзек чылбыр белән кулон сыман җиз якорь таккан иде. Нәзифә, балаларча беркатлылык белән:

– Тәре дисәм, тәре түгел, нинди әкәмәт бу? – дип гаҗәпләнде.

– Бумы? Бу – тылсымлы якорь, – диде Борһанов, җитди тонга күчеп. – Дөресрәге, безнең нәселдә буыннан буынга күчеп бара торган әманәт, ягъни вәгъдәгә, дуслыкка, мәхәббәткә тугрылык символы бу... Безнең нәсел әүвәл-әүвәлдән елгачы бит. Бу якорь безгә шуннан килгән. Минем әти, өйләнер алдыннан, бу якорьны гомергә тугрылык билгесе итеп әнигә биргән. Әти вафат булганнан соң, әни аны миңа тапшырды, син дә аның кебек ихлас бул, диде.

– Бик әйбәт символ, ә мин аңламый торам. Әткәң-әнкәң ихлас күңелле булган икән.

Бу минутта яшь штурман Нәзифәгә, моңарчы күренмәгән эчке матур ягы белән ачылгандай, тагын да якынрак булып китте. Тик шунысы сәер, теплоходта егетнең әнә шул рухи күркәмлеген, нечкә хислелеген күрмиләр, аны никтер өнәп бетермиләр.

Менә хәзер, иңгә-иң сыенып ярым караңгы кызыл почмакта серләшеп утырганда, Нәзифә ул кырын карашларны тагын хәтерләде һәм бу хәлне егетнең үзенә дә әйтте. Борһанов исә моны үзе дә күрә, сәбәбен дә яхшы белә икән.

– Укымыйча калган булдыксызларга, җыен ялкауга бер дә исең китмәсен. Минем кебек штурман була алмаудан көнләшәләр алар, шуңа кырын карыйлар, – диде ул, Нәзифәнең биленә кул салып. – Һәр кеше үз тормышын үзе төзи, максатына үз көче белән ирешә. Мин дә үз тырышлыгым белән штурман булдым, тормыш юлымда сине очратуыма шатмын. Атам-анамнан калган бу изге әманәтне менә хәзер сиңа тапшырам. – Борһанов, дулкынланып сөйли-сөйли, җиз якорьлы чылбырны салып, Нәзифә муенына элде, иңнәреннән сыйпап иркәләде. – Сиңа бик тә килешә, сөйдергеч таккан кебек, тагын да сөйкемлерәк, якынрак булып киттең... Нәзифә, сизәсеңдер, мин сине үлеп яратам бит. Әйтче, зинһар, син дә мине үз итәсеңме, ышанасыңмы?..

Нәзифә үзе дә ут эчендә; моңарчы һичкайчан булмаган хәл, егет кочагында балавыздай эреп утыра. Аның кайнар сулышыннан шашынып кочу-үбүеннән исергән хәлдә төштә саташкандай:

– М-мин дә үз итәм, ышанам, – дип, ишетелер-ишетелмәс кабатлады.

Алар, бер-берсен югалтудан курыккан кебек, кысып кочаклашып, үбешергә тотындылар...

Шулчак тышта, якында гына, нәрсәдер кыштырдаганы ишетелде, ачык тәрәзәгә эленгән ак ефәк пәрдәнең аскы читен җилмә, кешеме ялт ачкан кебек булды. Икесе дә, тәрәзәгә сискәнүле карап, хәрәкәтсез калдылар һәм тын да алмыйча бермәл тынлыкка колак салып тордылар.

Беренче булып егет телгә килде:

– Беркем дә юк, җил генә булды бугай, – диде, сагаеп калган Нәзифәне тынычландырырга теләп. – Юк, синсез бер көн дә тора алмыйм мин... Нәзифә җаным, әгәр син дә мине чын-чынлап яратсаң, әйдә без болай эшлик: иртәгә көндез теплоход Камышлыда бодай кабул иткәндә, загска барып гариза бирик... Йә, ничек, ризамы, каршы түгелме?

Нәзифәнең әлегә тикле мондый назлау сүзләрен ишеткәне юк иде. Егетнең кайнар кочагында башы әйләнде:

– Каршы түгел, мин дә риза... Ярар, шулай итәрбез, – дип пышылдады. – Әмма Камышлыда түгел, гаризаны затонга кайткач, үзебезнең шәһәрдә бирербез. Чөнки безгә башта әнигә күренергә, аның фатихасын алырга кирәк булачак. Шунсыз ярамый, аның наказы шундый. Мин аның бердәнбер кызы бит, юкса хәтере калуы бар.

– Ух, затонга кайчан әләгәбез әле, аңынчы күпме көтәргә кирәк. – Борһанов чарасыздан авыр сулап, авызын турсайтты. Аннары, Нәзифәне кочагына алып, тагын кабынып китте. – Шуны онытма, әниеңә генә түгел, хәзер син минем дә бердәнберем бит. Һич тә синсез кала алмыйм, гел синең белән бергә буласым килә... Вакыт соң инде, әйдә кызыл почмакны ябыйк. Җаным, син каютаңның ишеген бикләмә, шакылдатмый гына керерлек булсын. Тагын бераз гына сөйләшеп утырырбыз, яме...

Хәер, Нәзифә үзе дә аерылып китәргә бик ашыкмый, күңел кошы янында назлану аңа да рәхәт. Һәм ул сөйгәненең өзгәләнеп ялваруын кире кага алмады, ихтыярсыз күндәмлек белән риза булып, шундук өстәлдәге газета, пумала, буяуларны җыештырырга кереште.

Яктыдан палубага чыккач, Нәзифә беравык һичнәрсә күрә алмыйча торды. Аннары, караңгыга күз ияләшкәч, төн карасы сыегая төшкәндәй булды. Өстә рубкада һәм машина бүлегендә вахта торучылардан кала бар кеше йокыга чумган. Әйләнә-тирә тып-тын, теплоходның алга баруын сиздереп, түбәндә тынгысыз дулкыннар гына гөрли. Еракта, яр буендагы тау сыртларын шомлы яктыртып, ара-тирә аҗаган уйнап куя.

Нәзифә, кызыл почмакта озак тоткарлануыннан уңайсызланып, тизрәк каютасына кереп китәргә ашыкты. Чирек сәгатьтән ярым караңгы коридорда штурман Борһанов сак адымнар белән шыпырт кына килеп кагылганда, аның ишеге никтер ачылмады, ул эчтән бикле булып чыкты.

## VI

Иртәгесен Нәзифә гадәттәгечә сәгать алтыда уянды һәм, кичәге кичне хәтерләп, елмаеп куйды. Шунда кинәт күңелендә шик туды: чү, чын булдымы бу, матур төш кенә түгелме, дип, әйләнә-тирәсенә эзләнүле каранды һәм өстәл өстендәге җиз якорьны күргәч кенә тынычланды.

Хәлбуки иркенләп ятарга вакыт юк. Вахталар алмашыну башланганчы, сигезенче яртыга иртәнге ашны әзерләп өлгертергә кирәк. Ул тиз генә юынып, көзге каршында чәчен тарады, җиз якорьлы чылбырын муенына такты, ак калпагын киде, алъяпкычын буды. «Бүген үк әнигә хат язып салырга кирәк, тиздән кияү булачак егет белән очрашасын алдан белеп торсын», – дип, үзен-үзе искәртеп куйды.

Төнлә белән теплоход Камышлыга килеп туктаган икән. Хәзер аның трюмнарына тасмалы транспортерлар ярдәмендә бодай төйиләр; алгы якта матрос белән практикант егет каядыр югарыга карана-карана җанланып сөйләшеп торалар иде. Нәзифә дә шул якка күтәрелеп карады һәм рубка өстендәге оя эченнән мең тавышлы чыр-чу ишетеп шаккатты:

– Егетләр, сыерчыклар бала чыгарган лабаса!.. Әти-әниләре нәниләренә яр буеннан тырыша-тырыша бөҗәк ташып ашаталар бит, – диде.

Әмма һәрвакыт ачык йөзле, игътибарлы егетләр бүген аңа борылып та карамадылар, аны бөтенләй күрмәгән-ишетмәгән сыман, үзара сөйләшә бирделәр. Үзләре, кемгәдер хәтерләре калгандай, караңгы чырайлы, күз карашлары салкын иде.

Нәзифә, моны шундук сизеп, бик аптырап калды. Аннары кичә кич кызыл почмакта штурман Борһанов әйткән сүзләрне хәтерләде: безнең дуслыкны сизәләр, мөгаен, шуннан көнләшәләр дип, бүтән игътибар итмәскә булды. Шул фикер белән тынычланып камбузны ачты, титанга су агызып, чәй кайнатырга куйды, плитәсен кабызып җибәрде. Аны күрү белән җим өмет итеп төшкән сыерчыкларга: мәгез, бәгырькәйләрем, нәниләрегезне сыйлагыз, тизрәк үссеннәр, дип сөйләнә-сөйләнә балык калдыклары бирде.

Бая теге егетләр белән очрашудан туган күңелсез уйлар эш арасында акрынлап юкка чыкты. Күз алдына затон бистәсендәге туган-үскән өе, ифрат та кайгыртучан, тынгысыз әнкәсе килеп басты. Хатны алу белән ул әлсерәү йөрәкнең шундук аһ-ваһ тәшвишләнүе, әллә ниләр уйлавы бар бит. Димәк, хатны бик уйлап, ничек тә борчымаслык итеп язарга кирәк. Иң мөһиме – мәсьәләнең инде хәл ителгәнлеген, тәмам вәгъдәләшкәнне сизмәсен, хәзергә әле аның киңәшен, ризалыгын сорап кына килгән кебек булсын.

Нәзифә әнә шулай үзалдына уйлана-уйлана плитә янында маташканда, ачык ишек уемына штурман Борһанов килеп басты. Аяк астында чүпләнгән сыерчыклар, аны күрү белән сискәнеп, читкә ташландылар һәм, чыркылдашып, ояларына очып менеп киттеләр.

Борһанов, ишектән яртылай башын тыгып, бик ягымлы исәнләште, аны-моны сөйләгәндәй итте. Аннары, күз кырые белән әйләнә-тирәгә сагаюлы каранып алды да:

– Җанкисәгем, сүзеңдә тормадың бит, кичә ишегеңне бикләп яткансың, – дип, җиңелчә үпкәсен белдерде.

Нәзифә уңайсызланып калды, эшеннән туктап, акланырга тотынды:

– Юк, бикләмәгән идем, автомат йозак үзеннән-үзе бикләнгән булса кирәк.

– Ярар, анысы зур бәла түгел. Монда бүтән серьезныйрак күңелсезлек бар. – Борһанов, палубадагы егетләр ягына шелтәле карап алды да, тавышын акрынайта төшеп, дәвам итте. – Ни бит, төнлә без кызыл почмакта утырганны кайсыдыр күргән һәм бөтен теплоходка таратып өлгергән. Күреп торам, әнә теге булдыксызлар, базарчы хатыннар кебек, хәзер дә шуны чәйнәп утыралар.

– Күрсәләр ни булган, әллә җинаятьчеме без... Теле кычыткан кеше сөйли бирсен, бер дә борчылма.

– Борчылудан түгел, болай гына әйтүем... Шулай да син муеныңдагы бу якорьны салып куй әле. Юкса әдәпсезлек дип уйлаулары ихтимал. Син аны бүтән вакытта, өйләнешеп бергә тора башлагач тагарсың.

– Юкны сорама, гайбәтчеләрдән куркып, салачак түгелмен! Аларга үч итеп, юри тагачакмын! Күрсеннәр, йөрәкләре янсын юньсезләрнең!

– Нәзифә җаным, хәзер үк салып куюыңны сорыйм. Безнең дуслыкны кешегә бик сиздермәскә тырыш. Аңла мине, шулай кирәк. Ник кирәклеген мин сиңа соңынтын әйтермен. Кич белән минем вахта бетәрәк рубкага мен, шунда сөйләшербез.

Борһановны һәрвакыт ныклы, тәвәккәл итеп күрергә гадәтләнгән Нәзифәгә аның бу сагаючанлыгы ничектер сәер тоелды. Күңеленнән аның белән килешергә теләмәсә дә, бүтән карышмады:

– Шулай кирәкме?.. Алайса ярар, хәзер каютага керәм дә салып куям, – диде.

## VII

Төрле эш-мәшәкать тулы әлсерәткеч эссе көн, ниһаять, үтеп китте, җанга рәхәт җиңеллек биреп, җиләс һавалы кич керде.

Көнозын кызу плитә, кастрюльләр янында тулганса да, Нәзифә әллә ни алҗымаган, һәрвакыттагыча җиңел хәрәкәтчән, күңеле күтәренке. Камбузда кичке эшләреннән бушагач, душта коенды да, тиз генә киенеп, рубкага, штурман Борһанов янына менеп китте.

Нәзифә әлегә хәтле рубкадагы кешеләрнең эшләрен палубадан карап кына белә, ихтирам итә иде. Монда, гомумән, бар нәрсә бүтәнчәрәк күренә икән. Түбәндә машина гүелдәве дә, теплоход

кузгаткан дулкыннар шаулавы да ишетелми, әйләнә-тирә тып-тын. Текә тимер баскычтан күтәрелгән саен, тирә-юньдә офык киңәя бара. Кичке шәфәкъ балкышы белән өртелгән тын су өстендә бер генә җыерчык та юк. Әңгер-меңгердә йокымсыраган яр буйлары, тау-үрләр, алсу томанлы тугайлар күңелдә ямансу уйлар уята.

Иң өстә алгы мачтаның аркылы борысына кунаклаган сыерчыклар балаларының тынычлыгын саклап постта тора. Ишек һәм тәрәзәләре ачык рубка эчендә штурвал янында рулевой Хәйруллин баскан, аннан сулдарак штурман Борһанов бинокльдән алга карап бара иде.

– И, син менгән икәнсең, – диде ул, гаҗәпләнгән булып. – Рәхим ит, әйдә кер, безнең эшне күр.

– Минем бераз һава алырга гына менүем. Сезнең монда рәхәт, җиләс икән.

Рубкада тынлык урнашты. Караңгы күктә, утлы эз калдырып, йолдыз атылды. Берничә минут сүзсез генә барганнан соң, штурман Борһанов һич тә көтмәгәндә:

– Давыл купмагае... Трюмнар яхшы ябылган микән, бар, карап мен әле, – дип, рулевойны палубага төшереп җибәрде, штурвал янына үзе басты.

Төз гәүдәсенә сыланып торган ак кительдән, күн козыреклы фуражкадан бу минутта ул бик тә килешле һәм мөлаем иде. Нәзифә гашыйк күзләре белән аңа ихтыярсыз сокланып карап торды. Һәрьяктан килгән, әнигә, һичшиксез, ошар, дип, канәгатьләнеп уйлап куйды.

– Ят кеше кебек ишек катында торма, мондарак кил, – дип, Борһанов аны үз янына дәшеп алды һәм буш кулы белән иңеннән кочаклады. – Мә, штурвалга тотын, идарә итеп кара... Каушама, кыюрак бул, бернинди кыенлыгы юк аның. Әнә-ә, теге тау астындагы ак утка таба тот. Аннары, шул тауга җитәрәк, аз-азлап сулга таба борыла башларбыз.

Теплоход, чит кешегә буйсынырга теләмәгән сыман, башта уңга, сулга тайпылгалады. Әмма бераздан, кул күнегә төшкәч, артык салуламыйча, турырак бара башлады. Уңыштан күңеле күтәрелгән Нәзифә:

– Ничек уйлыйсың, әгәр өйрәнсәм, мин рулевой була алыр идемме? – диде.

– Син – зиһенле кыз бит, әлбәттә, булдырасың. Моның өчен күп кирәкми. Тырышсаң, суднолар йөртү кагыйдәсен бераз ятласаң, вәссәлам, шул җиткән. Мин сине үзем өйрәтермен. Теләсәң, елга техникумына укырга керерсең. Анда минем әшнә кешеләрем бар, тоткарлык-фәлән килеп чыкса, ярдәм итәрләр.

Бу теләк – киләчәктә судно йөртүче штурман булу хыялы – Нәзифәнең күңелен инде күптән җилкетә, теплоходта эшләве дә әнә шуннан бит. Аның якты ниятен хуплап, дәртләндергеч киңәш әйтүче, ярдәм итәргә әзер торучы штурман егет бу минутта тагын да якынрак, сөйкемлерәк булып тоелды, кыз үз итеп аңа сыенды. Ул тик бер нәрсәне, Борһановның бу якынлыкны кешедән яшерүен аңламый. Менә хәзер тагын шуны хәтерләп:

– Без беркемнең дә өлешенә тимибез бит, – диде. – Болай яшеренүнең, качып-посып очрашуның нигә кирәге бар, кемнән куркасың?

– Дөрес әйтәсең, беркемнең өлешенә кермибез, мин беркемнән курыкмыйм. – Әйтер сүзен таба алмагандай, беравык сүзсез торганнан соң, Борһанов тагын җанланып сөйләп китте. – Үзем өчен түгел, сине уңайсыз хәлгә куюдан, гайбәт таралудан шикләнәм мин. Кешедән ару түгел, бик күренеп йөрүне тыйнаксызлык дип уйлаулары бар... Мин үзем дә гел сине юксынып, синең белән буласым килеп йөрим... Хәзер вахта беткәч тә, мин керермен. Кара аны, кичәге кебек бүген дә ишегең бикле булмасын.

Хәзер инде шәфәкъ балкышы сүнгән иде. Төн карасы куера төшкәч, теплоход су өстеннән түгел, караңгы галәм диңгезендә йөзеп бара кебек.

Шулчак көтмәгәндә, тынлыкны бозып, стенадагы радиоалгычтан кырыс тавыш белән:

– Әй, теплоходта!.. Сезнең белән судоходство инспекторы сөйләшә, – дип кычкырып әйткән сүзләр яңгырап үтте. – Сигналга ник җавап бирмисез? Чүт безгә килеп бәрелмәдегез... Хәбәр итегез, нинди теплоход бу?

Кара син, ә... Болар монда бер-берсе белән мавыгып китеп, үр яктан төшеп килүче баркас сигналын күрмәгәннәр, имеш. Икесе дә бер мәлгә аптырап калдылар. Нәзифә тиз генә читкә тайпылды. Ә Борһанов, якыннан гына үткән баркас утлары артта калгач, ян стенадагы микрофоннан җавап кайтарды:

– Иптәш инспектор, гафу итегез, сигнал лампочкасы кинәт янды, шуны алмаштырып маташа идек, тоткарлык шуннан килеп чыкты. Андый хәл бүтән кабатланмас.

– Шулаймыни, лампочкаларны алмаштыралармыни?.. Оныттыңмыни, ул безнең теплоходның исемен дә сораган иде бит.

– Юк, лампочкаларга берни дә булмаган, – диде Борһанов, хәйләкәр елмаеп. – Мин аны болай гына, инспекторны тынычландырыр өчен генә әйттем. Ул үтеп китте инде, артта калды.

## VIII

Кеше үзе бәхетле булганда тормышны шатлык тулы итеп, әйләнә-тирәсендәге таныш-белешләренең, бергә эшләүче хезмәттәшләренең әйбәт якларын гына күрә, эчтән балкыгандай, ачык якты йөзле була. Бу көннәрдә Нәзифә дә нәкъ шундый хәлдә. Штурман Борһановка гашыйк булганнан бирле ул, чиксез шат, күңел күгендә ястык хәтле дә болыт әсәре юк. Хәзер ул фәкать бер нәрсә – тизрәк затонга кайтып, җан сөйгәне белән әнисенә күренү һәм аның фатихасын алып, матур тормыш кору турында хыяллана.

Үзенә турыдан-туры әйтмәсәләр дә, теплоход кешеләре Нәзифәнең бу уйларын беләләр һәм сагаюлы дикъкать белән күзәтәләр. Бөтен команда эчкерсез яраткан, артык ышанучан тәҗрибәсез үсмер кыз өчен һәркайсы борчыла.

## IX

Җаваплы рейс уңышлы тәмамланды. «Владивосток» командасы, Камышлыда төягән югары сортлы бодайның бөртеген дә чәчми-түкми, чылатмыйча, Казанга графиктан элек кайтарып җиткерде. Бүген көндез аны элеваторга тапшырып бетергәч, кичен теплоход затонга профилактик ремонтка китәчәк. Яздан бирле өйләрендә булмаган команда членнары гаиләләре, якыннары белән күрешәчәк.

Менә Нәзифәнең дә түземсезлек белән көтеп алган дулкынландыргыч көне килеп җитте. Иртәгә көндез әнисенә күренгәннән соң, алар, загска барып, язылышырга гариза бирерләр.

Теплоход элеваторга килеп туктау белән, эштән буш булган бар халык шәһәргә чыгып китте. Башта җыенмаган кебек булса да, штурман Борһанов та, бик мөһим эшем бар, дип, көтмәгәндә китеп барды. Нәзифә исә бүген беркая чыга алмый, аның эше муеннан: көндәгечә аш-су хәзерләп, теплоходта калган кешеләрне ашатырга-эчертергә, киләсе рейска базадан азык-төлек алырга, Камышлыда Борһанов белән бергә сайлап алган ак ефәк күлмәкне үтүкләргә кирәк. Иң мөһиме – иртәгә әнисе янына кайтканда, үз урынында камбузда калырга Әнфисә Борисовнаны күндерде. Үзсүзле түтәйнең Нәзифәнең бу ниятен хупламавы күренеп тора, бер дә теләмичә, бик ялварып сорагач кына, калып торырга көч-хәл белән риза булды.

Казан элеваторы бүген дә һәрвакыттагыча яхшы эшли, пневматик бушаткычлар туктаусыз зырылдап тора, трюмнарда йөк кимегән саен, теплоход корпусы судан чыгып, югары күтәрелә бара. Элеватор лаборанты, ак халат кигән зифа буйлы, күпереп торган бөдрә чәчле бер чибәр кыз, әле бер, әле икенче трюмнан бодай алып, җентекле тикшереп тора. Ара-тирә эшеннән бушап торган минутларда ул, кемнедер эзләгән сыман, әледән-әле каюталар ягына карана, берәр ишек ачылган, коридорда аяк тавышы ишетелгән саен ялт борылып карап ала. Эш арасында берничә мәртәбә күзенә чалынгач, Нәзифә ирексездән: бу нәүмиз йөзле кызый, нәкъ минем кебек бөдрә чәчле икән, безнең егетләрдән кемнедер эзли бугай, дип, хәтта кызганып куйды үзен.

Бичара кызның төш вакытында башкалар белән бергә элеватор ашханәсенә китмәве дә ничектер сәер тоелды. Ул теплоходта торып калып ашыкмый гына террасада, коридорларда йөренә, әйләнә-тирәгә һаман эзләнүле карана бирде. Камбуз тәрәзәсеннән күреп торган Нәзифә ул кызны отыры кызгана төште һәм, ахыр чиктә, ашханәгә дәшеп алды, балык шулпасы, кыздырган бәрәңге белән ит, чәй бирде.

Команда членнары ашап-эчеп инде таралышкан. Нәзифә үзе дә эштән бераз бушаган вакыт иде. Ул үзенә дә чәй салып, өстәл янына барып утырды. Сүз иярә сүз чыгып сөйләшә торгач, лаборант кыз дөрестән дә бер якын егетен эзли булып чыкты.

– Үткән җәйне ул «Баку» теплоходында эшли иде, алар бирегә ашлык төяп еш килә иде, – диде ул, бераз ачылып китеп. – Мин аның белән шунда таныштым. Эштән буш вакытларда аның каютасында радиодан концертлар тыңлый идек. Ул бик шигъри җанлы, миңа багышлап шигырьләр яза иде. Аның һәр килүен мин түземсезлек белән сагынып көтеп ала торган идем. Аннары гомерлек тормыш юлдашлары булырга вәгъдәләштек, инде матур гына гаилә кордык шикелле иде... Ә былтыр көз, навигация ябылгач, затонга киткәндә, ул тиздән мине дә үз янына чакыртырга вәгъдә иткән иде. Әмма чакыртмады, хатларыма да җавап бирмәде, суга баткан кебек юк булды. – Соңгы сүзләрен лаборант кыз кыенлык белән, ишетелер-ишетелмәс пышылдап әйтте, күз яшьләренә буылып, авыр сулап куйды. – Бер таныш елгачы ул егет быел шушы теплоходта эшли күк әйткән иде. Ялгыш әйткән булса кирәк, сездә күренми шикелле.

Лаборант кызның зарлы дулкынлануы Нәзифәгә дә күчте, аны кызганудан йөрәге кысылды. Аңа ярдәм итәргә теләп, ул егетнең кем булып эшләгәнен, исемен, фамилиясен сорамакчы булды. Шунда кызның ачык муенындагы җиз чылбырлы якорьны күреп, телдән язды: «Бу якорың нәкъ минеке төсле икән, сиңа аны кем бирде?» – дип сораудан чак тыелып калды.

Кичкырын, теплоходның йөге бушатылып бетәрәк, иртән шәһәргә чыгып киткән егетләр кайтып керде. Барысы да бик арыган, ачыккан, әмма күңелләре күтәренке иде. Нәзифә инде суына төшкән көндезге ашын тиз генә җылытып, аларга ашарларына бирде, кофе кайнатты.

Шул арада ашханәгә теге лаборант кыз тагын килеп керде һәм, сумкасыннан бланклар алып, бодайның элеваторга нормаль кондициядә, һичнинди дәгъвасыз кабул ителүе турында белешмә язарга утырды. Кызуда тамагы кипкәндер, дип, Нәзифә аның алдына бер кружка кофе куйды, егетләрнең сораулы карашына җавап биргәндәй, аның кем икәнен дә әйтте.

Табын янындагы практикантларның берсе, шәһәрдә күргәннәрен ашыкмый гына сөйләп утырган җиреннән, кинәт кемдер кытыклагандай, кычкырып көлеп җибәрде:

– И, без анда кемне очратканны белсәгез икән... Берәр кружка салкын сыра эчмәкче булып кафега керсәк, ни күрик: аулак кына почмакта безнең штурман бер чытлык хур кызы белән пырхпырх кәеф сөреп утыра. Шаккаттым, менә бу кияү егет, мин әйтәм.

– Хак сүз, мин дә шунда идем. Безне күрүгә тиз генә читкәрәк күчеп утырды, – дип, рулевой Хәйруллин да практикант сүзләрен раслады. – Карале, Нәзифәкәй, ул тасма тел белән сак бул син, төпсез көймәгә утырып кала күрмә.

Нәзифәгә уңайсыз булып китте, дөресен әйтмиләр, һаман шул өнәмәүдән күпертеп сөйлиләр кебек тоелды. Өстәлнең бер почмагында язып утырган лаборант кыз да, нидер сизенгән сыман, эшеннән туктап, сагаеп калды.

Тышта, ачык тәрәзә каршында палубада, баядан бирле сыерчыклар чыр-чу килә иде. Менә аларны кемдер куркыттымы, кинәт, өркүле пырылдап, читкә ташланганнары ишетелде. Шундук ашханәгә штурман Борһанов килеп керде һәм бусагадан атлап үтүгә, баскан җирендә тораташ кебек катып калды. Артык исерек булмаса да, аның кызмача икәнлеге күзгә бәрелеп тора: бите кызарган, кыңгыр фуражкасы астыннан җирән чәче тырпаеп тора, кителенең өске төймәсен чишеп җибәргән.

Менә ул, лаборант кызны күрүгә, сискәнеп куйды һәм, ялгыш, ярамаган җиргә эләккән кеше кебек, тиз генә кире чыгып китәргә теләгәндәй, як-ягына каушаулы күз атып алды; әмма кузгала алмады, үзенә төбәлгән салкын карашлар астында, кадакланган кебек ,баскан җирендә сүзсез тора бирде.

Лаборант кызның исә сагышлы йөзе яктырып китте. Җиңел хәрәкәт белән Борһановка каршы кузгалып:

– Күңелем сизеп көткәнмен икән, менә үзе кайтып төште ич... Исәнме, Зөбәер, – диде ул, киеренке тынлыкны бозып.

Борһанов шундук айнып китте, ни әйтергә белмәгәндәй чак кына сүзсез торганнан соң, лаборант кызга зәһәр карашын төбәп:

– Г-гафу итегез... Миннән ни кирәк сезгә? – диде.

– Зөбәер, ни сөйлисең син, әллә танымыйсыңмы?.. Ник алай күрмәгән-белмәгән кебек карыйсың?

– Юк, туташ, хәтерләмим. Бөтен күргән-очраган кеше истә торамыни... Сез мине бүтән берәү белән бутыйсыз бугай, – дип әйтте дә Борһанов, ишекне капылт ябып чыгып китте.

Ашханәдә авыр тынлык урнашты. Көтмәгәндә уңайсыз хәлдә калган лаборант кыз, нишләргә белмәгәндәй, бермәл аптырап торды да китеп барды. Егетләр дә үзара мәгънәле карашып алдылар да бер-бер артлы таралыша башладылар. Нәзифә исә, бу хәлне аңына сыйдыра алмыйча, югалып калды. Штурман Борһановның җан өшеткеч сүзләре, лаборант кыздан бигрәк, аның үзенә әйтелгән кебек йөрәген тырнап үтте, караңгыда искәрмәстән пычракка баскан сыман тәне чирканып китте. Өстәл янында үзе генә утырып калган рулевой Хәйруллин, аны дусларча юатып:

– Алай көенмә, Нәзифә, нык бул, үзеңне горур тот, – диде. – Өзгәләнүнең кирәге юк. Вакытында күзең ачылу хәерле, шуңа сөен.

# Гәрәйнең бер җәе

1

Менә, ниһаять, укулар тәмам булды. Имтиханнарны барысы да уңышлы тапшырдылар.

Гәрәй дә уңышлы тәмамлады. Аның да күңеле, менә шушы җәйге матур кояшлы көн кебек, аяз һәм якты.

Бер караганда, тормыш дигәнең гаҗәп тә инде. Әле кайчан гына Гәрәй күрше кызы Нәсимә белән өр-яңа форма киеп, китап-дәфтәр тулы зур сумка тотып, беренче мәртәбә мәктәпкә барган иде.

Нәсимәнең бер кулында чәчәк бәйләме иде. Икесенең дә әниләре урамга чыгып, уңышлар теләп, озатып калдылар. Нәсимәнең әнисе Гөлсем апа, борчылып: «Гәрәй, син малай кеше, күз-колак бул, яме, усал малайлар Нәсимәне кага-суга күрмәсеннәр», – дигән иде.

Барысы әйтерсең кичә булган. Уйласаң – ун ел үтеп тә киткән. Бүген мәктәпне тәмамлау кичәсе, бүген өлгергәнлек аттестаты бирәчәкләр.

Гәрәй сәгатенә карап калды. Әле төш вакыты гына. Кич җиткәнче ул Нәсимә белән Иделдә су кереп, көймәдә йөреп кайтырга сүз куешкан иде. Гәрәй инде баядан бирле ян тәрәзәдән күзен алмый: вәгъдә сигналының күренүен түземсезлек белән көтә. Элек алар бер-берсе янына тартынмыйнитми керә торганнар иде. Икенче ел инде Нәсимәнең әнисе Гөлсем ханым Гәрәйгә кырын карый, кызының Гәрәй белән дус булуын теләми. Гәрәйне урамда очраткан чакта да күрмәмешкә салынып узып китә.

Нәсимә белән Гәрәй аңа карап очрашмый калмыйлар, бер-берсен күрергә элеккедән дә битәр атлыгып торалар. Мәктәптә алар һаман бергә. Өйдә вакытта тиз генә күрешергә кирәк булса, хәбәрләшү өчен үзләре генә белгән яшерен сигналлары бар. Менә хәзер дә Нәсимәләрнең почмак тәрәзәсеннән ак пәрдә яртылай ачылып, кызыл чәчәкле кына гөле күренүгә, Гәрәйгә канат кунгандай булды, һәм ул, дөньясын онытып, кичтән сүз куешкан урынга – бакча артына чапты.

Ул барып җиткәндә, Нәсимә инде чыгып өлгергән һәм, гадәтенчә, шаярып, сәрби куаклары арасына яшеренгән, авыз эченнән ишетелер-ишетелмәс кенә нидер көйләп тора иде. Гәрәй яшел яфраклар арасыннан аның ак эшләпәсен һәм җәйге сары күлмәген күреп алды. Нәсимәне үсендереп җибәрү өчен, юри күрмәгән булып: «Күк-кү, күк-кү, сине эзләргә мөмкин күпме?» – дип, «Кая качтың соң син, сары күбәләгем?» – дип, әкрен генә аваз салып, ярату һәм сагыну хисләре белән аны эзләп йөрде.

Нәсимә, гадәтенчә, кош кебек пырхылдап, куаклар арасыннан очынып килеп чыкты да:

– Соңга калабыз ич, көймәләрне алып бетергәннәрдер инде! Нишләп шулкадәр озак эзлисең? – дип шаулатып көлеп җибәрде, һәм алар, кулга-кул тотынып, биек таудан йөгереп төшеп киттеләр.

Су буе, кырмыска оясы кебек, гөж килеп тора. Сары ком өсте кояшта кызынучы халык белән тулы. Вышкадан сикерәләр, пароходлар кузгаткан дулкыннарда чайкалалар, көймәләрдә йөзәләр. Басмаларга бәйләп куйган җиңел көймәләр янында бер төркем яшьләр чират тора. Гәрәй белән Нәсимә дә алар янына барып чиратка бастылар.

Озак та үтмәде, пристань каршындагы кафедан бер кыз белән ике матрос килеп чыктылар да чиратсыз-нисез алга үтә башладылар. Күренеп тора: матрослар кызмача. Бигрәк тә озын буйлысы бүртенгән. Чират торучылар ачулана башлагач, кыз белән янәшә үк баручы икенче матрос уңайсызланып шундук туктады. Ә теге колгасар матрос, куллары белән кешеләрне аралый-ера һаман алга узмакчы булды. Бу хәлгә кинәт ачуы кузгалган Гәрәй тиз генә капка янына барып басты да:

– Күрмисезмени, кешеләр чират тора бит?! – дип, тегенең юлын бүлде.

Матрос башта бер генә мизгел аптырап калды. Чират торучыларның исерек белән бәйләнергә теләмәвен күргәч, тагын батырая төште һәм, Гәрәйне читкә этәреп, капканы ачарга сузылды. Гәрәй тагын аның каршысына килеп басты – капканы ачарга ирек бирмәде. Тарткалаша торгач, ул, ялгыш эләктереп, матросның күлмәк җиңен төбеннән үк умырып чыгарды.

Чираттагылар тынып калдылар... Матрос, иелеп, өзелгән җиңен кулына алды, чынмы бу, әллә төш кенәме дигәндәй, җиңне әйләндереп карады да, кинәт кабынып китеп, җиңсез кулы белән яман кизәнә-кизәнә:

– Ни эшлисең син?.. Беләсеңме, моның өчен мин сине...– дип, Гәрәйгә ташланды. Ләкин ул Гәрәйгә сукмакчы булып селтәнгәндә, янында торучы көймәче картка ялгыш китереп бәрде.

Эш болайга киткәч, башкалар да түзмәде. Моңарчы бу ызгышка катнашырга теләмичә бер читтән карап торган ике таза егет, Гәрәйгә ярдәмгә килеп, дулаган матросның бик тиз кулын артка каердылар. Кайдадыр якында гына кемдер ачы тавыш белән сызгырып җибәрде. Шау-шуга халык җыела башлады. Исерек матросның иптәше якынрак килде дә:

– Халит, милиционер килә, эләктергәнче, әйдә, үкчәне күтәрик,– диде һәм тизрәк китәргә борылды.

Әмма алар китеп котыла алмадылар. Шул арада бер милиционер белән дружинниклар килеп җитте. Озын-озак сөйләшеп тормастан, ике матрос белән бергә Гәрәйне дә бүлеккә алып киттеләр.

II

Гәрәй чыгарылыш кичәсенә әнисе белән барды.

Бәйрәмчә киенгән классташлары һәм кунаклар тулы зур якты залга килеп кергәч, ул ничектер аптырап калды, кинәт күңеле тулып киткәндәй булды. Ун ел эчендә туган-үскән йорт кебек иялә-

шеп, күңелгә үз булып җиткән бу залга бүген соңгы мәртәбә килүен аңлаудан аңар моңсу булып китте. Ихтыярсыз әйләнә-тирәсенә күз төшерде. Бер ул гына түгел, бу минутта бүтәннәр дә үзләрен шулай хис итәләр, ничектер җитдиләнеп калганнар иде.

Гәрәй, әйләнә-тирәгә каранып урын эзләгәндә, бераз алдарак утыручылар арасыннан Нәсимәнең кояш кебек балкыган йөзен күреп алды. Ул, матур ак кулын болгап:

– Гәрәй-й!.. Безнең янга кил, мин сиңа урын алып куйдым, – дип дәшә иде. Ул, Гәрәйнең үзе генә булмавын күреп, әнисе янына кысылыбрак утырды.

Нәсимә куе коңгырт чәчен артка яткырып тараган; муенына таккан яшькелт мәрҗәннәре кузгалган саен су өстендәге вак дулкыннар кебек җемелди иде.

– Ярый әле килеп җиттең, – диде ул, Гәрәй килеп утыргач. – Юкса мин монда бик борчыла башлаган идем... Башка әллә ниләр килеп бетте... Шундый шатлыклы көн... Ә сине ябып куйсалар. Уф! Ничек җибәрделәр?

Гәрәй, аның әнисеннән уңайсызланып, милиция идарәсендә ниләр булганны аңлатып тормады, чөнки Гөлсем ханым алар белән ым кагып кына исәнләште. Ул Нәсимәнең Гәрәйне күрүгә кинәт җанланып киткәнен һәм аңа таба борылып елмаеп сөйләшкәнен өнәп бетермәде булса кирәк, ризасызлык белән тамак кырып куйды, матур ачык йөзе караңгыланды, зур күзләренең карашы кырысланды. Ә Нәсимәнең моңа исе дә китми, аның үз кырыгы – кырык. Классташларыннан берәрсе күзенә чалынды исә, искитмәле ачыш ясагандай:

– Илдусны күрегез әле, Илдусны...– дип гаҗәпләнә.– Нинди важный утыра, министрмыни!.. Әтисен күрсәң, әтисен! Үзе – милиционер, үзе, шук малай кебек, шаярып-көлеп кенә йөри.

Илдус Абдуллин белән дус булса да, Гәрәй аның әтисен якыннан белми иде. Көндез милиция бүлегендә очрашканнан соң, аны монда тагын күрүдән һәм ул вакыйганы искә төшерүдән Гәрәйгә бераз уңайсыз булып китте һәм ул якка бүтән карамаска тырышты.

Тиздән сәхнәгә мәктәп директоры Шәрифҗан Вәлиевич, укыту бүлеге мөдире, класс җитәкчеләре, ата-аналар советы членнары чыгып, кызыл постау җәелгән зур өстәл янына утырдылар. Алар үзара ни турындадыр сөйләшеп алганнан соң, Шәрифҗан Вәлиевич өстәлдәге графинга карандашы белән кагып алды да:

– Дуслар, безнең бүгенге тантаналы кичәбезгә килгән кунаклар арасында район мәгариф бүлеге мөдире Гөлсем Галиевна бар. Хөрмәтле Гөлсем Галиевнаны президиумга чакырырга рөхсәт итегез...– диде.

Бу тәкъдимне халык кул чабып каршы алды. Гөлсем ханым, Нәсимәгә нидер искәртеп куярга теләгәндәй, җитди генә карап алды да җитез адымнар белән алга үтте. Ул барып утыргач, Шәрифҗан Вәлиевич унынчы класс укучыларын мәктәпне тәмамлаулары белән тәбрик итеп, уңышлар теләде.

– Алда сезне зур эшләр көтә, завод-фабрикалар, иген кырлары, югары уку йортлары көтә. Сезнең өчен барлык юллар да ачык, – диде.

Гәрәй бу кичәдә үзен ничектер икегә бүленгәндәй хис итеп утырды. Көндез Идел буенда булып үткән күңелсез вакыйга онытылды. Күзе сәхнәдә булып, чират җиткәч, аттестатын барып алды. Болар бар да аның ихтыярыннан тыш үзеннән-үзе эшләнде. Ә колагында Нәсимәнең әледән-әле пышылдап кына әйткән сүзләре булды, аның кайнар сулышын тоеп утырды.

Кичәнең беренче өлеше тәмамлангач, ата-аналар, укытучылар өйләренә кайтып киттеләр. Тәнәфес вакытында эскәмияләрне коридорга, күрше бүлмәләргә чыгарып, стена буйларына күчереп куйдылар. Иркенәеп калган залда оркестр уйный башлауга, күпләр шундук пар-пар чыгып биергә тотындылар. Барысының шатлыгы йөзенә чыккан, бу шатлык һәркемнең елмаюлы карашында, оча-куна йөрүләрендә сизелә иде. Бер-берсенә карашып алуга, Гәрәй белән Нәсимә дә, алдан сүз куешкандай, шундук кулга-кул тотынып, биючеләргә кушылдылар һәм, күңелле, җиңел көй дулкыннарында тибрәнә-тибрәнә, әллә кайларга очып киткәндәй булдылар.

Бала чактан бергә уйнап, бергә укып үскән бу кызның үзен дә, тормышын да Гәрәй яхшы белә. Әнисе аның, мәгариф бүлегендә эшләү белән бергә, тиздән диссертация якларга, галим булырга җыена; аны бик тәкәббер кеше, диләр, мәктәп директорлары аның белән сүзгә килмәскә тырышалар, дип сөйлиләр. Нәсимәнең әтисен Гәрәй бары бер тапкыр, былтыр пароходта үтеп китешли ике көн кызы янында торып киткән арада гына күреп калды. Кешеләр әйтә, имеш, ул, хатынының тәкәбберлеге белән килешә алмыйча, өеннән чыгып китәргә мәҗбүр булган да шуннан әйләнеп кайтмаган. Мәскәүдә гыйльми эштә икән. Гәрәй аны бер күрүдә яратты: бик ачык, кече күңелле кеше. Нәсимә төскә-биткә әнисенә тартым булса да, холкы белән әтисенә охшаган булса кирәк: ачык йөзле, шат күңелле. Бүген ул үзен бигрәк тә бәхетле сизә бугай: шаяра, көлә.

Аның якты йөзенә, шатлыктан балкыган зур кара күзләренә караган саен, Гәрәйнең дә күңеле сөенеч белән тула.

Биеп туйгач, барысы бергә залны яңгыратып җыр җырладылар, уеннар уйнадылар. Түгәрәк уен вакытында Гәрәйне дә уртага тартып чыгардылар да: «Җырла да җырла!» – дип кыстый башладылар.

Гәрәй каушады, кып-кызыл булып кызарды, җырлый белмим ич мин, дип, тизрәк уртадан чыгып китәргә теләде. Кызлар бер-берсенә ныграк тотынып, аны чыгармадылар.

– Беләбез, беләбез! Сиздермәгән булып йөрмә, – диделәр.

Гәрәй җырламый калу мөмкин түгеллеген аңлады. Ләкин ул тагын оятка кала язды, бу минутта аның бар белгән җыры кинәт онытылган булып чыкты, һәм ул ни башкарырга белмичә аптырап калды. «Алдан хәзерләп куярга башка да килмәгән», – дип уйланып торды. Менә ул Нәсимәнең дустанә күз карашын күрде, шуннан соң җиңел сулап, елмаеп куйды һәм эчке дулкынлану белән җырлый башлады:

Күктә кояш, җирдә гөлләр,
Алда юллар, юлда мин.
Күктә йолдыз, җирдә ярым –
Сөйгән ярым гөлгә тиң.
Дөнья матур, дөнья киң!

Гаҗәп хәл, һәркемгә таныш булган һәм еш кына башкарыла торган бу җыр бөтен залның игътибарын үзенә җәлеп итте. Үзара сөйләшүләр дә, уен-көлкеләр дә кинәт бетте, барысы да, Гәрәйне әле генә таныгандай, сәерсенеп тынып калдылар.

Ә Гәрәйне чынлап та танырлык түгел: ул үз җырына үзе дулкынлана һәм эченә сыймаган шатлык хисләрен иптәшләре белән уртаклаша иде. Бу хисләр башкаларга да якын тоелган булса кирәк, кинәт башкалар да, бертавыштан ,аңар кушылып җырларга тотындылар.

Җыр кузгаткан хисләр шундый күп иде, мәктәп белән саубуллашканда, һәрбер класска аерым-аерым кереп йөрделәр, парталар арасында утырып карадылар.

Аннары барысы да Идел буена төшеп киттеләр. Әле кояш чыкмаган, еракта, каравыл таулары турысында, офык чите нәфис алсуланып кына килә, тынып калган Идел өстендә, хыял кебек билгесез һәм ымсындыргыч матур булып, таң шәүләсе ята иде.

Һәркемнең аеруча якын күргән дусты бар икән. Әле бер, әле икенче пар төркемнән ничектер сиздерми генә аерылып китә яки су өстендә чайкалган көймәләр янына тукталып кала иде. Икәү генә калып бераз сүзсез баргач, Нәсимә иң яраткан укытучысы, әдәбиятчы Галия апасын мактап сөйләде һәм үзенең дә әдәбият укытучысы булырга теләвен әйтте. Аннары ул:

– Гәрәй, ә син кем булырга телисең? – дип сорады.

– Минме?.. Мин... җырчы булам, – диде Гәрәй һәм кинәт әйтеп ташлаган бу сүзләрдән хәтта үзе дә уңайсызланып калды.

Дөресен генә әйткәндә, үзенең киләчәге, кая укырга барасы турында ачык итеп уйлаганы, нинди дә булса төпле бер фикергә килгәне юк иде әле Гәрәйнең. Аның күңеле әллә кайларга ашкына... Биек яр өстеннән хыялга чумып, Иделгә карап утырган минутларда мәһабәт пароходлар да йөртәсе, галәм дәрьяларын гизүче космонавт та буласы килә. Ә соңгы вакытта аны бүтән теләк, үзенәүзе атап әйтергә дә базымы җитмәгән яңа бер хыял дулкынландыра, еракта гы якты маяк уты кебек үзенә чакырып тора башлады. Концертларда, радиотапшыруларда ул үзенең яраткан җырларын аеруча бирелеп тыңлый һәм, аларга ияреп, үзе дә гел җырлап йөри иде.

– Бик дөрес итәсең, Гәрәй. Сиңа җырчы булырга кирәк. Синең тавышың матур, моңлы... Мин моны күптән сизеп киләм, син әллә ничек кенә рухланып җырлый беләсең. Үзең белән бергә тыңлаучыларны да кузгатасың...– диде Нәсимә.– Мин үзем менә җырлаган чакта кемне дә булса уйлап, кемгәдер атап җырлыйм... Син дә шулаймы?.. Әгәр шулай булса, әйт әле, син бүген кемгә атап җырладың?..

Гәрәй кызны ике кулыннан алды:

– Әйтимме?.. Дөресен әйтсәм, ачуланмассыңмы? – дип, аның күзләренә карады.

– Әйт, әйт. Ләкин дөресен әйт...

– Алайса, бел: мин сине уйлап җырладым, сиңа гына атап җырладым... Мин һаман сине уйлап җырлыйм, – диде Гәрәй. Ул кинәт Нәсимәне кочаклап алды һәм, күзләрен йомып, аны битеннән үпте...

Су буйлап алар озак йөрделәр. Иртәгә кич тагын шунда очрашырга сүз куешып, инде яктыргач кына кайтып киттеләр.

III

Пристаньнан берничә километр түбәндәрәк, елганың уң як ярында биеклеге һәм мәһабәтлеге белән бөтен Идел буена атаклы Каравыл тавы бар. Хәзергә Кызыл яр поселогы урнашкан урында борынгы заманнарда Болгарның зур крепосте булган. Дошман яулары кинәттән килеп төшмәсен өчен, сигналчылар әйләнә-тирәне шул тау башыннан күзәтә торган булганнар, тауның исеме дә шуннан калган дип сөйлиләр.

Гәрәй белән Нәсимә кичкырын әнә шул текә кыяташ төбендә очраштылар. Нәсимә, башын күтәреп, югары карауга:

– Әбәү, бигрәк текә, өскә җимерелеп төшмәгәе... – дип хәйран калды һәм ихтыярсыздан артка чигенде.

– Әле түбәннән шулай ул. Әгәр түбәсенә менеп карасаң, бөтенләй исең китәрлек...

– Их, шушы яшькә җитеп минем анда бер дә булганым юк бит әле. Гәрәй, булмаса, бер булган икән, әйдә, меник.

Тарихи риваятьләрдә телгә алынган бу атаклы тау башына Гәрәйнең моңарчы да берничә тапкыр менгәне һәм түбәндә салмак кына чайкалып аккан киң Иделгә карап, озак-озак уйланып утырганы бар иде. Нәсимә әйткәч, ул тагын җилкенеп китте һәм озак уйланып тормастан:

– Әйдә, menәбез... Киттек! – диде.

Каравыл тавы, су төбеннән үсеп чыккандай, текә кыяташ булып күтәрелгән һәм аның елгага караган ягы җил-яңгырлар ашаудан, картлар бите кебек, җыерчыкланып беткән. Аның түбәсенә турыдан гына һич тә менәрлек түгел. Гәрәй белән Нәсимә уңга борылдылар һәм, тирән тарлавык эченнән бераз барганнан соң гына, сөзәгрәк яктан күтәрелә башладылар.

Болай да бөркү көн тиздән тагын да кыза төшкәндәй булды. Гәрәй рюкзакка салып бәрәңге, икмәк, термос белән салкын су алган иде. Башта сизелмәсә дә, үргә менә торгач, ул да авыр тоела, иелеп калку ташларга, тал-чыбыкларга тотынганда әле бер, әле икенче якка авышып йөдәтә башлады. Кызудан Нәсимәнең дә битләре алсуланды, маңгаенда, күз төпләрендә вак-вак тир бөрчекләре бәреп чыкты. Тарлавыктан чыгып тауның беренче кәрнизенә күтәрелгәч, тын алырга туктаган бер арада, ул кыя читенә якынрак барып карамакчы булган иде.

– Юк, юк, моннан карама, бераз гына түзә күр, – диде Гәрәй, аны туктатып. – Бу – әле тауның яртысы гына. Әнә теге өркәч түбәне күрәсеңме? Шунда менеп җиткәч, берьюлы карарсың. Аның бөтен кызыгы да шунда: иң югарыдан караудa...

Бераз ял итеп алдылар да тагын юлга кузгалдылар. Тауның бу ягы артык текә булмаса да, зур-зур ташларны һәм ишелеп төшкән урыннарны читләтеп үтәргә туры килә иде. Калку ташларга, җир астыннан чыгып торган агач тамырларына тотына-тотына тирләп-пешеп күтәрелә торгач, алар, ниһаять, Каравыл тавының түбәсенә менеп җиттеләр һәм күз алларында ачылган чиксез-кырыйсыз күгелҗем киңлеккә хәйран калып, озак карап тордылар.

Тау башы чикләвек куаклары белән капланган. Тауның нәкъ уртасында, куе ботакларын як-якка җәеп, бакырдай саргылт кәүсәле мәһабәт нарат үсеп утыра иде. Шуннан сулдарак, текә киселеп төшкән кыяташ итәгендә, салмак кына тибрәлеп һәм кичке кояш нурларында иркәләнеп Идел ага. Аның өстендә ак тасмадай күбекле эз калдырып үткән теплоходлар, кәрваннар моннан караганда тартмадай гына булып күренә. Алар бер-берсенә юл бирешеп кычкырткан гудоклар таш кыялар, тарлавыклар арасында бәрелә-сугыла югарыга менеп җиткәнче хәлсезләнеп бетә һәм тонык кына булып ишетелә иде. Кайдадыр еракта яңгыр ява булса кирәк, аргы яктагы күгелҗем урманнар артыннан бөтен офыкны каплап, өер-өер кара болыт күтәрелеп килә иде.

– Нинди киңлек... Иге дә юк, чиге дә... Әлләниләр уйлата, күңелләрне җилкетә, – диде Нәсимә, күзләрен зур ачып карап торганнан соң. – Кара әле, Гәрәй, җыр да шулай бит: күңелне әллә кайларга алып китә, әллә ниләр уйлата... Шулай бит?..

– Әйе, дөрес әйтәсең, җыр да шулай, – диде Гәрәй, аны кулыннан алып.

Тауның Иделгә таба авышкан ягында, теге баһадир нараттан сулдарак, яртылай җиргә иңеп кергән зур салпы таш бар. Гәрәй белән Нәсимә коры чыбык-чабык җыеп, шул таш янында учак ягып җибәрделәр. Бераз көл төшкәч, бәрәңге күмделәр. Төрле сүз арасында Нәсимә бүген монда чыгар алдыннан әнисе белән үпкәләшкәнен әйтте:

– Шуны һич тә аңламыйм, синең белән дуслашканны яратмый, шуның өчен ачулана,– диде.– Ә мин, үч иткән кебек, сине күрми тора алмыйм, һаман синең хакта уйлап кына йөрим...

Учак янында шулай сөйләшеп утырганда, кайдадыр югарыда дөбердәп күк күкрәп үтте. Күтәрелеп карасалар, бая урманнар артыннан күтәрелеп килгән кара болыт күк йөзен яртылаш каплап өлгергән, көнбатыш якта әле сүнеп бетмәгән шомлы кызгылт шәфәкъ яктысы гына тонык булып балкый, һава бик бөркүләнгән иде. Әйләнә-тирәдә барча җан иясе ничектер тынып, сагаеп калган;

каршыдагы баһадир нарат кына, бернигә исе китмәгәндәй, караңгы күк фонында горур басып тора иде.

Менә көнбатышта соңгы шәфәкъ балкышын да болыт каплады. Каяндыр атылып чыккандай, чикләвек куакларын шаулатып һәм учак утларын тузгытып, кинәт дымсу җылы җил исә башлады. Тагын күк күкрәде, һәм агач яфраклары өстендә шыбырдап эре яңгыр яварга тотынды.

Гәрәй белән Нәсимә башта теге баһадир нарат төбенә барып посмакчы булганнар иде. Яңгыр бик каты бәреп ява башлагач, анда барып җитәргә вакытлары калмады. Әйберләрен тиз генә рюкзакка җыеп алдылар да якындагы салпы таш астына кереп ышыкландылар.

Тиздән караңгылык тагын куера төште һәм тирә-юньдә берни дә күренмәслек булды. Менә төн карасын телгәләп, күзләрне чагылдырырлык ялт-йолт итеп, баш очыннан гына яшен камчысы чыжылдап үтте, аннары тау-ташларны тетрәтеп тагын күк күкрәде һәм шундук якында гына җир астыннан янар таудай ут фонтаны бәреп чыкты. Каты җил аның очкыннарын йолкып алып әйләнә-тирәгә тузгыта башлады. Бу хәлдән тәмам коты очкан Нәсимә:

– Гәрәй, бу нинди тамаша?! Мин куркам...– дип пышылдады һәм калтыранган куллары белән Гәрәйгә тотынды.

Гәрәй башта үзе дә куркуга калган иде. Яраткан кызың шул хакта әйтеп, җылы тәне белән дердер килеп сиңа сыенганда, куркуыңны белдерергә ярыймы соң! Каяндыр, югарыдан коелган утлы очкыннар муенын, битен пешерә башлагач, ул, зиһенен җыеп, югарыга карады һәм баһадир наратны яшен сукканлыгын күрде. Нарат төбеннән очына кадәр дөрләп яна, давыл аның утлы күмергә әйләнгән тармакларын, ылысларын әйләнә-тирәгә тузгыта икән. «Ярый әле шул нарат төбенә ышыкланмадык, югыйсә һәлак буласы икәнбез», – дип шомланып һәм сөенеп уйлады Гәрәй.

Ул Нәсимәне тынычландырырга өлгермәде, ут өермәсенә әйләнгән нарат, төптән киселгәндәй, җил уңаена таба янтая башлады һәм, меңнәрчә чаткылар чәчрәтеп һәм тончыктыргыч кызу төтен бөркеп, утлы ябалдашы белән салпы таш каршына гөрселдәп ауды. Куркудан миңгерәүләнеп калган Нәсимә, еламсу тавыш белән:

– Ух, харап булдык...– дип кенә әйтә алды.

Гәрәй аны башыннан, калтыранган иңнәреннән сыйпый-сыйпый:

– Курыкма, Нәсимә, куркырлык берни дә юк,– дип тынычландырырга тырышты.– Нарат кына ауды, бары шул гына. Тынычлан, матуркаем, тынычлан инде. Әнә давыл да басыла. Хәзер, туктагач та кайтабыз да китәбез...

Давыл дөрестән дә озакка бармады. Күк күкрәве һәм яшен яшьнәве таулар артына, далага таба үтеп китте. Аргы яктан искән җил болытларны куып таратты да тиздән үзе дә хәлсезләнде, тынды. Яңгыр да туктады. Аяз күк йөзенә йолдызлар калыкты, су өстендә пароход утлары, йөзмә маяклар җемелдәп күренде. Дәһшәтле давыл корбаны – әле янып бетмәгән нарат кына, яуда яраланган батыр соңгы сулышын алгандай, әле һаман чатнап куя, янган ылыс һәм чәер исле ачы төтен бөрки иде.

– Менә әйттем ич, үтте дә китте, – диде Гәрәй, Нәсимәне юатып. – Йә, үксемә, тынычлан... Өс-башыңны рәтлә дә, әйдә кайтабыз... Ишетәсеңме, әйдә кайтабыз, дим...

Әмма Нәсимә аны ишетми дә, аңламый да. Аркасы белән ташка сөялгән хәлдә исәнгерәп тик тора һәм әледән-әле сискәнеп куя иде. Әйтеп-әйтеп тә төшендерә алмагач, Гәрәй дә шомга төште һәм ахыр чиктә аны култыклап алып кайтырга чыкты. Нәсимә, миңгерәү кеше кебек, аяк астына карамыйча, юл буена абына-сөртенә атлады, һаман үкси-үкси кайтты. Тау башыннан төшкәндә, берничә тапкыр чак кына егылып харап булмый калдылар, бөтен өс-башлары буялып бетте.

Алар поселокка кайтып кергәндә, вакыт бик соң түгел иде әле. Урамда чокыр-чакырлар яңгыр суы белән тулы, кайбер йортларның рәшәткәләре, капкалары аударып ташланган; һәркайда каты давыл эзе күренеп тора иде.

Олы урам чатыннан үткәндә, магазин уты яктысында Гәрәй Нәсимәнең өс-башын күреп аптырап калды: кызның сары күлмәге дә, ак эшләпәсе дә балчыкка пычранып ала-кола төскә кергән һәм манма су булып чыланган. Юеш чәче маңгаена, битләренә төшеп ябышкан. Йөзендә җан әсәре юк. Күзләре ничектер мәгънәсез карый, үзе һаман бөтен гәүдәсе белән калтыранып үкси иде.

Гәрәй аны өйләренә хәтле озатып куйды. Әмма кыз кайтып җиткәч, үз өен танымагандай, капка төбендә тик тора бирде. Гәрәй аны урамда ялгызын калдырырга арусынмыйча, капканы үзе шакыды һәм, эчке яктан Гөлсем ханымның өйалды ишеген ачканын ишеткәч кенә, аның күзенә күренмәс өчен ашыгып китеп барды.

## IV

Бик нык йончылган һәм шомга төшкән Гәрәй, өйгә кайтып яту белән, шундук авыр йокыга китте. Албасты баскан кебек куркыныч күреп газапланды, берничә мәртәбә сулышы кысылып уянды, тирләп бетте. Бераз тынычланып тагын йокыга китте исә, күз алдына кабат шул коточкыч давыл килеп баса, тагын шул яшен суккан ялгыз ут-нарат өстенә ава башлый һәм, аягы-кулы бәйләнгәндәй, талпына алмыйча, гаҗиз булып кала иде. Менә тагын кемдер уята кебек тоелды. Әмма бу юлы саташу түгел, баш очында әнисе басып тора иде.

– Тор әле, Гәрәй, өстеңә киен, – диде ул, борчулы тавыш белән.

Әле таң атмаган, бүлмә эче караңгы. Яртылай ачык ишектән түр якта ут яктысы күренә, кемнәрнеңдер сөйләшкәне ишетелә иде. Гәрәй, авыр йокыдан уяна алмыйча:

– Иртә ич әле, таң да атмаган... Йоклыйсым килә, – дип, стенага таба борылып ята башлаган иде:

– Гәрәй, әйдә тор әле. Әнә анда сине сорап килгәннәр, – дип, әнисе тагын аның иңбашына кагылып алды.

Шул арада түр яктан әтисенең ачулы тавыш белән:

– Нәрсә ул анда иркәләнеп ята?! Төрт тә уят үзен, – дип кычкырганын ишетеп, йокыдан тәмам айныды һәм, шундук барысын да абайлап, йөрәге жу итеп китте.

Тиз генә торып, җиңсез майкасын, әле кибеп тә өлгермәгән чалбарын киде дә, калтыранган куллары белән чәчләрен рәтли-рәтли, түр якка чыкты. Эре шакмаклы сары эскәтер җәелгән өстәлнең бер ягында Нәсимәнең әнисе Гөлсем ханым белән милиция лейтенанты Абдуллин, каршы якта Гәрәйнең әтисе утыра иде. Аны да хәзер генә уятып кузгатканнар: өстендә буй-буй сызыклы пижама гына, әле йокысы да ачылып җитмәгән иде.

– Менә шул үзе, – диде ул, Гәрәйгә ачулы карап. – Әнә сине эзләп килгәннәр. Сөйләп бир: син ничек шул хәлгә төштең? ...Син сабый түгел инде, үзең өчен үзең җавап бирергә тиешсең...

Гәрәй аптырап калды һәм, ни әйтергә белмичә уйлап торганнан соң:

– Ни өчен җавап бирергә? Мин... берни дә аңламыйм, – диде.

– Кара син аны, артистмыни, ничек килештереп кылана!.. – дип, кинәт Гөлсем ханым кабынып китте: аның матур йөзенә зәһәре чыккан, күзләре көйдереп алырдай карый иде. – Син монда аңламаган булып кыланып утырма, җинаятеңне барыбер яшерә алмассың...

– Гөлсем апай, ни сөйлисез сез... Нинди җинаять? Тиктомалдан шулай ярыймыни?..

– Бу нәрсә, җинаять эзе түгелмени?.. Менә чалбарың үзе әйтеп тора, кызыл балчыкка буялып беткән ләбаса...

– Буялса соң? Яңгыр яуганга мин гаеплемени?..

– Йә, җитте, диванага салышып утырма монда... – Гөлсем ханымның ачудан бөтен гәүдәсе калтырый, Гәрәйгә ташланудан ул үзен көч-хәл белән генә тыеп тора иде. – Бу нәрсә, җинаять эзе түгелмени?.. Нәсимәнең күлмәге дә нәкъ шундый кызыл балчыкка буялган. Димәк, сез бергә булгансыз, син, юлбасар, аның котын алгансың, куркытып көчләгәнсең...

Гөлсем ханым, сүзен әйтеп бетерә алмыйча, ярсуыннан сулышы кысылып, өстәлгә сыгылып төште һәм кычкырып елап җибәрде. Ә Гәрәй тик шунда гына ни турында сүз барганын аңлап, оялудан җир астына кереп югалырдай булды.

– Шулай мөмкинмени? Ни сөйлисез сез? – диде Гәрәй һәм, гаепсез икәнен исбат итә алмаячагын тоеп, коелып төште: – Юк, Гөлсем апай, һич тә алай түгел, уйлый да күрмәгез. Инә очы хәтле дә гаебем юк. Әгәр ышанмасагыз, әйдәгез, Нәсимәнең үзеннән сорагыз...

– Ничек сорыйсың... Син, явыз, аның котын алгансың. Телдән яздыргансың син аны, бер авыз сүз әйтә алмый. Стенага борылып яткан да үкси дә үкси.

Моңарчы сүзгә катнашмыйча тыңлап утырган милиция лейтенанты Гәрәйгә берничә мәртәбә гаҗәпләнеп карап алды, тамак кырып куйды. Әмма телдән аны-моны белдермәде. Өстәлдә яткан кара күн портфеленнән бер бит кәгазь, авторучка тартып чыгарды.

– Ярар, хәзер монда ызгышып торудан мәгънә юк,– диде ул, Гәрәйгә беравык игътибар белән карап торганнан соң.– Ярар инде, вакыт бик соң, бүгенгә өеңдә кун. Иртәгә сәгать унга милиция бүлегенә кил, шунда сөйләшербез... Ләкин кара аны, беркая да чыгып китәсе булма, шул хакта менә монда кул куй...

Гөлсем ханым, аның белән килешмичә, Гәрәйне хәзер үк кулга алдырмакчы булса да, лейтенант үз сүзендә калды. Тагын бер мәртәбә Гәрәйне һичкая чыкмаска кисәтеп куйды да портфелен алып китеп барды.

Өйдә үзләре генә калгач, Гәрәй барысын да сөйләп бирмәкче булган иде. Әтисе тыңларга да теләмәде: «Минем башка төшкән бер бәла булдың инде», – дип, ышанычсызлык белән кулын селтәде дә йокы бүлмәсенә кереп ятты. Соңгы вакытта ул гомумән еш кына кызып китүчән, әчелешле

кеше кебек, юкка-барга бәйләнүчән булып китте. Улының су транспорты инженерлары институтына керергә теләмичә, җырчы булам, дип, юкка хыялланып йөрүен өнәми ул. Берни булса, менә безнең Илһам Шакировларны уздырачак җырчыбыз, дип, гел кимсетеп көлә яки, кинәт кызып китеп, ачулана башлый. Әтисе белән очрашу, аның чәнечкеле сүзләрен ишетү Гәрәйне тәмам чыгырыннан чыгарды, өендә түзеп торыр хәлен калдырмады.

Шуның өстенә менә бу бәла килеп чыкты. «Моннан соң әти тагын да катырак бәйләнәчәк,– дип хафага төште Гәрәй.– Инде нишләргә?.. Монда аның белән әчелешеп яшәгәнче, кая да булса китеп, үз көнемне үзем күрсәм, яхшырак булмасмы?.. Чынлап та шулай итим. Берәр җиргә эшкә кермен, кичләрен имтиханнарга әзерләнермен. Башым тыныч булыр, ичмасам...»

Шул фикер аңа тәвәккәллек бирде, күңелен күтәреп җибәрде. Һәм ул, озын-озак уйлап тормастан, әле кибеп өлгермәгән чалбар, күлмәген тиз генә киде дә ачык тәрәзәдән бакчага сикереп төште. Әтисенә, әнисенә сиздермәс өчен бик сак кына, аяк очларына басып кына чыкты, оек, туфлиләрен агач арасына кергәч кенә киде.

Әле таң беленеп кенә килгән вакыт иде. Гәрәй, башын ия төшеп, юеш агачлар, түтәлләр арасыннан абына-сөртенә ашыгып китеп барды. Рәшәткә аша сикереп чыккач, соңгы кабат саубуллашырга теләгәндәй, өйләре ягына борылып карады. Кай якка юл тотарга белмичә чак кына уйланып торганнан соң, тиз-тиз атлап, яр өстеннән китеп барды.

Идел аръягыннан дөньяга якты нурларын сирпеп кояш чыкканда, Гәрәй инде Каравыл тавы башына менеп җиткән иде. Ул бик алҗыган, басып торырлык та хәле калмаган иде. Ул, бераз ял итәргә теләп, теге салпы ташка аркасы белән сөялеп утырды. «Тукта, мин монда ник мендем соң әле?» – дип, гаҗәпләнеп, үзеннән-үзе сорады, әмма нинди дә булса җавап таба алмады.

Кояш, югары күтәрелгән саен, яктырак балкып, катырак җылыта иде. Бар табигать яңа туып килгән матур иртәне шатланып каршылый. Әйләнә-тирәдә күбәләкләр оча, чәчәктән чәчәккә кунып, умарта кортлары бал җыя. Чыр-чу килеп, кошлар, чикерткәләр сайрый. Кичә кич давыл аударган чикләвек куаклары, үләннәр, тураеп, яшәреп тора. Бары тик төнге дәһшәтле давыл корбаны – яшен сугып кара күмергә әйләнгән бәхетсез нарат кына алан уртасында җансыз ята иде. Бу кояшлы матур иртә дә, шифалы саф һава да – хәзер инде болар берсе дә аның өчен түгел кебек...

## V

Кинәт кайдандыр куа килүчеләр тавышы ишетелә башлады. Алар күбәү бугай, этләре дә бар кебек. Үзләре күренмәсәләр дә, Гәрәй аларның якынаюларын сизә, әле бер, әле икенче якка ташланып котылырга тырыша, әмма куркудан тез буыннары калтырый, бар көченә чапса да, ерак китә алмый. Тиз арада аны, өч яктан камап алып, кыя читенә кысрыклап китерделәр. Башка чара калмагач, ул, күзен йомып, кыя таштан төпсез упкынга ташлана һәм куркып... уянып китә.

Гәрәй, күзен ачып тирә-юньгә караганнан соң да, беравык аңына килә алмыйча утырды. Ул, күңелсез уйларга талган хәлдә, аркасы белән ташка сөялеп утырган көе, үзе дә сизмәстән, изрәп йокыга киткән икән. Аркасы тирләгән, йөрәге дөп-дөп кага, сулышы кысыла. Әмма шунысына шат: бернинди куа килүче юк, барысы да авыр төш кенә булган икән.

Бераз тынычлангач, таудан төшеп, Иделдә су керде, күлмәген чайкап, таш өстенә киптерергә җәеп куйды, чалбарын, туфлиләрен чистартты һәм, кая барырга, нишләргә белмичә, аптырап калды. Иң яхшысы – туры Казанга Җәмилә әбисе янына ычкыну булыр иде, әлбәттә, ләкин юлга бер тиен дә акчасы юк...

Пристань белән Каравыл тавы арасында Паром пристане дип атала торган бер култык бар. Гәрәй, күңелсез уйларга чумып, каңгырап йөри торгач, шул култык читенә килеп чыкты һәм анда «Бурлак» исемле кечерәк кенә буксир пароходы күрде. Яр буенда зур-зур якорьлар, чылбырлар, тимерчыбыктан үрелгән юан арканнар өеме тора; бер төркем матрос шуларны пароходка төяп маташа иде. Гәрәй пароход турысыннан тиз генә үтеп китәргә тырышты. Бераз баргач, пристань ягыннан яр буйлап килүче бер кешене күреп алды: әлеге кешенең кулында чемодан, яныннан зур бер эт килә иде.

Гәрәй кинәт аптырап калды, тиз генә як-ягына каранып алды. Бер якта су, каршы якта текә яр. Кирегә чапса, тагын теге пароход яныннан үтәргә туры киләчәк. Яхшылабрак караса, сул якта текә ярны кисеп чыккан тарлавык бар икән. Гәрәй тарлавык буйлап йөгерде дә зелпе куаклары арасына кереп посты.

Әмма ул тын алырга да өлгермәде, аның эзеннән иснәнә-иснәнә, бөтен тарлавыкны яңгыратып, өрә-өрә теге кешенең кара эте килеп чыкты. Якында гына шактый юан карама агачы бар икән, Гә-

рәй тырмаша-тырмаша агачка менеп китте. Агач янына ук килеп җиткән эт, арт аякларына басып, сикерә-сикерә, ярсый-ярсый өрә башлады.

Ул арада этнең хуҗасы да килеп җитте.

– Ярамый! – дип, кискен итеп дәште ул. – Йә, Пират, җитте, тынычлан... Артык шаяра башладың әле син. Болай булсаң, бел аны, бәйдән ычкындырмам.

Чын спортчы кебек төз, таза гәүдәле, киң җилкәле, утыз яшьләр чамасындагы кеше иде бу. Киеменә караганда, елгачы булса кирәк. Өстенә зәңгәрсу китель, башына сары эмблемалы биек фуражка кигән. Бөтен кыяфәтеннән үзенә ныклы ышану һәм тормышыннан канәгать булуы күренеп тора иде.

– Син монда нишләп йөрисең? – диде ул, Гәрәй агач башыннан төшкәч.

Гәрәй ни әйтергә белмичә бераз уйланып торганнан соң:

– Эм... болай гына, – дип, ык-мык итеп куйды һәм бөтенләй теле бәйләнеп башын түбән иде. – Берни дә эшләмим, болай гына йөрүем. Су кереп кайтып килә идем...

Елгачы аның хәлен сизенде бугай, бүтән сораштырып тормады. Игътибар белән карап алганнан соң:

– Нишләп торабыз әле без монда?.. – диде. – Әйдә чыгабыз.

Ерганактан чыккач, ул Гәрәйне тагын бер тапкыр баштанаяк күздән кичерде һәм, үзен генә калдырып китәргә теләмәгәндәй, яр күләгәсенә утырып бераз ял итеп алырга булды. Зур чемоданын ачып бер кирпеч кара икмәк, колбаса чыгарды, хәнҗәр хәтле зур пычак белән аларны телем-телем турады. Әйберләре арасыннан бер шешә аракы, стакан табып алды да:

– Бүген рәтләп ашаган да юк әле, вакыт тими. Әйдә утыр, бераз тамак ялгап алыйк, – диде һәм, бер стакан аракыны бушаткач, чыраен сытмый гына тамак кырып куйды.

Гәрәйнең беркайчан да аракы эчкәне юк иде. Мондый киң күңелле кеше ярты стакан салып биргәч, кыстатып торырга арусынмады. Кулына колбаса кисәге алды да, нәкъ аның кебек итеп, берьюлы голт итеп йотып җибәрде һәм кинәт сулышы кысылып катып калды. Тамак төбен, бөтен эчен, ут йоткандай, нидер яндырып үтте, күзләреннән яшь бәреп чыкты һәм колбаса кисәге кабып җибәргәннән соң гына, көчкә тын алды. Елгачы үзе әйткәч кенә, Гәрәй моның аракы түгел, су кушылмаган чиста спирт икәнлеген белде.

Эчкәндә кыен булса да, спирт кызуы тиздән Гәрәйнең бөтен тәненә таралды, ничектер рәхәт, җиңел булып китте. Елгачыны Галләм Галиев дип йөртәләр икән. Үзе яр буенда торучы «Бурлак» пароходында беренче штурман булып эшли, хәзер авылда үлгән әнисен күмеп кайтып килеше икән. Сүз арасында Гәрәй дә, теле ачылып китеп, нинди авыр хәлгә эләккәнлеген сөйләп бирде. Гәрәй сүзеннән туктагач, Галиев үзалдына сөйләнгәндәй:

– Шулайдыр, кыяфәтең бик мөшкел... Күрү белән сизеп алдым. Ярдәм итәсе иде бит сиңа... – дип әйтеп куйды һәм, кашларын җыерып, уйланып торганнан соң, чырае яктырып китте: – Әһә, таптым бугай. Әйдә безнең пароходка, безнең бер матрос җитми, капитанны күндереп булса... бик үзсүзле кеше!..

Гәрәй аз гына да икеләнмәде. Икеләнеп тору мөмкинме соң? Шатлыгыннан хәтта Галиевнең чемоданын үзе күтәреп барырга теләгән иде. Әмма турылыклы Пират хуҗасын талыйлар дип уйлады булса кирәк, йоннарын кабартып, шундый өрә башлады, хуҗасына чемоданны тиз генә үзенә алырга туры килде.

Алар «Бурлак»ка кайтып җиткәндә, команда яр буендагы йөкләрне палубага төяп бетергән һәм юлга кузгалып китәргә җыена иде. Гәрәйнең күзенә ташланганы шул булды: Галиевне берәүләр коры гына исәнләшеп, икенчеләре, киресенчә, чын күңелдән кайгысын уртаклашып, хәл-әхвәл сорашып каршыладылар. Пиратның да командага мөнәсәбәте шундыйрак иде булса кирәк: хуҗасы белән кул биреп күрешүчеләргә ул койрыгын селкеп җавап бирә, коры гына исәнләшүчеләргә йоннарын тырпайтып карап тора. Пароходта Гәрәйне белүче дә бар икән. Алгы палубада трап янында җыелган матрослардан берсе бик гаҗәпләнгән тавыш белән:

– Менә гаҗәп... Күрегез әле: таныйсызмы бу асыл кошны? – дип кычкырып җибәрде.

Шул якка борылып карауга, Гәрәй үзе дә хәйран калды: аның каршында өченче көн көймә алырга чират көткәндә бәрелешкән һәм бергә милициягә эләккән колгасар матрос басып тора иде. Штурман Галиев, капитан белән сөйләшә-сөйләшә, кызыл почмакка кереп киткәч, палубада калган Гәрәйне беркөнге танышлары камап алдылар һәм төрлечә шаярта башладылар. Арада иң әтәчләнүче һаман шул Халит булды.

– Синең белән кабат очрашуга мин әйтеп бетергесез шатмын! – диде ул. – Шундый тәртип саклаучы булгач, мин аны чынлап та рәтлерәк бәндә дип уйлаган идем, ә ул безнеңише бер штрафник икән...

– Кем әйтте аны, нишләп штрафник булыйм мин? – диде Гәрәй.

– Һи, кара син аны, ялганларга да өйрәнеп алган. Хәер, бездә беркем дә үзен штрафникка санамый, ничек итеп булса да әйбәтрәк пароходка китәргә генә тырыша. Ярар, зыян юк, әгәр капитанга тәлинкә тота белсәң, син дә монда озак күгәреп ятмассың, бу әҗәл тагарагыннан тиз котылырсың.

Шулчак Гәрәйне кызыл почмакка капитан янына чакырттылар. Барып керсә, газета-журналлар җәеп куелган өстәл янында штурман Галиев белән капитан нәрсә турындадыр җанланып сөйләшеп утыралар. Капитан инде чигә чәчләренә чал кергән, зур күз тирәләрен вак җыерчыклар баскан, киң калку маңгайлы, илле яшьләр чамасындагы кеше иде.

– Син безгә матрос булып керергә телисеңме? – диде ул, Гәрәйгә түгәрәк күзләре белән карап торганнан соң. – Тик шунысы уңайсыз, документларың үзең белән түгел икән... Гәрчә Галләм Галиевич әйтә, сине яхшы беләм, ди. Алай булгач, ярар инде, документларыңны соратып алдырырсың. Ә хәзергә эшли тор. Югыйсә хәзергә безгә сал йөртергә керешкәч, матроссыз кыен булачак.

Эшнең болай тиз җайлануына Гәрәй җиңел сулап куйды һәм ярдәм иткән өчен Галиевкә рәхмәт тулы күзләре белән карап алды. Ә штурман, корт чаккандай:

– Нинди сал тагын ул? – дип, кинәт кабынып китте. – Нинди акыллы башы уйлап чыгарган аны? Без сал йөртүче түгел ләбаса. Приказларын алмаска, яхшылап сөйләшергә кирәк иде.

– Сөйләшеп тә карадым, барыбер риза булырга туры килде... Анда урманчылар зур бәлагә тарыган. Кыш буе әзерләнгән салларының Йөгерек елгада утырып калу куркынычы бар икән. Иделгә чыгара алмыйлар, су сай, ди.

– Калса соң, без гаеплемени!.. Сал йөртә торган пароход җибәрсеннәр...

– Барырга булгач, барырга инде. Бүтән пароходларга су җитми, бары без генә керә алабыз...

Капитан бүтән берни дә әйтмәде. Фуражкасын батырып киде дә кызыл почмактан чыгып китте. Ә штурман Галиев, Гәрәйне алгы палуба астына алып төшеп, алты кешелек кубрикта аңа буш карават һәм урын-җир күрсәтте:

– Менә монда безнең рулевойлар, матрослар тора, син дә шулар белән булырсың. Кайсы вахтага чыгасын мин үзем әйтермен, – диде.

Гәрәй кубрикта берүзе генә калды. Ул әле рәтләп урнашырга да өлгермәгән иде, тышкы якта пароход көпчәкләре шаулый башлады, аяк астында палуба чайкалып куйды. Гәрәй түгәрәк иллюминатордан тышка карады һәм тау битенә урнашкан җиләк-җимеш бакчалары, поселок урамнары, пристань складлары бер якка – артка таба агылуын күрде. Димәк, пароходның кузгалып китүе шушы иде; ниһаять, эләкмичә исән-сау котылдым бугай, дип, җиңел сулап куйды ул.

## VI

«Бурлак» Наратлы пристанена кич кенә барып җитте.

Урманчылар поселогы Йөгерек елганың сул як ярына, сөзәк тау битенә җай гына урнашкан. Ул өч яктан урман белән камап алынган. Олы урман түбән очы белән елгага килеп терәлгән турыда бер катлы кечерәк кенә дебаркадер тора. Каршыдагы такта рәшәткә белән уратып алынган агачлар арасыннан – ул поселокның ял паркы иде булса кирәк – күңелле музыка тавышы ишетелә иде. Дебаркадердан бераз югарырак саллар рейды башлана: бөтен су өстен диярлек каплаган саллар, рәтрәт тезелеп, ерактагы борылыш артына кадәр сузылып киткән, аларның исәбе-хисабы юктыр шикелле. Дымсу-талгын һавада ылыс исе, чәер исе аңкый. Елганың уң ягында кичке тынлыкка талган моңсу тугайлар өстендә ак томан күтәрелеп килә иде.

Пристаньга җитәрәк, «Бурлак», поселок белән исәнләшкәндәй, сузып кына гудок кычкыртты. Аның көр тавышы йокымсыраган тугайлар, урманнар өстеннән яңгырап үтте. Шундук каршыдагы өянкеләр очында кунаклаган каргалар, куркып уянып, кычкыра башладылар, яр бала-чага белән тулды.

«Бурлак»ны монда көтеп торганнар икән. Дебаркадер янына туктауга, пароходка зур, таза гәүдәле, сары мыеклы урта яшьләрдәге кеше килеп керде.

– Исәнмесез, дуслар, сау-сәламәт килеп җиттегезме? Иң элек танышыйк әле, рейд начальнигы Митрофанов булам мин, – диде ул, капитан белән кул биреп күрешеп. – Яшерен-батырын түгел, безнең бар ышаныч сездә. Әгәр дә бер ай эчендә бу салларны Иделгә чыгарып бетермәсәк, болар барысы да монда киләсе елга хәтле торып калачак...

– Нигә үз буксирыгыз белән тарттырмыйсыз? – диде капитан, пристаньнан чак кына түбәндәрәк ярга борыны белән терәлеп торган кечерәк кенә пароходка күрсәтеп.

– «Урманчы»ны әйтәсезме?.. Тарттырабыз, бер генә сәгать тә тик тотмыйбыз. Әмма су бик кими. Ул үзе генә көзгә хәтле дә ташып бетерәчәк түгел.

Ул бик ашыктырса да, «Бурлак» командасы килү белән үк эшкә керешә алмады. Әйләнә-тирәдә күтәрелеп килгән куе томан юлга чыгарга мөмкинлек бирмәячәк. Аннары «Бурлак» командасы таныш булмаган сай сулы, гаять бормалы елгада сал тагып, төнгә каршы, беренче рейска барыбер чыга алмас иде.

– Алайса, сезнең кешеләр без алып килгән якорь һәм лотларны, чылбырларны бушата торсыннар, – диде капитан, үзара киңәшеп алганнан соң. – Безнең егетләр бераз ял итеп алсыннар. Әнә яр буенда парк ачык бугай, вахтадан буш булган кешеләргә йөреп керергә мөмкин. Салны иртәгә, яктыргач, буксирга алырбыз. Ләкин кисәтеп куям, егетләр, әйбәт кенә йөрегез, кичәге кебек артыгыздан жалоба килерлек булмасын.

Командага шул җитә калды. Вахтадан буш булган кешеләр, шундук өс-башларын алыштырып, поселокка ашыктылар. Гәрәй башта пароходта калырга уйлаган иде, әмма рулевой Шәүкәт аңа күп сөйләнергә бирмәде:

– Безгә яр буена чыгу гел эләкми, җае туры килгәндә, әйдә, бераз җилләнеп керик,– дип, ирексезләп алып чыкты.

Пароходта шапшак кына киенеп йөргән матросларны, кочегарларны, майлаучыларны хәзер танырлык та түгел иде: барысы да киң балаклы кара чалбар, кайтарма зәңгәр якалы, ачык изүле ак күлмәк кигән, йөзләре дә ничектер ачылып киткән, барысы да диярлек повар Зәйнәп тирәсендә бөтереләләр.

Пристань каршындагы яр өстендә «Урман шавы» дигән кафе бар. Пароходтан төшкәч, бер төркем бурлаклылар, папирос, шырпы алырга дип, шунда кереп киттеләр. Зәйнәп белән Гәрәй, эчкә кермичә, аларны тышта көтеп торырга булдылар һәм, икәү генә калгач, бер-берсенә сынаучан карашып алдылар.

Киң ак халат киеп йөргәнгәме, Гәрәйгә Зәйнәп пароходта гәүдәгә юанрак һәм елак чырайлырак булып күренгән иде. Хәзер ул ак күлмәктән ничектер җыйнакланып калган. Йөзе ачык, күз карашымы, тешләрен елтыратып елмаюымы шунда, Нәсимәне хәтерләтә иде.

– Кичә Кызыл ярда бу Халит белән тәмам харап булдык, ояты ни тора, – диде ул. – Безнең Халит шул инде ул, кешечә генә йөри белми. Әтәч кебек сугышырга гына тора.

Бераздан кафедан бурлаклылар килеп чыктылар. Алар анда бер уңайдан азрак төшереп тә алганнар булса кирәк, йөзләре кызара төшкән, тавышлары көр. Ә Халит күкрәген киергән, авызында папирос, фуражкасын кыңгыр салган иде. Зәйнәп янына килеп туктагач та, ул иптәшләренә борылып күз кысып куйды һәм бик хәйран калган кыяфәт белән:

– Әмма өлгер дә соң безнең бу Зәйнәп, чуртаннан һич тә ким түгел, – диде. – Яңа егет килеп урнашырга да өлгермәгән, ул аны сихерләргә дә керешкән.

Зәйнәп аның болай сөйләшүенә күнегеп беткән булса кирәк, аз гына да каушамады һәм ачуланып та тормады. Нәкъ үзе кебек итеп:

– Ярар, ярар, теленә салынма, әнә чалбарыңны яхшылап төймәләргә онытkансың,– диде.– Бу тикле дә сыек булырсың икән. Башкаларда әллә ни сизелми әле, ә син ат хәтле гәүдәң белән бөтенләй җебеп төшкәнсең, ни сөйләгәнеңне дә уйламыйсың.

– Зыян юк ла, күп уйласаң, тиз, картаясың диләр ич.

– Ә син, күп булмаса да, бераз уйла. Югыйсә кичәге кебек тагын сайга утыруы бар.

Барысы да шаулашып көлеп алдылар. Халит үзе колагына да элмәде. Тартып бетергән папиросын ташлап, икенчесен кабызды да:

– И, куйсана, көйсез каенана булма әле,– диде.– Әйдә, тизрәк паркка барып җитик, юкса соңга калабыз, ябылуы мөмкин.

Урман кебек куе парк халык белән тулы. Капкадан кергәч тә, үзәк аллеядан уңда, якты итеп яктыртылган мәйдан уртасында, бөдрә чәчле, чандыр гына гәүдәле бер егет бар көченә тырышып баянда уйный, аның тирәсендә парлашып яшьләр бөтерелә, әмма биючеләрнең күпчелеге кызлар икәнлеге күренеп тора иде. Халит моны мәйданга килеп керүгә абайлап алды һәм күтәренке тавыш белән:

– Менә кайда җәннәт! – дип, телен шартлатып куйды. – Хатын-кызлар монастыре ич бу, егетләр юк ич монда...

Мәйданга килеп кергән елгачы егетләргә кызлар да шундук игътибар иттеләр һәм, баянчы яңа көй уйный башлауга, әле берсе, әле икенчесе килеп, үзләре матросларны биергә чакырырга тотындылар. Халит башта Зәйнәп белән биемәкче булган иде, әмма кыз никтер теләмәде.

– И, соңга калдың ич, без монда бергә биергә сүз куешкан идек. Син гафу ит инде, – дип җавап бирде һәм бераз аптырап калган Гәрәйне биергә үзе алып чыкты.

Халит телдән берни дә әйтмәде, кашларын җимереп карап калды. Ә Гәрәй, бии башлауга, тагын Нәсимәне хәтерләп авыр сулап куйды.

Моннан соң инде ул үзен ничектер авыраеп калгандай хис итте, теләр-теләмәс кенә биеде. Аның кинәт кәефе китүен тиздән Зәйнәп тә сизде һәм рәшәткә читенә килеп туктагач:

– Җитте, бүтән биемибез,– диде.– Егетләр теләсәләр биесеннәр. Әйдә, без пароходка кайта торыйк.

Паркта биек наратлар арасында кичке салкын сизелми, әле һаман җылы иде. Ачык яр буенда һава салкыная төшкән, үләннәргә чык кунган һәм бөтен дөньяны караңгы бушлык йоткан шикелле. Шулай да пароход тормышы, кешеләр турында Зәйнәпнең дусларча сөйләгәнен тыңлап бару аңа ничектер рәхәт иде.

Караңгыда ниндидер чокыр аша үткәндә, Зәйнәп, абынып егылмас өчен, Гәрәйнең беләгенә тотынды һәм шуннан соң инде яр өстенә чыккач та һаман шулай култыклашып бара бирде.

– Син безнең матросларга гаҗәпләнмә,– диде ул.– Нишләмәк кирәк, алар шундый бераз адашкан халык, кыскасы, штрафниклар инде.

– Ничек инде, ни өчен?

– Дөнья булгач, төрлесе була. Күпчелеге ниндидер гөнаһ өчен яхшы пароходлардан куып чыгарылган халык. Арада башка җиргә эләгә алмаучылар, булдыксызлар да бар, әлбәттә.

Зәйнәп барысы турында хәбәрдар, һәркемнең ни өчен «Бурлак»ка эләккәнен яхшы белә икән. Көтмәгәндә Гәрәй аннан:

– Син үзең ничек эләктең соң? – дип сорады. – Гафу ит, болай гына, үзең башлагач кына соравым. Әгәр әйтергә теләмәсәң, кирәкми, әйтеп торма.

– Миңа нәрсә, миңа барыбер...– Бераз уйланып торганнан соң, Зәйнәп үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды.– Хәер, анысын миннән башка да җиткерерләр әле, безнең пароходта сер саклап тормыйлар...

VII

Гәрәй әле генә башын мендәргә төрткән шикелле иде, ни арада яктырып та өлгергән соң! Ул кемнеңдер төрткәләвенә сискәнеп уянып китте. Күзен ачып караса – каршында Халит басып тора.

– Күрегез әле бу йокы чүлмәген, әбисенә кунакка килгәнмени... – диде ул, брезент бияләйле кулы белән биленә таянып. – Тегендә бөтен команда тирләп-пешеп салны буксирга тагып йөри, ә бу аксөяк монда йокы симертеп ята... Тор, әйдә, тизрәк кыймылда, синең өчен анда буксирны мин ташымам бит.

Аның өстендә кояштан уңып беткән җиңсез майка, башында иске соры беретка, биленә җиз якорьлы киң кара каеш салган. Кичәге типтерүнең нәтиҗәсе булса кирәк, күз төпләре шешенке, чырае чытык иде. Ул өстәлдәге чәйнектән бер стакан салкын чәй агызып эчте дә, тагын да яманрак җикеренә-җикеренә, кубрик ишеген ачык калдырып чыгып китте.

Гәрәйне вакытында дәшәргә онытканнар яки берәрсе юри уятмаган булса кирәк, югыйсә бөтен команда авралда катнашкан вакытта кубрикта йоклап калмас иде. Ул, тиз генә киенеп палубага чыкканда, кояш инде шактый югары күтәрелгән, пароход сал янына килеп туктаган иде. Беренче штурман белән рейд начальнигы салның аргы башында бүрәнә бәйләмнәрен исәпләп, аркылы-буйлы тарттырылган корыч арканнарның ныклыгын тикшереп йөриләр.

Бөтен халык эшләгәндә түбәндә йоклап калуы өчен Гәрәйгә уңайсыз булып китте, бу минутта һәммә кеше аңар шелтә белән карыйдыр кебек тоелды. Әмма телдән аны-моны әйтүче булмады. Мостикка менеп баскан капитан, җиз рупорын алып, кешеләрне әледән-әле ашыктыра, һәркем үз эше белән мәшгуль, Халит арткы палубада корыч буксирны салга күчереп маташа иде.

– Нәрсә шаккатып торасың, бар, салга төш,– диде ул.– Мин буксирны моннан биреп торам, ә син салдан торып тарттыр.

Гәрәй салга сикереп төште дә буксирны икенче башыннан тарта башлады. Бик тиз тирләп чыкты. Беләктән юан корыч буксир гаять авыр һәм, җитмәсә, энә очыдай тырпаеп торган тимерчыбык очлары кулны чәнчи иде. Аның хәлен капитан да сизеп алды һәм башка матросларга да салга төшәргә кушты. Бишәүләп тотынгач, эш җиңеләя төште, буксирны салга бик тиз эләктерделәр.

Ул арада якында гына гудок тавышы ишетелеп, урманнар, әрәмәләр өстеннән яңгырап үтте. Борылып карасалар, пристаньнан түбәндәрәк «Урманчы» пароходы сал тартып юлга чыгып бара икән.

– Озак кыймылдыйбыз, егетләр, озак, – дип, капитан ашыктырырга тотынды. – Әнә кешеләр китеп баралар инде, ә без әле һаман рейдта казынабыз. Кәлимуллин, Мортазин, тизрәк булыгыз, тизрәк!

Пароходта капитанны яратмыйлар икән, Гәрәй моны кичә үк сизеп алды. Әйткән сүзен тыңлыйлар, кушканын эшлиләр, әмма берсе дә җылы сүз белән телгә алмый. Ә Халит аны үзе юкта: «Аяклы устаз», – дип кенә йөртә һәм җае чыккан саен аның адресына усал сүз әйтми калмый.

– Бу хәтле дә формалист, бу хәтле дә үзсүзле кеше булыр икән. Юк кына нәрсә өчен шелтәлишелтәли тәмам теңкәгә тиеп, саруны кайнатып бетерә бит.

Хәер, Гәрәй дә аны күрүгә ничектер каушап кала, мөмкин кадәр аның күзенә чалынмаска тырыша. Түгәрәк күзләре белән сынаучан караган минутларда, капитан аны үтә күрәдер һәм хәтта күңелендә ниләр ятканын да сизәдер кебек иде.

Салны кабул итеп барысы да палубага күтәрелгәч, капитан кулына рупор алды да:

– Хәзер кузгалабыз, һәркем үз урынында булсын, – диде һәм, гудок кычкыртып, салчыларга якорьны күтәрергә сигнал бирде.

Пароход агым уңаена борылып, түбәндә көпчәкләр әйләнә башлагач, корыч буксир тиздән скрипка кылы кебек зыңгылдап тартылды, һәм ярты елганы биләп алган кәрван акрын гына кузгалып китте. Яр буенда җыелган урманчылар, сал бәйләүчеләр, кәрванга хәерле юл теләп, озатып калдылар.

«Бурлак» пароходының капитаны да, штурманнары да йөгерек елгада эшләгән кешеләр түгел, монда фарватерны белмиләр иде. Аларга ярдәмгә урманчылар үзләреннән лоцман итеп рейд начальнигы Митрофановны бирделәр. Наратлыдан Иделгә чыкканчы кырык километр чамасы арада шул кеше юл күрсәтеп барачак.

Саллар, төрле баржалар, баркаслар, шыгрым тулган кысынкы рейдны артта калдырып, ачык фарватерга чыккач, «Бурлак» бар куәтенә эшли башлады, корыч буксир тагын да катырак тартылды. Пароход көпчәкләре кузгаткан уйнак дулкыннар, бер-берсен ашыктырып, артка тәгәриләр, якякка җәелеп, ярларга кагалар.

Вахтадан буш булган кешеләр, аврал беткәч, кызыл почмакта иртәнге ашны ашадылар да ял итәргә таралдылар. Халит, рубкага менеп, штурвал көпчәге янына басты. Гәрәй, палубаны себереп, юеш швабра белән сөртеп чыкты. Эш арасында авыр уйларга бирелергә вакыт юк иде. Бераз бушаганнан соң, арткы палубада ял итәргә утыруга тагын Кызыл ярны, давыллы төндә яшен суккан наратны, куркудан телсез калган Нәсимәне, үзенең туган-үскән өеннән чыгып качуын хәтерләде.

«Әле кайчан гына дөнья матур, дөнья киң иде, – дип, күңелсез уйларга чумды ул. – Якын дуслар янда, барыр юллар ачык, алда зур эшләр көтә иде бит... Болар бар да коры хыял гына булды микәнни?»

Шулчак камбуздан, ике кулына ике чиләк тотып, Зәйнәп килеп чыкты. Ак халат, ак калфак кигән, кызу плитә янында йөрүдән бит урталары алсуланган. Гәрәйне күргәч, ул кинәт тукталып, чиләкләрен саклык белән генә палубага куйды да сүзсез генә карап торды. Аннары иелеп учы белән чиләгеннән су алды да Гәрәйнең муенына чәчрәтте һәм, кемгәдер охшатып булса кирәк, үтә җитди кыяфәт белән:

– Вахтада торганда, йокларга рөхсәт ителми, – диде.

Гәрәй, чынлап та, кинәт йокыдан уянгандай сикереп торды да, Зәйнәпнең шаяртканын күреп, чак кына уңайсызланып:

– Юк, йокламыйм ла. Болай ничектер онытылып утыруым гына, – диде.

– Барыбер ярамый, вахтада онытылып утырырга да рөхсәт ителми... Белегез аны, моннан соң күрәсе булмыйм!

Зәйнәп шулай дип әйтте дә үз сүзләреннән үзе көлеп җибәрде һәм, ике чиләген ике кулына алып, койрык якка китеп барды.

Аның артыннан Гәрәй дә ирексез елмаеп калды һәм: «Менә бәхетле кеше, һәрвакыт шат күңелле. Моңаюның нәрсә икәнен белми», – дип уйлап куйды.

## VIII

Йөгерек елга үзе болай зур булмаса да, исеме җисеменә бик туры килгән: куе урманнар, әрәмәләр арасыннан алкынып ага. Монда Иделдәге төсле фонарьлы маяклар юк. Шулай да сай урыннарны күрсәтә торган калкавыч билгеләр куелган, көндезләрен шуларга карап фарватер юнәлешен чамалап барырга мөмкин. Шуның өстенә юл күрсәтүче махсус лоцман да булгач, «Бурлак» хәвеф-хәтәрсез әйбәт кенә бара бирде.

Елга туры гына аккан участокларда салчыларга да, пароход командасына да эш юк диярлек. «Бурлак» палубасында кызыл почмак күләгәсендә үз тирәсенә җыелган бер төркем матросларга Халит башыннан кичергәннәрне сөйләп бирә иде.

– И дуслар, бәхетең бер булмаса булмый икән, – диде ул, авыр көрсенеп. – Менә мин хәзер, үзегез күрәсез, гади бер рулевой булып эшлим. Кайчандыр минем дә пароходта беренче кеше булган чакларым бар иде. Менә бит язмыш нишләтә кешене, ул чакларны хәзер инде сагынып сөйләргә генә калды.

Гәрәй аны ихтыярсыз кызганып куйды һәм аны-моны уйлап тормастан:

– Ничек инде беренче кеше, башыңа бәла төштемени? – дип сорады.

– Ул вакытта мин пассажир пароходында матрос булып эшли башлаган җәем генә иде, – диде Халит, һаман шулай кызганычлы кыяфәт белән. – Күп тә үтмәде, авылдан минем хәлне белергә әти килде. Үз күзе белән күрәсе килгән: ничек яши, ничек эшли, янәсе. Ни әйтсәң дә, әти бит! Үземә аны-моны әйтмәсә дә, сизеп торам, гел күзәтә бу мине. Мин якорьлы фуражканы киеп чыккан чакларда, нәни малай кебек, сокланып туя алмый бу. Кыскасы, бу бездә, Ульяновскидан әйләнеп кайтканчы, ике тәүлек торды, бик канәгать булып китте. Өйгә кайткач, мине мактап бетерә алмый, безнең Халит бөтен пароходта беренче кеше ул, дип сөйли икән. Авылдашлардан кайсыдыр ышанмаган булса кирәк: каян беренче кеше, моны ничек аңларга, дип сораган. Әти бер дә каушап калмаган: «Нигә беренче кеше булмасын, Халит бәйләмәсә, пароход туктамый, әгәр ул чалканы ычкындырмаса, кузгалып та китә алмый. Шулай булгач, сиңа нәрсә, атаң башымыни? Мин боларны барсын да үз күзем белән күреп кайттым лабаса», – дип җавап биргән.

Халитны тыңлаучылар кычкырып көлеп җибәрделәр. Арада иң рәхәтләнеп көлүче Гәрәй булды. Мондагы шау-гөр килеп көлешүне югарыда да ишеткәннәр булса кирәк, аннан капитан мостик читенә килеп, юри ачуланган кыяфәт белән:

– Әй бала-чага, бик каты кешнәмәгез, урманда аюларны өркетәсез,– дип кычкырды һәм, барысының да Халит тирәсендә җыелып утырганнарын күреп, үзе дә көлеп җибәрде: – Ә, синмени әле ул беренче кеше дигәннәре, тагын такмаза сатасыңмы?..

Халит, сүз тыңлаучан малай кебек, мостикка каерылып карап алды да:

– Әйе, әйе, үзем дә шуны әйтмәкче идем,– диде.– Җитте, егетләр, бик шауламагыз, юкса сезнең өчен тагын миңа эләгә.

«Бурлак» елга уртасыннан салмак кына чайкалып баруын дәвам итә иде. Тиздән алда елга картасында яшел әрәмәлек белән капланган кечерәк кенә атау күренә башлагач, су агымы салны ярга бәрмәсен өчен, пароход аз-азлап каршы якка авыша, алгы палубадан матрос озын наметка белән суның тирәнлеген үлчи башлады. Капитан тиз генә гудок кычкыртып алды да, мостикка чыгып, ак флаг селки-селки, салчыларга чуен лотларны елга төбенә төшерергә сигнал бирде. Әмма шуңар карамастан куәтле агым салны һаман үз уңаена кага, менә-менә атауга китереп бәрер, бөтен кәрван харап булыр кебек. Бөтен пароходны авыр киеренкелек биләп алган иде: вахтада торучылар да, Халит мәзәкләрен тыңлап утыручылар да, хәтта камбузда маташучы Зәйнәп тә – һәммәсе дә тын алмыйча, артка, зур тизлек белән атауга авыша барган салга караган иде. Капитан киеренке тавыш белән машина бүлегенә:

– Механик, самый полный! – дип кычкырды.

Түбәннән шундук:

– Есть, самый полный! – дип җавап кайтардылар, пароход тагын да куәтлерәк эшли башлады, корыч буксир тагын да катырак зыңгылдап тартылды.

Сал хәзер елга аша салынган йөзмә күпергә охшап калды. Пароходтан караганда, аның аргы башындагы кешеләр бәләкәй генә булып күренәләр; алар анда ничектер кабаланалар, берсен-берсе ашыктыралар иде. Сал атауның югарыгы очы белән тигезләнде, кешеләр кинәт сихерләнгәндәй, баскан җирләрендә хәрәкәтсез калдылар. Менә арадан берсе кинәт фуражкасын салып һавада болгый башлауга, мостикта бинокльдән карап барган капитан:

– Үттек... Хәвеф-хәтәрсез үттек, – дип белдерде һәм тирләп чыккан маңгаен кульяулыгы белән сөртеп алды.

Кешеләр, өсләреннән авыр йөк төшкәндәй, җиңел сулап куйдылар. Капитан салчыларга лотларны күтәрергә боерды, түбәндә машина нормаль режимда эшләүгә күчте; туры фарватерга чыккач, «Бурлак» тагын, салмак кына чайкалып, юлын дәвам итте.

Эштән буш матрослар тагын алгы палубада җыелдылар. Арадан берсе, бая бүленгән сүзне дәвам иттереп:

– Халит, син баягынак машиналарың, шоферларың турында әйткән идең. Монысын алдап сөйләвең инде, шулай бит? – диде.

– Юк, билләһи менә, энә очы хәтле дә ялганламыйм. Миңа ышанмасагыз, әтинең үзеннән сорагыз, юк-барны сөйләшә торган кеше түгел. – Халит, гадәтенчә, үтә җитди кыяфәт белән тыңлаучыларның күзләренә туры карап сөйли башлады. – Әйе, әтидән сорарга мөмкин, үз күзе белән күргә-

не бар. Өченче ел иде бугай, бу мине Октябрь бәйрәменә кунакка чакырырга килгән. Навигация яңа гына ябылган, кесәдә әле сәмән бетмәгән чак. Әти шул ук көнне кире китмәкче. Яхшылап ашсу әзерләттем, күрсен әле улының хөрмәтен, мин әйтәм. Безнең күршедә генә бик мәһабәт гәүдәле полковник тора иде. Квартирасы дүрт бүлмәле, үз машинасы бар, «Волга» маркалы. Әмма үзе борын чөеп йөри торган түгел. Хатыны күрмәгәндә, үзе белән ара-тирә төшергәләп тә алгалый идек. Менә шул. Әтине озату чәенә аны да дәшеп алдым. Әйтергә кирәк, әйбәт кенә гәпләшеп утырдык. Әмма бераздан әтигә җитә башлады бит. Күрәм, бик арып киткәнче, моны кайтарып яткырырга кирәк. Шунда мин полковникка: – Күрше, – мин әйтәм, – мәшәкать булса да, бу картны озатып куйыйк, – дим.

Полковник сүземне кире какмады, шунда ук машинасына утырып, әтине авылга кайтарып куйдык. Юлда кайтканда, әти миннән сорый, бу кемең була соң синең, ди. Моны полковник та ишетте һәм әз генә дә көлмичә:

– Мин Халитның шоферы булып эшлим, – диде.

Мин дә аны-моны әйтмәдем, әтигә карап тамак кырып кына куйдым. Шуннан соң әти авылга кайткач:

– Минем Халит хәзер инде зур кеше булды, аның шоферлары да полковниклар гына, – дип сөйли башлаган.

Палубада тагын гөр килеп җибәрделәр. Күләгәдә әлсерәп яткан Пират сискәнеп башын күтәрде һәм колакларын шәмрәйтеп өреп куйды.

Төштән соң «Бурлак» «Урманчы»ны куып җитте һәм, елга тар булганлыктан узып китә алмыйча, берничә сәгать аның артыннан тизлекне акрынайтып барырга мәҗбүр булды. Кичкырын, Йөгерек елгадан Иделгә чыккач кына, ул аны узып китә алды һәм киң фарватердан иркенләп бара башлады.

Монда инде әледән-әле суның тирәнлеген үлчәп, сәгать саен лотларны төшертеп-күтәртеп торуның кирәге юк. Елга киң, тирән. Кәрван салмак кына чайкалып бара бирә. Ике якта катлам-катлам булып күккә күтәрелгән текә ярлар, тау итәгенә урнашкан авыллар, пионер лагерьлары күренеп кала. Кояш нуры уйнап торган су өстендә пароходлар бер-берсенә гудок биреп үтәләр; алардан калган йөгерек дулкыннар кайдадыр ике арада очрашып челпәрәмә киләләр. Бу күренешкә сокланып карап барган Гәрәй, ихтыярсыз: «Дөнья матур, дөнья киң», – дип, авыз эченнән генә көйләп җибәрә һәм, үз хәлләрен исенә төшереп, башын түбән ия. Моннан соң инде ул, сәгатьләр буе кеше күзенә күренмичә, берүзе кубрикта утыра.

Кич җиткәч, кояш таулар артына төшеп баеган чакта, «Бурлак» Кызыл яр турыннан үтте. Моңа пароходта беркем дә игътибар итмәде, бары тик Гәрәйнең генә йөрәге ешрак тибә башлады, сулышы кысылгандай булды. Һәм ул, кеше күзенә чалынмас өчен, кубрикка төште дә, туган-үскән поселогына иллюминатордан йотлыгып карый башлады. Әнә пристаньнан уңдарак, тау өстендә, аларның өе, әнә Нәсимә белән очраша торган бакча арты. Их, белсәң иде, ничек икән аның хәлләре...

Гәрәй Кызыл яр күздән югалганчы карап барды. Менә Каравыл тавы текә кыялар белән өскә җимерелердәй шомлы булып тора. Төн урталарында пароход Усай ярлары буена – дачалар, пионер лагерьлары урнашкан турыга җитте. Гәрәйләрнең, Нәсимәләрнең дә участоклары шунда. Хәзер анда барысы да йоклыйлар булса кирәк, утлар күренми диярлек.

Иртәгесен көндез «Бурлак» чирек тәүлеккә срогыннан элек Тарлык рейдына төшеп җитте һәм рейдка туктау белән алып килгән салын агач эшкәртү заводына тапшыра башлады.

Шулчак һич көтмәгәндә юлда салның бер бәйләме югалганлыгы беленде. Завод вәкиле, бөтен йөзен җирән сакал-мыек баскан тәбәнәк кенә карт, шуны күрсәтмичә кабул итү актына кул куюдан баш тартты. Башта моңа ышанмадылар, ялгыш санагансыңдыр, без киткәч, иркенләп тикшерерсең, дип, ачуланып та, үгетләп тә карадылар. Берничек тә күндерә алмагач, салны тагын бер кабат бергәләшеп тикшерделәр, әмма картның сүзе дөрескә чыкты: илле кубометр чамасындагы бер бәйләм чыннан да юк иде. Салчылар бригадиры бу хакта: юлда сүтелеп таралган булса кирәк, ләкин төнлә караңгыда без күрмәгәнбез, дип кенә әйтә алды.

Моннан соң инде капитан завод вәкиле белән бәхәсләшеп тормады. Актка кул куйганнан соң, бу вакыйга турында Кызыл ярга милиция бүлегенә телефоннан хәбәр итте дә кире юлга кузгалырга команда бирде.

## IX

Йөксез генә барган чакта, «Бурлак» пассажир пароходларыннан һич тә ким йөрми, авыр баржалар таккан буксирларны әледән-әле куып җитеп, гудок бирә дә җиңел генә узып китә. Команда

членнарына да эш юк диярлек. Көндезге кызудан соң кичке салкынча һавада җиңеләеп калган кешеләр кызыл почмакта телевизордан футбол карыйлар. Футболны Халит кебек яратучы һәм дулкынланып караучы юктыр. Ул уйнаучыларның һәр хәрәкәтенә үзенчә аңлатма биреп, мактап яки ачуланып бара. Менә пароход борылган бер арада, экран тоныграк күрсәтә башлауга, ул ишек янында утырган Гәрәйгә түземсезлек белән:

– Нәрсә йоклап утырасың? – дип кычкырды. – Начар күрсәтә бит. Бар, тизрәк өскә мен дә антеннаны турылат.

Гәрәй мостикка менеп антеннаны пароход курсы авышкан якка акрын гына бора башлады һәм түбәннән Халит: «Булды, булды, бик әйбәт. Тизрәк төш, иң кызык җирен күрми каласың», – дип хәбәр иткәч кенә туктады.

Әмма ул футбол белән моңарчы да әллә ни кызыксынмый, үзе дә уйнамый, башкалар уйнаганны да мавыгып карамый иде. Менә хәзер мостиктан төшкәч тә, ул кызыл почмакка кермәде, бераз ялгыз калырга теләп, арткы палубага чыкты... Тагын Кызыл ярны, Нәсимәне, бергә йөргән бәхетле көннәрне хәтерләде. Аннары тагын Каравыл тавы, теге фаҗигале төн күз алдына килеп басты, һәм күз аллары томанланып китте.

Шулчак кемдер, сиздермичә арттан килеп, аның күзен каплады һәм ничектер ясалма, юри үзгәртелгән тавыш белән:

– Бел кем икәнен, юкса җибәрмим, – диде.

Гәрәй аны сизелер-сизелмәс кенә камыр исе килгән йомшак кулыннан шундук танып алса да, белмәмешкә сабышты.

– Кем булыр икән бу? – дип аптыраган кыяфәт белән ирексездән елмайган булды. – Менә гаҗәп, кулы бераз таныш та кебек, әмма тавышы белән һич тә күргән-белгән кешегә охшамаган.

Зәйнәп аның таныганын көтеп тормастан, кинәт үзе кулын ычкындырды.

– Чү, ни булды сиңа, елыйсың түгелме син?! – диде ул, бик гаҗәпләнеп, һәм Гәрәйнең күзләренә төбәп карады.

Ул тагын нидер әйтмәкче, кызганып сораштырмакчы, юатмакчы кебек иде. Әмма телдән берни дә әйтмәде. Иңбашы белән сүзсез генә Гәрәйгә елышып утырды да үзе авыр сулап куйды.

– Тормыш ник болай икән, башыма сыйдыра алмыйм, – диде ул, уйга талып утырганнан соң. – Күңел һаман каядыр җилкенә, нидер көтә... Кыш көннәрендә тизрәк яз җиткәнне, Иделгә чыгар көннәрне түземсезлек белән көтәсең. Пароходта бераз йөргәч тә, тагын күңел кайта. Кешеләрдән туеп бетәсең, тормыш бертөрлегә әйләнә, тагын шәһәргә, халык арасына кайтасы килә. Анда нәрсәдер көтәдер, чакырадыр шикелле... Хәер, бер тапкыр мин үз бәхетемне тапкандай булган идем, тәмам янып-көеп сөйгән идем, аны бер генә көн күрмәсәм дә, авыруга сабыша идем. Аның кебек чибәр, үткен, булдыклы егет бөтен дөньяда юктыр шикелле иде. Бактың исә, иң гадәти эчкече һәм бозык кеше, һәр юбка артыннан сөйрәлеп йөрүче булып чыкты... Мин моны өйләнешеп бергә тора башлагач кына белеп алдым... Шуннан бирле ир-атны күралмыйм, дөньясыннан гарык булдым. Беләсеңме, дөньяда бер генә минут та яшисе килмәгән минутларым була минем.

Тиздән Зәйнәп тынычланды, каядыр читкә караган хәлдә сүзсез генә утырды. Аннары:

– Әйдә, мин сиңа бер китап күрсәтим әле, – дип, Гәрәйне үз каютасына алып керде.

Зәйнәп өске палубада койрык якка караган кечерәк кенә каютада берүзе тора. Моңарчы Гәрәйнең монда аяк басканы юк иде әле. Килеп керү белән ул бөтен каютаны сокланып күздән кичерде. Ишектән кергәч тә уң якта: ак мендәрләре күпереп матур итеп җыелган карават. Түрдә тәрәзә буендагы кечерәк кенә өстәл өстендәге сулы вазага бер бәйләм кыр чәчәкләре утыртылган. Каршыдагы стенада китаплар тулы киштә. Гәрәй аларны кызыксынып карый башлауга:

– Болар барысы да шигырь китаплары икән ич. Син шигырь генә яратасыңмыни? – дип гаҗәпләнде.

– Әйе, шигырь яратам. Бик яраткан шигырьләремне аерым дәфтәргә күчереп җыя барам мин. – Зәйнәп иллюминаторның калын пәрдәсен төшерде, киштәдән китап кебек калын дәфтәр алып, Гәрәй янына килеп утырды. – Менә алар минем яраткан шигырьләрем, җырларым, һәммәсе дә менә шушы дәфтәрдә... Беркөн шушы дәфтәрне карап утырганда, бер үзгәрешне күреп бик гаҗәпкә калдым мин. Элегрәк, яшь кыз чагында, мин гел канатлы, күңелне җилкендерә торган шигырьләр генә укый идем. Ә соңгы вакытта, үзем дә сизмәстән, ямансу, сагышлы шигырьләр белән мавыга башлаганмын...

Зәйнәп, дәфтәрен ачып, кыз вакытта яраткан шигырьләрен укырга тотынды һәм тагын җанланып бөтен йөзе яктырып китте. Дөресрәге, дәфтәренә ара-тирә генә карап ала. Шигырьләрне ул күңелдән белә һәм җырлагандай башын чайкап куя, сүзләрен бераз сузып укый иде. Шигырь тыңлый торгач, Гәрәй дә, онытылып, әллә кайларга киткәндәй булды, кайчандыр Нәсимә белән бергә йөр-

гән бәхетле көннәрне тагын хәтерләп ихтыярсыз елмаеп куйды. Зәйнәп аны үзенчә аңлады булса кирәк.

– Ничек? Шәп әйтелгәнме!.. Чын мәхәббәт менә нинди була ул, дускаем, – дип көлемсерәп, дәфтәрен ябып өстәлгә куйды.

Гәрәй уйларыннан көч хәл белән арынып, чак кына сискәнеп куйды һәм, чыгып китәргә теләп, урыннан кузгалды. Шундук Зәйнәп тә аның каршына килеп басты һәм кулларыннан алып сүзсез генә төбәп карап торганнан соң:

– Гәрәй, ник син бүтәннәр кебек түгел! Шундый егетләр дә була микәнни? – дип сорады. – Минем хакта берәр гайбәт ишеттеңме әллә, шуңа чыгасыңмы?..

– Юк, Зәйнәп, аннан түгел. – Гәрәй нәни баланы иркәләгәндәй, аның иңбашыннан сыйпап алды. – Минем берни дә ишеткәнем юк. Вакыт соң инде, вахтага чыкканчы бераз ял итеп алырга кирәк. Син дә ят, тыныч йокы сиңа.

Гәрәй чыгып китәргә өлгермәде, тышкы яктан ишетелер-ишетелмәс кенә, тук-тук-тук итеп, өч тапкыр ишеккә шакып алдылар. Зәйнәп җавап бирмәде, саклык белән үрелеп, утны сүндерде. Тышкы яктан ишекне тагын шакыдылар. Бераз торганнан соң:

– Мин бу, Зәйнәбем, ач әле тиз генә, – дип дәштеләр.

Гәрәй аның беренче штурман Галләм Галиев икәнен танып алды һәм, нишләргә белмичә, кинәт коелып төште. Ә Зәйнәп, йокы аралаш әйткәндәй:

– Галләм абый, кәефем бик начар, авырып торган чагым. Бүген борчып йөрмә инде, – дип җавап бирде һәм бераздан, тышкы якта Галиевнең аяк тавышы ерагаеп юк булгач, нәфрәтле офтану белән өстәп куйды: – Тәмам бәла булды бит, һич котылыр хәл юк шушы баз күздән. Болай икәнен белсәм, мин аны якын җибәрмәгән булыр идем. Хәер, кем белгән аның алай икәнен, башта ул бик кеше җанлы, бик җылы күңелле күренгән иде шул.

Гәрәй ирексездән:

– Ничек инде котылыр хәл юк, ул сиңа кем була соң? – дип сорады.

– Кем булсын... Мин бит аңар кияүгә чыккан идем. Сиңа әйтмәделәрмени?.. Аның кармагына эләккәнемне сизми дә калдым мин... Ул гел шулай итә: берәрсе бәлагә тарыса, ярдәм иткән булып, үз кубызына биетә башлый.

Гәрәй, кубрикка төшкәч, караңгыга төбәлеп озак кына уйланып ятты. Таң беленгәндә генә, авыр йокыга талды.

## X

Наратлы рейдында сал тагып нәүбәттәге рейска кузгалыр алдыннан, пароходка утыз яшьләр чамасында бер ир кеше килде. Палубага сикереп менү белән, аны-моны сорашып тормастан, туптуры капитан каютасына кереп китте. Ул соры кепка, шактый уңган яшькелт гимнастерка кигән, беләгенә кара плащ салган иде. Бер сүз белән әйткәндә, аның төсе-кыяфәте бу тирәдә адым саен диярлек очрый торган урманчыга охшаган иде. Команда членнарыннан аңар игътибар итеп караучы да булмады. Бары тик Гәрәй генә аны күрү белән таныды.

Бу кеше – Кызыл ярда теге давыллы төндә Гәрәйне чак кына кулга алмый калдырган милиция лейтенанты Абдуллин иде. Гәрәй тиз генә кубрикка төшеп качты һәм, лейтенант пароходтан төшми торып, өске палубада күренмәскә булды.

Ниһаять, рейдта эш тәмамланды бугай, өстә гудок кычкыртып, салчыларга якорьларны күтәрергә сигнал бирделәр. Менә кәрван акрын гына кузгалып та китте. Гәрәй иллюминатордан бик игътибар белән күзәтеп торса да, милиционерның пароходтан төшкәнен күрмәде. Шулай да ул үзүзен юатырга, аның төшеп калганын, бәлки, мин сизми калганмындыр дип, тынычланырга тырышты. Бераздан ул өске палубага күтәрелде, күзгә бик чалынмас өчен, капитан каютасын читтән генә күзәтә башлады. Байтак вакыт караштырып та, шикләнерлек берни дә күрмәгәч, күңеле тәмам урынына утырды, юкка шүрләп калганы өчен ул хәтта үз-үзеннән көлеп куйды.

Көн буе аяусыз кыздырган кояш эссесеннән бөтен команда тәмам гаҗиз булган иде. Бигрәк тә беренче штурманның эте Пират бик әлсерәгән, күләгәдә көч-хәл белән сулап ята иде. Кич белән Кызыл ярга җитәрәк, күк йөзендә соры болытлар күренде һәм, кешеләргә җиңеллек биреп, җилсез, күк күкрәүсез җылы яңгыр явып үтте.

Гәрәй арткы палубага чыкты. Пароход аның туып үскән поселогы яныннан узып бара иде. Ул бик нык дулкынланып, Кызыл ярның тау буйларына карап торды. Елга буйлап, поселокка таба йөзеп китәсе килде. Шул мәлне ул пароходта көтелмәгән хәвеф, ыгы-зыгы башлануын тойды. Барысы да су өстенә карыйлар иде, Гәрәй кичке эңгердә буксирга тагылган сал янына күләгә яктан яше-

ренеп кенә берничә көймә килеп туктаганын күрде. Бу хәлне мостикта торучылар да күрделәр бугай, анда капитанның кемгәдер:

– Менә бинокльдән карагыз,– дип әйткәне ишетелде.– Икәү көймәдән салга сикерделәр. Бәйләмне ычкындырмакчы булалар... Ычкындырдылар бит. Нәрсә карыйбыз, сал тарала! Кешеләргә әйтегез, көймәгә утырсыннар. Кузгалырга вакыт!

Гәрәй, борт кырыена тотынып, көймәгә сикереп төшкәндә, Халит белән штурман Галиев шунда иде. Алгы якта түземсезлек белән колакларын шомрайтып Пират тора һәм тагын кемдер берәү бар иде. Галиев үзе койрыкта; Гәрәй белән Халитка ишкәккә утырырга кушты да кулындагы койрык-ишкәк белән көймәне читкә этеп җибәрде. Иллюминатордан төшкән ут яктысында Гәрәй теге кешенең бүген иртән Наратлыда пароходка утырган лейтенант Абдуллин икәнен танып алды һәм, йөзе белән аңар күренмәс өчен, ул якка борылып карамаска булды, караңгыда, бәлкем, танымас та әле дип, үзен-үзе тынычландырырга тырышты.

«Бурлак» үз юлы белән бара бирде, көймәдәгеләр бүрәнә урлаучыларны куа киттеләр.

Пароход яныннан кузгалып киткәч тә, штурман Галиев ишкәкчеләрне ашыктыра башлаган иде. Әмма лейтенант Абдуллинның планы бүтәнчәрәк икән:

– Юк, юк, хәзергә әле ашыгырга кирәк түгел,– диде ул.– Безне күрсәләр, алар бүрәнәләрен ташлап качачаклар. Без, күренмичә артларыннан барып, аларны яр буена туктаган җирләрендә эләктербез.

Теге көймәләр барысы да моторлы икән. Бераз читкәрәк киткәч тә, сакланып та тормастан, бөтен елганы шаулатып, моторларын эшләтә башладылар һәм өерләре белән уң як ярдагы тауларга таба юнәлделәр. Читтән караганда, алар диңгездә кораб талаганнан соң качып китеп баручы урта гасыр пиратларын хәтерләтәләр иде.

Бу хәлгә ачуы кабарган штурман Галиев каты кычкырып сүгенә, юлбасарларны куркытырга теләп булса кирәк, бөтен су өстенә яңгыратып, ачы тавыш белән сызгыртып та җибәргәли иде.

– Кирәк түгел, шаулый күрмәгез, – дип, лейтенант Абдуллин аңар туктарга кушты. – Шулай ярыймыни?! Әйтәм ич, без эзләреннән куып килгәнне сизеп алсалар, алар шундук бүрәнәләрен ташлап качачаклар. Зинһар, бүтән шаулый күрмәгез.

Көймәләр байтак юл алып, күздән югалган бер арада, лейтенант Абдуллин ишкәкчеләргә җәһәтрәк ишәргә, тегеләр күргәнче таулар ягына чыгып калырга команда бирде. Таулар күләгәсенә посып шулай каты ишә-ишә борылыш артыннан чыкканда, пиратлар флотилиясе, су агымын файдаланырга теләп булса кирәк, әле һаман елга уртасыннан бара иде. Дачалар турысына җитәрәк, алар уңга борылдылар һәм бер-бер артлы биек яр күләгәсенә кереп, тагын күздән югалдылар. Бераздан «Бурлак» кешеләре читтәрәк көймәдән төшеп сиздермичә кисәктән генә өсләренә килеп төшкәндә, алар инде ярга килеп туктаганнар һәм, караңгыда бер-берсен акрын гына ашыктырып, бүрәнәләрен өстерәп судан чыгарып маташалар иде.

Көтмәгәндә өсләренә чит кешеләр килеп төшкәч, караклар башта бик куркып калганнар иде. Галиевнең эте кулдан ычкынырга атлыгып ырылдый башлагач, арадан карлыккан тавышлы берсе танып алды:

– Фу, Галләм, син икәнсең әле, тәмам котны алдың, – дип, җиңел сулап куйды. – Аз гына сабыр ит, хәзер хуҗа хатын белән исәпләшкәч тә, сөйләшербез... ә болары кемнәр, синең егетләрме?..

Штурман Галиев ни дә булса әйтергә өлгергәнче, лейтенант кесә фонарен яктыртып җибәрде, каты тавыш белән команда бирде:

– Руки вверх! Кузгаласы булмагыз!

Караклар баскан җирдә катып калдылар. Карлыккан тавышлысы – башлык булса кирәк – кинәт читкә ыргылып, караңгыда күздән югалды. Гәрәй шундук аның артыннан ташланды, аяк тавышыннан чамалап, абына-сөртенә куа китте. Тиздән ярдәмгә Пират белән штурман Галиев тә килеп җиттеләр. Пират хуҗасының кулыннан ычкынуга, качкынны куып җитте бугай, төн эченнән:

– Каравыл, талап үтерә, коткарыгыз... – дип кычкырган тавыш ишетелде.

Штурман Галиев аны ярсыган Пираттан көч-хәл белән аралап алды да:

– Ычкын, милиционер тырнагына эләккәнче үкчәңне күтәр, – диде. – Без сине куып җитә алмадык, күрмәдек. Шулаймы, энекәш?

Гәрәй, соң дәрәҗәдә аптырап:

– Галләм абый... – дип, каршы сүз әйтергә авызын гына ачкан иде, штурман Галиев аны ярты сүздән өзде:

– Кем икәнеңне онытма.

– Юк, болай ярамый... юк... мин моңа ирек куймыйм! – диде Гәрәй, үҗәт бер кирелек белән. – Ә син нәрсә көтеп торасың, әйдә кузгал! – дип, ул каракның аркасына китереп төртте. Штурман

Галиев теш арасыннан сүгенеп куйды, Гәрәйне милициягә бирү белән янады, алай да булмагач, тәмле тел белән ялвара башлады:

– Кеше бит ялгышкан. Кызганырга кирәк.

Гәрәй дәшмәде, каракны якасыннан эләктереп баруын белде.

Ул арада Халит та йөгереп килеп җитте. Штурман Галиев бүтән үгетләп маташмады, карак та каршылык күрсәтмәде. Алар килеп җиткәндә, су буена инде дачниклар да җыелышып өлгергән, лейтенант Абдуллин сал талаучыларны такта койма янына җыеп саклап тора; алар арасында бер хатын-кыз да бар иде. Гәрәй бик гаҗәпләнгән хәлдә:

– Бу хатын да көймәгә утырып сал таларга чыкканмыни? – дип кызыксынды.

Нигәдер бик ачуы чыккан лейтенант Абдуллин:

– Юк, анысы урлаганны җыючы, арзанга гына дача салырга уйлаган... Менә бу юлбасарлар бүрәнәләрне шушы оятсызга китергәннәр, – дип, теге хатынның йөзен яктыртты һәм, үз күзләренә ышанмагандай, шаккатып әйтеп куйды: – Чү, Гөлсем ханым, сез түгелме бу?!

## XI

Бу вакыйгадан соң юлда бүрәнә югалтулар бүтән кабатланмады. Бүрәнә урлаучылар белән штурман Галиевнең дә бәйләнештә булганлыгы беленде. «Бурлак»ның Кызыл яр турыннан кайчан үтәсен аларга телефоннан алдан хәбәр итеп торган икән. Тикшерү барышында бу хәл ачылгач, ул да җавапка тартылды.

Бер ай эчендә Йөгерек елгада су саегып, пароход йөри алмаслык хәлгә җиткәндә, саллар инде Иделгә чыгарылып беткән, урманчыларның кыш буе әзерләгән бүрәнәләре киләсе елга хәтле утырып калудан коткарылган иде. Шуның өчен рейд начальнигы, «Бурлак»ны соңгы рейска озатканда, урманчылар исеменнән командага рәхмәт белдерде, һәркайсын яртышар айлык эш хакы белән бүләкләде.

Команда шат. Гәрәйнең дә күңеле күтәренке иде. Көндез вахтага чыккач, капитан Александр Терентьевич аны рубкага чакыртып алды да бизгәк белән авырып Наратлы больницасында калган Халит урынына койрыкчы булып эшли торырга кушты. Гәрәйнең моңарчы да берничә мәртәбә рульдә торганы бар иде. Хәзер дә ул бик теләп басты. Рульне борган саен, пароходның күндәм авышуын күрү аның көчен арттыргандай итә, дөньяда елгачы булудан да кызыклы эш юктыр шикелле аңар.

Шулай матур хыялларга чумып, бик әйбәт кенә барган чакта, Александр Терентьевич бик гади нәрсә турында сөйләшкәндәй:

– Гәрәй, мин кичә Кызыл яр милиция бүлегеннән хат алдым, теге чакта безнең пароходка килгән лейтенант Абдуллин язган аны, – диде һәм, сүзеннән туктап, трубкасына ут ала башлады.

Бу көтелмәгән хәбәрдән Гәрәйнең күз аллары караңгыланып китте. Кай арада гына күрде икән, бер дә танымаган кебек иде бит, дип, тәмам аптырап калды, шул арада әллә ниләр уйлап бетерде. Ә капитан китель кесәсеннән зәңгәр конвертлы хат алып, абына-төртелә укый башлады:

*«Безнең поселокта нахакка гаепләнгән һәм, куркудан булса кирәк, качып китеп хәбәрсез югалган Гәрәй Кәлимуллин дигән егетне сезнең пароходта очратып бик гаҗәпләнгән идем. Ул чакны ара тар булды, җаен туры китереп, мин аның үзе белән сөйләшә алмадым. Ә без, артык гаугалы бер хатын сүзенә ышанып, ул егетнең тормышын чак кына имгәтеп ташламадык. Әмма Гәрәйнең гаепсезлеге бик тиз ачыкланды. Дус кызы да савыкты. Егетнең хәбәрсез югалуы гына безне бик борчый иде. Күргәнемчә, ул әйбәт коллективка эләккән, юлдан язып йөрми. Гәрчә, бу турыда мин сезгә әйткән идем инде. Тик шунысы бар: ул егет югары уку йортына керергә хыяллана икән. Әйтегез үзенә, әгәр тели икән, соңга калганчы, укырга керергә документларын тапшырсын. Өенә кайтып әтисен-әнисен дә тынычландырсын иде...»*

Александр Терентьевич фуражкасын салып кульяулыгы белән такыр башын сөртеп алды. Ә Гәрәй теге фаҗигале төннән соң беренче тапкыр җиңел сулап куйды, күз алдында кинәт дөнья яктырып, иркенәеп киткәндәй булды.

– Александр Терентьевич, сез белә идегезмени, ничек берни дә әйтми йөрдегез? – диде ул, бик гаҗәпләнеп. – Ә мин, белмәгәйләре дип, һаман шүрләп йөри идем.

– И энекәем, бар ишеткән-белгәнне урынлы-урынсыз сөйләп йөреп булмый. Ул чакта әле үзенне дә белеп бетермәгән идем. Менә вакыт җиткәч әйттем бит. – Александр Терентьевич чаларган мыек астыннан сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды. – Син укырга җыенып бик әйбәт итәсең, пароходта кеше җитмәсә дә, без сине тоткарламыйбыз, әлбәттә. Әгәр сер булмаса, бәлкем, әйтерсең: син укырга кая керергә телисең соң?..

Фарватер читендәге кызыл маяк турыннан үтәрәк, Гәрәй рульне, капитан күрсәткәнчә, бераз уңгарак салды һәм «Бурлак» як-якка йөгерек дулкыннар кагып турыга бара бирде. Шулчак Гәрәй тиздән бу пароход белән саубуллашырга туры киләчәген шәйләп алды, һәм аңар ничектер ямансу булып китте... Кыска гына вакыт эчендә бу иске буксир пароход аның күңеленә якын булып әверелгән бит. Кешеләре дә якын. Наратлыда авырып калган Халит та, йомшак күңелле Зәйнәп тә, тыштан кырыс күренсә дә, аталарча кайгыртучан менә бу карт капитан Александр Терентьевич та – барысы да якын, үз кешеләр бит.

– Йә, ник дәшмисең? Кайда укырга, кем булырга телисең? – диде капитан, аның уйларын бүлеп.

– Дөресен генә әйткәндә, Александр Терентьевич, сез әйткән бу хәбәрдән уйларымның очын югалттым әле мин. Бер яктан, чиксез шатмын. Шул ук вакытта күңелсез дә миңа, «Бурлак»тан, сездән аерыласым килми...

– Анысы өчен рәхмәт. Шулай да укырга кая барырга телисең? Шул хакта уйлаганың бармы?

– Кайчандыр мин җырларга ярата идем, җырчы булырга хыяллана идем. Ләкин күрәм, ул коры хыял гына булган, аңлап, белеп сайлаган юл булмаган. Әгәр көчемнән килсә, хәзер мин Елга институтына керергә, елгачы булырга телим. Бу инде коры хыял гына түгел, пароходны, елганы якыннан белеп туган теләк.

...Шул ук көнне кичкырын, кәрван Кызыл яр буеннан үткәндә, Гәрәйне көймә белән пристаньга төшереп калдырдылар. Үзе инде яр буенда булса да, аның күңеле әле һаман пароходта иде. «Бурлак,» борылыш артына кереп күздән югалганга кадәр, саубуллашу гудоклары биреп барды.

Тау өстенә менеп туган-үскән поселогына килеп кергәч, ул шатланудан чак кына кычкырып җибәрмәде. Кечкенәдән күреп-белеп үскән һәр йорт, һәр тыкрык аны сагынып көткәндер, сөенеп каршылыйдыр шикелле. Менә үз урамнары. Үз өйләренә җитәрәк, Нәсимәләр турыннан үткәндә, урамда коедан су алып маташкан бер кызны күреп, йөрәге кинәт ешрак тибә башлады, күзләре томанланды. Чынлап шулмы бу, әллә күземә генә күренәме дип уйлап куйды ул.

Менә кыз да ул килгән якка борылды һәм, әле һаман ышанмагандай, зур ачылган күзләре белән шаккатып карап торды. Танып алгач, сулы чиләге кулыннан төшеп, бер читкә тәгәрәп китте, үзе, соңга калудан курыккан кебек, ашыгып Гәрәйгә таба йөгерде.

*1967*

## Фирдәвес

*(Балалы кызга өйләнгән егет авызыннан)*

Николай белән су буенда кояшта кызынып ятабыз. Николай – боцман, мин – койрыкчы. Дөресен әйткәндә, без хәзер гади боцман, гади койрыкчы гына түгел, икебез дә су транспорты институты студентлары. Читтән торып укучылар!

Кабул ителүчеләр исемлеген бүген иртән генә элделәр. Яшерен-батырын түгел, бик куркып, борчылып көткән идек. Исемлектә үзебезне күргәч, баш күккә тигәндәй булды. Димәк, пароходка тыныч күңел белән кайтырга, озатып калган иптәшләрнең күзләренә туры карарга мөмкин. Шунлыктан күңелләр күтәренке, кәефләр шәп. Нәни малай кебек дөньяны онытып бер шаярасы, рәхәтләнеп көләсе килә.

Көне дә искиткеч матур. Яр читеннән үк башланып киткән яшел урман кошлар чыр-чуыннан, бала-чага тавышыннан гөр килеп тора. Безнең аяк очында тын елга чайкала. Ул еракка, әллә кайларга тикле җәелгән – кайда су чите, кайда күк башланганын да аерырлык түгел. Зәңгәр киңлектә, канат җәеп очкан акчарлак сыман, җилкәнле көймәләр күренә.

Безнең пароход кич белән генә килеп җитәчәк әле. Шуңарчы безгә барыбер көтәргә, теләсәк-теләмәсәк тә, яр буенда кояшта кызынырга туры килә. Николай, гамьсез сабыйдай, рәхәтләнеп ята. Ул кабак чаклы зур такыр башын таза беләгенә салган да, йөнтәс ботларын як-якка сузып, йөзтүбән яткан. Мин кулымдагы салам очы белән аның муенын кытыклыйм, ул аны чебен дип белеп, шап итеп муенына сугып ала. Мин рәхәтләнеп көләм.

Менә урман кырыендагы бакчадан икешәр-икешәр булып сафка тезелгән, җитәкләшкән балалар килеп чыкты. Ул да түгел, ком өстендә таралышып, уйнарга да тотындылар. Тәрбияче апалары – җиңел ак халат кигән, беләкләренә йөнтәс сөлге салган урта яшьләрдәге ханым һәм киң читле салам эшләпә кигән яшь кенә кыз – безнең баш очына ук килеп туктадылар. Без аларның көн дә ятып кызына торган урыннарын алганбыз, ахрысы, кашларын җыерып ризасызлык белдереп тор-

дылар. Әмма авыз ачып аны-моны әйтмәделәр. Бер-берсенә сүзсез генә карашып алдылар да, халатларын салып, безнең белән янәшә сузылып яттылар.

Өлкәнрәк яшьтәгесе базык гәүдәле, таза беләкле, аз сүзле иде. Икенчесен – минем белән янәшә ятканын күрүгә сулышым кысылгандай булды. Чия төсле алсу иреннәре, елмайган чакта күренеп калган ап-ак тешләре, кояш яктысына кысыла төшкән күзләре бер үк вакытта наян үчекләп тә, дустанә үз итеп тә карыйлар төсле иде.

Сары ком өстенә чалкан ятты да йомры беләкләрен ике якка җәеп салды, сул кулы минем беләккә орынып китте. Мин аның бармак буыннарын, уч төбендәге нәфис сызыкларын күрдем, кулыннан сыйпап алудан үземне көч-хәл белән генә тыеп калдым. Шундый да чибәр, шундый да сөйкемле кыз булыр икән дөньяда!

Бераздан ул зәңгәр күккә төбәлеп уйга калды. Шул хәлендә әкрен генә сүз башлады:

– Гөлҗамал апай, кичә син кайтып киткәч, тагын Әхәт килеп чыкты.

– Соң нәрсә ди?

– Һаман шул бер сүзне кабатлый: тиздән командировкага китәм, өч атнасыз кайтмыйм, шуңарчы барып гариза бирик, ди.

– Ә син ни әйттең?

– Ни әйтим... Теге чакны ничектер җиңел генә риза булган идем дә, вакыты җиткәч, икеләнеп калдым...

Гөлҗамал яткан җиреннән торып утырды да, кызның чәчләреннән сыйпый-сыйпый:

– Бар, Фирдәвес җаным, ике дә уйлама, тот та бар,– диде.– Үзе чибәр, үзе уңган. Андыйлар гел очрап тормый...

Ихтыярсыздан кеше серен тыңлау уңайсыз булып китте. Алар безне татарча аңламый дип уйладылар булса кирәк, тартынмый-нитми сөйләшә бирделәр.

Шул мәлне баш очыма өч-дүрт яшьлек малай килеп утырды. Утырды да кулындагы кызыл саплы тимер соскыч белән комда бик тырышып кое казырга тотынды. Фирдәвес, яткан җиреннән генә үрелеп, аны үзенә тартып китерде:

– Марат, панамкаңны ки, башыңа кояш сукмасын.

Беркавым сүзсез яттылар. Гөлҗамал әйтте:

– Марат өчен бер дә борчылма, көзгә чаклы миндә торыр. Балам бар дип яшь гомереңне заяга үткәрмәссең бит инде! – диде.

– Анысы шулаен шулай ул, Гөлҗамал апа... уйламый булмый шул... Әхәт аны өнәп бетерми кебек. Баланы телгә алдыңмы – сүзсез кала.

Алар шулай серләшеп яткан арада, балаларның бер өлеше суга кереп киткән, калганнары яр буенда борыны белән комга килеп терәлгән моторлы көймә янында кайнаша башлаган иде. Ханымнар тиз генә торып балаларны судан куып чыгардылар һәм, тагын кереп китмәсеннәр дип, үзләре дә шунда утырып калдылар. Безнең белән калган Марат та кое казып туйды бугай, кулындагы соскычын читкә ыргытты, күзенә төшкән панамкасын күтәребрәк куйды. Минем газета өстенә куйган кителемне, алтын «кәбестәле» фуражкамны күрүгә, ул:

– Әй, бу кем капитанкасы?! – дип бик гаҗәпләнде һәм минем фуражканы башына киеп карады. – Абый, син капитанмы? Чын капитан, әйе? Пароход кычкырта беләсең, әйе?.. Мин дә капитан булырга телим, ярыймы?..

– Нигә ярамасын, бик ярый!.. Зур үскәч, менә дигән капитан чыга синнән, – дидем.

– Капитан Марат: ту-ту-ту. Капитан Марат: ту-ту... т-т-ту-у... – дип, Марат бик гайрәтләнеп яңакларын күпертә-күпертә пароход булып кычкыра башлады.

Тәрбиячеләрнең кайтыр вакыты да җитте бугай. Су кереп чыкканнан соң, халатларын киделәр дә балаларны сафка җыя башладылар. Хәзер алар кереп китәчәкләр, бу искиткеч матур, сөйкемле яшь ханымны мин бүтән беркайчан да күрәчәк түгелмен бит...

Шунда башыма үзем дә көтмәгән бер шаян уй килде. Исеме Фирдәвес иде бугай. Тукта, бер кызык булсын әле... Куен дәфтәремнән бер бит кәгазь ертып алдым да яраткан җырымны сызгаладым:

Кашың кара, күзең күк,
Сиңа сөйләр сүзем күп,
Сөйләр идем дә сүземне,
Фирдәвескәй, кара күзкәй,
Кайда күрим үзеңне?..

Язып бетергәч, кәгазьне дүрткә бөкләдем дә Марат кулына тоттырдым.

– Менә бу кәгазьне Фирдәвес апаңа бир. Югалтма, хәзер үк илтеп бир, яме...

Марат, укый белгән кеше кебек, язуны әйләндереп карады да:

– Ул апа түгел, минем әни,– диде.– Ярар, хәзер илтеп бирермен... Абый, сез иртәгә дә монда киләсез, әйе?..

– Килербез, Марат, килербез... Йөгер, сине көтәләр.

Инде безгә дә кузгалырга вакыт җиткән иде. Без киенгән арада, Марат язуны әнисенә илтеп тапшырды, кулы белән безгә таба күрсәтә-күрсәтә, телдән дә нидер әйтте. Ара шактый ерак иде, мин аның ни әйткәнен ишетә алмадым. Язуны тиз генә күздән кичергәч, Фирдәвеснең ак тешләрен җемелдәтеп безгә елмаеп караганын күреп калдым.

* * *

Портка барып төшсәк, безнең пароход әле һаман килмәгән. Юлда тоткарлык булган, имеш; күпкә соңарып, кояш баер алдыннан гына килеп җитәчәге билгеле булды. Димәк, тагын өч-дүрт сәгатьне бушка үткәрергә туры киләчәк.

Иртәдән бирле рәтләп ашаган юк иде, бераз тамак ялгап алырга дип, ресторанга кердек. Зур зал шыгрым тулы. Иделгә караган ачык балкондагы өстәлләрнең берсе янында ике генә буш урын бар, анда көләч йөзле, юантык ханым белән купшы киенгән бер егет кәефле генә сыйланып утыралар. Алар инде күптән кергән булса кирәк, алларындагы шешәләре дә, тәлинкәләре дә бушаган, көл савыты папирос төпчекләре белән тулган. Ханым әйбәт кенә күренсә дә, егете шактый мәлҗерәгән, күзләре аларган, йөзе кайнар мунчадан чыккандай, кып-кызыл булып кызарган иде. Официантка безне шулар янына утыртты да заказ ала башлады.

– Николай, бик шәп ак башлар бар икән. Институтка эләгү шатлыгын юып алыйкмы? – дидем.

Боцман аракы белән дус түгел. Пароходта эчкән кешене аеруча яратмый. Әмма бу юлы каршы килмәде:

– Әйдә, синеңчә булсын, бер савыт китертик. Гөнаһысы сиңа төшәр, сакаллы сабыйны аздыручы – син, дип язып куярбыз.

Аның сүзләреннән официантка да, безнең каршыда утыручы ханым да елмаешып куйдылар. Сәрхуш егет яны белән ханымга таба борылды да, үчекләгәндәй авызын бөрештереп:

– Кара син бу юеш балакны, теленә салынган булып кылана, – диде һәм официанткага коньяк китерергә кушты.

Тамак чылатып һәм капкалап алгач, Николайның чырае ачылды:

– Уйлап карасаң, гаҗәп тә инде,– диде ул, безнең каршыдагы егеткә бермәл сүзсез генә карап утырганнан соң.– Аракы кешенең аңын гына агуламый, йөзен дә ахмакландыра. Күр инде син бу җан көеген, адәм карарлыгы да калмаган бит.

Ханым моны ишеттеме, әллә үзе сизендеме, уңайсызланып, як-ягына каранып алды, алдындагы рюмкасын читкәрәк этеп куйды. Әмма егете, инде күзләре калайланган булуга карамастан, әле һаман коньяк чөмерә һәм нидер мыгырдана иде. Официантка килгәч, ул, менюга бармаклары белән төртә-төртә, тагын заказ бирергә азаплана, ә тегесе «сезгә җиткән инде» дип алмый иде.

Зал ягында музыка яңгырады. Яшьләр парлап биергә тотынды. Николай, миңа таба иелеп:

– Бу алабай официантка белән аңлашкан арада, без биеп килик әле, – диде дә ханым белән залга биергә кереп китте.

Сәрхуш егет бераздан янында ханым юклыгын төшенде, моны ничек аңларга дигәндәй, аларган күзләре белән миңа текәлде, сүз катарга теләп, рюмкага коньяк салырга сузылды. Мин рюмкамны читкәрәк алып куйдым.

– Читсенмә, мин үзем дә елгачы,– диде ул.– Чынлап әйтәм, елгачы мин... Училищеда производство бүлеге начальнигы... Иртәгә командировкага китәм. Пароходларда безнең укучыларның производство практикасын тикшерергә, инструктажга... Арылган... Ял итеп, Иделдә йөреп кайтасы килә...

Музыка туктагач, Николай белән ханым безнең янга килделәр. Икесе дә матур булып кызарынган, күз карашлары очрашкан саен, сизелер-сизелмәс кенә елмаешып куялар иде.

Тиздән моны сәрхуш егет тә сизде. Ул, калайланган күзләрен акайтып, Николайга ачулы карана, ачыктан-ачык әйтмәсә дә:

– Кара син юеш балакны, башы эшли икән...– дип, авыз эченнән мыгырдана иде.

Эш болайга киткәч, ханым, официантканы дәшеп, тиз генә расчет ясавын үтенде. Инде эшләре бетте, хәзер чыгып китәләр дип торганда, сәрхуш тагын гауга куптарды:

– Бер шешәне артык санагансың, соңгысы минем заказ түгел иде, – дип, официанткага ташланды.

– Ничек инде сезнеке булмасын, алар коньяк эчмәделәр бит, сез сораттыгыз...

Күрше өстәлдән безгә таба борылып-борылып карыйлар иде. Ханым уңайсызланудан нишләргә белмичә:

– Анысы да безнеке. Кеше көлдермә, акчаңны түлә дә тизрәк китик, – диде.

Шул сүзгә колак салып, тиз генә түләсә, әйбәт кенә чыгып киткән булыр иде. Юк, үз ирке белән түләргә теләмәде бит... Ул андый кеше түгел, янәсе. Документларын чыгарып үзенең кем икәнлеген исбат итәргә, тагын да катырак әтәчләнергә тотынды.

Моның белән ул бик начар эшләде. Милиция бүлеге вокзалның үзендә генә икән. Шунда алып кереп түләттеләр. Шаһит итеп безне дә алып керделәр. Соңынтын кирәк булса-нитсә дип, кайсы пароходтан икәнебезне, исем-фамилияләребезне дә язып калдылар.

* * *

Үткен борыны белән киң елганы урталай ярып һәм як-якка йөгерек дулкыннар тәгәрәтеп, күгелҗем утрау артыннан «Бурлак» килеп чыкты. Корпусыннан башлап мачтасына кадәр ап-ак. Мачта очында кызыл флаг җилферди. Салон һәм каюта тәрәзәләрендә, җиз трап тоткаларында кечкенә кояш нурлары уйный. Терраса тулы халык. Радиодан әйләнә-тирәгә күңелле музыка яңгырый иде.

Ай буе күрми торгангамы, пароход бик сагынылган икән, туган-үскән авылга кайтып төшкәндәй, күңелләр нечкәреп китте. Гадәттә тойгыларын белдерергә яратмаган Николай да, зур ачылган күзләре белән бермәл карап торганнан соң, кемгәдер мактангандай:

– Күрәсеңме «Бурлак»ны?! Карт булса да бирешми. Ай да молодец! – дип әйтеп куйды.

Иң өстә, рубка алдында, капитан Ислам Идрисович. Алтынчы дистәсен тутыра кеше. Ак китель белән кара чалбар аны егетләрдәй чибәр һәм нык итеп күрсәтә әле. Менә ул яр буйларын, тау битенә урнашкан шәһәр-бистәләрне яңгыратып гудок кычкыртты.

Әнә бит ничек: үз пароходыңның тавышы да тансык, күңелләрне җилкетеп җибәрде.

Команда членнары безне якты йөз белән каршыладылар. Ислам Идрисович югарыда торган җиреннән елмаеп кул болгады. Алгы палубада җиңнәрен сызганган Вәлишин, пристаньдагы халык арасыннан безне танып:

– И, кемнәрне күрәм мин!.. Студентларыбыз кайткан лабаса! Шулай да мәгез, тотыгыз! – дип, селтәнеп торып кулындагы чалкасын ыргытты һәм мин аны тартып алып причалдагы тумбага эләктереп куйгач, теленә салынып мактап та куйды: – Молодец икәнсең әле, студент булдым дигәч тә, кулларың чалкадан бизмәгән...

Причалга трап салу белән, малай-шалай кебек түземсезләнеп, пароходка кереп киттек. Пролетта пассажирлардан читтәрәк басып торган команда членнары белән кул биреп күрешеп чыктык. Рәхәтләнеп күрештек. Күзләренә туры карап.

Ул арада Ислам Идрисович төшеп җитте, туган улын каршылагандай, ачык чырай белән:

– Исән-сау кайтып җиттегезме?.. Юлыгыз уңдымы? – дип, гөр килеп сораштыра башлады.

Үзең бәхетле булгач, дөнья ал да гөл булып күренә, эчкә сыймаган шатлыкны иң якын кешең белән уртаклашасы, үзең бәхетле булган кебек, аны да бәхетле итәсе килә бит. Чемоданымны каютага кертеп куйгач та, Гөлчирәне күрергә ашыктым. Торак каюталар буеннан үттем, коридорларны һәм палубаны йөреп чыктым, команда кешеләренең һәммәсен күреп бетердем диярлек. Әмма мин ашкынып эзләгән, имтихан тапшырган көннәрдә өзелеп сагынган кешем – Гөлчирәне генә очрата алмадым. Кеше-кара күрмәгән арада, камбуз ишегеннән караштыргалап та, каютасы яныннан да берничә мәртәбә үттем. Әмма ул юк, ул югалган.

Боегып, моңаеп, пароходта йөренә башладым. Ул мин бөтенләй көтмәгән җирдән – беренче штурман каютасыннан килеп чыкты. Чыгып кына калса бер хәл иде, мине бөтенләй дә күрмәгән сыман, ак халатын төймәли-төймәли, җиңел адымнар белән камбузга таба китеп барды. Өметсез шайтан, ди. Ул мине, бәлки, чыннан да күрмәгәндер, күрсә дә танымагандыр? Мин аның артыннан:

– Саумы, Гөлчирә?.. Туктале, менә без кайттык иҗ, – дип, аның белән сөенечемне уртаклашырга теләдем.

Гөлчирә туктамады. Чак кына борылып, күз кырые белән ничектер төрпе генә карап алды да, берни дә әйтмичә, камбузга кереп китте. Мин исә, кинәт миңгерәүләнгән кешедәй, моны башыма сыйдыра алмыйча, баскан җиремдә катып калдым.

Ашханә ишеге янындагы эскәмиядә кичке аштан соң, куе төтенгә күмелеп, Вәлишин тәмәке тартып утыра иде. Әнә шул әрем тел минем аптырап калуыма бермәл күзләрен чекерәйтеп карап торды да ихлас күңелдән кызганган кыяфәт белән:

– И брат, юкка күз атып йөрисең, соңга калдың бит... Һи-һи-һи... – дип, борын тишекләреннән төтен чыгара-чыгара, ямьсез итеп көлеп җибәрде.

Кинәт кузгалган ачуымны тыя алмыйча:

– Ничек соңга калдым?! Шамакайланма, адәм рәтле әйт: ни булды? – дип, бугазыннан буып алдым.

Вәлишин куркудан хәтта ап-ак булды, тәмәке төтененә тончыга башлады:

– Җибәр, аю! Буып үтерәсең ич...

– Кара аны, авызың сөйләгәнне колагың ишетмәсә...

– Ничек инде ишетмәсен, аны бөтен пароход күрә ич. Үзеңне-үзең кимсетеп йөрмә, дип, якын күреп әйтүем.

Моның шулай икәнен мин үзем дә сизеп өлгергән идем инде. Тик әле ышанырга белмичә, икеләнебрәк тора идем. Вәлишинның соңгы сүзләре, гадәтенчә ямьсез итеп көлмичә, ничектер гафу үтенгән сыман, мине кызганып әйтүе икеләнүемне юкка чыгарды, тормышымда аяныч бернәрсә булганын аңлап алдым.

* * *

Бу ничек болай булды соң?

Безнең дуслык бик матур башланган иде бит. Гөлчирә белән без балалар йортында үстек, мәктәптә дә, училищеда да бергә укыдык.

Гөлчирә кечкенәдән үк шук телле чая кыз иде. Дөньясын онытып шаяра, усал малайлар белән ду килеп сугыша; шуның аркасында малайлардан да, тәрбиячеләрдән дә аның үзенә дә еш кына эләгә иде.

Бер тапкыр, бишенче класста укыганда бугай, мин аның үзе хәтле ике малай белән бакчада чынлап торып сугышканын күрдем. Әгәр шул чакны мин аралап калмасам, эше хөрти иде. Шуннан бирле ул миңа абыйсыдай олы итеп карый, кыерсытырга уйласалар, минем канат астына сыена иде.

Училищеда укыганда, без бер-беребезгә гашыйк булдык. Җәй урталары иде бугай, бер төркем яшьләр көймәгә утырып, Идел аръягына чыктык. Көне дә бик матур туры килде. Рәхәтләнеп су кердек, комда кызындык, уеннар уйнадык, әрәмәдә карлыган, кура җиләге җыйдык. Ничектер шулай килеп чыкты: сүз куешмасак та, Гөлчирә белән мин һаман бергә булдык. Йөри торгач, без иптәшләрдән аерылып ерак киткәнебезне сизми дә калганбыз.

Кичкә таба кайтырга борылганда, ярты күкне болыт каплады, кояшлы яңгыр ява башлады. Якында гына, түгәрәк алан уртасында, күптән түгел өеп куелган печән кибәне бар икән. Күреп алу белән, кулга-кул тотынып, шунда йөгердек һәм кибән астындагы куышка кереп ышыкландык.

Моңарчы безнең беркайчан да болай аулакта икәү генә калганыбыз юк иде әле. Кинәт бөркү булып китте. Тышта яңгыр яуганы да, яфраклар шаулавы да юк булды, аларның барысын басып, юеш күлмәк аша Гөлчирәнең йөрәге дөп-дөп тибә, кайнар сулышы битемне көйдерә, һәм мин, нишләгәнемне белештермәстән, аның битемә тиеп үк торган иреннәреннән үбеп алам. Гөлчирә телдән: «Юк, юк, ярамый», – дип пышылдаса да, үзе калтыраган беләкләре белән муенымнан кочаклап, миңа сырыша һәм шашынып үбәргә тотынды...

Училищены тәмамлагач, безнең икебезне дә бер судногa: мине – рулевой, аны кок итеп «Бурлак» пароходына җибәрделәр. Пароход тормышына без бик тиз ияләштек. Чандыр гына гәүдәле Гөлчирә, әллә ни арада буйга үсеп, тулышып китте һәм бик күпләрнең күзе төшәрлек чибәр кыз булып җитеште. Камбуз тәрәзәсеннән савыт белән аш биргән чакларда, матрослар, машинистлар аның зәңгәр күзләренә, кызуда эшләүдән матур булып кызарган йөзенә карана башладылар.

Соңгы вакытта аның тирәсендә беренче штурман Сәмигуллин чуала башлады. Җыелышларда урынлы-урынсыз мактап, берәр шәһәргә чыкса, вак-төяк бүләкләр ташып, төрле мәзәкләр белән шаяртып-көлдереп, аның башын әйләндерергә тотынды.

Баштарак мин Сәмигуллиннан көнләшмәдем, Гөлчирә аның коры куык икәнен аңлар, бик тиз күңеле бизәр дип уйлаган идем. Бактың исә, әнә ничек килеп чыкты.

* * *

Төне буе йокы күрмәдем. Берсеннән-берсе авыр, берсеннән-берсе үкенечле уйлар күңелемә килә, тормышымның яме калмаган төсле тоела. Бик азга гына онытылып черем иткән араларда әллә ниткән төшләр күреп саташып беттем, тик таң алдыннан гына йокыга талдым.

Озак йокларга туры килмәде. Тышкы яктан каты итеп ишек шакыганга сискәнеп уяндым. Күземне ачсам – әле бик иртә, вахтага чыгарга тагын өч сәгатьтән артык вакыт бар. Димәк, авралга чакыралар.

Торып ишекне ачтым, боцман Николай килеп керде. Өстендә – эшкә кия торган иске кителе, башында – изелеп беткән фуражкасы.

– Әйдә киен, механик чакыра, – диде ул, иллюминаторны ачып. – Сул көпчәкнең бер канаты ватылган, төзәтергә кирәк.

Бүтән көннәрне мин гел көлеп уянам һәм, Николайны шаяртып, тагын одеял астына кереп ята торган идем. Бу юлы көрсенеп кенә куйдым да, ашыктырганны да көтмәстән, өстемә киенә башладым.

...Мин киенеп чыкканда, пароход инде Чабаксарга килеп туктаган, боцман Николай белән механик Сергей Петрович сул көпчәк янында маташалар иде.

– Менә бу шайтан көпчәгенең калагы сынган,– диде механик, эчкә күрсәтеп.– Пароход туктап торган арада, шуны төзәтеп өлгерергә кирәк. Югыйсә расписаниедән кичегү куркынычы бар.– Гафу үтенгәндәй, икебезгә дә елмайганнан соң, ул тагын өстәп куйды.– Моны сез түгел, без, механиклар, ремонтларга тиеш идек. Ләкин анда подшипник киреләнә башлады. Кыскасы... сез, уңган егетләр, тырыша күрегез инде... Менә сезгә яңа калак, менә сезгә инструментлар.

– И дә хәйләкәр соң сез, Сергей Петрович, – диде Николай, аның кулыннан ачкычларын алып. – Болай оста юмалауга каршы торып булмый, кулдан килсә-килмәсә дә, тотынырга туры килә. Булдыра алмасак, ачуланмагыз...

– Була, сез беренче мәртәбә генә түгел лә... Мин сезгә ышанам, – дип сөйләнә-сөйләнә, Сергей Петрович түбәнгә, машинистлар янына ашыкты, без тегермән тәгәрмәче хәтле иләмсез зур көпчәк ныгытмалары арасына мүкәйләп кереп киттек.

Төнге караңгыда бүрәнә бәрелгән булса кирәк, көпчәкнең бер канаты урталай сынган, аркылыга каерылып тора иде. Иң элек гайкаларны ычкындырып, шуны алып ташладык, аннары, яңа калакны алып кереп, борау белән болтларга тишекләр тишә башладык.

Көпчәк арасында ярым караңгы һәм юеш. Түбәндә, аскы калакларга бәрелеп, чалт-чолт су чәчри, өстән тамчы тамып тора. «Эчке якта берәрсе машинага ялгыш пар җибәрсә, көпчәк әйләнеп безне харап итәчәк». Боцманга күз салам, Николай тыныч, авыз эченнән нидер көйли-көйли, калакның аргы башын гайкалар белән борып беркетә. Бер кызып киткәч, мин дә тынычландым. Авыр ачкычлар белән зур-зур гайкаларны борып, калакны ныгытып бетергәндә, шабыр тиргә баткан һәм дөньямны оныткан идем.

Ул арада, майлы кулларын коры чүпрәккә сөртә-сөртә, Сергей Петрович килеп җитте. Бик җитди кыяфәт белән безнең эшне җентекләп тикшерде, без куйган калакның барлык винтларын карап чыкты, тик шуннан соң гына:

– Булган бу, бик әйбәт булган. Молодцы! – дип, икебезнең дә иңбашларыбыздан кагып алды. – Без дә тегендә машинаны рәтләп бетердек. Хәзер кузгалабыз. Сез булышмасагыз, тагын ике сәгать чамасы казынырга туры киләчәк иде. Рәхмәт, дусларым.

* * *

Бу көннәрдә минем тормыш бик көйсезләнеп китте, өермә актарып ташлаган елга суыдай, тәмам буталып, асты өскә әйләнде. Бәланең берсеннән арынып һушымны җыярга өлгермәдем, икенчесе килеп төште. Авырткан башка тимер тарак дигәндәй, кичәге хәсрәт өстенә бүген көндез профсоюз җыелышында яңа бәла өстәлде.

Мин барып кергәндә, кызыл почмак инде шыгрым тулган, вахтадан буш булган команда членнары да, ресторан кешеләре дә – барысы да шунда җыелган; судком председателе Камардин, өстәлдәге кәгазенә иелеп карый-карый, үткән айның ярыш йомгаклары турында сөйли иде. Мин сиздерми генә керергә тырышып арткы рәттәге Николай янына кысылып утыруга, шуны гына көтеп торгандай:

– Әнә кулдашы да килеп керде,– дип, безнең якка төртеп күрсәтте.– Кичә судком утырышында беренче урынны беренче вахтага бирергә уйлаган идек. Болай бу вахтаның бөтен күрсәткечләре әйбәт кебек. График үтәлеше дә, ягулык һәм майларга экономия ясавы да, чисталык ягы да тел-

теш тидерерлек түгел. Әмма бу вахтада хезмәт дисциплинасы бик нык аксый, гафу итмәслек аксый, бөтен команданы оятлы итә...

Кешеләр карашып алдылар. Алгы рәттән кемдер берәү түземсезлек белән:

– Аңлашылмый әле бу, ачыграк итеп әйт, – дип кычкырды.

– Монда аңлашылмаслык берни юк. Бар да, аяз көн кебек, ап-ачык. Без эштән азат итеп әйбәт характеристика биреп институтка керергә җибәргән чибәр егетләребез – боцман Карпов белән рулевой Бакиров – Горькийда эчеп, сугышып йөргәннәр, милициягә эләккәннәр... Ышанмасагыз, әнә беренче штурманнан сорагыз.

Беренче штурман озак көттермәде. Бу хәлгә аптыраган кешеләр тын калгач, урыныннан торды да ачык тәрәзәдән каядыр еракка караган хәлдә:

– Үзегез беләсез, Горький вокзалында милиция бүлегендә минем энекәш эшли,– дип, тыныч кына сөйләп китте.– Кичә туктап торган чакта энекәш янына кергән идем. «Сездә Карпов белән Бакиров эшлиме?» – ди. Эшли, мин әйтәм. «Эшләсә, сак булыгыз, коллективны хур итә күрмәсеннәр. Кичә ресторанда эчеп-исереп хатын-кызларга бәйләнеп йөргәннәр, милициядә эшләрен тикшердек»,– диде.

Баягы түземсез кеше, әле һаман ышанырга теләмичә, тагын кычкырып куйды:

– Бу ничек була инде, алар соң укырга кермәгәнмени?

– Кем белгән аларны...– дип, Камардин кулларын җәеп җибәрде.– Әйдә, үзләре сөйләсен.

Әлегә хәтле ышаныр-ышанмас тыңлаган кешеләр барысы берьюлы безгә каерылып карадылар, әле аннан, әле моннан:

– Әйдә, үзләрен тыңлыйк... Үзләре җавап бирсеннәр,– дип кычкыра башладылар.

Мин, ни әйтергә белмичә, бер мәлгә уңайсызланып калдым. Николай, зур гәүдәсе белән ян тәрәзәне каплап, аягүрә басты да, әйтер сүзләрен оныткандай, тамак кыргалап, булган хәлне сөйләп бирде:

– Менә шул, без бераз тамак ялгап алырга гына кергән идек. Яшермим, бик аз гына тамакны да чылатып алдык. Әмма беркемгә дә бәйләнмәдек... Кем белгән аның шулай килеп чыгасын,– дип, көч-хәл белән сүзен тәмамлады.

– Һи, кара син бу мескеннәрне...– дип, Камардин зәһәр көлеп куйды.– Тамак ялгарга гына кергәннәр дә эчеп-исереп җәнҗал куптарганнарын сизми калганнар, имеш...

– Юк, иптәшләр, көлкегә бора торган эш түгел бу. Хәзер монда бөтенләй бүтән ситуация килеп чыга түгелме? Шулай бит... – Сәмигуллин, сүзеннән туктап, җавап көткәндәй, әйләнә-тирәсенә караш ташлады. – Транспортта эчүчелеккә каршы каты көрәш барган бервакытта, безнең укырга керергә дип киткән үрнәк егетләребез, ресторанда исереп, гауга чыгаралар, милициягә эләгәләр. Шундый кешеләргә институтка керергә фәтва бирә алабызмы без? Сез миңа шуны әйтегез: бирә алабызмы, юкмы? Шундый ышанычка лаекмы алар, юкмы?.. Минемчә, юк һәм булуы мөмкин дә түгел... Әнә шул хакта институтка хәбәр итәргә кирәк, исемлектә урын биләп тормасыннар...

– Минемчә дә шулай,– дип, Камардин тагын да катырак кызып китте.– Иптәш Сәмигуллин дөрес әйтә, Бакиров белән Карпов безнең ышанычны акламаганнар, безнең пароходка тап төшергәннәр икән, димәк, без аларга укырга рекомендация бирә алмыйбыз, шул хакта институтка хәбәр итәргә тиешлебез. Тагын кемнең нинди тәкъдиме бар?

Бу сүзләрдән миңа эсселе-суыклы булып китте, сулышымны кысып тамак төбемә төер менеп утырды. Кешеләр бер-берсенә тагын борчулы карашып алдылар. Түр тәрәзәгә яны белән утырган механик Сергей Петрович китель якасының өске каптырмасын ычкындырды да, гадәтенчә акрын тыныч тавыш белән:

– Дуслар, без төп мәсьәләдән читкә кереп киттек, чебеннән фил ясый башладык бугай,– диде.– Моңарчы без Карповны да, Бакировны да эштә тырыш, тәртипле егетләр дип белә идек. Бу күңелсез вакыйганы алар үзләре бөтенләй башкача сөйли бит. Димәк, аны башта яхшылап ачыкларга, шуннан соң гына чара күрергә кирәк.

– Дөрес! – диде Ислам Идрисович, аны хуплап.– Көн тәртибенә ярыш йомгаклары куелган икән, ярыш йомгаклары хакында сөйләшергә кирәк. Бакиров белән Карпов турындагы хәбәрне болай имеш-мимешкә таянып кына карап булмый. Горькийга менгәч тикшерербез. Чиста суны болгатырга ашыкмыйк әле.

* * *

Пароход авыл кебек: яңа хәбәр аның бер башыннан бер башына сәгате-минуты белән килеп җитә. Әле генә безнең «эчеп-исереп» йөрүебез турында шау-гөр килгәннәр иде, кичкә таба яңа медичка матрослар теленә кереп китте. Ул аның чибәрлеге! Ул аның буй-сыны!

Кичке аштан соң кызыл почмакта телевизор карап утыра идек. Николай терсәге белән янтыгыма төртеп алга таба ым какты. Ул әйткән якка борылып карасам, ни күзем белән күрим: бер генә рәткә алда безгә чак кына яны белән борылып... Фирдәвес утыра. Дөресен әйтим, башта ышанмадым. Ул түгелдер, күземә генә күренәдер, дип, алгарак сузылып, тагын карадым.

Әмма икеләнергә урын юк. Башын чак кына кыңгыр салып, гәүдәсен горур тотып Фирдәвес утыра. Матур итеп уеп ясагандай түгәрәк ияге дә, хәтта колагында җемелдәп торган асылташлы алкасы да – барысы да анык. Әмма шунысы бик сәер, безнең пароходка кайчан һәм ничек килгәнен, безнең кызыл почмакка ничек кергәнен һич кенә дә аңлап булмый. Тик бераздан, өстендә ак халат икәнлеген күргәч кенә, яңа медичка менә кем икән дип уйлап куйдым.

Теге көнне пляжда яткан вакытта Николай аны-моны күрмәгән шикелле иде. Кинодан соң, палубада икәү генә калгач, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды:

– Күрдеңме теге асыл кошны? Шул үзе ич, – дип, Фирдәвес үтеп киткән якка борылды. – Менә сиңа мә, медичка икән ләбаса. Теге чакны бик хәйран калган идең. Әнә артыңнан килеп тә җиткән. Кара аны, тагын башыңны җуя күрмә...

Ник икәнен үзем дә абайламастан, кып-кызыл булып кызардым. Каушавымны белдермәс өчен ачулы кыяфәт белән:

– Нәрсә әйтмәкче буласың? Ташла әле шул урынсыз шаяртуларыңны! – дип, аны кырт кистем дә, ялгызым гына калырга теләп, каютама кереп киттем.

Төнге вахтага чыкканчы бераз черем итеп алырга кирәк. Юкса таң алдыннан йокы килеп алҗыта. Яртылай чишенеп урыныма яттым, тизрәк йокыга китү өчен, гадәтемчә, санарга тотындым: бер, ике, өч... Бүтән вакытта егермегә җиткәнче оеп киткәнемне сизми дә кала идем. Бүген менә йөздән үттем инде, күздә йокының әсәре дә юк. Борсаланып озак яттым. Кинәт ямансу булып китте. Йоклап булмаячак иде – торып утырдым. Ачык тәрәзәнең пәрдәсен төшереп, ут кабыздым да, акрын гына көйли-көйли, өстемне киенә башладым.

Тышкы яктан, бик якыннан гына, кемнеңдер ишетелер-ишетелмәс кенә тамак кырганы ишетелде. Аны-моны уйлап тормастан, пәрдәне ачып тышка карадым һәм нәкъ минем тәрәзәм каршындагы эскәмиядә утырган Фирдәвесне күреп таң калдым. Идел өстендә инде төн карасы куерып килгән вакыт булса да, тәрәзәдән төшкән ут яктысында мин аны шундук таныдым һәм хәтта чак кына сискәнеп куйганын да күреп калдым. Хәер, бу көтелмәгән очрашудан мин үзем дә ничектер каушап киттем һәм, тел тибрәтә алмыйча, бер мәлгә сүзсез торганнан соң гына:

– Мин сезне борчыдым бугай, кичерегез, – дидем.

– Зыян юк, йоклар алдыннан һава алырга чыккан идем...

Бөтенләй сүзсез калмас өчен:

– Медицина кешеләре режим белән яши шул, – дигән булдым.

– Сез минем медицина кешесе икәнемне каян белдегез әле? Мин, бәлкем, бөтенләй медицина кешесе түгелмендер...

– Менә тамаша, үзебезнең пароход медичкасын ничек белмәскә...

– Һи, сез пассажир түгелмени, шушы пароходта эшләүчемени? Ә нишләп соң мин көндез, пароходны йөреп чыкканда, сезне күрмәдем.

– Сез команда белән танышканда, мин вахтада булганмындыр... Ә менә кызыл почмакта мин сезне күрдем...

Фирдәвес, әле һаман ышанып бетмәгәндәй, башта миңа, аннары каюта эченә карады һәм стенада эленеп торган ак кителемне, эмблемалы фуражкамны күреп булса кирәк:

– Чынлап та пароходта эшләүче икәнсез, – диде. – Мин сезне кызыл почмакта ничек күрмәгәнмендер. Кино башланганны көтеп утырган чакта, Гөлчирә миңа андагы кешеләрнең барысы турында да сөйләгән иде, никтер сезнең хакта гына берни дә әйтмәде.

– Анысын белмим инде, мин үземнең сезне күрүемне генә әйтүем. Хәер, мин сезне моңарчы да бер тапкыр күргәнем бар бит...

– Булмас, ялгышасыздыр, – диде Фирдәвес. – Әллә болай шаяртып кына әйтүегезме?

– Юк, ялгышмыйм, һич онытасым юк ул очрашуны...

Шуннан соң Фирдәвес бигрәк тә гаҗәпкә калды, балаларча түземсезлек белән:

– Кара син, шулай укмыни?.. – диде. – Ничек соң мин аны үзем белмим? Йә, алайса, үзегез әйтегез инде.

Сөйләп бирергә өлгермәдем, вахтага чыгарга хәбәр итеп, алгы палубада кыңгырау кага башладылар.

* * *

Ислам Идрисович белән очрашканда, мин аның күзенә туры карап, бер дә тартынмый, елмаепкөлеп исәнләшә торган идем. Бүген аны алгы палубада күрү белән кинәт уңайсызланып калдым һәм, күзенә чалынмас өчен, тизрәк өченче класс коридорына борылдым. Әмма капитан күреп өлгергән икән.– Бакиров, туктагыз әле, – дип, үзе дәште ул. – Кая болай ашыгасыз?.. Миңа керик әле.

Ислам Идрисовичның каютасы өске катта беренче класс салоны белән янәшә урнашкан. Барып кергәч тә, иң әүвәл каютаның иркенлегенә, чиста итеп җыештырылган, һәрнәрсәнең үз урынында булуына игътибар иттем. Ишектән уң якта зур көзгеле кием шкафы. Түр тәрәзә буенда яшел постау җәелгән язу өстәле. Стенадагы киштәдә төрле китаплар, дәреслекләр, кагыйдәләр, расписаниеләр. Тәрәзә белән барометр арасындагы буш урынга Ислам Идрисовичның яшь чагында хатыны һәм бәләкәй улы белән өчәү бергә төшкән фоторәсеме элеп куелган.

Минем бу каютада моңарчы да бер мәртәбә булганым һәм карт капитанның элекке Идел, елгачылар турында күргән-белгәннәрен, үз башыннан кичкән гыйбрәтле хәлләрне сөйләгәнен онытылып тыңлап утырганым бар иде. Хәзер исә мин, аның күзенә туры карарга базмыйча, башым түбән идем. Ислам Идрисович та уңайсызланып калды булса кирәк, көрсенеп куйды, үтәли күрергә теләгәндәй, мине ашыкмый гына күздән кичерде дә:

– Рөстәм, син бер дә алай түгел идең, нишләдең соң син? – дип, миңа төбәп карады.

Тизрәк акланырга кирәк иде:

– Ислам абый, зинһар, начар уйлый күрмәгез...– дидем.– Дөрес хәбәр түгел ул, ялган... Ышаныгыз.

– Ышанам мин сиңа, Рөстәм. Тик әле... олыларча киңәш итеп әйтүем: аракы – акыллының ярты акылын, акылсызның бөтен акылын алырмын, дип әйтә, ди. Моны мин үз башымнан кичердем.

Мин юләр, гаҗәпләнүемне тыя алмыйча:

– Ислам абый, ни сөйлисез?.. Сез эчкече идегезмени? – дип ычкындырганымны сизми дә калдым.

Истәлекләргә чумган капитан бу сорауга җавап бирмәде. Мине бөтенләй оныткандай, стенадагы фоторәсемгә бермәл сүзсез генә карап торганнан соң:

– Кичке техникумны тәмамлап чыккан көнне төшкән рәсем,– дип ашыкмый гына сөйләп китте.– Мин ул җәйне «Чаткы» дигән кечерәк кенә бер баркаста эшли идем. Капитан ярдәмчесе. Тормышымның иң бәхетле чагы шул булгандыр. Чынлап та, минем ише ятим үскән адәмгә ни җитмәгән: кечкенәдән хыялланган һөнәрем бар, яраткан хатыным бар, алма кебек матур улым бар. Эштән бушау белән туп-туры өйгә – газизләрем янына ашыга идем.

Беләсеңме, ул елларда елгачылар арасында искедән калган бер начар гадәт яшәп килә: кайбер яшь-җилкенчәк вакытлы-вакытсыз эчкәләүне үзенә бер егетлек, гайрәтлелек дип саный иде. Көннәрдән бер көнне бу сазлыкка мин дә кереп баттым: эшкә барышлый да, кайтышлый да буфетка кереп, аяк өстеннән генә тамак чылатып алам. Әгәр шунда кереп тамак кычытканын басмасаң, нидер җитмәгән кебек, кәеф китек була торган иде.

Бөтен Иделне шомга салган фаҗига буласы кичне дә, эшкә барышлый, гадәтемчә, берне төшереп алган идем. Вахтаны кабул итеп алдым да кранчыларны, грузчикларны рудникка илтә киттем. Төнге сменага – таш төяргә. Арада Наҗия дә бар: курста укыганнан соң, аның кранда яңа гына эшли башлаган көннәре иде. Көн болытлы. Яңгыр сибәли. Кешеләрем түбәндә, кубрикны шаулатып җырлап бара. Наҗия дә җырлый, тик аның гадәттәге шат тавышы ул көнне никтер сагышлы иде. Бәлки, миңа гына шулай тоелгандыр.

Төрле-төрле суднолар белән тулы тыгыз рейдтан елгага чыктым. Төн караңгылана төште. Берни күрерлек түгел. Фарватерны маяк утларына карап кына чамалыйм.

Түбәндә җырлыйлар. Караңгыга күз күнегә төшкәч, мин дә кушылып җырлый башладым. Үзем һаман бер нәрсәне – Наҗиямнең сагышлы итеп җырлавын башыма сыйдыра алмыйм. Ни булган аңар, ник алай сагышлы ул?..

Шулай үзалдыма шомланып барганда, кинәт якында гына нәрсәнеңдер куәтле шарлавыктай шаулавын ишеттем. Карасам – түбән яктан өстебезгә әкәмәт зур судно ыжгырып килә. Уты юк, сигналы юк. Каушадым. Кай якка борылырга белмим. Гудок кычкыртып тавыш бирерлек тә вакыт юк. Кубриктагыларга кычкырырга да өлгермәдем. Теге судноның килеп бәрелүе булды, безнең баркас дөбердәп авып та китте. Упкын мине рубкадан бәреп чыгарды да төпкә алып төшеп китте...

Бераздан, мин өскә калкып чыкканда, безне батырган судно инде кире борылган, прожекторы белән су өстен яктыртып безгә таба килә. Су өстеннән тавышлар ишетелә. Теге суднодан төшерелгән көймәләр халыкны җыеп йөри. Прожектор уты көймәләргә юл күрсәтә. Тиздән барыбызны да коткарып бетерделәр, карасам – Наҗия юк... Йөрәгем жу-у итеп китте. Кычкырып та карадык, эз-

ләмәгән җир калмады – юк Нажия. Өч көннән соң үле гәүдәсе балыкчылар җәтмәсенә эләгеп чыкты.

Карт капитан, сүзеннән туктагач, кайгылы истәлекләрдән арына алмыйча, башын түбән игән хәлдә тынып калды. Мин, аны ничек тә бераз юатасым килеп:

– Ислам Идрисович, үзйөрешле баржаның сигнал утлары булмаганга сез гаепле түгел ич... – дидем.

– Анысы дөрес, турыдан-туры минем гаеп юк. Соңынтын шул беленде: ул баржаның штурманы да, койрыкчысы да салмыш булганнар, караңгы төшкәч, сигнал утларын кабызырга онытканнар. Әгәр бер дә эчмәсәм, бәлкем, мин дә игътибар белән карап барган булыр идем, үзйөрешле баржаны алданрак күреп, ничек тә котылу әмәлен тапкан булыр идем... – Ислам Идрисович боларны миңа сөйләүдән бигрәк, үзалдына уйлангандай, пышылдап кына әйтте. Аннары, истәлекләреннән арынырга теләгәндәй, гәүдәсен турайтты һәм инде гадәтенчә ныклы тавыш белән өстәп куйды: – Безнең эштә, Рөстәм, менә нәрсәне аңларга кирәк: Идел нык ихтыярлы кешеләрне ярата, чүпчарны кабул итми, иртәме-соңмы ярга чыгарып ташлый.

* * *

Николай мине палубада көтеп торган икән. Капитан яныннан чыгып түбән төшүгә, шул килеп чыкты:

– Йә, ничек, кирәгеңне бирдеме? – дип култыклап алды. – Синең кергәнне күреп калдым мин. Шуннан элек кенә анда мин дә булган идем. Чыккач сине искәртеп куярга өлгермәдем, гафу ит инде... Син ни әйткәнсеңдер, мин берсен дә яшермәдем, дөресен сөйләп бирдем.

– Мин дә дөресен әйттем. Шундый киң күңелле картка ялганларга телем тартмады...

– Анысын әйбәт иткәнсең, молодец! Әгәр дә икебез ике төрле сөйләгән булсак, картның хәтере калыр иде,– диде Николай, тәмам тынычланып. – Шулай да эт адәм икән Сәмигуллин. Кара ничек күпертә.

– Үзенең арты чиста түгел.

– Ничек?

– Кичә кич Куйбышев вокзалында туктагач, алгы пролетта трап янында тора идем. Инде пассажирларның төшәсе төшкән, утырасылары утырып беткән, кузгалып китәргә сигнал гына көтә идек. Шунда грузчик кебек таза бер хатын килеп керде. Сигез яшьлек малай иярткән. Бер кулында чемодан, икенчесендә кәрзин. Бик ашыгып килгән, күрәсең, тирләп чыккан, уф-уф итеп көчкә сулый.

– Гражданка, рәхим итеп билетыгызны күрсәтегез,– дип туктаттым мин аны.

– Абау, нинди билет ул... Бу «Бурлак» пароходы түгелмени? – дип, хатын аптырап калды.

– Әйе, бу «Бурлак» пароходы,– мин әйтәм,– әмма барыбер билетыгыз булырга тиеш.

– Һи, башта ук шулай диләр аны...– ди. Күзләреннән утлар чәчә.– Бу пароходта минем законный ирем эшли, беренче штурман Сәмигуллин. Менә бу аның улы, без аңа кунакка килдек.

«Әһә, мин әйтәм, бу законный хатын карт әтәчнең кикриген бик тиз шиңдерер». Күп сөйләнеп торасы юк. Кулындагы чемоданын алдым да иренең каютасына озатып куйдым. Кунакны коридорда калдырып булмый, каюта ишеген дә үзем шакыдым:

– Иптәш штурман, сезгә кунаклар килгән, рәхим итеп каршылагыз!

Каютасында чагы икән. Эчке яктан аяк тавышы, кемнеңдер кабаланып пышылдаганы ишетелде. Ниһаять, ишекне яртылаш кына ачып, Сәмигуллин үзе карады һәм, көтмәгәндә хәләл җефете белән улын күреп, коелды да төште, ни әйтергә белми, авызын ачкан хәлендә катып калды. Аннары, аңына килгәч, хәзер, бер генә минутка, дип, ишекне ябып куймакчы иде, хатыны бик тә зәһәр нәрсә икән, ябарга ирек бирмәде. Ирен бер якка этеп җибәрде дә искиткеч җитезлек белән каюта эченә атылып кереп китте.

Бу миңа бик сәер тоелды.

– Ничек инде аның хатыны булсын, берәр авантюристкадыр ул,– дип, мин аның сүзен бүлдем.– Сәмигуллин ялгызак ич ул, Гөлчирәгә өйләнергә җыенып йөри иде бит.

– Мин дә шулай уйлый идем, әнә ничек килеп чыкты. Гөнаһ шомлыгы – Гөлчирә үзе дә Сәмигуллин каютасында булган икән. Мин шундук китеп бардым, ике көндәшнең ничек очрашканын да, беренче штурманның җәнҗалдан ничек котылганын да күрмәдем. Актыктан бер матрос әйтте, Сәмигуллинның хатыны каютага барып керү белән коточкыч тавыш куптарган, әшәке сүзләр белән сүгә-сүгә, тегеләрнең битләрен тырнап бетергән.

– Тукта әле, тузга язмаганны сөйләмә,– дидем мин, әле һаман ышана алмыйча.

Николай, ачуланып, миңа карап алды. Гел шулай ул: үзем күптән җәннәттә, күршем өчен кайгырам. Эт каешы – безне батырмакчы иде.

– Гөлчирәсе җәл. Ни дисәң дә, кыз кеше бит, халык күзенә ничек күренер инде, бичара,– дидем мин.

* * *

Фирдәвесне мин террасада очраттым. Каютада бик бөркү булгач, бераз җилләнергә теләп, мин дә шунда менгән идем. Койрык яктан әйләнеп күләгәгә чыксам, икенче класс салоны каршындагы эскәмиядә Фирдәвес утыра. Өстендә ак халат. Коңгырт чәчләрен артка яткырып тараган. Уйчан күзләренең карашы каядыр еракка, киң тугайлар артындагы күгелҗем тауларга юнәлгән иде.

Безнең пароходны канатлы «Метеор» куып җитте һәм, су өстендә йөгерек дулкыннар тәгәрәтеп, якыннан гына узып та китте. Аннан берәрсе сәлам биреп үттеме, әллә болай гынамы – Фирдәвес кул болгап калды һәм, «Метеор» үткән якка бермәл карап торганнан соң, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды. Аннары ул, мине күреп, дусларча ягымлы тавыш белән:

– Хәерле көн, исәнмесез! – дип, башлап үзе исәнләште һәм, үзе белән янәшә урын биреп, читкәрәк күчеп утырды. – Көнне әйтәм, бигрәк тә матур инде, сокланып туймаслык!

– Дөрес әйтәсез, Иделнең иң матур чагы.

– Карагыз әле, кичә сез башлаган сүзегезне әйтеп бетермәдегез бит, – диде ул, бераз уйланып утырганнан соң. – Сез аны чынлап әйттегезме, әллә юри генәме?.. Хәер, мин үзем дә сезне кайдадыр күргән шикелле. Әмма кайчан, кайда күргәнемне никтер хәтерли алмыйм. Әгәр сез әйтсәгез, бәлкем, мин дә хәтерләрмен...

– Ник әйтмәскә... Телисез икән, әйтергә дә мөмкин...

– Туктагыз, әйтми торыгыз. Башта мин сезгә бер сорау бирим әле, – диде ул, минем сүзне бүлеп. – Сезнең быел җәй Горькийда пляжда булганыгыз юкмы?

– Булганым бар. Институтка керергә имтихан биргәннән соң, пароход килгәнне көтеп су буенда яткан идек.

– Шулаймы? Яныгызда бер иптәшегез дә бар идеме? Ул да елгачы иде бугай.

– Әйе, иптәшем дә бар иде. Ул да елгачы, минем белән бергә менә шушы пароходта эшли.

Фирдәвес кинәт гаҗәпләнүдән зур булып ачылган күзләре белән миңа карап торды да:

– Әһә, алайса, мин дә сезне күреп беләм кебек, – дип, күңелле итеп көлеп җибәрде. – Кичә кич белән каютада җырлавыгызны ишеткәч тә, нидер сизенгән идем. Менә бит ничек, юкка булмаган, белеп сизенгәнмен икән.

Якында гына аяк тавышы ишетелде. Коридор ишегеннән, быргы кычкырта-кычкырта, бер малай атылып чыкты һәм йөгереп килеп Фирдәвескә сарылды. Ул ак бескозырка, ачык изүле, зәңгәр якалы матрос күлмәге, кыска кара чалбар кигән; кайдадыр лебедка тирәсендә чуалган булса кирәк, борын очы машина маена буялган иде. Нидер хәтерләргә тырышкандай, каш астыннан күзләрен миңа текәп карап торды да:

– И абый, мин сине күргәнем бар ич, – диде.

Мин аны чыккач та танып алдым. Бу теге, пляжда ятканда, минем фуражканы киеп уйнаган малай бит, Фирдәвес улы Марат лабаса. Шулай да мин, әле һаман танымагандай:

– Юк, ялгышасың, брат, син күргән ул абый түгел мин, – дип шаярта башладым.

– Алдама, шул, шул, – дип, Марат хәтта бармак янап куйды. – Син ул чакны минем әнигә язу да биреп калдырган идең... – Әни, шулай бит, калдырган иде бит...

– И Марат, болай булгач, харап иттең син. Серне шулай ачарга ярыймыни... Ул язуны кем калдырганын әниеңә әйтәсе түгел иде.

– Ничек әйтмәскә, үзе сорады ич. Шулай бит, әни, сораган идең бит...

Фирдәвес тә, мин дә ирексездән көлеп җибәрдек. Марат әнисенең алдына менеп утырды да:

– Абый, менә тыңла әле, пароход шулай кычкыртамы? – дип, бар көченә өрә-өрә быргысын кычкырта башлады.

* * *

Фирдәвес пароход тормышына бик тиз ияләшеп китте, аз гына вакыт эчендә бөтен команда белән танышып өлгерде. Аның кайчан ял иткәнен дә белмәссең. Әле медпунктта авыруларны кабул итә, әле ашханәдә, салоннарда санитария кагыйдәләре үтәлешен, аш-суның сыйфатын тикшерә, каюталарның чисталыгын барлап чыга.

Элекке медичка алай түгел иде, артык мәшәкатьләнми, интекми генә каютасында китап укып ятарга ярата иде. Фирдәвес килгәннән бирле медпунктка күбрәк йөри башладылар. Әле берсе, әле икенчесе, юк авыруын бар итеп, тизрәк шунда чаба, ах-ух килеп, күзен тасрайтып шунда утыра. Иркенләп бер сөйләшеп тә булмый үзе белән.

Фирдәвесне дә әйтер идем, бигрәк тә беркатлы инде. Шул оятсыз симулянтларны җилтерәтеп куып чыгарасы урында, аларның сүзенә ышанып, фамилияләрен кенәгәсенә теркәп куя, дарулар бирә, тырышып-тырышып дәвалап маташа бит.

Әмма мин шуңар шат: үзе генә калган минутларда Фирдәвес авыз эченнән һаман теге җырны көйләп йөри. Медпункт яныннан үткән чакларда, мин моны берничә мәртәбә ишетеп калдым. Фирдәвес аны минем өчен генә җырлыйдыр, шул җыр безне якынайтадыр кебек тоела миңа.

Кайчакларда Фирдәвес ничектер үзгәреп китүчән була. Бар дөньясын онытып, шаярып-көлеп утырганда, кинәт уйга чума, күз карашы төмсәләнеп кала. Мондый вакытларда ул, эше бетүгә, Марат белән каютасына кереп бикләнә дә сәгатьләр буе палубада күренми, кичен кино карарга да төшми. Ул төшмәгәч, миңа да күңелсез була, минем дә карыйсым килми.

Бүген ул миңа бигрәк тә уйчан булып күренде. Гадәттә ачык чырае хәзер никтер караңгы, күзләренең карашы сагышлы һәм борчулы иде. Коридорда минем белән очрашкач, көндәгедәй матур итеп елмаймады да, күңел күтәрерлек берәр җылы сүз дә әйтмәде, ишетелер-ишетелмәс кенә исәнләште дә, ашыгып, медпунктка кереп китте.

Әмма шунысы бик сәер, ул үзе, кунак каршыларга җыенган сыман, бәйрәмчә киенгән: өстендә кыска җиңле алсу күлмәк, муенына алтын чылбырлы брошка таккан, дулкынланып торган коңгырт чәчләрен артка яткырып тараган иде.

Бу хәлгә мин башта әһәмият бирмәгән идем. Әмма аның бик мөһим сәбәбе булган икән. Бераздан команда членнары арасында көтелмәгән хәбәр: пароходка медичканың кияү егете килгән диган сүз таралды. Моны беркем дә гаепкә санамый, гайбәт итеп сөйләми, әлбәттә. Фирдәвес өчен шатланып, кияве дә үзенә тиң, әйбәт кеше булуын гына телиләр иде.

Мин үзем «кияү егетне» кичкә хәтле күрә алмадым. Көндез анда-монда чыгу түгел, тамак ялгап алырга да вакыт тимәде. Ислам Идрисович тагын аврал ясады: көймәләрне күтәртә-төшертә торган чыгырлар тутыгып эшкә ярамаслык хәлгә кергән икән, көне буе диярлек шуларны чистартып майладык, һәркайсын эшләтеп, сынап карадык.

Саратовта безнең пароходка агитбригада утырды. Кичен, юлга кузгалып китү белән, койрык ягы террасада халыкара хәл турында лекция һәм порт үзешчәннәренең бик күңелле концерты булды. Аннары, теләүчеләрне биергә чакырып, баянчы вальс сызып җибәрде.

Фирдәвес миннән сулдарак пассажирлар арасында өстенә ак китель кигән елгачы белән сөйләшеп тора иде. Кичке Идел өстендә вальс дулкыннары агыла башлауга, алар шундук түгәрәк уртасына чыктылар һәм, кулга-кул тотышып, җиңел хәрәкәтләр белән биеп киттеләр.

Башта алар сизелер-сизелмәс кенә бөгелә-сыгыла аяк очларына басып мәйдан тирәли үттеләр. Аннары, көй тизли башлауга, кинәт икесе дә җилкенеп куйдылар да, бер-берсен билләреннән алып, күз иярмәс тизлек белән бер урында әйләнергә тотындылар. Егете бигрәк оста биюче икән. Өермәдәй ашкынып бөтерелгән минутларда аның аяклары палубага бөтенләй дә кагылмыйдыр, ул үзе дә менә-менә һавага бөтерелеп менеп китәр кебек иде.

Шулай сокланып карап торганда, кинәт бу егет миңа ничектер таныш, күргән-белгән кешеләрдән кемнедер хәтерләтә кебек тоелды. Әһә, хәтерләдем, бу теге кем, беркөн ресторанда безнең белән бер өстәлдә утырган һәм җәнҗал кузгаткан егет бит!.. Теге чакны ул елгачылар формасында түгел, гади киемнән иде. Юкса хәзер мин аны күрү белән таныган булыр идем.

Бу биюгә бер мин генә түгел, команда членнары да, практикантлар да исләре китеп карап торалар иде. Шулар арасыннан кемдер:

– Безнең медичканың кияү егете шушы буламыни инде? – дип куйды.

– Әйе, шул, – диде икенчесе. – Җиңел сөякле булырга охшый бу, өлгер егеткә охшый.

– Нинди кияү егете булсын, – диде практикантларның берсе. – Безнең училищедан бит ул. Монда эш белән килгән кеше, пароходтан пароходка күчеп укучыларның производство практикасын тикшереп йөри.

– Булса ни, алар берсе икенчесенә комачауламый бит.

– Кара син аны, башы эшли икән, кәләше янына да командировка исәбенә килгән.

Моңарчы мин моны үзем абайламыйча ничек онытылып утырганмындыр. Бу хәбәрне көндез үк ишеткән булсам да, менә хәзер Фирдәвеснең кияү егетен үз күзем белән күрү йөрәгемә ук кебек кадалды.

Бер уйласаң – көенергә сәбәп тә юк шикелле. Фирдәвескә мин беркем дә түгел бит, аны минем белән берни дә бәйләми. Ул хакта безнең сөйләшкәнебез дә юк. Шулай да моннан соң мин, аларның биегәнен тыныч кына карап тора алмыйча, халык арасыннан чыгып киттем...

Бераздан, төнге вахтага менәр алдыннан мин каютадан чыкканда, бар халык инде таралып беткән, пароход төнге тынлыкка чумган; алгы якта утлары сүнгән салон каршында караңгыда бары тик бер пар гына серләшеп утыра иде. Яннарыннан үтеп киткән чакта мин аларның берсе Фирдәвес, икенчесе аның кияү егете икәнлеген күреп алдым. Фирдәвес тә мине таныды бугай, чак кына читкәрәк күчеп утырды.

* * *

Волгоград портына без нәкъ расписаниедә билгеләнгән вакытта – иртән сәгать тугызда килеп туктадык.

Волгоград!..

Тиңдәшсез батырлык шәһәре...

Халыкның җиңелмәслеге, мәңгелек даны, горурлыгы...

«Бурлак» монда дүрт сәгать торачак. Пассажирлар да, вахтада бушаган команда членнары да проспект кебек киң мәрмәр баскычта шәһәргә менеп киттек.

Корбаннар мәйданы чәчәккә күмелгән. Кырыс сакчылар төсле каберләр тора. Обелиск янында мәңгелек ут яна. Үлеп калганнарның тынычлыгын саклап, ике якта кораллы ике сакчы – пионерлар тора. Мәйдан тулы халык. Төркем-төркем килүче сәяхәтчеләр, чит ил туристлары үз илләре, үз шәһәрләре исеменнән һәйкәл итәгенә венок куялар да берничә минут тын гына басып торалар, дөнья язмышын күңелләреннән кичерәләр бугай.

Мәңгелек уттан сулдарак, яшел өянкеләр күләгәсендә кызыл мәрмәр. «Монда Советлар Союзы Герое Рубен Ибаррури, Советлар Союзы Герое В.Г.Каменщиков һәм капитан Ф.Х.Фәттахетдинов күмелгән». Шагыйрь сүзләре искә төшә: «Батырлар бар җирдә татарлар бар». Гани Сафиуллин дивизиясе немец генералы Фон Дребберне биредә әсир иткән. Немец гаскәрләре командующие фельдмаршал Паулюсның бөтен штабы белән әсир төшәргә әзерләнүе әнә шуннан башланган бит. Күңелдән уйлап барам: Гитлер безнең ил халыкларын дошманлаштырырга теләгән, тик явыз ниятенә ирешә алмаган. Испан егете, рус егете, татар егете бергә берләшкән икән – Гитлер дип аталасыңмы син, әллә аждаһамы – азаккы көнең хурлык баганасында.

Гитлер кайчандыр Сталинградны җир йөзеннән җуеп ташларга кушкан, аның әмере белән шәһәр көл ителгән. Менә хәзер Волгоградта йөргән вакытта әнә шул хәрабәләр урынында күтәрелгән гигант заводларны, ташпулатларны, мәһабәт һәйкәл-монументларны, уннарча километрга сузылган киң проспектларны, яшел паркларны күреп хәйран каласың. Кеше кулы ниләр генә эшләми!

Әйе, кеше кулы ниләр генә эшләми... Мамай тавына барганда, мин кинәт тынычлыгымны җуйдым. Алар автобуска икәү бергә кереп утырдылар. Әхәт, «кияү егете» дигәнебез, уен-көлке яратучан җор егет булса кирәк, атлаган саен диярлек нидер пышылдап Фирдәвесне көлдерә иде.

Пароходка кайтышлый тагын мәңгелек ут яныннан үттек. Мәйдан һәм аллеялар әле һаман шыгрым тулы иде. Чәчләренә чал кергән, маңгаенда дуга сыман яра эзе беленеп торган карт адмирал алгарак чыгып басты.

– Без, Тын океанчылар, бирегә сугышның иң авыр көннәрендә килдек, – дип, дулкынланып сөйли башлады ул. – Ут эченә кергәндә, без: «Идел аръягында безгә бүтән чигенергә җир юк, менә шунда таш кыя кебек нык торырбыз!» – дип ант иттек һәм сүзебездә тордык – бөтен дөньяга шапырынган фашист ерткычның умыртка баганасын шунда сындырдык...

Адмирал сүзеннән туктап тын алган арада, якында гына кемдер берәү:

– Кара син бу каһарман бабайны, исән калганына сөенми, әле һаман җикеренеп маташкан була, – диде һәм үз сүзләреннән үзе кеткелдәп көлеп куйды.

Мин ихтыярсыз шул якка карадым һәм Әхәтнең көлә-көлә Фирдәвес колагына нидер пышылдаганын күрдем. Аны башкалар да ишеттеләр һәм шундук борылып шелтәле караш ташладылар. Кайсыдыр ачу белән тамак кырып куйды. Моны Фирдәвес тә абайлап алды һәм, кинәт битләре кызарып, башын түбән иде.

* * *

Ашханәгә барып кергәч, кинәт аптырап калдым. Бүтән көннәрне беркем дә башкалар җыелып беткәнне көтеп тормый, керү белән ашарга утыра торган иде. Бүген ни булгандыр, бар халык инде җыелып беткән, табын әзерләнгән булса да, кемнедер көткән сыман, әле берсе дә ашарга керешмәгән иде.

Чынлап та ник алай, кем хөрмәтенә икән бу? Ашханәдә бар да үзебезнең халык. Арада берdән-бер чит кеше Әхәт кенә. Хәер, кыска гына вакыт эчендә ул инде бөтен команда белән үз кеше кебек аралашып, бергә эшләгән кешедәй үзләшеп өлгергән. Фирдәвеснең кияү егете булганга, аңа беркем дә чит кеше итеп карамый иде.

Зур өстәл уртасында, нәкъ минем урындык турында, пыяла ваза белән чәчәкләр бәйләме һәм ике шешә шампанское куелган иде. Үз урыныма барып утыруга, барысы да миңа карап елмайдылар. Хәтта камбуз тәрәзәсеннән карап торган Гөлчирә дә, мине тәбрик иткәндәй, кыюсыз гына елмаеп ым какты. Тик шунда гына мин кинәт бу тантананың сәбәбен аңлап алдым һәм моңарчы шуны абайламый торуым өчен хәтта бераз уңайсызланып куйдым.

Безнең пароходта команда членнарының туган көннәрен бергәләп бәйрәм итү йоласы бар. Һи, бүген минем туган көнем ләбаса, ул хакта бөтенләй онытып җибәргәнмен.

Барысы да тантаналы-җитди кыяфәт белән тынып калдылар. Ислам Идрисович утырган җиреннән ашыкмый гына бөтен табынны күздән кичерде дә, миннән битәр башкаларга сөйләгәндәй:

– Дуслар,– диде,– безнең белән бергә эшләүче иптәшебез Рөстәм Бакировка бүген егерме яшь тулды. Барыбыз исеменнән Рөстәмне туган көне белән тәбрикләргә рөхсәт итегез...

Ислам Идрисович сүзеннән тукталып калды һәм, кәефе кырылгандай, җәенке кашларын җыерып, бермәл уйланып торды. Мин кинәт сискәнеп куйдым, капитан теге вакыйганы тагын искә алып бөтен команда алдында тиргәп ташламагае дип шомга төштем. Әмма юкка борчылганмын икән. Ислам Идрисович шундук ачылып китте, миңа эшемдә һәм укуда уңышлар теләп кулымны кысты.

Барысы да җиңелчә кул чабып алдылар, шау-гөр килеп мине тәбрикләргә, минем белән стаканнарын чәкештерергә тотындылар. Гөлчирә, тәлинкәләргә салып, мәрсин балыгы шулпасы бирде. Аны ашап бетергәч, минем алдыма табада тәмле ис бөркеп торган гаять зур бәлеш китереп куйды. Бәлешнең капкачына минем исемем һәм туган елым язылган иде.

– Менә сиңа пычак, менә сиңа кашык, – диде Гөлчирә. – Капкачын үзең ач, кунакларыңны үзең сыйла...

Башка вакытта бүтәннәрнең туган көненә Гөлчирә торт ясый торган иде. Бүген исә – моңарчы безнең пароходта әле бер дә булмаган хәл – искиткеч бәлеш пешергән. Аны күрүгә, исем-акылым китте, башкалар да хәйран калдылар. Кайберләре, мине тәбрикләгәндә, әллә ниләр ишарәләп шаяртырга тотындылар:

– Аңлашыла, менә кайчан сер ачыла...

– Тикмәгә генә түгелдер, моның берәр сере бардыр...

Бу шаяртулардан Гөлчирә, теше сызлаган кешедәй, чыраен сытып куйды. Шулчак ашханәгә беренче штурман Сәмигуллин килеп кергәч, аның йөзе тагын да караңгыланды һәм ул, бүтән беркемгә дә карамыйча, өстәлдәге буш тәлинкәләрне подноска җыеп, камбузга чыгып китте.

Фирдәвеснең кияү егете беренче штурман белән таныш икән. Әхәт аны шатланып каршылады һәм, кысыла төшеп, аны үзе белән янәшә утыртты, бәлеш салынган тәлинкәне алдына якынрак китереп куйды. Аннары ул шампанское да салып бирмәкче булган иде, әмма шешә буш булгач, якягына каранып алды да:

– Минем каютада бик шәп коньягым бар, тиз генә алып килимме? – диде.

– Юк, кирәкми, – диде капитан, кырт кисеп. – Без пароходта барыбыз да эш кешеләре, безгә ярамый. Ашадык, сыйландык, шул җиткән... Сез кунак кеше, безгә карамагыз... Телисез икән, әнә югарыда ресторан ачык, шунда иркенләп утыра аласыз.

Ислам Идрисович, аш-су өчен рәхмәт әйтеп, миңа тагын бер мәртәбә бәхет-уңышлар теләп, ашханәдән чыгып киткәч, Әхәт бик гаҗәпләнгән кыяфәт белән, күзләрен челт-челт йомгалап, Сәмигуллинга карады:

– Һи, сезнең монда пионерларны өйрәткәннән ким түгел икән, – диде. – Анысы ярамый, монысы ярамый. Туган көнне бәйрәм итү түгел, көлке итү ич бу.

– Дөрес, дөрес, – диде Сәмигуллин, аны хуплап. – Безнең карт уйлап чыгарган мәзәк бу, шулай итеп бердәм коллектив тәрбияли, пароходны яраттыра, янәсе.

– Кызык, бик кызык, шундый арысланнарны бакча балалары кебек тәрбиялиләр икән... – Әхәт, сүзеннән туктап, Николай белән миңа күз кысып куйды. – Болай гына булмый бит... Монда ярамаса, әйдәгез, минем каютага. Менә дигән коньяк бар, закускага лимон, шоколад бар, бераз сөйләшеп утырырбыз.

Николай, сәгатенә карап, эшкә ашыгуын белдерде. Беркөн ресторанда булган теге күңелсез вакыйганы хәтерләп, миңа да бик уңайсыз булып китте.

– Гафу итегез, мөмкин түгел, – дидем. – Сезгә дә җиткән бугай, юкса...

Кунакны уңайсыз хәлгә куймас өчен тел очындагы сүземне әйтеп бетермичә, шунда тукталган идем.

– Йә, йә, юкса ни була? – дип, Әхәт үзе кызышып китте.

Минем өчен аңар Николай җавап бирде:

– Юкса тагын Горький ресторанындагы кебек күңелсез хәлгә эләгүегез бар. Ул чакны сезнең аркада безнең авыз пешкән иде.

Әхәт безне хәзер генә таныды бугай, ул күз алдында айнып китте һәм әле Николайга, әле миңа бик гаҗәпләнеп карады. Әмма телдән аны-моны сиздермичә, шундук сүзне башкага борып җибәрде.

* * *

Төнге вахтага без, гадәттәгечә, нәкъ сәгать уникедә бастык. Рубкага менгәч тә, башта бик караңгы тоелган иде. Әмма тиздән, күз ияләшкәч, төн карасы бераз сыегая төшкән кебек булды; сул яктан болыт күләгәседәй булып яр күренә, еракта маяк утлары җемелди башлады. Минемчә, бу – Күчмә атау борынына куелган маяк уты. Аны сул якта калдыру өчен мин аз-азлап штурвалны уңгарак бора башлыйм.

Рубканың ачык тәрәзәсеннән сүзсез генә алга карап барган Ислам Идрисович, мине хуплагандай:

– Дөрес эшлисең, уңгарак тот! – дип әйтеп куя. Ислам Идрисович моны җитди-коры тавыш белән әйтсә дә, мин дөрес боруыма куанып, штурвал янында үземне ышанычлырак тотам. Бераз сүзсез баргач, мин үзалдыма сөйләнгәндәй әйтеп куям:

– Күчмә атау... Ничектер сәер исем, аны ник шулай атаганнар икән?..

– Нәрсәсе сәер аның,– ди Ислам Идрисович.– Бер урында тормыйча күчеп йөргәнгә шулай аталган. Моннан ун-унике ел элек ул елганың уртасында тора иде, хәзер әнә сул як ярга тоташып бара инде.

Кәефе әйбәт вакытта Ислам Идрисович бу атау белән бәйле булган берәр вакыйганы яки риваятьне дә сөйләп биргән булыр иде. Әмма бүген ул сүзсез генә бара. Димәк, кәефе шәп түгел.

Һавада әллә нинди авыр ис бар. Көньяк кызуы, чүл сулышы үзен нык сиздерә. Инде төн уртасы булуга карамастан, хәтта су өстендә дә әле һаман бөркү. Башка әллә нинди уйлар килә башлый.

Тормышны һич аңламассың. Җырлата да елата дигәндәй... Укырга кереп өлгермәдем, аннан чак колак какмый калдым. Аннары Гөлчирә белән бозылышкач, кая барып сугылырга белми йөрдем, ансыз дөньяда яши алмам кебек иде. Әмма түзәргә калган баш, авыр булса да, түзә, акрынлап барысына да күнегә икән. Шулай да йокысыз үткән төннәр, авыр кичерешләр, төзәлгән яра кебек, йөрәктә эз калдыралар.

Капитан гадәтенчә тыныч, әмма кырыс тавыш белән:

– Җитте, артык борылдың... Бераз сулгарак ал, әнә теге ике утка таба тот! – дип, команда бирде.

Кинәт сискәнеп киттем. Дөрестән дә, онытылып, артыграк борылып киткәнмен. Каушавымны сиздермәс өчен, шундук:

– Есть, сулгарак алырга! – дип, приказны кабатладым һәм капитан әйткән утларга юнәлеш тоттым.

Тиздән мин тагын уйга чумам. Әллә кайдан гына күз алдыма Фирдәвес килеп баса. Ул да бик сәер. Шундый яшь башы белән инде бер тапкыр кияүдә булып өлгергән, баласы да бар. Менә тагын кияүгә чыгарга җыена. Белсәң иде, кияү егетен яратамы икән ул?

Күз алдыма корбаннар, һәйкәлләр килә, һәйкәлләр каршына басып, карт адмирал сөйли, Әхәт кеткелдәп көлә...

Кинәт борынга каяндыр көек исе килеп бәрелә. Тугайда көтүчеләр ут яга, шуның иседер дип уйлыйм.

Күп тә үтми, борынны ярып тагын көек исе бәрелә. Бу юлы ул тончыктыргыч ачы һәм авыр. Икебез берьюлы диярлек әйләнә-тирәгә каранып алабыз. Ул да булмый, түбәндә кемдер, төнге тынлыкны бозып, шомлы тавыш белән:

– По-жар-р... Пожар! – дип, бөтен пароходка кычкырып җибәрә.

Шундук машина бүлегеннән дә:

– Сул як топканың форсунка торбасы шартлады, аккан мазутка ут капты,– дип хәбәр иттеләр.– Үз көчебез белән сүндерә башладык, ярдәмгә матрослар төшсен...

Ислам Идрисович бөтен командага тревога игълан итте. Миңа пароходны агымга каршы борырга, боцман белән матросларга, ут сүндергечләр белән коралланып, ашыгыч рәвештә кочегаркага төшәргә кушты.

Күз алдыма кинәт коточкыч күренеш килеп басты. Пароход нәкъ шырпы тулы кап кебек бит: әгәр ут тарала калса – тоташтан буяу һәм лак белән капланган коп-коры корылма йөзләгән халкы белән күз ачып йомганчы дөрләп янып бетәчәк. Телем аңкавыма ябышты, маңгаемнан салкын тир бәреп чыкты.

Ислам Идрисович, башка пароходларны ярдәмгә чакырып, гудок кычкырта башлады, шлангларны сүтеп сузарга, насосларны ходка җибәрергә команда бирде. Аның һәр хәрәкәте ышанычлы, боерыклары төгәл һәм катгый иде.

Түбәндә янгын көчәя бугай, тончыктыргыч төтен әллә кайлардан бәреп чыга, сөйләшә торган рупор торбасы буенча менеп рубкага тула, күзгә керә башлады. Ислам Идрисович рупордан механикка:

– Башка бүлекләрне саклагыз, ут тарала күрмәсен. Кочегаркага ут сүндергечләрдән сиптерегез дә бөтен ишекләрне, иллюминаторларны ябып куегыз! – диде һәм, якорь салгач, машинаны да туктатырга приказ бирде.

Команда членнары инде постка басканнар, янгынны сүндерделәр бугай, урта палубадан да, машина бүлегеннән дә эшнең барышы турында хәбәр итә башладылар. Хәзер иң мөһиме – янгынны кочегаркадан чыгармау, бөтен көч шуңар тупланган иде.

Пароход якорьга туктагач, миңа да рубкада эш калмады, Ислам Идрисович миңа түбәнгә боцман карамагына төшәргә кушты.

* * *

Рубкадан төшкәч, бөтен пароходны баскан паниканы күреп шаккаттым. Янгын турында хәбәр инде халыкка таралып өлгергән. Һәркайда күз ачкысыз төтен, юньләп күреп тә булмый. Пассажирлар уянып беткәннәр һәм, каюталарыннан чыгып, коридорларда кайнашалар, бер-берсенә шом салып кабаланалар. Күбесе рәтләп киенмәгән дә, кичтән ничек яткан булса, шулай атылып чыккан. Кулларында чемоданнары, кайберләре бала-чагасын җитәкләгән. Бүредән өреккән сарык көтүе кебек, әле анда, әле монда ташланалар. Бу коточкыч матавыкны тыярлык берникнди көч тә юктыр шикелле иде.

Шул мәлне репродукторлардан бөтен пароходка Ислам Идрисовичның буйсындыручан, тыныч калын тавышы ишетелде:

– Тыңлагыз, тыңлагыз, пароход капитаны сөйли. Пассажир иптәшләр, тынычланыгыз... Иң мөһиме – паникага бирелмәү. Дөрес, куркыныч бар иде, хәзер ул кимеде, янгын пар казаны бүлегеннән бүтән җиргә таралмады, төтене генә күтәрелә. Безгә ярдәмгә судно килә. Хәзер сезне шунда утыртып озатабыз... Тыныч кына әзерләнегез, җыеныгыз...

Кешеләр бераз тынычландылар һәм, үз урыннарына, каюталарына таралышып, ашыга-ашыга киенергә, әйберләрен чемоданнарына тутырырга тотындылар. Куркудан коты очкан халык дулкыны, чүлгә сеңеп хәлсезләнгән ташкын кебек, бер мәлгә басылды.

Түбәндә пар катнаш куе төтен эчендә безнең егетләр һәм пассажирларның яшьрәкләре, берберсен ашыктыра-ашыктыра, бар көчләренә ут сүндерәләр; алар арасында янган-көйгән кешеләр дә бар, каяндыр ыңгырашкан тавыш ишетелә. Николайның да кителе берничә урыннан янган, чәче яртылай өтелгән; аның утын насостан сиптереп сүндергәннәр булса кирәк, ул, суга манчып алгандай, баштанаяк юеш иде.

Безгә ярдәмгә нindидер судно килеп тә җитте. Миңа сул як борттан шуны кабул итәргә команда бирделәр.

Их, килүен килгән дә, әмма бик бәләкәй судно – су трамвае гына икән. Безнең пассажирларның чиреген дә алырлык түгел. Бөтен халык берьюлы ташланса, янтаеп харап булачак. Моны трамвай капитаны шундук сизеп алды һәм, килеп туктаганчы, ук рупордан:

– Барысы да берьюлы ташланмасалармы? Халыкны туктата алырсызмы? – дип кычкырып сорады.

Безнең пароход мостигыннан Ислам Идрисович аңар:

– Борчылма, әйдә сул яктан килеп тукта,– дип җавап кайтарды. – Алгы пролет аша гына үзебез санап утыртырбыз, урын бетү белән шундук туктатырбыз.

Трамвай якыная башлагач, яңадан паника кузгалды. Болай да күзе-башы тонган кешеләр, барысына да урын җитмәсен ишеткәч, тагын да катырак кабаланып, алгы палубага ташландылар. Чама-

сыз ыгы-зыгы эчендә берсе абынып егылды, кемнеңдер чемоданы ачылып китте, кайсыдыр чәрелдек тавыш белән кычкырып җибәрде. Әмма моны ишетүче дә, күрүче дә, егылган кешегә ярдәм итүче дә юк. Һәркемнең үз хәле хәл, һәркем, күршесен узып, трамвайга элегрәк эләгергә тырыша иде. Кайнаган халык арасында Фирдәвеснең кияү егете Әхәт тә күренеп китте һәм шундук күздән дә югалды.

Бөтен шау-шуны басып, репродукторлардан тагын Ислам Идрисович тавышы яңгырап үтте:

– Пароход командасы!.. Мине тыңлагыз...– диде ул.– Алгы пролет аша иң элек бала-чагалы хатын-кызларны, өлкән яшьтәгеләрне утыртыгыз...

Трамвай килеп туктауга, Николай белән мин сул як пролет ишеге янына килеп бастык һәм балалы хатыннарга, картларга, егылмасыннар өчен икебез ике яктан беләкләреннән тотып, трамвайга күчеп утырырга ярдәм итә башладык. Безнең матрослардан берсе кайнаган халык арасыннан Фирдәвес белән Маратны үткәрде:

– Менә әйберләре, капитан икесен дә утыртып җибәрергә кушты,– диде.

– Юк, мин үзем китә алмыйм,– диде Фирдәвес.– Берәрсенә ышанып, Маратны гына озатам. Күрмисезмени, янган-көйгән кешеләр бар, аларга ашыгыч ярдәм күрсәтергә кирәк бит...

Аның сүзен раслаган кебек, боцман Николай яртылаш өтелгән чәченә кулын тидереп алды, үзеннән-үзе сораган сыман:

– Анысы шулай да, тик мондый матавыкта бу малайны кемгә ышанып җибәрергә соң? – дип әйтеп куйды.

Шул арада әллә кайдан гына бик эшлекле кыяфәт белән Фирдәвеснең кияү егете Әхәт килеп чыкты һәм беркемнән дә рөхсәт-фәлән сорап тормастан:

– Дөрес әйтә, баланы үзен генә җибәрергә ярамый, әйдә минем белән,– дип, Маратны кулыннан тотып алды.

Марат, пароходтан китәргә теләмичә:

– Синең белән бармыйм мин, җибәр мине,– дип, бар көченә карыша башлады һәм, Әхәт кулыннан ычкынып, ялгыш ике судно арасына суга... егылып төште.

Үз күзенә ышанмагандай һәркем, нишләргә белмичә, бер мәлгә аптырап калды. Хатын-кызлардан кемдер чәрелдәп кычкырып җибәрде. Түбәндә ярым караңгыда су астыннан бөкедәй калкып Марат чыкты, нидер кычкырды да, тончыгып, тагын төпкә китте.

Бер генә секунд та кичегергә ярамый, аның кабат калыкмыйча, батып үлүе ихтимал. Мин шундук малай баткан турыга суга ташландым.

Суда дөм караңгы, берни күрерлек түгел. Кая таба эзләп китәргә дә белгән юк. Төптә озак торып булмый бит, мин алай-болай каранган арада, сулыш кысыла башлады. Түзә алмыйча өскә күтәрелергә мәҗбүр булдым. Тиз генә күкрәгем тутырып тын алдым да тагын суга чумдым...

Чү, якында гына нидер бүлт-бүлт итә кебек. Караңгыда берни күрмәсәм дә, әле бер, әле икенче якка сузылып әйләнә-тирәмне кармалый башладым. Кулыма ниндидер чүпрәк килеп эләкте. Әһә, үзе, Маратның күлмәк итәгеннән эләктереп алганмын икән.

Ниһаять, котылдык дип сөенеп, тиз генә өскә күтәрелсәм, су безне түбәнгә таба агызып киткән, пароход инде шактый еракта калган иде. Өскә калыккач, бераз тын алган арада, тагын хәтсез җир китеп өлгердек. Рәтләп кычкырып та булмый. Берничә тапкыр тавыш биреп карасам да, мине ишетүче булмады бугай. Ара ерагайган саен, мае беткән лампа кебек, пароход утлары аз-азлап тоныклана барды һәм тиздән бөтенләй юк булды.

* * *

Болай булгач, пароходтан безне күрмәячәкләр, димәк, аннан ярдәм килүгә өмет юк. Бары тик үз көчемә яки очраклы ярдәмгә генә ышанырга кала.

Бәләкәй малайга күп кирәкмени, мин су астыннан табып алганда, Марат инде тончыккан һәм һушын югалтып өлгергән иде. Өскә чыгып бераз тын алгач, ул буылып-буылып коса башлады. Күкрәгемә яткырып аңа судан арынырга ярдәм иттем. Тиздән ул аңына килде һәм куркудан кычкырып җибәрде, калтыраган куллары белән бар көченә миңа ябышты.

– Марат, курыкма... Диңгезче беркайчан еламый ул. Әнә шулай ныклап миңа тотын,– дип, мин аны юатырга тырыштым.– Әйдә бергә йөзәбез. Синең белән без батыр диңгезчеләр бит... Иделне генә түгел, диңгезне дә йөзеп чыгарбыз...

Сизәм, юеш кием мине төпкә тарта, йөзәргә комачаулый. Бик кыен булса да, буш кулым белән шнурларын өзеп, ботинкаларны, аннары чалбар белән күлмәкне салып ташладым, җиңеләеп калдым. Марат та бераз тынычланды.

Хәзергә әле бер яктан да яр-фәлән күренми. Кайсы яр якынрак икәнен һич чамалап булмый, димәк, кая таба йөзәсен дә белер хәл юк. Башка чара калмагач, мин батмас өчен агым уңаена акрын гына йөзә бирдем. Ярый әле, безнең бәхеткә, су җылы, югыйсә, көзән җыерып, бик тиз төпкә китәр идек.

Белеп булмый, миңа, бәлки, су өстендә озак булырга туры килер әле. Хәзер безнең хәлдә иң мөһиме – көчне саклау. Кайсы яр якынрак икәнен ачыклап, шунда йөзәргә кирәк. Әмма төн караңгы, әйләнә-тирәгә күзләрем авыртканчы текәп карасам да, алкынып аккан караңгы судан башка берни дә күренми.

Вакыт, үч иткән кебек, бик озак үтә. Тиздән мин арый башлавымны сиздем һәм, сай урын юк микән дип, әледән-әле аягымны тирәнгәрәк сузгаларга керештем.

Шулай агым кочагында бара торгач, кинәт аягым төпкә тигәнне сиздем һәм шатлыгымнан җиңел сулап куйдым. Иртәрәк сөенгәнмен, яр буе дигәнем, су төбендә бер очраклы калкулык кына булып чыкты. Куәтле агым туктарга да бирми, һаман алга җилтерәтә. Менә аяк астында ком юк булды, алкын су безне тагын агызып алып китте.

Тиздән түбән яктан, каяндыр борылыш артыннан, якты утлары белән балкып, бер судно атылып килеп чыкты. Тиз килүеннән мин аның канатлы судно – «Ракета» яки «Метеор» икәнен шәйләп алдым. Ул, атылган уктай, безне читләп еракта бик тиз үтеп китте. Шуның белән күңелдәге өмет йолдызы да сүнде, куәтле агым кочагында без тагы үзебез генә калдык.

Минем юлдашым тәмам изрәде, кыенлык белән генә миңа ябышып бара; ул хәзер инде кычкырып елый да алмый, авызына су кергән чакта тончыгып ара-тирә ыңгырашып кына куя иде. Үзем дә аз-азлап һаман хәлсезләнә барам, күз алларым томалануын сизәм...

Байтак вакыт үткәч, еракта, төн чаршавын ертып, тагын ниндидер утлар күренде. Болары үрдән, безнең «Бурлак» калган яктан. Башта алар бик тоньк кына, күренер-күренмәс кенә җемелдиләр, вакыт-вакыт бөтенләй сүнгәндәй югалып торалар иде. Бераздан, ара якыная төшкәч, ачыграк елтырый башладылар. Әһә, ачык күрәм: бер як бортында – яшел, икенче якта – кызыл, мачтасы очында ак ут балкый, димәк, пассажир судносы бу. Үзе нәрсәдер эзләгәндәй, әле бер, әле икенче яктан прожектор белән су өстен яктырта-яктырта килә иде.

Күңелемдә тагын өмет уты кабынды, хәлсезләнгән беләкләремә көч өстәлгәндәй булды. Үзем нәни малай кебек:

– Марат, бирешмибез, судно килә, хәзер туктатабыз аны,– дип кычкырып җибәрдем.

Хәзер инде ачык күрәм, бу зур судно түгел, су трамвае иде. Ул якынайганнан-якыная бара һәм туп-туры безнең өскә килә иде. Прожектор нурлары каядыр читкә юнәлгән. Бер яктан икенче якка борган арада, ул бер мизгел генә безне дә яктыртып үтте. Әмма берсе дә күрмәде бугай, тагын бездән бөтенләй читкә яктырта башлады. Ара тагын якыная төшкәч, мин, башымны бераз күтәреп, бар көчемә:

– Тук-та-гыз-з!.. Безнең өскә киләсез бит...– дип кычкырырга тотындым.

Шундук ачы тавыш белән хатын-кыз кычкырганы ишетелде һәм күзне камаштырып прожектор безне яктыртты. Шул арада машинаны да туктаттылар булса кирәк, трамвай безгә яны белән якыная төште. Палубадан трап төшерделәр. Кемдер минем кулдан алып Маратны өскә сузды. Аннары мине эләктереп алдылар.

Тәмам алҗыганмын икән. Су өстендә батмыйча ничек тора алганмындыр. Палубага күтәрелгәч, коелдым да төштем, гәүдәмне тотарлык та хәлем юк. Кулларым, аякларым берсе дә үземнеке түгел. Меңләгән кырмыскалар йөргәндәй, бөтен тәнем чымырдый. Күңел болгана, су коса башлыйм... Минем өчен борчылмагыз, Маратны карагыз... Маратны, дип әйтәсем килә. Әмма телем тибрәтә алмыйм.

Тирәмдә чуалган кешеләр арасында күземә Фирдәвес чалынгандай булды. Мин аңымны җуям, саташам бугай, югыйсә монда нинди Фирдәвес булсын инде. Аннары мине кемнәрдер эчемне авырттырып күтәрәләр, каядыр өстериләр. Ник алай итәләр икән алар? Минем кыймылдыйсым да килми бит. Юк, берни дә юк, боларны да мин төштә генә күрәм бугай...

* * *

Күпме йоклаганмындыр, белмим. Уянгач та әле, кайда ятуымны аңлый алмый аптырап яттым. Биек түшәмле, ак стеналы кечерәк кенә бүлмә. Минем аяк очындагы ачык тәрәзәдән кош-корт чырылдавы ишетелә, каяндыр күңел болгаткыч дару исе килә. Бөтен тәнемне хәлсезлек баскан.

Пароходтагы пожарны, су өстендә калуымны хәтерләү белән йөрәгем жу-у итеп китте. Сулгарак борылып карасам, тумбочка янында ак халат кигән бер ханым ниндидер кәгазьләр карап уты-

ра. Менә ул миңа таба борылды, мин аның Фирдәвес икәнен таныдым, күзләремә ышанмыйча, ирексездән:

– Фирдәвес, дөрес күрәмме? Өнме бу, төшме? – дидем.

– Борчылмагыз, тыныч кына ятыгыз, – диде ул, пышылдап кына.

– Марат кайда, аның хәле ничек, ул исәнме?

– Исән, исән, хәзер әйбәт инде. Башта бик курыккан идем. Эченә су тулып тәмам тончыккан иде, көч-хәл белән һушына китердек. Хәзер үтте инде, йоклый.

Марат шушы палатада каршы як стена буендагы караватта ята икән. Трусиктан гына, аяк-кулларын як-якка ташлаган.

Йөзе агарып калган Фирдәвес, минем уйларымны сизгәндәй:

– Зыян юк, савыгыр, тазарыр. Иң мөһиме – сезнең исән калуыгыз,– диде.– Эзләп-эзләп тә таба алмагач, мин сезне исән-сау күрүдән өмет өзгән идем. Рәхмәт инде сиңа, Рөстәм, бик зур рәхмәт.

– Фирдәвес, пароход ни хәлдә? Утны сүндерделәрме?

– Сүндерделәр. Кешеләр башта бик курыккан иде, аннары тынычландылар. Ярдәмгә өч судно килде.

Палатага ак халатлы, чал чәчле врач килеп керде. Ул күптәнге танышлар кебек безнең белән ягымлы гына исәнләшкәннән соң, башта мине, аннары әле генә йокыдан уянган Маратны бик җентекләп карады, тик шуннан соң гына:

– Барысы да нормада, молодцы! – дип, мыек астыннан елмаеп куйды. – Дару-мазар кирәкми. Бүген яхшылап ашасыннар, күп итеп йокласыннар. Көч-хәл җыйгач, иртәгә иртән кайтып китәрсез.

Ул безне шатландырып чыгып киткәч, Марат әнисе алдына менеп утырды, аннан күчеп минем муенга ябышты:

– Әни, төнлә без менә шулай йөздек, – дип сөйләнә-сөйләнә шаярырга тотынды.

Без уйнаганны читтән елмаеп карап торган Фирдәвеснең күзләренә мөлдерәмә яшь тулды:

– Әле һаман ышанып җитә алмыйм, – диде ул, безнең янга караваt кырыена утырып. – Исемә төшсә, хәзер дә котым оча.

– Әни, без бер дә батмадык, су өстендә йөздек тә йөздек.

– Марат, абыеңа рәхмәт әйт. Ул сине үлемнән коткарып калды. Юкса безнең эшләр харап иде.

Марат, балаларча беркатлылык белән:

– Әни, мин бер дә курыкмадым, Рөстәм абыйга менә болай тотындым... Йә, син дә тотынып кара әле, – дип сөйләнә-сөйләнә, Фирдәвеснең кулын минем иңбашыма куйды. – Рөстәм абый көчле ул, бик көчле, ныклап тотынсаң, син дә егылмас идең...

Фирдәвес ихтыярсыз көлеп җибәрде:

– Рөстәм абыеңа дәү итеп рәхмәт әйт, безнең өчен ул бик кадерле кеше...

Бу минутта мин, ничектер Фирдәвескә туры карарга кыймыйча, каушап калдым. Әгәр карасам, ул кулын тартып алыр кебек иде. Шунда мин үзем дә дулкынланып киттем һәм, аны-моны уйлап тормастан:

– Сез үзегез дә миңа дөньяда иң кадерле кешеләр, минем сездән якын беркемем дә юк,– дип, Маратны күкрәгемә кыстым...

Безнең «Бурлак»ны янгыннан соң буксир белән тарттырып затонга кертеп куйганнар икән.

Көндезге аштан соң ял итеп алгач, безнең хәлне белергә бер-бер артлы команда члennары килә башлады, күчтәнәч һәм чәчәкләр белән тумбочканы, тәрәзә төбен тутырдылар, пароход хәлләрен сөйләп утырдылар. Иртәгә больницадан чыгасын белгәч, Марат белән миңа киемнәр китерделәр.

Кич җитәрәк, иң азактан, бик ыспайланып киенгән һәм исле майлар сөртенгән Әхәт тә килде. Киң балаклы кара чалбары пөхтә итеп үтүкләнгән, ак кителенең җиң төймәләре чистартылган. Аның бөтен кыяфәтеннән бу очрашуга зур тырышлык белән әзерләнгәнлеге сизелә иде.

Ярым ачык ишектән Әхәт килеп кергәндә, без өчәүләшеп бик күңелле шаярып-көлеп утыра идек. Безне мондый хәлдә туры китерүдән ул бераз уңайсызланып калды булса кирәк, бер миңа, бер Фирдәвескә карап алды да рәсми тонда коры гына исәнләште:

– Алай икән...– дип, чыраен сытып куйды.– Мин борчылып килгән идем, сез монда әйбәт кенә яшисез сыман...

– Әйе, зарланырлык түгел... Болай булса, иртәгә чыгарга...

Фирдәвес сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, аны канцеляриягә чакыртып алдылар. Ул чыгып киткәч, Марат йөгереп килеп минем алдыма менеп утырды. Палатада тынлык урнашты. Әхәт, хәзер генә кинәт нидер шәйләп алгандай, шаккатып безгә маңгай астыннан бермәл сүзсез карап торды һәм чырае тагын да караңгылана төште:

– Кара син аны, җаен тапкансың икән...– диде ул, Маратка күрсәтеп.– Башта малаен үз ягыңа авыштырырга, аннары Фирдәвеснең күңеленә ачкыч табарга уйлыйсыңмыни?..

Кинәт ачуым кабарып китте:

– Сез культурный кешегә охшаган бит... Әдәплерәк сөйләшә белмисезмени?

– Дөрес әйтәсез, дорфа булырга ярамый, гафу итегез...– Әхәт, бераз дәшмичә торганнан соң, сүзләрен йота-йота, тагын кызып сөйләп китте.– Мин моны пароходта да сизгән идем, монда да шуны күрәм: нигә сез Фирдәвес тирәсендә чуаласыз, шаяру өчен генә кешенең башын әйләндерәсез. Алай эшләп сез аның җайланып барган тормышын бозасыз ич. Алай ярамый бит.

– Ничек инде мин аның тормышын бозам?

– Менә шулай,– Әхәт кипшенгән иреннәрен теле белән ялап алды һәм каядыр почмакка караган хәлдә сүзен дәвам итте,– турысын әйтми булдыра алмыйм, Фирдәвес белән мин... ягъни без өйләнешергә йөри идек. Әмма соңгы көннәрдә ул миңа никтер... күрәм, сәбәбе сез икәнсез... Борчымагыз аны, сез аңар тиң түгел. Үзенеке булмаса да, баласы да бар.

– Ничек үзенеке түгел?

– Анысы кечкенә мәсьәлә... Бәла шунда, сез гади койрыкчы гына бит әле, ягъни каккан казыгыгыз да юк. Димәк, аларга рәтле тормыш күрсәтә алмаячаксыз. Шулай булгач, кеше юлына киртә булмагыз.

Мин үзем болай тыныч һәм юаш кеше, юкка-барга кыза торган гадәтем юк. Гомердә булмаган хәл, бу юлы кинәт җен ачуларым чыкты, аңа ташланудан үземне көч-хәл белән генә тыеп калдым.

– Сез бу хакта минем белән түгел, Фирдәвеснең үзе белән сөйләшегез. Ә хәзергә сезнең миңа кирәгегез юк, – дидем, шыпырт тавыштан янауга күчеп әйттем.

Ярый әле Фирдәвес килеп керде. Юкса җәнҗал чыкмый калмас иде. Бу хәлне ул ишектән керүгә шәйләп алды булса кирәк, безгә сүз әйтергә ирек бирмәде:

– Кирәкми, ярамый... Әхәт, әйдә коридорга чыгыйк, шунда аңлашырбыз, – дип, Әхәтне палатадан алып чыгып китте.

* * *

Алар анда ни сөйләшкәннәрдер, белмим. Әмма Фирдәвес бик озак кермәде. Без аны көтә-көтә ялыгып беттек. Марат аны эзләп коридорга чыкмакчы булган иде. Минем сүзне тыңлап кына чыкмый калды һәм уйнап яткан җиреннән, ниһаять, йокыга талды.

Миңа кинәт бик күңелсез булып китте. Монда кунарга калмасак әйбәтрәк буласы икән. Һаман эш белән мәшгуль булып, су өстендә йөреп күнеккәнгәме, кичке эңгер-меңгергә күмелеп барган тын бакчага япа-ялгызым карап утыру ямансу, күңелдә сагышлы уйлар кузгата иде.

Мин тәрәзәгә төбәлеп, моңаеп утырганда, Фирдәвес килеп керде.

– Рөстәм абыйсы, ник без болай күңелсез утырабыз әле? – дип, ягымлы елмаеп иңемнән кочаклады.

Алар анда ныклап сөйләшкән булсалар кирәк, Фирдәвеснең әле дә тынычланмаганлыгы сизелеп тора. Ул, йөгереп килгән кеше кебек, еш-еш сулый һәм сизелер-сизелмәс кенә калтырана иде. Мин, кәефем бозылуын яшерә алмыйча:

– Йә, хушлаштыгызмы?.. Кияү егетегездән аерылуы кыен булды мәллә, бик озак озаттыгыз? – дидем.

Фирдәвес, уңайсызланып калгандай, авыр сулап куйды, әмма үзе миңа кыю карап:

– Ул бүтән минем кияү егетем түгел,– диде.– Мин әле генә аның белән араны өзеп кердем. Ул хакта син дә миңа бүтән әйтмәссең дип ышанам.

Күңелсез уйларым кул белән алып ташлагандай юкка чыкты. Шатлыгымнан, нәни бала кебек, кычкырып җибәрә яздым.

– Бетте, бәгырькәем, башы-азагы шул булсын... Ул хакта бүтән берни дә әйттем юк,– дип, Фирдәвесне кочаклап алдым да күкрәгемә кыстым.

Төннең үткәнен сизми дә калдык. Әле генә шәфәкъ баткан шикелле иде. Бактың исә, инде дөньяга яктылык сирпеп, яңа көн туып килә.

Фирдәвес әлерәк кенә изрәп йокыга китте. Коңгырт чәчләре ак мендәр өстенә сибелгән. Алсу иреннәрендә сүнмичә онытылып калган елмаю бар иде.

Минем күз карашымны сизгәндәй, Фирдәвес елмаеп уянды, күрше караватка үрелеп, саклык белән генә Маратның өстенә ак җәймә япты.

– Фирдәвес, әйтче миңа,– дидем мин, аны башыннан сыйпап,– бу кем баласы, каян алдың син аны?

Маратны уятмас өчен, Фирдәвес минем колакка пышылдап кына әйтте:

– Марат минем бертуган апамның улы иде. Алар – ирле-хатынлы ике геолог – экспедициягә киткән җирләреннән әйләнеп кайтмадылар, тайгада һәлак булдылар. Әтисез-әнисез калган Маратны мин уллыкка алдым, үз улым иттем. Хәзер ул безнең уртак улыбыз...

# Хәвефле сәфәр

***Җилдән туган бала***

Порт тәүлек буе гөрләп тора. Төп фарватердан биек дамба белән бүлеп алынган тын рейдка икешәр, өчәр катлы ак теплоходлар, баһадир буксирлар бер-бер артлы кайсы килә, кайсы китеп бара. Тимер бетон причалларда куәтле краннар, тасмалы транспортерлар ярдәмендә баржалардан ташкүмер, цемент, гравий, тоз бушаталар, озатасы йөкләрне төйиләр. Безнең «Зөя» баркасы да шунда тулгана: ераклардан килгән баржаларны йөкләрен бушатырга краннар янына китереп куя, бушатылганнарын рейдка чыгарып, юлга әзерли, төрле йомыш юлга йөрүдән туктамый.

Икенче җәй инде мин шул баркасның механигы. Тышкы күренеше белән артык мактанырлык мәһабәт булмаса да, яратам мин «Зөя»не, күңел биреп, тел-теш тидермәслек итеп тырышып эшлим. Без вахтада өчәү торабыз. Машина бүлегендә мин, рубкада штурман Солтанов Артур белән койрыкчы Харитон. Матрос вазифасын бергә үтәп, акчасын урталай бүләләр.

Бүген биш яшьлек улым Мансурның туган көне. Шунлыктан, дебаркадер янында туктап, вахтадан бушауга, шундук өйгә элдертмәкче идем. Тиз генә өс-башны алмашып, басмадан төшкәндә, штурман Артур юлымны бүлде:

– Ашыкма, әйдә безнең белән... Бераз тамак чылатып алырбыз, – дип, Харитон кулындагы канистрга ымлады.

Әһә, аңлашыла, көндез Печищега барышлый Югары Ослан кафесы мичкәләрен, он, ярма тулы капчыкларын әшнәләрчә бушлай гына илткән өчен алар биш литрлы канистр белән сыра һәм закускага каклаган балык юнәткәннәр иде, шуның белән кәефләнергә чакыра икән.

Әмма мин бармадым, чөнки аларның гел «юнәтү» белән шөгыльләнүләрен яратмыйм. Аннары иртән эшкә киткәндә, хатыным Сәрвиназ, соңга кала күрмә, эштән бушагач та, беркайда тоткарланмыйча кичке ашка кайтып җитәргә тырыш, дип кисәтеп куйган иде.

Кыстап-кыстап та күндерә алмагач, Артурның чырае сытылды.

– Алайса бар кайт, Сәрви чибәргә миннән кайнар сәлам әйтергә онытма, – диде, кинаяле төрттереп.

Ә мин барыбер бирешмәдем, бүтән сөйләнеп тормастан, тиз генә моторымны кабыздым да турыдан су өсләп кенә өйгә кайтырга чыктым.

Шулай да бу моторлы көймәне әмәлләп шәп эшләдем мин. Элек Юдинодан поездда шәһәр аша портка бару-кайту шактый вакытны ала, әни ике сүзнең берендә: «Ташла шул җәһәннәм астына йөрүеңне. Анда көннәр буе коры-сары белән тукланып, барлы-юклы жалованье хакына тимер-томыр арасында чиләнгәнче, Бәдретдин абыең янына ашханәгә керсәң, бер уңайдан шунда аш-су арасында тамагың да тук булыр», – дип, колак итен кимерә торган иде. Хәзер, үз моторкам булгач, эш көйләнде, станциядә озак-озак поезд көтеп торулардан котылдым, портка турыдан-туры су өсләп кенә җилдертәм.

Бүген көн матур түгел. Төштән соң башланган пыскак яңгыр һаман сибәли, куе томан кебек, әйләнә-тирәне томалап тора. Зур суднолар, тизйөрешле метеорларга комачауламас өчен, фарватердан читтә, сул як яр буйлап саклык белән генә кайтам.

Тиздән, кыя таш кебек биек водокачка турыннан үтеп бераз баргач, Юдино поселогына күренеш ачыла. Текә яр өстендә безнең кызыл калай түбәле, зур-зур дүрт тәрәзәсе Иделгә караган алты почмаклы өебез, челтәрле тимер рәшәткә белән уратылган җиләк-җимеш бакчабыз бөтен урамга ямь биреп тора. Арткы якта кош-корт, терлек абзары, ак мунча, яшелчә, бәрәңге бакчасы. Болар барысы да минем эшкә уңган әни тырышлыгы белән булдырылган. Инде шактый өлкән яшьтә булуга карамастан, ул хәзер дә көнаралаш базар юлын таптый, алу-сату, нәрсәдер юнәтү белән мәшгуль.

Үзебезнең турыга килеп җитәрәк, күрәм, су читендә такта басма өстендә улым Мансур мине көтеп тора. Их, малай актыгы, мәйтәм эчтән, өйдән әбисе күрмәгәндә чыгып шылган булса кирәк, салкында яланбаш тора, курткасын да төймәләмәгән ичмасам. Көймәдән чыгып, чалканы бәйләргә өлгермәдем:

– Тукта, әтием, бәйләми тор... Әйдә йөреп кайтыйк, – диде, көймә эченә сикереп.

– Юк белән башны катырма, бу вакытта нинди йөреп кайту ул? – дидем.

– Һи, оныттыңмыни, туган көнеңдә моторкада йөртәм, штурвал белән идарә итәргә бирәм, дип әйткән идең ич. Менә шул көн җитте, әйдә китәбез.

Хак сүз, гел сорап йөдәткәч, вәгъдә иткән идем шул. Вакыт шактый соң булса да, ташбашның теләген үтәргә туры килде. Рульне бер яктан Мансур, икенче яктан күрсәтмичәрәк үзем тотып, шундук кузгалып киттек. Шатлыктан малайның авызы җәелде. Аракчинога җиткәч, Сәрвиназның әтисе Зариф бабай өе каршында кире кайтырга борылганда, без килгәнне ишетсен дип, хәтта сузып-сузып сирена кычкыртып алды.

Үз басмабызга әйләнеп кайткач, көймәне су читендәге карт өянкегә чылбырладык. Асылмалы моторны, бензины яртылай бушаган канистрны сарайга менгезеп куйдык.

Шул арада өй каршындагы чия, алмагачларны шаулатып, җил күтәрелде, веранда тәрәзәләренә борчак сипкәндәй бәреп, эре яңгыр коя башлады. Бу хәлгә ничектер сагаеп калган Мансур, үзалдына уйланган сыман:

– Әтием, мин дә шундый салкын җилдә тудыммы, туңмадым микән? – дип әйтеп куйды.

Мин, аны-моны уйлап тормастан:

– Ник алай дисең, улым, кем әйтте аны? – дидем гаҗәпсенеп.

– Әби әйтте... Ул мине гел шулай җилдән туган шалапай, дип орыша.

Әйе, шулайдыр, бала чакта ул еш кына мине дә шул әшәке сүз белән хурлап тирги торган иде. Шуңа күрә моңа әллә ни әһәмият бирмәдем:

– Әбиеңнең сүзен тыңламагансыңдыр, мөгаен, шуңа орышкандыр, – дип, четерекле әңгәмәне икенчегә борып җибәрергә тырыштым. – Әйдә юеш курткаларны верандада салып элик тә өйгә керик. Син туган көнгә нинди сый хәзерләгәннәр икән, әйдә күрик әле.

***Биләмче хатын***

Бүтән көннәрне бу вакытта бездә инде ут алынган, кичке табын әзер, өй эче күтәренке тантаналы төскә кергән була иде. Бүген исә бәйрәм көн булса да, ярым караңгы түр якта шыксыз тынлык, беркем дә юк; алгы стенадагы путаллы рам эченнән әнинең әтисе Шакир бабай фотосурәте генә җәенке кашлары астыннан ачулы карап тора. Мәрхүм бабай заманында көн күрә белгән булса кирәк, әни һаман саен аның шул хасиятен мактап сөйләргә, мине дә аның кебек эш йөртә белергә, мал җанлы булырга өйрәтеп йөдәтә.

Һи, күрми торам, әни кухняда пешеренеп маташа икән ич. Кәефе шәптән түгел бугай, никтер ордым-бәрдем йөри, аяк астында буталган ялагай мәчене ачу белән тибеп очырды. Берни дә күрмәгән, сизмәгәндәй, көр тавыш белән:

– Күз бәйләнә бит инде, әни, ник ут алмыйсыз? Сәрвиназ кайда, кайтмадымыни әле? – дип сорадым, залда люстраны кабыздым.

– Мин каян белим аны, биләмдә йөридер, – диде әни, плитә янында орды-бәрде маташа биреп. – Юньле хатын булса, эштән соң туры өйгә кайтыр, кәнтәй кебек йөгәнсезләнеп йөрмәс иде.

– Әмма тел дә инде үзеңдә, тапкансың сүз... Нишләп биләмдә йөрсен ул, эшендә берәр тоткарлык килеп чыккандыр.

– Тоткарлыкмы, түгелме, анысы караңгы. Аның эше беткәнгә әнә күпме инде... Йә, үзең уйлап кара, ирен санга суккан, өйдә баласы барын онытмаган хатын шултикле олагамыни?..

Без, юеш өс-башны салып, кулларны юган арада, Сәрвиназ кайтып керде. Ул да яңгырга эләккән, плащы манма су, чәч бөртекләре чигәләренә ябышкан. Кулында азык-төлек тулы сумка.

– Местком утырышы озакка сузылды, көчкә чыгып котылдым, – диде ул, соңаруы өчен аклангандай.

Сәрвиназ кайтып керү белән өй эче җанланып китте, күңелсез киеренкелек юк булды. Моңарчы үзен ничектер басынкы тоткан Мансур, әнкәсе чишенеп беткәнне дә көтмәстән, моторкада Аракчинога хәтле баруы, Зариф бабасы өе каршыннан гудок кычкыртып үтүе турында мактанырга тотынды. Сумка эченнән бескозырка, зәңгәр якалы матрос күлмәге килеп чыккач, тәбрикләп биргәнне дә көтмәстән, шундук түземсезләнеп сорап алды. Минем дә бүләккә дип алдан әзерләп куйган уенчык биноклем бар иде. Йокы бүлмәсендә яшереп куйган җирдән шуны алып чыгып биргәч, шатлыктан малайның башы күккә тиде. Диңгезче формасы кигән, муенына бинокль аскан хәлдә көзге каршында үзенә-үзе хәйран булып карап торды.

Озакламыйча табын әзер булды. Әни аш-суны менә дигән итеп мулдан әзерләгән. Сыйның иң шәбе Мансур үлеп яраткан аш – зур табада тәмле ис бөркеп торган ит бәлеше булды. Барыбыз да ачыгып кайтканбыз, мактый-мактый ашадык. Сәрвиназның әлегә тикле күрсәтмәгән тагын бер

күчтәнәче – пломбир мороженое булган икән, сумкасыннан шуны алып биреп, баланы тагын бер кат шатландырды.

Ниһаять, малайның алҗуы җитте бугай, тамагы туйгач, якынрак күчеп, әнкәсенә сыенды. Сәрвинең күңеле йомшарды, күрәсең, улын кочаклап, маңгаеннан үбеп алды.

Тышта җил тагы да көчәя төште. Бәреп яуган яңгыр тамчылары тәрәзә пыяласында, вак гөрләвектәй, юл-юл булып ага башлады. Оясын давыл туздырган булса кирәк, кызыл түшле бәләкәй генә кошчык, түр тәрәзә рамына килеп кунды, ышыкка керергә теләгәндәй, канатлары белән җилпенде дә төн караңгысы эчендә юк булды. Моны күреп торган Мансур, кызганычлы тавыш белән:

– Әнием, мин дә шундый яңгырлы җилдә тудыммы, бик туңмадыммы? – дип сорады.

– Чү, үскәнем, ни сөйлисең син, кем сүзе ул?! – диде Сәрви.

– Әби сүзе... Җилдән туган, азман калдыгы, диде.

Табында авыр тынлык туды. Бер-беребездән уңайсызланып, һәркайсыбыз үз алдына караган хәлдә сүзсез калдык. Самовар янында кара көеп утырган әни, кинәт тончыккан сыман, йөткеренеп алды. Аннары тиз генә битләрен сыйпап, амин тотты да кухняга чыгып китте.

Ә тел бистәсе малай һаман текелдәүдән туктамый бит. Әбисе әйткән азман сүзен ул кеше исеме дип аңлаган икән, шуны сораштырырга кереште. Кәефе кырылган Сәрвиназ рәтләп тыңламагач:

– Азман абый кайда ул, аның безгә килгәне бармыни? – дип, миңа ябышты.

Бу гайбәт, бер-берсен күралмау, ызгышлар инде нервыга тия башлаган иде. Көтмәгәндә бая баркаста Артур әйткән кинаяле кайнар сәлам искә төште, әнинең шикләнүендә хаклык бардыр кебек тоелды. Шуның өстенә малайның ахмак сораулары мине тәмам чыгырдан чыгарды. Күп уйлап тормастан:

– Ул азманның килгәнен-килмәгәнен мин каян белим... Әнә әниеңнән сора, бәлкем, ул белә торгандыр, – дип ычкындырдым һәм гафу ителмәслек мәсхәрәле сүз әйтеп ташлавымны азактан гына абайлап алдым.

Сәрвиназ кулында калтырый башлаган чәйле чәшкесен өстәлгә куйды, яңаклары агарып китте. Зур ачылган күзләре белән миңа бермәл аптыраулы карап:

– Ни әйткәнеңне аңлыйсыңмы син?! – диде.

Ә мин, акыллы баш, шундук гафу үтенәсе урында, бернигә исем китмәгәндәй, турсаеп утыра бирдем. Аннары күп текелдәп табынның ямен җибәргән өчен Мансурны җиңелчә тиргәдем дә өстәл яныннан торып киттем.

Дөресен әйткәндә, монда малайның һичнинди гаебе юк. Һәр яңа күргән нәрсәне, яңа ишеткән сүзне аңларга тырышучан беркатлы сабый ни сөйләмәс. Андый мәнсез сүзне әни әйтергә тиеш түгел иде.

Сәрвиназ бик үпкәләде, ахрысы, миңа бүтән күтәрелеп карамыйча, сүзсез генә өстәлне җыештырырга тотынды. Әни өчен дә, үземнең дорфалыгым өчен дә иртәгә үк гафу үтенергә кирәк булыр дип уйлап куйдым.

Гадәттә, кичке аштан соң Мансур белән мин икәүләшеп телевизордан «Әлли-бәлли-бәү» тапшыруын карый торган идек. Баланы йоклаткач, үзем бер-ике сәгать имтиханга әзерләнеп тә ала идем. Бүген кәеф бозылды, уку кайгысы түгел. Сәрви белән күзгә-күз калмас өчен, ул табынны җыештырган арада, тизрәк ятып, йокларга ашыктым.

***Онытылмас сәфәр***

Әмма үч иткән кебек, күзгә йокы керми, табын янында кузгалган күңелсез уйлар йөрәкне тырнап тора. Әнинең Сәрвиназны күралмавына, адым саен бәйләнүенә тәмам аптыраган. Бу арада бераз басылган кебек иде, никтер әнә тагын тузынып каныга башлаган. Инде нишләргә дә белгән юк болар белән. Билләһи менә, ник өйләндем дигән көнгә килеп җиттем.

Гаҗәп хәл: егет вакытта минем беркайчан өйләнмәм дип әйткән катгый сүзем бар иде. Чөнки гаилә тормышының һичнинди кызыгы юктыр, хатын-кызлар барысы да минем әни кебек һаман файда итү, мал арттыру турында кайгыртып, вакчылланып теңкәгә тиючән тоела иде. Шунлыктан кыз-кыркын тирәсендә артык чуалмаска тырыштым, күз атучыларны күрмәмешкә сабыша идем.

Шулай да мин азаккача сүземдә тора алмадым, көннәрдән бер көнне антымны онытып, өйләнүемне сизми дә калдым.

Барысы да юлда машинада барганда башланды. Ул чакны без, елгачылар больницасының яшелчә бакчасына кәбестә алышырга баручы бер төркем шәфкать туташлары һәм техникумчылар, кичтән сөйләшенгәнчә, иртән порт идарәсе ишегалдына җыелган идек. Әйтелгән вакытка машина да килеп җитте. Такта утыргычлы ачык кузовка төялешеп кузгалырга торганда, шәфкать туташларыннан берсе:

– Бәрәч, бригадирыбыз Артур белән Сәрвиназ юк ич... – дип кычкырып җибәрде. – Әй, шофер дус, әз генә көтик әле. Клубтан гитара, транзистор алырга гына киткәннәр иде, менә-менә килеп җитәргә тиешләр.

Аның сүзләрен раслагандай, нәкъ шул минутта клуб ягыннан алар үзләре килеп чыкты. Гитара аскан тузгый башлы, чөгендер төсле кызыл борынлы чандыр егет кабинага шофер янына кереп утырды. Аның белән килгән җиңел гәүдәле яшь кенә чибәр кызга мин, кулыннан тартып, кузовка менәргә ярдәм иттем, күршеләрне бераз кысрыклап, үз янымда урын бирдем. Зур зәңгәр күзләре һава диңгезедәй төпсез тирән. Көмеш кыңгырау кебек ачык тавышлы икән, алсу иреннәре белән ягымлы елмаеп рәхмәт әйтүе күңелемне иркәләп үтте.

Бу кыз белән мин бөтенләй таныш түгел диярлек, шәһәргә барганда-кайтканда, ара-тирә поезд-да күреп кенә бераз беләм. Ул кем булыптыр елгачылар больницасында эшли бугай. Беренче ка-рашка үзен горур тотучан, тәкәббер сыман күренсә дә, асылда, кеше белән җиңел аралашучан, киң күңелле булса кирәк, иптәш кызлары әле бер, әле икенче яктан:

– Сәрви җаным, анда кырыйда уңайсыздыр, менә монда күчеп утыр, – дип, аны үз янына чакы-рып дәштеләр.

Мәгәр ул күченеп кеше борчырга арусынмады, ахры, утырган урынында кала бирде. Машина кузгалып китү белән, транзистордан яңгыраган «Юксыну» көенә моңлы җыр сузып җибәрде. Аңа бердәм кушылып, шундук башка кызлар да җырлый башлады.

Теге тузгый башка кабинада күңелсез тоелды бугай, машина туктаган бер арада кузовка менеп, алгы рәттәге кызлар арасына кереп утырды.

– Анда душно, бензин исеннән тошнить итә, – диде ул, ярым татарча, ярым русчалап. – Мин играть итәм, әйдәгез, сез җырлагыз, – дип, гитарасын зыңгылдатырга тотынды.

Дөресен әйтим, мин үзем аның нинди көй уйнаганын шәйли алмадым. Әле генә моңланып җырлап барган кызлар да бер-берсенә аптыраулы каранып тынып калды. Минем белән янәшә уты-ручы Сәрвиназ, үзалдына уйланган сыман:

– Бу бичараны әйтәм, туган телендә адәм рәтле сөйләшә белми икән... Уйнаган көе дә ташка үлчим, – дип җәлләп куйды.

Ә машина урман эченнән сузылган тип-тигез асфальт юлдан кош кебек очып бара. Зур тизлек-тән туган җил колакларда сызгыра, Сәрвиназның җилфердәгән йомшак чәче битемне кытыклый. Машина кинәт борылган мизгелләрдә егылмас өчен, ул әледән-әле минем иңемә тотына һәм, гафу үтенгәндәй, сизелер-сизелмәс елмаеп куя. Моны сизеп алу белән, мин, урынымны аңа биреп, үзем борт кырыена күчеп утырдым.

Больницаның ярдәмче хуҗалыгына барып җиткәч, безгә машинадан төшәргә дә бирмәделәр. Яшелчәчеләр звеносы җитәкчесе – яшькелт курткасын җилбәгәй җибәргән чылгый мыеклы урта яшьләрдәге агай – шофер янына кабинага кереп утырды да, безне шундук участокка алып китте. Без туктаган җирдән чак кына читтәрәк кемнәрдер инде эшли башлаган иде. Бакчачы агай алар бе-лән янәшәдә безгә дә һәркайсыбызга өчәр метр исәбеннән җир үлчәп бирде дә:

– Кәрзин һәм кучән чапкыч пычакларны әнә тегеннән алыгыз, – дип, җир башындагы такта са-райга күрсәтте. – Сезнең белән күршедә эшләүче әнә теге халык – үзебезнең кешеләр, алардан ка-лышмаска тырышыгыз... Ике кеше машинада калсын, башкалар алган кәбестәне төяп, пүчинкәгә амбарга ташый торырлар.

Бригадирыбыз Артурның тартырга сигареты беткән икән, яшелчәче агай белән кибеткә дип киткән җирдән озак кына йөреп килде, ә без шундук дәррәү эшкә керештек. Күчән чапкыч белән коралланган кызлар һәркайсы үз кишәрлегендә баш калкытмый эшләде. Сәрвиназ белән мин алар алган кәбестәне машинага төяп, амбарга кайтарып бушата тордык.

Иртәнге якта көн чалт аяз булган, урман полосасы ягыннан сизелер-сизелмәс кенә искән йом-шак җилдә үрмәкүч тоҗымнары очкан иде. Төштән соң, эш бетәргә бер-ике сәгать каларак, күк йө-зен бөдрә болыт каплады, кыйгач бәреп, җылы яңгыр сибәли башлады. Чыланмасын дип, мин Сәр-виназга тужуркамны салып бирмәкче идем. Кешедән арусынмады бугай, алмады, сүзсез генә рәх-мәт әйткәндәй:

– Юк, юк, кирәк түгел, борчылма... Тоз түгел, болай да эремәм, – дип елмайды гына.

Пүчинкәнең үз кешеләре, яңгыр ява башлау белән, өйгә кайтып киттеләр. Аш әзерләсеннәр, әй-тергә кирәк, дип, алар белән бергә бригадирыбыз Артур да китеп барды...

Бу вакытта безнең эшебез күп калмаган иде, инде бетермичә туктамаска булдык. Бәхеткә, тиз-дән яңгыр да үтеп китте. Ә без, бер-беребезне ашыктыра-ашыктыра, тагы да кызурак эшли бирдек.

Бераздан, бакчачы агай мотоциклда килеп төшкәндә, без инде, эшне тәмамлап, соңгы кәрзин-нәрне машинага төяп маташа идек. Бушап калган участокны күреп, аның исе китте:

– И-и, бетердегез дәмени... Шәп иткәнсез, безнекеләрнең борыннарына чирткәнсез... – дип мактап рәхмәт әйтте. – Чылангансыз, карныгыз да ачкандыр. Өйдәгез кайтыйк, юлга чыгар алдыннан тамак ялгап алырсыз.

Хак сүз, ачыккан идек, шулпалы пилмәнне дә, кролик ите белән карабодай боткасын да яратып ашадык. Без чәй эчеп бетергәндә генә, ашханәгә иреннәрен ялый-ялый Артур килеп керде. Ул бераз тамак чылатып алган бугай, күзләре ут уйный, болай да чөгендер төсле борыны тагы да кызара төшкән иде. Безнең шелтәле карашны сизеп булса кирәк, акланырга теләгән сыман:

– О том, что без действительно эшләдек, заведующидан справка алдым, шунда задержался, – диде.

Без юл буе әле шаярып-көлеп, әле җырлап кайттык. Ничектер шулай килеп чыкты, мин тагын Сәрвиназ белән янәшә туры килдем, аның иңбашы җылысын тоеп, колакны иркәли торган ягымлы тавышын ишетеп кайттым. Кичкырын, һава салкыная төшкәч, минем тужурканы иңнәребезгә салып бөркәндек. Хәзер инде Сәрвиназ миннән читенсенми, бераз үз итеп, җылырак карый сыман тоела башлады. Моңарчы гомер булмаган хәл, үзем дә сихерләнгән кебек, аның күңелгә ятышлы мөлаем йөзеннән, елмаюлы алсу иреннәреннән күзләремне аера алмыйм.

Шунда мин Артурның да Сәрвиназга битараф түгел икәнлеген, әледән-әле аңа күз атуын абайлап алдым. Кызның игътибарын җәлеп итәргә теләгәндәй, гитарасын зыңгылдатудан туктаган араларда, төче телләнеп, мәзәкләр дә әйткәли. Әмма күрәм, сүзләре барып җитми. Кыз ризасызлык белән кыйгач кашларын җыерып куя.

Шәһәр вокзалы янында Сәрвиназ белән мин, машинадан төшеп калып, безнең якка бара торган поездга утырдык. Юлда сөйләшеп кайтканда, мин аның больницада шәфкать туташы булып эшләвен, Аракчинода Идел яры буенда үз өйләрендә карт әтисе белән торуын белдем. Поезд Аракчинога җиткәч, Сәрвиназ белән бергә вагоннан мин дә төштем.

Гадәттә күп сөйләшүчән булмасам да, ул чакны кинәт телем чишелеп, байтак сайрадым, әлегә тикле һичкемгә әйтмәгән кадерле хыялларым, киләчәккә планнарым белән уртаклаштым. Моңар мине, мөгаен, аның игътибар белән теләктәшлек күрсәтеп тыңлый белүе рухландыргандыр. Хәер, Сәрвиназ үзе дә тормышта күп нәрсәгә минем төсле карый, киләчәктә читтән торып укып, врач булырга ниятләнә икән.

Кичке эңгер-меңгердә Сәрвиназны өенә хәтле озатканнан соң, үзем Юдинога яр буйлап турыдан җәяү генә кайттым. Аерылганда икебез дә сизмәгәнбез, тужуркамны аның иңендә онытып калдыруымны, өйдә әни әйткәч кенә, искәртеп алдым.

Һәм шуннан бирле без эшкә бергә бара, бергә кайта башладык. Моңарчы туйдырып бетергән поездда йөрүләр минем өчен бәхетле якты мизгелгә әверелде. Яңа бәхетле дөнья ачкан кеше кебек, мин гел елмаеп, Сәрвиназ турында уйлап, эчтән аның белән сөйләшеп йөри торган булып киттем.

Ярты ел чамасы вакыт үтеп, өйләнешергә килешкәч, Сәрвиназ мине әтисенә күрсәтергә булды. Аның әтисе Зариф агай, заманында авыр поездлар йөртүче атаклы машинист, безнең теләккә каршы килмәде. Әмма минем әнинең фатихасын алу җиңел булмады. Чөнки бу мәсьәләдә аның үз планы бар: пенсиягә чыкканда, үз урынына ашханәдә мөдир итеп калдырган Азалия исемле бик тә чибәр, ут кебек чая яшь кенә тол хатынга өйләндермәкче. Шунлыктан ул Сәрвиназны үтә салкын каршылады, ник килгәнен белгәч, әдәп-нәзакәт саклап тормастан, үзенә хас төрпәлек белән:

– Чак кына оят белгән кызлар кияүгә үзләре тагылып чыкмыйлар, аларга яучылап өйләнәләр, – дип кырт кисте.

Сәрвиназның түзем, сабыр холкын, әмма нык сүзле икәнен беренче мәртәбә мин шунда күрдем. Көтелмәгән хурлаудан төсе китте, иреннәре калтырый башлады, әмма әнигә бер генә дорфа сүз дә әйтмәде.

– Гафу итегез, тагылып түгел... Таһир чакыргач, сездән фатиха алырга килгән идек... Алайса, борчыган өчен гафу итүегезне үтенәм, хушыгыз, – дип, әдәпле генә саубуллашып чыгып китте.

Минем әнине ачуланып тыңлата торган түгел. Мин Сәрвиназ кебек сабыр булырга тырыштым. Бераздан аны өенә озатып, мөмкин кадәр тынычландырып кайтканнан соң, әнигә катгый рәвештә:

– Аның белән син торасы түгел, мин торачакмын, – дип әйттем. – Мин барыбер аңар өйләнәчәкмен... Яхшылап уйла... Әгәр дорфалыгың өчен барып гафу үтенмәсәң, мин иртәгә үк аларга күчеп китәчәкмен, бу йортка бүтән аяк басачак түгелмен...

Икеле-микеле уйланырга урын калдырмаслык итеп каты әйттем, шундук әйберләремне чемоданга тутыра башладым. Мин аның бердәнбер варисы. Минсез каласы килмәде бугай, теләсә-теләмәсә дә, зәһәрен йотып, Сәрвиләргә барып гафу үтенергә, аны үзе яучылап чакырырга мәҗбүр булды. Без, семья корып, матур гына яши башладык, бер елдан улыбыз Мансур туды.

Хәлбуки әни сүзендә тормады, ачыктан-ачык каты бәрелмәсә дә, хуҗалыкта, кухняда үзе командалык итте, җае чыккан саен, Сәрвиназны мал җанлы түгел, йорт турында кайгырта белми, дип бәйләнүдән туктамады. Шулай да соңгы вакытта бераз басылган кебек иде, бүгенге кебек зәһәрләнеп тузынганы юк иде. Шайтан белсен, әнә тагын никтер җене котырган, Сәрвиназны кимсетер өчен оныгын азман калдыгы дип атаган.

Юк, моңа юл куярга ярамый, иртәгә үк әни белән ныклап сөйләшергә кирәк: андый гадәтен ташласын, телен тыйсын. Табын янында ялгыш дорфа сүз ычкындырган өчен үзем дә иртәгә үк Сәрвиназдан гафу итүен үтенергә тиешмен.

***Ай-һай, улың микән...***

Кичтән йоклый алмыйча озак уйланып яту аркасында мин иртәгесен гадәттәгедән шактый соң уяндым. Хәер, зарар юк, күз ачу белән эшкә ашыгасы түгел. Бүген мин көнозын өйдә, кич белән генә төнге вахтага чыгачакмын.

Өйдә зурлардан беркем дә юк. Сәрвиназ бу вакытта, әлбәттә инде, эштә. Мансур кичә әнкәсе бүләк иткән матрос күлмәген киеп өлгергән, түр тәрәзәне ачкан да мин биргән бинокльдән Иделне, аргы яктагы Печище кыяларын күзәтү белән мәшгуль. Әни, көндәгечә, базарга җыена бугай, ян тәрәзә каршындагы бакчада җете кызыл кыңгырау чәчәкле лаләләрдән матур-матур букетлар ясап йөри.

Аны күрү белән кичәге ниятем искә төште, кичекмәстән хәзер үк сөйләшеп, каты кисәтергә булдым... Әһә, әнә кереп тә килә, лалә бәйләмнәре тулы кәрзинен верандага куйды да, кофтасын киеп, юлга җыена башлады.

– Әни, бер генә минутка туктале, сиңа әйтер сүзем бар, – дидем, юлын бүлеп. – Менә нәрсә: Сәрвиназга бәйләнүеңне, Мансурга җилдән туган, дип, тозсыз сүзләр әйтүеңне ташла син. Минем улым, синең оныгың бит ул. Кеше-кара ишетсә, әллә ни уйлавы бар...

Әни миңа әйтеп бетерергә дә бирмәстән:

– Ай-һай, оныгым микән?! – диде, сүземне бүлеп. – Яхшылабрак карале син аңа, безнең нәселгә аз гына да охшамаган, аның йөзендә синең чалымың да юк бит... Шуны да күрмәслек сукырмыни син... Моны бөтен күрше-күлән күрә, синнән көләләр ләбаса. Миңа ышанмасаң, әнә Азалиядән сора...

Бу сүзләр, биткә ут бөркегәндәй, көйдереп алды, кулымдагы чәшкеле чәемне чүт түгеп җибәрмәдем. Кинәт кузгалган ачуымны тыя алмыйча:

– Тукта, җитте сиңа!.. – дип, гомеремдә беренче тапкыр әнигә каты бәрелдем. – Бүтән ләм-мим әйтәсе булма, ишетергә теләмим...

Минем әни хәтәр кызу канлы, нервлы, бер кабынса, тиз генә басыла торган түгел. Бу юлы чамасыз ярсуымны сизде бугай, шундук телен тешләде, каршы әйтмәде. Шулай да барыбер үзенекен итте. Верандада кәрзинен кулына алгач, ишектән башын тыгып:

– Ярар, синеңчә булыр, ул хакта миннән бүтән бер кәлимә сүз ишетмәссең... Син мескенне жәлләп, күзеңне ачарга теләп кенә әйтүем ие... – дип, йөрәккә тоз салып, шәһәргә чәчәкләрен сатарга китте.

***Үксез бәрән***

Әни белән сүзләшүдән бик нервыланып калган идем, байтак вакыт тынычлана алмадым. Бакчада виктория җиләге, помидор төпләрен йомшартып, Мансур белән бергә Иделдә су кереп алгач кына, бераз басылып, имтиханга әзерләнергә утырдым. Әгәр ерып чыга алсам, быел көз ничек тә су транспорты институтына читтән торып укырга керергә телим. Үрмәкчедән күрмәкче дигәндәй, Мансур да кәгазь, карандаш белән коралланып, минем белән бергә нәрсәдер сызгаларга кереште.

Әмма күңелем һаман тыныч түгел, зиһенем таркау, колакта әни сүзләре яңгырый. Дәреслектән аерылып, улым Мансурга текәләм, йөз чалымнарыннан үземә охшашлык эзләп вәсвәсәләнәм, әнинең аны шултикле хурлап тиргәвенә аптырыйм...

Һи, онытa язганмын, минем үземне дә шулай үртиләр иде бит. Инде күптән, бала чакта ук әле, урамда шуның өчен бер күрше малайны дөмбәсләгәндә, аның әнисе күреп: «Үксез бәрән, җилдән туган бәдбәхет», – дип, мине яңаклады. Мин елап кайтып әйткәч, әни шундук урамга чыкты да, теге хатын белән бик каты кычкырышты, үз адресына тагы да әшәкерәк сүзләр ишетте. Ул көнне кич белән Бәдретдин абый килгәч, әни теге хатынны тирги-тирги сөйләде, кеше күзенә күренерлегемне калдырмады, дип зарланды. Шуннан соң күп тә үтмәде, без ул шәһәрдән бөтенләй киттек, Юдинода менә шушы алты почмаклы зур йортны сатып алдык. Тегендә туган кешебез саналган Бәдрет-

дин абый да тиздән Казанга күчте һәм безгә еш килеп-китеп йөри башлады. Кайчандыр без яшәгән, әни пристаньда ашханә мөдире булып эшләгән шәһәр Чистай икәнен дә, күңелемә тирән сеңеп калган үксез бәрән дигән сүзнең мәгънәсен дә мин бераз үсә төшкәч кенә аңладым. Ул хакта әни берни дә әйтмәгәч, мин үзем:

– Бүтән балаларның әтисе бар, ник минем әтием юк, мин ник үксез? – дип сорадым.

Әнинең иртән эшкә китәр алдыннан көзге каршында киенеп маташкан чагы иде. Минем сораудан кинәт сагаеп калды. Кашларын җыерып бермәл карап торганнан соң, кеше-кара ишетмәсен дигәндәй, акрын гына:

– Ул юк инде, үлде ул, – диде. – Бик җәнҗалчы, эчкече иде. Талашты-талашты да, синең белән мине ташлап, читкә китеп югалды. Китүенә ике ел тулганда, аның кайдадыр Ерак Көнчыгышта янгын сүндергәндә һәлак булуы турында хәбәр килде. Үлгән – беткән, хәзер инде ул хакта сүз кузгатып, хәсрәтләнеп йөрүнең кирәге юк. Моннан соң ул турыда бүтән уйлама, сораштырып башны катырма, оныт син аны.

Әмма мин оныта алмыйм, үсә төшкән саен күбрәк уйланам. Чөнки әтиемнең исемен дә, кем икәнен, туганнары бармы-юкмы икәнен дә әйтми әни. Безгә килеп-китеп йөрүче Бәдретдин абый да туган кешегә бер дә охшамаган. Күбрәк төшергән очракларда, әни тирәсендә иркә кияү кебек сырпалана. Бездә кунган төннәрдә иртән әни бүлмәсеннән чыкканын берничә тапкыр күргәнем бар. Бу хәлне башыма сыйдыра алмыйча бик аптырап калдым һәм, моны Сәрвиназ күрмәгәе дип, әни өчен оялудан ут йотып йөрдем.

Сәрвиназ исә моны үзе дә сизгән булып чыкты һәм минем кебек уңайсызланмыйча:

– Аңа ник исең китте?.. Мин монда гайре табигый берни дә күрмим... – диде. – Берсе – ирсез, икенчесе – хатынсыз, шунлыктан кемгәдер хыянәт иткән, кемнеңдер гаилә тормышын җимергән дип гаепләргә урын юк. Җилбәзәк яшь-җилкенчәкләр түгел, икесе дә өлкән яшьтәге кешеләр, ничек кирәген белә торганнардыр, үзләре теләгәнчә яши бирсеннәр. Минем өчен тик бернәрсә – күп еллар буе болай качып-посып йөргәнче, кешечә язылышып тормаулары гына бераз сәер.

Дөрес, анысы да бар. Әмма минем әни алдын-артын уйламыйча эш итә торган кеше түгел. Исемдә, миңа ачуланган минутларда берничә тапкыр:

– Син аңгыра бәрән өчен тырышам, сиңа артык вaристаш булдырмас өчен иргә дә чыкмадым, – дип тузынганы бар.

Уф, бу борчулы уйлар белән башым әйләнде, имтиханга рәтләп әзерләнә дә алмадым. Баксаң, көн кичкә авышып бара. Әнә станция ягыннан буш кәрзинен күтәреп, әни дә кайтып килә. Элек, азык-төлек арзан вакытларда ул гел икмәк төяп кайта, икмәк ашатып үгез симертә, чәчәкләрне, алмагачларны да икмәктә ачытылган су белән тукландыра торган иде. Хәзер андый мөмкинлек юк, һәрнәрсә кыйбатланды. Товары уңышлы сатылган көннәрдә ул күтәренке күңел белән кайта, аратирә хәтта Мансурга күчтәнәч итеп, бармак башы хәтле генә шоколад яки «пепси-кола» алып кайткалый иде.

Бүген ул караңгы чырайлы, кашы-күзе җимерелгән. Буш кәрзинен ишек артына ташлады да, калтыраган бармаклары белән кофта төймәләрен ычкындыра-ычкындыра:

– Ах, харап иткән, күрәселәр бар икән... – дип ачыргаланып аһылдарга тотынды.

– Ни булды, – мәйтәм, – кем нәрсәне харап иткән?

– Кем булсын, шул синең кара еланың инде, Бәдретдин абыеңны эшеннән чыгарттырган...

– Ничек инде чыгарттырган, Сәрвиназ аның начальнигы түгел бит... Әни, син нәрсәдер бутыйсың бугай. Сәрвиназның ашханәгә һичнинди катнашы юк. Ул шәфкать туташы бит, аның эше палаталарда, авырулар арасында.

– Медсестра гына түгел, ул анда профсоюз оешмасында контроль комиссиясе члены икән. Бүген базардан соң Бәдретдин абыеңа кергән ием, шул әйтә: әгәр ашханәгә тикшерүчеләр киләсен Сәрви алдан хәбәр итсә, барысы да шома үтәчәк, эләгәсе түгел идем, ди. Йә, уйлап кара, телефоннан шылтыратып хәбәр итсә, теле корымас ие бит... Ул оятсыз үзе дә Бәдретдин юнәткән ит, май белән тыгынып ята бит. Гөнаһ шомлыгы, шултикле дә яхшылыкның кадерен белмәгән, ашаган табагына төкергән мәнсез булыр икән.

Әни хәтәр дуласа да, нәрсәнедер әйтеп бетерми, һаман читләтеп-читләтеп тузына. Аның сүзләреннән Бәдретдин абыйның эштән куылуында Сәрвинең нинди катнашы барын аңлавы кыен. Шунлыктан хәзер ул хакта җентекләп сораштырып торудан файда юк. Анда ни булганын иртәгә Сәрвиназның үзеннән белермен.

Ә хәзер миңа төнге вахтага әзерләнергә кирәк.

***Көтелмәгән командировка***

Рәсми исеменнән тыш, безнең баркасның Йөзмә тәрбияханә дигән кушаматы бар; ә капитаныбыз Әюпгәрәй агайны үз артында кайберәүләр Аяклы устав дип йөртәләр. Чөнки бүтән судноларданкуылган төрле штрафчы, сәрхушларны кадрлар бүлеге акылга утыртырга безгә җибәрә. Гаҗәп хәл, һич теләмичә, мәҗбүри килүчеләрнең күбесе, гадәттә, төзәлеп, кешелеклеге, гадел таләпчәнлеге өчен капитанга рәхмәт әйтеп китә. Быел яз башында килгән яшь штурман Артур Солтанов кына әле һаман акылга утыра алмый, сәрхушлыгын дәвам иттерә бирә.

Безнең «Зөя»нең тагын бер үзгәлеге – ул кайчандыр хәрби судно итеп төзелгән булган, мачтасында күзәтүче мәйданчыгы – «карга оясы» бар. Шунлыктан без аны ерактан күрү белән танып алабыз.

Гадәттә, ул смена алмашу алдыннан диспетчер дебаркадеры янына килеп туктаган була иде. Ә бүген үз урынында юк, күрәм, никтер күрше причалда тәэминат склады каршында тора, палубасына төрле ящик, мичкә, капчык-капчык йөк төйиләр. Моторкамны үзебезнең дебаркадер басмасына чылбырлап, палубага менгәч белдем: безнең баркаска ашыгыч рәвештә Кама елгасындагы гравий чыгару районына ун көнлек командировкага барырга приказ булган; шул форсаттан файдаланып, тәэминатчылар андагы ашханәгә азык-төлек, кибеткә товар озатмакчы икән.

Ә мин бу көтелмәгән сәфәрдән нишләргә белмичә, тәмам аптырап калдым. Үч иткән кебек, шундый уңайсыз вакытка туры килүен күр син.

– Өйдәгеләргә әйтмичә, болай бернәрсәсез баралармыни?.. – дидем. – Һич югында алмашка эчке кием, сабын-сөлге, кырынырга бритва алырга кирәктер бит.

Капитан Әюпгәрәй агай миңа авыз ачарга да бирмәде:

– Юк, туганкаем, һичкая бардым юк, – диде, җөйле-ямаулы чыраен сытып. – Озакка түгел, ун көнгә генә эчке бельесыз да түзәрбез... Анда баркаслары ватылган, безне бик көтәләр, сәгать саен диярлек шылтыратып ашыктыралар. Менә бу йөкне төяп бетерү белән хәзер үк кузгалып китәргә приказ булды.

Әнә шулай Сәрвиназга берәр җылы сүз дә әйтә алмыйча, борчулы уйлар белән кинәт китеп барырга туры килде. Ахыр килеп, бу пошыну басыла төшкән кебек булды. Ярар, дөнья җимерелмәс әле, өйдәге җәнҗалдан бераз тынычланып торырмын дип, үзем дә ул хакта артык уйламаска кирәк таптым.

***Кама буе – туган як***

Моңарчы минем Кама елгасында беркайчан булганым, аны үз күзем белән күргәнем юк иде. Бары тик юл күрсәткеч китаплардан укып, «Гүзәллеге күңелләрдән җырга күчкән як» дип җырлаудан ишетеп, атаклы рәссамнарның сурәтләреннән күреп кенә азмы-күпме төсмерли идем. Шуңа күрә юлда эштән буш вакытларда әйләнә-тирәгә игътибар белән карап барырга уйлап куйдым.

Кама елгасы тамагына без кояш баеганда барып кердек. Әйләнә-тирә чиксез киң һәм моңсу. Кичке шәфәкъ балкышына алсуланган тын дәрья күңел түрендә яткан сагышлы уйларны уята; бик еракта калган борынгы заманнарны һәм бүгенге көннәрне берьюлы күргән кебек хис итәсең... Кайчандыр бу җирләр Бөек Болгар иленең үзәге булган, бу яр буйларында безнең ерак бабаларыбыз иген иккән, мал асраган, шәһәрләр төзегән, суларында җәтмә белән балык сөзгән, җилкәнле корабларда ерак илләргә барып сәүдә иткән, һәркайда мул тормыш гөрләп торган бит... Мәгәр көннәрдән бер көнне болар барысы да тар-мар ителгән, мәһабәт сарайлар, гыйбадәтханәләр булган урыннарда хәрабәләр торып калган, җимерелгән мәчет һәм бабаларыбызның кабер ташларыннан кемнәрдер чиркәү салган. Ирексездән башта сорау туа, ник болай булган, кем гаепле дип уйланасың...

Кайчандыр бер китапта мин атаклы француз географы Ж.Реклюның «Елгалар үзләренең дулкыннарында халыклар тарихын һәм тормышын алып килә» дигән сүзләрен укыган идем. Хәзер бу тирәдән үткәндә, ул сүзләрне тагын хәтерләдем. Хәлбуки илләр, халыклар кебек, елгалар үзләре дә бозыла, тереклек чыганагы булган чиста сулар зарарлы матдәләр белән агулана. Әнә бит ургып агып торган куәтле елга, торгын сулы күл кебек, акрынлап сөрси, өсте яшелләнә, суы эчәргә һәм балыклар яшәргә яраксызлана, акрынлап һәлакәткә бара. Бигрәк тә шунысы аяныч: адәм баласы күп очракта моны күрергә теләми, үзе утырган ботакка үзе балта чапкан гамьсез кеше кебек, бу һәлакәтне үзе ашыктыра.

...Баркас зур тизлек белән yргә каршы бара бирә. Алда кичке шәфәкъ балкышына кызарган су өсте көзгедәй шома. Артта, без кузгаткан йөгерек дулкыннар сыртында, җемелдек маяк утлары тибрәнеп кала.

Безнең штурманнар, рулевойлар Кама фарватерын белмиләр, баркасны саклык белән, маякларга карап кына алып баралар. Капитан Әюпгәрәй агай да тыныч түгел. Үз вахтасы булмаса да, палубада транзистордан концерт тыңлап утырган җиреннән әледән-әле алга борчулы каранып ала һәм, баркас юлдан читкә тайпыла башласа, рубкадагыларга рульне уңга яки сулгарак тотарга команда бирә.

Койрык якта ашханә мөдире Азалия порттан алган азык-төлек өемнәре арасында актарына иде. Менә шул кинәт ачыргалы тавыш белән:

– Ах, бер ящик ит консервы юк... Сезнекеләр урлаган, башка беркем түгел... – дип шәрран ярды.

Капитан транзисторны борып туктатты, Азалия янына якынрак килеп:

– Ут чыккан кебек ник тавыш күтәрәсез, ни булды? – диде.

– Ничек кычкырмаска, бөтен бер ящикны урлаганнар ич... Хәзер үк сезнең белән бергәләп, акт төзергә кирәк. Юкса бәясен миңа түләргә туры киләчәк бит.

– Әлегә тикле бездә андый кыек эш күренгәне юк иде. Бөтен командага зур гаеп бит бу. Акт төзегәнче, әйдәгез яхшылабрак карыйк әле, ялгышмадыгыз микән.

Капитанның сүзе рас килде. Базадан бирелгән накладной буенча җентекләп санагач, берни дә югалмаган, консервалы ящик он капчыклары артында яткан булып чыкты. Азалиягә шундук телен тешләргә туры килде.

Тагын берәр аңлашылмаучылык тумасын, җил-яңгыр чыгып чылатмасын өчен, капитан кушуы буенча, рулевой Харитон белән Азалия барча азык-төлекне бер тирәгә җыеп, брезент капладылар, өстеннән аркылы-торкылы сүс трос белән тарттырып бәйләргә керештеләр. Шулчак кулындагы трос ычкынып, Азалия арты белән суга ауды, винт кузгаткан күбекле дулкыннар эчендә юк булды... Аннары өскә калкып, кулын болгый-болгый ашыгыч ярдәм сорап кычкыра башлады...

Бераз саф һавада җиләсләнергә теләп, тамбурда торган чагым иде. Бу хәлне күрү белән тиз генә аска төштем һәм, рубкадан команда булганны да көтмичә, машинаны акрынайттым.

Берничә минуттан мин иллюминатордан караганда, баркас инде агым уңаена борылган, якында гына прожектор белән яктыртылган су өстендә кемдер буш кулы белән ишә-ишә Азалияне тартып килә иде. Безнең егетләр аларны палубага күтәреп алдылар. Коткаручының капитаныбыз Әюпгәрәй агай икәнен шунда гына таныдым. Ул трусиктан гына, ялангач тәнле, еш-еш сулый, битләре кебек үк, аның күкрәге, беләге, ботлары да күпсанлы җөй-ямаулык белән капланган иде.

Азалиянең бөтен өс-башы тәненә ябышкан. Ул бик курыккан һәм тончыккан, күрәсең, бизгәк тоткан кебек, дер-дер калтырый, буылып-буылып су коса. Бераз тын алгач кына, көч-хәл белән:

– Уф-ф, чак кына харап булмадым,– диде...– Мин бер дә йөзә белмим бит. Җитмәсә, караңгы төшкән вакыт... Әюпгәрәй агай, сезгә рәхмәт инде... Сез тизрәк килеп коткармасагыз, су төбенә китәчәк идем.

Капитан эскәмиядә салып калдырган киемнәрен җыеп маташкан җирдән:

– Үзем дә нәкъ шуннан курыккан идем... Арткы палубада беркем дә булмагач, тиз генә чишенеп, суга үземә ташланырга туры килде, – диде һәм, юлны дәвам итәргә күрсәтмә бирде дә, каютасына киенергә кереп китте.

Моңарчы мин чәчләренә кырау төшкән бу агайның ямаулы йөзенә ихтирам катнаш кызганып карый идем, гомеренең көзе җиткән, гәүдәсе сызлана, хәлсезлектән интегә торгандыр дип уйлый идем. Әмма аз белгәнмен икән. Бүген мин аның мускуллары калын, көч-куәткә ия, хәрәкәтләре ныклы икәнен күрдем... Минем уйларымны раслагандай, Азалия дә соклану белән:

– Кара син аны, төп кебек таза һәм җитез...– диде.– Алгы палубада домино уйнаучы яшьләр кыймылдаганчы, ул яшен тизлеге белән килеп коткарды. Әйтәм ич, юкса су төбенә китәчәк идем.

***Якыннан танышабыз***

Гравий чыгару районы Кама елгасының түбәнге агымында урнашкан. Елгачылар җәй буе шунда су төбеннән кыйммәтле төзелеш материалы – миллионнарча тонна гравий чыгарып, ерак республикаларга, өлкәләргә озаталар. Куәтле җирсуырткычлар, йөзмә краннар, килгән-киткән күпсанлы теплоходлар, баржалар тулы киң рейдта кызу эш тәүлек буе туктамый дәвам итә.

Бирегә килеп җитү белән без дә шул мәшәкатькә чумдык: нәкъ порттагы кебек, буш баржаларны краннар, җирсуырткычлар янына китереп куябыз, йөкләрен юлга озатырга әзерләп җыябыз, төягәндә эчләренә тулган суны насос белән бушатабыз, кешеләрне эшкә илтәбез, вахтадан бушаганнарын базага алып кайтабыз.

Район идарәсе куе урманлы биек тау итәгенә бәйләп куелган «Баһадир» исемле ике этажлы иске пароходта. Элемтә бүлеге, медпункт, кибет, клуб һәм ашханәләр дә шунда. Каюталарында механизаторлар, канцеляриячеләр яши. Террасада, коридорларда гаиләле кешеләрнең эреле-ваклы бала-чагасы дөбер-шатыр куыша, качыш-качыш уйный.

Безнең баркас командасын өске каттагы икешәр урынлы каюталарда урнаштырдылар. Мин Әюпгәрәй Харисович белән бер каютага туры килдем. Ике яруслы агач караватның аскы катында ул, өстә – минем урын; менеп-төшеп йөргәндә, олы кешене борчымас өчен, мөмкин кадәр саграк булырга тырышам.

Әюпгәрәй агай, отставкага чыккан хәрби диңгез флоты офицеры, безгә капитан булып былтыр гына килде һәм, хәрби корабтагы кебек, һәр эштә тәртип таләп итә башлады. Безнең арада кайберәүләр аны өнәп бетерми, үзен эре тотучан дип сукраналар. Шуңа күрә көтмәгәндә аның белән бер каютага эләккәч, ирексездән сагаеп калдым.

Мәгәр юкка шикләнгәнмен, мин моны шул кичне үк күрдем. Монда килгән көнне без урнашып, баш-күз алган арада, ашханә ябылган булып чыкты, төнгә каршы кичке ашсыз калдык. Чәйнек белән кайнар су алып кереп чәй пешергәч, Әюпгәрәй агай өеннән алып килгән азыктан миңа да өлеш чыгарды, тартынып торуымны күреп, кыстый-кыстый ашатты.

Төрле сменада эшләгәнгә күрә, моңарчы без вахта алмашынганда гына очраша, бер-беребезне аз белә идек. Чәй янында әңгәмә корып утыра торгач, якыннанрак таныштык. Сүз арасында ул, сәер нәрсә күргәндәй, кинәт миңа текәп карый башлады, аннары да берничә тапкыр күз кырыен маңгаема төшереп алды. Ахыр килеп түзмәдем:

– Әюп агай, ник алай карыйсыз, нәрсә күрдегез? – дип сорадым.

Ул көтелмәгән уңайсызлану белән:

– Юк, болай гына... Каш өстеңдә яңа туган ай урагы сыман ярым түгәрәк миң бар икән, шуңа каравым, – диде һәм үз маңгаендагы җөйле ямавына бармакларын тидереп алды.

Әюпгәрәй агайның егет вакытта ике сабый баланы янгыннан коткарганда, үзе ут эчендә һәлак була язганын, врачлар аны зур кыенлык белән үлемнән саклап калганын мин моңарчы да ишетеп белә идем. Менә хәзер йокларга ятар алдыннан җиңсез майкадан гына калгач, киң күкрәгендә, иңбашларында зур-зур ямау җөйләрен якыннан күреп, тәмам тетрәндем, дулкынлануымны тыя алмыйча:

– Әюп агай, бик авыр булгандыр бит, шултикле яну-көюгә, врачлар тирегезне каезлау, ямауга ничек чыдадыгыз? – дип сорау бирдем.

– Түзми нишлисең, башыңа төшкәч, чыдыйсың инде, – диде ул, җиңелчә елмаеп. – Ярый әле шундук һушсыз хәлдә самолетта Владивостокка озаттылар. Ярты елдан артык госпитальдә аунап ятарга туры килде... Озак югалып торгач, үзем хезмәт иткән погранпостта исән калыр дип уйламаганнар, уттан балаларны коткарганда һәлак булды дип, Чистайга хәбәр җибәргәннәр... Әмма мин исән калдым, дәваланып чыккач, хәрби-диңгез училищесына укырга кердем. Хәер, башта медкомиссия үткәрмәгән иде. Әмма мин ярдәм итүен үтенеп, флот командующиена гариза яздым. Шуның кушуы буенча комиссия кабат караганнан соң, эчке органнарымнан авыру тапмадылар, тышкы ямау-җөйләре төзәлгән дип, мине училищега кабул иттеләр. Җөйле курсант булып укый башладым.

Бу «җөй» миңа гомерлеккә ябышты, соңыннан корабларда хезмәт иткәндә, иптәшләр дә үзара шул кушамат белән йөртәләр иде... Әмма кайда гына яшәсәң дә, күпме еллар үтсә дә, туган-үскән җир гел истә, төшләргә кереп тора. Шуңа күрә отставкага чыгу белән туган шәһәрем Чистайга кайттым, әтием-әниемнең чардуганын буяттым, садака биреп, ясин чыгарттым. Үләр алдыннан әни мәрхүмәнең әйтеп калдырган васыяте шундый иде. Монда вакытны ничек тә тагын барып, каберләрен рәтләп кайтырга кирәк.

Ул кичне без караңгы каютада байтак вакыт гәп корып яттык. Башлыча Әюпгәрәй агай сөйләде. Минем тумышым да Чистайдан икәнне белгәч, ул кинәт җанланып, гаилә тормышым, әнием турында кайта-кайта сораштыра башлады, берничә тапкыр:

– Шулаймыни!.. Шулаймыни!.. – дип кабатлап, мине хәтта бераз гаҗәпкә калдырды.

### *Хат һаман килми*

«Баһадир»ның беренче класс салонын клуб дип йөртәләр. Кичләрен анда үзешчәннәр концерты, танцылар булгалый, телевизор карыйлар. Зур-зур тәрәзәләре шар ачылган, куәтле лампалар белән яктыртылган иркен салон төн уртасына хәтле шау-гөр килә.

Бирегә килгәннән соң атна-ун көн чамасы үткәч, бер кичне клубка мин дә кергән идем. Көндез эш киемнәреннән ничектер килбәтсез күренгән кызлар, егетләр хәзер бәйрәмчә киенгән-ясанган-

нар һәм күңелле музыкага җиңел хәрәкәтләр белән парлашып бөтереләләр. Аларга карап утыра торгач, мин дә күршемдәге коңгырт чәчле чибәр генә бер кызны биергә чакырдым. Сүз арасында мин аның Гөлбикә исемле икәнен, быел гына кулинария училищесы тәмамлап, бирегә өч кыз пешекче булып килүләрен белдем; танцылар бетеп, клубта ут сүнгәннән соң да, алар белән террасада беравык сөйләшеп йөрдек.

Көндезге вахтадан һәм танцылардан соң шактый арылган, бик тиз йокыга китәрмен шикелле иде. Мәгәр алай булмады, шыпырт кына урыныма менеп яту белән, күз алдыма өйдәге хәл килеп басты, башта берсеннән-берсе күңелсез уйлар кайный башлады. Бигрәк тә Сәрвиназны үпкәләтүем өчен оят, аннан гафу үтенмичә, тынычландырмыйча китүем өчен уңайсыз. Әнинең әлегә тикле беркайчан булмаганча зәһәрләнүенең сәбәбе дә аңлашылмый, нәрсәнедер әйтеп бетерми. Һәрхәлдә, гадәттән тыш нидер булган. Кайту белән ачыкларга, бу ызгышка чик куярга кирәк.

Мәгәр безнең командировка башта уйлаганчаункөнлек кенә булмады, Чистай заводында районның үз баркасын ремонтлау озакка сузылачагы беленде. Димәк, безгә монда Кама суларын тагын байтак сукаларга туры киләчәк әле.

Эшләр болайга киткәч, мин өйгә кайтуны көтмәскә булдым, ялгышлык белән ычкындырган дорфалыгым өчен, Сәрвидән кичерүен үтенеп, аны да, улым Мансурны да бик сагынуымны, еш кына төшләремдә күрүемне әйтеп җылы хат яздым.

Бу хатны җибәргәннән соң дүрт көн үткәч, почта йөртә торган метеорны ике күзем дүрт итеп каршылый, өйдән җавап көтә башладым. Кыенлык белән булса да, берничә тапкыр телефоннан шылтыратып та караган идем, кызганычка каршы, Сәрвиназның эштә юк чагы туры килде.

Шулай ут эчендә тагын бер атна үтте, ә җавап һаман юк та юк. Отыры борчуга төштем, көн саен өйгә бер-бер артлы хат яудыра башладым. Көтеп-көтеп тә һичнинди хәбәр килмәгәч, әллә ниләр уйлап бетердем. Ашым аш, йокым йокы түгел, тәмам авыруга сабыштым.

***Ихтирамлы дәвамчы***

Ниһаять, түзәр хәлем калмады, капитан белән сөйләшеп, бер тәүлеккә өйгә кайтып килергә рөхсәт алдым. Шуның өстенә кием-салым да керләнгән, бритва, сабын, ашаган өчен түләргә акчам да юк иде. Әюпгәрәй агайга рәхмәт, үтенечемне кире какмады, сәбәбен сораштырып казынмады. Каш өстемдәге миңемә күзләрен текәп карады да:

– Соңга калма, әйткән вакытка кайтып җитәргә тырыш, – дип, якын итеп искәртте генә.

Азалия иртән ашханәдә юлга ашыгуымны белү белән мине конторкасына алып керде, нидер тутырылган зур гына сумка тоттырып:

– Мә, Миләүшә апайга аз гына күчтәнәч, – диде. – Җәй башында монда күчеп киткәннән бирле күргән дә юк, күп итеп сәлам әйт... Җәйнең иң матур чагы бит, әйт үзенә: ничек тә вакыт табып, атна-ун көнгә безгә кунакка килсен. Бераз ял итәр, эшләгән җирләрен күреп, исенә төшереп китәр.

– Шактый авыр икән бу, шултикле нәрсә монда? – дип гаҗәпләндем.

– Юк, юк, һич тә авыр түгел... Анда нибары берничә банка икра, мәрсин консервасы һәм һинд чәе белән шоколад кына. Телдән әйт үзенә: бер төргәген минем әнигә кертеп бирсен... Мондый йомышны теләсә кемгә ышанып булмый. Син, зинһар, авырсынма, алып кайта күр инде.

– Авырсынудан түгел, шултикле күп деликатес ни өчен дип әйтүем генә.

– Һи, ни өчен буламыни... Миләүшә апай мине кешедән кешене аера, тормыш итәргә өйрәтүче остазым бит. Пенсиягә чыкканда, начальство белән сөйләшеп, үз урынына мөдир итеп калдырды. Аның каршында мин гомер буе бурычлымын.

***Бал мичкәсе көенә***

Шул ук көнне кичкырын мин Чаллы белән Казан арасында йөри торган метеорда Казанга кайтып төштем. Аннары үземнең шкиперда калдырган моторкама күчеп утырып, таныш юлдан су өсләп зур тизлектә туп-туры Юдиногa элдерттем. Чөнки вакыт тар, ашыгырга, бар эшне җайлап, иртәнге рейска өлгерергә кирәк.

Аракчино турыннан үткәндә, су читенә уйнаучы балаларның трусик кына кигән берсе мине күрү белән кулларын болгарга тотынды, башка берәү белән бутап булса кирәк, хәтта абына-сөртенә яр буйлап бераз йөгереп тә барды. Ярар, хәзер кайтып җиткәч, улым Мансур да мине шулай каршылар дип уйлап куйдым.

Үзебезнең такта басма янына килеп туктаганда, инде кояш батып барган вакыт иде, яр өстендәге өебезнең каралҗым күләгәсе вак дулкыннар өстендә тибрәнә. Бүтән көннәрне бу вакытта эштән кайтканда мине улым Мансур каршылый, һаман саен, әйдә көймәдә йөреп кайтыйм, дип йөдәтә

иде. Бүген ул юк. Мин кайтасын белми бит, уйнап арып, өйгә кергәндер. Басма янында карт өянке генә нәүмиз уйга талгандай, су читендә берьялгызы йокымсырап тора иде.

Тәрәзәләрдә никтер ут юк. Веранда ишеге бикле булгач, әни өйдә юктыр дип уйлаган идем. Үз ачкычым белән ачып керсәм, ул өйдә булып чыкты, түр яктагы зур көзге каршында авыз эченнән нидер көйли-көйли битләрен, күз төпләрен сыйпап утыра, имеш! Мине күрүгә ул, ярамаган эш өстендә тотылгандай сискәнеп:

– Аһ, син кайттыңмыни?! – диде һәм, куллары белән күкрәген каплый-каплый, тиз генә үз бүлмәсенә кереп китте.

Өстәл өстендә буш аракы шешәсе, ике рюмка һәм ашамлык калдыклары. Күрше бүлмәдә әни ишетелер-ишетелмәс кенә нәрсәдер мыгырдый шикелле. Менә ул ефәк халатын кигән һәм инде каушавыннан арынган хәлдә, һәрвакыттагыча ныклы адымнар белән үзе килеп чыкты, ни өчендер акланган сыман:

– Билләрем сызлап тора... Бераз ярдәм итмәсме дип, мунчадан соң чак кына менә бу нәстәне капкан ием, – дип, тиз генә өстәлдәге шешәне, рюмкаларны җыештыра башлады. – Үзең нихәл, бөтенләйгә кайттыңмы?.. Әбәү, сакал-мыегыңны күрми торам, йоннан төргән кебек булгансың.

Тегеннән Азалия биреп җибәргән күчтәнәчләрне әни бик шатланып кабул итте, рәхмәтләр әйтә-әйтә, сумканы бушатырга тотынды. Шунда сервант өстендә яткан конвертлар күземә чалынды. Алып карасам, күрәм, барысы да мин җибәргән хатлар, берсе дә ачып каралмаган.

– Болар ник болай ачылмыйча ята? – дидем, бик аптырап. – Сәрвиназ белән Мансурны күрмим. Өйдә юклармыни, кая киттеләр?

– Юк, өйдә түгелләр, алар хәзер бездә тормый ич... – диде әни.

– Ничек инде бездә тормый?.. Ник киттеләр, кая киттеләр?

– Анысын белмим, тәгаен генә әйтә алмыйм. Ул ләтчә синнән соң монда күп тормады, җилдән туган көчеген җитәкләде дә чыгып китте. Шуннан бирле күренгәне юк, ире өйдә юкта иркендә сөйрәлеп йөрүедер. Ул хәзер этисе янында булса кирәк, беркөн шәһәрдән кайтканда поездда Аракчино хатыннарының шулайрак такылдавы колагыма чагылган ие.

Тегендә борчылуларым юкка булмаган, күңелем сизенгән икән. Шулай да бу тикле булыр дип уйламаган идем. Әнинең сүзләреннән кинәт миңгерәгәндәй, нишләргә белмичә аптырап калдым. Кузгалган ачуымны көч-хәл белән тыеп, сыкрану белән:

– Тагын дөньяга сыймагансың, харап иткәнсең икән... – дип кенә әйтә алдым.

– Әй, пүчтәккә борчылмасана... – диде әни, искитмәле берни дә булмагандай. – Олагуы хәерле, күптән шулай кирәк ие. Бүтән чакыра күрмә, эзе булмасын берүк... Дөньяда хатын беткәнмени. Синдәй бай иргә менә дигәне табылыр... Әнә Азалиянең кай җире килмәгән. Төсе-бите, уңганлыгы белән синең нәсел корткычныңише генә түгел. Шуңа өйләнерсең, йорт җанлы хатын рәхәтен күреп яшәрсең ичмасам.

– Ни сөйлисең, нәсел корткыч булып Сәрвиназның безгә ни зыяны тигән?!

– Корткыч булмаса, Бәдретдин абыеңны эшеннән кудыртмас, контрольгә киләбез, сак тор, дип хәбәр итәр ие...

Әни Сәрвиназны әшәке сүзләр белән хурлап сөйли, шул арада әледән-әле күз кырые белән генә үз бүлмәсе ягына никтер борчулы каранып ала... Чү, анда чынлап та ниндидер хәрәкәт бар бугай, ара-тирә нәрсәдер кыштырдый, уфылдап куя шикелле. Менә кемдер сулышы кысылгандай буыла-буыла кычкырып җырлый да башлады:

Җырлыйк әле, җырлыйк әле, бал мичкәсе көенә
Яратмаса кайтып китсен анасының өенә...

Алла биреп баесам, камалы тун тектерәм.
Җә баермын, җә бөләрмен, бүгенгесен типтерәм...

Җырлаучының Бәдретдин абый икәнен мин беренче сүзләреннән үк танып алдым. Артыграк төшерде исә, ул һаман «Бал мичкәсе көе»нә шушы ике җырын мөгрәргә тотына. Бүген ул тәмам хәлдән тайганчы чөмергән булса кирәк, рәтләп сүзләрен әйтә алмый, тамагына төер тыгылгандай, әледән-әле гыр-р... гыр-р... итә.

Менә ул якта ниндидер авыр нәрсә дөп итте һәм Бәдретдин абый ах-ух ыңгыраша башлады. Әлегә тикле берни дә ишетмәмешкә салынып маташкан әни, инде бүтән яшеренеп тормастан:

– Ай, караваттан егылды бугай, имгәнмәгәе... – дип хафаланып бүлмәсенең ишеген ачты.

Бәдретдин абый дөрестән дә караваттан егылып төшкән, без барып кергәндә, кулларын як-якка салган хәлдә идәндә «бүгенгесен типтерәм»не мөгрәп ята иде. Без аны көч-хәл белән караватка салдык. Әни өстенә простыня япты, форточканы ачты, оялырлык берни дә булмагандай:

– Барысы да шуның аркасында... – дип, тагын Сәрвиназны каһәрләргә тотынды. – Элек болай ук булмый ие, синең азгының эштән чыгарткач, кайгыдан башын югалтты, һаман эчә дә эчә...

И, тик хәзер генә шәйләп алдым, бу ыгы-зыгы белән күрми торам, бөтен өй эче, талап чыккан кебек, бушап калган ич: ян стенадагы бизәкле зур келәм дә, сервант тулы хрусталь савыт-саба да, төсле телевизор һәм тегү машинасы да юк.

– Нинди бөлгенлек бу, караклар баскан кебек... Син өйдә юкта Сәрвиназ төяп киттеме әллә? – дип шаккаттым.

– Юк, хәзергә аңа барып җитмәде әле, булмаганны әйтә алмыйм...– Әни як-ягына искәртүле каранып, тавышын акрынайта төште. – Шулай да Алла, саклангенны саклармын, дигән бит. Бәдретдин тотылганнан соң, тентү, опись булмагае дип, затлырак әйберләрне Азалия әнисенә кертеп куйган ием.

Шикле шикләнер, чикмәнен бөркәнер, дип, тикмәгә әйтмиләр, күрәсең. Әнә бит ничек, кәкре куллы булгач, калтырап яшәргә туры килә. Ә мин, күзле сукыр, нинди мохиттә яшәгәнемне күрмәгәнмен.

Мәгәр ара тар, минем монда озын-озак чуалырга вакытым юк. Иртәнге теплоходка хәтле Аракчинога барып, үземнекеләрне күрәсем бар бит әле. Артык зурга киткән бу низагны болай гына калдырып китеп булмый. Барыннан да бигрәк Сәрвиназны тынычландырырга, ничек тә күндереп, икесен дә өйгә кайтарырга кирәк.

Иртәдән бирле тамакка капканым юк иде, әнигә тиз генә берәр нәрсә әзерләргә әйттем. Ул кухняда маташкан арада тиз генә юындым, кырындым да, алмаш кием, бритва, сабын, сөлге алдым. Монда күз көеге булып тормасыннар дип, бер уңайдан ачылмаган конвертлы хатларымны да сумкага салдым.

Иркенләп ашап-эчеп утырырга вакыт та, теләгем дә юк. Кан кайнаган чак, кызулык белән берәр ахмаклык эшләп ташлаганчы, бу бозыклык оясыннан тизрәк чыгып китәргә ашыктым. Әни бүлмәсе турыннан үткәндә, эчке яктан сәрхуш Бәдретдин абыйның йокы аралаш көчәнә-көчәнә «Бал мичкәсе көе»нә мөгрәве ишетелеп калды.

***Сәрвиназ җылы сүз дә әйтмәде***

Тышта инде төн уртасы. Куе томан төшкән. Су өстендәге маяклар, елга аръягындагы утлар ерак галәм җисемнәре кебек җемелди. Бездән ерак түгел үрге якта бер теплоход, томан таралганны көтеп, якорьда тора булса кирәк, әледән-әле сузып-сузып гудок кычкырта. Югыйсә мондый томанда башка бүтән судноның килеп бәрелүе бик ихтимал.

Әмма мин томан таралганны көтеп тора алмыйм. Суднолар йөртү кагыйдәсен бозып булса да, тәвәккәлләп кузгалдым һәм көндез дә, төннәрен дә күп тапкырлар йөрелгән таныш юлдан саклык белән китеп бардым.

Зариф бабайлар әле барысы да ятмаган бугай, елгага караган тәрәзәләренең берсендә ут бар. Әкрен генә шакуга өйалдында ут кабынды, мин икәнне белгәч, ишекне Сәрвиназ ачты. Әлерәк кенә башын юып, сөртенгән чагы булса кирәк, иңендә ак сөлге, чәче юеш.

Бер-беребезне сагынып эштән кайткач, гадәттә, Сәрви мине якты йөз белән каршылый, өйдә икебез генә булганда җиңелчә пәп итеп ала торган иде. Бу юлы алай итмәде, елмаймады да. Күрәм, үзен тотышында моңарчы төсмерләнмәгән яңа чалым бар, ничектер күзгә туры карамый. Төскәбиткә дә сизелерлек үзгәргән: күз карашы моңсу, яңаклары суырыла төшкән. Кыйгач кашлары арасында күренер-күренмәс кенә җыерчык сызыгы хасил булган. Мине күрүгә әллә ни исе китмәде шикелле. Гадәттәгечә елмаеп каршы алмады. Алгы бүлмәгә кергәч, сөлгесен чөйгә элеп куйды да:

– Түр якта әти белән Мансур йоклый, шунда гына сөйләшик, – дип, өстәл янындагы урындыкка күрсәтте, үзе каршыга утырды. Беравык сүзсез утырганнан соң, ризасызлык белән:

– Инде төн уртасы бит, ничек болай соң киләсе иттең? – диде.

Мин бу очрашуны бөтенләй башкача күз алдыма китергән идем, тегендә төннәр буе йокламыйча борчылуларымны әйтергә җыенып, кара гайбәт аркасында арабызда туган салкынлыктан арынырга өметләнеп кайткан идем бит. Аның шултикле илтифатсыз каршылавыннан тел очымдагы җылы сүзләрем, җил алгандай, юкка чыкты, ирексездән күңелемдә шик кузгала башлады. Әни дөрес әйтә, күрәсең, ул миннән тәмам бизгән, күзгә туры карап сөйләшми дә, дип уйлап куйдым... Шулай да эчемдәген шундук сиздертмәскә тырыштым, мөмкин кадәр сабырлык белән:

– Ни булды сиңа, кеше көлкесе ясап, ник өйдән чыгып киттең? – дип сорадым.

– Юк, үзем китмәдем, алар куып чыгарды мине, – диде Сәрвиназ. – Ул кичне Бәдретдин абый бик исереп килгән иде, башта шул тиргәп бәйләнде. Аннары дары кебек кабынып әниең ташланды, әллә ниләр әйтеп хурлап бетерде.

– Бәдретдин абый эшенә ник тыгыласың? Әләкләмәгән булсаң, сиңа беркем дә тимәс иде.

– Һич алай түгел, мин һичкемнең эшенә тыгылганым да, әләкләгәнем дә юк, – диде Сәрви, күзгә туры карап. – Дөресе менә болай булды аның: палаталарда авырулар ачлы-туклы утырабыз, ашларның тәме юк, дип шаулый башлагач, профком кушуы буенча контроль группасы төшке аш вакытында ашханәдә тикшерү үткәрде. Нәтиҗәдә кухняда Бәдретдин абый салып биргән һәр порциядә ит нормадан ким чыкты. Шуның өстенә кухня суыткычында аның сумкасына салып куелган ике килодан артык ит, ике пачка атланмай табылды. Ул инде моңарчы бер эләккән булган, шуның өчен эшеннән чыгардылар... Кызганычка каршы, контроль группасында мин дә бар идем, шунлыктан Бәдретдин абый каршында мин гаепле булып калдым: тикшерү киләсен берничә минут кына алдан шылтыратып хәбәр итсәм дә, беркем һичнәрсә сизмәячәк, барысы да шома гына үтеп китәчәк иде, дип, мине таларга тотындылар.

Мин, акыллы баш, күп уйлап тормастан:

– Чынлап та, ник хәбәр итмәдең? – дип әйтеп ташладым.

Бу сорау Сәрвиназга сәер тоелды бугай, колакларына ышанмагандай, бермәл гаҗәпләнеп карап торды да:

– Андый уй ничектер башыма килмәде, – диде. – Минем урында булсаң, син нишләр идең, хәбәр итәр идеңмени?

– Минме, синең урыныңда булсаммы?.. М-мин... – дип, ык-мык килеп, сүземне әйтеп бетерә алмыйча, уңайсызланып калдым. Миңа эсселе-суыклы булып китте, кызаруымны сиздем. – Шулаймыни... Алайса, теге чакны ул якларын мин күреп бетермәгәнмен. Син дә ачык итеп әйтмәдең, – дидем, акланырга теләп.

– Һи, ул кичне син әйткәнне тыңларлык түгел идең шул, авызыңа су капкан кебек, иреннәреңне турсайтып, сүзсез утырдың. Баланың беркатлы соравына: Азман абыеңның безгә кайчан килгәнен әнә әниеңнән сора, бәлкем, ул белә торгандыр, дип әйткәнеңне оныттыңмыни?..

– Юк, онытмадым... Андый сүзне тиктомалдан ничек әйтеп ташлавымны хәзер дә һич башыма сыйдыра алмыйм, бик үкенәм. Күңелеңдә үпкә саклама, зинһар, кичер. Һич тә сине кимсетергә теләп әйтмәгән идем. Үзең дә беләсең, мин андый кеше түгел...

– Кайчандыр беләм шикелле иде, ышана идем... Әмма белеп җиткермәгәнмен, күрәсең...

– Ялгышасың, бер дә алай түгел, кичер мине. Болай ярамый, әйдә хәзер үк кайтарып куям үзегезне.

– Ялварып сорама, ул комсызлар янына мин бүтән аяк басачак түгелмен.

Үгетләп-үгетләп тә күндерә алмагач, мин аңа:

– Алайса, әйдә болай итәбез: мин үзем сезгә күчеп киләм. Монда бергә яшәрбез, мин синсез тора алмыйм, – дип, кинәт башыма килгән яңа ниятемне әйттем.

Минем уйлавымча, Сәрвиназ моңа каршы килмәскә тиеш, элегрәк шундый фикерне берничә тапкыр үзе дә әйткәне бар иде. Хәзер исә ул берни дә ишетмәгән сыман, үз уйларына чумган хәлдә битараф чырай белән сүзсез утыра бирде. Бу минутта ул безнең өйдән, холыксыз энидән генә түгел, минем үземнән дә бизгән, тәмам суынган кебек тоелды. Үзе телдән әйтмәсә дә, мин моны күңелем белән сиздем һәм, суга бата башлаган кеше саламга тотынган кебек, безне бер-беребезгә бәйләүче йөрәк парәбез булуын искәртү теләге белән:

– Мансур нихәл йөри, мине телгә алгалыймы? – дип кызыксындым.

Сәрвиназ, күзләрен һаман каядыр читкә төбәгән хәлдә:

– Ни булсын аңа, көнозын бабасы белән йә бакчада казыналар, йә су буенда кармак салып утыралар, – дип, теләр-теләмәс кенә әйтеп куйды.

Улымның мине телгә алу-алмавы турында берни әйтмәгәч, йөрәгем ачынды:

– Мансур мине шулай бик тиз онытты микәнни, бер дә искә алмыймыни? – дип кабат сорадым.

– Искә алмаган кая ул, телендә һаман син генә... Су өстендә мотор тавышы ишетелсә, эти түгелме дип, тәрәзәгә ташлана. Ә бүген кичкырын безнең турыдан үткәнеңне күргәч, ут чыккандай атылып керде дә, эти кайтты, эти... Әйдә аның янына, дип шашына башлады. Көчкә тынычландырып йоклата алдык.

Кара син аны, таныган икән балакаем, мин сезнең турыдан үткәндә яр буеннан миңа кул болгап калучы шул булган икән ләбаса. Яшермим, моны белү йөрәгемә май булып ятты.

Минем шатлыгымны уртаклашкандай, нәкъ шул мәлне ябылып бетмәгән ишек аша түр яктан улым Мансурның йокы аралаш:

– Ур-ра, безнең көймә... Әти кайтып килә... – дип кычкырганы ишетелде, улым, мин монда дип, аның янына атылып керүдән чүт тыелып калдым.

Сәрвиназ халәтемне сизде бугай, тиз генә барып, ишекне кысыбрак япты. Аннары стенадагы сәгатькә карап:

– Таң атарга да күп калмаган... – диде. – Иртән эшкә барыр алдыннан бераз черем итеп алырга кирәк. Бар, сиңа да вакыттыр инде.

Аның сүзләрен раслагандай, төнге тынлыкны бозып, өй артындагы кетәклектә таң әтәче кычкыра башлады. Көнчыгышка караган ян тәрәзәдә дөрестән дә караңгылык сыегаеп килә иде. Миңа юлга кузгалыр вакыт җитте.

Сәрвиназ мине озата чыкты. Караңгы өйалдында мин аны кулыннан алып:

– Сәрви бәгырем, син бер дә болай түгел идең ич, – дидем өзгәләнеп. – Мин тегендә синең өчен ут йотып, төннәр буе рәтләп йокламыйча борчылып, сагынып кайттым. Шулай бер генә җылы сүз дә әйтмичә җибәрәсеңмени?.. Нишләвең бу, һич аңламыйм...

– Хәзерге вакытта нишләвемне үзем дә белмим, башым тәмам түнгән... – диде Сәрвиназ, күз яшьле тавыш белән. – Син дә мине аңларга тырыш: түзмәдем түгел, алты ел түздем, бүтән тәкатем калмады. Тәмам җаным бизде, ул якка борылып карыйсым да килми.

Өй эченнән Зариф агайның картларча буылып йөткергәне ишетелде.

– Ярар, болай аяк өсли генә сөйләшә торган сүз түгел бу. Бар, хәерле юл сиңа... – дип, Сәрвиназ минем артымнан өйалды ишеген ябып калды.

Сагынып кайткан хатынымнан бер генә җылы сүз дә ишетмичә, улымны да күрмичә, тагын да авыррак уйларга чумган хәлдә, кире китәргә мәҗбүр булдым.

***Кадерен белмәдем***

Гомер булмаган хәл, юлда моторым сүнеп кәҗәләнде, аны рәтләп маташып, иртәнге рейска чүт соңга калмадым. Мин портка төшеп җиткәндә, иртәнге метеор инде пассажирларны кабул итеп бетергән, чалкаларын ычкындырып, ашыкмый гына юлга кузгала башлаган иде. Йөгереп килгән шәпкә теплоходның койрык ягына башта сумкамны ыргыттым, аннары причал култыксасы аша тиз генә атлап чыгып, үзем сикердем. Шунда мин дебаркадер кырыенда кулын болгап кемнедер озатучы бөдрә чәчле яшь кенә бер ханымны ашыгычлык белән чүт бәреп екмадым һәм теплоход палубасыннан гафу итүен үтенеп башымны идем. Чөнки мин кеше алдында тиргәп кызартыр дип уңайсызланган идем. Әмма киң күңелле икән, ачуланмады, хәлемә кергәндәй, сизелер-сизелмәс елмаеп, бармак кына янаган булды.

Теплоход халык белән шыгрым тулы. Шулай да салонның сул як ишеге янында бер буш урын табылды. Шунда утырган хәлдә йокымсырап барганда, янымдагы сумкамны кемдер тарткан кебек тоелды. Күтәрелеп карасам, техникумда минем белән бер группада укыган сабакташым Петр Некрасов шаярта булып чыкты. Шушы теплоходта механик ярдәмчесе икән, шундук үз каютасына алып керде. Эше тыгыз вакыт иде, озак сөйләшеп утыра алмады. Исәнлек-саулыкны белешкәннән соң, миңа һичнинди тартынусыз урнашырга әйтте дә үз эше белән машина бүлегенә төшеп китте.

Бу Некрасов безнең группада укуда барыбыздан алда баручы булды, шуның өстенә ике ел эчендә үзлегеннән саф татарча сөйләшергә өйрәнде. Тик шунысы бераз сәер, кәефе начар кеше кебек, һәрвакыт караңгы чырайлы, аз сүзле, акрын кыймылдаучан иде. Хәзер аны тиз генә танырлык та түгел: шатлыгы эченә сыймаган кеше кебек, ачык йөзле, җиңел хәрәкәтчән һәм уенчак булып үзгәргән иде.

Кичәдән бирле аяк өсли йөрүдән һәм берсеннән-берсе күңелсез кичерешләр аркасында бик арыган идем. Җиңелчә тамак ялгап, чәйләп алгач, ятып бераз черем итәргә булдым. Шунда карават белән янәшә тумбочка өстендә Некрасовның бөдрә чәчле бик тә чибәр яшь хатын-кыз белән башын башка куеп төшкән фоторәсем күземә чалынды. Былтыр бугай, мин аны өйләнгән дип ишеткән идем, хатыны шушы ерык авыз булса кирәк. Рәсем астына кызыл кара белән «Гомергә бергә» дип язылган, икесе дә кул куйган, йөзләрендә сөю-сөелү шатлыгы балкый. Шунда мин бу бөдрә чәчбинең бая причалда миңа бармак янаган хатын икәнен танып алдым.

Их, без дә болардан ким түгел идек, күзгә-күз карашып кына яши идек ич. Әлеге дә баягы һаман шул минем ваемсызлыгым, адым саен бәйләнү, җәберләрдән яклый белмичә, Сәрвиназымны үзем биздердем.

Шулай да арыганлык үзенекен иткән, авыр уйларга чумып ята торгач, оеп киткәнемне сизми дә калганмын...

Күпме йоклаганмындыр, белмим, бермәлне саташулы төш күреп уяндым. Сабый бала чагым, бик зур залда тимер караватта утырам, имеш. Як-ягымда рәт-рәт тезелгән тимер караватларда да минем ише мескен нәниләр җан әрнеткеч ачы тавыш белән елый-елый кычкыралар:

– Әнием, мине монда калдырма...

– Өйгә кайтасым килә...

– Су бирегез, эчәсем килә...

Алар белән бергә мин дә шыңшыйм. «Әнием, мине тизрәк ал, монда каласым килми», – дип кычкырып елый башладым һәм уянып киттем.

Бактым исә, әйләнә-тирәмдә һичнинди бала-чага да, ак халатлы сестралар да юк. Каршымда каюта хуҗасы Некрасов өстәл янында чәй эчә-эчә газета караштырып утыра. Минем аңгы-миңге уянуым аңа сәер тоелса кирәк:

– Тынгысыз йокладың, шау-шулы төш күрдең бугай, берничә тапкыр кычкырып кемгәдер эндәштең, – диде, термостан чәй салып, өстәл янына чакырды.

– Әйе, бик сәер һәм чын тормыш белән һичнинди бәйләнеше булмаган төш күрдем, – дип, үзем дә гаҗәпкә калдым. – Хәтерлисеңдер, техникумда физиология укытучысы безгә: кеше төштә өнендә башыннан кичергән хәлләрне күрә, дип сөйләгән иде. Ә менә мин моны чынлыкка туры килми дип саныйм... Тукта, авыз ерма син... Чөнки минем беркайчан ятим сабыйлар йортында булганым юк, әмма бала чакта үземне шунда итеп еш төштә күрә идем. Менә хәзер дә шунда елап яткан җирдән уяндым.

Некрасов мине игътибар белән тыңлаган кебек булса да, ара-тирә күз кырые белән тумбочка өстендәге фоторәсемгә елмаюлы карап ала иде. Менә ул мин тынып торган бер арада:

– Ихтимал, шулайдыр, син әйткәнчәдер, – диде, көтмәгәндә күңелле кәмиткә юлыккан кеше кебек елмаеп. – Ярар, хәзергә катлаулы фән дөньясын калдырып торыйк. Дусларча дөресен генә әйт әле, сиңа ни булды? Ничектер үзгәргәнсең, күз карашың сагышлы... Күңелсез күренәсең, шуннан соравым.

Өйдәге ызгыш-талаш күңелле хәбәр түгел, аны теләсә кемгә әйтеп булмый бит.

– Бик алҗыган чагым, шунлыктандыр, – дип, икеле-микеле җавап бирдем һәм Некрасовның үз хәл-әхвәле белән кызыксындым.

Ул исә шуны гына көтеп торган кебек, үзенең эше, быел институтка керергә әзерләнүе, тиздән бәби көтүләре турында җанланып сөйләп китте һәм сүз арасында тагын берничә тапкыр хатыны рәсеменә кайгыртучан күзләре белән карап:

– Исән-сау котыла гына күрсен берүк, – диде.

Эчендә җаны булган мәнле кеше хатыны турында әнә ничек кайгырта, аның өчен ут йотып йөри. Ә мин, туң йөрәк, Сәрвиназымны һәртөрле җәберләү, кимсетүләрдән яклап, вакытында канат астыма ала белмәдем.

### *Әюпгәрәй агай ник дулкынлана?*

Сүземдә тордым, төнге вахтам башланырга өч сәгать кала мин гравий чыгару районына барып җиттем. Әюпгәрәй агай инде борчыла башлаган булса кирәк, мин каютага барып керүгә, җөйлеямаулы йөзе яктырып китте:

– Менә шәп булган, әйткән вакытка кичекмичә кайтып өлгергәнсең, – диде һәм, мине күздән кичергәннән соң, кинәт сагаеп калды: – Чү, ни булды сиңа?.. Төсең качкан, каты авырудан терелеп, яңа гына аякка баскан кешегә охшап калгансың...

Гөнаһ шомлыгы, юлда килгәндә механик Некрасов та әйткән иде. Менә тагын шул. Шифоньер ишегендәге көзгегә карагач, үзем дә аптырап калдым: бер тәүлек эчендә сизелерлек ябыкканмын, яңак сөякләрем калкып тора, борчылуларым йөземә чыккан иде. Ихтыярсыздан авыр көрсенеп куйдым.

Әмма бу болай аяк өсли берничә сүз белән генә әйтә торган хәл түгел. Әюпгәрәй агайның соравына, берни дә булмагандай, күтәренке кыяфәт белән:

– Зыян юк, Әюп агай, шактый арыдым, шуның галәмәтедер... Фәкать шул гына, ял иткәч, үтәр-китәр, – дип, күңелсез әңгәмәдән котылырга тырыштым.

Вахтага чыкканчы тамакка кабып юлдан соң аз гына булса да ял итеп алырга кирәк иде. Әюпгәрәй агай да әле ашамаган икән, ашханәгә бергә төштек. Азалия, мине күрү белән алтын тешен җемелдәтеп:

– Әле кызлар әйткәч кенә белдем, Таһир кайткан ич... – диде, төче телләнеп. – Әйбәт йөреп кайттыңмы?.. Минем әманәтемне тапшырдыңмы үзенә?

Бу артык төчеләнеп елмаю беркөн әнинең: «Әнә Азалиягә өйләнерсең, кай җире кемнән ким», – дип әйткән сүзләрен хәтерләтте.

Моны Әюпгәрәй агай да сизгән булып чыкты, ашап-эчеп каютага менгәч:

– Бу Азалиянең сиңа күзе төшкән, ахры, чамасыз чытлыклана, – диде шаяртып. – Карале, ул кайгыртучанлык күрсәтеп сораштырган хатын аның кеме, туган-тумачасы түгелдер ич?

– Юк, туган-тумачасы түгел, ә остазы, эшкә өйрәтүчесе. Минем әнием ул.

– Синең әнием шундый остаз кешемени?

– Әйе, Азалиянең остазы булган кеше... Аңа ник шаккаттыгыз әле?

– Шаккатудан түгел... Бер таныш хатынны хәтерләтте, шуннан гына әйтүем...

Әюпгәрәй агай күзләрен миңа төбәгән хәлдә хәрәкәтсез калды, кинәт дулкынланудан иреннәре генә дерелдәп куйды. Әмма ул моны сиздермәскә тырышты бугай, шундук үзен кулга алды, җиңелчә елмаю белән:

– Ә-ә, алай-й икән, ихтимал, бик ихтимал... – диде, үзалдына уйлангандай. Аннары сүзне икенчегә борып җибәрергә теләгәндәй: – Азалияне әйтәм, чытлыкланучан булса да, яхшылыкка игелек кайтара белә икән. Беркөн судан коткарган өчен миңа да очраган саен рәхмәт әйтә, ашханәгә керсәм, калҗаның тәмлесен үзе салып биреп, мине кеше алдында уңайсыз хәлгә куя.

– Әни Азалиянең уңганлыгын училищедан килгәч тә күргән, канаты астына алып шомарткан. Пенсиягә чыгар вакыт җиткәч, үз урынына аны ашханәдә мөдир итеп калдырган.

– Алай икән, тәрбияләп үстергән турылыклы дәвамчысы икән, – диде Әюп агай. – Ярар, алар калып торсын әле. Йә, үзең ничек йөреп кайттың? Өйдә нихәлләр, иминлекме?

– Юк, Әюпгәрәй агай, кызганычка каршы, хәлләр имин түгел, – дидем. – Мин монда вакытта хатыным, малайны җитәкләп, Аракчинога әтисе янына кайтып киткән.

– Ничек инде кайтып киткән, шулай ярыймыни?! Хатының кызу канлымыни? Әллә чынлап җитди сәбәбе бармы?

Монда бергә булган кыска гына вакыт эчендә безнең арада инде җылы мөнәсәбәт урнашкан; мин Әюп агайны рәсми начальнигым булудан бигрәк, кеше хәлен аңлый белүчән киң күңеллелеге өчен, якын туганым кебек үз итәм, аның белән аралашудан җан азыгы табам, мәгънәви баюымны сизәм. Шуңа күрә һични яшермичә, өйдә һәрдаим сизелеп торган киеренкелекне, әнинең Сәрвиназны күралмавын, адым саен төрлечә бәйләнеп җәберләвен – һәммәсен сөйләп бирдем.

Әюп агай игътибар белән тыңлады, мин туктагач, ямаулы битләре тартышып куйды, кашлары җыерылды. Беравык сүзсез утырганнан соң, күңеленнән кичергәндәй:

– Эшләрең шәптән түгел икән, – диде, сузып кына. – Әниең алай бик зәһәрле булгач, бераз тыярга, хатыныңны якларга кирәк булмады микән?.. Әллә араларына тыгылып, вакланырга теләмәдеңме?

– Әйе, шулайрак булды, игътибар җитмәде, хатынны яклый белмәдем.

– Ху-у-ш, әниең шулай булсын ди... Ә әтиең ничек? Әллә ул да синең кебек, салкын канлымы, бу хәлгә битараф караучанмы?

Әюпгәрәй агай бу соравы белән минем бик авырткан җиремә кагылды, ни әйтергә дә белмичә аптырап калдым. Чөнки мин әтисез үскәнмен, аның кем икәнен, исемен, фамилиясен дә белмим. Әни әйтүенә караганда, ул бик җәнҗалчы, вөҗдансыз кеше булган, миңа ике яшь чакта, безне ташлап китеп, кайдадыр еракта эзсез югалган. Берничә ел үткәннән соң, пожар вакытында янып һәлак булган бугай.

Бер башлагач, уңайсыз булса да, Әюпгәрәй агайга боларын да сөйләргә туры килде. Башта тыныч кына тыңласа да, ул тиздән гадәти сабырлыгын югалтып, түземсезлек белән: «Шулаймыни, йә, йә, шуннан, аннары ничек?» – дип ашыктыра-ашыктыра сөйләтте, үзенә урын тапмагандай, ишекле-түрле иләс-миләс йөренә башлады.

***Безне эзәрлекләделәрме?***

Баркас командасы яңа урынга бик тиз ияләште. Эшебездән канәгатьләр. Тормыш шартлары ярыйсы гына, эш хакына өстәп командировка акчасы да түләргә вәгъдә итәләр. Тамак ягы да зарланырлык түгел. Кыскасы, барысы да канәгать. Тик мин генә тынгысыз, миңгерәү балык кебек, кая барып бәрелергә белмичә каңгырап йөрим.

Башта бу буталчык низаг, минемчә, болай зурга китмәс, Сәрвиназ белән рәтләп сөйләшкәч, барсы да җайланыр кебек иде, шул өмет белән юанып йөргән идем. Чынлыкта киресенчә килеп чыкты, томанлы диңгездә калган ишкәксез көймәче кебек, гаҗизлеккә төштем. Ашым – аш, йокым – йокы түгел, эренле шеш сыман, җанны һаман бер хәсрәт тырнап тора.

Шуның өстенә бу арада эшнең дә рәте-чираты юк, кәнитил артыннан кәнитил туып тора, бигрәк тә төнге вахталар ыгы-зыгылы үтә. Узган төнне эштән бушрак арада, бераз һава алыйм дип, өскә күтәрелсәм, нindидер тар елга тармагында, әрәмәле яр буена бәйләп куелган кечерәк кенә агач баржа янында торабыз, имеш. Палубасында бозау хәтле зур эт ачулы ырылдап арлы-бирле йөренә. Алгы якта кемнәрдер берсен-берсе ашыктыра-ашыктыра баркаска нәрсәдер төйиләр. Караңгыда кемнәр икәнен, нәрсә төягәннәрен рәтләп күрергә өлгермәдем, баржа палубасыннан карлыккан тавышлы кемдер:

– Әй, «Зөя» баркасында... Бар, тизрәк ычкыныгыз... – дип, кабаланып кычкырды. – Әнә үрге яктан шикле ут якынайганы күренә, балык инспекторы яки милиция булмагае... Әгәр куып җитеп төпченә башласа, телеңне кыска тот: сез монда булмаган, мин сезне күрмәгән... Тагын менә нәрсә: Азалия чибәркәйнең исенә төшер әле: саранланмасын, котырган үгез сөтен күбрәк җибәрсен, бездән эш тормас диген...

Безнең баркас рубкасыннан штурман Артур сагаеп кына:

– Аңлашылды, әйтермен... Тизрәк чалканы ычкындыр, без шылыйк, – дип җавап кайтарды һәм шундук машинаны эшләтә башларга команда бирде.

Без кузгалу белән зур тизлектә китеп бардык. Чалулы юлдан барган чана кебек, баркас әле уңга, әле сулга ташлана, елга төбенә бәрелеп, бөтен корпусы белән сикереп-сикереп куя. Сигнал утларыбыз сүндерелгән. Бая баржа янында торганда утлары күренгән теге шикле судно гудок кычкырта-кычкырта һаман эзәрлекләп килә, менә-менә куып җитеп, койрыкка басар шикелле.

Шулай да ул куып җиткәнче, без кысан елга тармагыннан Кама киңлегенә чыгып өлгердек һәм төнге рейдта мәш килгән күпсанлы суднолар, гравий чыгару агрегатлары, йөзмә краннар арасында эз югалтып, эзәрлекләүчеләрдән җиңел котылдык.

Тиздән без хәвеф-хәтәрсез базага кайтып җиттек. Инде төн уртасы үткән булуга карамастан, ашханә мөдире Азалия безне көтеп торган, күрәсең. Баркас «Баһадир» янына барып туктауга ишетелер-ишетелмәс кенә:

– Кайттыгызмы, булдымы?.. – дип каршылады һәм, кладовой ишеген ачып, йөкне бушатырга урын күрсәтте.

Рулевой, сыек гәүдәле сузан егет Харитон, балык тулы капчык күтәреп чыкканда, аягы таеп егылды. Әгәр шунда мин тотып калмасам, капчыгы белән бергә үзе дә ике судно арасына барып төшәчәк иде. Бу балык бер капчык кына түгел, шактый күп булып чыкты, рубкага менә торган тимер трап астындагы кәрзиннәр дә балык белән тулы иде.

Азалия кесә фонаре яктысында мине күрүгә, бу нинди артык күз дигәндәй, кинәт аптырап калды. Штурман Артур аны шундук аңлады булса кирәк:

– Ой, бирергә онытканмын, менә балыкка квитанция, – дип, Азалиягә кәгазь кисәге сузды. – Балык ашарга барыбыз да яратабыз, әйдәгез, бушатырга помогать итәргә кирәк.

Дөресен әйтим, башта миңа монда нindидер кыек эш, урлашу бар кебек тоелган иде. Әмма ялгышканмын, юкка шикләнгәнмен. Ашханәгә дип законлы рәвештә алганнар бугай, әнә квитанцияләре дә бар бит. Өчәү бергә без балыкны кладовойга тиз ташып бетердек, бер уңайдан палубада калган пычракны да швабра белән сөртеп чыгардык. Бар эш тәмам булгач, штурман Артур безне алгы кубрикка дәшеп алды:

– Тырыш хезмәт өчен Азалия безгә менә нәрсә бирде, – дип, өстәлгә үгез рәсемле бер шешә аракы, ярты кирпеч икмәк һәм каклаган өч балык, өч пачка сигарет куйды.

Ул үзе инде авыз итеп өлгергән, тукмак борыны сизелерлек кызара төшкән. Моңарчы ничек күрмәгәнмендер, бу минутта ул бик тә Бәдретдин абыйга охшаган, нәкъ аның кебек итеп, тел очы белән әледән-әле аскы иренен ялап ала иде. Аракыны стаканнарга бүлеп салды да: «Тотыгыз, әйдә, чәкешми генә күтәрик», – дип чөмереп куйды, тешләре белән балыгын ботарлый башлады. Аның ярдәмендә эчүгә остарып өлгергән Харитон да стаканын бер тында чөйкәлтеп җибәрде. Эчмичә балык капкалап утыруыма башта кырын карасалар да, азактан, урталай бүлеп, алар минем өлешне дә бушаттылар.

Шуның белән дөньялары түгәрәкләнде, телләре чишелде. Азалиянең эш йөртә белүен, чибәрлеген мактый-мактый сигарет көйрәтергә тотындылар.

Ә мин һаман үзебезнең караклар кебек кемнәндер куркып качуыбызның сәбәбен һич төшенә алмыйм. Юкса төягән балыкка документ та бар шикелле бит. Аптырагач, әллә һичнинди куучы булмады, миңа шулай тоелды гынамы дип уйлап та куям.

***Тау белән тау очрашмаса да...***

Гадәттә, мин төнге вахтадан бушаган көннәрне сәгать унбердә уянып, төшке ашка хәтле физзарядка ясарга, коенып, кырынып алырга өлгерә идем. Бүген күбрәк йоклаганмын, инде ашханәгә төшәргә вакыт җитеп килә иде.

– Ах, син йокы капчыгы, шултикле урын өстендә аунап ятарга ярыймыни... – дип, үземне җиңелчә тиргәп алдым.

– Таһир туган, кемне битәрлисең син анда? – дип, аста Әюпгәрәй агайның сөйләнгәне ишетелде.

– Юк, беркемне дә түгел, үземне генә... – дидем һәм, өлкән кешене көттермәс өчен, тиз генә юынып өстемә киенә башладым.

Әюп агай өстәл янында ниндидер пичәтле кәгазьләр карап утыра иде. Мин торуга ул аларны тиз генә җыеп, курткасының куен кесәсенә салды. Нидер эзләгәндәй, эш киемнәре шкафын ачып иснәнә-иснәнә:

– Фу, менә моннан икән... Борынга балык исе бәреп керә, синең эш костюмыңнан бугай, – диде.

– Әйе, шуннандыр... Төнлә ашханәгә алып кайткан балыкны бушатуда булышкан идем, мөгаен, шуның иседер, – дидем. – Монда каютаны сасытып тормасын, тышка чыгарып, җилләтергә кирәк булыр...

– Туктале, нинди балык ул, кайдан алдыгыз? – дип, Әюпгәрәй агай күзләрен миңа текәде.

– Бигрәк инде сез... Машина бүлегеннән торып, аның кайдан, кемнән икәнен мин ничек белим? Ул хакта штурман белә торгандыр, бик кирәксенсәгез, аннан белешергә мөмкин.

– Юк, әллә ни кызыксынудан түгел... Беркөн син юкта гражданский киемнән бер милиционер килгән иде. Моннан ерак түгел, аргы яктагы иске елга утравындагы балыкчылар базасына ниндидер кечерәк кенә судно иярләшкән, ди. Кемнәрдер аракы, самогонга алмаштырып, капчык-капчык балык, тозлы икра төяп китәләр икән. Милиционер шуны эзләп килгән, берәр шикле судно күрмәдегезме, дип сораштырды.

– Ул җәһәттән шикләнмәскә мөмкин. Хәер, башта миңа да бераз шикле тоелган иде. Әмма ялгышканмын, законлы рәвештә яздырып алынган булып чыкты, квитанциясен үз күзем белән күрдем.

– Алайса, бүтән сүзем юк, – диде Әюп агай. – Безнең команданы оятлы итәрлек булмасын дип әйтүем генә.

Балык караклары турында сүз белән мавыгып, көндезге ашка соңга кала язганбыз ич. Без ашханәгә барып кергәндә, инде бар халык ашап-эчеп эшкә таралган, ян тәрәзә катындагы өстәлдә безнең штурман Артур белән рулевой Харитон гына чәйләп утыралар. Бераз кәефләнеп өлгергәннәр бугай, битләре кызарган, өстәл астында буш шешә ялтырап тора. Безне күрүгә, сәлам бирделәр дә, авызларын сөртә-сөртә, тизрәк чыгып юк булдылар.

Тик шунысы сәер, зур бәйрәмгә әзерләнгән кебек, бүген бөтен ашханә ялт иткән. Өстәлләргә зәңгәр чәчәкле яңа клеенка җәелгән, стакан белән кәгазь салфетка, матур-матур фарфор савытларда тоз, борыч, горчица куелган, юынгыч янына бизәкле тастымал элегән. Залдан прилавка белән генә аерылган кухняда ашчы хатын-кыз тыз-быз килә. Кыска ак халат кигән Азалия касса янында көндезге керемне саный булса кирәк, чут төймәләрен чалт-чолт салып утыра. Әйтәсе дә түгел, бик тә тырыш, бик тә уңган: ашханәдә мөдир генә түгел, кладовойчы да, кассир да – барсына өлгерә, барсы да аның кулында.

Безне күрүгә, аның җитди чырае яктырып китте. Акчаларын тиз генә касса ящигына салып бикләде дә:

– Хуш киләсез, менә монда рәхим итегез, – дип, түр почмактагы өстәлгә күрсәтте, аннары кухня ягына борылып. – Әй, Гөлбикә җаным, Әюп агай белән Таһирга ашарга китер... Аны кара, мәрсин ухасына яшел суган салырга онытма, – диде.

Быел гына кулинария училищесын тәмамлап килүгә карамастан, һәр эштә Азалиянең уң кулы булып өлгергән сөйкемле кыз Гөлбикә мәрсин ухасын да, икенчегә итле бәрәңгене дә мул итеп китерде. Әюп агай бигрәк тә яратып, мактый-мактый тәмләп ашады, азактан чынаяк чокырларына салып мәтрүшкәле чәй китергән Гөлбикәгә, җиңелчә шаярту белән:

– Күптән болай сыйланган юк иде, тәмле аш-су өчен рәхмәт сиңа, тормышта барча теләкләрең кабул килсен... – диде.

Менә ул чәйле чокырын авызына китергән хәлдә, кухня ягына карап, кинәт хәрәкәтсез калды, яртылай көйгән кашлары җыерылды, нервылануы йөзенә чыкты... Әмма ул үзен кулга алырга тырышты шикелле, телдән аны-моны белгертмәде. Чокырын өстәлгә куеп, сәгатенә карагандай итте дә:

– Ах, мин порт белән сөйләшергә заказ биргән идем, телефонга ашыгам, – диде һәм, аш-су өчен тиз генә түләп, элемтә бүлегенә менеп китте.

Өстәл янында үзем генә калгач, мин ирексездән кухня ягына каерылып карадым, һәм анда пешекче хатын-кыз арасында әниемнең никахсыз ире Бәдретдин абыйны күреп шаккаттым. Авырулар өлешенә кул сузган өчен шушы арада гына больница ашханәсеннән куылган шеф-повар монда килеп оялаган, имеш.

***Загс язуыниләр сөйли?***

Берничә минуттан соң мин каютага менгәндә, Әюпгәрәй агай әле һаман тынычланмаган, авыз эченнән нидер сөйләнә-сөйләнә ишекле-түрле йөри, ризасызлык белән әледән-әле тамак кырып куя иде. Гадәттә, һәрвакыт сабыр холыклы капитанның бу халәте миңа сәер тоелды:

– Әюпгәрәй агай, ни булды, нәрсәгәдер кинәт кәефегез кырылды шикелле? – дип сорадым.

– Әле генә кухняда поварлар арасында беләсеңме кемне күрдем мин... – диде ул, һәмишә басыла алмыйча. – Хәтерлисеңдер, беркөн мин сиңа Чистай порты ашханәсендә мөдир булып эшләүче бер азгын хатынның бергә эшләүче повар белән зина кылып яманаты чыгуы, аннары ире читтә эзсез югалгач, йорт-җирен сатып, ике яшьлек улын ятим сабыйлар йортына калдырып, сөяркәсе белән каядыр күчеп китүе турында сөйләгән идем бит. Менә хәзер кухняда шул хатынның сөйрәлчеген күреп шаккаттым.

– Ялгышасыз, Әюп агай, башка берәү белән бутыйсыз бугай. Сез әйткән кешене мин дә күрдем, кечкенәдән беләм мин аны. Бәдретдин исемле, безгә еш килеп йөри. Әни әйтүенә караганда, кем ягыннандыр туганы кебек иде. Әмма үсә төшкәч белдем, туган-тумача түгел, тик болай гына, күптән белгән-күргән дус кешесе сыман...

Күрәм, Әюп агай тагы да катырак дулкынлана башлады, уңайсызлану белән:

– Туктале, Таһир туган, әниең кем синең, исеме ничек? – дип сорады.

– Миләүшә исемле.

– Миләүшәме?.. Әтисенең исеме, ягъни отчествосы ничек? Маликовна түгелме?

– Әйе, Маликовна... Сез аны каян беләсез? – дип, хәзер инде мин гаҗәпкә калдым.

– Әһә, алай икән, Миләүшә Маликовна икән-н... Алайса аңлашыла, барысы да мин уйлаганча килеп чыга...

– Нәрсә аңлашыла? – дидем түземсезләнеп. – Ачыграк әйтегез, сез уйлаганча нәрсә килеп чыга?.. Миңа берни дә аңлашылмый...

– Тукта, сабырсызланма... Алай бер-ике сүз белән генә әйтә торган түгел бу... Керәшен әйтмешли, әкрен кирәк, иплә кирәк сөйләшергә... Шунсыз мөмкин түгел. – Сабыр булырга әйтсә дә, Әюп агай үзе дә дулкынлана, әмма сиздертмәскә, тыныч күренергә тырыша. Сүзен ничек башларга белмәгән сыман, беравык уйланып торды да, минем иңемә кулын салып, ашыкмый гына сөйләп китте: – «Зөя» баркасына капитан булып килеп, беренче тапкыр күргәч тә, син минем игътибарны җәлеп иттең, күңелемдә дулкынландыргыч сизенү уяттың. Үзеңә белгертмәсәм дә, шуннан бирле игътибар белән күзәтеп, һәр сүзеңә колак салып киләм. Әмма ул хакта турыдан-туры сөйләшеп аңлашырга кыенсынып йөрдем. Күрәм, сизенүем нигезсез булмаган, хәзер мин моны ышанып әйтә алам. Менә бу кәгазь аны тагын бер кабат исбатлый. – Әюп агай курткасының куен кесәсеннән алып, кечерәк кенә форматтагы яшькелт кәгазь күрсәтте: – Мә, игътибар белән кара, бәлкем, сиңа да кайбер нәрсәләрне ачыкларга ярдәм итәр.

Аның бу сүзләре миңа бик сәер тоелды:

– Нинди тылсымлы кәгазь ул, кайдан таптыгыз, кем бирде аны? – дип мәзәксенеп сорадым.

– Анысы болай булды аның. Узган атнада Чистайга тешемне дәвалатырга барган идем. Шунда врачка чират торганда, кайчандыр бергә укып үскән, суднолар ремонтлау заводында бергә эшләгән кордашым Каюмовны очраттым. Бик ябыккан, кечерәеп калган. Мине үзем әйткәч кенә таныды, шунда да күзләренә ышанмагандай, битләремдәге җөйләргә озак кына шаккатып карап торганнан соң: «Гафу ит, тиз генә төсмерләрлек түгелсең... Синең үлгән хәбәрең килгән иде бит, сөбханалла, исән-сау икәнсең...» – дип, бик гаҗәпләнде.

Поликлиникадан чыккач та җибәрмәде, өенә алып кайтты. Өй каршындагы бакчасында берничә баш умартасы бар икән. Карчыгы чәй әзерләгән арада, берәр чынаяк әчегән бал белән сыйлады. Карчыгы сүзгә саран күренсә дә, мин күршеләрендәге теге ашханәче хатынның баласы турында сораштыра башлагач, өстәл янына килеп утырып, теле чишелде:

– Хәтерлим, исемен дә хәтерлим, Җантаһир атлы иде, – дип сөйләп китте. – Ятим сабыйлар йортында яңа гына эшли башлаган көннәрем иде. Әнкәсе калдырып киткәннән соң, өйгә кайтасым килә, дип кычкырып елый-елый тәмам шешенеп, тамагы карлыкты. Мескенне юата-юата йөдәп

беттем... Әнкәсе аны ике ел чамасы вакыт үткәч алып китте. Бу вакытта ул хатын, йорт-җирен сатып, инде каядыр күченеп киткән, бүтән җирдә тора иде. Шуңа күрә ул баланың шуннан соңгы язмышын белмим, бүтән берни дә әйтә алмыйм...

Каюмовның гаиләсе зур түгел, загста мөдир булып эшләүче сазау кызлары белән өчәү бергә торалар. Өйлә вакыты җитәрәк, төшке ашка шул кыз кайтып керде. Сазау кызлар, гадәттә, ачулы, усал була торган иде. Ә бу, киресенчә, ачык йөзле, йомшак күңелле икән. Әнисе сабый малайның ятимнәр йортында интегүләрен телгә алып тагын сөйләгәч, бик тә кызганып, авыр сулап куйды. Алар тынып торган бер арада мин загс мөдиреннән:

– Сез ничек уйлыйсыз, ул баланың фамилиясен, әтисе-әнисе кемнәр икәнен ачыклап булмас микән? – дип сорадым.

– Эзләп карарга кирәк, – диде загс мөдире. – Исеме, чама белән туган елы да билгеле булса, безнең архивта табылырга тиеш.

Һәм нәкъ шулай, ул әйткәнчә килеп тә чыкты: иске кенәгәләрдән бергәләп эзләп тапканнан соң, малайга... туу турында таныклык дубликаты язып бирде. Шунда бер уңайдан хатынымның миннән аерылуы хакында таныклык та алдым. Мә башта менә шунысын күр.

Әюпгәрәй агай биргән таныклыкка карау белән ике күзем дүрт булды, әллә ялгыш күрәмме дип, кабат укып чыктым. Чөнки бу минем әни белән Әюп агайның никахы бозылганлыгын, ягъни аерылышуларын раслый торган рәсми документ иде.

Мин моны башыма сыйдырырга, рәтләп аңларга өлгермәдем, Әюпгәрәй агай миңа икенче кәгазьне тоттырды. Монысы Җантаһир дигән малайның туу турында таныклык дубликаты: әтисе кем дигән графада – безнең баркас капитаны Кирамев Әюпгәрәй язылган, анасы кем дигән графада исә – минем әни исеме, фамилиясе.

Дөресен әйтим, акылга сыймастай бу көтелмәгән хәлдән күз алларым томанланды, төштәге кебек зиһенем чуалды. Шуңа күрәдер аны-моны уйламастан, механик рәвештә:

– Кара син аны, бу Җантаһир минем белән бер елда, хәтта бер числода туган икән... – дип әйтеп куйдым һәм, ниһаять, үзем турында сүз барганын, Әюп агайның минем... әтием икәнен абайлап, кинәт исем-акылым китте. Моны башыма сыйдыра алмыйча телсез калдым...

Минем дулкынлануым йөземә чыкты бугай, Әюп агай беравык сынаулы карап торды да:

– Ник уйга баттың әле син? Барып җитмимени?.. – диде.

Ул тагын нидер әйтмәкче булып авызын ачкан иде, шулчак өстәл кырыендагы репродуктордан кемнеңдер бераз карлыккан тавыш белән:

– «Зөя» баркасы капитанын ашыгыч рәвештә район начальнигы кабинетына чакыралар... Тиз булыгыз, сезне көтәләр... – дигән команда сүзләре яңгырап үтте.

Әюп агай, дөресрәге, хәзер инде әтием, мине иңемнән кочаклап:

– Фу, тапканнар вакытын... – диде, канәгатьсезлек белән. – Ашыктырып чакыргач, бармый ярамас. Мин чыккач, иркенләп сөйләшербез.

***Ур-ра, мин әтиемне таптым...***

Әти район начальнигы янына кереп киткәннән соң, кинәт зиһене чуалган кешедәй, каютада миңгерәп калдым. Эчемә сыймаган зур шатлыктан: «Әй, кешеләр, барыгыз да ишетегез, белегез: мин әтиле булдым, кара язмыш югалткан әтиемне таптым...» – дип, горурланып кычкырудан көчкә тыелып утырам, аның һәр җәһәттән әйбәт кеше булуына куанам.

Бераз тынычлана төшкәч, ул калдырган герблы, түгәрәк печатьле таныклыкны алып кабат карый башладым һәм бик аптырап калдым. Чөнки мин, кечкенәдән әни фамилиясендә йөрим, паспортымда да шулай язылганмын. Таныклыкта Җантаһир дигән исемем паспортта кыскартып Таһирга әйләнгән, әтисе кем дигән графада Әюпгәрәй түгел, ә Гәрәй дип кенә кыскартып язылган. Әнә шулай мин бөтенләй бүтән кешегә әверелгәнмен.

Тик шунысы сәер, игътибарсызлык аркасында килеп чыккан очраклы хәлме, әллә берәр максат белән эшләнгән махинациями бу? Һәрхәлдә, монда нидер бар, мондый әверелү үзеннән-үзе генә булырга тиеш түгел. Хәзер әти керү белән ачыкларга кирәк.

Әмма ул һаман юк әле. Начальник янында мөһим мәсьәлә тикшерәләр, ахры, сөйләшүләре озакка сузылды. Ә бераздан минем үземне дә шунда чакырттылар.

***Тиз генә эзенә төшәрлек түгел***

Гравий чыгару районы начальнигының эш кабинеты пароходның койрык ягында ике каютаны бер итеп зурайтылган, түшәм һәм стеналары тавышйоткыч зәңгәрсу тукыма белән каплаулы иркен

бүлмәдә урнашкан. Кабинет хуҗасы – әзмәвер кебек зур гәүдәле, яртылай такыр башлы урта яшьләрдәге Петраков, мин барып кергәндә, кем беләндер радиотелефоннан сөйләшә. Кыска җиңле ачык изүле сары күлмәк кигән, бакыр төсле җирән чәче маңгаен каплаган чандыр кеше, өстәл өстендәге картага карый-карый, әтигә нәрсәдер аңлатып утыра иде. Әти миңа үз янындагы буш урындыкка утырырга ымлады да, бакыр чәчле кешегә күрсәтеп:

– Бу иптәш – милиция хезмәткәре, безгә зар белән килгән, – диде.

– Юк, зар белән түгел, дөресрәге, бер четерекле эштә ярдәм итә алмассызмы дип килдем. – Милиционер, бармагы белән өстәлдәге картага төртеп күрсәтә-күрсәтә, сүзен дәвам итте: – Менә бу утраудагы балык базасына төннәрен ниндидер судно ияләнүе, аракыга, самогонга алмаштырып, кемнәрнеңдер күпләп балык чәлдерүе турында сигнал бар... Дуслар, сез һаман бу тирәдә рейдта эшлисез бит, чит-ят катер, баркас йөргәне күзегезгә чалынмадымы дип килүем.

Әмма бу минутта миндә әллә кайдагы караклар кайгысы түгел, күңелем әтиемне табу шатлыгы белән тулы, күз карашым аңа төбәлгән иде. Шунлыктан күп уйлап тормастан:

– Юк, андый судно күзгә чалынмады, күрмәгәнне әйтә алмыйм, – дидем. – Мин һәрвакыт диярлек аста, машина бүлегендә бит, өстә ниләр барын, кайда йөрүебезне, нинди теплоходлар очраганын күрмим. Аларын рубкада торучы штурман белә торгандыр, шулар белән сөйләшеп карагыз.

Минем җавабым Петраковка ошады бугай, караңгы чырае ачыла төште, зырылдап әйләнгән вентилятор каршында җилләп утырган җиреннән:

– Дөрес әйтә, хак сүз, – диде, калын иреннәрен җәеп. – Узган-барган һәр катерны күзәтү, хәтергә алу безнең командалар вазифасына керми. Шулай булгач, гомумән, монда ул хакта сүз куертып тору урынсыз, механикка чыгып китәргә мөмкин.

Мин урынымнан кузгала башлауга, әти, иңемә кулын салып:

– Туктале, ашыкма, – диде. – Син кичә төнлә кайдандыр балык алып кайтуыгыз турында әйткән идең. Нинди балык ул, кайдан алдыгыз?

– Кайдан алганнарын анык белмим, әйтәм ич, алар төйи башлаганда, мин машина бүлегендә идем, күрмәдем, – дидем. – Әмма бу очракта һичнинди алдашу юклыгын, балыкның законлы рәвештә яздырып алынганын ышанып әйтә алам, штурманның квитанцияне ашханә мөдиренә тапшырганын үз күзем белән күрдем.

– Ихтимал, әлбәттә, ихтимал... – диде милиционер, үзалдына сөйләнгәндәй. – Шулай да ныклабрак уйлагыз, исегезгә төшерергә тырышыгыз әле: ул балыкны ниндирәк җирдән алдылар: складтанмы, катерданмы, ул тирәдә берәр каралты, баржа кебек нәрсә күзгә чалынмадымы?

– Әһә, искә төшердегез, хәтерләдем... Ул вакытта без әрәмәле яр буена бәйләп куелган кечерәк кенә баржа янында тора идек, балыкны шуның трюмыннан алдылар шикелле. Төн караңгы булса да, иллюминатордан төшкән ут яктысында ачык күрдем: арткы палубасында тумбага бау белән бәйләп куелган бозау хәтле зур сары эт тә бар иде.

Боларга өстәп мин тагын аннан кинәт кузгалып, зур тизлектә кайтуыбызны да сөйли башлаган идем. Начальник ризасызлык белән:

– Җитәр, бу тел тегермәнен шунда туктатыйк, – диде, мине бүлеп. – Ашыгыч эш күп, менә-менә зур начальник – пароходчылык идарәсеннән тәэминат башлыгы килеп җитәргә тиеш, шуны каршыларга әзерләнергә кирәк.

Начальник кабинетыннан чыккач, милиционер безнең каютага да кереп байтак төпченде, минем балык исе сеңгән спецовкамны да игътибар белән карады. Бераз тынып торганнан соң:

– Сезнең ашханәдә гел яңа тоткан балык ашаталар бит, – диде. – Моңарчы ул балыкны кайдан алулары мәгълүм түгел иде, хәзер менә бераз ачыклана шикелле. Ашханә мөдире үзе кладовойчы да, кассир да булгач, хәрәм балыкны беркайда теркәмичә, аны сатудан кергән акчаны йотып калырга бөтен мөмкинлеге бар.

Милиционерның бу шикләнүе миңа нигезсез тоелды, аның белән килешергә теләмичә:

– Бу очракта сез ялгышасыз бугай, – дидем. – Монда һичнинди астыртын хәйлә-мазар юк; ашханә мөдире беркемнән яшермичә, балыкның һәм башка төр ашамлыкларның үлчәвен, бәясен ачыктан-ачык менюга язып стенага элә, моны һәркем күрә, кирәк чакта тикшереп ачыклап була бит.

– Бөтен хикмәте дә шунда, тикшереп тә хакыйкатьне ачыкларга мөмкинлек булмауда. Мондый очракта көндәлек чыгымнарны исәпләү кенәгәсендә менюда язылган хәрәм балыкны күрсәтмәскә, аннан килгән керемне тулысынча үзләштерергә мөмкинлек туа. Чөнки аның кладовойга керүе дә, ничек сатылуы һичкайда күрсәтелмәгән, гүя ул бөтенләй булмаган яки өлешчә генә сатылган. Шунлыктан тиз генә эзенә төшәрлек түгел.

***Уртак рухлылар***

Ниһаять, без каютада аталы-уллы икебез генә калдык һәм, бик гаҗәпләнгән хәлдә, бермәл сүзсез генә күзгә-күз карап тордык. Башлап әти телгә килде, дулкынланудан калтыранган тавыш белән:

– Җантаһир, улым минем, кая яхшылап күрим әле үзеңне... – дип, иңнәремә кулларын салды, маңгаемнан үбеп алды. – Ничәмә-ничә еллардан соң, ниһаять, табыштык бит. Шунысы гаҗәп, мин сине һаман сабый бала итеп күңелдә йөртә идем, төшләремдә күрә идем. Ә син әнә нинди баһадир булгансың, бер-беребезне белмичә, ничаклы вакыт бергә эшләгәнбез...

– Әткәй, мин дә сине бик юксына идем, урамда әтисе кулына тотынып барган шат бала күргән саен, үземне дөньяда иң бәхетсез ятим итеп тоя идем. Бу табышуга мин әйтеп бетергесез шатмын. Күпме вакыт бергә эшләп, шушы көнгә кадәр бер-беребезне танымавыбыз гына гаҗәпләндерә... Шулай да мин сине өлкән туганым кебек якын итә идем, димәк, безнең арада рухи уртаклык, кан тарту дигән нәрсә сизелерлек булган.

– Мин бу уртаклыкны беренче очрашулардан ук сизендем һәм игътибар белән күзәтә башладым, вакытыннан элек әйтмәдем генә. Чөнки бу имеш-мимешкә, сизенүгә таянып кына кузгата торган сүз түгел. Менә хәзер загс таныклыгы белән дә раслангач, һич тә икеләнмичә, аяк терәп сөйләшергә мөмкин.

– Әлбәттә, шулай, монда аз гына да икеләнергә сәбәп юк. Тик шунысы бик сәер: загста әтием фамилиясендә теркәлеп тә, мин кечкенәдән әнием фамилиясендә йөргәнмен, паспортымда да шулай язылган. Үз исемем, әтием исеме дә яртылай кыскартылган. Андый алмаштыру, кыскартулар кем тарафыннан, нинди максат белән эшләнүе аңлашылмый. Әллә болар бар да берәр игътибарсызлык нәтиҗәсендә, очраклы рәвештә генә килеп чыккан микән?

– Юк, юк, һич тә очраклы түгел, бу ныклы уйлап, синең белән мине табыша алмаслык итеп адаштыру максаты белән эшләнгән. Ул вакытта Миләүшәнең әтисе милиция бүлеге начальнигы иде, бу махинация, һичшиксез, аның эше. Шуннан элегрәк кызымны кыйнады, дип, минем гаебемне күпертеп, ялган акт төзүдә, мине иректән мәхрүм итүдә, соңыннан минем йорт-җиремне кызы исеменә күчереп яздыруда – барысында аның кулы уйнаган. Күрше-колан моны сизеп, ишетеп торган; өлкән яшьтәге агайлар, түтиләр әле дә булса онытмаганнар, аталы-кызлы икесен дә комсыз-карун, дип яманлап сөйлиләр.

– Дөрес әйтәләр, әни комсызлануын хәзер дә дәвам итә, андый сыйфатым булмаган өчен мине еш шелтәли, Сәрвиназны өзлексез җәберли. Мин монда вакытта әтисе янына кайтып китәргә мәҗбүр иткән.

– Ә син күрә торып шуңа юл куясыңмыни, хатыныңны нахакка кыерсытудан якламыйсыңмыни?

– Әйе, шулайрак килеп чыкты, вакытында әнине тыя белмәдем... Сәрвиназ миңа бик үпкәләде. Телдән әйтмәсә дә, беркөн очрашканда салкын сөйләште, ул йортка кире кайтачак түгелмен, диде.

– Йә, ярар, ул хакта калып торсын әле. Адәм рәтле хатын булса, гаиләсен алай кинәт кенә җимереп ташламас. Ничек тә аңлашырсыз, килешерсез дип өметләник. Зур шатлыклы көнне күңелсез уйларга бирешмик әле... Шулай да молодец син, шундый бозык мохиттә сазлыкка батмагансың, намуслы егет булып үскәнсең, – барыннан бигрәк мин шуңа шатмын.

Төш вакытында ашханәдә күзгә чалынган чистарыну, аш-суның гадәттәгедән мулрак һәм тәмлерәк булуы, гомумән, бәйрәмчә күңелле җанлылык юкка түгел икән: менә-менә зур дәрәҗәле түрә – пароходчылыкның тәэминат начальнигы килергә тиеш, һәммәсе дә шуны олылап каршыларга әзерләнә. Барыннан бигрәк пешекчеләр тырыша. Ашханә залын, кухняны ялт иттерүдән тыш, дәрәҗәле кунакка дигән иң шәп каютаның урын-җирен, тәрәзә пәрдәләрен тиз генә алмаштырдылар, хәтта клубтагы телевизорны, район начальнигы өстәлендәге вентиляторны да шунда кертеп куйдылар. Ашханә мөдире Азалия боларның барысын да үзе карап эшләтте.

Олы түрәнең килгәнен ерактан күреп хәбәр итү өчен махсус күзәтүче куелган иде. Кояш инешкә авышкач күп үтмәде, өске каттан каты тавыш белән «Киләләр-р... Әнә наратлы борылыш артыннан «Тәэминатчы» килеп чыкты...» дип, бар көченә кычкырып хәбәр итте. Аннары радиоузелдан пароходтагы бер кешегә, сул як бортка чыгып, начальствоны каршыларга команда булды.

Әти белән мин шунда күләгәдә күңелле гәпләшеп утыра идек. Тантаналы очрашуга иң башлап Азалия командасы, ак халат, ак калпак кигән, кайберләре чәчәк бәйләме тоткан пешекчеләр килеп чыкты; алар артыннан күптөрле канцеляриячеләр, эштән буш механизаторлар, матрослар җыела башлады. Кайберләрен вахтадан соң ял иткән җирдән уятып чыгарганнар, күрәсең, арадан ризасызлык белән: «Ут чыкканмыни, ни шайтаныма вакытлы-вакытсыз борчыйлар», – дигән сүзләр ишетелде.

Озакламыйча «Тәэминатчы» теплоходы рейдка килеп керде һәм, йөрешен акрынайтып, салмак кына сулга борыла башлады. Йөзмә магазиннан үзгәртеп яраштырылган кечерәк кенә судно булса да, карар күзгә ул ярыйсы гына: тоташтан акка буялган, иллюминаторларында кояш нурлары җемелди, арткы мачтасы очында флаг салмак кына чайкала.

Пароходчылыкның баш тәэминатчысы – шактый өлкән яшьләрдәге калын гәүдәле агай – рубка каршындагы чыбыктан үрелгән диванда түрәләрчә җәелеп утыра. Ак тужуркасының җиңнәрендә сары укалы нашивкалары, күкрәгендә бер-ике орден, медаль җемелди; озынча баш очында зонтик сыман киң читле, сары эмблемалы зур фуражка. Озата йөрүчесе булса кирәк, аннан сулда басканы – челән кебек чандыр, чәй тәлинкәсе хәтле зур күзлекле яшьрәк елгачы, әйләнә-тирәгә бинокльдән карый-карый кылә һәм, әледән-әле борылып, начальнигына нәрсә турындадыр хәбәр итә.

Дәрәҗәле кунак каршылаучылар белән ягымлы елмаеп исәнләште, район начальнигы Петраков һәм Азалия белән кул биреп күреште. Шунда ул, тәрәзә каршында эскәмиядә утырган этине күреп, кинәт хәрәкәтсез калды, үз күзләренә ышанмагандай, аксыл кашларын җыерып карап торды да:

– Ба-а, кемне күрәм мин?! Иптәш капитан-лейтенант, сезне күрәмме?.. – дип, гаҗәпләнеп кулларын җәеп җибәрде. Аннары моның белән үзен ничек тотарга дигән сыман, күз кырые белән генә район начальнигына каушаулы карап алды. Петраков этинең баркас капитаны икәнен әйтү белән, ул шундук каушавыннан арынды, түрәләрчә кыю тонга күчте. – Менә бу чынлап та көтелмәгән очрашу... Әйдәгез, кул биреп күрешик әле, исәнмесез...

Мәгәр эти танымады:

– Гафу итегез, сез ялгышасыз, мине башка берәү белән бутыйсыз, – диде.

– Юк, һич ялгышмыйм, сезнең физиономиягезне башка беркем белән дә бутарлык түгел. Онытгыгызмыни, Тын океан флотында бергә хезмәт иттек бит. Сез командалык иткән корабта мин интендант идем.

– Әһә, менә хәзер искә төште, хәтерем ялгышмаса, сез Хазанов Сәмин Фидаярович бит?

– Нәкъ шулай, Хазанов, исемем, отчеством гына бераз башкачарак. Әйтергә уңайлырак булсын өчен мине хәзер Семен Федорович дип йөртәләр, сезгә дә шулай гына дәшәргә киңәш итәм.

– Әйбәт эшлисез, заманасы шундый, – диде эти ирония белән. – Хәер, сез киң натуралы интернационалист бит, хәрби хезмәттә чакта ук үзегезне шулай йөртә идегез. Ул чакны сез какча гына гәүдәле яшь офицер идегез, хәзер әнә нинди зур дәрәҗәле җитәкче булып күтәрелгәнсез, төскәбиткә дә солидныйлангансыз.

Бу сүзләр киная белән әйтелгән булса да, адым саен ялагайлану күреп күнеккән Хазанов моны сизмәде, туры мәгънәсендә мактау итеп аңлады, үзенә бер горурлык белән:

– Дөресен әйтәсез, безнең идарәдә булдыклы кешеләрнең кадерен беләләр, – диде.

***Безнең заман каһарманы***

Ашханә мөдире Азалиянең люкс каютасын зур тырышлык белән матурлап җиһазландыртуы юкка булып чыкты. Баш тәэминатчы туктаган портларда, затоннарда казна кунакханәләренә күченеп мәшәкатьләнүгә караганда, бөтен уңайлыклары булган үзенең персональ теплоходын кулайрак күрә, туктаган урыннарда киңәшмәләрне шуның салонында үткәрә, кешеләрне дә шунда кабул итә икән.

Шуңа күрә ул зур тырышлык белән әзерләнгән комфортлы каютага кереп тормады. Очрашып хәл-әхвәл белешкәч тә, азык һәм промышленность товарлары кибетләренә кереп чыкты, иңенә ак халат салып, пекарняны, ашханәне, камбуз җиһазларын күздән кичерде, пешергән ашларын татып карады. Кешеләр тарафыннан әйтелгән зарлануларны, үтенечләрне озата йөрүчесенә яза барырга кушты.

Пешекчеләрдән кемдер, ашханә кладовоенда яшерен рәвештә кудырылган самогон биреп, браконьерлардан балык алу, шуны халыкка ашатудан кергән акчаны мөдир үзләштерүе турында идарәгә ике тапкыр жалоба язган булган. Идарәдә аны да игътибарсыз калдырмаганнар:

– Аноним сигнал булса да, монда килер алдыннан мин аны махсус тикшерттем, әмма андый факт расланмады, – диде һәм киләчәктә алай яла ягу белән шөгыльләнмәскә кисәтте.

Семен Федоровичның базадагы инспекциясе шуның белән тәмам булды һәм ул эшләрнең торышы белән канәгать калды. Аннары район начальнигы Петраков белән бергә үз судносына утырып, гравий чыгаручы земснарядларда инспекция үткәрергә китеп барды. Азалия аларны озак йөрмәскә, бик соңгармыйча, мөмкин кадәр иртәрәк әйләнеп кайтырга искәртеп, озатып калды.

Район халкы бу шау-шулы каршылауга мәҗбүри бер чара итеп карады, искитмәле һични булмагандай, шундук таралышып, һәркем үзенең көндәлек шөгыленә кереште. Хәер, мин үзем дә мо-

ңа әллә ни әһәмият бирмәгән идем. Хәлбуки этине бу вакыйга, төгәлрәге, элекке хезмәттәше белән очрашу никтер тәшвишкә салды, нервларын кузгатты. Каютага керү белән, борсаланып, ризасызлык белән үзалдына мыгырдый башлады:

– Кара син хәрәмчене, нинди түрә булган, сугымга симертелгән чучка кебек тәмам бүртенгән...

Аның кинәт әсәрләнеп китүе миңа сәер тоелды:

– Түрә булмагае, шайтан булсын, аңа ник исең китте?.. Син аны яхшы беләсеңмени? – дип сорадым.

– Әйе, кайчандыр яхшы беләм кебек иде, – диде эти. – Безнең корабта интендант булып хезмәт иткәндә, хәрби званиесен күтәрү өчен, мин аңа әйбәт характеристика язган идем. Нәкъ шуннан соң үткәрелгән ревизия вакытында аның командага дип ялган документ белән базадан алган обмундированиене үзләштерүе фаш ителде. Шулай да янмады, бөтен гаепне үз кул астында эшләүче писер белән баталер өстенә аударып, судан коры чыкты.

Гайбәт сатучы сыманрак булсам да, бер башлагач сөйләп бетерим инде: шуннан соң күп тә үтмәде, интендантыбыз шәһәргә чыккан чакларда кергәләп йөри торган тол хатынның унөч яшьлек кызын көчләгән өчен янды. Бу юлы ул җиңел генә котыла алмады, трибуналга эләкмәс өчен, авырыйм дигән булып, кемнәрнеңдер ярдәме белән тиз генә хәрби хезмәттән шылып, күздән югалды...

Әнә шул адәм актыгы хәзер зур түрә булып, корсак киереп йөрсен, имеш! Кагыйдә буларак, андый җитәкче үз тирәсендә үз ише яраннарын туплый, бөтен законсызлык, бозыклыкларын шулар ярдәмендә, һичкемнән курыкмыйча, оялмыйча шулар белән бергә эшли. Андый бозык атмосферада намуслы кеше дә юлдан язарга мәҗбүр була. Юкса аны бик тиз кысрыклап чыгарачаклар. Күпне белеп, телен теш артында тотмаса, башына җитүләре дә ихтимал.

***Гөлбикәнең хәтере калды***

Бүген көн артык кәнитилле булды, кызганычка каршы, бер-бер артлы туып торган ыгы-зыгы белән төнге вахтага чыгар алдыннан, гадәттәгечә, бераз черем итеп алырга чират тимәде.

Кич белән эш киемнәремне киеп, мин вахтага чыкканда, начальство инде рейдтан кайткан, алар утырып йөргән «Тәэминатчы» теплоходы «Баһадир»ның койрык ягына бәйләп куелган иде. Ә безнең «Зөя» баркасы исә алгы якта ашханә кладовое каршында тора; Бәдретдин абый белән пешекче хатын-кызлар аның палубасына төрле ашамлык, шешәләр тулы кәрзин, сумкалар ташыйлар. Штурман Артур, алар китергән әйберләрне кабул итеп, рубкага менә торган баскыч астындагы зур ларга тутыра, кубрикка төшереп урнаштыра бара иде.

Мин, машинаны, ягулык-майлау материаллары запасын күздән кичереп, вахтаны кабул иткән арада, баркаска начальниклар да килеп керде. Инспекциядә йөргән җирләрендә алар сизелерлек кәефләнеп кайтканнар бугай, артык кычкырып сөйләшүләре, хахылдап көлүләре аска машина бүлегенә дә ишетелә, ара-тирә гармун тавышлары да яңгырап куя. Ни булыр икән дип, өскә күтәрелеп карасам, ашханә кызлары да безнең белән бара, гармунда шуларның берсе өздерә, имеш!

Хәзер кызлар баягы кебек ак халаттан түгел, кунакка җыелгандай, бәйрәмчә киенгәннәр, баркас кузгалып киту белән, гармунга кушылып, күтәренке көйгә җырлый да башладылар. Азалия баш тәэминатчының култык астына керердәй сыланып утыра. Чәч бөтеркәләре, дулкын-дулкын булып, иңнәренә төшкән. Өстендә зәңгәрсу ефәк кофточка, муенса таккан, яртылай ачык күкрәк йомрылары арасында черви тузы төсле кызылсу кулон җемелди. Каш-керфекләре сөрмәле, иреннәренә мул итеп помада сөрткән һәм артык бизәнүдән үзенең табигый матурлыгын югалтып, ничектер курчакка охшап калган.

Безнең белән баручы өч кызның берсе – үзешчәннәр хорында башлап җырлаучы Гөлбикә – Азалия кебек артык бизәнмәсә дә, үзенең мөлаемлыгы белән җәлеп итә: кызмача кунаклар аның талчыбыктай сыгылмалы зифа буена, кызарып пешкән чия төсле тулы канлы көлемсә иреннәренә комсыз күзләре белән йотардай булып карап утыралар. Бигрәк тә баш тәэминатчыны озата йөрүче купшы адъютантның күзе кызган, юк сәбәпне бар итеп, кәҗә тәкәсе кебек, гел Гөлбикә янында ышкыла.

Кунаклар үзара әвәрә килгән бер арада, Гөлбикә минем янга койрык якка чыкты һәм, ачык тамбурдан машина бүлегенә кызыксынып карап:

– Әбәү, синең монда харап эссе икән... Җитмәсә, колак тондыргыч гөрелте тагын. Ничек түзәсең, канатым, – диде, юри җәлләгән булып.

Шаян кыз алдында сер бирәсем килмәде:

– Бер ияләшкәч, әллә ни кыен түгел... Сезнең кухняда мондагыдан эссерәк булса да, түзәсез бит, зарланмыйсыз... Туктале, Гөлбикә туташ, шултикле киенеп-ясанып кая барасыз? – дип сорадым.

– Анысы безгә билгесез, ул хакта мин үзем синнән сорамакчы идем. Азалия апай да әйтмәде, баргач күрерсең, диде. Барган җирендә кунакларга хезмәт күрсәтергә булса кирәк, алар белән ягымлырак булырга, күңелләрен күрергә кушты... Юлга чыгар алдыннан алар сезнең капитаныгыз Әюп агайны да чакырганнар иде. Әмма ул теләмәде, ахры. Иртән вахтага чыгар алдыннан ял итмичә мөмкин түгел, диде, бармады.

Хәзер бу сәфәр инде миңа да сәер тоела башлады. Аны-моны уйламастан, үзем дә көтмәгәндә:

– Әйтәсе дә юк, дәрәҗәле кунакларга сый мулдан әзерләнгән... Өстәвенә десертка чәчәк кебек яшь кызлар да алып бара, тере ит белән сыйламакчы, күрәсең, – дип, җиңелчә чеметтереп алдым.

Әллә ни әдәпсез сүз әйтмәгән шикелле идем, әмма Гөлбикәнең бик ачуы килде, шелтәле тавыш белән:

– Кемне әйтәсең син, Азалия апайнымы? – диде. – Шултикле дә пычрак телле булырсың икән, оят түгелме сиңа? Алай итәргә без кәнизәкләр түгел ич...

Гөлбикә чынлап торып үпкәләде һәм, минем гафу үтенүемә карамастан, бүтән берни дә әйтмичә, ачулы адымнар белән китеп барды.

***Шунсыз ярамый***

Без базадан кузгалып киткәч, ярты сәгать үтмәгәндер, рубкадан машинаны акрынайтырга, аннары туктатырга команда булды. Тамбурдан башым тыгып карасам, яр буена бәйләп куелган кечерәк кенә агач баржа янына барып туктаганбыз икән.

Монда без киләсен алдан белеп, көтеп торганнар, ахры, шундук кемдер, өзек-өзек сәер тавыш белән: «Киләләр-р, киләләр-р...» – дип, кычкырып хәбәр салды; әмма кычкыручы үзе күренми, ул каядыр яшеренгән җирдән чыжылдый сыман иде. Ул да түгел, палуба уртасындагы будка эченнән бозау хәтле зур сары эт чыгып, ярсулы тавыш белән һау-һаулап өрә башлады. Аның артыннан ук күлмәк изүен төймәли-төймәли базык гәүдәле шкипер алпан-тилпән атлап чыкты: «Дускай, шауламa, болар үз кешеләр, кунаклар...» – дип, аркасыннан сыйпап, башта бурзаен тынычландырды.

Ул сизелерлек сәрхуш бугай, безнең баркастан сузылган чалканы тумбага элгәндә, нәрсәгәдер абынып, чүт егылмады. Шулай да якты чырай белән:

– Кадерле кунаклар, рәхим итегез... Әйдәгез, юлны үзем күрсәтәм, – диде, авызын ерып.

Азалия, аның артык төчеләнүен өнәмәгәндәй, ризасызлык белән тамак кырып алды. Трап куйганны да көтмәстән, баржа палубасына сикереп чыкты да:

– Озатуның кирәге юк, юлны үзебез дә табарбыз... Ә син монда уяу бул, шикле кеше-кара күренсә, шундук хәбәр ит, – дип кисәтте һәм бөтен компаниясе белән такта басмадан яр буена төшеп китте.

Алар тәбәнәк яр өстендәге тар сукмактан куе тал-тирәк арасына кереп күздән югалгач, бермәл кайда икәнебезне чамалый алмыйча тордым. Шунысы сәер: без һәрвакыт эшли торган күп сулы киң Камада түгел, ниндидер тар елга тармагында, кечерәк кенә агач баржа янында торабыз. Бөтенләй таныш булмаган чит-ят җир, әйләнә-тирәдә шомлы тынлык.

Һе, күрми дә торам, таныш урын, беркөн төнлә балыкны без шушы баржадан алдык бит!.. Әйе, әйе, нәкъ үзе. Әнә койрык якта киптерергә элгән җәтмә җылымнар да, эре хәрефләр белән «Карантинлы утрау, якын килмәскә!» дигән белдерүле фанер такта да, Дускай атлы бурзай да – барысы да шулар. Ул чакны караңгыда шкиперын яхшылап күрмәсәм дә, тавышы шул – гырылдап сөйләшә ләбаса.

Әнә шулай гаҗәпкә калып торганда, киткән җиреннән ут капкандай йөгерә-атлый Азалия кайтып керде:

– Черек ми, иң кирәк әйберемне онытканмын, – дип, үзен-үзе әрли-әрли, кубрикка төшеп китте. Бер-ике минуттан палубага чыкканда, аның бер кулында кара икра тулы зур гына пыяла банка, икенчесендә – аракылы шешә һәм ниндидер төргәк иде. – Монда үзегезгә генә күңелсез булмасын, менә монысы сезгә, – дип, шешә белән төргәген миңа сузды.

– Кирәк түгел, эш вакытында эчәргә ярамый, – дип, шешәсен кире кактым һәм кинәт кузгалган җирәнүемне сиздермәс өчен, мөмкин кадәр сабырлык белән: – Карале, ник әле син үз исеменнән ваз кичкән шул Семен Федорович каршында җаныңны ярып бирердәй булып яхшатланып йөрисең? – дип әйттем.

Азалиянең сөрмәле кашлары җыерылды, ни әйтергә белмәгәндәй чак кына уйланып торды да:

– Безнең өчен бик кирәкле кеше бит, шунсыз ярамый, – диде. – Синең әнкәң – Миләүшә апай – башлы хатын, ул да шулай итә, кирәкле кешенең салпы ягына салам кыстыра белә иде, мине дә шуңа өйрәтә иде... Әйтәм ич, шунсыз ярамый, аннан гына ука коелмый бит.

***Карантинлы утрау***

Гравий чыгаручылар арасында колактан колакка сәер сүз йөри: Кама елгасының сул як тугаенда «Карантинлы зона» дигән сәер утрау бар икән, югары оешмалардан килгән инспектор, ревизор кебек тикшеренүчеләрне шунда майлап йомшарталар, дәрәҗәлерәк түрәләрне хәтта «тере ит» белән дә кунак итәләр, ди. Кайда икәнен тәгаен генә әйтмәсәләр дә, ул җылы оя һәр яктан су белән уратып алынган, аңа илтә торган бердәнбер тар сукмакны яр буенда усал эт белән мылтыклы кеше саклый, дип сөйлиләр.

Беренче тапкыр ишеткәч, мин моңа аз гына да ышанмаган идем, мәзәк өчен генә сөйләнә торган уйдырма итеп караган идем. Әмма хәзер күрәм, минем әнинең турылыклы шәкерте Азалия дәрәҗәле кунакны алып килгән бу урын да шундыйрак аулак ояга бик охшаган: «Карантинлы зона» дигән белдерү дә, яр буенда куе әрәмәлеккә керә торган тар сукмак та, аны саклаучы ярсу бурзайлы шкипер да бар бит.

Кунаклар әрәмәлеккә кереп киткәч, баржа палубасына чыктым. Будка тәрәзәсе каршындагы такта өстәл өстендә ике стакан, каклаган ике балык, икмәк һәм бер шешә аракы тора; аркасы белән стенага терәлгән шкипер, уйга талгандай, йокымсырап утыра иде.

– Рәхим ит, әйдә утыр... Менә Азалия калдырган күчтәнәч, сине дә сыйларга кушты, – диде, стаканнарга шаулатып аракы салды. Өстәл астында эсседән әлсерәп яткан бурзай ачулы ырылдый башлагач: – Аракы исен күралмый, салмыш баштан якын килсәм, мине дә тешләргә генә тора, – диде.

Шул арада көтмәгәндә, будка түбәсе кырыена ак канатлы саескан килеп кунды һәм, гәүдәсеннән озын койрыгын болгый-болгый: «Хәерлегә түгел бу, хәерлегә түгел...» – дип, ятышсыз тавыш белән шыгырдарга тотынды.

Ул – шкиперның кулга ияләшкән һәм кешегә ияреп берничә сүз тәкелди торган саесканы икән. Баягынак безне киләләр, киләләр, дип кычкырып каршылаучы шул булып чыкты.

– Саесканым бик әйбәт хезмәт итә, ят кеше-кара килгәнен эттән дә элегрәк күреп хәбәр бирә торган иде, – диде шкипер. – Авылдан әни килеп, монда бераз торган иде, шуннан ишетеп, кошчыгымның холкы бозылды: өстәлдә шешә күрсә, «Хәерлегә түгел бу...» – дип, әнидән өйрәнеп калган сүзләрне кабатларга тотына. Попугай кебек, һаман шуны такылдап, нервыда уйный. Ярар, черт с ним... Әйдә, бераз тамак чылатып алыйк әле.

Әнә шулай саесканнан зарлана-зарлана, аракыны икегә бүлде, аннары чыраен да сытмыйча, тулы стаканын шундук берьюлы аударып куйды, кипкән балык эченнән уылдык алып капты. Минем гомумән аракы эчмәвем аңа бик сәер тоелды бугай, колакларына ышанмыйча, беравык гаҗәпләнеп карап торды. Аннары мине мактап берничә сүз әйтте дә, синең саулыкка булсын, дип, шундук икенче стаканны да бушатты.

Шунда будка стенасына кадаклап куелган язулы фанер тактага тагын күзем төште:

– Нинди карантин бу, сезнең монда йогышлы авыру бармыни? Аның безгә куркынычы юкмы? – дип шикләнеп сорадым.

– Юк, һичнинди карантин юк. Ул хакта аз гына да борчылма, – диде шкипер, кәефле хахылдап. – Мин аны болай гына, чит-ят кеше бу тирәгә якын килмәсен өчен язып куйган идем.

Без килгәнче үк инде шактый салмыш шкипер, тагы ике стакан өстәгәч, отыры исерә төште, балык кылчыгы белән тешләрен казый-казый:

– Тормышта иң мөһиме – файдасы тиярлек кешене табарга, аның ышанычына керә белергә кирәк, – дип, акыл сатарга кереште. – Элекке ашханә мөдире Миләүшә түтигә рәхмәт, монда кладовщик итеп мине шул куйды. Бик башлы хатын иде, бу карантин белдерүен дә мин аның кушуы буенча яздым. Хәер, үзем дә аның каршында бурычлы калмадым, миннән күпкә өлкән яшьтә булса да, үзе теләгәндә, күңелен күрә торган идем...

Сәрхуш шкипер ниләр ничек булганын, вак-төягенә кадәр җентекләп, бәйнә-бәйнә сөйли. Аның һәр сүзе бәгыремне өзгәли, әни өчен оят. Хурлануга чыдый алмыйча: «Җитте сиңа, тукта!» – дип, өстәл сугып кычкырудан үземне көчкә тыеп утырам.

Дәрәҗәле кунаклар утырган аулак оя моннан ерак түгел, кайдадыр якында гына булса кирәк. Яр өстендәге куе тал-тирәк арасыннан гармун тавышы, кычкырып көлүләр ачык ишетелә, шау-шулы җанлылык көчәйгәннән-көчәя бара. Әле берсе, әле икенчесе мөхтәрәм Семен Федоровичны

олылап, елгачылар турында аталарча кайгыртканы өчен аңа ихлас күңелдән рәхмәтләр әйтеп, озын гомер, саулык-сәламәтлек теләп тост күтәрә...

Бераздан мәҗлестә тәнәфес ясап таралыштылар бугай, өзек-өзек сөйләшү, чыр-чу килгән тавышлар төрле тарафтан килә башлады.

Әле без бирегә килеп туктаганда гына, һава чалт аяз, көнбатышта офык буйдан-буйга кансу кызыл иде. Кичке эңгердә күрми калганмын, мин монда сәрхуш шкипер янында көенеп утырган арада, күк йөзен болыт каплаган булып чыкты. Көтмәгәндә, кичке тынлыкны бозып, баш очында гына гөрселдәп күк күкрәде, эре тамчылы җылы яңгыр сибәләргә тотынды. Әмма болыт агымы безгә кырые белән генә кагылды бугай, яңгыр озак яумады, балык чүпләре тулы өстәлне, киптерергә элгән җәтмәләрне чылатты да, агым уңаена түбән якка таба китеп барды.

Тәмам җебегән шкипер кыска вакытлы яңгырны сизми дә калды, ахры, будка стенасына аркасын терәп утырган хәлдә йокыга чумды. Ә мин үз баркасыбызда эш юктан бер эш булсын дип, койрык якта кармак салырга утырдым.

Берсеннән-берсе күңелсез уйларга батып утырганда, кинәт якында гына кемнәрнеңдер ыгы-зыгы килгәне, чытырманлык арасында дөп-дөп басып йөгергәне ишетелде. Караңгы тынлыкта ачы тавыш белән:

– Таһир-р... ярдәмгә кил-л... – дип, хатын-кыз кычкырганы яңгырап үтте.

Чү, мине атап кычкыра бит, безнең ашханә кызларыннан берәрсе бугай. Тиз генә йөгереп чыгып, тайгак сукмактан яр өстенә менсәм, якында гына дәрәҗәле түрәнең озата йөрүчесе, нәрсәдер мыгырдый-мыгырдый, повар кыз Гөлбикә белән тарткалаша, култыклап аны куе чытырманлыкка алып керергә маташа иде.

– Нишлисез сез, туктагыз... Оят түгелме... – дип туктатып, оялтмакчы булган идем.

Кая ул оялу... Төкереп тә бирмәде, ичмасам. Искитмәле берни дә булмагандай:

– Нинди оят булсын... – диде. – Бу дуамал кыз тегендә минем күзлегемне төшереп югалтты, шуны эзләшергә генә алып бармакчы идем. Ә ул шуны аңламыйча, көйсез бала кебек тавыш куптарды.

### *Үпкәләткән булсам, гафу ит*

Бик дулкынланган Гөлбикә баркас палубасына кергәч тә тиз генә тынычлана алмады. Аның өсбашы таушалган, чәче тузгыган, үзе, каты йөгереп килгән кебек, еш-еш тын ала, бөтен гәүдәсе сулкылдап калтырый.

– Ярый әле син килеп җиттең, юкса эш харап иде, – диде һәм, тузгыган чәчен рәтли-рәтли, башыннан үткәннәрне сөйләп китте. – «Яшел ресторан» дигәннәре әрәмәле кечерәк кенә утрауда зур өстәл, бүкән утыргычлар белән җиһазландырылган, һәрьяктан үрмәле колмак җәтмәсе белән каплаулы түгәрәк беседка булып чыкты. Шунда тиз генә табын әзерләгәч, Азалия апай миңа начальникны озата йөрүче – чиләк кебек ябык гәүдәле, чәй тәлинкәсе хәтле зур күзлекле бәндә янына утырырга, аңа илтифатлы булырга, күңелен күрергә кушты. Үзе исә һаман дәрәҗәле кунак янында булды, кайнар тостлар әйтә-әйтә аны сыйлады. Ә минем башта тәкәббер күренгән кунагым, киресенчә, үзе кайгыртучанлык күрсәтеп, тәлинкәмә закускалар алып салды, рюмкаларны чәкештерәчәкештерә мине кыстап, көлдергеч мәзәкләр сөйләп утырды. Моның юкка булмаганын, сизгерлегемне оныттырып, мине исертү өчен эшләнгәнен чак кына соңрак күрдем.

Сезнең Артур дигән штурманыгыз эчүгә комсыз, ахры. Азалия апай аны: «Син эштәге кеше, безне алып кайтасың бар, күп эчмә», – дип, берничә тапкыр кисәтүгә карамастан, теге күрмәгән арада чөмерә дә чөмерә.

Бераздан тәнәфескә таралышып, сәйранда йөргәндә, шыбырдап җылы яңгыр коеп ява башлады. Ярый әле, безнең бәхеткә, якында гына алан читендә печән богылы бар икән. Бик чыланмас өчен, тиз генә йөгереп барып, шуның ышык ягына сыендык.

Гөлбикә шунда сүзеннән туктады, оялчан яшь кызларга хас уңайсызлану белән:

– Юк, бүтән берни дә әйтмим, анда ниләр булганны, ниләр ишеткәнне сөйләргә телем бармый, – диде һәм, мин кызыксынып үгетләгәч кенә, кыяр-кыймас сүзен дәвам итте: – Без йөгереп килүдән соң рәтләп тын алырга өлгермәдек, янәшәдә генә нәрсәдер кыштырдаган, кемдер авыр сулап уфылдаган кебек тоелды. Ул да түгел, ир кешенең: «Картлык сездерә, гафу ит, шәп булмады бу...» – дип, ни өчендер акланганы ишетелде. Шундук хатын-кыз тавышы аны бүлеп: «Юкны сөйләмәгез, зинһар, Семен Федорович, сез яшь егет кебек әле», – диде, төче кеткелдәп. Мин моның Азалия апай тавышы икәнен шундук танысам да, башта ни турында сүз барганын аңламадым. Аннары ча-

малап алгач, оялудан җир тишегенә керердәй булдым һәм ул мине дә шуңа этәрә түгелме дип шиккә төштем.

Алар монда озак тормадылар, тиздән яңгыр туктау белән шыпырт кына чөкердәшә-чөкердәшә китеп, караңгыда юк булдылар. Богылның астында печән җилләсен өчен кечерәк кенә шалаш сыман куыш бар, анда керү юлы каршы якта икән. Азалия апай дәрәҗәле түрәне шунда алып кереп, күңелен күргән, димәк.

Минем кунагым хуҗасының мондый сыйлануларын күп күргән, үзе дә шомарган бугай, аз гына да гаҗәпләнмәде. Һи, нинди коры, аулак оя, әйдә карыйк әле, дип, җилтерәтеп эчкә алып кергәнен абайламый да калдым.

Куыш эче дөм караңгы, күзгә төртсәң дә күрерлек түгел. Әлегә тикле азмы-күпме әдәп саклаган кавалерым аулакта тыйнаксызланырга, шаярган булып, кулына ирек бирергә, капшанырга тотынды. Башта кунак хакына каты бәрелмәскә тырышкан идем. Әмма артык узынырга тотынгач, түзмәдем, бар көчемә этәреп җибәрдем. Караңгыда ялгыш битенә эләкте бугай. Ул шунда: «Ай, харап иттең, күзлегемне бәреп төшердең...» – дип, аяк астындагы печән арасында кармалана калды, ә мин шул арада куыштан тиз генә чыгып ычкындым.

Мин инде котылдым дип тынычланып, караңгыда ашыкмый гына кайтып бара идем. Ә ул әле һаман суынмаган, күрәсең, тиздән куып җитте дә, баудан ычкынган кебек исәренеп, тагын бәйләнергә тотынды. Минем тавышка шунда тиз генә син килеп җитмәсәң, хәлем хөрти иде.

Гөлбикә сүзеннән туктап, авыр сулап куйды, үзалдына уйлангандай:

– Таһир, бая мин сиңа пычрак авыз, гайбәт сөйлисең, дип ачуланган идем. Үпкәләткән булсам, зинһар, кичер мине, – диде. – Азалиянең бозыклыгын, безне дә шул сазлыкка этәрүен белеп әйткәнсең, барысы да син уйлаганча килеп чыкты. Ә мин, күзле сукыр, шуны күрмәгәнмен, һәр эштә аңа охшарга, аның кебек булырга тырыша идем. Ул исә үзенең остазы итеп һаман саен Миләүшә исемле хатынны мактап, тормыш итәргә шуннан өйрәндем, дип мактана.

### *Хәерлегә түгел*

Тәнәфестән соң утрауда мәҗлес тагын җанланып китсә кирәк, берсеннән-берсе катырак кычкырып сөйләшү, гармун, җыр тавышлары отыры көчәя барды. Кунакларның булуы җиткән бугай, нинди көйгә җырлауларын да аңларлык түгел, һәркайсы үзенчә мөгри. Ул да түгел, арадан берсе эче итеп сызгырып җибәрә, кемнәрдер тыпыр-тыпыр бииләр. Пәри туе кебек дөбер-шатырдан бөтен әрәмәлек гөр килә, куркудан уянган кош-корт коркылдап куя.

Бу шау-шуга шкиперның саесканы да йокламаган, уяу булган икән. Кинәт шул һич көтмәгән җирдән: «Килә-ләр... Килә-ләр-р...» – дип тавыш күтәрде, аңар ияреп, бурзай ярсулы ырылдарга тотынды. Әле һаман өстәл янында йоклап утырган шкипер, үзе дә шундук уянып, пружина кебек ялт торып басты.

Тиктомалдан кузгалган бу ыгы-зыгы башта миңа һичнинди сәбәпсез, йокы аралаш саташу, иләс-миләсләнү кебек тоелган иде. Колак салыбрак тыңлап карасам, чынлап та безгә таба нәрсәдер үкереп килә, ара якынайган саен, аның тавышы көчәя бара иде. Мин аның кай тарафтан – үр яктанмы, түбәннәнме – ишетелгәнен чамаларга өлгермәдем, төн карасы эченнән зур тизлектә моторлы көймә килеп чыкты һәм, тын су өстендә дулкыннар кузгатып, баржа белән янәшә туктады. Аның мотористы – тузгак чәчле чандыр егет – шыпырт кына нәрсәдер хәбәр итүгә, сәрхуш шкипер кинәт корт чаккандай:

– Милиция нарядымы?! Кай яктан киләчәкләр?.. – дип кычкырып җибәрде. – Хәзер үк барып әйтергә кирәк, тизрәк таралсыннар... Әйдә син дә минем белән, ярдәм итәрсең...

Алар бик тиз йөгереп барып җиттеләр, күрәсең, берничә минуттан тегендә җыр, гармун тавышлары басылды. Әйләнә-тирәгә шом таратып шау-шулы ыгы-зыгы, тәртипсез кабалану кузгалды. Тиздән алар бер-берсен ашыктыра-ашыктыра әрәмәлектән яр читенә килеп чыктылар. Баш кунак көчкә басып тора, бер яктан аны район начальнигы Петраков, икенче яктан Азалия култыклаган. Озата йөрүчесе күзлексез начар күрә, ахрысы, штурман Артурга тотынган. Башкалары төрле савыт-саба, аш-сый тулы сумка, тартма күтәргән. Барысы да иләс-миләс, бер-берсен этә-төртә кабаланып ашыга.

Сыгылмалы тар такта басмадан баржага күтәрелгәндә, авыр гәүдәле Семен Федорович тотрыклылыгын югалтып, кинәт як-якка авыша, һавада тотка эзләгәндәй, кулларын болгый башлады, башындагы кайма читле шәп фуражкасы суга төшеп китте. Аның үзен мәтәлеп төшеп китүдән көчкә тотып калдылар.

Бу шау-шу зирәк саесканга җитә калды булса кирәк, ул бәла хәбәрчеседәй: «Хәерлегә түгел бу... Хәерлегә түгел...» – дип, әсәренеп шомлы тавыш күтәрде. Якында гына бәйдә тыныч яткан бурзай да ыгы-зыгылы сәрхуш кунакларны кертмәс өчен өзгәләп ташлардай ярсып өрә башлады. Хуҗасы аны кыенлык белән читкәрәк күчереп бәйләде. Тик шуннан соң гына мөхтәрәм кунаклар баржа аша хәвеф-хәтәрсез үттеләр һәм, баркас палубасына аяк басып, ниһаять, җиңел сулыш алдылар, басылдылар.

Бары тик ярсулы саескан гына, кемнедер ләгънәтләгәндәй:

– Хәерлегә түгел бу!.. Хәерлегә түгел!.. – дип, гыжылдап әйләнә-тирәгә шом тарата иде.

***Инде котылдык дигәндә генә...***

Штурман Артур сизелерлек сәрхуш булса да, ничек тә бирешмәскә, үзен кулга алырга тырыша. Район начальнигы Петраков хәзер үк кузгалырга кушу белән абына-сөртенә тимер баскычтан рубкага менеп китте. Аның артыннан күтәрелгән рулевой Харитонның чалбар кесәсеннән аракы шешәсе тырпаеп тора иде.

Мин дә тиз генә аска үз постыма төштем, рубкадан машинаны ходка җибәрергә, аннары шундук бар куәтенә эшләтергә команда булды. Ишкеч вал зур тизлеккә зырылдап әйләнә, бөтен корпус дер-дер калтырый башлады, ә без бәйләп куйган кебек, һаман бер урында торабыз, һич кузгалып китә алмыйбыз. Менә өстә нәрсәдер ухылдап куптарылган, шарт-шорт сынган кебек булды. Әле генә куштанланып кунакларга булышып йөргән шкипер кинәт ут чыккандай:

– Туктагыз, шайтаннар... Күзегез чыккырлары, бөтен ныгытмаларны җимерәсез ич... – дип, яман сүзләр белән сүгенә башлады; аннан катырак ярсып бурзай һау-һу куптарды, шомлы тавыш белән саескан тагын: «Хәер-рлегә түгел... Хәер-рлегә түгел...» – дип такылдады.

Тиз генә машинаны туктату белән шундук моның сәбәбе дә ачыкланды. Исерекбаш рулевой-матрос Харитон арткы чалканы ычкындырырга онытკан, штурман Артур шуны күрмичә, машинаны бар куәтенә эшләтергә команда биргән булып чыкты. Нәтиҗәдә баржаны яр буена тарттырып бәйләгән тросларны өздереп, басманы җимереп, үзебез белән тарттырып китә язганбыз. Бүтән чакны моның аркасында зур җәнҗал чыгар, закон кушканча рәсми акт язып, штурман җавапка тартылыр иде. Хәзер вакланып торырга вакыт юк. Зыян-низагны зурга җибәрмәделәр.

– Ярар, тамак ертып кычкырышудан файда юк... Иртәгә балыкчылар кайткач, боларын алар белән бергә үзем рәтләрмен, – дип, иң акыллы фикерне исерек шкипер әйтте... – Булышкан өчен аларга тамак чылатырга бераз шайтан сөте калдырыгыз да тизрәк шылыгыз. Шуның белән вәссәлам: сез монда булмаган, мин күрмәгән...

Бу киңәшкә барысы да шундук бик теләп берсүзсез риза булдылар. Азалия кушуы буенча Бәдретдин абый сумкадан берничә шешә аракы тартып чыгарды. Шкипер аларны борт аша гына сузылып алды да:

– Әнә үр яктан нindидер ут якынаеп килә... Милиция катеры булмагае, тизрәк шылыгыз. Төн караңгы, бәла-казага юлыгуыбыз бар, сак йөри күрегез... – дип, безгә хәерле юл теләп озатып калды.

Без баржа яныннан кузгалу белән, узышка чыккан чабышкы кебек, шундук ыжгыртып зур тизлектә китеп бардык. Бу тирәдә елга тармагы бик тар һәм дугайлы-дугайлы, әледән-әле уңга-сулга борыла-борыла элдертәбез. Саерак урыннардан үткәндә, елга төбенә бәрелүдән баркас сикереп-сикереп куя, яр читендә суга салынып үскән талчыбык иллюминаторларны чалт-чолт камчылый.

Ниһаять, түзмәдем, нигә болай чамасыз кызулыйлар дип, тамбурдан башым күтәреп карадым. Алда – дөм караңгы. Артыбыздан гудок кычкырта-кычкырта һәм прожектор белән яктырта-яктырта нindидер судно куалап килә. Ә безнең сигнал утларыбыз сүндерелгән, бәладән качкан пиратлар шикелле, җан-фәрманга җилдертәбез.

Эзәрлекләүче судно безнең койрыкка баса килә, ара якыная бугай, штурман Артур калтыравыклы тавыш белән:

– Самый полный... Ишетәсеңме, самый полный... – дип, әледән-әле мине дә куыра.

Машина каты шауласа да, сөйләшү трубкасына якынрак килеп тыңласаң, рубкада ниләр булганын ишетеп чамаларга мөмкин. Штурманның күзләре, әлбәттә, алга төбәлгән, артка борылып карарга вакыты юк. Рулевой Харитон аңа әледән-әле:

– Якыная... якыная... Өч-дүрт минуттан куып җитүе ихтимал... – дип хәбәр итеп тора.

– Өч-дүрт минутмы?.. Алайса котылдык... – диде штурман шатланып. – Әнә Кама киңлегенә чыктык бит. Алар монда килеп җиткәнче, без төн карасы эчендә эреп югалачакбыз... Уф, тамагым кипте. Харитон дус, кесәңдәге шешәңне ач әле, хәзер инде шатлыктан авыз чылатып алырга да мөм...

Ул соңгы сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, безнең баркасны нәрсәдер төртеп аударды һәм, дөбер-шатыр шыгырдап, өстебездән үтеп китте. Ут сүнде, машина бүлегенә гөрләп су тула башлады. Мин караңгыда нинди бәлагә дучар булуыбызны абайламый да калдым, башыма нәрсәдер бәрелеп, күземнән утлар күренгәнне генә беләм...

***Су төбендә бер төн***

Авызыма су тулуга чыдый алмыйча, тончыгып уяндым һәм буылып-буылып укшый башладым. Үзем муен тиңентен су эчендә утырам. Кайда икәнемне, бу хәлгә ничек эләгүемне һич белә алмыйм.

Өнемме бу, әллә төшемме дип беравык шомланып торганнан соң, коточкыч һәлакәткә дучар булуыбызны хәтерләдем, һәм асты өскә әйләнеп суга баткан баркас эчендә калуымны төшендем. Әҗәлем шушы икән дип йөрәгем жу-у итеп китте.

Әйләнә-тирәдә тынлык, кайдадыр якында гына йөрәккә шом салып ишетелер-ишетелмәс кенә нәрсәдер чырылдый. Караңгыда кармалап эзли торгач таптым, ябылып бетмәгән иллюминатор ярыгыннан чаптырып су керә икән. Көч-хәл белән ябып, суны туктаттым.

Әмма су барыбер бүтән тишек-ярыклардан керүен дәвам итә, акрынлап күтәрелә бара, тончыкмас өчен аягүрә бастым. Хәлем хөрти, тиздән корпус эче тулып, мин баштанаяк су эчендә калып, гарык булачакмын.

Асты өскә әйләнгән булса да, хәзергә баркас әле йөзмә хәлдә, салмак кына тирбәнә-тирбәнә агым уңаена бара бирә. Менә ул елга төбендәге сайлыкка төртелеп, кинәт кыйшайды, корпус эчендә шул якка ташланган су массасы мине дә тәгәрәтеп алып китте. Кайнам басылгач, көч-хәл белән аякка бастым, шул арада эчемә тулган мазутлы судан косып арындым.

Мәгәр бераздан корпус эчендә су басымы белән һава басымы тигезләнде бугай, су күтәрелү тукталды шикелле. Аның каравы һава басымы күкрәкне кыса, тын алуы сизелерлек кыенлаша башлады. Гел басып торудан тез буыннарым калтырый, трап култыксасына көчкә тотынып торам, хәлдән тая баруымны, уйларым буталуын сизәм. Аңым ачылган араларда: «Бирешмә, ничек тә түз... Минем монда икәнемне беләләр бит, тиздән ярдәмгә килеп җитәрләр...» – дип, үземне өметләндерергә тырышам.

Мин аркам белән сөялеп торган тимер стенаның (переборканың) теге ягында кинәт нәрсәдер кыштырдаган кебек тоелды. Мин тук-тук итеп җавап бирүгә, аннан кемдер тагы да катырак шакый башлады, хәтта ачыргаланып кычкырган тавыш та тонык кына ишетелде... Бу аның соңгы өне булды бугай. Шуның белән тыны бетте, җан тәслим кылды, күрәсең, ул яктан бүтән берни дә ишетелмәде. Ирексездән инде күп калмады, миңа да чират җитә дип уйлап куйдым. Барыннан да бигрәк улым Мансурны ятим калдырып, хәләл җефетем Сәрвиназдан, яңа гына табылган этиемнән аерылып китүе аяныч...

Ә өстә тормыш үз юлыннан бара бирә бит. Мин моны сизеп торам. Якыннан гына суднолар үткән саен, шаулы дулкыннар килеп бәрелеп, баркасны як-якка кыйшайта, корпус эчендәге су чалтчолт чайкала, биткә чәчрәп йөдәтә... Ярый әле эти бу өергә ияреп бармаган, югыйсә, минем кебек, ул да харап булачак икән.

Хәзер инде минем тез буыннарым гына түгел, бөтен гәүдәм калтырый, аның саен хәлдән тая барам. Авыз, борынга мазутлы су тулмасын өчен иягемне югары күтәреп торырга мәҗбүрмен.

Әнә шулай җәфа чигә торгач, мәңге бетмәс кебек тоелган озын төн, ниһаять, үтте, таң атуын хәбәр итеп, су катламы аша иллюминаторлардан тонык кына булып яктылык шәүләсе күренде, шуның белән күңелдә янә өмет туган кебек булды.

Тиздән мин тагын истән язып, аягүрә баскан килеш саташа башладым, ахры. Төшемдә якында гына нәрсәдер шакыганын ишетәм, баш өстемдә кемнәрдер дөп-дөп басып йөриләр шикелле.

Чү, төш түгел, коткаручылар килгән ич... Водолазлар булса кирәк. Бик акрын кыймылдасалар да, корпус тирәсендә нәрсәдер маташтыралар. Ә мин тәмам йончыганмын, тез буыннарым дер-дер калтырый, бер генә минут та басып торыр хәлем юк. Түзә алмыйча чүгәләсәм, мин бүтән күтәрeләчәк түгелмен, ниһаять, котылам дигәндә генә суга батып харап булачакмын... Кызганычка каршы, тышкы якта һаман сузалар, шак-шок бәреләләр, нәрсәдер җайлыйлар...

Менә әлегә тикле сайда хәрәкәтсез утырган баркас кинәт чак кына кузгалган кебек булды. Әһә, трослар белән эләктереп, йөзмә кран ярдәмендә күтәртә башладылар. Баркас югары күтәрелә барган саен, әйләнәмдә суның азаюын сизәм, иллюминаторларның өскә калкып чыгуын күрәм һәм, бүтән басып тора алмыйча, сыек чыбык кебек сыгылып төшәм.

Корпус эченнән су бушап бетү белән, машина бүлегенә барыннан элек әти килеп керде һәм ярым караңгыда миңа абынып чүт егылмады. Тел тибрәтерлек дәрманым булмаса да, мәгәр күрәм: мине үлгән дип хәсрәткә төште, ахры, таш кебек катып калды, авыр сулап куйды. Аннары минем иреннәрем кыймылдавын күрде бугай, тиз генә иелеп, пульсымны капшап карады да, шат тавыш белән:

– Тере бит... Чынлаптыр исән, йөрәге тибә... – дип кычкырып җибәрде.

Шул арада машина бүлегенә тагын кемнәрдер кереп, минем тирәмдә ах-ух иттеләр. Арадан берсе үзалдына сөйләнгәндәй:

– Кара син аны, монысы исән калган, бәхете бар икән... – дип гаҗәпләнде.

Шунда мин хәлсезләнеп, тагын һуштан язганмын, бүтән берни дә хәтерләмим...

***Сәрвиназ килеп җиткән***

Көчле агымлы зур елгада су коенганда кинәт төпсез упкынга эләктем. Гөрелдәп бөтерелгән агым, үз тирәсендә әйләндереп йөртә-йөртә, мине төпкә тарта. Ярдәмгә чакырып кул болгыйм, кычкырам. Яр буенда җитәкләшеп йөрүче улым Мансур белән Сәрвиназ мине бар дип тә белмәгәндәй, ашыкмый гына китеп баралар. Ә упкын мине аның саен төпкә тарта. Менә-менә батам, инде бетәм дигәндә:

– Коткарыгыз-з... харап булам-м... – дип, көчкә кычкырып җибәрдем һәм үз тавышыма уянып киттем.

Шөкрана, бу бәла өндә түгел, төштә генә икән. Үзем шабыр тиргә батканмын, дер-дер калтырыйм. Кыйнап ташлаган кебек бөтен гәүдәм үтереп сызлый, кыймылдарлык та җегәрем юк.

Күземне ачсам, тирә-юнем караңгы, йомшак урында ятам. Еракта-еракта, күк күкрәгән шикелле тонык кына гудок тавышлары яңгырап үтә. Менә мин йокыдан тәмам айныдым, су астында газапланууларымны хәтерләп, йөрәгем кузгалды. Тик бернәрсә, бу бәлагә ничек дучар булуыбыз, безне кем аударып суга батыруы аңлашылмый. Кешеләр нихәл икән, бәла-казага тарымадылар микән?..

Ул хакта уйлый башлау белән тагын йөрәгем кузгалды. Тыным кысылуга чыдый алмыйча:

– Уф, һава җитми... – дип авыр көрсендем.

Мин моны эчтән уйлагандай акрын гына әйттем, якын-тирәдә беркем дә юк сыман иде. Чынлыкта исә шундук янәшәдә генә кемдер, балаларча түземсезлек белән:

– Әнә әти уянды ич... Әти уянды... – дип кычкырып җибәрде, калын штораны яртылай ачып, мин яткан якка улым Мансур атылып керде, караватка сикереп менеп, муеныма сарылды, өтәләнеп битләремнән үбә башлады.

Күктән төшкәндәй шундук Сәрвиназ да пәйда булды, тәрәзә, бүлмә штораларын ачты, шашынган Мансурны бераз тыярга теләп:

– Ай, тукта, улым, алай ярамый... Әтиеңне авырттырырсың, – диде, баш очыма утырып, маңгай тиремне сөртте.

Әле генә төшемдә Сәрвиназ белән улым мине упкын эчендә калдырып киткәнгә бик нәүмиз идем. Менә хәзер көтмәгәндә шуларның килеп керүе – көзге яңгырлы көнне караңгы болытлар арасыннан кояш елмаеп караган кебек, дөнья яктырып китте. Сәрвиназга рәхмәт инде, хәвефле хәбәр ишетүгә, малайны ияртеп, көне-сәгате белән килеп җиткән бит.

Ә Мансур мине әле һаман танып бетермәгәндәй, күзләрен түгәрәкләндереп, бермәл сәерсенеп карап торды да:

– Әтием, синең чәчең мондый түгел иде, менә бу төшен агарткансың икән, – диде, маңгай чәчемә кагылып.

– Фу, бу очлы күзнең күрмәгәне юк. Бер уч маңгай чәчең чынлап та ап-ак булган икән, – дип, Сәрвиназ да бик гаҗәпләнде. – Әйтүе генә ансат, шултикле коточкыч газаптан чәчең агару түгел, акылдан язуың да ихтимал.

Хәер, Сәрвиназның үзенең дә битләре сизелерлек суырылган, күз төпләренә борчылу күләгәсе кунган. Аның белән сөйләшүдән мин үземнең база медпунктында ятуымны белдем. Ашыгыч ярдәм врачы имгәнү, яралану юк, берничә көннән нервлары тынычланып хәл кергәч, аякка басар, дигән. Турыдан-туры әйтмичә, йомшатып кына сөйләсә дә, Сәрвиназ үзе дә зур тетрәнү кичергән: ирең су төбендәге баркас эчендә һәлак булды дигән хәбәр алгач, бирегә юл буе елап килгән. Менә хәзер тагын күз яшьләрен сөртә-сөртә:

– Сине исән-сау күрер көн дә бар икән, күңел әле һаман ышанып бетә алмый... – диде.

– Ник ышанмыйсың... Әти яр буенда яткан мәетләр арасында түгел, менә исән ич... Җитәр, елама инде, – дип, Мансур әнисен юатырга кереште.

Ә мин аның сүзләрен башыма сыйдыра алмыйча кинәт миңгерәп киттем, зиһенем чуалды. Көч-хәл белән:

– Нинди мәет, кемнәр ул?! – дип әйтә алдым.

Минем нервлануым йөземә чыкты булса кирәк, Сәрвиназ ничектер югалып калды. Ни әйтергә белмәгәндәй ык-мык итеп:

– Рәтләп күрмәдем, кемнәр икәнен танымадым, – диде.

– Оныттыңмыни, әни... Азалия апайны таныдык ич...

– Их, син малай актыгы, әти-әниең сөйләшкәндә тик тор әле, – дип, Сәрвиназ Мансурны җиңелчә шелтәләп туктатты: – Таһир җаным, мин сиңа барысын да үзем сөйләрмен... Ә хәзер менә нәрсә: врач сиңа уянгач та укол бирергә язган иде, әйдә шуны эшлик әле.

Әнә шулай, үзалдына сөйләнә-сөйләнә, ул күлмәк җиңемне кайтарып күтәрде, шприц белән коралланып, беләгемә чәнчеде, боз тигәндәй, шул төшемне дару туңдырып алды. Аннары бу салкын төер, җылы агымга әверелеп, бөтен тәнгә таралды, салмак дулкын мине каядыр алып китте.

***Бабай, ник син безгә килмисең?***

Йокыдан уянып күземне ачу белән:

– Сәрвиназ... Мансур... Бик сусадым, су бирегез... – дип сорадым.

Яртылай ачык штораның теге ягыннан:

– Су кирәкме?.. Хәзер була ул, – дип, ир кеше җавап кайтарды. Кем тавышы икәнен таныргa өлгермәдем, сулы стакан тотып әти килеп керде: – Сәрвиназ белән Мансур ашханәгә төшеп киткәннәр иде, тиздән менеп җитәрләр. Алар бүген көндезге теплоход белән килеп төштеләр. Без таныштык инде, Мансур белән дуслашып та өлгердек. Әмма мин синең әтиең икәнне белмиләр әле, анысын үзең әйтсәң, әйбәтрәк булыр шикелле... Шулай да бәхетебез бар икән, мәйтәм. Юкса бик борчылган идем, күп еллар көтеп табышканнан соң, шундук сине бөтенләйгә югалту ифрат авыр булачак, ялгыз калачак идем...

Инде үзем бала атасы булсам да, әтинең бу сүзләреннән күңелем тулды, күзләрем яшьләнде...

Әмма күрәм, әтинең яртылай өтелгән кашлары салынкы, сүз арасында әледән-әле чырае сытылып куя иде. Ирексездән:

– Әтием, кәефең шәп түгел шикелле, берәр җирең авыртамы әллә? – дип сорадым.

– Юк, авыртудан түгел, – диде әти, тирән көрсенеп. – Әлерәк кенә мәетләрне теплоходка төяп шәһәргә озаткан идек. Бик авыр күренеш, шуның тәэсиредер... Азгын бәндәләр аркасында харап булган гаепсез кешеләрнең мәетләрен төяп озату, туганнарының күз яшьләрен күреп җан әрни.

Аста машина бүлегендә булганлыктан, мин авариягә ничек эләгүебезне күрмәдем бит. Бер башлагач, әти анысын да бәян итте: тар елга тармагыннан Кама киңлегенә чыгу белән безнең баркас үрге яктан ыжгырып килүче зур теплоходның борын астына үзе барып кергән, шуның астында йөзтүбән капланып тапталган. Чөнки рубкада штурман да, рулевой да исерек, аңгы-миңге; караңгыда теплоходтан да күрмәгәннәр, баркасның сигнал утлары сүндерелгән булган. Нәтиҗәдә баркастагы бар халык җан тәслим кылган, бер мин генә исән калганмын. Мәрхүмнәрнең агым уңаена сибелгән үле гәүдәләрен балыкчылар җәтмә белән җыешканнар. Арада бары тик безнең Бәдретдин абый гына әле һаман табылмаган...

Бу җан өшеткеч авыр хәбәрдән, башыма таш төшкәндәй, тәмам миңгерәп калдым, күз алларым томаланды. Көч-хәл белән аңга килдем. Су төбендәге баркас эчендә өметсезлеккә төшкән газаплы минутларда мин алар турында: бәхетлеләр, исән калалар, дип уйлаган идем бит.

Озакламый ашханәдән Сәрвиназ белән Мансур менеп җитте. Өстенә тәлинкә каплаган мискидә миңа да нәрсәдер алып менгәннәр. Мансур миңа килеп сыенды, зур ачылган күзләре белән әтигә карап:

– Бабай, синең маңгаең, битләрең ник әтинеке төсле түгел, ник ямаулы-ямаулы? – диде кыюсыз гына.

Бу сорау Сәрвиназга урынсыз тоелды бугай:

– Ах син, тел бистәсе, олылар янында тик кенә утыр, тының чыкмасын, – дип, малайны туктатырга теләгән иде.

– Зыян юк, сораштырсын, кызыксынучан, төпченүчән булып үссен, – диде әти. – Минем битләрем дә сезнеке шикелле шома иде. Кайчандыр Мансур яшендәге бер малайны ут эченнән алып чыкканда каты пештем, врачлар үлемнән көчкә саклап калдылар, тәнемнең көйгән җирләренә ямау салдылар, җөйләделәр.

Әтинең бу сүзләреннән, Мансурдан бигрәк, Сәрвиназ ныграк әсәрләнде, дулкынлануын тыя алмыйча:

– Коточкыч бәла булган икән, ничек түзмәк кирәк, – диде ачыну белән.

Ә Мансурның үз туксаны-туксан, әнкәсе сүздән туктауга:

– Әюп бабай, ник син бер дә безгә килмисең, әллә юлны белмисеңме? – дип сорады. – Без хәзер Аракчинода Зариф бабайларда торабыз. Шунда кил, бергәләп моторкада йөрербез, балык тотарбыз... Моторканы мин хәзер үзем дә йөртә беләм инде. Биноклем дә бар, әти бүләк итеп бирде.

– Дөрестән дә, әлегә чаклы белми идем, менә син әйткәч, хәзер белдем. Мин, әлбәттә, сезгә килермен, – диде әти, Мансурның башыннан сыйпап.

***Ышаныргамы, юкмы?***

Безнең Кама елгасына гравий чыгару районына командировкага баруыбыз әнә шундый авыр фаҗига белән тәмамланды. Ул хакта сатлык җаннарны гаепләп, шулар аркасында һәлак булган пешекче кызларны кызганып язылган үзәк өзгеч бәет көне-сәгате белән тирә-юньдәге шәһәр, авылларга, пристаньнарга таралып, халык күңеленә шом салды.

Бу фаҗигадән соң бераз хәлем җиңеләйгәч, Сәрвиназ мине Аракчинога үзләренә алып кайтты. Менә икенче ай инде мин монда, Сәрвиназ эштә вакытта Зариф бабай белән улым Мансур тәрбиясендә яшим. Әти әле һаман командировкада, ватылган баркасны Чистай заводында ремонтлата. Ара-тирә хәл белергә бергә эшләүче иптәшләрдән берәрсе килгәли.

Беркөн транспорт милициясеннән тикшерүче килеп озак төпченде. Башта ул миңа авария турында, сәрхуш түрәләр, аларны зурлап сыйлаучы артык кунакчыл хуҗалар турында сораштырыр кебек тоелган иде. Ә ул, исем, фамилия, адрес кебек формаль мәгълүматларны язып алганнан соң:

– Әйтегез әле, гравий чыгару районыннан кайткач, сезгә монда шеф-повар Солтанов Бәдретдин белән очрашырга туры килмәдеме? – дип сорады.

– Чү, ни сөйлисез сез?.. – дидем шаккатып. – Шеф-повар Бәдретдин Солтанов авария вакытында һәлак булды бит ул, үлгән кеше белән ничек очрашыйм мин?!

Хәзер инде тикшерүче аптырап калды:

– Туктагыз әле, ни сөйлисез сез? – Әниегез сезгә берни дә әйтмәдемени? – дип, сөйләнә-сөйләнә кара күн тышлы портфеленнән кәгазь чыгарды. – Әнкәгез милиция бүлегенә биргән гариза бу. Анда авария булган төннең иртәгесен Бәдретдин Солтановның сезгә кайтуы, әниегез базарга киткән арада, аның алтын балдак-беләзекләрен, асылташлы алка, муенсаларын, алтын корпуслы кул сәгате, миллион сумнан артык акчасын, сатып алынган ваучерларын урлап качты дип язылган. Әниегезнең әйтүенә караганда, ул хәзинәнең күп өлеше шәхсән сезнеке исәпләнә... Дөрестән дә шулаймы, ул тикле алтын, акча, ваучерлар чынлап та булганмы, аның күп өлеше сезнекеме?

– Нинди хәзинә, нинди ваучер ул... Белмим, һич күргән, ишеткән нәрсәләрем түгел.

Бу минем өчен һич тә көтелмәгән яңалык булды. Кара син ә, әнинең иң ышанычлы, һәр эшкә оста зирәк кешесе әнә кем булып чыккан, имеш...

– Ихтимал, белмәвегез бик ихтимал, әнкәгез астыртын кешегә охшаган, – диде тикшерүче. – Авария вакытында энегез Артур Солтанов һәлак булган, кайгылы көннәрегез икән...

– Штурман Артур минем туганым түгел, кем беләндер бутыйсыз бугай, – дидем.

Инде чыгып китәргә кузгалган тикшерүче кире урынына утырды, портфелен ачып, тагын нәрсәдер алды. – Менә штурман Солтанов кесәсеннән алынган паспорт, суда шактый җебегән булса да, хәрефләрен танырга мөмкин әле. Монда аның гаилә хәле буйдак, этисе Солтанов Бәдретдин, әнкәсе Маликова Миләүшә дип язылган. Әтиләрегез төрле кеше булса да, сез икегез дә бер ана балалары, димәк, бертуганнар. Нәрсә бу, кан-кардәш энегезне белмәгән булып кылануыгызмы?!

Тикшерүченең сүзләренә ышанмадым, паспортны кулыма алып, үзем укыдым һәм, дөресен әйткәнен күреп, бик аптырап калдым. Әнинең дә, Артурның да, Бәдретдин абыйның да ул хакта һични әйткәннәре юк иде бит. Тикшерүче каршында уңайсыз булып китте.

– Моңарчы белми идем, хәзер ышанырга мәҗбүрмен... Шикләнеп каравым өчен кичерегез мине, – дип гафу үтендем.

Тикшерүче ихтирамлы кеше икән, миннән рәтле мәгълүмат ишетә алмаса да, борчыган өчен гафу үтенеп, үз юлына китеп барды. Ә мин башка сыймаслык авыр уйларга батып калдым. Кайчандыр колхозга кәбестә алышырга барганда Артур белән беренче тапкыр очрашкан, баркаста бергә эшләгән чакларны, гел салмыш йөрүләрен хәтерләп утырам. Әмма аны бертуган энем итеп һич күз алдыма китерә алмыйм, андый хәл ничектер табигый күренеш түгелдер шикелле.

Тагын шунысы бик сәер: бу хәл мәрхүм Артурга мәгълүм булды микән, әгәр булса, миңа ник сиздертмәгән икән? Әлегә тикле мин этиемне белмәгән кебек, әллә ул да әнисен белмәгән микән?..

### *Әнине кем талаган?*

Мин Аракчинода тора башлаганнан бирле әнинең килгәне юк иде. Бүген шәһәр базарыннан кайтышлый, ул сугылды. Почмак тәрәзәдән карап тордым, кеше-кара күрмәсен дигәндәй, як-ягына карана-карана бакча яктан гына керде. Редиска, кыяклы суган саткан булса кирәк, кулында буш кәрзин. Өйдә үзем генә икәнне күргәч, кыюлана төште, һичкайчан булмаганча якты чырай белән:

– Син анда зур бәхетсезлеккә очрагансың, чак кына башың бетмәгән икән. Шуны ишетеп, хәлеңне белергә килүем ие, – дип сораштырган булды. Аннары, минем җавап биргәнне дә көтеп тормастан, үзенең бәлагә таруы, кемдер кыйммәтле әйберләрен урлап чыгуы турында үрсәләнеп зарланырга кереште. – Бәдретдин урлаган булса кирәк, әйберләрнең кайда икәнен ул гына белә ие. Соңгы вакытта милиция еш кызыксына башлагач, каядыр ычкынып, эзен югалтырга җыена иде. Һичшиксез, шуның эше, шул урлап качкан. Ул хакта милициягә биргән жалобамда да только шуннан шикләнәм дип яздым... Улым, игътибар белән тыңла, тагын менә нәрсә: ул жалобада мин җыен алкашлардан сатып алган ваучерларны синеке, ә алтын беләзек, йөзек, балдакларны Сәрвиназныкы дип язган ием. Икегез дә белеп торыгыз, килеп сораштырсалар-нитсәләр, зинһар, шулай дип, безнеке дип әйтә күрегез. Юкса шултикле акчаны ничек җыйдың, кайдан алдың дип төпченүләре бар.

Мине ятим бала кебек әтисез үсәргә дучар иткән, Сәрвиназны рәхимсез җәберләп гаиләмне җимерә язган тар күңелле әнигә ни әйтергә белмичә сүзсез калдым. Бер-беребезнең эчке уйларын аңларга теләгәндәй, беравык күзгә-күз төбәлеп торганнан соң:

– Син зиһенле, үткен күзле хатын бит, – дидем. – Гомер буе хәерсез тормышта яшәвеңне менә хәзер, упкын читенә барып чыккач кына күрдеңмени?! Әмма мин сиңа берничек тә ярдәм итә алмыйм.

– Ничек инде ярдәм итә алмыйсың? Тудырган әниеңә булышырга теләмисеңмени, әллә хатының ачуланудан куркасыңмы?! – диде әни, кинәт агарынып.

– Теләмәүдән дә, куркудан да түгел. Чөнки тикшерүче синнән элегрәк монда булып, миннән сорау алды инде. Аннары син бу гаепне Бәдретдинеңә ягып ялгышмыйсың микән? Әлегә тикле мәете табылмаса да, ул авария вакытында һәлак булган санала бит.

– Юк, үлмәгән ул... Әгәр үлгән булса, мин шәһәргә чыккан вакытны, безнең ишекләрне ачып, өйгә керә алмас ие.

– Бәлкем, ул булмагандыр, башка берәү ачкыч яратып кергәндер. Хәзер андый осталар аз түгел, аның саен квартира басып чыгалар.

– Бүтән кеше керсә, идән астында күмелгән чүлмәкне таба алмас ие... Соңгы вакытта ниндидер теплоходта буфетчы булып эшләүче яшь кәнтәй белән бутала башлавы сизелә ие, шуның белән кыяклаган, димәк. Мин бит аңа үземә ышанган кебек ышана ием, ләгънәт төшсен үзенә!..

Авыр хәсрәт баскан, юка иреннәре дер-дер калтыраган әни әнә шулай сөяркәсен каргый-каргый бездән чыгып китте.

### *Әти кайтып төште*

Бүген төштән соң Чистайдан, заводта баркасны карап ремонтлаткан җирдән, әти кайтып төште. Ишектән керүгә каршына йөгереп барып сарылган Мансурны күтәреп кочаклады:

– Исән-саумы, үскәнем... – дип, күкрәгенә кысты, сумкасыннан алып, кул сәгате хәтле генә түгәрәк уенчык бирде. – Компас бу, диңгездә корабларга юл күрсәтә торган прибор. Урманда адашсаң, сиңа да дөрес юл табарга ярдәм итәр.

Мин аны Сәрвиназның әтисе Зариф бабай белән таныштырдым. Хәл-әхвәл белешеп, бераз тын алгач, без, яр астына төшеп, Иделдә су коендык. Мансур һаман Әюп бабасы янында мәш килде, басма өстеннән баштүбән суга чумып күрсәтте, колачлап йөзә белүе белән мактанды, компасны карап горизонт якларын күрсәтте.

Без су буеннан менгәндә, Сәрвиназның табыны әзер иде. Яңа өлгергән редиска һәм яшел суганнан салат ясаган, көндез Зариф бабай белән Мансур алып кайткан мәрсин балыгыннан уха пешергән. Бабайның былтыргы җиләк-җимеш вареньесыннан әчеткән ширбәте бар иде, хрусталь графин белән өстәл уртасына шуны китереп утыртты. Очрашу хөрмәтенә берәр рюмка бушатып, азрак капкалап алганнан соң, әңгәмә корып, ике кода бер-берсе белән якынрак таныштылар. Аннары сүз безнең баркас фаҗигасенә күчте, әти аны махсус комиссия килеп җентекле тикшерүе турында сөйләде. «Зөя» не ремонтлау көзгә тикле сузылачак, савыгып аякка баскач, мин дә шунда әтигә ярдәмгә барачакмын икән.

Табын янында гәп корып утыра торгач, шактый вакыт үтте, кояш түбәнәйде, әти кайтырга җыена башлады. Аны бер яктан мин, икенче яктан Мансур җитәкләп, поездга озата иттек. Урам буйлап сөйләшеп барганда, станциягә җитәрәк, әти мине үзе култыклап алды, эчке дулкынлану белән:

– Шулай да бәхетебез бар икән, озак еллардан соң булса да, ниһаять, табыштык бит. Безнең өчен иң мөһиме шул... – диде. – Синең өчен мин бик шатмын, шундый болгавыр кешеләр арасында намуслы булып үскәнсең. Комсыз түгел, күпләр кебек эчүчелеккә бирелмәгәнсең, әйбәт гаилә коргансың. Сәрвиназың да, улың Мансур да әйбәтләр. Бер-берегезнең кадерен белеп, матур гомер итегез.

Бер-беребезне табышканнан бирле әтигә әйтергә уңайсызланып йөргән сүзем бар иде. Станциягә барып җитәрәк, менә шул тел очыма килде:

– Әткәй, синең гаиләң бармы, кайда, кем белән торасың? – дип сорадым.

– Гаиләм бар иде, бик тату тора идек, былтыр Казанга кайткач, җәмәгатем вафат булды. Татарстан урамында ике бүлмәле фатирда торам. Болай һичнигә мохтаҗчылык күрмәсәм дә, төзәлмәс яра кебек гел бер хәсрәт – синең табылмавың интектерә иде. Аллага шөкер, менә сез табылдыгыз, инде бергә яши башларбыз.

Тиздән поезд килеп җитте. Без әтине вагон ишегенә тикле озатып куйдык. Шунда аерылышыр алдыннан Мансур аны иелдереп, бәләкәй куллары белән муеныннан кысып кочаклап алды да:

– Син әйбәт бабай, иртәгә тагын кил яме... Мин көтәрмен, бергә балыкка барырбыз, – дип, битләреннән үбә-үбә саубуллашты.

Мансурның дулкынлануы миңа да күчте, кинәт нарасый балага әверелгәндәй булдым, әтине кочаклап үптем. Сабый авызыннан ихлас әйтелгән җылы сүзләрдән аның күңеле тулды, күрәсең, әсәрләнүе йөзенә чыкты. Тиз генә иелеп, Мансурның колагына калтыраган ягымлы тавыш белән:

– Килермен, үскәнем, әлбәттә, килермен... Бүгенгә хушыгыз, җанкисәкләрем... – диде һәм күз төбендәге шатлыклы яшь бөрчекләрен кул аркасы белән сөртеп алды.

Вагон эченә кергәч, ул ачык тәрәзәдән кул изәп елмайды. Без аны поезд күздән югалганчы кул болгап озатып калдык:

– Хуш, әйбәт бабай, иртәгә тагын кил, без көтәрбез...

– Хәерле юл, газиз әткәем, сау бул...

## Ике капитан

*(Зәйтүнәнең икеләнүле кичерешләре)*

### I

Зәйтүнә бүген дә иртүк уянды.

Гаҗәп хәл, элек һәр көн иртән торып эшкә барырга кирәк булганда, ул йокыдан уяна алмыйча йөдәп бетә һәм еш кына эшкә дә чак кына соңармый торган иде. Ә хәзер, ялга чыккач, үч иткән кебек, никтер иртүк уяна торган булып китте һәм, гомумән, вакытын ничек үткәрергә белми аптырый башлады.

Кышкы айларда затонда торганда, аны Илбарис уята торган иде. Илбарис үзе уяна, үзе чәен әзерли, акрын гына ашап-эчә, өстенә киенә һәм тик шуннан соң гына Зәйтүнәне уята. Бик ашыккан чакларда да ул, чыгып китәр алдыннан, ишек янында тукталып кала һәм, сүзсез генә саубуллашкандай, сизелер-сизелмәс кенә елмаеп, бермәл Зәйтүнәгә карап тора. Аннары, кире килеп, саклык белән генә аның одеялын рәтләбрәк куя, ак мендәр өстендә тузгып яткан кара чәчләреннән сыйпап ала. Ә Зәйтүнә, инде уянган булса да, әле һаман йоклагандай күзләрен ачмыйча юри дәшми ята һәм Илбарис чыгып киткәч кенә, тизрәк торып, ашыга-ашыга өстенә киенә башлый иде.

Ә менә бүген янында Илбарис та юк, торып эшкә ашыгасы да түгел. Бөтен өй эче ничектер шыксыз кебек. Өченче көн дә, кичә дә шулай кызыксыз үтте. Ел буе көтеп алган бөтен ялы шулай өй саклап күңелсез үтәр микәнни?..

Бер уйларга тотынсаң, башка ниләр генә килми. Хәтта хәтерләве ничектер уңайсыз булган вакыйгалар, кешеләр искә төшеп йөдәтә. Әнә Илбарис белән бергә эшләүче капитан Әсәдуллин да әллә кайдан гына искә төште дә һич тә күз алдыннан китми бит. Һаман бер читтән көлемсерәп карап торадыр кебек...

Шул чак телефон шылтырады. Иңенә кыска җиңле зәңгәр халатын гына салып, трубканы күтәрде, Илбарис икән. Телефоннан аның:

– Зәйтүнгөлем, Иделдән сәлам сиңа! – дип кычкырган шат тавышы ишетелде. – Причалдан шылтыратуым, әле генә килеп туктадык... Тиздән монда митинг булачак, бөтен начальство килә бугай: безнең теплоходка күчмә вымпел тапшырачаклар... Югыйсә йөгереп кенә кайтып килгән дә булыр идем... Ишетәсеңме, кайтып килгән дә булыр идем, мин әйтәм... – Илбарис тагын нидер әйтмәкче иде бугай, әмма никтер тыелып калды һәм, әйтер сүзен таба алмаган кеше кебек, тамагын гына кырып куйды.

Зәйтүнәнең кинәт ачуы кузгалды:

– Йә, йә авызыңа су алдыңмы әллә? Балык кебек телсез калдың, – дип, иренә ташланды ул. – Их, үзеңне дә әйтер идем, бу тикле дә җебегән җан булырсың икән... Күпме күрми торган хатыныңа сагындым дип тә әйтә белмисең...

Илбарисның еш кына шулай тыелып кала торган гадәте бар. Зәйтүнә аны шуның өчен өнәп бетерми дә. Кайчакларда, үзе дә абайламастан, аңа төксе сүзләр дә әйтеп ычкындыра. Менә хәзер дә әле һаман ачуын тыя алмыйча:

– Әйдә, авызыңдагы суыңны йот та әйтәсе сүзеңне әйтеп бетер, – дип, ихтыярсыз тагын бер мәртәбә төрпә генә чәнчеп алды. Аның күз алдына тагын өйдәге эчпошыргыч ялгызлык килеп басты, һәм ул үзе дә көтмәгәндә, кисәк кенә башына килгән ниятенә шатланып тезеп китте. – Илбарис, беләсеңме нәрсә?.. Сезнең белән бергә мин дә китәргә булдым... Әйе, әйе, мин дә сезнең белән рейска китәм, дим... Мин хәзер ялга чыктым бит, өйдә берьялгызым бикләнеп ятканчы, дөнья күреп кайтырмын, ичмасам. Хәзер тиз генә җыенам да юлга чыгам.

– Монда сиңа күңелсез булыр, ник килгәнеңә генә үкенерсең. Без пассажирлар йөртмибез ич, – дип, Илбарис аны дүндермәкче дә булган иде.

Әмма Зәйтүнә авыз ачарга да бирмәде:

– Юкны сөйләп тә торма... Барам булгач, барам инде, менә шул! Хәзер чыгам да чабам. Бер аягым монда, икенчесе – пристаньда...

Һәм Зәйтүнә шулай эшләде дә. Аннан-моннан тиз генә җыенып, кулына күн чемодан алды да, шат күңел белән, яр буйлап турыдан гына җил-җил атлап пристаньга ашыкты.

Иске пароход һәм баржалар тулы кысынкы затоннан елга буена чыккач, аның күңеле тагын да ачылып китте. Кая карама, чиксез киңлек. Кояш нурына чумган Идел әллә кайларга җәелгән. Түбәндә, яр итәгендә, меңнәрчә көмеш тамчылар җемелдәтеп, ярга вак дулкын кага, төрле кошлар сайрый. Зәйтүнәнең дә күңеле җырлый.

Аның элемтә техникумында укыган вакытта ук әле Илбаристан еш кына көлеп җырлый торган бер җыры бар иде. Яр буена чыгып киң Иделне күрүгә, ул тагын шул җырын авыз эченнән генә көйли башлады.

Идел бит ул, тирән бит ул,
Тирән бит ул, киң бит ул.
Сөйгән ярың кыю булмаса,
Яшь йөрәккә кыен икән шул...

Пристаньга җитәрәк, вокзал мәйданында, ыгы-зыгы агылып торган халык арасыннан бер елгачы Зәйтүнәгә ничектер таныш кебек күренде. Рәтләбрәк караса, Әсәдуллин икән.

Зәйтүнә почмактагы киоск артында тукталып, ридикюль көзгесенә карый-карый, кульяулыгы белән тиз генә күз төпләрен сөртте, маңгаена салынып төшкән чәч бөртекләрен киң читле эшләпәсе астына кыстырып куйды. Шунда ук, «Күр инде мин юләрне, ничек кыланам!» дип, үзенә-үзе гаҗәпләнде һәм кем беләндер бик күңелле көлә-көлә сөйләшеп килүче Әсәдуллинга каршы чыкты.

Сумала кебек чем-кара чәчле, хәйләкәр елмаеп караучан зур калку күзле, төз-таза гәүдәле бу япьтәш егет, былтыр затонда кышлаганда, Зәйтүнә тирәсендә байтак бөтерелгән һәм кыз күңелендә мәхәббәт чаткысы да уяткан иде. Ләкин ул чаткы ничектер дөрләп кабынып китми калды. Кызның күңеле гел элекке дусты Илбариста булды. Әнисе дә шул якны тартты. Сүз уңае туры килгән саен:

– Кайбер кызыл авызлар кебек ләчтит сатарга оста булмаса да, гомер итү өчен бик төпле егет, – дип, гел Илбарисны мактады һәм көннәрдән бер көнне бик шатланып кызын аңа кияүгә бирде.

Шулай да күренекле егет, зур теплоход капитаны Әсәдуллин Зәйтүнә күңеленнән бөтенләй үк югалмады. Инде тормышка чыкканнан соң да, ул еш кына Зәйтүнәнең исенә төшкәли, очрашкан минутларда төрле уен-көлке, йөрәккә ятышлы сүзләре белән аның күңелен иркәли иде. Хәзер, Зәйтүнәне күргәч тә, гадәтенчә ачылып китте:

– Чү! Кемне күрәм мин?! Өнемме бу, төшемме? – диде ул, Зәйтүнәнең чемоданын алып. – Нинди җилләр монда алып чыкты сезне?

Көтелмәгән бу очрашуга Зәйтүнә үзе дә бик шат иде.

– Дөресен генә әйткәндә, нинди җилләр алып килгәнен үзем дә белми калдым. Иделдә бер йөреп кайтасым килде. – Зәйтүнә уң якка – кояшка елмаеп салмак кына чайкалган киң елгага карап алды. – Күп кешеләр әллә кайлардан килеп Иделне буйдан-буйга гизәләр, елларын пароходта үткәрәләр. Өйдә бикләнеп ятканчы, мин әйтәм, миңа да никбер дөнья күреп кайтмаска...

– Бик тә шәп, Зәйтүнә, бик әйбәт иткәнсез... Башкалар ничектер, белмим... Мин үзем сезнең килүгә бик шатмын. – Бу сүзләрне аеруча басым ясагандай, Әсәдуллин буш кулы белән Зәйтүнәнең терсәгенә чак кына кагылып та алды. – Җитмәсә, тагын нинди шатлыклы көнгә туры килдегез... Бүген бездә зур бәйрәм бит. Күрәсезме, «Урал»ны ничек бизәдек!..

Причалда ялгызы гына торган йөк ташучы «Урал» теплоходы чынлап та әле генә заводтан чыккандай өр-яңа һәм сокландыргыч матур иде. Каюта тәрәзәләре, трапларның тоткалары кояшта җемелди. Акка буялган биек мачтасы очында кызыл флаг, аннан бераз гына түбәндәрәк күчмә вымпел җилферди. Палубасында бәйрәмчә киенгән бер төркем яшьләр. Кызыл почмакның ачык тәрәзәсеннән әйләнә-тирәгә музыка яңгырый. Ә трюмнарына траспортерлар буенча бертуктаусыз кар кебек ак тоз агып тора иде.

Яр буена килеп җиткәч, Әсәдуллин, калку күзләрен зур итеп ачып, бермәл сокланып карап торды һәм, үзалдына сөйләнгәндәй, горурлык белән сөйләп китте:

– «Урал»ны әйтәм, чын баһадир бит!.. Без дә молодец, сынатмадык, шәп эшләдек. Идарә начальнигы безне социалистик ярыш флагманы, дип мактады. Күрәсезме, бөтен команда нинди шат... Ә минем өчен бүген икеләтә бәйрәм... Әйе, әйе, чынлап әйтәм, икеләтә бәйрәм...

Зәйтүнә аның тел төбе кая тартканын аңламыйча:

– Ничек инде икеләтә бәйрәм? – дип кызыксынып сорады. – Икенчесе ни була инде аның?..

– Әйе, Зәйтүнә, миңа бүген ике бәйрәм берьюлы килде. Берсе бөтен команда белән уртак бәйрәм – навигация планын Иделдә беренче булып үтәү шатлыгы. Ә икенчесе... икенчесе синең килүең... сине күрү шатлыгы...

Аларның транспортерлар яныннан сөйләшә-сөйләшә төшеп килгәнен теплоход палубасыннан да күрделәр. Арадан бер усал теллесе бик хәйран калган кыяфәт белән пырхылдап көлеп җибәрде:

– Туганкайларым, күрегез әле безнең көязне, нинди чибәрне эләктергән... Менә бу балыкчы... Әйтсәң дә ярый ичмасам...

– Син нәрсә, төнлә туган җан, күзеңне кан басты мәллә?.. Күрмисеңмени, безнең беренче штурман хатыны бит ул, – дип, кемдер аны шундук бүлде һәм каюталар ягына борылып хәбәр итте: – Илбарис Рамазанович, сезгә кунак килә, каршылагыз...

Зәйтүнә белән Әсәдуллин причалдан палубага күтәрелгәндә, ачык коридордан ак кителен төймәли-төймәли, Илбарис үзе килеп чыкты.

– Әһә, килеп тә җиттеңмени? – диде ул, сыгылмалы такта траптан менеп килгән Зәйтүнәне каршылап. – Үзең дә бер дә чикерткәдән ким түгел инде, бик тиз килеп җиткәнсең.

– Анысы да монысы, Илбарис дус, син башта миңа рәхмәт әйт. Әгәр мин очрап туктамасам, безгә килү Зәйтүнәңнең башында да юк иде, – дип, Әсәдуллин да шаяртып алды һәм кулындагы чемоданны Илбариска бирде.

Шул чак причалга бер матрос белән милиционер килеп туктады. Палубадагылар, үз күзләренә ышанмагандай, бер-берсенә аптыраулы карашып алдылар. Милиционер китергән киң җилкәле, базык гәүдәле ул матрос кем беләндер сугышкан булса кирәк, әле тынычланып та өлгермәгән; ачык изүле күлмәгенең зәңгәр якасы ертылган, сул күзе өсте дә бераз сыдырылган иде. Аны озата килгән милиционер фуражкасына кулы белән хәрбиләрчә, җиңелчә генә кагылып исәнләшкәннән соң, Әсәдуллинны бер читкәрәк дәшеп алды да:

– Иптәш капитан, менә бу сезнең егет бугай. Буфет янында ниндидер матрослар белән тавыш куптарып сугышып йөри иде, – дип хәбәр итте. – Менә бит ничек... Үзе болай әллә ни исерек тә түгел шикелле. Без аны бүлеккә илтеп тоткарлап тормадык инде, бая гына бөтен халык алдында вымпел алган коллективка тап төшерәсе килмәде... Чарасын үзегез күрегез...

Әкрен генә әйтелгән булса да, бу сүзләрне палубадагы кешеләр барысы да ишетте. Әсәдуллин гаепле матроска калку күзләре белән көйдереп алырдай зәһәр караш ташлады. Әмма шунда ук үзен кулга алды, телдән ачуын сиздермәде, хәтта елмаеп та куйды шикелле.

– Рәхмәт, туры монда алып килеп дөрес эшләгәнсез. Чарасын күрербез. Үзем күрермен... бүтән кабатланмаслык итәрмен, – дип, милиционерга вәгъдә бирде һәм саубуллашып аның кулын кысты.

## II

«Урал», киң елганы урталай ярып һәм үз артыннан йөгерек дулкыннар калдырып, агымга каршы кузгалып китте. Өске палубасында бәйрәмчә киенгән матрослар, моторчылар, рулевойлар һәм

практикантлар җыелган. Арадан әле берсе, әле икенчесе мәзәк әйтеп халыкны көлдереп ала иде. Менә кичәне алып баручы, үзе дә бик җор кеше механик Федор Степанович, команда членнарыннан кемгәдер охшатып, әйтер сүзен оныткандай аптыраулы кыяфәт белән:

– Әйе, әйе, хәтерләдем... Хәзер теплоходыбызның атказанган солисты Харис Әсәдуллин җырлый, – дип белдерде. – Ул безгә «Дуслык елгасы» җырын башкара... Харис, шулай бит?..

Шаяртып әйтелгән бу сүзләрдән барысы да көлешеп алдылар. Әмма уртага чыгып баскан җырчы үзе хәтта елмаймады да. Ул никтер караңгы чырайлы, соргылт күзләренең карашы каядыр читкә юнәлгән иде. Зәйтүнә аны ирексездән кызганып куйды һәм янында утырган Наташаның колагына пышылдап кына:

– Карагыз әле, ни булган бу егеткә? – дип сорады. – Ә үзе сезнең капитаныгызга охшаган кебек.

Бу минутта Наташа ниндидер уйга чумып утырган булса кирәк, Зәйтүнә эндәшкәч, кинәт йокыдан уятылган кеше кебек, бөтен гәүдәсе белән сискәнеп китте һәм әйләнә-тирәгә каушаулы карап алды.

– Бертуган абыйсы булгач, охшаса да гаҗәп түгел, – диде ул. – Әмма холыклары белән алар бер-берсенә аз гына да охшамаганнар. Абыйсы гел чит күрә аны... Бүген пристаньда кемнәр беләндер ызгышкан өчен хәтта бөтенләй теплоходтан төшереп калдырырга ук җыена бугай...

Пристаньда күргән вакытта Зәйтүнә игътибар белән карамаган булган икән. Тик менә хәзер Наташа әйткәч кенә, Зәйтүнә аның көндез причалда милиционер китергән егет икәнлеген төсмерләп алды. Абыйсының аны ник үз итмәвен белергә теләп, ул Наташага тагын сорау бирмәкче булган иде, ләкин шул арада баянчы уйный башлады, һәм Харис күкрәген тутырып бер тирән сулыш алды да озын көйгә җырлап җибәрде:

Иделкәем минем, туган җирнең
Матурлыгын күрәм суыңда.
Иделкәем минем, җырым да син,
Ерак илтә торган юлым да...

Башта бераз кыюсызрак яңгыраса да, аның ачык тавышы бик тиз ныгыды һәм эчке киеренкелек һәм моң белән кичке Идел өстендә дулкын-дулкын тирбәлеп таралды, үзе белән бергә тыңлаучыларны да ерак-еракларга алып китте:

Маякчы маяклар тезгән
Минем юл читләренә,
Кая гына юл тотсам да,
Ышанам җитәремә...

Аннан соң тагын берничә кеше җырлады, төрле мәзәк һәм декламация сөйләүчеләр дә, биючеләр дә булды. Шаян җырлардан, күңелле мәзәкләрдән рәхәтләнеп көлделәр, моңлы җырларны тын алмыйча тирән уйга талып тыңладылар.

Беренче җырдан күңеле тулган Зәйтүнә башкаларны әллә ни бирелеп тыңлый алмады. Колагында һаман Харис тавышы яңгырап торды. Аңа карап алган саен, күңеленнән ихтыярсыз, «Нәселләре белән шундый нечкә хисле булырлар икән... Тик шунысы бик сәер, ник алар үзара килешә алмыйлар, бер-берсен чит күрәләр икән?» дип уйлады.

Бераздан, биюләр башлангач, Зәйтүнә кызыл почмак тәрәзәсе каршына килеп басты һәм Федор Степанович белән әңгәмә башлап җибәрде. Озакламыйча алар янына Әсәдуллин да килде. Пөхтә итеп үтүкләнгән ап-ак кителе, кара чалбары аның төз гәүдәсенә килешеп тора, янәшә якын урнашкан калку күзләре биек фуражкасы астыннан ягымлы елмаеп карыйлар иде.

– Нигә болай читтә генә утырасыз? – диде ул, ак тешләрен ялтыратып. – Әйдәгез, алгарак күчик. Күрик әле, ничек бииләр икән?

Федор Степанович көтмәгәндә кулларын җәеп җибәрде дә Әсәдуллинны шелтәли башлады:

– Их, Якуб Хисамович, карап торам-торам да аптырап калам... Без егет чакта туташ-ханымнарны биергә чакыра идек, ә син урын турында сөйләнеп вакыт уздырасың... Сиңа берәр ни булмагандыр, йөрәгеңә йон үсмәгәндер ич?..

– Әйе, әйе, Федор Степанович, әйтәсе дә түгел инде, – дип, Зәйтүнә дә шаяртып аны җөпләгән булды. – Хәзерге егетләрне белмәссең... Колакларына тукып тормасаң, үз башлары җитми, күрәсең...

– Федор Степанович дөрес әйтә, гаеп миндә... Әлеге дә баягы, һаман шул сәбәп – кыюсызлык һәм булдыксызлык бәласе. Зәйтүнә, сез мине гафу итегез инде һәм хатамны төзәтергә мөмкинлек бирегез, – диде Әсәдуллин һәм, яңа вальс яңгырый башлауга, Зәйтүнәне биергә алып чыкты.

Әсәдуллин затон клубында иң оста биючеләрдән санала һәм еш кына, әллә нинди яңа биюләрне беренче башлап, бик күп кызларны сокландыра иде. Алай ук оста булмаса да, Зәйтүнә дә биюгә бик һәвәс һәм, кайбер шаян телләр әйтмешли, «аяктан егылганчы» биергә ярата торган иде. Оста биюче чибәр егет белән күңелле вальска бөтерелә башлауга, ул йөгерек дулкыннар арасында йөзеп киткәндәй булды, бөтен тәнендә рәхәт җиңеллек хис итте. Әсәдуллинның ашкынып бөтерелә-бөтерелә биегән шәпкә:

– Башкалар ничектер, белмим, ә мин үзем синең килүеңә чиксез шатмын, – дип, колагына пышылдап әйткән кайнар сүзләре аның күңелен тагын да нечкәртә төштеләр.

Һәм ул, һич тә ышанмаудан түгел, тик болай гына, матур комплименттан бераз уңайсызлануын сиздермәс өчен генә:

– Алай ук түгелдер лә инде... Шулай көләргә ярыймыни? – дип шаярткан булды.

– Юк, Зәйтүнә, һич тә алай түгел... Син һәрвакыт минем исемдә. Синең турыда уйласам да, йөрәгемә ял була минем, күңелләрем күтәрелеп китә...

Әсәдуллин, башка кешеләр алдында Зәйтүнәгә сез дип дәшсә дә, икәү генә калган чакларда, еш кына, ничектер абайламастан гына, «син»гә күчә һәм әңгәмәне бөтенләй икенчегә борып җибәрә иде. Менә хәзер дә ул, бермәл сүзсез генә биегәннән соң:

– Бөтен бәла дә әнә шунда – синең миңа ышанмавыңда шул, – дип, өметсезлек белән көрсенеп куйды. – Әгәр ышансаң, без инде дөньяда иң бәхетле кешеләр булыр идек...

Сүзнең кинәт җитди сукмакка борылып керүеннән, Зәйтүнәгә бөркү булып китте. Кем белгән аны, бәлкем, чынлап та шулайдыр. Ышанмаган булып, үз бәхетен үзе кире какмыймы соң ул?..

Моннан соң алар инде сүзсез генә биеделәр.

III

Төн уртасы җитәрәк халык таралды. Кызыл почмакта һәм палубада утлар сүндерелде. Бөтен теплоходны караңгы тынлык басты.

Каютага кергәч, Зәйтүнә, Илбарисның вахтадан төшкәнен дә көтмәстән, тиз генә чишенеп йокларга ятты. Ләкин аның күзенә йокы кермәде, уйлардан арына алмыйча, зур ачылган күзләре белән караңгыга карап байтак ятты. Аннары тәрәзә янына килеп басты. Ачык тәрәзәнең ак пәрдәсен сизелер-сизелмәс кенә тирбәтеп кергән төнге салкынча дымсу һава аның ачык муеныннан, битләреннән иркәли, рәхәт җиңеллек бирә иде.

Зәйтүнә тәрәзәнең пәрдәсен яртылаш этәреп тышка карады. Дөньяны төн карасы баскан. Әйләнә-тирәдә серле тынлык. Кайдадыр түбәндә, бөтен теплоходны сизелер-сизелмәс кенә дерелдәтеп, машина гүләве һәм йокымсыраган дулкыннар чайкалуы ишетелә... Идел үзе дә изрәп йокыга талган кебек. Караңгы су өстендә анда-санда калкавыч маяклар гына җемелди. Алар төн пәрдәсе аша кайдандыр килеп чыгалар да артта калып тагын караңгылык эченә югалалар.

Зәйтүнәнең тынгысыз уйлары, шул маяклар кебек, бер-бер артлы калкып чыгалар да артта калган көннәрен исенә төшереп үтәләр. Соңгы айларда ул, гомумән, күп уйлана торган булып китте һәм уйланган саен күңелендә бушлык, ниндидер ризасызлык барлыкка килүен сизә башлады.

Әле кайчан гына Зәйтүнә төшенкелекнең нәрсә икәнен дә белмәгән гамьсез, шаян кыз иде. Ул кечкенәдән бик шук һәм үткен телле булып үсте. Бигрәк тә ул күрше малае Илбаристан көләргә ярата торган иде. Һәрвакыт бар дөньясын онытып, әллә ниләр ясап йөргән өчен аны Хыялбай дип атаучы да, үсә төшкәч, елга техникумына укырга озаткан чакта, «Бар, капитан Немо булып кайт» дип көлеп калучы да Зәйтүнә булды.

Биш елдан соң затонга кайткач, Илбарисны уйламаганда-көтмәгәндә клубта очраткач, Зәйтүнә күзләренә ышанмыйча хәйран калып озак карап торды. Аптыравын яшерә алмыйча:

– Кызлар, күрегез әле, безнең Илбарис түгелме соң бу?! – дип, бик гаҗәпләнде. – Күрегезче үзен, кай җире капитан Немодан ким моның?! Бер караудa гашыйк итәрлек... Хәтәр, бик хәтәр... Син монда безнең барыбызның да башын әйләндереп бетермәгәең...

Бу сүзләрне ул болай шаяртып кына, егетнең үзен бераз каушатырга теләп кенә әйткән иде. Әмма уеннан уймак чыга, диләр. Көлеп кенә әйткән сүзнең бик тиз чынга әйләнгәнен үзе дә сизми калды ул. Кайчандыр чандыр гына буйлы, оялчан карашлы яшүсмер киң җилкәле, сабыр хәрәкәтле чибәр егет булып кайткан. Чак кына кысынкы зәңгәр күзләре ягымлы карыйлар. Бергә уйнап, бергә укып үскәнгәме, бертуган кебек якын да, сөйкемле дә иде ул.

Алар спектакльне бергә карадылар, бергә кайтырга чыктылар. Урамда көзге салкын җил ыжгыра, яңгыр катнаш җепшек кар ява иде. Алар салкын җилне дә, җепшек карны да сизмәделәр, аерылышып китә алмыйча, бер-берсен озатышып, поселок урамнары буйлап бик озак йөрделәр. Шул кичне алар бер-берсенә гашыйк булдылар һәм озакламыйча өйләнешеп бергә тора да башладылар.

Әмма семья тормышы Зәйтүнә көткәнчә матур булып чыкмады. Зәйтүнәгә киң холыклы һәм артык күндәм Илбарис ничектер кызыксыз, эчпошыргыч булып тоела башлады. Һәм ул кайчандыр үзенә гыйшык тотып йөргән Әсәдуллинны еш кына исенә төшерә, аның белән очрашкан вакытларда ихтыярсыз кабынып китә. «Ирең әнә шундый үткен булсын икән» дип, еш кына сокланып куя иде.

Баягынак палубада биегән вакытта Әсәдуллин әйткән сүзләр, утка бензин сипкән кебек, моңарчы күңел төбендә пыскып яткан әнә шул чаткыны янә кабызып җибәрделәр. Һәм ул кайта-кайта һаман бер сорауны кабатлады: «Чынлап та бөтен гаеп үземдә микәнни, ышанмыйча үземне дә, аны да бәхетсез итәм микәнни?..»

Караңгы каютада берьялгызы шулай күңелсез уйларга чумып утырганда, кинәт якында гына кемнеңдер аяк тавышы ишетелде һәм, су астыннан калкып чыккандай, ачык тәрәзә каршына Әсәдуллин килеп басты. Ул никтер каушаган күренә һәм әледән-әле як-ягына борчулы карана иде. Аны күрүгә, Зәйтүнә дә сискәнеп куйды һәм, үзе дә абайламастан, шелтәле тавыш белән:

– Якуб, сез ничек монда?! Болай соң нишләп йөрисез? – дип сорады.

Әсәдуллин хәзер эш киеменнән. Җиңел кара китель, ак фуражка кигән. Күзләре ничектер тынгысыз ялтырый. Көтелмәгән очрашудан ул да уңайсызланып калды бугай. Ни әйтергә белмичә, бермәл сүзсез торганнан соң:

– М-менә... вахтага чыгар алдыннан бер карап, барлап йөрүем иде, – дип, ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдап сөйләп китте һәм, тәрәзә аша үрелеп, Зәйтүнәне кулларыннан алды. – Зинһар, гафу ит, кичер мин акылсызны. Үзеңне очратырмын дип өметләнмәгән идем, вахтага менешли тәрәзәң турыннан үтәргә теләвем генә...

Әсәдуллин тынып калды һәм тиз генә тагын әйләнә-тирәгә борчулы каранып алды. Аның сулышы кысылган, йөрәге күкрәгеннән бәреп чыгардай булып дөп-дөп сикерә иде. Зәйтүнә телдән:

– Якуб, шулай ярыймыни?.. Җибәрегез мине, – дип, кулларын ычкындырырга омтылса да, үзе ихтыярсыз аңа сыенды.

Әсәдуллин исә берни ишетмәде дә, ишетергә дә теләмәде. Тәрәзәдән яртылай эчкәрәк кере төшеп, калтыранган куллары белән Зәйтүнәне ачык иңбашларыннан алды, кочагына кысып иреннәннән суырып үпте һәм, кайнар сулышы белән көйдереп алырдай итеп, һаман үз сүзен кабатлады:

– Мин бер генә минут та сине уйламыйча тора алмыйм... Аңлыйсыңмы?.. Синсез тормышым тормыш түгел, дөньяның яме юк... Бөтен киләчәгем, бөтен бәхетем-шатлыгым – барысы да синең кулда... Зәйтүнәм, бәгърем, тик бер нәрсәне ачык беләсем килә: син дә мине үз күрәсеңме... сөясеңме?.. Әгәр юк икән, дөресен әйт... Мине болай газаплама...

Зәйтүнә үзе дә аңа елышты һәм ни эшләгәнен уйламастан:

– Ник юк булсын?! Күрмисеңмени... – дип пышылдады.

Шул чак, төнге тынлыкны бозып, кемнеңдер еракта карык тавыш белән:

– Әй, пароходта-а... Акрынайта төшегез, балык... – дип сузып кычкырганы ишетелде.

Көтелмәгән бу тавыштан икесе дә сискәнеп куйдылар һәм шундук тиз генә бер-берсеннән читкә тайпылыштылар. Беркавым тын да алмыйча торганнан соң, башлап Якуб телгә килде:

– Курыкма, берни дә юк... Балыкчылар кычкыралар, балык китергәннәр, – диде ул. – Ярар, син тыныч йокла. Ә мин хәзер рубкага менәм, сине уйлый-уйлый вахтада торырмын...

Зәйтүнә Әсәдуллинның тимер траптан җиңел атлап югарыга күтәрелгәнен тәрәзәдән карап калды, рубкага менеп җиткәч, аның командирларча коры гына:

– Илбарис Рамазанович, ишетмисезмени? Балыкчылар кычкыра бит, ник акрынаймыйсыз? – дип эндәшкәнен ишетте.

– Көннәрдән бер көнне бу балык безнең тамакка тыгылмагае, – диде аңа җавап итеп Илбарис.

Аннары түбәндә винт гүләве басыла төште һәм теплоход акрынрак бара башлады.

Тиздән уң як бортка моторы белән дөп-дөп шаулый-шаулый баркас килеп тагылды. Кемдер алгы палубаны прожектор белән яктырткан иде, аңа шунда ук баркастан кычкырдылар:

– Юк, юк, кирәк түгел, яктыртмагыз, болай да яхшы күрәбез...

– Хәзер үк сүндер!.. Кем ул анда кушмаганны эшләп маташа, – дип, югарыдан Әсәдуллин да ачуланды. Аннары ул артельчене чакыртып менгезде: – Әсәтернең эреләрен тозлама, холодильникка куй... Корбан балыгын бүгеннән үк трюмда тозга сал, киптерергә булыр... Сорап кара, кипкән воблалары юкмы? Әгәр булса, ике-өч капчык ал... Бар, озак маташма...

Аны бик тиз аңларга күнеккән өлгер артельче:

– Була ул, Якуб Хисамович, нәкъ шулай итәрмен, – диде дә палубага йөгереп төшеп китте.

Инде башкалар да шунда җыелып өлгергәннәр иде. Караңгыда кешеләр берсен-берсе ашыктыра-ашыктыра баркастан балык алып, кайсы палубага, кайсы трюмдагы тоз өстенә бушата башладылар. Илбарис вахтадан төшкәч, Зәйтүнә дә:

– Әнә балыкчылар килгән бугай, без дә алмыйбызмы? – дип сүз кузгатып караган иде, Илбарис җавап бирмәде; өстәлдәге лампочканы кабызып, кителен салгач кына:

– Һи, исең киткән икән, – дип әйтеп куйды. – Менә иртәгә Саратовта йөзмә магазин чакыртырбыз. Шунда алырсың... Ярар, син йокла, минем иртәгә занятие үткәрәсем бар, бераз әзерләнim әле.

Зәйтүнә барыбер йокыга китә алмады. Чаршау ярыгыннан күреп ятты: Илбарисның чырае караңгы, нәрсәгәдер бик кәефе киткән иде. Түбәндә тимер палубага шап итеп балык бушаткан тавыш ишетелгән саен, кашларын җимереп куя иде ул.

Озакламый кайдадыр караңгыда тагын бер моторлы көймә якынлашып килгәне ишетелә башлады. Аны югарыда вахтада торучылар да күрделәр булса кирәк, Әсәдуллин мостиктан:

– Баркаста... Хәзер үк китегез... Без – сезне, сез безне күрмәдегез, – дип кычкырды һәм, балыкчылар аерылып калуга, түбәндә машина тагын бар куәтенә эшли башлады, моторлы көймә куып җитә алмыйча ерагаеп артта калды.

## IV

Зәйтүнә иртәгесен шат күңел белән уянды. Каюта эче кояш нурына балкыган, каяндыр музыка ишетелә. Илбарис инде торып киенгән һәм стаканнан чәй эчә-эчә логарифм линейкасы белән нидер исәпләп утыра иде. Зәйтүнә, яткан җиреннән генә үрелеп, аның муенын кытыкламакчы булган иде, кинәт Әсәдуллинны хәтерләп, шундук кулын кире тартып алды һәм йоклаган булып чаршау күләгәсендә тын гына ята бирде.

Тышкы яктан кемнеңдер ишек шакыганы һәм эчкә башын тыгып, яңгыравык тавыш белән:

– Илбарис Рамазанович, барыбыз да җыелып беттек. Сезне көтәбез, – дип чакырганы ишетелде.

Илбарис чыгып киткәч, Зәйтүнә, рәхәт җиңеллек белән торып, урын-җирен күпертеп җыеп куйды, юеш чүпрәк белән өстәлне, савыт-саба шкафын, китап киштәләрен сөртеп алды; коридордан Әсәдуллинның кем беләндер сөйләшеп үткәнен ишетеп, кәефле елмаеп куйды.

Вак-төяк эшләрдән арынганнан соң, ул өске палубага чыкты. Кояш нурына чумган киң елгага, юлда очраган кәрваннарга, текә ярларга карап барды. Кояш катырак кыздыра башлагач, күләгә урын эзләп кызыл почмак каршына килеп чыкты. Наташа да шунда, ачык тәрәзәдән эчкә башын тыгып, нидер тыңлап тора иде. Зәйтүнә янәшә килеп баскач, ул башын кагып кына исәнләште дә:

– Занятие бара, тыңлыйк әле, – дип, пышылдап кына искәртеп куйды.

Зәйтүнә ачык тәрәзәдән эчкә карауга, Илбарис белән Әсәдуллинны икесен дә берьюлы күреп, ничектер уңайсызланып калды. Әмма аңа игътибар итеп беркем дә карамады. Озынча зур өстәл тирәли тезелеп утырган егетләр нидәндер дәррәү көлеп җибәрделәр. Шау-шу басыла төшкәч, Илбарис кулындагы акбур белән кара тактага шакыды.

– Җитте, тынычланыгыз, сүз уңаеннан киңәшеп аласы бер нәрсә бар, – диде ул һәм телевизор өстендәге кәгазьне кулына алды. – Менә мин монда, үткән рейска отчет ясаганда, без алып кайткан теге баржаның йөген дә өстәп караган идем. Бик кызык хәл килеп чыга: баржа белән барганда тизлек гадәттәгедән егерме биш процентка кимесә дә, йөк ташу планын шул вакыт эчендә икеләтә диярлек арттырып үтәгәнбез. Күрәсезме, нинди зур отыш?

Арадан берсе балаларча беркатлылык белән:

– Менә бәхет... Прогрессивканы каерабыз икән алайса... Шулай бит?.. – дип әйтеп куйды.

Берсен-берсе бүлешеп башкалар да шаулый башладылар:

– Тукта әле, авызыңны ермасана, бу сиңа уен түгел ич...

– Кара син аны, чынлап та шәп бит.

– Тагын шулай итәсе иде...

– Илбарис Рамазанович, үзебезгә бер баржа сорап карасак, барып чыгар иде микән?..

– Нигә чыкмасын!.. Минемчә, бик мөмкин. – Илбарис ишек янагына яны белән сөялеп торган Әсәдуллинга карап алды. – Әнә Якуб Хисамович та монда, әйдәгез бергәләп уйлашыйк, киңәшик. Әгәр сорап карасак, кире какмаслар, сынап карар өчен генә булса да, бер баржа бирерләр иде...

Әсәдуллин өстәл тирәли утыручыларга күз йөртеп чыкканнан соң, бермәл уйланып торды да:

– Дуслар, безгә әллә ниләр уйлап чыгарган булып дөньяны шаккатыруның кирәге юк, – диде. – Без сабый балалар түгел, төрле юк-барга исебез китмәсен. Безгә баржа йөртүнең бернинди дә әһәмияте юк, ул эш безгә исәпләнми, чөнки безгә андый күрсәткеч бирелмәгән... Аннары, мин әйтер идем, ул безгә артык комачау гына...

– Ничек инде артык комачау гына? – дип куйды кемдер.

Әсәдуллин, бу ризасызлык соравын ишетмәгәндәй, сабыр гына сүзен дәвам итте:

– Без монда барыбыз да үз кешеләр, яшерен-батырын түгел, дигәндәй, турысын әйтергә мөмкин. Сез үзегез дә яхшы беләсез бит: хәзерге вакытта безнең «Урал» Иделдә беренче булып навигация планын тәмамлады, ягъни мәсәлән, ярыш флагманы булып бара. Әнә газеталарны карагыз, башка командаларны безгә тиңләшеп эшләргә, уралчылардан үрнәк алырга чакырып язалар. Аллага шөкер дигәндәй, акчасы да әйбәт кенә килә бит, – диде ул аннары, тавышын күтәрә төшеп. – Безгә, дуслар, моның кадерен белергә, сак булырга кирәк. Югыйсә, чатаклык килеп чыга калса, үзебезне генә түгел, идарәне дә уңайсыз хәлгә куюыбыз бар. Ә кайбер кайнар башлар шуны аңламыйча, төрле юк-бар белән безнең башны әйләндерәләр...

Әсәдуллин тагын нидер әйтмәкче иде, кинәт якында гына гудок кычкырганын ишетеп, тәрәзәгә күз салды. Башкалар да тәрәзәләргә каерылып карадылар һәм киң елганы ярып килгән мәһабәт теплоходны күреп, хәрәкәтсез калдылар. Сигнал бирешеп, сул як бортлары белән аймылышканнан соң, теплоходтан гудок кычкыртып сәламли башладылар. Аннары мостигында торучы ак китель кигән капитан кулына җиз рупор алды да: «Ярыш флагманы – «Урал»га сәлам!» дип кычкырды. Аңар ияреп пассажирлары да, команда членнары да, уралчыларны күңелле тәбрикләп үттеләр.

Кызыл почмактагылар кул болгап җавап бирделәр һәм, теплоход үтеп киткәч, кәефле елмаеп, бер-беренә карашып алдылар.

Әсәдуллин үзенә бер горурлык белән өстәл тирәли күз йөртеп чыкты, кем беләндер бәхәсләшкәндәй, тагын да җанланып сөйләп китте:

– Әнә күрдегезме ничек... Әле кайчан гына «Урал» һичкемгә билгесез бер теплоход иде, йөк ташу планын көч-хәл белән генә үти, аны санга санап телгә алучы да юк иде. Быел уйлап эшли белгәч, әнә кая барып чыктык. Моның кадерен белергә кирәк... Иптәш Рамазанов, сез дә занятие вакытында җыен тузга язмаган нәрсәләр белән вакытны әрәм итмәгез.

Бу минутта Зәйтүнәгә Илбарис бик кызганыч булып күренде. Әсәдуллин сүзләреннән соң хәзер барысы да аннан кычкырып көлә башларлар кебек тоелды... Хәер, әйдә көлә бирсеннәр, шул кирәк ул Хыялбайга! Сабак булыр ичмасам... Әмма гаҗәп, көлүче дә, көләргә уйлаучы да күренми, барысының да йөзләре җитди, күз карашларында ризасызлык күренеп тора иде.

– Аннары, туганкаем, сез, беренче штурман буларак, белергә тиеш, ул баржаны безгә исәпләмәделәр бит аны. – Әсәдуллин, сүзеннән туктап, Илбариска ачулы карап алды. – Чөнки безнең теплоход үзе баржа, дөресрәге, үзйөрешле баржа, шунлыктан аңа баржа йөртү планлаштырылмаган, андый күрсәткеч тә бирелмәгән. Ә теге баржаны без аны очраклы рәвештә, буксир пароход юлда сафтан чыкканлыктан гына алып кайткан идек. План өчен ул безгә берни дә бирмәде, коры мунчала белән юыну гына булды бит ул...

Аның бу сүзләреннән Зәйтүнә ирексез пырхылдап көлеп җибәрде һәм, урынсыз көлүен абайлап, ничектер уңайсызланып калды.

– Хәзер исәпләмәсәләр, киләчәктә исәпләрләр, – диде Илбарис. – Һәрхәлдә, бу – зур резерв, аннан файдаланырга кирәк. Безнеке кебек куәтле теплоходлар барысы да баржалар йөртә башласалар, өстәмә рәвештә күпме йөк ташып булыр иде!..

– Һи, һаман бер балык башы булыр икән, – Әсәдуллинның күзләре тагын да түгәрәкләнә төште. – Сез беренче штурман, белергә тиешсез: безнең теплоходның корпусларында тиешле ныгытмалары юк, димәк, баржалар эттереп йөртергә җайланмаган. Корпусы яньчелүен көт тә тор. Алай тиктомалдан кузгатылган эшнең азагы аянычлы була аның.

– Юк, тиктомалдан түгел. Беренчедән, безнең бәләкәй генә тәҗрибәбез бар, агым уңаена булса да, үткән рейста баржа алып кайттык ич – хәвеф-хәтәр булмады кебек. Аннары мин кичә базада вакытта бу турыда капитан-наставник Космачевка да, институттан килгән инженерга да сөйләгән идем. Алар бик кызыксындылар һәм тиздән үзләре дә килеп карарга булдылар.

– Әйтәм ич, һаман шул башбаштаклык белән күп беләмлек... Алдан ук әйтеп куям, белеп тор: төрле юк-бар белән маташырга безнең вакытыбыз да, мөмкинлегебез дә юк, без йөк ташырга, план үтәргә тиешбез. Дуслар, чынлап та шулай бит...

Ләкин Әсәдуллинны хуплап бер авыз сүз әйтүче булмады. Ул чыгып киткәндә, барысы да телләрен йоткандай, караңгы чырай белән утырып калдылар.

## V

Коридорда белдерүләр тактасы янында бер төркем кешеләр җыелган. Үтеп барышлый күргән һәркем шунда килеп туктый да, бүтәннәрне этә-төртә алгарак үтеп, белдерүне укырга ашыга иде.

Камбузга чәй алырга барышлый, Зәйтүнә дә кызыксынып туктаган иде. Әмма халык арасыннан ерып алга үтә алмады.

– Шауламагыз... Әгәр арттагыларга күренмәсә, хәзер үзем кычкырып укыйм, – диде алдагылардан берсе. – Приказ бу, капитан приказы. Тыңлагыз, менә ниләр язылган:

*«Теплоход Владимировка пристаненда торган вакытта эчеп һәм сугышып йөргән өчен һәм шуның белән бөтен команда өстенә тап төшергән өчен, практикант Әсәдуллин Харисны теплоходтан төшереп калдырырга приказ бирәм. Аның практикада үзен начар тотуы турында укыган техникумына хәбәр итәргә... Шул уңай белән бөтен команданы кисәтеп куям: киләчәктә порт һәм пристаньнарда туктап торган вакытларда һәркем әйбәт йөрергә, алдынгы теплоходның абруен сакларга тиеш.*

*«Урал» теплоходы капитаны Я.Әсәдуллин».*

Приказны укыган почык борынлы егет, күзе белән укыганны башына сыйдыра алмыйча, кинәт бик гаҗәпләнеп:

– Ничек, төшереп калдырыргамы? – диде. – Димәк, Харисны, бертуган энесен... Бик тә сәер инде, чынлап әгәр, адәм күрмәгән хәл...

Башкалар да ни әйтергә белмичә аптырап калдылар. Арттарак кемдер, тыны кысылгандай, «уфф» итеп тирән сулап куйды. Зәйтүнә борылып караса, якында гына Наташа тора икән. Аның ничектер төсе китеп, еларга җыенгандай, юка иреннәре, борын канатлары дерелди иде.

– Юк бит, дөрес түгел, – диде ул, эчке өзгәләнү белән. – Милиционер китергәндә барыгыз да күрдегез ич, исерек түгел иде ич.

– Анысын мин дә раслый алам, Харис бер грамм да эчмәгән иде, – диде боцман Соколов та, сүзгә кушылып. – Без аның белән чыктык. Турысын әйтергә кирәк, мин үзем бер кружка сыра белән аны сыйламакчы булган идем. Юк, кермәде бит, чаттагы киоскта китаплар карый калды... Тиз генә эшне бетереп чыксам, ни күзем белән күрим, Хариска ике исерек матрос бәйләнеп маташа... «Алдынгылар түгел, алдакчылар сез, взяточниклар» дип мыскыл итәләр. Берсе, исерегрәге, йодрыгын ук хутка җибәрә башлаган иде, Харис берне кундырып алды... Шул арада милиционер килеп чыкты... Менә шул, теге исерекләр үзләре бәйләнделәр, ә Харис бер грамм да эчмәгән иде... Нинди алдакчы, нинди взяточник?.. Анысын мин белә алмадым, хәзер дә белмим...

Иң артта, механик Федор Степанович белән янәшә, сүзсез генә Әсәдуллин да күзәтеп тора икән...

– Белмәгәч, сөйләмиләр аны, – диде ул, боцманны төрпә генә бүлдереп. – Аек баштан сугышырга шыр тиле түгел бит ул. Ни такылдаганыңны үзең дә аңламыйсың...

Кешеләр үзара бәхәсләшә-бәхәсләшә таралыша башладылар. Бу хәлне моңарчы сүзсез генә күзәтеп торган Федор Степанович, үзалдына сөйләнгәндәй:

– Әллә ничек кенә килеп чыга әле бу, – дип әйтеп куйды. – Әнә халык та риза түгел... Якуб Хисамович, син Харисның үзе белән сөйләштеңме соң?.. Боцман сүзләренә караганда, исерек булмаган бит... Ачыкладыңмы шуны?..

– Болай да ачык мәсьәләне нәрсә ачыклыйсың аны?.. Аннары моның башка ягы да бар. Ул минем бертуган энем бит, димәк, йомшаклык күрсәтсәм, туган-тумачалык, юл куючанлык килеп чыга. Башкалардан таләп итүе дә кыен булачак.

– Юк, Якуб Хисамович, ачыкларга, аңлашырга кирәк: гаепләме ул, түгелме? Юкса уңайсыз бит... Мондый очракта җиде кат үлчәргә, тик шуннан соң гына кисәргә кирәк.

Әсәдуллин бүтән берни дә әйтмәде. Ничектер иңбашларын җыерып алды да гадәтенчә җиңел, ышанычлы адымнар белән рубкага менеп китте. Зәйтүнә аның артыннан ирексез сокланып карап калды. «Һәрхәлдә, капитан үзенчә хаклы булса кирәк, беркемгә дә ташлама ясамый. Чын җитәкче шулай булырга тиештер, күрәсең...» дип уйлады ул.

Кичкә таба Зәйтүнәне радиорубкага чакыртып алдылар. Барып керсә, Илбарис белән Әсәдуллин да шунда иде. Кая карама, тәртипсезлек күзгә бәрелеп тора. Өстәл өсте һәм аппаратлар тузан белән капланган, идәндә тәмәке төпчекләре аунап ята. Бер читтәрәк, бөтен гәүдәсен көзән җыергандай әледән-әле уфылдап һәм өзгәләнеп, радист утыра иде.

– Менә безнең радист-электригыбыз каты авырып китте әле, – диде Әсәдуллин, аңа күрсәтеп. – Бүген кичен Саратовка җиткәч, аны больницага салырга туры килер, ахры... Зәйтүнә, сез аның урынына калып торыгыз инде. Бу сезнең кулдан килә торган эш бит.

Башыңа төшкәч, башмакчы буласың, диләр. Теләсә-теләмәсә дә, Зәйтүнәгә ризалык бирергә һәм вакытлы рәвештә радист урынында калып торырга туры килде.

VI

Иртән кызыл почмакта Илбарис белән сүзгә килешкәч, Зәйтүнә Әсәдуллинның хәтере калгандыр дип борчылган иде. Юк, калмаган икән. Көндезге аштан соң, Зәйтүнәләр каютасына ачык елмаеп, ул үзе килеп Илбарис белән бергә рейс отчетын карап чыкты. Ай азагына хәтле тагын күпме эшләп буласын исәпләделәр. Зәйтүнә аларга урталай киселгән зур гына кып-кызыл карбыз алып керде, икесенең алдына ике тәлинкә куйды.

– И Зәйтүнә, нинди шәп карбызны кисеп харап иткәнсез, – диде Әсәдуллин. – Монысы бал әчетергә әйбәт булган бит...

– Нинди бал? Ничек әчетергә? – дип аптырап калды Зәйтүнә.

– Шуны да белмисезмени? Бик җиңел эшләнә ул. Савыт та, бал-шикәр дә кирәк түгел, барысы да карбызның үзендә. Пычак очы белән карбызның кабыгын тишеп эченә чүпрә салсаң, үзе шаулап әчи ул. Ни җитте кызыл аракыларың бер читтә торсын инде... Ләкин мин аны сезгә сер итеп кенә әйтәм, әгәр әчетсәгез, шуның өчен мине бер сыйларга тиеш булырсыз.

Шул чак бер төркем яшьләр тышкы якта алар тәрәзәсе турысындагы күләгәгә өстәл һәм урындыклар китереп куйдылар. Кызыл почмактан шахмат тактасы алып чыктылар.

«Урал»да шахматчылар күп, еш кына турнирлар үткәрәләр. Бүген шулар чираттагы уенга әзерләнәләр икән.

Утырышып беткәч, шахматчылар әйләнә-тирәгә карана башладылар.

– Харис кайда?

– Лидер ник чыкмаган?

– Моны ничек аңларга... Шүрләмәгәндер ич?..

Арадан кемдер аларга җавап биргәндәй:

– Менә үзеңне теплоходтан куып төшерсеннәр әле, башыңда шахмат кайгысы булыр идеме? – дип әйтеп куйды.

Чандыр гына гәүдәле булса да, мичкәдән чыккандай яңгыравык тавышлы боцман Соколов ачу белән кычкырды:

– Барыгыз, барыбер китерегез! Судья чакыра дип әйтегез... Аңа карап турнирны ярты юлда калдырып булмый бит... Харисны да әйтер идем, исе киткән икән. Бөтен дөнья бер Әсәдуллинга барып терәлмәгән бит... Һаман саен күз буяп, мин-мин дип борынын чөеп кенә йөри алмас, ул туңбашка да бер авызлык табылыр әле.

Артельче, төнтек чырайлы рулевой Мортазин, башкалар уйнаганны читтән генә карап торган җиреннән:

– Монда капитанның гаебе юк. Харис пристаньда сугышып йөргән икән, капитан аны яклап калырга тиешмени? – диде.

– Әй, син, ялагайбай, тик кенә тор, – диде Соколов кырт кисеп.

– Мортазин чын вояжердан бер дә ким түгел ул, – дип, тагын берсе чәнчеп алды. – Капитан күчтәнәчләрен дә диспетчерларга шома гына илтеп тапшыра белә, бер уңайдан үзен дә онытмый: әле кара икрасын, әле балыгын итәк астыннан гына озатып, кесәсен калынайта белә ул.

Моңарчы бик кәефле генә сөйләшеп утырган Әсәдуллинның җәенке кашлары җимерелде, күзләрендә зәһәр очкыннар кабынып китте. Шулай да ул ярсуга ирек бирмәде, үзен бик тиз кулга алды һәм, тышта ишетелгән сүзләргә бөтенләй колак салмаган кебек, тыныч кыяфәт белән, карбызны ашый-ашый сөйли бирде. Илбарис белән Зәйтүнә дә, аны уңайсыз хәлдә калдырмас өчен, алдан сүз куешкан кебек, аеруча игътибар белән тыңлыйлар һәм, урынлы-урынсыз булса да, мөмкин кадәр күбрәк көләргә тырышалар иде.

– Якуб Хисамович, – диде Илбарис, аның тәлинкәсенә кып-кызыл карбыз телеме салып, – командага эш хакы биреп бетердем, әмма сезнең энекәшегез Харис прогрессивкасын алмады. Кирәк түгел, намусым тартмый, диде.

– Ничек?! Кире кагамыни?.. Менә гаҗәп, намусына ни булган аның? – Әсәдуллин, авызына китергән карбызын капмыйча, көлеп җибәрде. – Ярар, алмаса, ялынмыйбыз... Хәзер кушмаса, соңрак кушар, үзе соратыр әле.

– Якуб Хисамович, тагын менә нәрсә. Наташа да расчет сорый, никтер теплоходтан китәргә җыена. Сәбәбен белергә теләп сораштырып та караган идем, берни дә әйтмәде, яшьләнгән күзләрен сөртә-сөртә чыгып китте.

Әсәдуллинның тагын кашлары җимерелде.

– Зыян юк, тели икән, әйдә китсен, – диде ул, кулындагы карбызын тәлинкәгә кире куеп. – Безнең монда балалар бакчасы түгел, барысын да иркәләп кенә торып булмый... Әгәр китә калса, кадрлар бүлегенә хәбәр итәргә кирәк, бүтән кеше җибәрсеннәр...

## VII

Радиорубкада бик эссе һәм бөркү. Көндез кызган стеналардан эссе бәреп тора. Өстәл почмагында зырылдап әйләнгән вентилятор да бернинди җиңеллек бирми.

Тиздән «Урал» идарә белән сөйләшергә тиеш. Шуңарчы Зәйтүнә аппаратларны көйләп утыра. Кулы эштә, ә күңелендә Әсәдуллин. Менә-менә үзе килеп керергә тиеш. Ул гел шулай итә: Зәйтүнәнең рубкада икәнен белде исә, юк эшне дә бар итеп, бик тиз кереп җитә, һәм аның белән аулакта булырга тырыша. Хәер, Зәйтүнә үзе дә аны күрергә ашкынып тора һәм очрашу минутларын түземсезлек белән көтеп ала иде.

Әнә Әсәдуллин кереп тә җитте һәм яктыдан кысыла төшкән күзләре белән бермәл әйләнә-тирәгә елмаеп карап торды.

– Син бу чүп оясын кайчан чистартып өлгердең әле?.. – диде ул һәм приемник көйләп утырган Зәйтүнәнең чәчләрен сыйпап алды, иелеп маңгаеннан, аннары иреннәреннән үпте.

Әсәдуллин урындык алып янәшә утыргач, Зәйтүнә үзе дә көлемсерәп елмайды һәм көтмәгәндә аның күзләрендә комсыз ашкыну күреп, ихтыярсыз сагаеп калды, аңа ничектер уңайсыз булып китте.

Нәрсәдән икәнлеген ачык итеп белмәсә дә, Әсәдуллин бу үзгәрешне шундук сизде, бүтән кагылмады. Хәтта читкәрәк тайпылып авыз эченнән нидер көйли-көйли куен дәфтәрендә актарынгандай итте. Шул арада идарәдән тапшыру башланды. Инде бераз тынычланган Зәйтүнә һава торышы, фарватердагы үзгәрешләр турында мәгълүматларны гадәтенчә бик тиз язып алды.

Иң соңыннан, ике яктан да тапшырулар тәмам булгач, эфирдагы башка авазларны җиңеп, никлы калын тавышлы ир кеше:

– «Урал»! «Урал»мы бу?.. Якуб Хисамович, хәерле кич, – дип эндәште.

Әсәдуллин аны беренче сүзләреннән ук таныды һәм трубканы тиз генә үз кулына алды:

– Тыңлыйм, иптәш начальник... Исәнмесез, Николай Николаевич, – дип, түбәнчелек белән җавап кайтарды. – Эшләрне әйтәсезме?.. Әйбәт кенә тәгәри... Бу рейста да хәзергә графиктан алда барабыз... Кешеләрме?.. Әйе, алар да әйбәт кенә... Барысының да күңелләре күтәренке, бүген прогрессивка бирдек. Кыскасы, барысы да тырышып эшли, ышанычыгызны, ә-әл-бәттә, аклarбыз.

Зәйтүнә аңа, әле генә таныган кебек, бик гаҗәпләнеп карап торды. Моңарчы һәрвакыт һавалы һәм горур күреп гадәтләнгән, команда членнары алдында үзен эре тотып кына йөргән Әсәдуллин бу митутта кинәт юашланып калды, гаепле кешедәй, ничектер түбәнчелек белән һәм әйтер сүзен таба алмагандай, еш кына тотлыга-тотлыга сөйли иде.

Бермәл дәшми торганнан соң, репродуктордан шул ук никлы тыныч тавыш:

– Анысы әйбәт, кешеләр турында һаман кайгыртырга, игътибарлы булырга кирәк. Шулай эшләп яхшы итәсез, – дип мактап алды. – Тагын менә нәрсә, син баржа йөртеп карарга җыенасың икән. Без монда иптәшләр белән уйлашып-киңәшеп караган идек. Ниятегез кызыклы гына күренә. Сынап карарга рөхсәт бирәбез һәм уңышлар телибез. Диспетчерларга әйтелде, үзеңә юлда баржа әзерләп куярлар...

– Иптәш начальник, аңламадым, нинди баржа, кем җ-җыена?.. Теге ни, болай команда арасында сөйләнү генә бит әле ул... Кысыр хыял гына...

– Сез нәрсә? – диде начальник ризасызлык белән. – Андый ният кысыр булырга тиеш түгел. Без моңа зур өмет баглыйбыз. Мондый эштә кирле-мырлы ярамый. Сынап карарга кирәк.

– Иптәш н-начальник, мин болай гына әйтәм, принципта каршы түгелмен... Кушасыз икән, тырышып карарбыз...

– Әлбәттә, карарга һәм булдырырга кирәк... Югыйсә тапкансың сүз: кысыр хыял да коры сөйләшү генә, имеш. Кузгалгансыз икән, эшләргә кирәк. Менә шул, уңыш теләп калабыз, хушыгыз...

Рубка эче тынып калды. Әсәдуллин үзен начальник каршында хис иткәндәй, репродукторга озак карап торды һәм маңгаендагы тир бөртекләрен кульъяулыгы белән сөртеп алды.

## VIII

«Урал» киң елганы ярып һаман алга бара. Як-якта тәбәнәк ярлар, яшел болыннар, су читенә үк сыенып утырган хуторлар күренеп кала. Төрле пароходлар, кәрваннар, балыкчы сейнерлары очрый.

Мәһабәт Волгоград ГЭСы шлюзларын үткәч, кинәт диңгезгә килеп чыккан кебек булып китте. Кая карама, чиксез-кырыйсыз су чайкала.

Саратовка җитәрәк Увяк пристане турысында «Урал»ны кечерәк кенә баркас каршылады. Өске палубасында елгачылар формасын кигән, кулына кара плащ һәм кечкенә чемодан тоткан өлкән

яшьләрдәге бер кеше басып тора иде. Танып алу белән, Әсәдуллин аны үзе каршылады, үзе белән янәшә буш каютага алып керде.

Бу – Иделдә туып үскән, бөтен гомерен пароходларда эшләп үткәргән карт елгачы, капитан-наставник Космачев иде. Каютасында әйберләрен куйгач, ул шундук рубкага күтәрелде, команданың эше, тормышы турында сорашты. Аннары кителенең куен кесәсеннән кәгазь чыгарып:

– Мин башка теплоходларда йөргән арада, сез монда кызыклы гына фикер күтәреп чыккансыз икән, – диде. – Идарә каршы түгел. Ярдәмгә-киңәшкә дип мине җибәрделәр. Менә диспетчердан приказ: Саратов рейдында бодай төягән баржаны алырбыз...

Әсәдуллинның чырае караңгыланып китте.

– Иван Кириллович, минем үземнең моңа никтер бер дә кулым тартмый, – диде ул, Илбариска таба ачулы караш ташлап. – Әнә кем хыялы ул, бөтен команданың башын шул әйләндерде...

Космачев, нәрсәнедер ачыкларга теләгәндәй, башта Әсәдуллинга, аннары Рамазановка бермәл сүзсез генә карап торды, чаларган кыска мыегын селкетеп алды. Әмма телдән аны-моны сиздермәде.

– Ярар, бу хакта соңыннан... Һәрхәлдә, бу буш хыялга охшамаган. Әнә Саратовка якынлашып та киләбез инде. Бу баржаларның кайсысы безнеке икән? – дип, бинокль алып, рейдтагы судноларны карый башлады.

Тиздән алар ике мең тонна бодай төягән зур металл баржа янына килеп тукталдылар. Баржаның шкиперы, базык гәүдәле, тәбәнәк кенә буйлы егет, башта ышанмый торды.

– Үзйөрешле баржа белән баржа йөртәләрмени?.. – дип, бик гаҗәпләнде.

Әмма аңлатып биргәч, риза булды һәм бөтен командасы белән эшкә кереште.

Баржаны эттереп барырга булдылар. «Урал» арттан килеп борыны белән баржаның кринолинына терәлде. Ике яктан һәм аркылы-торкылы корыч арканнар белән тарттырып бәйләделәр.

Илбарис бу хакта инде алдан ук байтак баш ваткан, күп пароходларның баржаларны ничек бәйләүләрен караган һәм техминимум занятиеләрендә команда члennарына да аңлаткан иде.

Якорьларны күтәргәч, ашыкмыйча гына юлга чыктылар. Тиздән рейд артта калды. Яңа күпер астыннан үткәч кенә, чак бер күңелсезлек булмады. Югарыдан төшеп килүче «Авангард» теплоходы кузгаткан куәтле дулкыннарда кәрван чайкала башлауга, сул яктан корыч «дилбегә» шартлап өзелде. Баржа, туры барырга теләмәгәндәй, кинәт уңга борыла башлады һәм тиздән агымга аркылы ятты.

Бер мәлгә барысы да аптырап калдылар. Бик тиз генә нинди дә булса чара күрелмәсә, авария яки башка төрле күңелсез хәл килеп чыгачагы ачык иде.

Авыр тынлыкны башлап бозучы Әсәдуллин булды.

– Ах, харап иттеләр, – дип каударланып кычкырып җибәрде ул. – Баржаны да, теплоходны да харап иттеләр. Иван Кириллович, сез булмасагыз, мин моңар юл куячак түгел идем... Инде хәзер теләсәгез нишләгез, җавабын үзегез бирегез, мине бутамагыз... Минем монда бернинди катнашым да юк...

Иван Кириллович белән тиз генә киңәшеп алгач, Илбарис баржаның алгы ике якорен да салырга, теплоходтан сузылган корыч арканнарны ычкындырырга команда бирде. Бөтен командага берничә авыр минут кичерергә туры килде. Тик баржа якорьга туктагач кына, кешеләр җиңел сулап куйдылар.

Сул як «дилбегәгә» иске, тузган аркан куелган булган, баржаны дулкын чайкаган вакытта шул өзелгән икән. Яңа корыч аркан белән тарттырып бәйләгәч, кәрван тагын кузгалып китте. Теплоходлар очрап дулкын кузгатып үтсәләр дә, инде кәрван бернинди хәвеф-хәтәрсез һаман алга бара бирде.

– Болай булгач, борчылмаска да мөмкин, – диде Иван Кириллович. – Әйбәт барабыз, яхшы бәйләгәч, тоташ бер судно кебек. Күз тимәсен, рульгә дә әйбәт буйсына...

Түбәндә команда члennары да җанланып киттеләр.

– Күрәсеңме, бара бит, ыжгырып бара...

– Менә тамаша, үзйөрешле баржа белән дә баржа йөртеп булыр икән.

– Чынлап та шәп кенә бара... Гаҗәп тә инде.

– Бер караганда монда хәйран калырлык әллә нәрсә юк, – диде Соколов, сүзгә кушылып. – Хәзер үзйөрешле баржаларны әнә нинди куәтле итеп төзиләр, күрәсез, аңарга үзе хәтле судноны йөртү дә әллә ни кыен түгел...

Тагын байтак вакыт шулай әйбәт кенә баргач, Иван Кириллович белән Илбарис, капитанга хәерле вахта теләп, түбән төшеп киттеләр һәм палубада әле һаман таралышмыйча үзара җанланып сөйләшеп торган яшьләр янында тукталдылар.

– Иван Кириллович, шәп бара бит! – диде боцман Соколов, баржага күрсәтеп. – Югыйсә безнең монда булмас, барып чыкмас, дип каркылдап колакны тондырып бетергәннәр иде.

– Әйбәт барабыз, дуслар, бик әйбәт, бер дә зарланырлык түгел. – Иван Кириллович фуражкасын салды, эсседән тирләгән маңгаен, битләрен кулъяулыгы белән сөртеп алды. – Әгәр без алып китмәгән булсак, баржа буксир пароход көтеп күпме торган булыр иде әле... Башка үзйөрешле баржалар да шулай эшли башласалар, нихәтле зур экономия булачак!.. Бик зур эффект бирәчәк бу...

## IX

Зәйтүнә каютада кичке ашка табын хәзерләп йөри иде. Тышкы яктан кемнәрнеңдер кычкырып сөйләшкәне ишетелде һәм яртылаш ачык ишектән Илбарис, аның артыннан исәнләшеп Иван Кириллович белән механик Федор Степанович килеп керде:

– Зәйтүнәм, син безне чәй белән сыйла әле, бу челләдән тәмам сусап беттек, – диде Илбарис. – Әнә Иван Кириллович әйтә: «Чын татарча каты чәй эчәсем килә», – ди... Әйдә, осталыгыңны күрсәтергә тырыш...

Иван Кириллович киштәдәге китапларга игътибар белән күз йөртеп чыкты, кайберләрен кулына алып актарып та карады:

– Дөрес, лоциясе дә, навигациясе дә, компасы, локаторы да кирәк, – диде ул. – Хәзер елгачының бөтен эше техника ярдәмендә үтәлгән чорда китапсыз мөмкин түгел... Әле кайчан гына бер якорьны, бөтен команда җыелышып, мең газап белән күтәрә идек, хәзер бер матрос брашпильнең кнопкасына гына баса...

Алар сөйләшә-сөйләшә кулларын юып утырышкан арада, Зәйтүнә өстәлгә җиләк-җимешен китереп куйды, камбуздан кыздырылган балык алып керде, чынаякларга чәй салды, Федор Степанович белән карашып алганнан соң, Илбарис шкаф артыннан шешә тартып чыгарып балык алдыннан берәр рюмка салып бирмәкче дә булган иде, әмма Иван Кириллович риза булмады.

– Мондый кызуда һич тә кирәге юк... Аннары вакыты да ул түгел, – дип каршы килде ул һәм, мактый-мактый балык ашаганнан соң, борчулы чырай белән сорау бирде: – Дуслар, миңа бер хәл бик сәер тоелды, Әсәдуллинны ник команда яратмый? Сәбәбе нәрсәдә?.. Үзе болай сәләтсез капитан түгел бит ул...

Барысы да ашаудан туктап көрсенеп куйдылар. Бу сорау Зәйтүнәгә аеруча авыр тоелды. Мондый хәлне ул инде үзе дә ничектер сизгән һәм ялгышамдыр, миңа гына шулай тоеладыр дип уйлаган иде, үзен шулай тынычландырырга тырышкан иде.

– Әйе, Әсәдуллин булдыксыз капитан түгел, – диде Федор Степанович, күңелсез тынлыкны бозып. – Елга транспортын белеп, яратып эшли. Ләкин аның бер зур җитешсезлеге: үз кул астында эшләүчеләрне кирәксә-кирәкмәсә дә рәнҗетә торган гадәте бар. Команда членнары белән борын чөеп кенә сөйләшә, әз генә аныңча булмаса, беркемгә дә колак салмый. Хаклымы, түгелме, тик ул кушканча гына булсын... Шуңа күрә бездә кешеләр дә яратып эшләмиләр, җае чыкса, башка суднога күчеп китәргә мәҗбүр итә...

– Кара син аны, шулаймыни? – Иван Кириллович, теше сызлый башлагандай, кинәт чыраен сытты. – Ә мин, картлач, шуны күрми йөргәнмен. Алдынгы теплоход булгач, андый нәрсә башыма да килмәгән иде...

Һич тә көтмәгәндә Әсәдуллин ишектә үзе күренде һәм гадәтенчә кыю кыяфәт белән бусага аша атлап кергән шәпкә:

– Ә, сез мондамыни... Тәмле булсын ашыгыз, – диде һәм, кыстаганны да көтмәстән, өстәл янына килеп утырды. – Илбарис, син нәрсә, Иван Кириллович хөрмәтенә рәтлерәк балык китермәдең. Анда осетр бар иде бит...

– И бөтенләй оныта язганмын, үзең балык дигәннән искә төште... Менә монда рыбнадзордан сиңа хат бар әле, – дип, Иван Кириллович стенага эленгән китель кесәсеннән кечерәк кенә конверт алып бирде. – Ни язганнардыр, белә алмадым, баркаска утырганда гына китереп тоттырдылар. Озакка сузмасын, җавап язып җибәрсен, дип әйтеп калдылар.

Конвертны ачып укый башлауга, Әсәдуллинның кашлары җыерылып килде. Зәйтүнә аның кулындагы кәгазь калтырый башлаганын күрде. Моны Иван Кириллович та сизде, ахры.

– Ни булган, күңелсез хәбәрмени? – диде ул, Әсәдуллин кулындагы кәгазьгә күз салып. – Акт! Рыбнадзор акты... Сез төннәрен бораконьерлардан күпләп-күпләп балык аласызмыни?.. Дөресме шул?.. Нигә сезгә шулхәтле балык, кая куясыз аны?..

– Иван Кириллович, алар башка судно белән бутаганнар булса кирәк...

– Ярар, анысы шулайдыр, бәлкем... Ләкин әнә алар бу хәл инде беренче тапкыр гына түгел, эшне прокурорга тапшырабыз дип язганнар бит.

Иван Кириллович күзлеген киеп актны яңадан укырга тотынды. – Антиповка турыннан сәгать ничәләрдә үттегез әле сез!.. Төнге сәгать уникедәме? Шул, шул, сезгә туры килә бит...

Әсәдуллин телдән ачык итеп ни дә булса әйтә алмады, иңбашларын гына җыерып куйды.

– Тагын менә нәрсә, дуслар, – диде Иван Кириллович, барысына да мөрәҗәгать итеп. – Сез практикант Әсәдуллинны теплоходтан төшереп калдырырга булдыгызмыни? Монысы ни өчен тагын, яхшылап ачыкладыгызмы? Бик кискен каерып ташламыйсызмы?..

– Юк, ялгышмыйбыз, Иван Кириллович... Харис минем бертуган энекәшем ул, мин аны яхшы беләм һәм бик хаклы рәвештә төшереп калдырам... Бүтәннәргә гыйбрәт булыр...

– Тукта әле, Якуб Хисамович, тукта... Син ничектер сәеррәк сөйләшәсең. Һаман мин дә мин... Алай гына булмый бит ул, теплоходта коллектив та бар бит әле... Ә коллектив практикант Әсәдуллин өчен бик борчыла. Ул аны һич тә хаксызга рәнҗетелде дип саный... Халык белән сөйләшкәндә мин әнә шуны сиздем.

– Мин теплоходта кешеләрдән дисциплина таләп итәм, эш таләп итәм. Шунлыктан ризасызлык күрсәтүчеләр дә булуы мөмкин... Ә Харис пристаньда исереп, әллә кемнәр белән сугышып коллективка тап төшергән икән, үз туганым булса да, күз йомып кала алмыйм...

– Якуб Хисамович, турысын әйткән өчен хәтерең калмасын, мин сиңа бер вакыйганы исеңә төшерергә телим, – диде Илбарис. – «Рошаль» пароходында практикада йөргән вакытта, хәтерлисеңдер син, бер дә сәбәпсезгә Астраханьда калган идең. Синең өчен без өч көн вахтада тордык... Шундыйрак хәлләр аннан соң да булгалады бит. Әмма сине куып төшермәделәр, хатаңны аңлатырга тырыштылар... Безгә дә, шулай эшләсәк, бер дә гөнаһ булмас иде.

Моңарчы тыныч кына сөйләшкән Иван Кириллович сабырлыгын җуя башлады. Илбарис белән Федор Степановичка сораулы караш ташлады:

– Алайса, менә нәрсә, практикант Әсәдуллинның үзен чакыртыйк та ачыклыйк... Кыек-мыек сөйләргә урын калмасын...

Тиздән Харис Әсәдуллин кереп җитте һәм, коры гына исәнләшеп, ишек янында тукталды. Өстендә зәңгәр якалы, ачык изүле ак күлмәк. Куе кара чәчләре артка яткырып таралган. Соргылт күзләренең карашы җитди иде.

– Харис, син комсомолец башың белән ни эшләп эчеп исереп йөрисең? – диде Иван Кириллович, бермәл дәшми торганнан соң.

– Юк, мин эчмәдем, мин исерек түгел идем... Дөрес түгел, ялган сөйлиләр.

– Менә сиңа мә! – Капитан Әсәдуллин көчәнүле елмаю белән кулларын җәеп җибәрде. – Аек кешене милиционер озата киләмени?.. Рәхмәт әйт, ярый әле ябып куймаганнар...

– Алайса, ник сугыштың соң? Бала түгел бит син. Шулай ярыймыни?

– Ярамаганын хәзер үзем дә аңлыйм, – диде Харис уңайсызланып. – Кисәк кенә кызып китеп, тыела алмый калдым. Барысы да шул балыктан килеп чыкты...

– Нинди балык ул? Балыкның монда нинди катнашы бар?.. Син белеп такылда!..

Харис ничек җавап бирергә белмичә аптырап калды, әйтер сүзе авызында терәлеп калгандай, тамак кырып куйды.

– Мин түгел, теге исерек матрослар такылдаган балык, – диде ул, абыйсына кыю карап. – Шуларның берсе бөтен халык алдында миңа бәйләнә башлады: бу юлы да осетр күп алдыгызмы, икрасы да, вобласы да җитәрлекме, ди. Ә икенчесе: «Урал»ның капитаны белә ул, диспетчерга балыкның иң шәбен генә ташып тора, ди. Шуның өчен аларга кире кайтканда да йөге табылып тора, причалларда да чиратсыз төйиләр, чиратсыз бушаталар, ди... Их сез, күз буяучы алдынгылар, дип, бөтен халык алдында миннән көлә, төрткәли башлады... Һәм мин түзмәдем, ачудан үзенә бәреп җибәрдем...

Харис чыгып киткәч, өстәл янындагылар, бер-берсенә туры карарга уңайсызланып, барысы да сүзсез калдылар.

## X

«Урал» Казанга иртән килеп җитте. Алып килгән баржаны элеваторга куйдылар. «Урал»ның үз йөген куәтле краннар белән тоз причалында бушата башладылар.

Иван Кириллович белән Әсәдуллин рейсның уңышлы тәмамлануы турында селектордан идарәгә хәбәр итәргә киттеләр.

Теплоход монда бер тәүлек торачак иде. Вахтадан буш халык шәһәргә чыгып китте. Илбариснын, шәһәргә чыгу түгел, иркенләп утырып тамагына ашарга да вакыты юк иде. Зәйтүнә башкалар белән бергә чыкты.

Берничә көн рәттән су өстендә килгәннән соң, коры җир ничектер тансыкланган икән. Алар кибетләрдә булдылар, музейга кереп чыктылар, Үзәк стадионда футбол карадылар. Кич белән арыпталып кайтып керсәләр, боцман Соколов аларны көтелмәгән хәбәр белән:

– Егетләр, Әсәдуллинны бездән алалар, – дип шаккатырды.

– Кемне?.. Әсәдуллинныммы?..

– Нәрсә такылдыйсың?.. Булмас ла...

– Нигә булмасын... Теплоходны бая ук тапшырып бетерде... Әнә әйберләрен җыештыра инде... Зурлап озатып калырга әзерлән...

Зәйтүнә бу хәбәргә ышанырга да, ышанмаска да белмичә аптырап калды. Ә башкалар аны барысы да җиңеллек белән каршыладылар. Арадан берсе:

– Бик шәп иткәннәр, ул тутый кошка күптән шул кирәк иде, – дип, хәтта шатланып та куйды: – Әйдә, китә бирсен, ак юл телибез үзенә... Анысы да монысы, яңа капитан килдеме соң? Нинди кеше?

– Килде, килде, инде эшләрен дә кабул итеп бетерде... Кем икәнен белергә телисезме?.. Әнә ул үзе, – дип, машина бүлегеннән менеп килгән Илбариска күрсәтте.

Барысы да кәефле елмаеп куйдылар. Ә Зәйтүнәгә тагын гаҗәпләнергә туры килде. Хыялбай дип көлеп кенә йөрелгән мыштым Илбарисны бөтен команданың шулай якын итүен һәм аның капитан булып калуына шатлануларын ничектер башына сыйдыра алмый иде ул.

Тиздән Әсәдуллин, чемоданнарын күтәреп, палубага чыкты. Илбарис аңа вокзалга әйберләрен илтешергә ике кеше бирде. Иван Кириллович белән бергә үзе дә аны причал капкасына кадәр озата чыкты һәм хәерле юл теләп саубуллашты. Ә команда членнарыннан озатучы бүтән беркем дә булмады. Бары тик Зәйтүнә генә аның китүен кызгану катнаш әрнү белән каюта тәрәзәсеннән пәрдә аша карап калды.

Берничә минуттан Илбарис белән Иван Кириллович кайтып керделәр. Кызыл почмак ишеге төбендә тәмәке көйрәтеп утырган Федор Степановичны да дәшеп алдылар. Бөтен команданыкы кебек, аларның өчесенең дә күңелләре күтәренке, йөзләре якты иде.

– Ну, Илбарис Рамазанович, сине капитан булу белән котлыйм һәм уңышлы эшләвеңне телим! – диде Иван Кириллович, беравык елмаеп карап торганнан соң. – Тырышып эшлә, һәрвакыт кешелекле бул. Хәзер, безнең көннәрдә бу бигрәк тә әһәмиятле. Әгәр бик борыныңны чөя, юкка да, барга да акырына башласаң, кешеләрне биздерәсеңне көт тә тор. Әнә Әсәдуллинны үзең күрдең. Югыйсә болай үзе тырыш та, эшен дә яхшы белә иде бит.

– Анысы шулай, ул яктан тел-теш тидерерлек түгел иде, – диде Илбарис. – Хәзер аны кая алдылар соң?.. Гомумән, бу ничек болай килеп чыкты әле?

– Башкача мөмкин түгел, бөтен коллективны таркатырга ярамый бит. Идарәгә һәм парткомга барысын да яшермичә сөйләп бирергә туры килде. Билгеле, бераз миңа да эләкте, элек кая карап йөрдең, диләр... Хәер, аны да төртеп екмадылар... Заводтан яңа теплоход чыгып килә икән, шуны кабул итәргә җибәрделәр... Идарәдә аның белән сөйләшерләр әле... Сабак булыр...

– Әгәр булмаса, тормыш үзе өйрәтә ул... Шулай бит, Зәйтүнә? – диде Илбарис, көтмәгәндә күзләре белән генә хәйләкәр елмаеп. – Ярар, ул хакта җиткән. Үз эшебез дә муеннан. Хәзер безгә карванга нинди сигнал куярга? Нинди чалкалар кулланырга, аларны ничек тарттырып бәйләргә?.. Иван Кириллович монда чагында болар турында бергәләп киңәшергә, хәл итәргә кирәк...

Зәйтүнә, ни әйтергә дә белмичә, аңа аптырап карап тора. Илбарис гомергә шулай Хыялбай булып калган һәм җилбәзәк хатынының күңелендә ниләр барын белергә дә теләми, күрәсең... Әллә, киресенчә, Зәйтүнә үзе ялгыша, үзе аны аңламый инде... Ничек тә әнә шуны беләсе иде...

## Рәссам кыз хикәясе

Без, өч скульптор, Тирән елгада йөри торган «Стрела» исемле баркаста утырабыз. Баркасның капитаны якындагы район үзәгенә киткән. Ул кайтып җитүгә, кузгалып китәчәкбез.

Безнең бригада шушы елганың түбәнге агымында күптән түгел генә төзелә башланган электр станциясе корылмаларын сынлы сәнгать фигуралары белән бизәргә тиеш. Без башта төзелешкә самолет белән барырга уйлаган идек. Юлга чыгар көн килеп җиткәч, һич тә көтмәгәндә, маршрутны үзгәртергә туры килде. Бригадабызның җитәкчесе Григорий Данилович безгә:

– Менә нәрсә, җанкисәккәйләрем, әйдәгез, бер кызык итик әле, озак булса да, су юлы белән барыйк! – дип, безне шаккатырды. – Әйе, дуслар. Тирән елга буйлап! Кызыгы да, файдасы да булыр. Безнең кебек өйдә бикләнеп ята торган халыкның фикерен уяту, хыялын канатландыру өчен дә болар бик кирәк нәрсәләр...

Шулай диде дә ул, чаларган кашларын сикертеп, миңа карап елмайды:

– Менә безнең Сәлимә табигатькә гашыйк кыз... Каршы килмәс.

Мин аның тәкъдименә шатланып кушылдым. Тик өченче иптәшебез Исрафилов кына чытык чырай белән:

– Моның нигә кирәге бар инде? Борынгы транспортка хөрмәт йөзеннәнме? – дип, ризасызлык күрсәтеп маташса да, ахыр чиктә, ул да килешергә мәҗбүр булды.

Маршрут турында киңәшүләр дә, юлга әзерләнүләр дә инде артта калды. Без менә баркаста утырабыз, кузгалып китәр өчен, капитанның кайтып җитүен генә көтәбез. Бигрәк тә Исрафилов түземсезләнә. Сөзәк тау битенә урнашкан район үзәге ягына күңелсез генә карап ала да иртәнге салкынча һавадан калтырана-калтырана:

– Юк-к, һаман күренми әле... Тиз генә күренергә исәбе юк, ахрысы, моның, – дип мыгырдана, плащының якасын югарырак күтәрә, эшләпәсен батырыбрак кия. – Әгәр самолетка утырып китсәк, кичә үк барып җитеп, инде эшкә керешкән булыр идек. Менә хәзер шушы әҗәл тагарагында кемнеңдер килгәнен көтеп утыр инде...

Хәзер таң аткан, бар табигать, төнге йокыдан уяныл, яңа көнне шатланып каршылаган тантаналы вакыт. Яр буендагы таллыкта меңнәрчә тавыштан төрле кошлар сайрый. Болын чәчәкләреннән татлы хуш исләр аңкый. Офык артыннан елмаеп калыккан кояшның беренче нурлары, сыек томан аша үтеп, тәбәнәк ярлары арасында тын гына аккан елгага сирпелә, яр буендагы кыяклы үләннәргә, камышларга кунган чык бөртекләрендә җемелди. Иртәнге һаваның искиткеч сафлыгын мин бөтен тәнем белән сизәм. Бу күренешкә күзләрен бераз кыса төшеп карап торган Григорий Данилович:

– Исрафил дус, җанкисәгем, күрәсеңме, нинди матур иртә!.. Ә син, дөньяга ник туганыңа үкенгән кеше кебек, сыкранудан туктамыйсың, – диде. – Мондый матур иртә көн дә булмый. Туры килгәндә, рәхәтен күреп кал...

Баркасыбызның рулевое ачык йөзле, кунакчыл егет икән. Багажларыбызны урнаштырганнан соң, үзебезгә ял итәр өчен кубрикта урын күрсәтте. Мачта очына кызыл флаг күтәрткәч:

– Сез, зинһар, борчылмагыз... Мансур Харисович бик төгәл кеше, тиздән кайтып җитәр, – дип, Исрафиловны тынычландырырга тырышты, машина бүлегенә иелеп, мотористны да кисәтеп куйды: – Әй, син анда әзер тор! Әйтүгә кузгалып китәрлек булсын...

Ул сүзен бетерергә дә өлгермәде, яр буенда капитанның зур-зур атлап кайтып килгәне күренде. Аның өстендә зәңгәрсу китель белән кара чалбар, башында сары эмблемалы биек фуражка. Күрер күзгә караңгы чырайлы һәм бераз тәкәббер тоелса да, сөйләшә башлагач, гаҗәп иркен, ачык күңелле егет булып чыкты бу капитан. Ап-ак тешләрен күрсәтеп елмайганда, бигрәк тә ягымлы һәм, якын дус кебек, үз күренә.

Ул барыбызга да кул биреп исәнләшкән арада, машина бүлегендә мотор гүли башлады һәм баркасыбыз, кинәт җан кергәндәй, бөтен корпусы белән тартылып алды да су өстендә дулкыннар күтәреп кузгалып та китте.

Бу баркасны тикмәгә генә «Стрела» дип атамаганнар икән. Ул чынлап та, җәядән атылган ук кебек, үткен борыны белән елганы урталай ярып, алга ыргыла, ул күтәргән йөгерек дулкыннар, сыртларында ак күбекләр уйнатып, артка тәгәриләр һәм, бик еракта калып, күздән югалалар. Тиз барудан туган йомшак җил мачта очындагы кызыл флагны җилфердәтә, күлмәк итәге, чәч толымнарым белән уйный, муенымны, битләремне кытыклап уза...

Болар барысы рәхәт, ләкин мин күңелемне әрнеткән бер авыр тойгыдан һич тә арына алмыйм. Ничек кенә онытырга тырышсам да, ул тойгы миңа тынгылык бирмичә, тишелмәгән сызлавык кебек, үзен гел сиздереп, гел мазалап тора.

Әле кайчан гына боегуның нәрсә икәнен белмәгән ачык, шат күңелле кыз идем мин. Укуда да уңмаганнар рәтендә йөрмәдем. Гадәттә аз сүзле, караңгы чырайлы Исрафилов миңа еш кына: «Шул шат күңелле булуың, булдыклылыгың өчен яратам да мин сине», – дип әйтә һәм минем янымда үзе дә ачылып китә, уйный-көлә башлый торган иде...

Институтны тәмамлап эшли башлагач, мин зур уңышсызлыкка очрадым. Мин ясаган пионер сыны яңа төзелгән зур мәктәп каршына куярлык булмады, ничектер җансыз, сүлпән килеп чыкты. Шуннан соңгы икенче эшем тагын уңышсызлыкка очрады, һәм мин, укып алган белемемне дә, сә-

ләтемне дә югалткан кебек, гаҗиз булып калдым... Менә хәзер яңа эштә тагын теләгемә ирешә алмаудан куркам.

Шундый авыр тойгыларга чумып утырганда, баркасның капитаны, үтеп барышлый, яныма килеп туктады да кичерешләремне сизенгәндәй, күңелгә ятышлы эчке бер җылылык белән, ягымлы итеп:

– Нигә болай бик моңаеп утырасыз? – дип сорады.

Әле кузгалып киткәнче, кулымны кысып күрешкән вакытта ук, бу егет миңа кай ягы беләндер үз булып күренгән иде. Шунлыктандыр, ахры, аның соравы миңа урынсыз тоелмады. Моңарчы һич тә очына чыга алмаган авыр кичерешемне, бер дә тартынмыйча, аңа сөйләп бирдем. Ләкин шуннан соң тагын борчулы уйларга бирелеп, уңайсызланып калдым: «Ничек соң мин болай изрәп төштем әле? Кисәктән генә артык ачылып китүемнән чит кешенең әллә ни уйлавы бар».

Юкка гына шикләнгәнмен икән. Ул көлмәде дә, мондый чакларда әдәп өчен генә әйтелә торган сүзләр белән тынычландырырга да тырышмады. Үзе, нидер хәтерләгәндәй, авыр көрсенеп куйды һәм, куе кашларын җыерып, беркадәр сүзсез утырганнан соң:

– Бик авыр хәл, әлбәттә... Моннан берничә ел элек, хәрби диңгез флотында хезмәт иткәндә, мин... минем бер иптәшем шулай төшенкелеккә бирелгән иде, – диде һәм, сул кулын чалбар кесәсенә тыгып, сөйләргә кереште. – Дошман белән бәрелеш вакытында бер кулы каты яраланган иде аның... Дәвалау бик авыр була, озак дәвам итә. Шулай да, алты ай гипста торганнан соң, терсәк сөяге ялгана, ләкин озак хәрәкәтсез торудан һәм кан йөреше бозылудан, бөтен беләге корый башлап, чит нәрсә кебек булып кала. Ә үзе ул дәрья суларында пароходлар йөртергә хыялланып үскән егет була һәм, матур хыялларын тормышка ашыра алмыйча, сафтан чыгуына бик кайгыра. Чынлап та, кулсыз кеше нинди капитан булсын инде!.. Әмма иптәшләре аңа төшенкелектән котылырга ярдәм итәләр, госпитальгә хәлен белергә килгәндә, күңелен күтәрергә тырышалар. Үзе дә бирешергә теләми. Зәгыйфь кулын терсәктән әле бөгеп, әле турайтып хәрәкәт итәргә күнектерә башлый. Берничә ай тырыша торгач, моның беләгенә аз-азлап ит куна, бераз хәл керә, ниһаять, ул тәмам савыга; тик баш бармаксыз гына кала. Хәзер инде ул теләгенә иреште: рәхәтләнеп эшли һәм су транспорты институтында читтән торып укый...

Капитан сөйләгән бу вакыйгада, беренче карашка, гаҗәпләнерлек берни дә юк шикелле. Ләкин ул аны авыр көрсенеп сөйләгәнгәме, диңгезченең язмышы мине дә дулкынландырды һәм уйландырды. Мин дә бит әле бар көчемне биреп эшләмәдем, әгәр чын-чынлап тырышсам, теге диңгезче егет кебек теләгемә ирешермен, җиңеп чыгармын шикелле тоелды миңа.

Кичә бу тирәләрдә каты яңгырлар булып үткән икән. Тирән елга, язгы ташу вакытындагы кебек, тулып ага. Урыны-урыны белән ул ярларыннан ашып чыгып, тугайларга җәелгән, тәбәнәк атауларны су баскан.

Баркасыбыз шәфәкъ яктысына алсуланган тын елга уртасыннан һаман алга бара, җанны рәхәтләндереп җай гына тирбәлә. Сирәк-мирәк баржа тартып баручы баркаслар каршыга очрый, андасанда балыкчы көймәләре күренеп кала. Елганың уң ягындагы тезмә тауларның түбәләре баеп бара торган кояшның соңгы нурларына балкыган. Каршы якта йокымсыраган болыннар һәм күлләр өстендә күтәрелгән ак томан сизелер-сизелмәс кенә агыла.

Григорий Данилович белән Исрафилов ял итәргә кубрикка төшеп киттеләр. Үзем дә бөтен тәнемдә ниндидер рәхәт талчыгу сизәм... Шулай да күземә йокы керми. Чыбыктан үрелгән диванда кичке табигатькә сокланып карап барам. Бөтен тирә-як кичке тынлыкка чумган. Тик машина бүлегеннән мотор гөрелдәве һәм койрыкта йөгерек дулкыннар гүләве генә, бик ерактан килгәндәй, тонык кына булып ишетелә. Рулевой мачта очыннан флагны төшерде, сигнал утларын кабызды. Капитан Харисов рубкада басып тора һәм, куе кашларын җыерып, бинокльдән алгы юлны күзәтә. Үзенә сиздермичә генә аның сурәтен, омтылышын альбомыма сызгалап аласым килә, тик моның өчен аның үзенә генә хас хәрәкәтен, торышын ачык итеп күрә алмыйм шикелле.

Шулай әйбәт кенә барган вакытта, баркасыбыз нәрсәгәдер абынгандай булды һәм әле бер, әле икенче якка нык кына чайкалып алды да шып туктады. Кинәт тукталудан үзем дә диваннан чак кына егылып төшмәдем. Кубриктан башы-күзе тонган Исрафилов килеп чыкты, аның артыннан Григорий Данилович күренде. Ә капитан, кулындагы биноклен рулевойга биреп, шунда ук штурвал көпчәге янына үзе басты һәм машинаны туктатырга кушты. Аннары артка борылды да килгән юлга карап хәрәкәтсез калды. Инде бераз тынычлана төшкән Исрафилов: «Их хәсрәт-капитан, бөтенләй коты очты үзенең», – дип көлгән булса да, ул аңа игътибар итмәде, һаман хәрәкәтсез тора бирде. Бездән калган дулкыннарны агымсу баркас турысына китереп җиткергәч кенә, ул бөтен гәүдәсе белән машина рупорына җитез генә борылды да:

– Вперед, полный! – дип команда бирде һәм, шул дулкыннар сизелер-сизелмәс кенә тибрәтеп үткән арада, баркасыбыз сайлыктан ычкынып та өлгерде.

Бу минутта капитан егет минем каршымда кинәт үзгәреп, үсеп киткәндәй булды. Аның җитди хәрәкәт белән штурвал көпчәген боруында, куе кашларын җыерып алга каравында, команда бирүендә – һәммәсендә дә кыюлык, нинди генә тоткарлык очраса да, җиңеп чыгарга сәләтлелек күренә иде.

Сай җирдән үтүгә, без һәммәбез дә җиңел сулап җибәрдек һәм капитанга аеруча ихтирам белән карый башладык. Григорий Данилович:

– Менә бу художник!.. Менә бу үз эшенең остасы! – дип, гадәттә бик булдыклы укучыларына гына әйтә торган иң югары бәясен бирде.

Әле һаман тынычлана алмаган рулевой:

– Мансур Харисович, кичә бу турыдан тоткарсыз гына үткән идек. Бүген, су артуга карамастан, әнә ни эшләдек, – дип гаҗәпләнде.

Капитан нидер эзләгәндәй әйләнә-тирәгә күз йөртеп чыкты да:

– Син дә шул, кызлар янында гына очлы күзле буласың, – дип шаяртып алды һәм елганың сул ягыннан килеп кушылган инешкә таба кулы белән төртеп күрсәтте: – Әнә күрәсеңме? Кичәге яңгырдан соң ташыган инеш басулардан алып килгән ләмне шушында өеп калдырган.

Шул чак мин капитанның сул кулында баш бармагы юклыгын күреп калдым. Һәм ихтыярсыз: «Кара син аны, бу үзе дә баш бармаксыз икән!» – дип, бик гаҗәпләндем һәм бераздан, ул кубрикка төшеп киткән арада, рулевойдан:

– Капитаныгызның сул кулында бер бармагы юк икән. Кайда өздергән ул аны? – дип сорамыйча түзмәдем.

– Әйе, юк шул... Флотта хезмәт иткәндә ул чак кына кулсыз калмаган, – дип җавап бирде рулевой.

Бу сүзләрне ул, эшеннән туктамыйча, тыныч кына әйтсә дә, мин бик гаҗәпләндем:

«Шулаймы икәнни?! Аның үз башыннан үткән хәл микәнни?» – дип, чак кына кычкырып җибәрмәдем. Ул, кубриктан чыгып, тагын штурвал көпчәге янына баскач, мин, күзләремне ала алмыйча, озак кына аңа карап тордым һәм шунда ук альбомга рәсемен дә сызгалый башладым. Баягынак тотып алуы читен булган сызыклары да, үзен тотышы да хәзер минем өчен ачык, аңлаешлы һәм кәгазьгә төшәргә сорап тора иде. Әгәр мөмкин булса, хәзер үк мин аның мәһабәт сынын да ясый башлар идем.

* * *

Гидростройга барып җиткәннең иртәгесен без квартирага урнаштык, төзелеш белән, үзебезнең мастерской белән таныштык. Яңа урында вакыт бик тиз үтте. Көндезге мәшәкатьләрдән бушагач, кичкырын миңа ничектер ямансу булып китте. Йокларга иртә иде әле. Укырга да күңел тартмагач, бераз йөреп керергә теләп, урамга чыктым.

Төзүчеләр поселогы Тирән елгага караган биек тау итәгендә җайлы гына урнашкан. Су буйлары көндезге эштән бушаган халык белән тулы. Тау өстендәге парктан күңелле музыка тавышы килә, радиодан булса кирәк, кемнеңдер җырлавы ишетелә.

Менә шул бакчадан чыгып, урам буйлап китеп баручы берәүнең йөреше миңа танышларымнан кемнедер хәтерләткәндәй булды. Һәм мин, үзем дә сизмәстән, күздән югалтмас өчен аның артыннан иярдем. Өстенә кыска җиңле ак күлмәк, кара чалбар кигән, кабарып торган коңгырт чәчләрен артка яткырып тараган бу кеше акрын гына атлый иде. Арабыз якыная төшкәч, ул, артыннан кеше килгәнен сизгәндәй, кинәт кенә борылып карады һәм мин аның кичә безне монда алып килгән капитан Харисов икәнен таныдым. Шул вакыт бөтен йөзе ачылып, яктырып киткән Харисов:

– Менә көтелмәгән очрашу! – дип, бик гаҗәпләнде һәм, әле һаман күзләренә ышанмагандай, тагын бер тапкыр миңа карап алды. – Кая юл тотасыз болай?.. Кайтып баруыгызмы, кая да булса ашыгасызмы?

– Болай беркая да ашыкмыйм... Поселокны күрергә теләдем. Бераз йөреп керергә чыгуым иде...

– Дөрес, яңа урын белән таныш булырга кирәк... Әгәр рөхсәт итсәгез, поселокны да, пристань тирәләрен дә сезгә үзем күрсәтәм...

Ул кичне без Тирән елга буенда озак йөрдек. Харисов үз тормышы турында, су транспорты институтында читтән торып укуы турында сөйләде. Аны тыңлау миңа рәхәт, күңелемне иркәли, ул сөйләгән вакыйгалар миңа да якын булып тоела иде.

Көндез бик бөркү иде. Эңгер-меңгер төшкәч, һава бераз сүрелде, талгыная төште. Аргы яктагы әрәмәләр артыннан күтәрелгән тулы ай нуры Тирән елга аша якты күпердәй балкып китте... Ай инде шактый югары күтәрелгәч, мин:

– Мансур иптәш, вакыт соң инде... Кайтырга кирәк, – дидем һәм, гаҗәп, бу исемнең, яраткан көй кебек, күңелемә ятышлы булуын хис иттем.

– Сәлимә, күрәсезме елга нинди матур! – диде Мансур, минем сүземне ишетмәгәндәй. – Шунда туып, шушы елга суларында коенып үскәнгәме, мин аны яратам. Кайчандыр, малай вакытта ук әле, аның турында бер шигырь дә язган идем. Балачак – юләр чак бит, ниләр генә эшләмисең... Бүген бу елга минем өчен бигрәк тә ямьле... Әгәр сезгә күңелсез булмаса, кайтырга ашыкмасагыз иде...

Без ашыкмадык. Төн сокланып туйгысыз матур, зәңгәрсу күктә тын гына йөзгән ай да искиткеч якты балкый иде. Мин, кайту турында әле генә әйткән сүзләремне онытып:

– Айның болай якты балкыганын моңарчы бер дә күргәнем юк иде... Карасана, дөньяга ничек нур сирпи! – дидем.

– Мин дә шуны әйтмәкче идем, – диде Мансур. – Беләсезме, Сәлимә, безнең танышу шатлыгыннан шулай якты балкый ул...

Икебез дә рәхәтләнеп көлдек.

* * *

Бу көнгә кадәр төзелешне ачык итеп күз алдыма китерә алмаганмын икән. Минем уйлавымча, ул гади бер гидроэлектростанция булырга тиеш, димәк, безне дә зур эзләнүләр таләп итми торган җиңел генә эш көтәдер шикелле иде. Төзелеш белән таныша башлауга, мин үземнең ялгыш караштa булуымны аңладым. Гидроузелның Тирән елга буендагы бөтен өлкә тормышына үзгәрешләр кертерлек зур көч булачагын һәм без иҗат итәчәк сынлы сәнгать образлары да шул эчтәлеккә тиң булырга, электростанциянең мәһабәт корылмаларына эстетик ямь бирергә тиешлеген күрдем.

Турысын әйтергә кирәк, бу җаваплы бурыч алдында башта мин каушап, эшкә ничек керешергә белмичә, аптырап калдым. Үч иткән кебек, нәкъ шул көннәрдә каты авырый башлаган Григорий Даниловичны шәһәргә больницага озаттык. Тиздән Мансур да Тирән елганың су астында калачак районнарын өйрәнүче бер төркем геологларны утыртып китеп барды. Җитмәсә, тагын Исрафилов аптырата башлады үземне.

Исрафилов белән без институтта бергә укыган идек, практиканы да мин аның әтисе җитәкчелегендә үттем. Шулай гел бергә йөри торгач, без бер-беребезгә ияләшеп, дуслашып беткән идек.

Әмма арабыз юк кына нәрсәдән бозылып китте. Көндезге ял вакытында институт каршындагы кечкенә бакчада йөргәндә, мин аңа эшемнең авыр булуы турында сөйләдем. Шул чак Исрафилов артык уйлап тормыйча:

– Һи, тапкансың борчылырга сәбәп! Икәү бергә эшләрбез, миңа ярдәм итәрсең, – диде. – Үзеңә билгеле, әти картның сәламәтлеге бик какшаган инде, мәңге яшәмәс. Аның бай мастерское да, сынлы сәнгать даирәсендә мәшһүр Исрафиловлар фамилиясе дә миңа кала. Аңла, бу кечкенә нәрсә түгел. Мин заказлар табу, аларның идеясе, эчтәлеге турында кайгыртырмын, матбугатта, күргәзмәләрдә популярлаштыру чарасын күрермен. Ә син миңа ярдәм итәрсең, күбрәк мастерскойда эшләрсең.

Мин, гаҗәпләнүемне яшерә алмыйча:

– Моны ничек аңларга?! – дип сорадым. – Димәк, миңа иҗади эзләнүләр кирәкми, бөтен эшем, гади һөнәрче кебек, син җыйган заказларны үтәү, синең фикерләр буенча эшләү белән генә чикләнәчәкмени?

Бала чактан ук мин кызыл балчыктан матур итеп курчаклар, уенчыклар ясарга бик ярата идем. Шушы һәвәслек үземне художество мәктәбенә алып килде. Аннары институтка кердем, зур эчтәлекле сәнгать образлары тудыру турында хыялландым. Менә хәзер, инде чынлап торып эшкә керешер вакыт җиткәч кенә, мине гади бер һөнәрче итеп калдырмакчы булалар. Билгеле, Исрафилов белән килешә алмадым:

– Юк, дускаем, бу гаделсезлек булыр иде, – дидем һәм аның ялгыш караштa булуын аңлатырга тырыштым.

Ул көнне без күңелсез генә аерылыштык. Исрафилов башта үпкәләп, сөйләшмәгән булып йөрде. «Ялыныр, гафу үтенер» дип уйлады булса кирәк. Соңыннан үзе гафу үтенсә дә, инде мин ачылып китә алмадым, көннән-көн читләшә генә бардым.

Билгеле, төзелешкә килгәч Мансур белән минем арада башланган мөнәсәбәтне ул сизенә, үзенчә авыр кичерә иде. Мансур китүгә, ул башта җайлап килешергә теләде, ахырда, барып чыкмагач, мине чынлап торып эзәрлекли башлады.

Әйдә, теләсә ни эшләсен, мин аңа артык борчылмыйм. Чөнки күңелемне җылытып, куанычымны арттырып тора торган кешем бар минем. Аны сагынган минутларда эштә онытылырга тырышам. Мастерскойда эшләп арысам, төзелеш мәйданына чыгам, төзүчеләр белән очрашам.

Күбесенчә мин шлюз каналында булам, этюдлар ясыйм. Плотина төзү тәмам булгач, пароходлар, кәрваннар, шушы шлюз аша үтеп, Тирән елганың моңарчы олы юллардан еракта торган районнарына барып җитәчәк. Мин ясый торган статуя, әгәр уңышлы чыкса, шушы шлюз башнясы өстенә куелырга тиеш. Мин аны штурвал көпчәге янында баскан капитан итеп ясыйм. Аның зур куллары белән штурвал көпчәген тотуында, бөтен гәүдәсенең торышында, зирәк күзләренең еракка каравында – барысында да кыюлык һәм ихтыяр көче сизелергә тиеш.

Моңарчы минем беркайчан да болай рәхәтләнеп эшләгәнем юк иде әле. Мастерскойда ялгызым гына булган чакларымда яраткан җырымны җырлый-җырлый эшлим:

Елмай, иркәм, елмай, иркәм,
Елмаюларың күркәм.
Синең елмаюларыңны
Күз алларымда йөртәм.

Көннәрдән бер көнне ясый торган статуямның Мансурга охшаган булуын күреп, үзем дә таң калдым. Ул минем ихтыярымнан тыш шулай чыкты булса кирәк. Чөнки күңелемдә гел Мансур, үземне гел аның белән бергә хис итәм, аның йөзен күз алдымда күреп эшлим мин.

Бу охшашлыкны Исрафилов та күрде. Бүген иртән эшкә килсәм, станогым янында басып тора. Сөмсере коелган. Исәнләшүемә җавап та бирмәстән:

– Нәрсә бу?! Сез монда сөйгән ярыгызга монумент куймакчы булдыгызмыни?– дип тотынды һәм, минем җавап кайтарырга җыенмавымны күреп, тагын да катырак кызып китте. – Юк, мин моны рөхсәт итә алмыйм... Монда мине бригадир итеп калдырганнар икән, димәк, моның җавабы миңа да төшә. Бу хакта бүген үк төзелеш идарәсенә дә, институтка да җиткерергә тиешмен!

Ләкин аңа күп тыпырчынырга туры килмәде. Төш җитәрәк Григорий Даниловичның кайтуын хәбәр иттеләр. Тиздән ул үзе дә мастерскойга килеп җитте. Үзе белән төзелеш архитекторы Николай Кузьминны да ияртеп килгән. Болай да чандыр гәүдәле Григорий Данилович авырганнан соң тагын да ябыгып калган, яңак сөякләре калкып чыккан. Шулай да үзе шат күренә. Эчкә баткан күзләре елмаеп карыйлар. Өстәлләрдәге һәм киштәләрдәге төрле бюстларга, этюд һәм детальләргә күзе төшүгә, мактап та алды үзебезне:

– Күрәм, күрәм, тик тормаганнар болар... Шулай кирәк тә, көч түкмичә, эзләнмичә генә булмый бит. – Ул, нидер эзләгәндәй, әйләнә-тирәгә карап алды да сорап куйды: – Ничек соң, ни дә булса тәмамлый алдыгызмы? Минә Николай Кузьмич та сезнең эшләр белән кызыксына.

Исрафилов безне үзе эшли торган якка алып керде. Шакмаклы зур ширма белән бүлеп алынган бу почмакка бер дә аяк басканым юк иде. Яшермим, мин монда бик кызыксынып кердем, чөнки Исрафиловның эшен беренче тапкыр күрүем иде. Чандыр гына гәүдәле бер яшүсмер, ике куллап, баш очына кувшин сыман әйбер күтәргән. Җентекләп караганнан соң, сынның башыннан берничә тапкыр зур итеп ясалган бу әйбернең кувшин түгел, ә электр лампочкасы икәнен аңлап алдым. Архитектор Николай Кузьмичның да беренче тәэсире шундый булса кирәк, күзлеген бер киеп, бер салып карады да, берәүгә дә атап әйтмичә, кулындагы көмеш саплы таягы белән «кувшинга» төртеп күрсәтте:

– Монысы нәрсә була инде аның?.. Электр лампочкасымы?–дип сорау бирде.

– Әйе, әйе, Николай Кузьмич, бик дөрес аңлагансыз, – диде Исрафилов, кәефле елмаеп. – Гидроэлектростанциянең бу якларга яктылык алып килү идеясен шушы лампочка белән бирергә теләдем.

Әлегә бер сүз дә дәшмичә торган Григорий Данилович сын әйләнәсендә ашыкмыйча гына тагын бер тапкыр йөреп чыкты. Якыннан да, читкәрәк китеп тә озак-озак карап торды һәм чаларган мыекларын ризасыз гына селкетеп алды, Исрафиловка туры карамаска тырышып:

– Гаҗәбрәк килеп чыккан икән. Җанлы кешедән бигрәк, лампочка турында сүз йөртергә туры килә икән... – диде.

Аннары ул җәенке кашлары астыннан миңа өметсез генә карап:

– Йә, инде сез ни белән шатландырмакчы буласыз, – диде дә мин эшли торган якка чыгып китте һәм, килеп җиткәнемне дә көтмичә, җәймәне ачып, эшемне карый башлады.

Гаҗәп, минем капитанымны күрүгә, Григорий Данилович үзе дә, коеп куйган сын кебек, җәймә тоткан көе хәрәкәтсез калды һәм бер минут чамасы вакыт үткәч кенә, үз күзләренә ышанмагандай, бер Николай Кузьмичка, бер миңа карап алды һәм соклануын яшерә алмыйча:

– Менә бу капитан! Менә бу чын баһадир! Иңбашларыннан сыйпап аласы килә үзен, – диде. – Шлюз башнясы өстендә ул бик мәһабәт булып торачак. Әйләнә-тирәдәге пейзаж белән дә ярашкан, шлюзның архитектурасына да ямь бирәчәк... Эчтәлеге дә ачык: ераклардан килгән кәрваннарны сәлам биреп каршы алыр. Тирән елга буйлап киткәндә, аларга хәерле юл теләп калыр!

Статуяны тагын бер тапкыр карарга керешкәндә, ул кинәт нидер хәтерләгәндәй:

– Карыйм-карыйм да, мин бу егетне кемгәдер охшаткан кебек булам... Әгәр ялгышмасам, теге кемгә, безне монда алып килгән капитан егеткә бераз тартым, – дип елмайды һәм, йөземә кинәт куе кызыллык йөгерүен күреп, сүзен тиз генә икенчегә борып җибәрде.

## Казан кызы

Һөҗүм төннең иң караңгы вакытында башланды һәм башта партизаннар өчен уңыш белән барды.

Көтелмәгән һөҗүмнән котлары очкан немецлар оешкан рәвештә каршылык күрсәтә алмадылар. Оялары туздырылып ташланган шөпшәләрдәй, ары барып бәрелделәр, бире ташландылар һәм, шул рәвешчә, кая гына булса да качып котылырга, башларын саклап калырга ашыктылар.

Ә партизаннар, шушы паникадан файдаланып, район үзәге булган Биектау исемле зур авылның яртысына якын өлешен тиз арада үз кулларына алып та өлгерделәр.

Бу – уңышлы башлангыч иде.

Беренче уңыш, үзенә ияртеп, зур кайгы алып килде: сугышның иң кызу вакытында отрядның командиры Борисов каты яраланды. Яраланган командирны сугыш уты эченнән отрядтагы берденбер татар кызы Сания алып чыкты. Командирны авыл читендәге кечерәк кенә таш өйгә кертеп урнаштыргач та, ул аның янында һаман үзе булды. Командирны күтәреп кертергә ярдәм итүчеләргә:

– Иптәшләр, сезгә урамда булырга, андагыларга ярдәм итәргә кирәк. Авыруны үзем карармын... Калдырыгыз аны! – диде һәм, шул минуттан башлап, яраланган командирны үзе генә карый, үзе генә дәвалый башлады.

Партизаннар аның эшенә катнашмадылар. Йорт хуҗасы карчыкка:

– Әби, сез, зинһар, тарсынмагыз инде... Без хәзер үк, немецларны куып чыгаргач та, авыруны сездән алып чыгарбыз, – диделәр дә урамга дошман калдыкларын куарга ашыктылар.

Әмма немецларны куып чыгару алай җиңел генә булмады. Киресенчә, аларга ярдәмгә килеп җиткән яңа көчләрнең кысуы аркасында, партизаннар үзләре авылны калдырып чигенергә мәҗбүр булдылар. Немецларның бу яңа көчләре арттан, карчыкның өе урнашкан яктан китереп бәргәнгә, командирны да, аның янындагы Санияне дә коткара алмадылар. Аларны коткарырга теләп таш өйгә таба берничә мәртәбә ташланып карасалар да, файдасыз кан түгүдән башка нәтиҗәгә ирешмәделәр.

Шулай итеп, һич тә көтелмәгән бәхетсез шартлар нәтиҗәсендә, отряд, үзенең сөекле командирын дошман кулында калдырып, урманга кайтып китәргә мәҗбүр булды.

Партизаннар өчен авыр көннәр башланды.

Тиңе булмаган авыр хәлдән котылу юлын берәү дә күрсәтә алмады. Командирны югалту кайгысы һәркемнең күңелен хәсрәт белән тутырды, күңелсез уйлар уятты. Кайберәүләр эчкәли дә башладылар...

Шулай өч тәүлек үтте.

Сания дүртенче тәүлек башланганда гына кайтып керде. Вакыт соң булуга карамастан, партизаннар йокламаганнар иде әле. Санияне күрү белән, берсен-берсе бүлдереп:

– Борисов кайда?

– Командирны кем белән калдырдың?

– Үзең ничек котылдың? – дигән сораулар белән аны әйләндереп алдылар.

Беренче минутларны Сания болай берьюлы яуган сорауларның кайсына җавап бирергә дә белми торды. Бераз тынычлык туып, сүз әйтергә мөмкинлек булгач кына, сорауларга сорау белән җавап биреп:

– Ә монда сезнең эшләр ничек? – дип куйды.

Шау-шу шул ук секундта басылды, һәркем тирән сулап алды. Кайберәүләр, гаебен сизгән кешедәй, читкә борылдылар яки түбән карадылар. Тирә-юньне авыр тынлык басты. Сания ирексез-

дән: «Нәрсә булган тагын? Җитмәсә, кайдандыр аракы исе дә килә», – дип, үз-үзенә сөйләнгән булып, борчылып куйды һәм шунда ук үз тирәсендәге халык арасында эчкән кешеләр барлыгын сизеп алды. Гадәттәгедән артык кычкырып сөйләшүләр дә, «Монда сезнең эшләр ничек?» дигән сорауга туры җавап бирә алмау да моны ачык аңлатып тора иде.

Элек, командир бар чакта, отрядта эчү катгый рәвештә тыела иде.

Бу начар яңалыкны аңлау белән Саниянең тыны беткәндәй булды. «Командир булмагач, шулай бик тиз таркаулык башландымыни?» – дип, иптәшләренә карап эндәшәсе, аларны оялтасы килде.

Сания, бернәрсә дә сизенмәгән булып, шаян тавыш белән:

– Нәрсә борыннарыгызны салындырдыгыз? – дип шаярып алды да Борисов турында сөйләргә кереште. Командирның ярасы авыр булуга карамастан, хәле бераз җиңеләя төшүен, саташудан туктавын сөйләп, һәммәсен дә шатландырды. Аларның күңелләре күтәрелүен күргәч, үзенең дә боеккан йөзендә елмаю туды.

– Йорт хуҗасы бик яхшы һәм җылы күңелле карчык булып чыкты. Аның үз улы да фронтта икән. Сез авылны калдырып киткәч тә, немецлар күрмәсен дип, безне чоланга, идән астына урнаштырды. Борисовның ярасын дарулап бәйләргә ярдәм итте, – дип, партизаннарны шатландырганнан-шатландыра барды.

Кыскача гына итеп авыл хәбәрләрен сөйләп бирде дә аннары яңадан командир турында сөйләргә кереште:

– Борисов ике-өч атна чамасы урыныннан кузгала алмас әле. Юклы-барлы хәле белән аны авылдан монда кайтарырга ашыгу – куркыныч эш. Шуңа күрә безгә бу көннәрне командирның авылдан торып җитәкчелек итүе белән канәгатьләнергә туры килер. Отряд белән үзе арасында элемтәче итеп иптәш Борисов мине билгеләде. Беренче бурыч итеп, ул сезгә Тирән елга күперен җимерергә боерды. Чөнки шул күпер аша немецлар үзләренең Биектауда тупланган көчләрен фронтка озаталар, – диде һәм үзе, озак та тормыйча, авылга, авыру командир янына китте.

Өченче төнне ул тагын әйләнеп кайтты. Партизаннар аңа командирның боерыгы ничек үтәлүен, фрицларны ничек кыруларын җиткерделәр. Сания аларның һәммәсенә дә отряд командиры Борисовның сәламен тапшырды, ничек савыгуын сөйләде, күп кенә нәрсәләр турында үзе сорашты, үзе хәл кыла алмаган мәсьәләләрне командирга җиткерергә булды.

Әнә шул рәвешчә аңлашып беткәннән соң, Сания командирның яңа боерыгын белдерде:

– Без урнашкан урманның көнчыгышындагы зур аланлыкта немецлар яшерен аэродром әзерлиләр. Анда самолетлар да, бомба складлары да бар. Шушы аэродромнан очып китеп, алар безнең шәһәрләргә бомба ташларга җыеналар. Әгәр шул аэродромны эштән чыгарып ташлый алсак, үзебезнең гаскәрләргә зур ярдәм булыр иде, – диде, үзе, караңгыдан файдаланып, командир янына китәргә ашыкты.

Сания үзе кайчандыр Казан авыл хуҗалыгы институты студенткасы иде. Бу якларга һәм бу эшләргә ул практикага килгән җиреннән әләкте. Кызганычка каршы, практика белән шөгыльләнә алмады – сугыш башланды һәм, ул үзе кебек совет кешеләре белән бергә, явыз дошманга каршы көрәшкә ташланды.

Отрядта аны беренче көннән башлап ук «Казан кызы» дип атадылар һәм үзе юкта һәркайчан диярлек шушы яңа исем белән атап йөртә торган булдылар.

Үзенең ягымлы булуы, авыруларга уңышлы ярдәм күрсәтә алуы һәм, бигрәк тә, ирләр арасында үзен тота белүе, көрәш авырлыкларын җиңел кичерүе белән Казан кызы тиз арада бөтен отрядның мәхәббәтен һәм ихтирамын казанды. Партизаннар аңа ияләнделәр, якын күрә башладылар.

Дошман кулындагы авылда калган авыру командирны карарга һәм аның белән отряд арасында элемтәчелек эшен үтәргә керешкәннән бирле партизаннар Казан кызын бигрәк тә якын күрә, Борисовның үзенә карагандай, аңа тирән ихтирам белән карый башладылар.

Менә бүген, урманга әйләнеп кайтуы белән, партизаннар аңа аэродромга ничек һөҗүм ясауларын, самолетларны шартлатуларын – һәммәсен дә, командирга җиткергәндәй, сөйләргә керештеләр. Сания аларны зур игътибар белән тыңлады. Кайбер нәрсәләрне кабатлап сорашып, бәрелеш планын үзе төзегән командирдай, һөҗүм картинасын күз алдына китерергә, аның уңышлы һәм җитешмәгән якларын аңларга тырышты. Булдыклылык күрсәткән егетләрне шунда ук мактап та куйды:

– Мин сезнең турында командирга җиткерермен. Ул бик канәгать булыр,– дип күңелләрен күтәрде һәм командирның яңа боерыгын белдерде:

– Иртәгә Биектауга икенче мәртәбә һөҗүм ясарга кушыла, – диде һәм һөҗүмнең планын аңлатырга кереште.

– Болай турыдан-туры ташланып кына без авылдан немецларны куып чыгара алачак түгелбез. Немецлар анда шактый нык утыралар. Аларны ул ныгытмалардан ничек тә алдап чыгарырга һәм үзебезгә җайлы позициядә кыйнарга кирәк. Моның өчен без, иптәш Борисов күрсәткәнчә, ике төркемгә бүленеп эш итәрбез. Төркемнәрнең берсе авыл читендә утырган монастырьга кереп, шуннан авылның немецлар урнашкан урамнарына таба минометтан ут ача. Немецлар бу картинага тыныч кына карап кала алмаячаклар, әлбәттә. Авылдан чыгып монастырьга ташланачаклар. Менә шул вакытны безнең икенче төркем, аларның артыннан килеп, шәп кенә итеп бәрергә тиеш булыр, – диде.

Бу төнне Сания авылга кайтып китмәде, һөҗүмгә әзерлек эшләре белән үзе җитәкчелек итте. Тәҗрибәле сугышчылар белән киңәште һәм, шулай итеп, һөҗүмне уңышлы үткәрүгә ирешү өчен кирәк булган чараларның һәммәсен дә күрергә тырышты.

Икенче төнне, план буенча билгеләнгән вакыт җиткәч, төркемнәрнең берсе, Сания җитәкчелеге астында, монастырьны камап алды.

Кайчандыр монастырь булган, ә хәзер ташланган чиркәүгә әйләнгән гыйбадәтханәдә сакчы хезмәтен үтәүче Антон карттан башка берәү дә юк иде. Ул башта төнге кунакларны ризасызлык белән: «Нинди җеннәр йөртә сезне?» – дип мыгырданып каршы алса да, аларның үз кешеләр икәнен аңлагач, каршылык күрсәтмәде. Партизаннар арасыннан үзенең улы белән уйнап үскән шаян егет Александрны танып алып, аның:

– Атакай, юкка борчылма! Изгеләреңнең серле тынлыгын бозмас өчен ничек сак кылануыбызны үзең күрәсең бит, – дип, шаян көлүен ишеткәч, бөтенләй тынычланды. Төркемнең җитәкчесе кыю хәрәкәтле яшь кыз аны гаҗәпләндерде. Кызның боерыкларын һәркемнең тизлек белән үтәвен күргәч, ул: «Марфа Посадская кебек юлбашчыларыдыр, ахры», – дип, үзен-үзе тынычландырды.

Антон карт әнә шулай уйлангалап торган арада, партизаннар пулеметларын тәрәзәләргә урнаштырдылар, гранаталар ташларга, автоматлардан ут ачарга әзерләнеп өлгерделәр һәм ишегалдындагы минометтан авылга таба ата да башладылар.

Төнге тынлыкны бозып, бер-бер артлы миналар шартлый башлауга, бөтен авыл хәрәкәткә килде: чалтырап тәрәзәләр ватылды, берничә автомат тәртипсез такылдарга тотынды. Авылны яктыртып салам өеме яна башлады.

Беренче чуалыш озакка сузылмады. Авылның үзендә куркыныч булмавына төшенгәч тә, немецлар аңнарына килделәр һәм, «тәртип бозучыларны» акылга өйрәтү теләге белән, монастырьга юнәлделәр.

Немецлар авылдан чыкканда, сызылып таң атып килә иде.

Авыл белән монастырь арасында яз көннәре кар сулары белән кушылып тулы су агып торган, хәзер исә тәмам саеккан инеш үтә. Инешнең монастырьга таба ягы сары ком белән капланган. Сызылып таң атканда, монастырь тәрәзәсеннән карап торган Антон картка ком капланган мәйдан җан иясе булмаган чүл кебек булып күренә иде.

Елганы үтеп шушы комга керүгә, алдан килүче зур гәүдәле офицер, артына борылып, нәрсәдер кычкырынды да, кулындагы автоматын болгый-болгый, монастырьга таба йөгерә башлады. Башкалар, ямьсез акырышып, аның артыннан йөгерергә тотындылар.

Калтыраган иреннәре белән бертуктаусыз нидер укынып тәрәзәдән күзәтеп торган Антон картның күзләре офицердан аерылмады. Зур гәүдәле офицер чаба башлауга, Антон карт чын күңеленнән:

– Йа Раббым, гыйбадәтханәңне саклаучыларыңны үзеңнең ярдәмеңнән мәхрүм итмә инде!.. – диде дә ашыгып-ашыгып чукынырга тотынды.

Ул яңадан «Йа Раббым!» дип үзенең Алласына ялварырга өлгермәде, монастырь эчен яңгыратып, пулемет һәм автоматлар дәррәү атарга тотындылар.

Антон картның күзләре әле һаман алдан акыра-акыра килүче алыптай гәүдәле офицерны күзәтә иделәр. Пулеметлар такылдый башлауга, зур гәүдәле офицер кинәт, нәрсәгәдер сөртенгәндәй, абынып китте һәм берничә адым атлагач та икенче тапкыр «сөртенеп» әйләнеп төште.

Моңа кадәр аңа ияреп килгән солдатлар, хәзер дә офицерларыннан үрнәк алган төсле, нәкъ аның кебек төрлесе төрле якка ава, тәгәри башладылар.

Сафлар алга барган саен кимеделәр һәм монастырьга якынайганда бөтенләй сирәгәеп калдылар. Менә алар туктадылар һәм, давылга каршы бара алмагандай, комга яттылар. Әмма озак ята алмадылар, бәреп яуган үлем яңгырына чыдый алмыйча, чигенә башладылар.

Башта алар күтәрелергә батырчылык итмичә, үлгән иптәшләренең гәүдәләре артына яшеренә-яшеренә, ятып кына шуыштылар. Бераздан, инешкә җитәрәк, аякларына басып, барлык көчләренә чабарга, качарга тотындылар.

Антон карт бу картина белән озак кызыксына алмады. Аның тәртипсез чигенүче немецларга каршы килгән сафларга күзе төште. Ул тагын: «Йа Раббым, бу иблисләргә яңа ярдәм җибәрдеңмени?!» – дип, үзенең Алласы белән сөйләшергә тотынды. Әмма күп сөйләшә алмады. Аның сүзләрен бүлеп, бөтен монастырьга Саниянең тавышы яңгырады. Ул:

– Иптәшләр, әнә килеп тә җиттеләр. Әйдәгез, минем арттан! – диде дә ишектән чабып чыгып та китте. Башкалар, «ура!» кычкырып, аның артыннан ташландылар...

Немецларның үлекләре ком өстендә анда-монда аунап калдылар. Берничә әсирдән һәм яралланучылардан башка бер генә фриц та исән калмады.

Сугыш бетүгә, партизаннар авылга, командирлары янына юнәлделәр. Алар урамдагы халыкның рәхмәтләрен дә гадәттәгечә иркенләп тыңламадылар, якын туганнары турында да сорашмадылар, һәммәсе дә сөекле командирны күрергә, аның хәлен белергә ашыктылар.

Алар барып җиткәндә, таш өй янында таякка таянып бер карчык тора иде. Теге бәхетсез төнне яраланган командирны күтәреп кертергә ярдәм иткән шаян егет Александр карчыкның шушы таш өй хуҗасы булуын шунда ук таныды.

– Хөрмәтле әби, безнең командирыбыз һаман кузгала алмыймыни әле? Без бөтен семьябыз белән аның хәлен белергә килгән идек, – дип куйды.

Карчыкның йөзе кинәт агарып киткәндәй булды. Кансыз иреннәре калтырый башладылар.

– И балакаем, сезнең командирыгыз... үлде бит ул. Сезнең кызыгыз кайтып җитә алмагандыр шул. Югыйсә сөйләгән булыр иде... Әнә, аның кабере моннан ерак түгел, – диде дә, калтыраган кулы белән бәрәңге бакчасы буендагы калкып торган каберне күрсәтте.

Партизаннар, бер карчыкка, бер ул күрсәткән кабергә карап, нәрсә әйтергә белмичә аптырап калдылар...

Авыр тынлыкны Александр бозды. Ул үзенә генә хас булган җитезлек белән моңа кадәр арттарак торган Санияне халык алдына җитәкләп китерде дә:

– Әйтегез тизрәк: бу карчык нәрсә сөйләнә?! – диде.

Сания байтак вакыт сүзсез торды. Аның күзләреннән чыккан яшь бөртекләре яңа гына күтәрелеп килгән кояш нурларында ялтырый-ялтырый битләре буенча тәгәриләр иде.

– Иптәшләр!.. Әби дөрес әйтә, Борисов яраланган төнне үк... үлде. Без аны шушы бәрәңге бакчасы буенда күмдек, – диде. Бөтен халык баш киемнәрен салды. Ул сүзен дәвам итте. – Үзегез беләсез, безнең эшләр ул чагында тегеләй-болайрак кына иде. Шуңа күрә сафларыбызны таркатудан шикләнеп, мин мәрхүмнең исеменнән сезне йөртә бирдем... Ә командир янына барган булып отрядтан киткән вакытларны, разведкаларда йөреп, сез шартлатасы объектларны күздән үткәрдем, өйрәнә йөрдем.

Ул башка бер сүз дә әйтә алмады. Партизаннар да аны сораулар белән аптыратмадылар. Нәрсә сорарга? Ярты айдан артык отрядның командиры шушы Казан кызы булганы, моннан соң да шулай булачагы болай да ачык аңлашыла иде.

Эчтәлек

Алтын балдаклы абыстай *(повесть)*

***Хикәяләр***

Хатлар язам сагынып

Яшен суккан имән

Сыерчыклар ни дип сайрый?

Гәрәйнең бер җәе

Фирдәвес

Хәвефле сәфәр

Ике капитан

Рәссам кыз хикәясе

Казан кызы

Литературно-художественное издание

*Сафа Сабиров*
(Сабиров Сафа Сабирович)

Барыня с золотым кольцом
Повесть, рассказы

(на татарском языке)

Редакторы *Р.Ә.Заһидуллина*
Рәссамы *Й.М.Вәлиәхмәтов*
Бизәлеш редакторы *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник редакторы һәм компьютерда биткә салучы *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, С.Н.Мифтахова, Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.
Оригинал-макеттан басарга кул куелды 23.11.2004. Форматы $84\times108^{1}/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Futuris» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 19,32 + форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 20,58.
Нәшер-хисап табагы 20,47 + форз. 0,36. Тиражы 3000 экз. Заказ Э-867.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

ААҖ «Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.